ISSN 0206–4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

12.2001





**Кави Нәҗми**

**1901—1957**

# Казан утлары
# Qazan utları

*2001*

# 12

**(950)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Sibgət XӘKİM. Dawıl çəçəklərе. *Şiger* .......... 5
Зиннур ХӨСНИЯР. Терсәк сугышы. *Роман* .......... 6
Клара БУЛАТОВА. Яңа елга—сәгать ярым ... *Шигырьләр* .......... 82
Чыңгыз МУСИН. Үз җырым бар. *Шигырьләр* .......... 86
Фарсель ЗЫЯТДИНОВ. Күзгә кояш тауга сыенганда. *Шигырьләр* .......... 112
Резидә ӘХТӘМОВА. Сөяргә, сөелеп яшәргә. *Шигырьләр* .......... 114
Луиза ЯНСУАР. Барысы да—яратудан!.. *Шигырьләр* .......... 116

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Туфан МИҢНУЛЛИН. Шәҗәрә. *(Драматик хикәя)* .......... 89

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Ак һәм кара кәрәше .......... 119
Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ. Өметләр уята торган әсәр .......... 129

КАВИ НӘҖМИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Марс ШАБАЕВ. Күренекле әдип, җәмәгать эшлеклесе .......... 142
Гомәр БӘШИРОВ. Замандаш турында берничә сүз .......... 145
Афзал ШАМОВ. Кави Нәҗми—«артистка» .......... 147
Гариф АХУНОВ. Әдипнең кинәшләре .......... 149

СИБГАТ ХӘКИМНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Роберт МИҢНУЛЛИН. Аккош күленең ак күңелле шагыйре .......... 153

ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Ак чәчәктәй гомер .......... 163

ЗӘКИ НУРИНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Рәдиф ГАТАШ. Шагыйрьне яд итеп .......... 164

ФӘИЗ ЗӨЛКАРНӘЙНЕҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ

Флүс ЛАТЫЙФИ. Кеше китә—җыры кала .......... 167
Сабыр төбә алтыным *(Ф. Зөлкарнәй белән С. Зыя әңгәмәсе)* .......... 168

КИТАП КҮЗӘТҮ

Эльмира ГАЛИЕВА. Җырлы чишмәләр .......... 177

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Зәки ЗӘЙНУЛЛИН. Олуг якташым... *(М. Акмулланың тууына 170 ел)* .......... 181
Мәгъсум ХУҖИН. Киң карашлы әдип *(С. Җәлалнең тууына 110 ел)* .......... 184
2001 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге .......... 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан .......... 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман З. ХУСНИЯРА «Борьба за жизнь», стихи К. БУЛАТОВОЙ, Ч. МУСИНА, Ф. ЗИАТДИНОВА, Р. АХТЯМОВОЙ, Л. ЯНСУАР.
«Драматургия»: драматический рассказ Т. МИННУЛЛИНА «Родословная».
«Литературная критика»: статьи Ф. БАЙРАМОВОЙ «Борьба контрастов» и А. ГИЛЯЗОВА «Не гаснущие надежды».
«К 100-летию К. Наджми»: Воспоминания писателей современников—Г. БАШИРОВА, А. ШАМОВА, Г. АХУНОВА *(с предисловием М. Шабаева).*
«К 90-летию А. Абсалямова»: статья М. Валиева посвящена творчеству писателя.
«К 80-летию З. Нури»: Р. Гаташ. «Думы о поэте».
«К 50-летию Ф. Зулькарнаева»: статья Ф. Латыфи «Человек уходит—песнь остается», беседа Ф. ЗУЛЬКАРНАЕВА о современной татарской литературе.
«К 90-летию С. Хакима»: Р. Миннуллин. «Поэт светлой души».
«Книжное обозрение»: Э. ГАЛИЕВА рецензирует книгу М. Залялиевой.
«Наш календарь»: статьи о жизни и творчестве М. Акмуллы и С. Заляла.
Слово читателя.
Библиографический список произведений, опубликованных в 2001 году.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Национальная библиотека республики Татарстан; писатель Т. Назмиев.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": Z. KHUSNIAR'S novel «The fight for lifes»; the verses of K. BULATOVA, CH. MUSIN, F. ZIATDINOV, R. AKHTIAMOVA, L. YANSUAR.
"Dramatics": T. MINNULLIN'S dramatic story "The family tree".
"Literary criticism": F. BAIRAMOVA'S article "The fight of contrasts", A. GILIAZOV'S article "Not going out hopes".
"Commemorating the 100 Anniversary of K. Najmi": recollections of writers: G. BASHIROV, A. SHAMOV, G. AKHUNOV (with the preface of M. SHABAEV).
"Commemorating the 90th Anniversary of A. Absaliamov": M. VALIEV'S article devoted to A. Absaliamov's creative works.
"Commemorating the 80th Anniversary of Z. Nury": R. GATASH "Reflections about writer".
"Commemorating the 50th Anniversary of F. Zulkarnaev": F. LATIFI'S article "The song is staying", the talk with F. ZULKARNAEV about morden Tatar literature.
"Commemorating the 90th Anniversary of S. Khakim": R. MINNULLIN "The poet with bright heart".
"Books review": E. GALIAVA'S review of M. Zalialieva's book.
Our calendar: the articles about life and creative works of M. Akmulla and S. Zalial.
Bibliographical list of works issued in 2001 year.
The diary of social and cultural life.
In our covers: the National library of Tatarstan republic; the writer T. Nazmiev.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция жавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-34-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 23.11.2001 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108¹/₁₆.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8219 Заказ А-520
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2001 ел.

## Sibğət Xəkim

### Dawıl çəçəklәre

*Peçən citkən, min bolında yərim,*
*Tuğaylarga künļem tabındı.*
*Ozın, sarı dawıl çəçəklәre*
*Kətep utıra kebek dawılnı.*

*Cir əstennən küpme dawıl uzdı,*
*Bəterelde küpme əyermə...*
*Utıra şomlı dawıl çəçəklәre,*
*Qurqam nikter yaqın kilergə...*

*Qıņğırawlar, sarı qıņğırawlar*
*Sizərlər də dawıl qubarın,*
*Xəbər salıp, uyatırlar təsle*
*Bu tıņğısız cirneņ ulların.*

*Yuq, qupmasın ide qabat suğış...*
*Qıņğırawlar nigə qağarğa?*
*Xalıq cıyına, niçənçe qat cıyına*
*Çın-çınlap ber yəşəp qararğa.*



## Зиннур Хөснияр

# ТЕРСӘК СУГЫШЫ

РОМАН

**Мөхәммәт—пәйгамбәр түгел**

Юл буендагы әрем арасыннан, пырхылдап, ике нәни кошчык килеп чыкты. Алар тургай балаларына да охшамаган, сыерчыктан да бәләкәйрәк иде. Әүвәл, бер-берсен куыша-куыша, күз күреме биеклегендә әйләнделәр-тулгандылар да, шул рәвешле канатларын бераз чарлаганнан соң, кинәт югарыга, аккош каурые сыман ак болытларга таба күтәрелә башладылар. Алар иксез-чиксез күк белән хозурланып туя алмыйлар иде.

Каяндыр икенче бер зур кош пәйда булды. Ул, чыннан да, иләмсез зур. Гайрәтле бөркеткә дә, тилгәнгә дә охшамаган кыяфәтсез дәү кош; аның аяклары да җирдән күтәрелеп киткән вакытында җыеп өлгерелмәгән очкыч-самолет тәгәрмәчләре кебек канат асларына яшерелмәгән, шөкәтсез булып тырпаешып, асылынып торалар.

Ике нәни кошчык һаман биеккә, һаман болытларга таба күтәрелде, ә теге кош, җилкән кебек канатларын иренеп кенә җилпи-җилпи, нәкъ алар турысында әйләнгәләп йөрүендә булды. Һәм кинәт кенә ул котсыз гәүдәсен күккә чөеп җибәрде, күз ачып йомган арада югары күтәрелде, очкан унайдан нәни кошчыкның берсен авызына капты, икенчесен тырнагына эләктерде дә, кыя башыннан егылып төшкән таш кебек, җиргә якынлашты. Төшеп җитәм дигәндә генә кош балаларын мәхбүслектән ычкындырып, ирекkә җибәрде; тегеләре исә, чырык-чырык елашып, болын өстеннән әйләнделәр дә, янә тузанлы әрем арасына кереп югалдылар.

Иләмсез канатлы кыяфәтсез дәү кош алтын кояш нурлары белән чигелгән зәп-зәңгәр күктә үзе генә калды. Бу—аның патшалыгы!

Юлчы егет әлеге галәмәтне күзәтеп бара иде. Ләкин бу хакта исе

---

Зиннур ХӨСНИЯР *(1961)—прозаик, «Таң ата да кич була», «Тәгәри китте язмышлар» һәм башка китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

китеп, шаккатып, уй-фикер йөртә-йөртә нәтиҗәләр ясарга анын исәбе күренми. Күрәсен, кулындагы сумкасы авыр, яисә үз уйлары көчлерәк иде.

Кешеләр, бу Җирнен бай бәндәләре, хәерче адәмнәре, аларнын да йорт-җирсезләре, мулла-мунтагайлары, рухани-чукынилары, наданнары вә гыйлемлерәкләре, шыр тилеләре һәм түгәрәк башлары... сыерлары-сарыклары һәм дунгызлары, шуннан килеп, очар вә сайрар кошлары, туфракта сөйрәлүчеләре, тагын... чебен-черкиләре, кычыткannaры, иманнәре, каеннары, кыскасы, бар җансызлар һәм җан ияләренен анлый алганнары, һаман анларга, белергә, танырга теләмәүчеләре, дөньяны тою әгъзалары белән тоярга сәләтлеләре бер хакыйкатьне һич кенә дә кабул итә алмыйлар: Хак Тәгалә китабында язылганча гына түгел, чын тормышнын үзендә дә ахырзаман күптән, әллә кайчан килеп житкән һәм барчасы да шунда кадалышып, чукынышып, сөешеп-суешып, сатып-сатылып, адашып-саташып, тагын әлләниләр кыланган булып, яшәгән кыяфәт ясап, шуышалар гына, бәргәләнеп кенә яталар ләбаса!

Кемдер фани дөнья тәмугында яна. Кайсылары шул ук җиһаннын оҗмахына эләккән. Ләкин һәммәсе дә бер йорт эчендә. Ул йортны күптән социализм дип тә, капитализм дип тә атамыйлар инде. Ул—ахырзаман җәмгыяте. Бер төшеннән ямап кына куялар, икенче җирдән бөселеп тә чыга. Ары ни булыр, алдагысы, чираттагысы?.. Ахырзаманнын да ахыры булырмы?..

... Кәстүмен ун җилкәсенә салып, ашыкмый-кабаланмый гына Ташсу елгасы яры буйлап сузылган сукмактан туган авылына таба атлаган Мөхәммәт атлы егерме сигез яшьләр тирәсендәге гәүдәгә нык, таза ир-егетне әлеге дөньяви уйларыннан су буендагы комлыкка туплауга җыелган сарык-кәҗә көтүенен ара-тирә кычкырган тавышлары арындырдымы, ул болай да күнелуйларын еш кына Җир һәм Күк арасында чөеп уйнатырга яраткан, тәгәлрәге, ярым хыялый, ярым реаль кеше,—капылт туктап, көтүне күзәтергә кереште.

Иртәгә аларга да көтү чираты житә. Мөхәммәт инде шәһәр кешесе. Мәктәп тәмамлап чыгып киткәннән бирле калада яши. Авылдагы әтиәнисенен ике баш сарыгы, сынар кәҗәләре бар. Әнә шуларны көтәргә чират килеп житкән икән.

Иртәгә анын туган авылы Байтимердә Сабан туе. Ә ул үз теләге белән урман буена сарык көтүен алып чыгачак. Сабантуйга барырга күнеле тартмый.

Мөхәммәт ахырзаман җәмгыяте хакындагы уйларын үзе туктатты. Кыскасы, шартлатып бикләп, бер шагыйрь дусты авызыннан ишеткән сүзләр белән мөһерләп тә куйды:

Йә, житәр. Үчләнмим.
Калганы хакында авыртсын ар башы.

Ар авылы ерак түгел, күршедә генә, ике чакрымлап булыр. Янәшәсендә урыс авылы да бар. Аннан чак кына арырак мари авылы. Кыскасы, бик тә интернациональ төбәк булып чыга икән әле бу!

Аны баягы уйларыннан... фәлсәфәсеннән, дөресрәге, комлы-тузанлы Байтимер юлыннан шактый авыр сумкасын күтәреп, тәпиләп кайтып барганда, арттан куып житкән җинел машина бүлдерде. Олы юлдан читкә тайпылып, Ташсу буендагы сукмакка шуннан сон гына кереп китте ул. Артыннан машиналы тагын берәр авылдашы куып житмәсен дип... тагын узып китмәсен дип.

Тегесе алай выжылдап ук узып китмәде китүен, туктады. Классташы Сәмигулла икән. Өр-яңа «Нива»га менеп кунаклаган. Ул шып итеп туктады да, көпчәк тузаны басылганчы әүвәл ишегеп ачмый торды, аннары, сикереп төшеп, очына-очына, узгынчы машинага утырам дип өметләнгән Мөхәммәт янына килде.

—А-а! Яшьти! Кайтып килешме? Менә мин дә яна машина алып кайтам әле. Казаннын үзеннән үк! «Нива» алдым инде, яшьти, «Нива». Авыл җирендә шәп машина! Түлке мин, яшьти, ачуланма инде, утырта

алмыйм. Өр-яңа әле ул! Нумеры да юк. Беренче итеп хатынны—Рәзифәне—утыртырмын дигән ием. Шулай тиеш икән ул. Мәһирә әби шулай диде. Малай да бар минем, яшьти. Ачуланма инде син берүк. Иртәгә сабантуйда көрешербез. Әле нумеры да алынмаган, яшьти!

Яңа машина, Мөхәммәтне соры тузан болыты эчендә калдырып, Байтимергә таба чапты.

Сәмигулла авылда үзенең такта яру җайланмасын ачып җибәргән. Мәктәптә укыганда бик тә надан, жылак малай иде. Өйгә биргән эшләрне күчертергә сорап тәмам желегенә төшүе әле дә истә Мөхәммәтнең. Үзе гел «бишле» билгеләренә генә укыды ул. Кызык бу дөнья дигәнең: Сәмигулла машинада чаба, Мөхәммәт, әти-әнисенә, күрше-күләнгә дип җыйган күчтәнәчле сумкасын өстерәп, комлы Байтимер юлыннан җәяү тәпили. Югыйсә, бер жылак малай иде. Рәзифә артыннан да жылый-жылый йөрде. Ә Рәзифә... Әйе, рәнжетте бугай аны Мөхәммәт. Шуңа күрә бүген ул хакта искә дә төшерәсе килми иде аның. Хәер, күңелсез хатирәләрне кемнең кабат яңартып торасы килсен инде!..

Юк, гарьләнмәде Мөхәммәт. Вак-төяккә генә һич тә исе китә торган кеше түгел иде ул. Менә иртәгә сабантуе, ә көн нинди шыксыз, салкын, әйтерсең, җәй башы түгел, янадан көз житкән диярсең. Мөхәммәтнең әнә шуңа гына эче пошарга мөмкин. Хәер, кемгә нәрсә, кәҗәгә—кәбестә дигәндәй, кемгә—сабан туе, кемгә—сарык көтүе.

Мөхәммәтнең тагын нәрсәгә эче поша, йөрәген ни талый соң? Әнә, әле өченче көн генә, зур Залда рәссамнарның күргәзмәсе булды. Эшләре исемлеккә кермәсә дә, Залның директор урынбасары, үтә чая, кыскасы, бик булган, үткен ханым—ул әле дәрәжәле сәнгать белгече дә—аны эзләп тапты һәм эшләрен алып килергә кушты. Почмакта буш урын бар икән, аның хезмәтләрен шунда урнаштырасы иттеләр. Мөхәммәт, шатлана-шатлана, рәсемнәрен алып килеп тапшырды. Күргәзмә ачылгач, ни күрсен—зур гына бер эше юкка чыккан!

—Эзләмәгән җир калмады. Урлап китүләре точно!—диде директор урынбасары, әнисе ягыннан татар, әтисе ягыннан яһүд булган Сиринә Самуиловна.

Әнә шул чакта да исе-акылы киткән иде Мөхәммәтнең! Ничек? Кем? Нигә кирәк булган!

Сиринә Самуиловна,—Мөхәммәтнең иҗатына үлеп гашыйк булган сәнгать белгече,—әлеге хәбәрне әйтте дә, моңа бары тик үзен генә гаепле санап:

—Мөхәммәт Уразмәтович! Мин гаепле! Кичерегез дип әйтмим. Тик минем тарафтан махсус эшләнгән дип уйламагыз, зинһар!—дип, елап ук җибәрә язды.

Сиринә Самуиловнаның гаепле түгел икәнлеге болай да көн кебек ачык. Нинди гаепләү ди аны! Әгәр шушы мөлаем ханым булмаса, аны... аның?.. Әйе шул, Мөхәммәт Уразмәтовичның һәрбер эшенә шундук бәя биреп, ин әһәмиятлесе—аны, җае туры килгән саен, һәртөрле күргәзмәләр исемлегенә кертеп, гел ярдәм кылып торучы шул ханым бит инде! Әгәр ул булмаса, Мөхәммәтнең әсәрләре Италия, Франция күргәзмәләрендә урын алыр идеме соң?! Әле күптән түгел генә Мәскәүдәге зур күргәзмәгә Сиринә ханым тырышлыгы белән биш әсәре китте!

—Сиринә Самуиловна, юк өчен борчылмагыз! Сезнең гаеп түгел бу!

Сиринә Самуиловнаның,—Мөхәммәт ана күңеленнән генә «Гүзәл ханым» ди,—матур йөз-кыяфәтендә гел балкып торган кояшны бүген күләгә каплаган, зур, чем кара күзләрендә моңсулык сизелә. Күренеп тора: әлеге хәл Мөхәммәтнең үзеннән бигрәк, бу матур ханымны хафага салган иде.

—Сволочи! Найду, убью!—дип җикеренде ул. «Кара, Сиринә Самуиловна да сүгенә белә икән?!»—дип уйлап куйды Мөхәммәт.

Һәм шулчак ханымны, иннәреннән кочып, тынычландырасы, юатасы килде. Ул үзе дә аны бер туган апасы кебек якын итә, ана бу ханым янында рәхәт тә, тыныч та. Инде утызны түгәрәкләү алдында торган ир

заты булуга карамастан, авыл туфрагында шытып, гап-гади татар гаиләсендә канына сеңгән мокытлык һәрдаим егеткә тышау булды... берничә катлы тышау. Шуның ин юаны, ат арбасына төялгән саламның бастырыгын кыса торган аркан кебек юаны, әлбәттә, кыюсызлык иде. Ул һәрдаим үз-үзенә ышанмау дигән хәерсез хис-гамәл белән аралашып тора, егетнең Ходай тарафыннан индерелгән сәләтенә тулысынча ачылып китәргә ирек бирми, кыршаулап куйган кебек. Мөхәммәт акылы белән моны тоемласа да, шуны җимереп, ватып сындырырлык көч табудан гаҗиз. Әлеге гаҗизлектән туган бушлыкны Сиринә Самуиловна гына тутырып тора, өстәвенә хатын егетне магниттай үзенә тарта иде.

—Кай җиренә кызыктылар икән соң ул картинаның?—дип аптырады Мөхәммәт.

Әле генә еларга житешкән ханым кинәт кабынып, терелеп китте:

—Политический иде ул синең! Җәмгыятьнең асылын сәнгать аша күрсәтү, ул—политика, Мөхәммәт Уразмәтович!

Сиринә Самуиловна, бер карасаң, үзен нәкъ мәктәп укытучысы кебек хис итә бугай. Ул—укытучы, Уразов Мөхәммәт—укучы. Иң алдынгы тәртипле укучысы әле! Мөхәммәт шуны уйлап, елмаеп куйды. Сиринә Самуиловна, имән бармагын—ханымның һәрвакыт буялган озын тырнаклы нәфис бармаклары бүген лакланмаган иде—чак кына өскә күтәрде.

—Кем эше икәнлеген чамалыйм мин. Ну тотсам!.. Беләсең килсә, иң яхшы унбиш эш Мәскәүдә узачак күргәзмәгә сайланып алынырга тиеш иде. Теге ата таракан моны сер итеп мең кат йөзек астында сакласа да, шулай булачагын белдем мин! Ул анда швабра белән рәсем ясаучы киявенең эшләрен төртмәкче!

Мөхәммәт «ата тараканның» кем икәнлеген чамалый иде. Шул җитәкчене таракан итеп күз алдына китергәч, аның кычкырып көлеп җибәрәсе килде. Тыелып калды. Көлемсерәп кенә куйды.

Юкка чыккан рәсемдә югыйсә гап-гади табигать күренеше тасвирланган. Урман алды, су буе күренеп тора, болын сыман җирдә өч кара сыер утлап йөри, дүртенчесе,—анысы кызыл сыер,—читтәрәк. Шул сыерларны биш көтүче көтә.

Мөхәммәт барган җиреннән шып туктап калды. Карале, нәкъ менә шушы урыннар табигате иде ич рәсемдә! Ташсу елгасы яры буенда аякларын салындырып утырып, бер атна тирәсе язган иде ул картинаны Мөхәммәт.

Искиткеч гүзәл табигать күренеше. Юан, сап-сары кәүсәле нарат агачлары, әйтерсең, Ташсу елгасына су эчәргә төшеп килә. Урман алдындагы ачыклыкка бура бурап куйганнар. Юк, юк, наратларның су эчәргә төшүләре түгел бу. Әнә, теге өч нарат,—алары алгарак чыгып үскән,—урманнарыннан аерылып, үзләренең балаларын эзли киткәннәр. Кайларга китеп югалган соң аларның газиз балалары? Әле генә, яна гына янәшәләрендә шаулап утыралар иде. Бураның агачлары бик нечкә күренә. Әллә... шуларны кисеп, каезлап-тунап?..

Ә сыер көтүе нишләп йөри монда? Юк ла, көтү түгел лә! Дүрт сыер нинди көтү булсын инде! Ә нишләп дүрт сыерга биш көтүче?

Зур урманнан бары өч-дүрт кенә төп нарат агачы аерылып чыккан. Көтүе дә көтүгә охшамаган. Тәңгәллек бозылган бит монда. «Табигатьтә тәңгәллек бозылган. Кешеләр тормышында да бозылган ул! Юкса, өч сыерны дүртәүләп көтмәсләр иде! Табигатьтәге тәңгәллек бозылу кешеләр тормышына да йогынты ясаган. Бәлкем, киресенчәдер әле ул! Это точно!»—дип, әллә шаяртып, әллә чын-чынлап шәрехләгән иде картинаны Сиринә Самуиловна. «Бозылган инде, бозылган шул,—дип, үзалдына уйланды Мөхәммәт.—Бозылмаган булса, сабакташым, җан дустым, үзе әйтмешли, колхоз персие Барый Әкбәров авыл каләр авылны тау башына күчерәм дип җенләнеп йөрмәс иде!

Мөхәммәт, авылның сарык көтүен җыеп, иртән иртүк Сай суга таба куып алып киткәндә сабан туена барырга тиешле халыкның күпчелеге йокысыннан да уянып җитмәгән иде әле.

Нәкъ шул чакта Байтимер авылының икенче башыннан районга таба ак «Волга» чыгып чапты.

Көтү чиратта булса да, сабан туе көнне аны көтү мәҗбүри түгел, бер көнгә абзарда да түзә алырлар иде, әлбәттә. Ләкин шунысы бар: сабан туе көнне көтү көтү ике чиратка санала, ягъни икенче юлы син көтмисең дигән сүз. «Гөлчәчәк тә булмагач, нишләп йөрим!» дип уйлаган иде Мөхәммәт.

Ул сарыкларын су буена җыеп алып төште дә, колхоз печәнлеге белән янәшәдәге чирәмлеккә таратып җибәрде. Үзе, кулындагы таягына таянып, елганың аръягындагы урманга таба карап тора башлады. Көтүнең артыннан тагылып йөрисе юк иде. Болын киң, иркен, сарык малы өчен генә монда үлән җитәрлек; тамаклары туеп та, нәфесләре, күзләре туймый икән инде, әнә, колхозныкына керсеннәр. Әкбәровтан куркып торган юк. Барый аннан үзе курыксын, ни дисәң дә куркырлыгы бар бит!

Көтү, чынлап та, чыклы яшел үләнне кетердәтә-кетердәтә, колхоз печәнлегенә таралды. Колхозныкы тәмлерәк иде, күрәсең.

Мөхәммәт, Ташсу буендагы болында япа-ялгызы калгач, малай чагына «кайтып китте». Елга ярына аякларын салындырып утырды да, күңел көймәсен су өстенә «төшереп куйды»; балачак көймәсе, кара сыртлы дулкыннар өстендә җай гына тирбәлә-чайкала, мари урманнары буйлап акты да акты. Көймәдә Мөхәммәт Уразов атлы танылып килә торган рәссам түгел, дулкыннар өстендә Байтимернең Мөхәммәт исемле малае, элеккеге балта остасы, колхозның алтын куллы тимерчесе, хәзер пенсия акчасына карчыгы белән туган авылында көн күреп ятучы, көтү чираты житсә, әнә шулай дүрт күз белән каладагы малаен көтеп алучы Уразмәт аганың бердәнбер улы иде. Исеме Мөхәммәт булса да, ул пәйгамбәр түгел, ул—егерменче гасыр ахыры һәм яна гасыр башында иҗат итүче бер рәссам иде. Бик тә талантлы егет, әгәр «терсәк сугышында» харап булмаса, киләчәге бик зур иде егетнең.

## Мин

Ашыга бу, дип гаепли күрмәгез, серне алдан ук чишеп куярга булдым: мин, Мөхәммәт, урманчы кызы Гөлчәчәкне, урманыннан аерып, шәһәргә алып китү турында хыялланам. Аларның өйләре әнә генә, урман буенда гына.

Безнең балачак та, үсмер вакытлар да Ташсу буенда, шул елгада көннәр буе бака малайлары белән бергә коенып, ярындагы гәрәбәдәй сары комында аунап, чуен кебек каралышып, данлыклы мари урманнарында аюбүреләрдән курка-курка булса да, вакыты житкәч, әүвәл җиләген, аннары гөмбәләрен җыеп узды. Әнә, Кызылъяр өстендәге наратлар да картайган, безнең балачак та Ташсу буйлап еракларга агып киткән; елганың үзе кебек үк әүвәл Илләткә[1], аннан килеп, Иделнең үзенә барып кушылган. Ә Идел исә Каспий диңгезенә коя. Әгәр безнең гомерне шул елга-диңгезләр белән чагыштырырга мөмкин булса, мин малайчакны Ташсу, үсмер чакны Илләт белән чагыштырыр идем. Иделгә кушылган чагымдыр. Тора-бара Каспий диңгезенә дә җитәсе бар бит әле дигән уйлар мине кайчагында шомландыра, күп вакыт әлеге хис, киресенчә, ымсындыра, ашкындыра гына кебек.

Байтимер халкы сарык көтүен гадәттә Наратлы болынында көтә. Мин, әни әйтмешли, Алланың бер кире һәм карышкан бәндәсе буларак, көтүне Сай суга алып төшеп киттем әле. Авыл үзе тау башында, елга үзәненнән биектәрәк булганга күрә, без Ташсуга барабыз дип түгел, төшәбез дип сөйләшәбез. Ташсуның да Сай су дип аталган бер тугайлыгында мин хәзер сарыклар артына тагылып йөрим.

Сай су—Ташсуның ин тирән урыны. Малай чакта без бөтенләй икенче төштә, су өстендә йөзеп йөргән гөнаһсыз сыер тизәкләре белән бергәләшеп,

[1]Илләт—елга исеме.

җәйләү дип йөртелгән урында коена идек. Җәйләү турысыннан узганда Ташсу текә ярга ышыкланып акмый, тигез яр буенда сап-сары кайнар комы да булганлыктан, бала-чага өчен су коенырга ин шәп җирләр иде ул. Хәзер ярлары җимерелеп, ул төшләр күнелсезләнеп калган.

Ташсу да үзгәргән, мин дә картайганмын бугай. Хәер, егерме сигез яшьлек ир-егетнен гаиләсе, ким дигәндә бер-ике баласы булырга тиеш иде бит инде, югыйсә. Әле һаман өйләнә алмыйча йөрим. Гомумән, үземне таркау кеше дип исәплим. Үземә бүген, иртәгә нәрсә кирәклеген беләм, әмма бер атнадан сон ни кылачагымны һич төшенеп бетә алмыйм. Анын каравы берәр елдан ни булырга тиешлеген күз алдына ачык китерәм. Таркау адәм булсам да, максатым бар. Алдан ук әйткән идем инде, урман каравылчысы кызы Гөлчәчәкне Казанга алып китәчәкмен!.. Әгәр шулай булмый икән... йә эчүгә сабышачакмын, йә наркотиктан дөньянын кызыгын табармын кебек. Бер дә булмаса, мәгънәсез тормыш алып барып, анда-санда рәсем-картиналар ясаштыргалап, шулардан килгән акчага иректе, бәйсез, гомумән, дилбегәсез тормыш кичерәчәкмен. Кыскасы, башкага өйләнмәячәкмен!..

Кискенрәк әйтелде бугай, нәзерем булмасын тагын!..

Алла сакласын!..

Гөлчәчәк турында да ашыгыбрак әйтеп ташладым ахырысы, син дә, укучым, ашыктыра күрмә, чөнки ул максатыма гомерем буе,—ундүрт яшьтән алып исәпләсән, ундүрт ел килеп чыга икән,—барам бугай инде. Әлбәттә, кыен чаклар да күп булды, аптыраганнан чукынасы килгән вакытлар да булмады түгел... Ләкин алай гына җинеллек килсә иде ул! Чукынсан, урыс буласын да куясын инде. Шул гына... Йөрерсен аннан сон муенына салкын тәре асып...

Ундүрт яшемдә шофер булырга хыяллана идем.

Әти белән әни төне буе йокы күрмиләр, бер төнне билдән кар ерып колхоз басуына саламга барсалар, икенчесендә ферма янындагы сенаж чокырына китәләр. Маллар күп. Сыер, тана, унҗиде баш сарык, өстәвенә сыерыбыз ел саен бозаулап тора. Ашатырга, һәммәсенә җиткерергә кирәк, тамаклары ачыкса, ярты авылны күтәреп, акыра-бакыра башлыйлар. Ә курмы машина белән кайтмый. Колхоз мин белгәннән бирле үләксә хәлендә. Басудагы салам-печәнен, фермасына ташырга да хәленнән килмичә, җир өстендә черетсә-черетә, ләкин колхозчысына бирми. Әни җәй буе колхоз эшендә сәнәк-көрәк күтәреп йөрсә дә, әти данлыклы балта остасы, тимерче булса да... Ә мин әле бәләкәй. Дөрес, әти-әнигә ияреп, салам урлауга йөрергә ярый башладым инде. Тик күтәреп кенә күпме алып кайтасын! Мәсәлән, сыек җилкәм өстендә кайткан сенажны үзе комсыз, үзе чырсыз танабыз бер кабуда юк итә дә куя. Аннары, ашарга сорап, тагын паровоз кебек үкерә башлый.

Тимер юл станциясе янында тормасак та, аталары машина-тракторда эшләмәгән минем кебек малайларнын лапаслары паровоз депосы кебек: кемнен кыш чыккан үгезе үкерә, кемнен сыер-танасы акыра. Авызларына, паровоз мичене тыккан шикелле, утын-фәлән салып булмый шул инде. Печән сорыйлар, башак кирәк ул җүнсезләргә!

Нәкъ шул туймас тамаклар аркасында шофер булырга хыялланып йөри башладым да инде. Саламын, печәнен дә машинасы белән генә алып кайтып тондырыр идем дә ашасыннар, тыгынсыннар иде шунда! Юк ла, тыгылмасыннар тагын! Тыгына-тыгына ашасалар йә тыгылып куярлар. Дүрт апа бар бит әле. Шулар кияүгә чыга-нитә калса дип асрыйбыз без ул хәтле малны. Ичмасам, кыз бала булып тумаганмын шунда, дүрт кыз янына сыяр идем әле, болай иттереп колхоз саламын урлап йөрмәс идем, йоклар идем бер рәхәтләнеп. Алай дисән... әти белән әни җәлке инде. Икесе генә азапланачаклар бит! Мин алып кайткан өлеш әлләни күп булмаса да, барыбер иш янына куш булып тора әле ул. Әни шулай дип башымнан сыйпый. Әллә үсендерүе, әллә чынлап та шулай уйлый.

Ыштан туздырып мәктәпкә йөрүем, бигрәк тә анда алган белемнәрем

дә шоферлык кына иде. Шофер була алсаң, шул да бик житеп тора инде. Әти әйтмешли, барыбер үз борыныңнан да югарырак сикерә алмассың. Кушаматыбыз «болан» булса да сикерергә яратмыйм мин. Сикерергә яратмаган кебек, математика дәресләрен дә женем сөйми. Ярый әле математиканы Зөләйха апа укыта. Тәрбия эшләре буенча завуч ул безнең. Чиреккә «икеле» чыгармагыз дип, аның артыннан ялынып йөрисе урынга, классларны бизик яки стена газетасы чыгарыгыз дип, үзе арттан йөри. Ә рәсемгә кул ята минем. Шулай дип кешеләр әйтә. Әйтмиләр икән,—фикерләре үзләренә булсын,—оста икәнлегемне үзем дә бик яхшы белеп торам. Рәсем укытучысы,—сабакташым Барыйның бертуган абыйсы Һадиулла,—бик якын итә. Миннән рәссам ясамакчы була ул. Әллә нинди акыллы китаплардан укыган акыллы сүзләрне тукый-тукый башымны катырып бетерә. Имеш, искусство начинается там, где начинается чуть-чуть. Янәмәсе миңа табигать тарафыннан хәтта «чуть-чуть» кенә дә бирелмәгән. Күбрәк тамызылган икән. Ялкауланмаска гына кирәк. Чуртыма хажәте бар иде рәссамлыгыңның, дип уйлыйм эчемнән генә. Ак кәгазьгә төшергән трактор яки машина белән безнең паровоз депосы чаклы лапаска бер йөк печән түгел, шырпы салып та алып кайтып булмый. Һәм монын шулай икәнлеген Һади абыйга ничек аңлатасың! Маңгаенны парта кырыена бәрә-бәрә аңлатсаң да аңламаячак ул аны! Чөнки аның әтисе колхоз рәисе. Салам урларга йөрми алар. Урламый гына алып кайта. Көпә-көндез. Ә йөге белән көндез урлаган кеше каракка исәпләнми дә, бездә шулай: култык астына кыстырасың икән, ул вакытта син чып-чын карак, угры, бур, тагын әллә кемнәр әле. Кыскасы, эләгәсең икән, урының өтермәндә. Ә өтермәндә, күрше Самат абый әйтмешли, гел макарон гына да ашатып тормыйлар. Ул белсә белә инде,чөнки хатынына кырын караган саен, гел унбиш тәүлектә бушка ашап кайта ул.

Рәсемне болай гына ясыйм мин. Мәктәп директоры Фәрит абый, тәрәзә ваткан саен, «мунча» кертмәсен дип тә ясыйм. Андый чакта завуч Зөләйха апа яклый, Һади абыйның яклавы бигрәк тә тәэсирле була. Ә Һади абыйның сүзен, директор булсаң да, тыңламый хәлең юк, әтисе—персидәтел!

Үзеңнән нинди сүз көткәннәрен белмәсәң, чын дөресен әйтүе кыен диләр. Ә мин сөйлим дә сөйлим, егерме сигез ел эчендә үзем белән ни булганын түкми-чәчми, курыкмыйча дөресен сөйлим. Чөнки болар чит кеше турында гайбәт түгел, үзем турында сөйлим бит.

Һади абый, беркөнне рәсем дәресендә эленке-салынкы гына утырганымны күргәч, үземне генә алып калып, калын китап белән «салам чүбеге» тулган маңгайга кундырып алды да: «Син, малай актыгы, туган ягынны яратасыңмы?»—диде. Таптын сорар нәрсә, туган ягын кем яратмасын инде! Яратмасам, монда туып та тормаган булыр идем әле. «Безнең якларның табигате искиткеч гүзәл шул ул! Без шуны,—бу очракта өмет синдә,—бар дөньяга күрсәтергә тиешбез, белденме?»—дип дәвам итә бу.—Күрсеннәр, шаккатсыннар һәм безнең якка ял итәргә дип, бар халык агылсын! Үзебезнең Ташсу буйларыннан, урманнан зоповедник ясыйбыз. Ял итәргә теләүчеләр күп булгач, доходы була диган сүз! Шуннан соң безнең яклар баеп китәчәк!»

«Монысы да нәкъ перси атасы кебек хыялый икән,—дип уйлыйм мин.—Заманында бабаң тау башында утырган авылны үзәнгә күчереп утырткан бит инде. Зират хәтле зиратны каберләре белән бергә күчерттергән! Хәзер бәрәңге бакчаларын су басып интектерә!

Бу сүзләрне телем белән әйтмим.

Һади абый башка кундырган теге калын китапны ачты да, үзенә кирәкле битен эзләп тапкач, борыныма төртте. Мә укы, янәсе. Борын белән укый алмыйм ич инде дигәндәй, карышып, башымны күтәрәм, акыллы фикерләрне Һади абзый үзе укып бирә: «Лондонские туманы не существовали, пока их не открыло искусство,—дигән Оскар Уайльд абыең.—Без дә үзебезнең якның матурлыгын сәнгать ярдәмендә ачып биреп, дөньяны шаккатырырга тиеш! Аңладыңмы, малай актыгы! Әфлисун гына ашап яшәргә тиеш бу як халкы. Ә хәзер бәрәңгегә дә туймый, бакчалары суда утыра»,—

ди ул, якын итеп, инемнән кочаклап. Анладым, билгеле, борын белән төртә-төртә анлаткач инде... Тагын бер нәрсәне анладым әле: безнен Ташсу буенда курорт ачып, шунда ял итәргә киләчәк берәр интеллигент кыз-хатынга өйләнергә телисендер әле. Авыл кызлары ярамый бит сина. Ярасалар, ялгыз ата каз кебек утыз яшенә чаклы йөрмәс иден болай!

Баш гел кире якка эшли, карышкан тек карышкан, үҗәт, кире беткән малай инде мин. Югыйсә, Һади абый турында шулай начар уйлыйлармы сон? Әйбәт кеше бит ул, чөнки мине үз итә!..

Сабакташ булса да әйтәм әле, Барыйлары гына үҗәт аларнын. Алай ук җүнсез түгел ул түгелен, тар мангаендагы уйлары гына җүнсез кайчакта.

Һади абыйсынын җибәргәнен мәктәп капкасы янында көтеп торган икән. Дус бит, мәктәптән бергә кайтабыз. Кызыксынуы да көчле инде, әлбәттә. Дус булса да көнче ул.

—Абый сине нигә алып калды?

Барыйнын беренче соравы шул булды. Кәефкә болай да кырау төшкәнрәк вакыт иде, үртәргә керештем:

—Синен турыда борчыла ул, беләсен килсә! Гел «бишле»гә генә укып, безнен Барыйнын башына кан саумаса ярый инде, ди. Син дусты бит, әйт әле шуна, артык көчәнмәсен, яраткан энекәшемнән колак кагасым килми минем, ди.

Барый, әлеге сүзләремә ачуы килеп, кулындагы ялтыравык күнле портфеле белән берне ямамакчы иде, минем үзеннән көчлерәк икәнлегем исенә төшеп булса кирәк, ул, кырыйга борылып, черт иттереп төкерде дә, үчен сүз белән алырга уйлап:

—Бу затлы портфелемә синен кебек «ике»ле салып йөри алмыйм бит инде мин!—дип телләште. Кайсы яктан суктырырга кирәклеген белә перси малае! Анын кулында өр-яна портфель, миндә исә эти элек өтергеләр салып йөри-йөри тузып, кыршылып беткән арзанлы букча.

Анын сүзләреннән сон эчем кендек турысыннан авырттырып борып куйса да бирешергә һич исәбем юк:

—Мактанмасана! Беләсен килсә, эти хәзер өйдә бака тиресеннән портфель тегеп утыра! Суда да батмый ул, беләсен килсә! Бу синен суда бата бит! Әйдәле, әйдә, синен бу әтәч тиресеннән эшләнгән портфеленне суга салып карыйк әле! Ике күзем чәчрәп чыксын, таш кебек төпкә китәчәк ул! Менә күреп торырсын!

—Баткан ди сина, бар!

—Әтәч йөзә белми ич ул! Шулай булгач, портфелен бата да бата инде синен!

Без өч чакрым араны шулай үртәшеп, телләшеп кайтабыз да авыл башындагы күпергә килеп җиткәндә, янадан дуслашып беткән булабыз. Бүген дә Барый мина ин якын дуска гына әйтелә торган бер сер әйтте. Дөресрәге, әйтеп бетермәде, күнелне генә ымсындырып куйды.

—Бу шимбә урманга барабыз, бер кызык күрсәтәм мин сина!

—Нинди кызык?—дип, күпме генә телен чишәргә азапланып карасам да, әйтми, Һади абыйсынын мине нигә алып калганлыгын әйтмәгәнгә үч ала, сары баш!

Барыйнын чәче урысныкы кебек сары, йөзе кызгылт иде. Ачуым килгән чакларда: «Мунчала баш! Мунчала!»—дип үртим. Ул мина: «Болан!»—дигән кушаматымны исемә төшерә. Ә аларнын кушаматлары юк. Авылда һәммә кешенен дә кушаматлары бар, ә Барыйларныкы юк. Күрәсен, персидәтел кешенен кушаматы булмый торгандыр инде. Кушаматсыз бер ялгызы ятим булып, кангырып йөрмәсен әле дип, «мунчала»ны Барыйга үзем тактым. Барыйнын үзенә генә ошап бетми, сабакташларга бик ошый ул ошавын.

Күршеләр булганга микән, Барый нәкъ минем кебек үк кире-үҗәт иде. Нинди кызык икәнлеген әйтми бит тәки. Әйтер, әйтер, хәзер әйттерәбез аны дип уйлап бетердем дә... уйлаганны эшләргә дә кирәк бит инде: Барыйнын муеныннан каптырып алып, башын җиргә таба бөктем.

—Әйтмәсәң, күпердән очырам бит хәзер!

Тел чиштерү әмәле шәп минем. Барый шундук бирелде. Прәннек ашап кына көч жыеп булмый ул, кара ипи ашарга да кирәк бераз.

—Бу шимбәдә урманга барабыз. Гөлчәчәк белән Гөлйөзем янына кунакка!

Муенны тагын да катырак кыса төштем:

—Нинди кунак ул? Күтенә Ярулла абзыйдан тоз белән аттырасың киләмени!

—Без качып кына, шыпырт кына. Хәзер сорама, калганын шунда баргач, үзең күрерсең.

Ул кызларның исемен ишетү тынычландырып җибәргән иде, мин, «келәччәм»не ычкындырып, Барыйның муенын «ирекка җибәрдем».

—Әйдә, Барый, теге колонкага хәтле минем жилкәгә атланып кайтасың киләме?

Барый буйга шактый калыш булганлыктан, минем өчен аның бернинди дә авырлыгы юк, дустымның күңелен күрәсе килгәндә бик еш шул тәкъдимне ясый идем. Барый тешләк, буе Наполеон кебек кәтүк кенә булса да, телгә бетәшкән адәм иде. Бик каты ачуы килгәндә аның озын теле аеруча зәһәр һәм кычытканлы була. Ә бүген аның ачуы килү өстенә, үтереп муены да авырта булса кирәк, сүзләре белән минем маңгайга аллай шәп чәпәде ул! Күпер астына мәтәлә яздым, билләһи. «Әйдә, жилкәгә утырасыңмы?»—диюгә, Барый, авырткан муенын ышкый-ышкый, бер генә сүз әйтте:

—Ишәккә атланып йөрмим мин!

Шул мизгелдә без, Барый белән кочаклашып,—мин сугып җибәрәм дигәндә, ул бер кулы белән букча каешыннан эләктереп өлгергән икән,— икебез дә күпер астына очтык.

Шимбә көн житкәндә, без ике күрше, Барый белән Мөхәммәт, аерылгысыз дуслар идек инде. Бүген кич урман каравылчысы Ярулла абзыйлар катына барырга тиешбез. Үзе чакырмаса да, Ярулла абзыйның игезәк кызлары безне, койрыксыз әтәчләрне, магниттай тартып тора.

Ул кызлар дип, хәтта кабырга сындырган малай мин!..

Барыйның әтисенең энесе Сибгат абый ел да урман каравылчысының аланлыктагы печәнен чабарга булыша һәм шуннан үзенә дә шактый өлеш чыга иде. Узган ел печән аеруча котырып уңды. Ярулла Сибгат белән бергә әтине дә дәште. Елга буйларыннан кырып йөргәнче, кыш ашатырлык печәнен булыр дигәч, чабылган печәнне киптереп, чүмәләгә салырга дип, әти үзе белән мине дә алды. Сибгат абый энесе Барыйны ияртте.

Урман урман инде! Рәхәт анда. Кигәвеннәре, усал чебеннәре дә булмаса менә...

Өлкәннәр печән чапкан арада Барый белән рәхәтләнеп жиләк ашадык.

Әбәт тирәләрендә урманчының ике кызы төшке аш алып килде. Болар,—безнең тирәме, әллә яшьрәкләр, берсеннән-берсе матур жиләк кебек ике игезәк кыз,—тынычлыгыбызны алдылар. Алар килгәнче, әтиләр чапкан печәнне тиз-тиз генә таратып ташлап, агач башында тукран куркытып, маймыл шикелле ботактан-ботакка сикерә-сикерә тиен куып йөргән малайларың кинәт житдиләнеп калды. Югыйсә, әле борын астына сынар бөртек төк тә чыгып өлгермәгән, ә үзебез кисәк кенә үзгәрдек тә куйдык. Әти әйтмешли, менә сина табигать балалары!..

Кызлар үлән яфрагындагы чык тамчылары сыман охшашкан да, бер тамырда үсеп икесе ике төрле каен жиләгедәй бер-берсенә охшамаган да. Хәтта игезәк булсалар да.

Мин учымдагы жиләкләрне Гөлйөзем атлысына сузганымны сизми дә калдым. Югыйсә, икесенә дә тигезләп бүлеп бирәсе иде каңә! Тик нишлим, жиләкле кулымны Гөлчәчәккә таба сузарга батырчылыгым житмәслеген нindidер эчке тойгы белән чамалап өлгергән идем, кулларым калтырар, ә үзем уч төбемдәге жиләкләр кебек кызарырмын төсле иде.

Гөлчәчәкнең каен жиләгедәй алсу иреннәре жинелчә генә дерелдәп

куйды, ул зуп-зур, кап-кара күзләрен тагын да зуррак ачып, нишләп мина җиләк юк дигәндәй, аптырап карады да, аннары әле тагын бер мәртәбә күз сирпеп алды. Гәүдәм буенча кырмыска көтүе чабышып узды дип торам, өстәвенә шунын артыннан ук бөтен җанымны авыр халәт биләде, авызым кибеп, телем аңкауга ябышып калды. Мин, ялгышканымны аңлап, җәһәт кенә хатамны төзәтмәкче булам, аяк астына күз ташладым: җиләк күп, ләкин алары пешмәгән әле.

Бәлки, минем үземә генә шулай тоелгандыр, чөнки Гөлчәчәк тамчы да үпкәләмәгән икән: ул учындагы кура җиләкләрен, төгәл ике өлешкә бүлеп, әүвәл миңа (мин Барыйга караганда шактый читтәрәк тора идем),— аннан соң гына Барыйга суздьі.

Кара күзле, алсу йөзле бу кызлар үзләре дә пешәр-пешмәс җиләк кебек иделәр. Икесе дә пардан киенгән, ак ситсага төшкән кара чәчәкле күлмәкләре янәшәдәге пар каеңга охшап тора. Борыннары уймак сыман гына, әйтерсең, бу матур йөзләрдә борын да булырга тиеш бит инде дигәндәй генә утыртып куелган. Гөлйөземнең иреннәре югарак, Гөлчәчәкнеке калынрак та, алсурак та. Кызларның буе безнекеннән чак кына кайтышырак. Төгәлрәге, минем колга буй белән Барыйның кәтүк буе үлчәме арасында. Гөлчәчәкнең ирен өстендә, сул яктарак, канәфер төсендә матур, кечкенә миңе бар. Шундый ук миң Гөлйөземнең нәкъ уң бит алмасына кунган.

Безнең авылда мондый ук шомырт кара күзле кызлар юк, барысы да йә минеке кебек яшькелт яисә канәфер төсендәге күзлеләр.

Дөресен генә әйткәндә, мин урман аланында кызларның йөз-кыяфәтләренә җентекләп игътибар итеп, аларны энә күзе аша үткәреп тора алмадым инде. Аерылышкач кына, тере булып, аларның йөз-сыннары аерымачык күз алдыма килде.

Менә сиңа мә: мин, бүтән чакта телемә шайтан төкергән күп сүзле малай, телсез-өнсез калган идем. Урман аланында монарчы кызлар белән күрешмәгәнгәме шунда...

Гөлйөзем игезәк туганына караганда кыюрак, чаярак күренә. Шуңа да Барый күбрәк аның белән сөйләшергә тырыша:

—Аю-бүреләрдән курыкмыйсызмы соң сез?

Гөлйөзем, ялт кына гөлҗимеш куагы төбенә чүгәләде, аннан ике көпшәле мылтык тартып чыгарды.

—Менә.

Без «аһ» иттек. Икебезнең дә монарчы мылтык күргәнебез юк иде. Чын мылтык, зур, авыр мылтык, түтәсенә тасма уралган, күрәсең, шул төшеннән ярылып киткән булгандыр.

Гөлчәчәк, мылтыкны нигә күрсәттең дигәндәй, туганына шелтәле караш ташлады да, аннан соң, эш узгач соң инде, дигән кыяфәт белән янәшәдәге каен агачына сөялде.

Мылтык күргәч, әсәренеп киттем. Тотып та карыйсы килгән иде— горурлыгым комачаулады, кызлар каршында уенчыкка кызыккан бала-чага хәлендә каласым килмәде, телем дә һаман аңкауга ябышкан килеш иде әле. Җәһәт кенә алан читендә үсеп утырган озын нарат агачына таба киттем, игътибарны башка нәрсәгә юнәлтү иде исәбем. Агачның очында ук тиен сикергәли иде. Шул тиенне тотып Гөлйөземгә бүләк итәсем килеп китте.

Агач башында шәп йөрим, нәкъ маймыл кебек. Барый, кул-аяклары кыска булгач, минем сымак ук булдыра алмый, калышмаска тырыша үзе. Тиен, әлбәттә, агач кәүсәсенә орынуга, җәһәт кенә янәшәсендәгесенә сикереп, күздән югалды. Барыбер менәм! Өстәвенә күптән түгел Тарзан турындагы кино да караган идек.

Нарат хәйран биек. Иң очтагы бер ботакка менеп атландым. Алан тагын да бәләкәйләнеп калды. Кызлар да кеп-кечкенә булып күренәләр. Аларның күзәтеп торганлыкларын күрәм бит, шуңа күрә шаккаттырасым килде, озак уйлап тормыйча, янәшәдәге наратка сикердем. Куллар, йөзләр тырналып бетеп, бер очлы ботак чак кына күзне төртеп тишмәде, барыбер агачка эләгеп кала алдым. Астагылар шаккатып карап торалар бугай. Хәтта

сокланыптыр да. Бигрәк тә Гөлйөземнең исе киткәндер! Бу тойгылар миңа рәхәтлек бирә, янадан-яна батырлыкларга ымсындыра. Агачтан бер күркә өзеп алдым да, Гөлйөземнең кай төштәрәк басып торганлыгын чамалаганнан соң, аны аска таба аттым. Тагын агачтан агачка сикерәсем килде. Теләгән нәрсәне эшлим инде мин анысы. Сикердем дә... Һәм бу юлы эләгеп кала алмыйча жиргә мәтәлдем.

Ярулла абзый өендә аныма килгәндә ничә кабыргамның сынганлыгын белерлек хәлдә түгел идем әле...

* * *

...Бүген шимбә, без Барый белән урман каравылчысы өенә кызык карарга барабыз. Барый әйтмәсә дә, урманчы кызларын күптән (аз дигәндә ел ярымлап булыр) күрәсем килеп йөри иде. Башта кабырга сындырган «батыр» малай буларак күзләренә күренергә оялып йөрдем: алар миннән көләрләр кебек иде. Көлгән чагында, Гөлйөземнең матур кара күзләре чак кына кысыла төшеп, шул серле күзләрдә мыскыллы караш та чагылса, беттем, үләм, бүтән яшәмәячәкмен! Гөлчәчәк, бәлкем, көлмәс тә. Хәер, шайтан белсен, кызлар көләргә ярата инде алар...

«Мәхәббәт—иң соңгы, иң көчле бала-чага авыруы», дигән кемдер. Ул акыллы башның әлеге сүзләрен ул чакта белми идем, ишетмәгән идем әле.

Мөгаен, балачак белән саубуллашу вакыты булгандыр ул. Үзебезнең авылдагы кызларга, хәтта көн саен аралашып яшәгән кызларга карата йөрәктә беркайчан андый сәер, ят хиснең кабынганы булмады ич?.. Бәлләһи менә!.. Күрше кызы Алмазиянең—без бер сыйныфта укыйбыз—сәгать ничәдә йокларга ятканын да, иртә белән нәрсә ашаганын да, сөтле аш яратмаганын да, зәңгәр чәчәк төшкән күлмәк өчен апасы белән сатулашып, төне буе мендәр чылатып чыкканлыгын да, аның гөлләр үстерергә яратканлыгын, өендәге роза гөле сулгач, тамактан калганын да белә идем.

Мәхәббәт дигән олуг хиснең килүен мин ерактан көтә идем. Бер дә булмаса, хет күктән ишелеп төшсә төшсен, тик безнең авылныкы гына булмасын. Безнең авыл кызлары—безнең авыл кызлары инде. Алар да «болан» кушаматлы Уразмәт малае икәнлегемне белә, апаларымның төпчек энекәше дип кенә карыйлар, тик алар күңелемдә ниләр кайнаганын мәңге белә алмаячаклар...

Чын мәхәббәт өрәк кебек була микән әллә ул? Бар кеше дә аның турында сөйли, әмма берәүнең дә күргәне яки орынып караганы юк!..

Мин—Байтимер Тарзаны, әни әйтмешли, жүнгли маймылы—ул моны яратып, исән-сау калганыма сөенеп әйтә—аныма килгәндә Ярулла абзыйлар өендә йомшак урын-жирле тимер караватта чалкан ята идем. Яныма кешеләр жыелган: әти, Сибгат абый, хатыны белән Ярулла абзый үзе, бераз читтәрәк, зур батырлыклар кылырга сәбәпче булган шомырт кара күзле ике кыз. Күзләремне ачкач, барысы да жинел сулап куйдылар.

Барый, машина алып килергә дип, авылга чапкан икән. Ул килгәнче, берәр сәгать чамасы, Ярулла абзыйның сагызлы түшәменә карап тик яттым: кузгалмаска, торып йөрмәскә кушылган иде. Имеш, башта «землетрясение» булырга мөмкин. Күнелең болганмыймы, дип сорый-сорый тәмам жәлегемә төштеләр.

Өлкәннәр таралгач, янымда калган ике кызга «землетрясение» турында әйткән идем, алар, шуны ишетүгә, тәгәрәделәр генә; «землетрясение» түгел, «мозготрясение» яки «сотрясение мозга» була икән ул. Димәк, минем баш тулысынча эшләп бетерми икән әле. Көлеп аргач, Гөлйөзем беравык миңа төбәлеп карап торды-торды да, аннан соң почык борынын жыерып:

—Малай-шалай... агач башында йөрмәсәң. Бue үскән, акылы үсмәгән,—дип куйды. Аның бу сүзе миңа бер дә ошамады. Гөлчәчәккә дә ошамаган икән, ул туганының беләгеннән тотып, ишеккә таба борды.

—Эч пошырып торма әле монда!

Аның бу сүзләреннән бик тә күнелем булып, елыйсыларым килеп

китте, тик яшь күрсәтү түгел, суламаска да тырышып, эчкә һава жыям диеп киерелгән идем, авыртуга түзә алмыйча, ыңгырашып жибәрдем. Кабыргамны нидер чәнчеп алды. Гөлчәчәк яныма ук килде.

—Кай жиреӊ авырта?

Кыз кечкенә йомшак кулын мангаема куйды. Мин югалып калдым. Шул мизгелдән Гөлчәчәк аеруча якын булып китте.

Ә Гөлйөзем? Һай, жавап көтмәгез: бу сорауга батырып кына жавап та бирә алмыйм икән бит! Күнел һаман иләс-миләс. Чынлап та, кайсысына күбрәк тартылам соң әле? Шушы иләс-миләслегем киләчәктә үз башыма гына булмаса ярый инде...

Жәйге көн минем буй кебек озын булса, төне Барыйныкы сыман кыска. Көтүләр кайтып, сыерлар савылып, күрше кызлары кичке уенга чыгарга дип, нәкъ көзге янында бөтерелгән вакытта без, ике дус, кәжә бәтиләре кебек черт-черт теркелди-теркелди, урман буена, каравылчы өенә таба юл тоттык.

Барый, мунчала тәре, Ташсуны кичкәндә минем жилкәгә атлангач кына (ыштанын салса, кичке елга суы салкын, салмаса, балагы суга тия) серенеӊ бер читен генә ача төште: бүген Ярулла абзый хатыны мунча яга икән, үзләре кереп чыкканнан соӊ мунчаларында төн буе урман кызлары юына икән. Нәкъ Такташ шигырендәге урман кызлары ди. Үзе, кәтүк тәре, жилкәмдә утырган килеш, хисләнеп китеп, аяк үкчәләре белән күкрәккә төя-төя, кычкырып, шигырь укырга тотынды.

Шул урманда
Үскән фәрештәдәй кыз бала,
Жирдә түгел, күктә, гарештә дә
Булмаган бер генә тиӊ ана.

Урман биргән аӊа матурлыгын,
Күлләр саф суларын сипкәннәр.
Гөлләр, йоклаганда, яшрен генә
Иелеп-иелеп аны үпкәннәр.

Әгәр шигыре ошамаса, мин аны су уртасында ук жилкәдән чөеп төшерә идем, билләһи! Шигыре әйбәт. Аны Барый язмаган, аны Такташ язган.

Шигырь сөйләп йөрү кызлар эше дип уйларга гадәтләнгәнгә күрә, моӊа төкереп тә бирми идем. Соӊгы араларда, урманчы кызлары белән танышкач, минем ул фикерләрем жилләбрәк тора әле: исәп тамырдан үзгәрергә. Әдәбият дәресләрен монарчы бигүк өнәмәсәм дә, укытучы Мәдинә ападан китаплар сорап торып, мин дә шигырьләр ятлый башлыйм әле. Аннан соӊ... Ярулла абзыйның йорты каршысындагы иӊ озын нарат башына менеп утырам да сөйли башлыйм:

Таӊ жилләре анын, исә-исә,
Озын чәчкәйләрен тараган,
Төне, ае, төннәрдә йокламыйча,
Ана булып күктән караган!

Таӊ жилләре кайсысының чәчкәйләрен тараган соӊ әле: Гөлчәчәкнекенме, Гөлйөземнекенме? Шайтан белсен!..

Урман каравылчысының мунчасы шактый читтә. Каралты-кура өчен урын иркен булгач, хужа жирне кызганмаган, ат абзары гына өй янәшәсендә үк салынган. Атларга угрылар кызыкмасын диптер инде.

Без мунча тәрәзәсе каршындагы юан каен кәүсәсенә сыендык. Мунча эчендә ут юк, дөм караӊгы. Мин, беркавем күз бәбәкләрем авыртканчы көчәнеп, караӊгы мунча эчендә берни шәйли алмаганыма гажиз булып, терсәгем белән Барыйга төртеп алдым. Без һәрвакыт шулай аӊлашабыз: буем озын булгач, терсәк очы Барыйның нәкъ колак төбенә туры килә, Барыйның терсәге минем бөерләр турысында, ул шунлыктан... Күл күтәрел...

сукмагач, айканмагач, берәү дә безне күрми, нигә сугышасыз дип, әрли дә алмыйлар. Барый бөеремә жинелчә генә төртеп: «Ашыкма, хәзер, хәзер»,—дип, мине тынычландыра.

Алдамаган икән: беравыктан мунча эчендә гөлт итеп ут кабынды. Аулак булгач, тәрәзә пәрдәсен дә тартып тормадылар, ап-ак итеп акшарланган мунча миче дә, ләүкәдәге ләгәндә яткан себерке сабы да аерымачык күренеп тора. Ярулла абзый мунча тәрәзәсен артык биек иткән, мунча эчен тагын да яхшырак күрим дисәң, агач башына ук менәргә туры киләчәк. Менә берзаман эчтә бер шәүлә чалынып алды. Ике шәүлә! Шәүлә генә түгел, ап-ак иң башлы ике кыз! Шәрә урман кызлары! Минем кинәт авызым кипте: телемне әйләндерә алмас булдым. Күрдеңме инде, күрәсеңме дигәндәй, терсәк очы белән янәшәмдә мыш-мыш сулап торган Барыйның колагына төртеп алдым. Кисәк кенә бөерем авыртып киткәннән Барыйның: «Күрдем, мин сукыр түгел лә!»—дигән ымын аңладым.

Без ул чакта тормыштагы шактый кызык хәлләрнең кендектән астарак булганын да чамалый идек инде: агач башына үрмәләдек. Мунча эче нәкъ кинодагы кебек күренде. Икебезнең дә авыз куышлыгында сулар күптән кибеп бетеп, тирләп-пешеп чыктык, гәүдәләребез менеп кунаклаган каен агачының яфраклары сыман дер-дер килә: яфраклар безнең еш-еш сулаудан гына шыбырдаша бугай.

Тәрәзә янында урман кызларының берсе, гәүдәгә чак кына калкурагы, күбрәк кайнаша, аны танып, чак кына: «Гөлйөзем бит бу!»—дип кычкырып җибәрмәдем. Шөкер, тыелып кала алганмын, кычкырсам, кызны да, аның шәрә матурлыгын да куркытачак идем.

Барый, хисләнеп китеп, саксызрак кыймылдап куйдымы, әллә каенның очына ук үрмәләмәкче булды инде, ул утырган ботак шартлап сынып, тын урман эчендә мылтык аткандай яман каты тавыш чыкты. Барый бер кулы белән янәшәдәге ботакка ябышып өлгергән иде, әмма озак асылынып тора алмады, шапылдап, агач төбенә барып төште. Мунча эчендә ут сүнде.

Бер-бер артлы мылтык гөрселдәгән тавышка Ярулла абзыйның артыбыздан ни дип кычкырып калганын һич тә ишетерлек түгел. Күрмәгәннең күрәсе, күргәннең качасы килә дигән әйтем бу очракта безгә тач туры килеп тора иде...

Җирдән аерылып киткәндә космик ракета да, билләһи дип әйтәм, шундый зур тизлек җыеп өлгерә алмый торгандыр! Йомшак җирләребезнең авыртуына түзә алмыйча, уктай атылып, Ташсуга таба томырылдык. Чапкан уңайдан бер куян баласын узып китеп, өстеннән сикереп чыгуым гына азмаз исемдә калган, бүтәнен хәтерләмим. Тозын җәлләмәгән иде Ярулла абзый. Монысын без үз артыбызда ай-һай, шәп татыдык соң!..

Өйдәгеләрне, урманда ялгыш бүре җиләге ашадык, эчебез авырта дип, хәйләләргә туры килде. Караватка чалкан ятып булмый да булмый инде, авыртуга түзәр әмәл юк, төнне керфек какмыйча, корсакта килеш уздырырга туры килде.

Авырту нинди генә каты булмасын, ул барыбер урманда күргәннәрне оныттыра алмады. Күргәнең сигез, күрмәгәнең тугыз дигәндәй, мунча тәрәзәсе гел күз алдыннан китмәде. Барыйның, урман кызлары, урман ияләре дип мине алдаганын яхшы белсәм дә, бу юлы, нигәдер, аңа ачуланмадым. Әмма бар курыкканым урман каравылчысының безне танып калуы иде. Шөкер, икенче көнне дә, өченче, дүртенчесендә дә өйгә килмәде Ярулла абзый. Тора-бара мин дә, Барый да тынычландык.

Күзең кайда булса, күңелең шунда дигәндәй, күңел күземнең каршында һаман урман кызларының фәрештәдәй гүзәл шәрә сыннары тора. Мин аны яшертен генә ак кәгазь битенә төшердем. Астына: «Урман кызы Гөлйөзем»,—дип язып куюдан чак кына тыелып калдым. Әмма барыбер Барыйга күрсәтмичә түзә алмадым. Ул бик озаклап карап торды-торды да: «Аллай!»—дип, соклануын яшерә алмады. Тик шунысын гына аңлап

житкермәдем, минем осталыкка шаккаттымы Барый, әллә сурәтнең үзе әсәрләндердеме? Мин рәсемне китап эченә яшердем.

Шунысы яхшы истә калган: әлеге хәлдән соң—урман мунчасы мажарасыннан соң була инде бу—без Барый белән шактый вакыт мәктәптән бергә кайтмадык. Бер-беребезгә күтәрелеп карарга да ничектер уңайсыз сыман иде.

Оятсыз оялса, каты оялыр ди бит...

Әмма шуннан соң, беркавем вакыт узгач,—аралар тагын да якынайды гына сыман. Үзебез дә әллә ничек житдиләнеп киткәндәй булдык...

* * *

Ел кебек озын жәйге көндә таңнан алып кичкә кадәр көнозын көтүдә йөргәннән соң, капканы сынар мөгезе белән генә төртеп ачып, әлсерәп, ишегалдына кайтып кергән сыер хайванын күргәнегез бардыр инде. Сусаган була ул. Ашыга-кабалана, су эзләп, ишегалдындагы бар савыт-сабаны, чиләк ише нәрсәләрне тикшереп, аударып чыга, максатына ирешеп, су тапса, дөньясын оныта.

Үзебезнең капка төбенә житәрәк, озак торып каладан кайтып кергән саен, минем белән дә гел шулай була: ашыгам-кабаланам, еш-еш сулый башлыйм. Күкрәк читлегендәге кош баласы уянып китә. Мин капкага килеп төртелгәндә, аның keләсе төшкән булса, keләсе-ние белән очыртырга теләгәндәй, капканың калын тактасына тез башым белән төртеп алам; тимерчелектә әти үзе эшләгән нык келә кымшанырга да уйламый, ана уч төбем белән генә сугам да нәкъ сыер кебек капкага бәреләм, ул ачылып китә.

Мин тәгәрәп үскән ишегалды... Лапас янында нидер эшләгән булыпмы, өйлә житеп килсә дә минем һаман кайтып житмәүгә эче пошыпмы, юкны бушка аударып, әти йөри. Әти, мине күргәч, үзе дә сизмәстән көлеп жибәрә: кайтты! Аның бияләй чаклы авызы (әни шулай дип әйтә) колакларына житә. Малай кайтты! Әти дәү авызын һаман жыеп бетерә алмый әле. Аның нәкъ менә чын ирләрнеке кебек зур авызлы булуы миңа бик ошый. Ир-ат уймак авызлы булырга тиеш түгел кебек, минемчә.

Әти көтүгә дигән озын каеш чыбыркысын күптән әзерләп куйган, ул рәшәткә башында эленеп тора. Беренче эш итеп миңа шуны күрсәтте. Менә әзер, янәсе.

Әтинең йөзендәге беренче шатлыклы тойгыны икенче төрле хис алыштыруын бары мин генә чамалый-сизә алам: авылга минем жәяү кайтуга бик тә эче поша инде аның. Рәссам дигән зур исемең бар, дәрәжәң бар, үзең, тузан таптап, жәяү йөрисең! Әнә, фәләннең малае! Әнә, тегенең малае! Кыскасы, әтинең әйтергә теләве шул: кеше малайлары машинаны күлмәк урынына алыштыра. Ә син?..

Әти миңа ни уйлаганын турыдан-туры әйтми. Үзем дә беләм. Аның малае бит мин...

«Төкерсәнә, әти, машинасына, жәяү йөрү файдалырак ул!»—дип, аны бик тә юатасы килә килүен. Ләкин ул фикерен кычкырып әйтмәгәч, ничек итеп авыз ачасың инде.

Чукынып китсен машиналары, әти, борчылма! Синең малаеңныкы да булыр, әле кешенеке төсле генә дә булмас! Һай, белсә иде әти мин эшләгән берничә картинаның күпме торганын! Егылып китәр иде, билләһи! Алайса ник машина алмыйсың соң, малай актыгы, диячәк шул ул.

Сиринә Самуиловна берьюлы ике машинасын миңа бирергә әзер тора, дисәң дә аңламаячак ул. Аннары сорау арты сорау китәчәк: кем ул Сиринә дигәнең, нигә ул сиңа машинасын бушка бирсен? Әллә башына тай типкән бер тилемсә хатынмы?

Без әти белән бик жылы күрештек.

Ишегалдында әйтмәгән сүзен әти чәй янында барыбер әйтеп куйды. Эчендәгесе тышында инде үзенең.

—Барый тагын яна машина апкайтты. «Волга». Ап-ак төстә.

—Чукындың инде шул машина белән! Алса алсын шунда. Хет унны. Барый колхоз малын кимереп ята ул!

Монысы әнинең сүзләре. Әйе, анысын да яхшы беләм, әнигә минем исән-имин күзгә күренүем машинага караганда меңөлеш кадерлерәк. Машинага утырып кайтасыңмы син, әллә атка атланыпмы? Кайт кына, исән-сау гына йөре!

Анысы әнинең дә эчен тырнап торган бер борчуы бар: ул—минем өйләнмичә йөрүем. Әнигә килен кирәк. Үз янында бергә тормаса да, килен кисәге кирәк әнигә.

Әти машина ди, әни килен ди. Мин боларның барысын да яхшы беләм, аңлыйм, хәтта миндә шул нәрсәләрнең ичмаса берсе генә булмавына борчылам да кебек үзем. Әмма бәрелеп сугылмыйм. Чөнки беләм, бары үзем генә беләм: әти белән әни хыялланган ике теләкнең берсен генә булса да иртәгә үк тормышка ашыра алам лабаса!..

Алайса нигә шулай итмим соң? Ә менә анысы бөтенләй икенче мәсьәлә инде...

«Машина белән килен» темасын онытырырга, бастырыклап куярга теләп, мин чәй янында ук әти ягына карап:

—Көтүне кайсы болынга алып чыгасы булыр инде?—дигән булам. Бик тә әһәмиятле сорау, янәсе. Теләсәң, Наратлыга алып бар, телисең икән сарык-кәҗәләренне Сай суга куасың, әмма минем картлар өчен бу дөньяда әһәмиятсез бер генә нәрсә дә юк: чыннан да, ул чират көтүен кайсы болынга алып бару мәслихәтрәк булыр икән соң? Әти белән әни шул хакта баш ватарга керешә. Ахырдан Сай су дигән катгый карарга киләбез дә, рәхмәтемне әйтеп, ишегалдына чыгам. Әти бу юлы чыбыркының шәбен әзерләп куйган. Зәһәрен дип әйтсәң дә була. Үзе озын. Үзенең каешы да, кылы да шәп күренә.

Рәшәткә башындагы чыбыркыны алдым да бер-ике мәртәбә, кул язу өчен генә, айканып алганнан соң, аннары чынлап торып, шәп итеп урман ягына таба каратып, шартлатып җибәрдем.

Чыбыркы тавышы урманга кадәр барып җиттеме икән, юкмы икән? Җитсә, беренче булып кайсысы ишетте икән: Гөлчәчәкме, Гөлйөземме? Кайсысы? Шуны беләсе иде, ә?.. Кайсы ишетте икән?..

## Мин һәм Гөлчәчәк...

Көтү тыныч кына, таралмыйча гына елга буенда утлап йөри. Берәр сарык бәрәне яки мут кәҗә качып китсә дә артыннан кумам кебек, уйларым, бар күңелем урман каравылчысының шәйләнеп торган йорт-җире тирәсендә чуала.

Теге чакта Барыйга ияреп йөреп, адәм мәсхәрәсе булганнан соң, урман кызлары белән тиз генә күрешү насыйп булмады. Күрәсе килә иде үзләрен. Мунчаның парлы тәрәзәсе аша шәрә шәүләләрен күргәннән соң бу күрешү бөтенләй башкача булырга тиеш иде кебек. Кызганыч, кызлар безнең мәктәптә укымыйлар. Ярулла абзый аларны урман артындагы Бурян мәктәбенә йөртә. Бурян—урыс авылы. Анда урысча укыталар. Ул чакта баланы урыс мәктәбендә укыту зур дәрәҗә санала иде.

Кызларны мин сабан туенда очраттым. Очраттым да телсез үк калдым бугай, барлы-юклы бер ел эчендә алар тәмам үзгәргәннәр. Әлбәттә, бар үзгәреш аларның үсүләрендә, балалыкның күкәй кабыгын ватып чыгып, җиткән кызлар булып өлгерүләрендә иде. Ул вакыт эчендә үзем дә үскәнмендер инде, көн саен көзгедән күреп торганга гына сизми калганмындыр... Көн дә күрешеп торгач, Барыйда да әллә ни үзгәреш күренми. Ул да бер урында гына тормагандыр, мөгаен.

Сабан туе сабан туе булмады минем өчен ул көнне. Карак-угры кебек Гөлчәчәк белән Гөлйөземне күзләп йөрдем. Үзем дә сизмәстән, алар халык

арасында күздән югалуга, кызларны эзлим, әмма яннарына барып сүз катарга йөрәк житми, тик барыбер күз уңаеннан да югалтасы килми үзләрен. Күзең кайда булса, күңелең шунда да бит. Дөресрәге, күп вакыт кызлар артыннан күңел үзе ияреп йөрде бугай. Сабан туе таралгач та кызларга ияреп китте ул. Һәм шуннан соң бүтән үземә кире әйләнеп кайтмады, урманчы кызлары яныннан күкрәк читлегендә тыпырчынган бәләкәй кошчыкка берөзлексез җим биреп тора кебек иде.

Сабан туеннан соң нәкъ бер атна тирәсе аңгы-миңге йөрдем әле. Кызларны сабан туенда Барый да күргән булырга тиеш. Ләкин аның белән теге вакыттан соң урманчы кызлары турында сөйләшәсем килми, ничектер тел әйләнмиме, күңел тартмыймы...

Бер дә уйламаган җирдән, мина әти ярдәмгә килде! Ул тимерчедә эшли иде бит. Беркөнне, эштән кайткач, ат арбасыннан ниндидер тимер-томырлар алып, аларны баз өстендәге келәткә җыеп куярга кушты да:

—Иртәгә боларны Ярулла абзаңа илтеп бирерсен,—диде. Нәрсә икәнен әйтмәсә дә, үзем шундук чамаладым, җәнлек тозаклары иде ул.

Ни булса да булсын—йөгерә-йөгерә илтермен, әти бәгърем! Рәхмәтләр яусын сина! Анда кадәр баргач, урманчының кызларын да күрәм дигән сүз бит инде! Тик мунча вакыйгасы гына бераз күңелне тырнап тора торуын. Гөлйөземне очраткач, колакларыма ут кабып, эшне сиздермәсәм генә ярый инде. Колаклар бигрәк сатлыкҗан шул минем! Берәр төрле мутлык кылу гына түгел, хәтта аны эшләү турында уйлап куйсам да хәзер кызарырга гына торалар. Барыйга рәхәт, аның әрекмән колаклары кызаруның ни икәнен дә белми!

Башка вакыт булса, җәнлек тозакларын илтергә Барыйны да ияртkән булыр идем дә... Ләкин «мунча тәрәзәсе» һаман тынгылык бирми. Шуның өчен әле һаман Барыйны сүгәм, хәер, сүгүен сүгәм дә... Икенче яктан, ул кичне күргәннәр һаман күз алдыннан китми... күңелне кытыклап тора. Әллә бу күңелнең ояты юк инде... Тфү! Үзем дә буталып беттем. Дөресен әйтим, ул турыда тамчы да уйлыйсы килми... Ә үзе уйлаттыра, еш уйлаттыра.

Авылны чыгып китеп, Ташсу елгасына җитәрәк, колаклар гына түгел, әллә нинди сәер хис тәэсирендә бөтен гәүдә-тәнем үк кызыша башлады. Бәлкем, кызу-кызу, ашыга-ашыга баргангадыр? Байтак вакыт елгада суынып яттым. Әллә шул ярдәм итте: гәүдәм генә түгел, хисләр дә суына, тотрыклана төште бугай.

Мин барып җиткәндә Ярулла абзый мотоциклы янында кайнаша иде. Урман хуҗалыгыннан яңа мотоцикл биргәннәр. Монарчы гел ат җигеп йөри иде әле.

Матае, күрәсең, ватылып киткән, Ярулла абзыйның беләкләренә кадәр майга манчылган.

Ул тозакларны кабул итеп алды да, тикшереп караганнан соң: «Шәп булган бу! Рәхмәт!»—диде.

Аннары, сорашмасам да, әлеге тозакларның нигә кирәклеге турында аңлатырга керешә.

—Төлкегә бу тозаклар. Лапаска килеп ничәмә ничә тавыкны буып китте инде. Кыш көне, алла боерса, алма бакчасына килгән кылый куяннарга да куярбыз.

«Бик әйбәт, Ярулла абзый, куярсың, куярсың. Мине алар кызыксындырмый. Мине...» Шулчак ишегалды бакчасына сузылган баудагы керләрдән тып-тып су тамганына игътибар итеп өлгердем. Күңелгә җылы кереп китте. Кызлар кер уа, димәк, тагын ишегалдына чыгачаклар әле. Шуңа күрә монда, Ярулла абзый янында, ничек тә булса озаграк тоткарланып торырга кирәк. Ә матай моның өчен менә дигән сәбәп иде. Барыйның «Минск» матаен атнага җиде тапкыр сүтеп җыябыз без. Шуңа күрә бу техниканы ярыйсы ук чамалыйм мин.

—Ярулла абый, нәрсә, матаең ватылганмы әллә?

—Кабынмый шул, кәҗәләнә,—диде ул.

—Үзем актарып карыйммы соң?

—Әйдә, булдырасынмы? Конторга барасы бар иде. Ашыгам.

Ике кулымны сызганып, эшкә керештем, матайның ватык җирен тиз таптым. Ярый әле башым эшләп өлгерде: серне Ярулла абзыйга шундук ярып салмадым.

—Ярулла абый, лесхозына бара тор. Син кайтканда матаең сәгать кебек эшләячәк!

Мин, таз башнын, әнә шулай дип әйтергә кыюлыгы житте! Үземнең тапкырлыкка үзем шаккаттым.

Ярулла абзый атын җигәргә кереште. Юкка гына мотоциклы белән маташмаган икән, биясе абзардан алып чыгуга чыгымлый башлады. Ярулла абзыйга аны арбага җигешергә булыштым. Бияне җиккәндә урманчы берике сүз белән генә бер атна элек биянең таена бүре һөҗүм итүе, шуннан соң, таен югалткач, акыллы биянең кинәт кенә холкы үзгәрүе хакында сөйләп алды.

Безнең урманда бүреләр бар шул. Бигрәк тә узган кыш котырды алар. Күрше авылдан мәктәптән кайтышлый уникe яшьлек мари малаен да ботарлап ыргытканнар иде. Малайны, укуын юньләп белмәгәне өчен, укытучы дәрестән соң алып калган була. Биш чакрымдагы авылына караңгы төшәр алдыннан гына кайтырга чыга малай. Басу юлында бүреләр очрый. Малайның китаплар салынган букчасы белән киез итекләре генә торып калган дип сөйләделәр. Бу хәбәрдән соң бар тирә-як шаулап алган иде. Район үзәгеннән махсус кешеләр килеп, кыш буе бүре аулап йөрделәр. Сөйләүләренә караганда, алар соңгы елларда безнең як урманнарында үрчеп, котырып киткән шактый гына бүрене киметкәннәр. Тик, аларны бөтенләй кырып бетерергә дә ярамый бит әле. Шул кыштан соң, исән-сау калган бүреләрнең кешеләргә бик ачуы килеп, хәтта җаен дә гел зыян салып торырга карар кылганнар, имеш. Халык шулай сөйли. Биянең тае шул бүреләр корбаны булган да инде.

Ярулла абзыйны капкадан хатыны Гөлчирә апа озатып калды. Хуҗаның кушуы буенча, әгәр дә мәгәр мотоцикл рәтләгәндә миңа кирәк-ярак булса, шул Гөлчирә ападан сорарга тиеш идем. Гөлчирә апа белән дә күптән таныш без. Ярулла абзыйга утырып, авыл кибетенә килгәли ул.

Әйткәнемчә, матайның очына тиз чыктым: гаеп карбюраторында гына иде. Тиз генә кабызып карарга исәпләгән идем дә... Шулчак, өй артыннан кулына керләр өелгән бәләкәй ләгән күтәреп, Гөлйөзем килеп чыкты. Минем тамакка туралмаган бербөтен бәрәңге килеп «тыгылды», колакларыма гөлт итеп ут кабуын тойдым, борыныма су җыелып, мышык-мышык суларга керештем. Бу халәтемнән мине матай коткарды. Басып җибәрүем булды, аның кабынып китеп, чатыр-пытыр эшли башлавы булды. Сүндерергә вакыт булса да, алай эшләмим, матайны һаман акыртам да акыртам. Ишегалды зәп-зәңгәр төтен белән тулды.

Гөлйөзем, керләрен янбакчадагы бауга элеп бетереп, ишегалдына чыккан, миңа нидер ымлый-әйтә бугай, аны ишетмим, матайны һаман акырта бирәм. Төтенгә үзем дә тончыгып беттем, кызның да күзләре яшьләнде, куллары белән нидер аңлатмакчы була, ирендәре дә хәрәкәтләнә. Йә, нәрсә димәкче буласың, чибәр кыз!

Мин матайны сүндерәм.

—Мөхәммәт, керләрне төтенгә батырып бетерәсең бит инде! Ишегалдында эшләтмәле бүтән!—ди Гөлйөзем.

—Ярулла абый бензинга майны күп кушкан,—дим, мин аңа каршы.— Шуңа төтенле ул.

Минем бу сүзләр мәгънәсезлекнең аръягында икәнлеген үзем дә беләм. Бүтән чарам юк. Колаклардагы утны ничек тә булса сүндерергә кирәк бит. Рәхмәт төшкере, матай сүнүгә, колакларым да салкыная башлады бугай.

Зәңгәр төтен, җил белән капка астыннан урамга суырылып чыгып бетте. Әмма барыбер Гөлйөземгә нинди дә булса сүз кушарга кирәк иң, каен букәнедәй бу рәвешле күпме басып торып була инде!

—Әйдә, Гөлйөзем, бер әйләндереп киләм,—дидем мин, телемә шундый сүз килүенә үзем дә сөенеп.

—Ана утырып йөрергә куркам мин. Әнә, Гөлчәчәккә әйт. Ул өйдә елап ята. Яраткан таен бүре суккан.

Рәхмәт төшкере, сүзләр генә түгел, эшләр дә жайга салынырга тора бит әле болай булгач! Сөенүемне яшерә алмыйча (әйтерсең, тайны бүре алып киткәнлегенә куанам):

—Кайда соң ул? Бар, әйт,—дим.

Гөлйөзем жәһәт кенә өйгә кереп китте. Күп тә үтмәде, алар, Гөлчәчәк белән икәүләшеп, килеп чыктылар. Чыннан да, Гөлчәчәкнең йөзләре сулыгып та, чак кына агарып та киткән сыман. Кыз туп-туры минем янга атлады.

—Мөхәммәт, әйдә, Аккашкага бүре ташланган урынга барып кайтыйк әле,—диде кыз.

«Бик хуп, әйдә киттек!»—дип, шатланып-сөенеп, шундук матайны кабызасы урынга мин югалып калдым, ана каршы ни диярга да белмәдем. Мин жавапсыз торгач:

—Матай эшли торгандыр бит? Мин әнидән рөхсәт сорадым,—диде кыз.

Бу хәлгә, Гөлчәчәкне утыртып (егылып төшмәс өчен мина тотыначак та бит әле ул!), урманга чыгу жае туры килүенә һич кенә дә ышанып житәсе килми бит! Бүкән сыман һаман сүзсез басып торам!

—Беләм, вакытың юктыр инде?

Мин кисәк кенә аңыма килдем.

—Капканы ач әле!

Матайны капкадан этеп алып чыктым, Гөлйөземнең ап-ак керләре чынлап та жәл иде.

Тайга бүре һөжүм иткән урын Бурян ягында икән. Анда Бүре чокыры дигән урын барын да беләм әле мин. Без ел саен әти белән Бүре чокырында мунча миллеге жыябыз, яшь каеннар күп анда.

Ярулла абзыйның матае зәһәр икән, газын боруга йолкып алып та китте. Аннары Гөлчәчәк янында үзем дә гомер буе матай өстендә чапкан ярышчы кебек кыланам. Ярулла абзыйның кызы чытырдатып миңа ябышты. Һай, күктән кинәт ишелеп төшкән бәхет! Һай, өнемме соң, төш кенә түгелме икән бу! Күңелем «чиләк» булган: унбиш яшьлек үсмернең, шулчак әллә нинди батырлыклар, әллә ниткән жүләрлекләр кыласы килә башлады бугай. Мин, тиле, мәгънәсез малай, берара хәтта: «Рәхмәт сиңа, соры бүре!» дип тә кычкырып жибәрә яздым.

Гөлчәчәк урманда үскән кыз, мондагы һәр сукмак, һәр агач төбе ана яхшы таныш: ул юлын күрсәтеп баргач, Бүре чокырына турыдан гына бик тиз килеп життек.

Гөлчәчәк белән икәүдән-икәү генә калып күзгә-күз беренче сөйләшүем Бүре чокырында булды. Дөресен генә әйткәндә, урманда минем Гөлйөзем белән ялгыз каласым килгән иде. Чөнки мунча тәрәзәсеннән аны күрдем бит! Күрдем дә гашыйк булдым. Мизгел эчендә минем иләс-миләс күңелдән кырыкмаса-кырык төрле уй-фикер үтте. Әйе, Гөлйөземне ялангач килеш күрдем дә ди. Шуннан ана гашыйк булдым да ди. Ә менә аның урынына күрше кызы Алмазияне күргән булсам? Аңа гашыйк булган булыр идем микән?..

Гыйшык-мыйшык турындагы уйларым бер-берсенә шул рәвешчә гел каршы килә дә тора. Бернинди эзлеклелек-фәлән юк.

Бүген шуларны кабат искә төшереп уйлыйм да, хәзерге яшьләрне кызганып куям. Бер-берсе белән кочаклашып йоклаганнан соң, шуны мәхәббәт белән бутап, тормыш корып жибәрүче яки: «Я без него (нее) не могу!»—дип, адашкан-саташкан яшьләрне кызганам! Шул рәвешле алар чын мәхәббәтнең ни икәнлеген белми, татымый да кала! Моның азагы бер: алдавыч хисләр дулкынында кабынган учак үзеннән-үзе сүнә дә китә. Әйе, чынлап та шулай бу. Чөнки бүген, моннан унбиш-егерме ел элек вакыт белән чагыштырганда, яшь кыз белән яшь егетнең женси якынлык кылуы

чаттагы әбидән сатып алган бер уч көнбагыш чиртү кебек кенә. Һәммәсе өчен булмаса да, һәрхәлдә күпчелек өчен шулай. Беләм бит, чөнки мин үзем дә бу тормышта яшим, шушы казанда кайныйм ләбаса!

Үзем, теге вакытта, Гөлчәчәк белән Бүре чокырында ялгыз калгач, аның кулын тоту түгел, хәтта күзләренә күтәрелеп карарга да курыктым. Ул очрашу бүген дә хәтернең һәр күзәнәгендә диярлек саклана.

Гөлчәчәк Аккашканы үзе тәрбияләп үстергән булган. Атларны бик тә ярата икән ул! Теге хәбәргә ышанасы да килмәгән. Хәзер менә, бүре чокырына үзе баргач, күнеле чынлап торып ышанды. Кыз шунда үскән бер яшь каен янына килде дә аны учлары белән сыйпап:

—Һай, каенкаем, ул хәлне син күреп торгансыңдыр бит инде? Ник ул явыз бүрегә Аккашканы харап итәргә ирек бирдең соң син, ә?—дип куйды. Мин, матайга сөялгән килеш, кулымдагы абага белән кигәвен куып тора идем, кызның бу сүзләреннән эсселе-суыклы булып киттем. Әүвәл кычкырып җылап җибәрәсем килде, аннары, тиз генә акылыма килеп, Гөлчәчәкне юатмакчы булдым:

—Гөлчәчәк, теләсәң, ул бүрене үтереп, колагын сиңа кисеп китерәм!

—Кирәкми, Мөхәммәт,—диде Гөлчәчәк миңа таба борылып.—Син ул бүрене үтерсәң, аны җәлләячәкмен бит мин!..

Гөлчәчәк минем янга килде. Матайны кабыздым. Ярулла абзыйның матае, урман эчендә булгач, нәкъ танк чыгарган тавышлар белән эшли башлады.

Юлга чыкканчы, урман чәчәкләрен таптый-таптый, тар сукмактан гына элдерттем. Кыз:

—Әти миңа ак ат алып бирәм дип вәгъдә итте!—дип кычкырды.

## Мөхәммәт һәм мәхәббәт

Ярулла абзыйның малае булмау Мөхәммәткә бик уңай килде. Урманчының мотоциклын рәтләп биреп, бер егетлек күрсәткәч, урман хуҗасы малайны бигрәк тә үз итте. Кыскасы, арадагы сукмак шактый такырайды: утын кисәргә кирәк булса да, матае ватылып аны ремонтларга туры килсә дә Ярулла абзый Мөхәммәтне чакырта, шуның өчен аларга кыш ягарлык утынын, печәнлегеннән печәнен бирә иде. Бу эшне бигрәк тә Мөхәммәтнең әтисе Уразмәт абзый хуп күрде. Шулай булмыйни, авылда утын белән печәннән дә кадерлерәк тагын ни бар соң?

Мөхәммәт исә, җае туры килгән саен, Гөлчәчәк белән күрешә ала иде.

Егет өчен дөнья кинәт кенә үзгәреп китте. Моңарчы эленке-салынкы гына йөреп, Һади абыйсы таләп иткәнгә генә рәсем ясаштыргалаган малай, чынлап торып рәссам булырга хыяллана башлады. Ә рәссам булу, бик яхшы рәссам булу кирәк иде Мөхәммәткә.

—Мин урманчы кызы гына түгел, мин урман кызы да.

—Гомерең буе шушы урманыңда ятармын дип уйлыйсыңмы?

—Әйе!

—Ә мин Казанга китәм!

—Казан—таш кала ул. Ә ташта чәчәк үсми.

—Ә рәссам буласы кеше авылда яши алмый. Шәһәр тормышында кайнарга кирәк аңа.

—Ә мин урмансыз саргаеп үләрмен кебек. Әгәр шәһәргә китсәм, дим.

—Мин синең урманыңны шәһәргә алып китәчәкмен!

—Ничек итеп?

—Әүвәл синең урманыңдагы һәр агачны, һәр абага-чәчәкне, һәр төсне күнелемә сеңдерәм. Аннары шәһәргә алып китәм. Шәһәрдә, синең урманыңны күреп, бар кеше дә сокланачак! Урманың шәһәрдә дә булгач, син үзең дә анда теләп барырсың!..

—Ничек итеп алып китәсең дип сорыйм бит?
—Рәсемгә төшерәм мин синең урманыңны!
—Бар урманны дамы?
—Әйе. Барысын да. Мин сине шәһәрдә урмансыз саргайтмаячакмын. Вәгъдә бирәм.
—Вәгъдәме?
—Чын-чынлап менә. Вәгъдә инде!
—Ай-һай, булдыра алырсыңмы икән?
—Булдырам. Мин булдырачакмын! Синең хакка... мин!..
—Алдан кычкырмәле, яме.
—Вәгъдә дидем бит инде.
—Вәгъдә булса гына...

## Бирәү сата, бирәү ала

Миндәге үзгәрешне беренче булып Һади абый күреп алды: рәсем ясау соңгы көннәрдә минем өчен мавыгу гына түгел, яшәеш рәвешенә әверелеп, ак кәгазьгә төшәчәк төсләр бар тормышымны тутырды.

Мин тиле кебек урман ясыйм да урман ясыйм, йә урман аланын сурәтләргә маташам да шунда чәчәк җыйган бер кыз бала төшереп куям. Тора-бара, күп кәгазь бозып, үзем үк ертып ата торгач (өйдә әнигә мич тергезеп җибәрү өчен файдалы булса, мәктәптәгеләре чүпкә әйләнеп, җыештыручы апаларның нервысына гына тия иде), урманыма чак кына урман рәвеше керде. Әмма чәчәк җыйган кызым күбәләккә яисә су анасына охшый иде.

«Барыбер Казанга алып китәм әле мин сине, урман! Гөлчәчәгең белән бергә!..» Бу минем йөрәкнең ярсулы тибү тавышы, бу уналты яшьлек үсмер егетнең үз башыннан узачак язмышына, фани дөньяда күрәчәк кырыкмаса кырык төрле тормыш сынауларына кизәнүе, алай гына да түгел, киләчәгенә: «Сиңа бик көчле, каны кайнап торган бер егет килә, тормыш! Аяк чалырга уйлап та карама! Ул барыбер җиңүче булачак!»—дип, алдан ук аваз салуы һәм әледән үк йодрык төйнәп куюы иде.

Җикеренмә, малай! Үз башыңа булмасын! Тормышның күсәге бик саллы аның!..

Ярый, хуш. Укуым да үзгәрде минем: ничә еллар буе аяктан артка сөйрәп килгән «өч»леләр язгы сулар белән бергә Иделгә таба агып киттеләр, өстәвенә рәсем җене миңа чын-чынлап кагылды. Моңа иң куанган кеше Һади абый булды. Тырыша-тырыша өйрәтә. Ул мине генә түгел, энесе Барыйның да кабыргаларына төрткәләп тора. Әлегә Барыйның ни-нәрсәгә талантлы икәнлеге ачыкланып бетмәгән, ләкин малайның колаклары зур булу өстенә баш та шактый түгәрәк. Бу кечкенә буйлы энекәш киләчәктә Наполеон булып куярга да мөмкин әле. Шуңа күрә Һади абыйсы аңа да кул селтәми, ышаныч вә өмет белән карый иде. Тик Барыйның дөньяны болгатырга яратуы гына аның күнелен бераз тырнап тора.

Ышанасызмы, юкмы: уналты яшьтә Барый белән икебез Ницше фәлсәфәсен өйрәнә башлаган идек инде без. Әлбәттә, Һади абый ярдәме белән. Гитлер әлеге философ тәгълиматын ни рәвешле үз максатларында файдаланса, Һади абый да аны безгә кирәгенчә, бары тик безнең файдага гына эшкә җигә: Мөхәммәт атлы күрше малае зур рәссам булырга, Барый энекәш җитәкче-сәясәтче булып үсәргә тиеш!..

Ул китаплардагы акыллы сүзләр әле дә булса колагымда яңгырый. Чөнки без аларны дәфтәргә күчереп алып, ятлый да идек.

«Матурлыкның иң күркәм йөзе шундук үзенә тарта алмый, ул көчле исертүгә дә ия түгел (андый матурлык бик җинел генә нәфрәт уятырга да мөмкин); ул сиздермичә генә күңеленә сеңә торган матурлык төре; син аны әле кабат очратасың, безнең йөрәкләрдә бик озак тыныч кына посып ятканнан соң, ул кабат безне тулысынча биләп ала, күңелебезне яшь сагышы белән

тутыра. Матурлык иҗат иткәндә без нәрсәгә омтылабыз соң? Әлбәттә, гүзәл булырга! Бәхет тә нәкъ шуның белән килә бит инде. Ләкин бу ялгышу!»

Рәссамнар балкыш-нурлануның кинәт киләсенә кешеләр ышанырга тиеш дип тырыша. Икенче төрле ул илһам килү дип атала. Сәнгать һәм шигъри әсәрләрнең идеясе, фәлсәфи системаның төп фикерләре күктән яктылык булып ингән кебек. Чынлыкта, яхшы рәссамның яки фикер иясенең фантазиясе һәрвакыт яхшылыкны, уртачаны һәм начарны тудыра: ләкин аның үткәне, тәҗрибәле фикер сөреше кире кага, үлчи-исәпли; күп төрле караламаларыннан һәрдаим гүзәл көйләр сайлап ала торган Бетховен көндәлекләреннән дә күренә бу.

... Барлык даһилар да фидакарь эшчеләр булганнар; алар арып-талып иҗат итеп кенә калмыйча шулай ук тырыша-тырмаша кире дә какканнар, кабат тикшергәннәр, тәртипкә салганнар».

«Сокландыргыч әсәр! Ләкин шунысы түзеп торгысыз: иҗат итүче һәрвакыт безгә бу әсәрнең анык икәнлеген искәртеп тора».

«Ул үзенең фикерен анык әйтә алырга өйрәнгәннән соң, ана ышанмый башладылар. Тотлыгучыларга күбрәк ышаналар».

Барыйга исә немец фәлсәфәчесенең өйрәтүләре үз каланчасы биеклегендә тамызыла иде. Барый үзенең шул каланчасыннан да өскәрәк менә алмастыр. Хәйләкәр ул. Үзенең хәйләсен бирәү дә сизми дип уйлый. Унынчы класста укыганда мин аның шарж-рәсемен ясап, үзенә күрсәттем. Кыска буйлы, базык бәдәнле, башы да түгәрәк кенә, ягъни нәкъ үзенеке сыман килеп чыкты. Ә колаклары... колакларын мин аларны юри, куян колакларына ошатып, озын итеп ясадым: ул колаклар Барыйның үзен дә узып китте. Бу, минемчә, Барый башындагы хәйләнең шулай зур булып калкып торуына бик шәп ишарә иде. Колак-хәйлә Барыйның үзен дә узып киткән. Барый үз колакларын үзе күрми, ә кешеләр күрә.

Теге чакта, күпердән төртеп төшергәндә дә ул бу чаклы ук үпкәләмәгән иде. Бу юлы Барый бөтенләй телсез-авызсыз калды, сөйләшмәс булды: без мәктәпкә өч чакрым ераклыктагы Байтимергә йөреп укыйбыз бит, барганда да, кайтканда да мәктәпкә Барыйның матаена атланып йөри идек, колак-хәйлә рәсеменнән соң тагын җәяүгә калдым. Әмма сизеп торам, Барыйның үч алуы моның белән генә тәгәлләнмәячәк иде әле. Классташ дустым мина каршы тагын нинди этлек уйлар?..

Байтимер юлында Барый дустым мине бер көн тузанга коендырып китте, икенче көнне дә янымнан пырылдап узды. Тик гарьләнмим. Үземнең кем малае икәнлегемне беләм бит, шуна ияләнгәнмен, күнеккән инде. Бер түгел, ун матай алып бирәм дисәләр дә барыбер Хаҗи малае булмас идем мин. Минем үз әтием алтын! Куллары гына түгел, чынлап та, үзе дә алтын кеше ул! Җитмәсә, быел көзгә әти мина да матай алып бирергә уйлый бугай. Бу серне шыпырт кына әни чишә.

Аннан соң, мәктәптән кайтканда, мин адым саен, каерылып, урман ягына карыйм, Гөлчәчәкне күз алдыма китерәм, күнелдән аның белән сөйләшә-сөйләшә атлыйм. Шул рәвешле өч чакрым араны ничек кайтып житкәнемне сизми дә калам. Өйгә кайтуга, көндәлек эшләрне тәмам кылгач, дөньямны онытып рәсем төшерергә тотынам. Юлда чагында мин бүген урманны тагын бүтән сурәттә күрдем. Карашым ул күренешне, капылт кына югала күрмәсен дигәндәй, үзенә җыеп алып, күнел сандыгыма салып куйды.

Минем исәп буенча, рәсем-картинада тере урман аланлыгында бер кыз чәчәк җыярга тиеш иде. Аланлык әлләни зур да түгел. Як-ягын төрле яшьтәге төрле-төрле агачлар: каеннар, усаклар, наратлар уратып алган. Карт усак башында, чәчәктән-чәчәккә кунып йөргән кызны күзләп, дәү козгын утыра, икенче якта, яшь наратның очына ук лачынмы, бөркетме кунган. Ул кызның тынычлыгын саклый. Әйбәт килеп чыкканлыгын үзем дә беләм. Һади абыйга әйтсәм, ул да шулай диячәк. Ләкин бу минем серем, аны хәтта Һади абыйга да чишә алмыйм. Урман кызы Гөлчәчәккә булган хисләрем бары тик минеке, үземнеке генә!..

Өченче көн дигәндә, Барыем түзмәде, узып киткән жиреннән кире

борылып килеп, янымa туктады да матаена утырырга чакырды. Күптән беләм инде, Барый дустым купысырак булса да, күңеле яхшы аның. Бердәнбер якын дустым лабаса ул минем! Әүвәл утырмаска маташып карышасым килгән иде, Барый гаепле тавышы белән:

—Киреләнмә инде, Мөхәммәт. Син дә, мин дә бүтән алай эшләмибез түлке, яме,—дип, чын күңеленнән әйткәч, нишлисең, тәпи-тәпи кайту «ләззәте»ннән баш тартырга туры килде инде.

Анысы да монысы, Ярулла абзыйның матаен ремонтларга да без Барый белән икәүләшеп йөри башладык. Бу минем тарафтан оештырылган кечкенә, ләкин бик изге хәйлә иде: Гөлйөземгә дә пар кирәк бит инде. Бәлкем, Барый белән борчаклары пешәр дип, уйладым мин һәм ялгышмадым бугай, алар хәтта холыклары белән дә бер-берсенә туры килеп торалар; Барый да, Гөлйөзем дә безнең белән чагыштырганда кыю да, чаярак та, алар нинди булса гамәлне кылганчы түгел, соңыннан гына уйлыйлар иде. Эшнең нәтиҗәсе турында аны кылганчы түгел, соңыннан, эш беткәч кенә уйлыйлар иде.

* * *

Сәгать уннарга кадәр сарык-кәҗәләр капланып ашаячак әле. Унбер тулганда мин аларны Ташсуның комлы ярына туплауга алып килергә тиеш. Тамаклары туйгач булса, өйлә вакыты авышканчы комлыкта тынсыз ятачаклар. Мин бу чаклысын гына беләм, чөнки яшьтән үк чират көтүе көтеп үскән малай. Шулай да арада туймас тамаклы чорсыз маллар да бар. Бигрәк тә кәҗәләр холыксыз була. Үз артларыннан сарыкларны ияртәләр!

Шуңа күрә яр буенда аякларны озак салындырып утыра алмадым, торып йөрим, көтүнең әле бер ягыннан, әле икенче ягыннан әйләнәм. Башка чак булса, көтү көтешергә үзем белән берәр күрше малаен да ияртнән булыр идем. Тик бүген малайлар буш түгел, бүген—сабан туе.

Кичә Казаннан соң кайтылды, Гөлйөземне дә күрергә өлгермәдем. Сабан туе мәйданы урман каравылчысының өеннән ерак түгел. Гөлйөзем, бәлкем, җыеңга чыккандыр.

Ә Гөлчәчәк хәзер ерак районнарның берсендә эшли. Мәктәптә укыта. Читкә китеп яшәвенең сәбәбе бар: әнисенең бертуган апасы, моннан ел ярым элек параличланып, урын өстенә яткан иде. Ул апа ялгыз башы гына яши.

Минем Гөлчәчәгем, университетның биология факультетын тәмамлап, кире үз урманына кайтып киткән иде. Әйтергә онытып торам: Гөлйөзем, кыз башы белән урман техникумында укыды да, әти-әнисе янына кайтты. Урман кызларын шәһәр үзендә алып кала алмады. Гөлчәчәк бәхетенә, урман буенда иң яхшы юртаклардан гына торган ат заводы да ачылган иде. Ул шунда эшкә керде. Яшьтән үк ат җене кагылган иде шул кызга. Мин үзем дә атларны бик яратам. Ләкин мин яратам гына. Ат өстендә үсмәгәч, аларның холыкларын белмим, үсмер чакта, ат өстеннән мәтәлеп төшеп, аягымны имгәткәннән соң, аларның янына килергә дә куркам.

Вәгъдә иткәнчә, Аккашка тайны бүре суккач, Ярулла абзый ак ат алып кайткан иде. Урманчы өчен бик унай транспорт: телисең икән арбага җик, теләсәң, атланып чыгып кит.

Әнә, ул ак ат моннан, мин көтү көткән урыннан да, шәйләнеп күренеп тора. Ярулла абзый атны арканга чыгарган. Гөлчәчәк булмагач, күрәсең, атның күп гомере арканда уза. Гөлчәчәк ничек яраткандыр, чорсыз-холыксыз ат ул. Гөлчәчәк уйлап тапкан «Лачын» дигән кушаматы да бар әле аның. Тайдан яңа гына ат булып килгән Лачынны алып кайткан көнне Барый белән без Ярулла абзыйның утының кисә идек. Мотопычкы белән чытыр-пытыр кисәбез-кисәбез дә, аннары ярып ук куябыз. Кызлар ярылган каен утыннарын әрдәнәгә өеп тора. Күңелле, рәхәт. Ярулла абзый өйдә юк, күрше колхозга ат сайларга китеп барган. Гөлчирә апа безгә, ягъни

утын кисүче яшь «кияүләр»гә өйдә өчпочмак пешерә.

Соңгы утын пуләнен әрдәнәгә куйганда, Ярулла абзый да кайтып керде. Арба артына каеш белән шул Лачынны бәйләгән.

Лачын бик матур иде. Ул әле яшь тә икән. Үзе әкияттәге ак байтал кебек ап-ак, алгы аякларына кара итекләр киерткәндәй тояктан өстәрәк, кап-кара. Кыскасы, кара аяклы ак ат иде Лачын. Монарчы анын тәртәгә дә кергәне булмаган, ләкин атланып йөрергә өйрәткәннәр инде.

Гөлчәчәкнең сөенүләрен күрсәгез иде шулчакта! Әгәр дә ат куян баласы булса, билләһи, кочагына алып шундук иркәли башлаган булыр иде.

—Җигәргә өйрәтмәбез инде моны. Атланып йөрергә булса шунда,— диде Ярулла абзый.

Атны арбадан ычкындыруга, Барый егетлек күрсәтергә теләп, сыртына сикереп тә менде. Менүе булды, Лачын артын чөеп җибәрде, Барыебыз очып та төште. Әмма Барый ат янында (Әтисе Хаҗи абый да атка атланып йөри иде) кайнашып үскән малай, алай гына сер бирер димә. Ул җәһәт кенә сикереп торды да тагын атланмакчы булган иде, Гөлчәчәк туктатты.

—Борчыма әле атны, Барый. Юлдан соң бераз ял итсен, хәл алсын. Аңа ияләшергә дә кирәк бит әле,—диде кыз, бер кулы белән атның йөгәненнән тотып, икенчесе белән муеныннан сыйпый-сыйпый.

—Лачын, Лачын!—дип исем кушам мин аңа, әти, яме!

Лачын, хәл алгач, Гөлчәчәк келәттән ияр алып чыкты.

—Малайларны яратмый ул. Менә хәзер карап тор, Барый, яме.

Ярулла абзый иярне үзе киертте дә, каршы сүз әйтергә урын калдырмаслык итеп:

—Әүвәл үзем атланып карыйм!—дип, җинел генә ат өстенә сикереп менде. Болай гына атландырмый ул. Башта ук ияр салырга кирәк булган. Шулай дип әйттеләр.

Хурлыгыннан җиргә сенеп беткән Барыйга әлеге сүзләрдән соң янә җан керде. Ишеттегезме дигәндәй, ул әле мина, әле кызлар ягына карап куйды: «Иярсез атланганым өчен егып төшерде ул мине!» ди кебек иде анын яктыра башлаган карашы.

Дөрес хәлгә ни әйтерсен, чынлап та шулай икән шул: Ярулла абзыйны тыныч кына әйләндереп килде Лачын. Аннан соң иярга Гөлчәчәк менеп кунаклады. Атның шул чактагы кыяфәт-кыланышын күрсәгез икән сез! Гомере буе сыртына Гөлчәчәк атланганын гына көткән диярсен, әүвәл ул бер урында тыпырдап, хәтта биеп, дип әйтсәң дә була, торды-торды да аннары Ташсу буеннан искән җил белән куышкан кебек, юыртып, юк, алай түгел, кияү егетләре кебек, кәс-кәс басып атлап китте. Бармый да, атламый да, ә йөзә кебек! Анын борын тишекләре киңәйде, зур коңгырт күзләрендә кояш нурлары чагылып-чагылып алды. Ат Гөлчәчәкнеке иде, гомере буе яратачак иде ул аны...

Гөлчәчәк әйләнеп килгәч, ана иярдән төшәргә булышкан арада, йөгәнне Барый эләктереп алган иде. Лачын аны да хәтәр-хәвефсез генә әйләндереп килде. Чират мина житәчәген сизгән идем. Ләкин үз гомеремдә бер мәртәбә дә атка атланып караганым юк. Мәтәлеп төшәчәгем көн кебек ачык иде. Каян башыма килгәндер, мин чарасызлыктан пычкы янына атылдым һәм:

—Ярулла абый, бу агачларны да кисәседер бит!—дип кычкырдым.

Ярулла абзый тыныч кына:

—Утынга түгел алары,—диде.

Мин аны ишетмәгәнгә салыштым һәм пычкыны да кабызган идем инде. Анын чытыр-пытыр эшләгән тавышы ак атнын котын алды, ул Барый кулыннан ычкынып, лапаска таба шылды. Лапаснын кайда икәнлеген ничек чамалады диген, бу йортка беренче аяк басуы бит әле!

«Урманчыда агач бетмәгәндер әле, монысы да утынга булыр»,—дип, мин, атка атланырга чакыруларыннан котым ботыма төшеп, пычкыны каезланган агачка батырган идем. Ярулла абзый кулымнан килеп тотты да

пычкыны сүндерергә кушты. Нишлисен, кушкач, сүндерәсен инде. Әмма кушсалар да атка атлана алмаячагымны яхшы белә идем. Рәхмәт инде Гөлчирә апага: өчпочмаклары пешеп чыккан икән. Ул, тәрәзәне ачып:

—Кулларыгызны юыгыз. Өчпочмакларым суына!—дип кычкырды.

«Дөрес әйтәсен, Гөлчирә апа, дөрес. Өчпочмакны кайнар килеш ашарга кирәк»,—дип, сөйләнә-сөйләнә, юынгычка таба иң беренче булып мин атладым.

Бүген атка атланудан котылдым. Ләкин бит әле иртәгә бар, берсекөне... Бу нисбәттән нәрсә булса да уйларга, ни булса да кылырга кирәк иде. Шуннан сон мин, инде буй житкән егет, атта йөрергә өйрәнергә ныклы карар кылдым. Күрше Хәмит абый бер карт алаша жигә. Әүвәл шуна атланып өйрәнәчәкмен!

Хәмит абый эштән кайткач, алашасын ишегалдында туара да, кәнүшнигә илтә. Мин аның нәкъ шул чагын сагалап торып, беркөнне:

—Хәмит абый, кая үзем илтәм,—дип, ана каршы сүз әйтергә ирек бирмичә, йөгәненә килеп тотындым.

Ике арада шундыйрак сөйләшү булып алды.

—Оясын беләсенме сун?

—Табармын, борчылма. Күнних шунда бит! Атландырамы сун ул?

—Атланып караган жук шул. Сон, нишләп атландырмасын. Юаш хайван ул. Карт бит инде, минем кебек.

Безнен мунча янында узган-барган машина-трактор бәреп китмәсенгә зур таш куелган. Алашаны шул таш янына алып килдем дә атланып карарга исәпләдем. Алаша карт булса да шактый биек, гәүдәгә зур. Корсагы да мичкә кебек бүселгән. Сыртына ике кулым белән ничектер жайсыз гына ябышып, сикереп атланмакчы булган идем, күрәсен, артыграк тырышып ташлаганмын, сикергән унайга атнын икенче ягына—юлдагы пычракка барып төштем. Шөкер, бу хурлыклы хәлемне алашадан бүтән жан иясе күрмәде. Җәһәт кенә сикереп торып, пычракка буялган киемнәргә дә исем китеп тормастан, янә таш өстенә мендем. Бу юлы каударланмадым, каты көчәнмәдем—ат өстенә менеп утырдым. Бер кулым йөгәндә, икенчесе белән атның ялын урап тоттым. Киттек бит, әй! Як-якка чалшаям, ияр булмагач шуа да, әле ярый корсагы зур мескен алашаның, аның «мичкәсен» бар көчемә аякларым белән кысам. Барабыз шулай. Чак кына ара узуга иямәшә дә башладым. Кызык икән ат өстендә, рәхәт. Кәнүшнигә барып житәрәк бәләкәй генә тау менәсе әле. Бар курыкканым—алаша атландырган килеш таудан менә алырмы-юкмы? Ирексездән, атның колагына үрелгәнемне сизми дә калдым. Имеш, таудан хут белән менсен өчен матайның «газын»—ат колагын борырга кирәк. Алашам ачу белән башын чайкап алгач кына исемә килеп, матайда бармаганлыгымны аңладым. Бу гамәлем үземә дә көлке булып тоелды.

Алаша таудан бик жинел менде. Чынлап та кызык икән бу. Кызыгын кызык та, тик мәтәлмәсәм генә ярый инде.

Бу юлы мәтәлмәдем тагын.

Минем өйрәнү шул рәвешле көн саен дәвам итте. Хәзер ат өстендә ышанычлы йөрим. Хәтта чаптыртып та карыйсым килә. Тик алашам ялкау, күпме генә тарткаласам, чөнгерсәм дә чабарга уйлап та карамый, бер көйгә атлый да атлый. Ә минем юырттырып карыйсым килә. Чөнки Лачын мондый көйгә йөрми бит, баскан урынында да биеп кенә тора.

Атта тәмам өйрәнеп житкәнче аяк басмадым урманга. Хәмит абыйга да, аның алашасына да бик зур рәхмәт, хәзер мин чын кавалерист кебек. Кулда кылыч, аркада мылтык кына юк.

Гөлчәчәк белән алай еш күрешеп торырга да жай гел чыгып тормый. Ә күрәсе килә, көн саен очрашып сөйләшәсе килә. Узган баруымда (бу юлы Барыйны ияртмәдем, аның белән аралар бозылышкан чак иде) Гөлчәчәкнен кулларын тоттым. Менә бәхет! Шундый кечкенә, үзләре йомшак, үзләре кайнар иде ул куллар. Хәтта уч төбем пешкән кебек булды. Кулын гына да тотмадым әле...

Ул көнне без аның белән Кызылъярга чишмә суына бардык. Икәү генә, җәяү генә.

Гөлчәчәк сөйләшә дә сөйләшә. Нигә бу кыз шулчаклы күп сөйләшә икән дип, аптырап та куйган идем. Икебез генә калудан курыккан булган икән ул! Урман кырыеннан барган юлыбыз, кинәт каерылып, агачлар ышыгына кереп китте. Урманның тәмле исе борынны яра. Сулыш алуы ук җиңел, рәхәт. Урман эченнән сузылган олы юл комлы, өстәвенә ул машина-трактор тәгәрмәчләре белән казылып та беткән иде. Кызылъяр чишмәсенә куян сукмагыннан да барып була. Гөлчәчәк сөйли дә сөйли. Мин аның нәрсә турында сөйләгәнен тыңламыйм да бугай. Башымда үз уйларым кайный. Кинәт моның алдына чыгып туктадым да:

—Гөлчәчәк, әйт әле, менә бер шагыйрь «усак егете каен кызын үпмәкче була» дип яза. Ничек уйлыйсың, чынлап та гашыйкмы ул аңа?—дидем.

Гөлчәчәк бермәл йөзенә җитдилек чыгарып, аптырап торды, аннары кинәт көлеп җибәрде. Чү! Тукта! Ул көлдеме соң? Әллә, әллә инде әнә теге чәчәкләр, янәшәдәге аланда шаулап үскән берсеннән-берсе матур, аллы-гөлле чәчәкләр шулай тирбәнеп, чыңлап куйдымы?!

—Әй, әйе,—ди Гөлчәчәк көлү аралаш,—усак егете каен кызына үлепләр дә гашыйк ул! Сөя усак егете каен кызын! Шулчаклы көчле итеп сөя ул, синең белән мин аны күз алдына да китереп карый алмыйбыз, Мөхәммәт!..—ди Гөлчәчәк кыланчык тавыш белән.

—Ә мин...—дидем кызның көлүен бүлдереп,—мин моны күз алдына китерәм, Гөлчәчәк!

Әлеге сүзләремнән соң урман кызы көлүеннән дә, кыланчыклануыннан да туктап калды.

—Ничек! Каян?

—Мин... ә мин үзем усак егете!

Кызым бермәл тын гына шомырт-кара күзләрен зур итеп ачып, бик игътибар белән миңа текәлеп карап торды-торды да, кинәт аның инбашы сикереп куйды, ул янә матур тавышы белән урманны чыңлатып көләргә кереште!

—Мөхәммәт! Син... син бит агач түгел! Усак утын агачына гына ярый бит ул!

Кызның бу сүзләренә бик тә ачуым килде. Көл, әйдә көл. Утын агачын күрерсең менә хәзер. Кулымдагы бидонны сукмак кырыендагы абагалар арасына ташладым да, Гөлчәчәкнең кулларыннан тотып, үземә тартып китердем. Һәм... һәм, кызны кочып алып, аның миңле битеннән үптем!..

Иреннәремнең бик кайнар икәнлеген үзем дә сизгән идем, әллә кызның битен пешердем инде, ул «Ай!»—дип кычкырды да артка чигенде. Кызның йөзе ап-ак булды, болай да зур чем-кара күзләре тагын да зуррак булып ачылдылар, иреннәре, ирен читендәге кара миңе—барысы да дер-дер килә. Мин курка калдым. Һушын җуя язган кыз баланы ничек тә аңына китерергә кирәк иде.

—Гөлчәчәк, Гөлчәчәк, дим! Мин чынлап та усак егете кебек. Ә синең каен кызы буласың киләме, Гөлчәчәк?

Кызның йөзенә алсулык йөгерде, әмма күзләреннән сирпелгән карашы җитди, хәтта куркулы да иде.

Ул миңем сорауга җавап бирмәде. Без бер авыз сүз сөйләшмичә генә чишмәгә барып җиттек, аннан су алдык та, ике телсез кебек ләм-мим дәшмичә өйләренә кире кайттык. Миңем күңелгә шөпшә кереп ояларга өлгергән иде инде. Үземне сүгәм: «Усак егете, имеш. Бернинди усак егете дә түгел син, белдеңме. Мокыт! Утын агачы син!»

Капка келәсенә кулы тиюгә, Гөлчәчәгем кинәт ачылып китте (аңламассың бу кызлар холкын!), кояштай балкыган матур күзләрен тутырып бер карады да:

—Әйдә, Мөхәммәт, Лачында йөрибез!—диде.

Утын агачы, ягъни усак булсам да шундук сиздем, кыз миннән чишмә сукмагындагы наянлыгым өчен үч алмакчы, көлмәкче була! Атта йөри белмәгәнемне теге көнне чамалап алган иде булса кирәк. Мин батыраеп:

—Әйдә!—дидем һәм күнелемнән Хәмит абыйның карт алашасына тагын бер тапкыр рәхмәт укыдым.

Ишегалдында кеше-кара күренми иде. Ярулла абзый урманга чыгып киткәндер, Гөлчирә апа авыл кибетенә барам дип калган иде. Гөлйөземнен өйдә икәнлеген беләм, ул чыкмый. Ник чыкмаганлыгын да яхшы беләм: мина үпкәләгән. Барыйны ияртеп килмәгәнем өчен. Нигә гел-гел мин аны үзем белән ияртеп йөрергә тиеш ди әле. Ияртмәдем шул. Сөйсә, үзе килсен. Мин менә килдем бит әле, юк-бар сәбәп эзләп таптым да йөгереп килеп життем. Имеш, Ярулла абзыйга куян тозаклары тагын кирәк түгелме икән? Әти сорарга кушты, имеш. Кушкан ди сина әти! Әгәр минем шулай дип хәйләләгәнне ишетсә, колакны борачак әле ул. Һич югында бармак янаячак!

Барыйны ияртмәвем бик яхшы булды әле, алайса чишмә суына без дүртәүләшеп барырга тиеш була идек.

Гөлчәчәк, йөгән киертеп, Лачынны ишегалдына алып чыкты, мин ана ияр салдым. Белеп торам, урманга чыгуга, Гөлчәчәк: «Атлан!»—диячәк. Ләкин анын кушуын көтеп торырга уйлап та карамадым, ишегалдында ук жинел генә ат өстенә сикереп мендем. Гөлчәчәк капканы ачты. Күрәм: кыз бик игътибар белән күзәтә, мәтәлеп төшүемне, көлкегә калуымны көтә бугай. Ачуым бер чыкса, мин бик усал малай. Әмма эчемдәгесен кызга сиздермим, ана күз кысып алам да, жай гына тезгенне тартам.

Йа! Чынлап та, Лачын лачын икән шул инде! Бу сина лырык-лырык килеп атлаган карт алаша түгел, әнә, ничек биеп бара ул. Капкадан чыккач та без шактый юл киттек, тагын Гөлчәчәк янына кире әйләнеп килдек. Рәхәт! Һәм бу рәхәтлектән тигез генә аерылырга исәбем дә юк. Гөлчәчәк, миннән көләргә жыенганына үкенә дә башлагандыр инде. Көл, әйдә көл, көләренә сәбәп булса инде әгәр... Кеше белән атны чыбыркы берләштерә дигән берәү. Лачын акрын бара. Карт алашага өйрәнгән гадәт буенча, егетләнеп китеп, тезгенне тарткаларга, аякларым белән атнын корсагын тәяргә керештем. Шулай итүем булды, Лачыным, алгы аякларын югары күтәреп, ачу белән бер кешнәп жибәрде дә томырылып чабып китте. Их! Мин тиле! Истән чыгарып жибәргәнмен бит! Бу карт алаша түгел, бу—Лачын ләбаса!

Лачын ничек тә булса мине сыртыннан сыпырып төшерү максатын куйды булса кирәк, ә мин, чытырдатып, тезген тоткан кулларым белән анын жилдә жилфердәгән ялына да ябыштым.

Хәзер әлеге хәлләр турында сөйләргә түгел, хәтта искә төшерергә дә яратмыйм. Ничек исән-сау калганымны бер үзем генә беләм.

Битемә жылы, юеш нәрсә тигәнгә күзләремне ачып жибәрдем дә... котым алынып, тиз генә йомдым: бүреме, этме колакларымны, йөзләремне ялый. Ул үзе бертуктаусыз еламсырап шыншый, борыны белән гәүдәмә төрткәли, шул арада жиннәремнән дә тарта иде. Куркуны жинеп, күзне тагын чак кына ача төшәм. Нинди эт булсын бу! Бүре бит! Дәү башлы, соры күзле чып-чын бүре ләбаса! Бер караганда Барыйларның урманда адашып калган Пиратларына да охшаган төсле үзе!

Мин тагын анымны жуйганмын.

Кабат һушыма килгәндә янымда чорсыз ат (ул агачка бәйләнгән иде) белән Гөлчәчәк басып торалар иде. Комлы юлда чалкан ятам. Үтереп сул аягым авырта. Тубык турысыннан шартлап сынганмы, әллә тайганчатнаганмы, шайтан белсен! Әмма авырту бик көчле. Әгәр янымда Гөлчәчәк булмаса, елап жибәрер хәлдә идем.

Гөлчәчәк, күземне ачуга, шатланып, яныма тезләнде, йомшак, нәни куллары белән битемнән сыпыра, кайнар бармак очлары иреннәремә кагылып-кагылып ала. Авырту басыла төшкәндәй булды. Гөлчәчәккә елмаясым килә. Тик чыраем утын агачы кебек авырту-сызланудан катып

калган. Гөлчәчәк, иелеп, тиз генә битемнән үбеп алды. «Бүре ялады бит аны!»—дип, чак кына кычкырып җибәрми калдым. Авырту бетеп китте шикелле. Исән кулым белән Гөлчәчәкне үземә таба тартам. Карышмый, буйсына! Иреннәр иренгә тиде. Ләкин бу бәхетле рәхәт мизгелләр мизгел генә булды, кинәт ат кешнәп җибәрде. Гөлчәчәк җәһәт кенә аякларына торып басты.

—Кайдадыр бүре йөриме?

Кызның тавышы куркулы. Мин аны юатмыйм. Комлы урман юлында чалкан ятам. Урман шаулый, исемнәре дә билгесез әллә нинди кошлар сайрый, чикерткәләр сикерешә, тәмле чәчәк исләре килә. Матур! Һай, матур бит бу дөнья! Әйе, бик матур икән шул!..

Көтүем елга буйларына таралып, болынны тутырган. Сарыклар «пейзаж»ны кетердәтә.

Вакыт тизрәк узсын өчен, көтүдә ничәләп сарык булыр икән дип, тәртипсез таралган малларны санарга азапланам.

Көтүдә сарык башы санап утыру миңа рәхәтлек бирә, шул рәвешле кичәдән бирле кымырҗып торган җаныма тынычлык иңәрдер төсле. Ә кичә нәрсә булды соң ул? Кичәме? Кичә кич урманга киттем. Мәктәптә укыганда әти алып биргән кызыл матай йөрерлек иде әле. Шуңа атландым да, руленә күчтәнәч салынган сумка асып, туп-туры Ярулла абзыйлар катына элдерттем. Байтактан күрешкән юк. Аннары, авылга кайтыр алдыннан гына, телефоннан Гөлчәчәк белән сөйләшкән идем.

Урманчы йортына үзем белгән кәҗә сукмагыннан гына бармакчы булдым. Матайның шул ягы шәп, сукмактан да яхшы чаба. Таныш урманыма килеп кереп, беркавым баргач, авып китә яздым, әйтерсең, моннан зур сугыш узган! Галәмәт зур түгәрәк аланлыкта бер-бер артлы төзеп куелган төрлесе-төрле зурлыктагы буралар—өй буралары, мунча буралары. Кем бураткан, нишләп шул чаклы күп! Анысы-анысы, урманны, балачак урманымны, тетеп бетергәннәр: аяк атларлык урын юк, аркылы-торкылы усак, каен агачлары, төп башлары аунап ята! Йә, Хода! Сугыш кына узмагандыр моннан! Бомба төшкәндер. Урман өстеннән очып узган берәр хәрби самолеттан берәр бомба егылып төшкәндер монда! Кая карама—төп башлары, киселгән нарат агачлары, трактор сытып-изеп узган усаклар, каеннар! Артларыннан ботаклары да җыештырылмаган. Нәрсә, әллә Ярулла абзый үлгәнме соң? Әти дә, Гөлчәчәк тә ул турыда аны-моны әйтмәделәр бит! Югыйсә, ишетелгән булыр иде! Һай, Аллакайгынам, элек мичкә ягу өчен коры утынга килә торган идек! Ярулла абзый артыбыздан ук килеп тикшерә иде, янәсе арттан ботак-чатак калмаганмы, үсеп утырган агачны екмаганбызмы! Кайда икән соң ул Ярулла абзый?!

Таныш сукмагым өстендә аркылы-торкылы юан агач ботаклары, киселгән нарат-каен башлары аунап ята. Әле һаман ис-һушымны җыя алмыйча, кире борылдым, урман буйлап сузылган комлы юлга чыктым.

Бу юлның да юл диярлеге калмаган! Танклар узган кебек. Казылып, чокырланып беткән. Әле кайчан гына без—мәктәп балалары—19 нчы май көнне шушы юлдан Әмир чишмәсендәге аланлыкка пионер туган көнен бәйрәм итәргә бара идек. Кулдагы киндер капчыкта ике-өч телем ипи, утыз өч тиенлек кильки консервасы, әни пешереп салган берничә күкәй. Без бәхетле! Өстәвенә бүген консерва ашаячакбыз! Бәйрәм! Барый белән минем арттан ике эт теркелди. Минем этем кечкенә, әмма бик чәнгелдек, усал. Сигнал кушаматлы. Барыйныкы—бүре! Әйе, әйе, әтисе Хаҗи абый күрше мари авылыннан алып кайткан иде. Имеш, Барый сөйләвенчә инде бу, марилар аны, бала вакытында урманнан табып алып кайтканнар, шуңа күрә бүрегә охшаган ул, зур башлы. Бәлки, уйласаң, чынлап та бүре баласы булгандыр әле. Күзләре, борыны, гәүдәсе генә түгел, соры йоннарына хәтле чын бүренеке шикелле инде менә. Акыллы эт ул. Акыллы икәнлеген күзләре үк әйтеп тора. Барый артыннан иярүен ияргән ул үзе, ләкин алар Барый белән дус түгел. Минем Сигнал холкы белән җилбәзәк. Әмма тыңлаучан, өстәвенә цирк эте кебек һөнәрле дә. Аны күрше Заһидулла

абый Казан юлында очратып, машинасына салып алып кайткан. Мина бүләк итте. Чынлап менә, бик һөнәрле эт Сигнал. Әти әйтә, бу эт баласы, циркътан качып, Казан юлында адашып йөргәндә очрагандыр әле Заһидулла абыена, ди. Сигнал ыргыткан таякны җәһәт кенә кире алып килеп бирә, кыршау аша сикерә, хәтта кулны чәбәкләп торсаң, арт аякларына басып, биегәндәй дә итә. Аның бу һөнәрләреннән Барый көнләшеп үлә иде инде. Чөнки аның Пират кушаматлы бүрегә охшаган эте һөнәр белми. Бик салмак, акрын ул. Тик күзләре акыллы инде менә, адәм күзләре диярсең!

Бу урманның шул тиклем таланганын Гөлчәчәк нигә сөйләмәде икән соң? Петербургтан кайтканнан бирле без хәзер гел күрешеп торабыз бит.

Мәктәп тәмамлагач, мин Казан сәнгать мәктәбенә барып кердем. Аягым гарип булганга,—теге чакта ат өстеннән егылып төшеп имгәнгән аяк,—хәрби хезмәткә яраксыз дип таптылар; сизелерлек аксамасам да тубыктан бөгелеп бетми. Казанда укыганда ук мина «ак билет» тоттырдылар. Сәнгать мәктәбеннән соң мин, үҗәт-үзсүзле малай, Ленинградтагы сәнгать Академиясенә—Репин исемендәге югары уку йортына барып керә алдым.

Барый Пиратны кыйный, кулына ни туры килсә, шуның белән бәрә, Сигнал кебек һөнәрләргә өйрәтмәкче була. Нигә каһәрлисең аны дип, гел каршы төшәм. Барый, телгә беткән малай, бер сүз белән генә минем авызны каплый да куя. Этнең койрыгын кем күбрәк кисә, ул шуңа тугрылыклырак була, янәсе! Була сиңа, бар! Гел алай яманлык белән генә булмый ул! Булмый икән шул! Пират кыенга түзә алмады, көннәрдән бер көнне Барыйга ияреп урманга барган җиреннән кире әйләнеп кайтмады. Тагын кыйнаган булгандыр инде!

Читкәрәк киттем бугай. Нишләтәсең, бүгенгедәй истә бит.

Матай казылган юлдан бара алмагач, кырыйга каердым.

... Сарыкларым, көтүченең игътибар итмәвен сизеп, төрлесе-төрле якка чәчелә башлаган. Мин аларны җыярга керештем. Урман ягына борылып карыйсым килми.

Тора-бара Петербургтан кайтулар сирәгәйде. Гөлчәчәк белән йә телефоннан сөйләшәбез, янсә сагыну хатлары язышa идек. Гөлчәчәгемне берәүгә дә алыштырмадым. Группа кызлары: «Однолюб» дип кушамат тактылар.

Академиядә укыган чагында мин рәсем сәнгатенең серләренә тагын да тирәнрәк төшендем. Шуның өстенә тәмәке тартырга өйрәндем, сакал үстереп җибәрдем.

Кичә кич бөек рәссам кыяфәтендә кызыл матайга атланып булачак кияү-балакай, ягъни мин барганда Ярулла абый өйдә туры килмәде. Игезәк сыңары Гөлйөзем үзенең ат заводында иде, аны эзләп йөрмәдем. Барые килеп эзләсен дидем. Хәер, кайгысын уртаклашсам буласы икән дә. Мин шул көнне урманнан әйләнеп кайткач, әни яна хәбәр житкерде. Күптән түгел Гөлйөземнең ике яшьлек малае суга төшкәндәй юкка чыккан. Өй янында ялгыз башы уйнап йөргән җиреннән югалган бала. Эзли-эзли бөтен урманны аркылы-торкылы карап чыкканнар—бала табылмаган. Мин, нигә аны кайтуга ук әйтмәдең дигәндәй, әнигә үпкәле караш ташладым да, беркавем ишегалдында таптанып йөргәннән соң Барыйларга сугыласы иттем. Әнисе Хәдичә апа: «Барый районда»,—диде.

Югалган бала Гөлйөземнеке генә түгел, ул Барый малае да иде ич! Моның шулай икәнлеген бар авыл белә, алар аны үзләре дә яшермиләр. Һәм берни булмагандай бер-берсенә килеп-китеп кунакка да йөрешәләр.

Бергә яшәмәсәләр дә... Хәер, ни генә булмасын, мөнәсәбәтләре барыбер сәер иде. Авыл халкы баштарак чәйнәде-чәйнәде дә хәзер иләнде, ризалашты—исләре китми, аерым торалармы, бергәме—авылның анда эше юк. Дөрес булса, Барыйның авыл саен никахсыз хатыннары, законсыз балалары бар ди. Булдыра икән яшь хуҗа!..

Мин түзмәдем, өйгә кире кайтып матайны кабыздым да урманга чыгып киттем. Ташсу елгасына таба сузылган комлы юлдан (безнең якта туфрак комлы, көне-төне чиләкләп яңгыр яуганнан соң да, кояшы карап торса, жир өйлә вакытына кибет бетеп, юлда тузан оча башлый) урманга

таба юнәлдем. Көн кичкә авышкан булса да җәйге көннен кызуы әле сүрелеп өлгермәгән, җылы җил күлмәк изүе аша, җин очларыннан үтеп кереп, тәнне рәхәт кытыклый. Матай гына булса да, артта машина узган кебек тузан болыты. Каршыма урман ягыннан ак машина килеп чыкты. Дәүләт номерлары урынына алгы тәрәзәсенә транзит кәгазе ябыштырылган. Мин акрынайдым. Тузан туздырып килүче машина да акрынаер, тузанга батырмас дип уйлап, әллә ни читкә дә чыкмадым. Ләкин ак машина минем яннан узганда тагын да кызулады, аптыравымнан авызымны ачып калдым дисәм дөрес булмас, чөнки авызга бер пот тузан кереп тулачак иде. Сәмигулла иде бу! Ул, мокыт, баштанаяк тузанга коендырып китте! Юри эшләде ул моны, мине шул рәвешле мыскыл итәсе, көләсе килде бугай! Шып туктадым. Чөнки сулап булырлык түгел, авыз-борыным ком белән тулды, чәч-башлар, киемнәр тузанга батты. Судан чыккан ата каз кебек кагына-кагына: «мокыт!»—дип кычкырып калдым. Куып житеп, машинасыннан сөйрәп төшерәсем, тукмап атасым да килгән иде. Тик бу уемнан шундук кире кайттым. Мәктәптә укыганда ул җылак Сәмигне күп тукмадым инде мин. Әләкче иде ул.

Тузаннан арынгач, матаемны кабыздым, анын утыргычларында да катлам-катлам тузан иде.

Матаемны капка төбендә калдырдым да, шакымый-нитми генә, үз кеше кебек, урман каравылчысының имән ишеген тарттым. Гөлйөзем өйгә кеше керүен сизми калды, ул киемнәрен алыштыра иде. Чалбарын салып урындык артына элгән, ярым шәрә килеш идән уртасында басып тора, кулында халаты, тырыша-тырыша ул анын унай ягын әйләндереп маташа. Мин кире чигендем, тышкы ишек катына ук барып, тамак кырдым. Киен тизрәк, кеше бар янәсе. Гөлйөзем «абау!» дип кычкырып, зал ишеген ябып куйды да, беркавымнан, халатын төймәле-төймәли атылып чыкты.

—Уф, Аллам! Кеше куркытып йөрмәсәң!

—Исәнме, Гөлйөзем!

—Исәнме, Мөхәммәт, исәнме, Уз, әйдә.

Үзем дә сизмәстән, чекрәеп, хатынның йөзенә текәлдем. Ябыккан, суырылган Гөлйөзем. Бала кайгысы, күрәсең, аны шулай бетәштергән, тагын ни булсын! Әмма Гөлйөзем Гөлйөзем булып калган. Бәхеткә күрә, анын гел янып, яктырып, балкып торган шомырт күзләре сүрелмәгән. Малае хакында сүз кушкач, ул ике сүз белән генә:

—Бүре алып китте Әнвәремне!—дип, офтанды да, башка бу хакта сөйләшәсе килмәде. Авыр иде ана, әйтеп-анлатып булмастай авыр иде!..

Һай, Гөлйөзем! Тормыш шулай шул ул, тиктомалдан гына гел көтелмәгән яктан, күсәк белән китерә дә суга. Сизми дә каласың. Бик бирешмә инде син! Кайгы кешеләрне берләштерә бит ул. Барысын да никах укытып, сине алып кайтып китәр. Начар малай түгел бит ул, күнеле яхшы анын! Менә, күрерсен.

Гөлйөземдә Гөлчәчәк чалымнары бар дисәм, хата сүз булыр, чалымнар гына түгел, игезәкләр бер-берсенә коеп куйгандай охшаган, нәкъ менә бер тамчы чык инде. Элек мин аларны битләрендәге миннәреннән генә аера идем. Аны күргәч, Гөлчәчәкне сагына башлавымны тойдым. Күптәнге танышынын килеп керүе Гөлйөземне дә сөендергән күрәсен. Ул йөгереп барып чәй куйды, өстәл хәстәрли башлады.

—Юк, юк, Гөлйөзем, мәшәкатьләнмә. Чәйләр эчеп тормыйм. Синен хәленне белешергә генә килгән идем,—дип, ишеккә таба атладым.

—Хәл дип... нәрсәсен белешәсең инде анын. Бер ай була инде.

—Барый килеп керсә дә, яхшы булмас.

Гөлйөзем Барый дигән исемне ишеткәч, кинәт агарып китте, йөзендәге хәсрәт томанын җил куып тараттымыни, хәтта ул көлемсерәп тә куйды һәм:

—Барый кичкырын урманга килергә курка ул!—диде. Хатынның йөзе ачулы.

—Нишләп курыксын! Мылтыгы бар ич анын. Минем кебек матайга

атланып та йөрми. Машинасы бар,—дидем Гөлйөземгә каршы.

Әлбәттә, Барыйны яклап әйтүем түгел, сүз булсын дип кенә инде. Кем белә, Барыйны яклап маташуым Гөлйөземгә ошармы, юкмы? Гөлйөзем бу юлы кычкырып ук көлеп җибәрде.

—Мылтык дисен син, Мөхәммәт! Кая мылтык кына! Машинада граната да йөртә әле ул. Чын менә! Шунын өстенә газовый пистолет! Газ баллоны! Тот та хет бүген ук Чечняга җибәр! Вооруженный да зубов! Чөнки аны инде менә елдан артык күрше мари авылы егетләре сагалап йөри. Анда да бер мари кызына бала ясап киткән бит ул, ата мәче!

Бу хәбәрне инде ишеткән булсам да, Гөлйөземгә кушылып көлмичә түзә алмадым.

—Ну, Барый! Өлгер егет икән!

Без Гөлйөзем белән утырып чәй эчтек. Урман буйларына әнгер-мәнгер төшә башлады. Мин кайтырга кузгалдым. Ишекне ачам дип, ишеккә үреләм дигәндә генә,—сизми дә калдым,—Гөйөзем кинәт муеныма асылынды.

—Кунып кит, Мөхәммәт!

Анын кайнар сулышы битләремне, муенымны пешерде. Мин коелып төштем. Дөресрәге, баскан җиремдә бер каен букәненә әйләндем дә калдым, ни кылырга белмәдем.

—Үч аласым килә минем ул Барыйдан. Әүвәл үч алам, аннан сон законный кияүгә чыгам мин ана!

Ниһаять, минә да тел керде бугай.

—Гөлйөзем, дидем пышылдап.—Әйдә, тынычлан әле син!

—Минем Гөлчәчәктән дә үч аласым килә, анлыйсынмы, Мөхәммәт!

Монысы һич анлашылмый иде инде. Барыйдан үч алуын анлыйм. Чөнки Барыйны үзе ата мәче диде. Ә Гөлчәчәкнен, Гөлчәчәкнен нинди гаебе бар? Игезәк сынарынын?..

—Башта Барый минем арттан йөри башлагач, анын янына чыкмый идем. Гөлчәчәк, этә-төртә, мине Барый янына чыгарга кыстый. Аптырагач, беркөнне үзе чыгып китте. Карангы төшкән иде шул. Барый Гөлчәчәкне танымаган. Мин дип уйлаган. Мине көнләштерү өчен икенче көнне дә чыгып китте Гөлчәчәгем. Өченче көнне дә чыгам дигән иде. Чыгармадым, үзем киендем. Хәзер шуна үкенәм инде. Гөлчәчәк булмаса, Барый белән йөреп китәсе түгел идем. Син, Мөхәммәт, Гөлчәчәк турында начар уйлый күрмә тагы. Ул сине ярата, ул синен белән бәхетле булачагын белә. Барый янына шаяртып кына, көнләштерер өчен генә чыкты ул. Чөнки аны җәлли иде. Анын җавапсыз мәхәббәтен кызгана иде ул. Ә теге вакытта ике чыгуында мин булып сөйләшеп кергән. Үбәргә үрелгән иде, янагына чалтыраттым, диде.

Мин телсез калдым. Әлбәттә, бу халәтемне Гөлйөзем яхшы анлады, ул минем кулымны тотып, түргә әйдәде. Мин карышмадым. Һаман үз анымда түгел идем әле. Хәер, Гөлйөземнен сонгы сүзләре томан пәрдәсен бераз ача төшкән, күкрәгемдә гөлт итеп кабынган көнчелек уты, шактый сүрелеп, төтенли генә башлаган иде. «Барый янына шаяртып кына... Мине көнләштерер өчен генә чыкты ул. Капканын эчке ягында нәрсә сөйләшкәннәрен шыпырт кына тынлап тордым. Барый Гөлчәчәккә: «Гөлйөзем, мин сине үлеп яратам бит!»—дигәнен ишеткәч, түзә алмадым, өченче көнне үзем йөгереп чыгып киттем. Күнелем белән Барыйны кабул итеп бетерә алмасам да. Һай, Гөлчәчәк кенә гаепле! Ул шул рәвешле кыланмаган булса, ул ата мәчегә борылып та карамаган булыр идем! Минем әле Гөлчәчәк кебек анын янагына да чылтырата алганым юк!»

Әйе, бу сүзләр мине айнытты, тора-бара көнчелек уты хәтта төтенләми дә башлады, бөтенләй сүнде.

Гөлйөзем мине шаша-шаша үбәргә кереште, күлмәгемне аерып төшерде. Авызымны ачып һәм нишләргә белмичә, катып торган арада өстендәге халатын салып атты. Каршымда бая ялгыш кына күргән яшь шәрә хатын басып тора иде. Анын кайнар куллары: мине, күзле букәнне, караватка төртеп екты. Абайламыйча карават өстендә йоклап яткан кара

мәче өстенә барып төшкәнмен икән. Ул, мыраулап кычкырып, идәнгә атылды. Гөлйөзем, һаман шашып, кайнарланып үбә, бу вакытта үземнең тәндәге күзәнәкләр дә уянып, хатынны кочакларга батырчылык иткән идем инде. Ничек кенә тырышсам да хисләр каршында акылымның бәләкәйләнеп, көчсезләнеп калганын тойдым. Үз-үземә ачуым килде. Шул рәвешле үз-үземне әрли-сүгә, орыша-тирги һаман хатынның шәрә тәне буенча кармаландым.

—Гөлчәчәк! Гөлчәчәгем минем!

Авызымнан ялгыш шул исем чыгу булды, Гөлйөземне алыштырып куйдылармыни, ул ялт итеп сикереп торды да җәһәт кенә өстенә халатын элеп, әмма тыныч, йомшак тавыш белән:

—Гафу ит инде син мине, Мөхәммәт. Бар, кайтып кит, Мөхәммәт,—диде, идәндә аунап яткан кыска җинле күлмәгемне өстемә ташлады.

«Ә» димәдем, «җә» димәдем, яна гына кышкы йокысыннан уянган аю кебек алпан-тилпән килеп, идән сайгакларын шыгырдата-шыгырдата, ишеккә таба атладым. Кулым тотканны эзләп тапкач, артыма борылып карадым. Гөлйөзем мендәргә капланган да үксеп-үксеп елый иде. Аның иң башлары калтырый. «Ела, ела! Сиңа елау бик файдалы ул, Гөлйөзем,—дип пышылдадым мин.—Елау жинеләйтеп җибәрә ул...»

Елга ярына ак «Волга» килеп туктады. Әле яңа, буяулары да йолык-йолык килеп тора. Машинадан Барый килеп чыкты. Авызын ерган. Сагынгандыр, яшьлек дустым бит. Казанда чакта үзем дә юксынам аны. Барый артыннан ук машинадан ике малай да төште, үзебезнең авыл малайлары, бәйрәмчә киенгәннәр, күрәсең. Барый аларны сабантуй мәйданыннан ук утырткандыр.

—Менә сиңа көтүчеләр алып килдем!—диде Барый ике кулын сузып, миңа таба күрешергә килә-килә.—Даһи башың белән көтү көтеп йөрмәссең бит инде! Ха! Бигрәк кызык килеп чыга икән: бөек художник һәм көтүче! Шул рәвешле тарихка кереп каласың килә ахыры синең! Ярамый, брат, ярамый, ярамый!

—Нишләп ярамасын,—дим Барыйның кулларын учларымда кысып.—«Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек» дигәнме әле!

—Чепуха! Син күптән күтәрелдең инде!

Барый бервакытта да тиктомалдан гына мактый белми иде. Мин аңа сынаулы карашымны ташладым. Барый дустымның «мунчала»сына беркадәр коңгырт төс керә башлаган димме? Зәңгәр күзләре дә, эрекмән колагы да шул ук, үзгәрмәгәннәр. Хәер, күрешмәгәнебезгә ярты еллап кына бит әле. Узган кайтканында үзен күрмәдем, шоферы районга чаклы илтеп куйган иде куюын.

—Машинаны күлмәк алыштырган кебек алыштырасың син малай, ә!—дим, ак «Волга»га ымлап.

Яшьтәшем һәрвакыттагыча тапкыр, җавапсыз кала торганнардан түгел:

—Машина—не роскошь! А средство передвижения!

—Барый, малайларны сабантуеннан аермаска иде бит, ә?

Барый сүз уңаеннан малайларның да күңелен күреп алды:

—Нинди малайлар булсын алар! Быел икесенә бер комбайн бирәм мин аларның! Күрмисеңмени, полный җегетләр бит инде!

Барый түш кесәсеннән шытырдап торган ике йөзәрлек чыгарып малайларга бирде.

—Көтүне шәпләп көтегез, яме! Колхоз печәнлеген таптату обязательно түгел, аңладыгызмы!

Малайларның берсе минем чыбыркыны алды.

—Их, урман буенда рәхәтләнеп йөрергә исәп иде! Ирек бирмәдең бит, брат, ә!—дип, мин дустымның иңбашын шапылдатып алдым.

—Нием калган сиңа урман буенда! Гөлчәчәгең барыбер кайта алмаган.

—Гөлйөзем монда булгач сиңа рәхәт!—дидем шаяртып.

Кинәт Барыйның йөзе сытылып китте, әмма ул минем моңа игътибар иткәнне сизеп булса кирәк, үзен бик тиз кулга алды, хәтта көчәнеп елмайды да әле.

—Гөлйөзем кая китсен ди ул! Урман буендагы ат заводының башлыгы ул хәзер. Юртаклар үрчетәбез бит, туган, юртаклар. Икесе хәтта Франциядән кайтарылган!..

—Аһа, зур эшләр майтарып йөрисен икән әле син.

—Беләсең, ат белән хатын-кызга үлеп гашыйк бит мин!

Барый шаркылдап көлеп җибәрде. Һаман кеше төсле көлә белми икән әле бу дип, уйлап куйдым.

—Ат заводы ерунда ул, брат! Аннан да зуррак эшләр тора әле монда! Алла боерса, тиздән революция ясыйбыз!

—Беләм, беләм, ишеттем инде. Авылны күчерергә йөрисез икән. Халык зар елый. Берәүнен дә күченәсе килми.

Барый житдиләнеп китте, беркавым дәшми торганнан соң (без машинага кереп утырган идек инде):

—Күчәрләр, брат. Йөгерә-йөгерә күчәрләр! Их, рөхсәт алсаммы!

—Анламыйм мин, Барый! Авылны тау башына күчереп утырту нигә кирәк сон сина, ә?

—Нигә кирәк дисезме? Һи, кирәк, брат, кирәк. Бик кирәк.

—Алайса анлатып карале?

—Минем бабам егерме бишенче елда тау башындагы авылны үзәнгә күчереп утыртканмы—утырткан. Шул күченү мәшәкате белән халык революцияне генә түгел, хәтта ата-анасын да онытакан.

—Йә, шуннан.

—Шуннанмы? Шуннан, брат, хәзер үзәндәге авылны мин тау башына кире күчерәм инде! Анладынмы?

—Бернәрсә дә анламадым, брат.

Барый инбашларын сикертеп, мина таба борылып карады. Ул машинаны кабызган иде, кире сүндерде һәм, шуны да анламыйсынмы инде дигәндәй, әүвәл беркавым сәерсенеп карап торды.

—Бабай тау башыннан үзәнгә күчергән. Мин кире менгезәм. Минем малай яки онык аны, кирәк тапса, тау башыннан янадан үзәнгә күчерәчәк!..

Әллә Барый фикерен әйтеп бетерми, әллә үзем анлап житкермим инде, карашым һаман сораулы иде әле. Барый, сина анлатканчы дигәндәй, жәһәт кенә машинасын кабызды. Кузгалып киттек. Авыл белән елга арасында комлык бар безнен. Комы бик әйбәт, балчык изгәндә төпкә дә утырмый, мич чыгарырга яраклы диләр. Комлык турысына житкәч, Барый дустым машинасын шып туктатты да тәрәзәдән комлыкка таба ишарәләп:

—Күрәсенме, жил елга ягыннан исә. Комны да шул якка, үзе искән тарафка күчерә. Авыл ягыннан искәндә, киресенчә, ул комны шул якка—елгага таба себерә. Мәнге шулай, әле авыл ягына, әле елгага таба. Кыскасы, әле болай, әле тегеләй. Гел хәрәкәттә, гел тудый-судый. Син, тау башына күченүнен халыкка ни файдасы бар, дип сорыйсын. Файдасы турында кем уйлап торган инде анын, брат. Самый главный хәрәкәт булсын! Селкенергә кирәк халыкка, хәрәкәт кирәк. Тормыш гел хәрәкәттән торырга тиеш, брат. Хәтерлисенме, Һади абый безнең чүбек башларга тырыша-тырыша дөнья философиясен тутырган иде. Ул һаман истә әле минем. Син хәтерлисенме Ницшены: «Кем муеннан эшкә чумган, анын нәрсә эшләгәнен уйлап торырга вакыты юк, дигәнме?» Сүзен сүзгә китерәм, урысча, үзебез анлаганча: «У кого много дел, тот сохраняет свои общие взгляды и точки зрения почти неизменными. То же бывает со всяким, кто трудится во имя какой либо идеи: он уже никогда не будет проверять саму идею, так как для этого у него нет времени; более того, его интересам противоречит вообще допущение какого либо ее обсуждения».

Барый мина карады. Хәзер анладынмы инде, ди кебек иде анын бу карашы. Ә мин барыбер берни анламадым. Әллә кайчангы, әллә кайдагы немец ни әйтмәс!

—Ницше кешегә шулай булырга кушмаган,—дип каршы киләм мин.

—... его интересам противоречит вообще допущение какого либо ее обсуждения.

Түзмәдем, көлеп жибәрдем. Һәм дустымның җилкәсенә кулымны куеп, аны үземә таба тарттым:

—Ну, Барый, әйттең син, малай!

—Мин әйткән сүзләр түгел... что ценить каждого исключительно как средство для своей собственной цели и не признаешь в других отношениях. Монысы—синең «кешеләр» дигән сүзләренә җавап, брат!

—Гитлер да Ницше тәгълиматен өйрәнеп эш иткән. Ярый ла, синең бабаң колхоз председателе, бронь эләктереп өлгергән. Минем ике бабам да сугышта үлеп калганнар!!!

Барыйга да, аның Ницшесына да ачуым килә башлаган иде. Бу халәтем сүзләремә дә, йөземә дә чыкты бугай, чөнки ул аны шундук сизеп алды. Дәшмәде, җавап кайтармады, үрелеп, арткы утыргычтан кәгазь тартма алды да, аны ике арага урнаштырып, ачып җибәрде. Мин сул күземнең кырые белән генә тартма эченә карадым: ул аракы, сыра һәм кабымлыклар белән дыңгычлап тутырылган иде.

—Сабан туе бит бүген, брат! Бәйрәм бүген! Әйдә, берәрне кәгеп алыйк әле шул хөрмәткә!

Минем, моннан ярты еллап элек, эшләрем бүләккә тәкъдим ителеп тә, бер талантсыз ялагай адәм җинеп чыкканнан соң, ачудан дөньясына төкерә-төкерә эчеп-буталып алганнан бирле аракы ише нәрсәне авызыма да алганым юк иде. Ул чакта мине Сиринә Самуиловна айныткан иде. Ике эшемне Англиягә күргәзмәгә җибәртергә сөйләшкән булган һәм ун-унбиш көн эчендә без үзебез дә аның белән чит илгә чыгарга тиеш идек. Минем «творческий запой» тәмамланган гына вакыт, үзем салкын көнне дә шабыр тиргә батам, өстәвенә кан басымы уйный, күзләрем куян күзе кебек кызыл. Шул хәлдә мин чит ил паспорты һәм виза артыннан чаптым. Тиз айнытты мине Сиринә Самуиловна! «Рәссамнар һәрвакыт чак кына салмыш һәм сакаллы булырга тиеш» дигән принципларны читкә куеп торырга туры килде. Хәер, салгалап йөрүемә Гөлчәчәк тә каршы иде, ул шул хакта ым кагуга, мин аны тиз хәл иттем. Бүген сабан туе, бүген бәйрәм! Бүген мин туган авылымда, янымда яшьлек дустым Барый.

Чак кына кәефләнеп алдык.

—Синең сабан туенны кем алып бара соң?—дип, сорыйм Барыйдан.

—Сельсәвит!—диде ул, казылыгын чәйни-чәйни.—Син көтү көтеп ятканда мин бәйрәм итеп йөрмәм бит инде,—дип тә өстәп куйды.

Барый күңелле күрә белә. Хәер, шулай булмаса, җитәкче булып та эшли алмас иде ул.

—Слушай, брат,—диде Барый рюмкаларга аракы койганнан соң. Шатлыклы хәбәр! Бүген таң тишегеннән районга чакырттылар. Синең авылда, отпускада икәнлегеңне белгәннәр, дөнья бетереп Казан эзли сине анда!

Мин, аптырап, Барыйга карадым: «Нигә?».

—«Урман кызы» дигән картинаңа Мәскәү кунагының күзе төшкән. Дәрәҗәле, бер зур түрә хатынының.

—Кит! Булмаганны!—дип, кычкырып җибәрүемне үзем дә сизми калдым, кулымдагы аракы чайкалып, тез башларына түгелде.—Ул картина остаханәдә саклана бит! Аннан соң мин аны берәүгә дә күрсәтергә уйлаганым да, күрсәткәнем дә юк! Сатыла да, бүләк ителә дә торган картина түгел ул!

—Анысы мина караңгы, брат. Әйдә, конторга киттек. Сина Казанга шалтыратырга куштылар. Ниндидер начальникның замы, Сиринә Самуиловна диме шунда?

Йа! Сиринә Самуиловна мине моннан да эзләп тапкан! Ул чая хатынның мина мәңге тынгы бирәсе юк! Димәк, мәскәүлеләрне остаханәмә дә ул алып кергән! Ичмасам, андагы шешәләрне алгалап куйдымы икән соң!

—Бүләк ителә торган картина түгел ул!—дидем мин, Барыйга ачулы караш ташлап. Әйтерсең, монда Барый гаепле иде. Югыйсә, аның ул картинаны күргәне дә юк бит. Ул минем ничәмә-ничә еллар буена, кырыкмаса-кырык кат сыза-сыза, төннәр буе иҗат иткән картинам! Ул Гөлчәчәк өчен!

Әгәр дә минем урманымны шәһәргә алып китә алсан, сина ияреп китәм дип, әллә шаяртып, әллә чын-чынлап әйткән иде бит Гөлчәчәк... Ниһаять, анын урманын рам арасына сыйдыра алдым бугай. Үзенә дә күрсәтергә өлгермәдем. Ашыкмый да идем әле. Чөнки ул көн минем тормышымда гаять зур вакыйга булачак, ул көнне мин дистә еллар буе зарыгып көттем, ул мизгелләр ничәмә-ничә еллар жиде төн уртасында төшләремә керел сөендерә, сөелергә, сөяргә ашкынып торган йөрәгемне өмет утында яшәтә, кыскасы, әгәр шул картина ижат итәргә моннан ун ел элек максат итеп куймасам, бәлки, рәссам булып та китмәс идем. Архитектор булган булыр идем, төзүче...

Барыйга боларны сөйләп тә, анлатып та торасым килми. Хәер, «Урман кызы» дигәч, сизенә торгандыр инде. Анын үзенен дә урман кызы бар бит!

Шулай да конторага барудан баш тартмадым, Сиринә Самуиловнага шалтыратып, эшнен нәрсәдә икәнлеген үземнен ачыклыйсым килә, берочтан минем эшләргә рөхсәтсез кысылып, тыгылып йөргәне өчен үпкәмне дә белдерермен, дип уйладым.

Хәер, рөхсәтсез дип инде... Остаханә ачкычымны ана үзем биргән идем бит. Кысылып, тыгылып диюем дә урынсызрак бугай. Әгәр Сиринә Самуиловна булмаса, Казандагы көнче дусларым ук мине, бер теләксез авыл малаен, күптән төкереп чүплеккә аткан булырлар иде. Әйе, әйе, үзен дә сизми калачаксын. Терсәк сугышы заманы бу! Кул күтәреп, йодрык йомарлап, мона сугам әле дип, зурдан кубып сукмыйлар хәзер, терсәк белән генә төртеп алалар. Кем төрткәнен дә, нигә төрткәнен дә сизми каласын. Безнен татарда бу бигрәк тә шулай. Яһүд булса, бер-берсен ничек тә булса йолка, тарта, күтәрә әле. Безнен туганнын исә очлы терсәге һәрвакыт һөжүмгә әзер. Ерак бабайлардан килгән кан безнен тамырларда да ага. Юкса, заманасында, тәхет өчен сугыша-сугыша хәлләре бетеп, мескенлеккә төшеп, үзләрен урыслардан тукматырга ирек куярлар идеме сон?.. Шул рәвешле мәнгелек коллыкка төшәргә риза булырлар идеме? Дүрт гасыр буе маржа итәге астында бит инде бу халык! Яман холкы, терсәк сугышы, бер-берсен сату, сыту, изү һәм көнләшү һаман бетә алмый!.. Үз бәхетен тәхеттә генә дип уйлаган халык мәнге яктылыкка чыга алмаячак!..

Мин милләтче түгел. Бары тик татарнын тарихын яхшы беләм, чын тарихын. Үзем аралашып йөргән язучы дусларым белән без бик еш шул темаларга гәп куертабыз. Язучылар арасында да каткан милләтчеләр юк. Татарнын бу хәленә аларнын йөрәкләре авырта. Минеке дә авырта, сызлый.

Һай, терсәк сугышы дигән спортнын яна төрен уйлап табып, шунын дөнья чемпионатында катнаштырасы иде безнен татарны! Алтын медаль белән күкрәкләре тулыр иде, билләһи!..

Барый дустымнын машинасында барганда әнә шуларны уйладым мин. Барый да күнелемдәге тойгыларнын каршылыклы һәм төссез икәнлеген чамалый бугай. Үзенчә юатмакчы була:

—Балтан суга төшкән кебек утырма әле, брат, ә! Гөлчәчәгенне бүләк итәргә кушмыйлар бит. Картинаны син тагын ясыйсын бит аны! Между прочим, бик талантлы художник диләр сине. Беркөнне телевизорда кич буе мактадылар.

Мин дәшмим. Үземнен талантлы икәнлегемне беләм, шуна күрә дә дәшмим.

Шалтыраттым. Сиринә Самуиловна өендә дә, эштә дә юк иде. Шуннан сон Барый Казанны үзе жыярга кереште. Анын кешесе урынында иде. Барыйнын сөйләшүенә, бигрәк тә мизгел эчендә ялагайлы елмаю катыш курку, каушау чыккан кыяфәтенә караганда, телефоннын теге очындагы кеше түрә, һәм шактый зур түрә булырга тиеш.

—Хәниф Хатыпович! Мин идем әле бу, Барый. Байтимердән. Председатель. Колхоздан. Хәниф Хатыпович! Сабан туена көткән идек Сезне. Кайта алмадыгыз, ахрысы? (Ул бер ара тын торды. Күрәсен, Казан кешесе нидер әйтә бугай). Хәниф Хатыпович! Уразов белән сөйләштем мин. Ул риза, Хәниф Хатыпович! Яхшы, Хәниф Хатыпович! Рәхмәт, Хәниф Хатыпо-

вич! Сез әйткәч, тырыштык инде, Хәниф Хатыпович! Сау булып торыгыз, Хәниф Хатыпович!

Мин өнсез калдым. Барый телефонын шапылдатып аппаратына куйгач кына аңыма килдем һәм аның изүеннән каптырып алдым:

—Нәрсә диден син?! Нәрсәгә риза диден мине! Пред дип тормыйм, тәрәзәннән очырам бит хәзер үзенне!—дип, аны җилтерәтергә керешкәнемне сизми дә калдым. Ләкин Барый тыныч иде. Аның баягы ялагайлы елмаюы хәзер чын, дусларча елмаю белән алышынды.

—Туктале, брат. Тынычлан әле. Беләсенме кем белән сөйләштем мин?

—Беләсем дә килми! Син мине нәрсәгә риза диден? Картинаны бүләк итәргәме? Менә сезгә картина, менә кукиш, яме!

—Тынычлан әле дим бит, Мөхәммәт, дустым, брат! Причем монда бүләк итү! Сиринә Самуиловнаң синең киребеткән, үҗәт икәнлегенне, сине ризалатуның кыен булачагын әйткән булган икән инде Хәниф Хатыпычка. Сатып алабыз, ди. Долларга, брат, долларга! Монарчы синең төшенә дә кереп карамаган суммага!

—Кукиш!—дип кабатладым Барыйның изүләрен ычкындырып.

Барый, минем тарафка кулын селтәп, урыныннан торды да, суыткычын ачып өстәл өстенә шешә һәм кабымлык чыгарып утыртты.

—Кызма әле син, брат! Юкка нервыланма!

—Как-так нервыланмыйм ди мин! Минем картинада синең ни эшең бар!!!

—Мөхәммәт, дим, дустым, аңла инде. Байтимерне тау башына күчерү мәсьәләсен тик Хәниф Хатыпович кына хәл итәчәк! Ул миннән синең белән сөйләшергә попросил. Ышанмасаң, Сиринә Самуиловнадан шалтыратып сора.

Һаман юньләп берни аңлап житкермәгән идем әле. Кабат Казанны жыярга керештем, бу юлы Сиринә Самуиловнаны өендә туры китердем. Мәсьәлә аңлашыла төште. Сиринә Самуиловна Мәскәү кунагы хатынына «Урман кызы»н күрсәткән. Ул аңа бик охшаган, шуның өстенә миңа бер бүлмәле фатиремда урнашкан кысан остаханәм урынына, икенчесен, үзәктә зур фатир бирергә тиешләр икән. Әгәр «Урман кызы»н бүләк иткән очракта инде...

Мин лып итеп артыма утырдым. Сиринә Самуиловнага Барыйга кычкырган кебек жикеренә алмый идем, әлбәттә. Ак димәдем, кара димәдем, телефонны ташладым да, Барый өстәлендәге рюмканы кулыма алдым.

—Әйдә, Барый дустым, сабан туе хөрмәтенә, берәрне тотып куйыйк әле! Ә картина, кабатлап әйтәм, кукиш аларга! Син дөрес әйтәсең, нигә юкка нервыланам соң әле? Бирмим дигәч, бирмим инде, әйе бит, дустым? Остаханәләре үзләренә булсын!

—Киреләнмә, Мөхәммәт, остаханә дип, күптән хыялланасың бит инде син!

—Элек хыяллансам, менә хәзер хыялланмыйм инде. Кадалып китсеннәр шунда! Әйдә, эчеп җибәрик әле!

Барый минем белән чәкештерергә үрелде. Ул бераз тынычланып калган һәм мине ризалатачагына да һичшиксез ышана бугай, «мунчала баш»!

—Написать картину может последний дурак, а вот продавать ее только умный сумеет. Кем әйткән моны, беләсенме?

—Белмим. Беләсем дә килми!

—Мин дә белмим. Анысы не важно. Но әйткәннәр бит! Һәм дөрес әйткәннәр, брат! Синең турыда әйткәннәр моны, понимаешь!

Мәсьәлә тәмам ачыкланды. Мәскәү түрәсенең хатыны тагын ике атнадан Казан сабантуена килергә тиеш икән. Минем «Урман кызы»ым шул вакытка бүләк ителергә әзер булырга тиеш икән ди...

* * *

Бер атналык ялым өзелде. Мин тагын Казанда. Таш кала, баш кала. Элек минем бабаларымныкы гына булган шәһәр. Казан... Син хәзер хәтта губерна башы да түгел инде! Синең белән элеккечә Мәскәүдән

торып түгел, Түбән Новгородтан—губерна тәхете хәзер шунда—идарә итәрләр. Район үзәге, гап-гади бер райүзәк син хәзер, Казаным!..

Гасыр ахырында чак кына кымшанып куйган идең син, селкенеп алган идең, өстеңдәге тузаннарны кагынгандай иттең дә янә тынып калдың. Йөгән, дөресрәге, тагын авызлык киертелде сиңа, Казан... Ахырзаман житүе шулмы икән әллә, Казан? Милләт ахырзаманы...

Ачуланма миңа, Казан! Кәеф юк минем бүген. Картинам Мәскәү кунагына кирәк дигәч кенә киреләнеп, ачудан сүгенү бу! Шуңа күрә башыма чүбек кебек кирәксез һәм күңелсез уйлар туган. Тизрәк шагыйрь дусларымны күрергә, чак кына булса да алар белән аралашырга кирәктер. Алар оптимистлар. Алар сиңа борын салындырып утырырга ирек бирми инде...

Менә безнең Ватан.
Соңгы көне булып сүреләм дә,
өр-яңадан таңы булып атам.

Бу юлларның авторы чыкылдаган мишәр егете. Дустым... Мишәрләр белән яһүдләр өсләренә яңгыр урынына таш яуса да төшенкелеккә бирелмәсләр. Алардан үрнәк алырга кирәк. Минем тамырларда да ерак бабалардан килгән кыпчак-мишәр каны ага. Өстәвенә нугай бабалар каны. Кыяфәттә нугайлык чалымнары—кысык күзләр, табак бит—кайда мишәрлек тантана итә бугай.

Язучылар союзына кагылдым. Анда дусларны туры китерә алмагач, туп-туры Сиринә Самуиловна фатирына юл тоттым.

—Картина язу—һөнәр, ә аларны сату зур сәнгать ул, туганым!

Сиринә Самуиловна—минем туган апам кебек ияләнгән кешем—ишектән әнә шундый сүзләр белән каршы алды. Ул өч бүлмәле фатирында үзе генә. Аның өендә еш булам. Зәвыклы хатынның өе дә зәвык белән киендерелгән. Затлылык, зиннәтлек монда. Килгән саен кәефем күтәрелә, күңелнең йомыкый чагы булса, хәзер үк уяна ул.

Бу ханымга өендә авыз тутырып «Сиринә Самуиловна» дип әйтәсем дә килми, ничектер тел авыр әйләнә. Ләкин «Сиринә» дип кенә дә эндәшеп булмый инде. Ул хөрмәтле, абруйлы, дәрәжәле сәнгать белгече. Ул миннән ун яшькә өлкәнрәк. Сиринә Самуиловнага кырык тула дип һич кенә дә әйтеп булмый, әлбәттә. Хәтта буй-сынына хәтле кызларныкы кебек. Холкы да жиңел, кыз-кыркынныкыдай чуар-чобар, килделе-киттеле. Аларны еш кына Гөлчәчәк белән янәшә куеп, тикшереп, чагыштырып карыйм. Гөлчәчәк, әлбәттә, яшьрәк. Ул ничектер ачылып житмәгән чәчкә сыман. Әйтерсең, аңа, урман куләгәсендә үсеп утырган бик матур чәчәккә, озак вакыт кояш нурлары төшми торган. Әйтерсең, бер генә тамчы, бер генә сынар якты нур кирәк аңа—ачылып—китәчәк тә бар жиһанны гүзәллеккә күмәчәк!.. Ул гүзәллек үзенә жәлеп итеп, мине тилертәчәк, шаштырачак, соклануымнан башымны югалтачакмын! Тик аның бар жиһанны яктыртуын теләмим. Ул минеке, тик минеке генә!..

Усак агачы кебек каткан адәм булмасам да, көнләшәм. Яратып көнләшәм. Көнләшә-көнләшә яратаммы, анысын—бер Алла белә!

Әйткәнемчә, мәктәп тәмамлагач, Петербургтагы Репин исемендәге сәнгать Академиясенә киттем. Гөлчәчәк,—ул миннән өч яшькә кечерәк,—Казан университетының биология факультетына кереп укыды. Без сирәк очраштык. Ләкин һәр очрашу исән-сау Петербургтан кире әйләнеп кайтырга житә. Оят булса да әйтим: мин Татарстанга әти-әниемне түгел, күбрәк Гөлчәчәкне сагынып кайта идем...

«Урман кызы»н тәмам кылмыйча, Гөлчәчәккә өйләнү хакында авыз ачарга базмадым. Яшүсмер чакта куйган максатым, күрәсең, андый-мондый гына түгел, бик житди, үтә житди иде. Без сирәк булса да күрешеп торабыз. Гөлчәчәк хат яза, мин күбрәк телефоннан чылтыратам. Соңгы араларда вакыт ягым чамалырак, әлбәттә. Аннан соң егерме сигез яшь хәйран гомер икән шул инде ул. Беркадәр сабырлана да төштем бугай. Кайчак: «Әллә Гөлчәчәкне яратмыйммы икән?»—дип тә уйлап куям. Әйе, әйе, әнә шундый

фикер кылә башка. Яратсам, Петербургтан кайтуга өйләнешик дияр идем Гөлчәчәккә. Алай дип әйтмәдем бит! Хәер, Гөлчәчәк бу тәкъдимне әле үзе дә көтми, ул да минем: «Урманыңны шәһәргә алып китәм» дип, күкрәк кагуымны чынга алган, шуны көтеп яши булса кирәк. Мин дә көтәм. Без икебез дә көтәбез. Инде ул эшем тәмамлану алдында.

Берничә ел элек,—әле очларга ерак иде,—мин «Урман кызы»н Сиринә Самуиловнага күрсәткән идем. Ул аңа бик озак, хәтта чамадан тыш артык озак, әле янына ук килеп, әле артка чигенә-чигенә карап торды. Мин мактау сүзе көткән идем, ә ул дәшмәде, сүз әйтмәде. Киресенчә, йөзе караңгылангандай булды, кара күзләре дымланды, кулыннан яраткан курчагын тартып алган кыз бала кебек йөз-кыяфәтенә үпкәләү галәмәтләре чыкты, турсайды. Әмма, хисләрен йөгәнләргә өлгергән тәҗрибәле ханым, күнелендәгесен тышка чыгармады. Аның бу кыланышына бик тә сәрсенсәм дә, мин сүз катарга, сорау биреп аптыратырга җөрьәт итмәдем, дөресрәге, үзем дә тел белән генә аңлатып бирә алмаслык сәер хәлдә калган идем.

Кыскасы, «Урман кызы» ошамады бугай Сиринә Самуиловнага. Ә хәзер ул бүген шуны зур кунакка бүләк итәргә, хәтта сатарга йөри! Аңлашылмый иде бу!

Сиринә Самуиловна мине кочаклап каршы алды. Ике як битемнән үбеп алып, кулымнан тоткан килеш, залга алып керде. Без икебез йомшак диванның ике читенә чумдык. Сиринә Самуиловна зәңгәрсу юка кыска халат кигән. Диванга утыргач, болай да кыска итәге тагын да өскәрәк күтәрелде. Үзем оялам, унайсызланам, ул якка карамаска тырышам. Ул шуны сизгән кебек итәкләрен аска тарта, рәтләнгәндәй итә. Хәер, бер караганда матур аякларын халат астына яшерәсе дә килми бугай, шулай булмаса, озын халат кигән булыр иде...

Бу хакта мизгел эчендә генә уйлап алам. Кыяфәтем житди. Мин ачулы, хәтта үпкәле дә.

—Мин ул картинаны сатарга да, бүләк итәргә дә жыенмыйм бит, Сиринә Самуиловна! Әнә, бутәннәрен, пожалуста!

Сиринә Самуиловнаның матур калын иреннәре дерелдәп куйды. Ләкин ул бик тыныч иде.

—Мәскәү кунагы, дөресрәге, аның хатыны синең нәкъ менә «Урман»ына кызыкты бит, Мөхәммәт. Башкасы кирәкми аңа. Аңла! Син андый гына картинаны унны, тагын йөзне язарсың әле. Якты, зур остаханәдә!

—Чит кешегә бирә алмыйм мин аны, Сиринә Самуиловна!

—Һе... ә син беләсеңме, кунакның нәкъ шул картинага күзе төшкәч, теге тараканнар нишләделәр?

—Нишләделәр соң?

—Берни эшли алмадылар. Каттылар да калдылар. Көнләшүләреннән хәтта акырып елыйсылары килде!

—Мине тагын күралмаячаклар икән инде.

—Юк. Киресенчә, синең янда алар калтырап торачаклар моннан соң!..

—Юк, Сиринә Самуиловна, хет нәрсә әйтегез, ул картинаны бүген үк күздән югалтам мин! Кешегә бирә алмыйм мин аны...

—Үҗәтләнмә, Мөхәммәт. Дөрес, бик талантлы эшең ул синең. Урман кызыңны да нәкъ жанлы, тере итеп иҗат иткәнсең. Нәрсә, ул кыз фантазия генә түгелмени? Реаль кызмы әллә ул?

—Беләсез бит инде, Сиринә Самуиловна. Гөлчәчәкне күргәнегез бар.

Сиринә Самуиловна утырган урынында сикереп куйды, шул унайдан халат итәге өскә менеп китте, матур аяклары, нигә безне монарчы ирекка чыгармый утырасың дигәндәй, минем карашны үзләренә таба магниттай тарта, суыра, кызыктыра иде. Ләкин бу минутта миндә аяк кайгысы түгел. Минем бар дөньясына, хәтта Сиринә Самуиловнага да ачуым килгән чак. Ишегең шапылдатып ябып чыгып китәргә дә уйлаган идем бер. Ләкин акылым шундук хисләремне суытып өлгерде. Бу ханым, мине, мокыт авыл малаен, колакларымнан тарта-тарта якты дөньяга алып чыккан, кешеләр

арасына алып кереп, исемемне таныттырган изге жанлы кеше! Бу терсәк сугышы заманасында ул көтелмәгән һөҗүмнәрдән касыгымны, бөерләрне, кабыргаларны саклап калган кеше. Шуна күрә кызуым соңгы дәрәҗәгә житсә дә, үземне тыеп кала алдым. Хәерлегә булсын... Тик... тик хәерлегә булырмы икән соң?.. Күнелемнең бер почмагына авыр тойгы кереп урнашты. Мин ул тойгыдан үземнең тиз генә арына алмаячагымны сиздем.

Сиринә Самуиловна, кинәт нидер исенә төшкәндәй, урыныннан сикереп торды да кыска халат итәген тезенә таба тарта-йолка кухнясына чыгып китте. Аннан мин аның газ плитәсенә чәйнек утыртканын һәм савыт-саба шалтыраганын ишеттем, гәүдә-сыным кыйналган эт кебек, уй-хисләрем болганчык, авыр иде. «Кем соң мин?—дип уйладым мин.—Әйе талантым бар, әйе, кулымнан килә. Нинди илдә яшим мин? Бу сәләтле егет-кызларның кадерен белә торган илме? Һич юк! Киресенчә, соры адәмнәр тантана иткән Рәсәй бит бу! Бу илдә мин кем? Әйе, яшь булсам да дәрәҗәм бар, исемем бар. Талантым булганга шулаймы соң ул? Һич юк. Күкрәк киереп йөргән чамалы һәм талантсызлар буа буарлык бит. Әллә аларның исем-фамилия-псевдонимнары шулай везучий инде?..

Талантымны калкан итеп, ялгыз башым гына максатыма таба олы юлга чыксам әгәр? Барып житә алырмынмы? Үземә ышанам: барып житәчәкмен! Тик соңга калып, ун-егерме ел соңга калачакмын мин! Юлымдагы ясалма проблемалар, каршымда махсус төзелгән баррикадалар вакытымны алачак, энергиямне суырачак! Моннан биш ел элек кенә дә мин берни анламый торган самими үсмер, яшь рәссам идем. Хәзер тормышның чуар икәнлеген яхшы беләм. «Урман кызы»н тәмам кылгач, шул дөньяны рәсемгә төшерергә хыяллана идем. Аны ничек башкарачагымны анык кына күзалламасам да, бу теләгем бик көчле иде.

Сиринә Самуиловна мине кухняга чакырды. Ул тиз арада бай гына табын әзерләгән. Йөзе якты, бая житди карашлары белән миемне бораулаган шомырт күзләре көлә.

—Әйдә, Мөхәммәт, бәйрәм итәбез.

—Нинди бәйрәм?—дим аптырап.—Туган көнегез дә түгел инде?

—Туган көн түгел. Бәлки, туган көндер дә, әйдә, Мөхәммәт, син миңа башка «Сез» дип дәшмә әле. Без дуслар бит. Отчествомны әйтмә. Сиринә диген, бары Сиринә генә!..

Сәерсенеп калдым: ничек «син» инде ул, ничек «Сиринә генә»? Алай әйтергә минем телем әйләнерме? Ияләнмәгән, күнекмәгән килеш?

Сиринә Самуиловна, ягъни Сиринә өстәл өстенә коньяк чыгарып утыртты.

—Син авылдан көтү көтеп килгән хөрмәткә бу! Пикассо и пастух! Ха! Кызык бит! Ерак китәчәксен син, Мөхәммәт!

Сиринә Самуиловнага кушылып, көләсе дә иттем. Авыз каткан, ихтыярыма буйсынмый, көлүем ыржаю булып килеп чыкты бугай. Теләгем булмаса да (коньяк кан басымын күтәреп, башны томалаячак иде), тизрәк канны уйнатып Сиринә Самуиловна белән бер дулкынга күчеп сөйләшә алыр өчен рюмканы кулыма алдым.

—Сезнен... синең исәнлеккә Сиринә... Самуиловна!

Сиринә Самуиловна яңгыравыклы көмеш тавышы белән янә көлә башлады. Минем югалып калуым ана ошый иде, күрәсең. Аның кинәт көлеп жибәргән тавышына, газ плитәсе янындагы артсыз урындыкта йокымсырап яткан йонлач песие дә башын күтәреп карады. Ни булды янәсе, нигә шулай көләсез? Минем белән дә уртаклашмыйсыз! Хужабикәнең бу песиендә—кушаматы «Фәрештә»—адәм баласы акыллары бар, сөйләшә белмәсә дә аның соры күзләренә туры карап анлашып буладыр кебек иде. Сиринә Самуиловнаның «йонлачы» мине үз итә, килеп керүгә, сырланырга, аякка чорналырга керешә торган иде. Бу юлы да мине күргәч ялт итеп урындыгыннан сикереп төште дә алдыма менеп утырды. Аның башыннан сыйпап куйдым.

—Минем Фәрештәм үлеп гашыйк инде сина, Мөхәммәт.

Телем чишелә башлап, кәеф тә башка дулкынга күчкән иде, тапкыр сүз әйтәсем килеп китте:

—Мине песиләр генә ярата бугай.

Сиринә Самуиловна иренենә тидергән рюмкасын читкә этәрде, күз карашы янә бораулый башлады.

—Ә урман кызы?

—Урман кызымы?.. Әгәр дә мәгәр картинамнан колак каксам, ул мина сәлам дә бирмәячәк!

Җавабым Сиринә Самуиловнаны шулчаклы өтәр дип һич тә уйламаган идем, ул хәтта утырган урындыгыннан сикереп торды.

—Чынлап та шулай дип уйлыйсынмы?

—Уйлыйм. Нигә?

—Алайса ул синең бик җинел акыллы нәмәрсә икән! Җинел акыллы хатын-кыз ирләрне бәхетсез итә!

Сиринә Самуиловна бу сүзләрне сөенә-сөенә әйтте. Әйтерсең, Гөлчәчәк чынлап та җинел акыллы кыз, гүя мин бәхетсез булачакмын, ә остазым шуна куана иде.

—Җинел акыллы булса, егерме бишкә чаклы мине көтеп утырмас иде!—дидем, тавышыма кырыслык, кыяфәтемә төксе сурәт чыгарырга тырышып.

—Ярый. Кеше тикшереп утырмыйк! Синең өчен күтәрик әле, Мөхәммәт! Синең зур киләчәгең өчен!

—Сездән башка минем киләчәк зур булмаячак!—дип кыланыбрак җавап бирдем. Чөнки Сиринә Самуиловнаны картина турында сөйләшүдән, Гөлчәчәк хакындагы сүзләрдән читкә алып китәсем килә иде.

—Чынлап та шулай уйлыйсынмы?

—Уйлыйм, Сиринә Самуиловна, уйлыйм.

Хатын, кара күзләрен тутырып, беравык мина карап торды да рюмкасын янә иреннәренә китерде.

—Рәхмәт, Мөхәммәт! Тик син үзең дә талантлы егет. Үҗәтлегенне, кирелегенне генә җинсәк менә,—дип көлде ул һәм бу юлы рюмкасын кире куймады.

Иртәгесен кара махмырдан уянып китеп, байтак вакыт үземнең кайдалыгымны анышмыйча яттым. Тубал булган башны чак кына күтәрә төшеп каршы стена буендагы кәнәфи-караватта тынсыз йоклап яткан Сиринә Самуиловнаны күргәч кенә хәтер күзәнәкләре хәрәкәткә килеп, уяна башлады шикелле. Димәк, монда кунып калганмын. Сиринә Самуиловна (аның өстенә япкан юрган идәнгә төшкән, ул эчке күлмәктән бөгәрләнеп ята иде). Май урларга җыенган карак песи кебек башны чак кына күтәрдем дә сулыш алырга да куркып, Сиринә Самуиловнаның ярым ялангач гәүдәсенә карап өнсез калдым. Күнел ничектер кытыкланып, кымырҗап куйды.

Йонлач песи, уянганымны сизеп булса кирәк, әллә кайдан гына килеп чыкты да яныма менеп, күкрәгемә сыенды. Аның мыр-мыр килгән тавышы ачуымны китерде, песине идәнгә төртеп төшердем, бу хәлгә аптыраган песием идән уртасына утырды да елаган тавыш белән «мияу» дип куйды. Үпкәләгән иде ул... аннары сыртларын дугаландырып бер киерелде дә ярымшәрә хуҗабикәсе янына менеп ятты.

Беркавым аларга карап яттым-яттым да песи кебек сак кына юыну бүлмәсенә атладым. «Моннан соң чынлап та «Сиринә» дип кенә йөрермен мин сине, мөгаен»,—дип тә уйлап куйдым әле...

## Мөхәммәтнең беренче мәхәббәте

Мөхәммәт үзенең Мөштәри урамындагы бер бүлмәле фатир-остаханәсенә кайтып кергәндә төш вакыты җитеп килә иде. Бүген, балалар киләчәк. Ул үз остаханәсендә «Балалар сәнгать студисе» ачып, рәсем дәресләре бирә, укучылар киләсе көнне һәрвакыт түземсезләнеп

кетә. Әлеге эше буйдак егеткә зур шөгыль булып, шулар белән уздырган минутларын иң бәхетле мизгелләр дип исәпли. Балалар килергә иртәрәк әле. Ишегенә язу кыстырып киткәннәр. Мөхәммәт буш путевка бланкасы артына язылган кылдый-былдый язуны күрүгә, көлемсерәп куйды: Барый килгән. Аның язуын йөз кешенеке арасыннан да танып алыр иде Мөхәммәт. Болай ямьсез итеп бары тик Барый гына яза ала. Шул язуы өчен мәктәптә укыганда да гел әрләнә, сүгелә торган иде ул. Барлык фәннәрне дә су урынына эчә, әйбәт укый, алдынгылардан санала, әмма язуы юк инде, дәфтәр бите өстеннән бер көтү таракан йөгерешеп узган кебек. Язуының ниндилеге кешенең холкын билгели диләр. Имеш, язуына карап, адәм баласының холкын әйтеп биреп була. Дөрестер бу, чөнки Барыйның холкы, чыннан да, кылдый-былдый, аның бүген кичтән нәрсә уйлап, иртәгесен ни кылачагын берәү дә алдан белә алмый. Шуна күрә аның колхоздагы нарядны да кичтән биргәне юк, җәйме ул, кышмы—барыбер. Барый нарядка кешеләрне һәрвакыт иртән, таң тишегеннән җыя.

«Тагын картина турында авыз суы чайкарга килгәндер инде»,—дип уйлады Мөхәммәт һәм шул чак аның иртәдән бирле күзгә томан сарып алгандай тонықланып торган башы кисәк ачылып киткәндәй булды, ул кызу-кызу ванна бүлмәсенә керде, әүвәл җылы, аннары салкын су астында пырхылдый-пырхылдый, бик озак басып торды.

Барый кичкырын сугылырмын дигән. Кибеткә чыгып керергә кирәк.

Аның өендә ашарга пешереп ашаганы да юк. Күпвакыт янәшә-тирәдәге ашханәләргә йөри, өендә исә такы-токы белән чәй генә эчкәли.

Авылдашы сүзендә торды, кичке якта ишек кыңгыравына бастылар. Мөхәммәт, ишек артындагы кешенең Барый булуын тәмам ышанган хәлдә «Кем бар?» дип тә сорамады, күз-тишектән дә карамады, шундук ишеген ачты. Ачты да... артына авып китә язды: бусагада Барый да түгел, башка дусты да түгел... авылдашы, элекке сыйныфташы, күптән түгел генә яна машина алган Сәмигулланың хатыны Рәзифә басып тора! Авыл хатынына артык мул иннек-кершән килешми, ә бу артыгын тырышып ташлап, бизәнгән, үзе елмайгандай итә, үзе, күренеп тора, бик каушаган да. Мөхәммәтнең аптыравы хатынга кыюлык өстәп җибәрде булса кирәк, баягы оялчан күзләре янып, ялкынланып алдылар. «Таныдың инде, рәхмәт! Мин инде танымассың да дип уйлаган идем»,—диде хатын. Тел-тегермәненең хәрәкәткә килүе янә кыюлык өстәде бугай, ул бер адым арткарак чигеп, ике адым алга атлады, Мөхәммәтнең алдына ук килеп басты. «Кертәсеңдер бит инде!». Мөхәммәт, ялт кына кырыйга тайпылып, юл бирде, аның җилкәсе аша тагын кемнедер эзләп баскычка күз ташлады. Үзенең авызы һаман ачык иде әле.

«Йә, кайда узыйм соң? Әллә кертәсең дә килми инде авылдашынны... Классташыңны һәм...»

«Һәм! Нәрсә «Һәм»?..»—дигән уй мизгел эчендә Мөхәммәтнең инде кыймылдый-хәрәкәтләнә башлаган акыл шәрифләрен чеметеп узды, ул, тиз арада ис-һушын җыеп өлгереп, хатынга түргә узарга кушты, аның артыннан ишекне ябып, бермәл бикләргәме, юкмы дигәндәй, тоткадан кулын алмый торды һәм аннары, уйламастан шартлатып, йозакны борды.

Чыннан да, алар Рәзифә белән классташлар, алай гына да түгел, ун ел буе бер партада утырдылар. Рәзифә аңа математикадан бирелгән өй эшләрен күчертә иде. Математиканы су урынына эчкән кыз монын өчен мәктәпкә махсус алдан килә, кыңгырауга чаклы аның дәфтәрендәге катлаулы мәсьәләләрнең чишелеше шундук Мөхәммәтнең дәфтәрендә урын алганын түземлек белән көтә. Малай исә, үз чиратында, партадаш кызына әүвәл рәсем ясарга булыша, аннары үсә төшкәч, аның шигырь белән тулган калын дәфтәрен бизәкли-чуклый иде.

Рәзифә кыска итәкле, ачык изүле (авыл хатынына мондый фасонлы кием ятышлы түгел дибез, галәттә) юка күлмәк киеп, чәчен ясаттырган һәм өстәвенә тәмле хушбуй сөртенгән. Моны һич кенә дә авылда такта яручы Сәмигулла хатыны димәссең! Хәер, авылда яшәсә дә, аның тан

белән торып, фермага сыер саварга йөрмәгәнен белә иде Мөхәммәт. Рәзифә колхоз кәнсәләрендә бухгалтериядә эшли. Барыйның ун кулыннан санала. Өстәвенә алар чыбык очы туганнар да бугай әле.

Рәзифәнең чәче каре фасонында киселгән һәм бу егерме сигез яшьлек хатынның берничә елын артка чигергән. Кыз чактагы сипкелләре һаман сакланган икән әле. Хәер, аны сипкелле дип тә әйтеп булмый. Канәфер төсендәге ул мөлаем төрткеләр бик текәлеп карамасаң, күзгә дә чалынырлык түгел, ләкин аны сипкелсез дип тә әйтеп булмый иде. Коңгырт зур күзләрен ул әле зур итеп ача, әле күрә караучы кешедәй, тәмам кысып бетерә.

Рәзифәнең кыяфәте килешле,бар жире дә килгән иде. Инде бала табуга карамастан, бизәнү-ясанулары, яшьләрчә киенүе хатыннан егерме яшьлек ымсындыргыч затны әвәләгән дә куйган.

Рәзифә залдагы диванга кереп урнашты, бер аягын икенчесенә атландырды. Матур аяклары белән Мөхәммәтне ымсындырырга тели иде булса кирәк. Хәер, бәлки аңа шулай утыруы жайлырактыр? Үзенең ашыгыч нәтижә чыгаруын тойган Мөхәммәтнең колак очларына ут капты.

Хужа кешенең әле һаман аптырабрак утыруын күреп, хатын беренче сүзне үзе башлады:

—Сиңа йомышларым бар иде, Мөхәммәт. Шуңа дип килдем. Мин Казанда, бухгалтерлык курсларында, бер атна булам әле. Иртәгә, дүшәмбедән башлана,—дип мәсьәләнең пәрдәсен чак кына ача төште.

Рәзифә үзе белән төрле күчтәнәч-жимешләр күтәреп алып килгән иде, Мөхәммәт, жәһәт кенә кухняга чыгып, чәй куярга уйлады. Бәхеткә күрә, суыткычында шампан шәрабе дә бар. Нинди генә йомыш белән килсә дә ул үз дәрәжәсен саклап, авылдашы, классташын сыйлап жибәрә алачак. Кухняга чыккач, беренче уйлаган нәрсәсе шул булды буйдак егетнең.

Кайнап чыгуын борынын сызгыртып хәбәр итә торган чәйнегенә краннан су агызды, газга ут элдерергә дип, тәрәзә төбендә яткан шырпыны табып алды. Аның кабы юешләнгән, эчендәге шырпылары дымлы иде. Өендәге берләнбер шырпысы бу аның. Шуна күрә буйдак егетнең әлеге хәлгә кәефе китеп, беркавым аптырап торды да, аннары, бәлкем кабынырсың әле дигәндәй, шырпыны бер юлы сызып жибәрде. Ни гажәп: юеш капка ышкылган дымлы шырпы гөлт итеп янып китте, газга ут элдергәнче сүнмәде.

Ул зал якка чыкканда Рәзифә: тез өстенә калын дәфтәр салып, бармак очларын иреннәренә тидереп юешли-юешли шуны актарып утыра иде. Мөхәммәтне күргәч, дәфтәрен кулына тоткан килеш, урыныннан торып басты, икенче буш кулы белән кыска итәкләрен тарткалап-рәтләп:

—Синең вакытыңны аламдыр инде мин, Мөхәммәт?—дип куйды.

—Юк, нишләп? Утыр әле, Рәзифә!

Мөхәммәт үзе дә диванның икенче кырыена килеп урнашты.

—Утыр инде, утыр, тартынма!

Хатын янә диван кырыена чүмәште, бу юлы аякларын бер-берсенә атландырмады, әмма утыргач, бик тырышып, күлмәк итәген ачык тез башларына тартты. Мөхәммәт шунда гына игътибар итте: хатын бу күлмәген авылдан ук киеп килмәгән, шәһәрдә генә алган һәм кибеттә үк киеп, туптуры аның янына килгән; күлмәкнең кибет тамгасы да өзелмәгән, ул артта, муен турысында, асылынып тора иде. Шуны күргәч, Мөхәммәтнең көләсе килеп китте, әүвәл, үрелеп, ул тамганы үзе тартып алмакчы иде, әллә унайсызланды, әллә хатынны оялтырмын дип курыкты—дәшмәде.

—Мөхәммәт, мин синең вакытыңны озак алмам. Ачуланма. Миңа сиңа шушы дәфтәрне генә тапшырмакчы идем. Редакциягә иде ул.

—Нинди ачулану ди ул, Рәзифә. Ташла әле шундый сүзләреңне, зинһар! Йә, нинди дәфтәр ул?—дип, Мөхәммәт аңа таба кулын сузды. Ләкин Рәзифә дәфтәрен аңа бирергә ашыкмады.

—Шигырьләр монда. Үзем язган. Телисеңме, берәрсен укып китәм? Вакытым бар дисең ич?

—Рәхәтләнеп! Хәзер чәй дә кайнап чыга. Классташны кунак итмичә жибәреп булмас,—дип Мөхәммәт диванга тагын да жайлабрак урнашты.

Рәзифәнең шигырьләр белән шыплап тулган калын дәфтәрләрен төрлечә бизәкләгәне исенә төште аның. Әле дә истә калган, бәлкем, шул вакытта игътибар ителмәгәндер: ул шигырьләрне кемнән булса да күчереп язган дип уйлый иде Мөхәммәт. Баксаң, янәшәсендәге математик кыз шигырьләрне үзе иҗат иткән икән! Югыйсә, үз-үзен тотышы яки холкы белән дипме, Рәзифә бер дә шигырь яза торган кыз балага ошамаган, ул йә елак, йә бар дөньяга ачуы килгәндәй үпкәле, төксе кыяфәтле иде. Баксаң, кыз баланың күңелендә ниләр генә кайнамаган икән!

Әнә ул, бик бирелеп, дөньясын онытып, ана үзе язган шигырьләрен укырга җыена. Сәер дә, кызык та.

Син шаян күрше малай,
Мин елак бер кыз идем.
Бер партада без утырдык.
Чәчләремнән тарттың, шаярттың.
Ә мин,
Ә мин елаган булдым.

Син рәсемче малай идең,
Бик зур иде хыялың.
Тик мине сурәтләргә
Житмәде шул буявың.

Син хәзер ерак киттең,
Мин дә елак кыз түгел.
Янәшәңдә булмасам да,
Гел синең янда күңел.

Пумаланны чылат әле
Минем күз яшьләремә.
Рәсем генә түгел, үзем итеп
Төшер әле күңел дәфтәреңә!..

Шигырьнең шактый кытыршы икәнлеген шундук тойды Мөхәммәт. Юк, башка кеше укыса, шулай кытыршы-мытыршы тоелган булыр иде әлеге такмак-шигырь. Шигырьдән дә бигрәк, Рәзифәнең укуы, һәр юлын йөрәге, күңеле аша уздыруы таң калдырган Мөхәммәтне!

Син шаян күрше малай,
Мин елак бер кыз идем...

Әлеге гап-гади генә сүзләр тезмәсен ул шундый итеп әйтте ки, Мөхәммәт эсселе-суыклы булып китте. Әйтерсең, аны мизгел эчендә мәктәп елларына кире алып кайтып утырттылар! Гап-гади сүзләр югыйсә. Тик... ләкин аларны Рәзифә әйтә бит! Аның классташ кызы Рәзифә! Һәм ул бу сүзләрне Мөхәммәткә укый! Әллә нәкъ менә шуның өчен, шулай булганы өчен генә тәэсирлеме соң ул сүзләр!

Йа, Хода! Бу дөньяда балачакка кайтып килүдән дә ләззәтлерәк нәрсә юктыр! Утызга якынлашып килүче ир-атның, буйдак егетнең, тагын бер кат яшүсмер чагында «яшәп» алуы дисәк тә була бу халәтне. Әлбәттә, әлеге аралар берничә дистә еллар белән исәпләнми исәпләнүен. Нибарысы түп-түгәрәк ун еллап булыр. Шулай да һәр үткән көн, яшәгән гомер, вакыт үлчәменә дә карамастан, барыбер хатирә инде ул. Әгәр дә ул матур булса, бигрәк тә истә кала, аны искә төшерү бик тә ләззәтле.

Урманнарга кереп адаштың да
Кире чыгар юлың тапмадың.
Мин дә сине йола алмадым,
Алдандың син, егет, алдандың!..

Нинди алдану соң ул? Кем турында, нинди егет хакында яза Рәзифә?

Бу сорауны Рәзифәнең үзенә бирергә уңайсыз иде. Әле алай гына да түгел, наданлык, шыр наданлык билгесе булачак иде мондый сорау белән тинтерәтү. Чөнки ул үзе иҗат кешесе бит: әдәбият-сәнгать әсәрләрендәге геройларның прототиплары булса да, аларда барыбер ниндидер кеше төгәл рәвештә үк сурәтләнә алмый, җыелма образ, бу очракта исә аның «егете» шигъри образ буларак аңлашылырга тиештер...

Мөхәммәт шулай дип уйлап бетермәде, Рәзифә, үзе кыпылт кына, зур күзләрен тутырып, аңа күтәрелеп карады да:

—Сүзнең кем хакында барганлыгын беләсең киләме?—дип куйды.

Мөхәммәт көлемсерәде, шулай да әгәр Рәзифә атарга әзер икән, ул

әлеге образның кем икәнлеге турында беләсе килгәнлеген аңлатып, баш какты.

—Синең турында...

Мөхәммәт утырган урынында кыймылдап куйды.

—Ничек? Минем урманда адашканым юк бит?

—Адашкансың шул. Менә син аны туры мәгънәсендә аңлыйсың. Адашу бу очракта күчерелмә мәгънә. Урманы исә тәгәл, дөрес.

—Мин барыбер аңлап житкермәдем, Рәзифә?

Кинәт хатын, кытыгы килгән кешедәй, көләргә кереште. Мөхәммәт күрә, сизә: бу хатын-кызның бармак күрсәткәннән генә көлүенә һич тә охшамаган. Бу көлү ничектер сәер көлү, ачынган, бәргәләнгән жанның көлүе иде. Һәм бу көлүне тиздән хатын-кызның тагын бер гамәле—чәчләрне йолка-йолка елау галәмәте алыштырырга да бик мөмкин икәнлеген тойды егет. Дөрестән дә, беркавымнан шулай булды. Хатын, такмаклый-такмаклый, еларга кереште:

—Син гомер буе аңламадың инде. Аңламаганга салыштың! Без синең белән ун ел буе бер партада утырдык. Күпме генә теләсәм дә, син мине күрмәден, белмәден! Шул кыргый урман кызың янына чыгып чаптың! Хәзер дә үзенә кияүгә чыкканың көтеп, өйләнмичә йөрисең! Сукыр син! Кеше белән кешене аера белмисең!

Әнә шундыйрак сүзләр сипте Рәзифә күз яшьләре аша.

Мөхәммәт катып калган иде. Әйе, әйе, ул ни әйтергә, нәрсә дип тә юатырга белмәде ир хатынны! Рәзифә алдында аның гаебе юк бит! Ярый да, булсын ди, тугызынчыдамы икән, унынчы класста укыгандамы—ул аны бер-ике мәртәбә озата барды. Очраклы рәвештә клубтан икесе бергә чыкканнар иде. Рәзифә үзем генә кайтырга куркам дигәч, капка төпләренә кадәр бардылар. Икенче көнне: «Мөхәммәт Рәзифә белән йөри икән» дигән сүз чыкты. Икенче көнне мәктәпкә килгәч, аның парта утыргычына кадак какканнар иде. Өченче көнне парта өстенә язу карасы түгеп киттеләр. Шул көнне мәктәптән кайтышлый юлда ул классташы Сәмигулла белән канга-кан сугышты. Инде хәтерләми дә, тегесе, мыскыл итеп, ниндидер сүз әйтте бугай. Юл тузанында ауный-ауный чәкәләшкән ике әтәчне классташлары Барый килеп аралады. Истә калганнар әнә шулар гына.

Әлбәттә, әүвәл Мөхәммәт Рәзифәгә гашыйк та булган шикелле иде. Әммә Гөлчәчәк белән чираттагы бер очрашу-күрешү үк әлеге хис-мисне кысрыклап чыгарды.

Мөхәммәт бу хакта оныткан да иде инде. Рәзифә исә әнә ничек житди кабул иткән булган икән ләбаса!

Ул үзен аның алдында гаепле итеп сизгәндәй булды һәм сулкылдый-сулкылдый чын күз яшьләре белән елаган хатын чынлап торып кызганыч иде. Мөхәммәт Рәзифә янына күчеп утырды, кулын иңенә салып юатырга теләде. Хатын кискән агачтай аның алдына авып төште һәм аннары жәһәт кенә күтәрелеп муеныннан кочты.

—Мөхәммәт, мин аңлыйм, барсы да узды, артта калды инде. Тик минем синнән бер бала табасым килә. Минем малаем бар инде. Жиде яшьтә. Икенчесенең синнән булуын телим! Мина боларны әйтүе бер дә жиңел түгел. Тик нишлим!.. Беләм, аңлыйм. Минем поезд күптән узып китте инде. Зинһар, каршы килмә. Ичмасам, гомерем буе синең балаң дип, шуның белән үземне юатып, шушы язмышым белән килешеп яшәрмен. Каршы килмә, Мөхәммәт!

Буйдак егет хатынның кулларыннан араланырга тырыша-тырыша, аны акылына китермәкче булды.

—Ни сөйлисең син, Рәзифә! Сәмигуллаң бар бит синең! Әле генә яңа машина алып кайтты. Сине ярата. Тормышың начар түгел бит синең, Рәзифә!

Хатын елавыннан шып тукталды, әмма кулларын ычкындырмады.

—Тормышым авыр түгел. Ирем акча таба. Алма кебек малай үстерәбез. Иртәнге дүрттән торып фермага сыер саварга да йөрмим. Эшем чиста.

Үзем сайлаган һөнәрем бар, Мөхәммәт. Син дөрес әйтәсең! Ләкин! Ләкин жанымдагы бушлыкны ни белән тутырыйм соң мин, Мөхәммәт! Яратып чыкмадым бит мин кияүгә. Аптырагannan, карт кыз булып утырып калудан куркып кына чыктым. Сине кыргый Гөлчәчәгеңнән аерып, аралап алмаслыгымны белгәч кенә. Кирәкми мина Сәмигулланың шкаф тулы затлы күлмәкләре, кыйммәтле туннары. Кадалып китсен шул чүпрәкләре белән! Мәхәббәткә сусадым мин, бик сусадым, Мөхәммәт!

—Тынычлан әле, Рәзифә. Тормышның бөтен булуы хатын-кыз өчен зур бәхет бит инде ул...

—Һай, Мөхәммәт, анламыйсың икән әле син! Шунын гырылдавына хәтле сөймим бит мин, беләсең килсә!

Хатын янә еларга керешге.

—Бәхетсез хатын мин, Мөхәммәт. Кыйммәтле туннарга, затлы күлмәкләргә төренгән бәхетсез, жансыз курчак кебек итеп хис итәм мин үземне!

Ичмасам, синнән бала табып, гомерем буе шуның белән юанып яшәрмен дип хыялланган идем!..

Хатын капылт кына кулларын ычкындырып, диваннан торып басты да чәч-башын төзәткәли-төзәткәли, ванна бүлмәсенә кереп бикләнде, аннан шыбырдап су аккан тавыш ишетелде.

Мөхәммәт әле һаман ис-һушын жыеп өлгермәгән, әле һаман диван почмагында өнсез утыра иде. Су тавышы аны кинәт айнытып жибәргәндәй булды. Ул урыныннан торырга теләп талпынды. Ләкин диван магнитлы кебек, жибәрми, дөресрәге, күнелендәге авыр таш шулай басып тора сыман иде аны.

Рәзифә юыну бүлмәсеннән бөтенләй икенче кеше булып чыкты. Тынычланган, үз-үзен кулга алган хатын. Әйтерсең лә аны алмаштырып куйганнар, хәтта сүзләренә кадәр суык йөгергән:

—Мин сина бая укыган шигырьләр унынчы класста язылган иде инде. Пешеп житмәгән алар, чиле-пешле дип әйтсән дә була. Ә менә болары... болары яналары,—дип ул сумкасыннан баягысы кебек үк калын яшел тышлы дәфтәр чыгарды.—Редакциягә тапшыра алмассынмы? Синен танышларың күптер? Мин беркемне белмим.

Мөхәммәт яшел тышлы дәфтәрне алып көзге янәшәсендәге тумбочка өстенә куйды.

—Тапшырам, әлбәттә. Вәгъдә бирәм.

—Ярый, Мөхәммәт, мин китим инде. Вакытынны алдым, ачуланма!

Мөхәммәтнең хатынны нинди дә булса жылы сүзләр эзләп табып юатасы, хәтта гафу да үтенәсе килеп китте. Бу теләге мизгел эчендә шулчаклы зурайды, көчәйде ки, ул үзе дә сизмәстән, урыныннан ук сикереп торды, ләкин кирәкле сүзләр барыбер тиз генә теленә килмәде, Рәзифә каршысына басып, аптырап, сүзсез-авазсыз калды. Хатын, аның бу теләген анлагандай, әлеге хәлдән чыгарга үзе булышты:

—Кирәкми, юатма мине, Мөхәммәт! Хәзер тынычландым инде. Хатын-кыз бит инде мин, ничек тиз кабынсам, шулай тиз суына да алам. Кирәкми, юатма...

—Рәзифә...

Хатын кулы белән аның авызын каплады.

—Юк, Мөхәммәт, син мина бер сүз дә әйтә күрмә, яме. Тик син, Мөхәммәт, артык наивный да булма. Алдап йөриләр бит сине! Мин сина моны әйтмичә булдыра алмыйм. Шуны бел, Гөлчәчәгең чәчәк түгел инде синен. Синнән көлеп йөри ул. Имеш, ана багышланган картинанның тәмамланганын көтә! Жир бит ул! Чәчәгең күптән койганнар инде аның! Ә син һаман бала-чага кебек.

Хатын әлеге сүзләрне кызу-кызу сипте-сипте дә жәһәт кенә сумкасын эләктереп, йөгереп диярлек ишеккә китте. Әйтерсең Мөхәммәтнең башына күсәк белән суктылар—ул идән уртасында өнсез торып калды. Буйдак егетнә ишек йозагының ачылган тавышы сискәндереп жибәрдеме, әллә

Рәзифәнең сүзләре яна гына аңына барып ирештеме—ул ишекне яртылаш ачкан хатын артыннан атлады, аның беләгеннән эләктереп алды.

—Дөресме бу! Кайдан беләсен?!

—Әй, Мөхәммәт, хатын-кызның белмәгәне юк аның. Берсе, Гөлйөземе, уйнаштан бала тапты бит инде! Игезәк сыңары да ерак киткәндер дип уйлыйсыңмы әллә?

Мөхәммәт ишекне шапылдатып кире япты, бер кулы һаман Рәзифәнең беләген кысып тоткан килеш иде әле.

—Чынлапмы? Гайбәт бит бу!

—Һа! Гайбәт!—Хатын ямьсез итеп көлеп куйды.—Синең өчен, бәлки, гайбәттер!

Ачуыннан бүртенеп, шартлар дәрәҗәгә җиткән буйдак егет хатынны залга кире тартып кертте.

—Ант ит!

—Ник мин шул себерке өчен ант итеп торыйм суң әле!

Мөхәммәтнең бөтен гәүдәсе дерелдି, тәне уттай кызыша башлады.

Ул хатынны җилтерәтеп, диван янына алып килде дә дорфа гына аны төртеп аударды. Тегесе карышмакчы булып, сикереп тормакчы иде, тик егет ирек бирмәде, шулай ук тупас кыланып, хатынның киемнәрен йолкып атты.

Кухнядагы чәйнек яман итеп сызгырырга кереште һәм әле шул рәвешле суы кайнап беткәнче сызгырачак иде...

Кичкырын, чыгып киткәндә, Рәзифә Мөхәммәткә таба борылып:

—Миңа Барый сөйләде. Миңа үпкәләмә. Бигайбә, Мөхәммәт, җаным!—диде. Гап-гади сүзләр. Акланумы бу, әллә тынычландырырга теләүме? Алла белсен...

Сәнгать студиясенә йөрүче балалар килергә сәгатькә якын вакыт бар иде әле.

Барый һаман күренмәде. Хәер, Барыйның Казанда икәнлеген белсә дә, аның үзе янына керергә уйлап та карамыйча, Рәзифәне махсус котыртып җибәргәнен чамаламый иде Мөхәммәт. Барый, колхоз рәисе буларак кына түгел, интригалар, кешегә төрле тозаклар кору буенча да шактый шомарган һәм түгәрәк башлы адәм иде. Гөлчәчәкнең «чәчәге» хакындагы әкият-гайбәтне дә ул юри уйлап чыгармадымы икән әле? Барый Әкбәровның башында нинди уйлар кайнаганын этем белсен диме! Дистә еллар буе тау итәгендә яшәгән Байтимер чаклы Байтимерне тау башына күчерергә йөргәнне инде! Бу кешегә хәйлә-тозаклар күп, бик күп кирәк булачак, югыйсә, ул әлеге максатына шуларсыз үлсә дә ирешә алмаячак!

Мөхәммәт исә боларны чамалау гына түгел, бу хәлләр аның ике ятып бер мәртәбә төшенә дә керәп карамый, ул иҗат кешесе, Хак Тәгалә аңа кызганмыйча талант биргән, ул әнә шул талант исереклеге белән саташып яши, калганында аның эше юк, андый кеше печән урынына салам бирсәләр дә куанып кабул итәр һәм әле шуна сөенеп тә йөрергә мөмкин. Малярга тиң рәссамнар, буш, мәгънәсез такмакчы, язучылар эт сөяккә барган көй язучы композиторлар замана шаукымыннан файдаланып хакимият тирәсен, зур тәхет яннарын хәшәрәт тараканнар шикелле урап алдылар, талантларга печән урынына саламны да әнә шулар өләшеп утыра.

Бу талантлы дигәннәре, ичмасам, шуны анласыннар иде инде канә!

## Иртәгә көн болытлы булачак

«Урман» картинасы иҗат ителеп тәмам кылынган иде инде. Аның исеме әүвәл «Урман кызы» иде. Хәлләр бу рәвешле куера башлагач, ягъни ана тирә-юньдәгеләрнең күзе төшеп, ул игътибар үзәгенә әйләнгәч, Мөхәммәт әлеге исемнең койрыгын кисте: «Урман» булып кына калды.

«Урман»ны Гөлчәчәккә күрсәтәсе, бүләк итәсе, күрәсеңме, мин вәгъдәдә тордым, синең урманың таланып беткән инде, ләкин мин сина

син үскәндәге, моннан ун ел элек булган урманыңны саклап калдым, Гөлчәчәк, диясе килде егетнең. Тик ничек итеп ул кыз янына бармак кирәк!? Рәзифә сөйләп киткән коточкыч хәбәрләрдән, гайбәттән соң? Әллә бәлки, чыннан да, ул гайбәт кенә булса? Мәкер, хәйлә белән тулган бу соры жиһанда нинди генә ялган булмас!

Ул әүвәл Барый белән күрешеп сөйләшергә уйлады, шул максат белән авылга җыенды. Ләкин Барыйны авылда күрергә язмаган икән, алар шәһәрдә күрештеләр. Барыйны ярты үлек хәлендә Казанга—хастаханәгә алып килеп салганнар икән.

Әлеге хәбәрне ишетеп Мөхәммәт хастаханәгә барганда дусты реанимациядә ята, янына кертмиләр иде. Ул ишек төбендә беркавым таптанып торды да хәлен генә белим, ичмаса, дип, бүлек мөдирен эзләп тапты. Реанимация бүлеге мөдире кырык-кырык биш яшьләр тирәсендәге баһадир гәүдәле, маңгай чәче пеләшләнә башлаган ир-ат (ишегендәге язудан ул аның Ибраһимов Виктор Саматович икәнлеген укып белде) Барыйның хәле турында анык кына җавап бирә алмады.

—Әлегә берни әйтә алмыйбыз. Он пока к коме,—диде ул ярым татарча, ярым урысча һәм әлеге сүзләрен мөһерләгәндәй инбашларын сикертеп куйды.

—Монда, больницага кем алып килде соң аны, Виктор Саматович?

Мөхәммәтнең берни белмичә кайтып китәсе килми, шуңа күрә төпченә иде.

—Мин абыйсы белән сөйләштем. Абыйсы монда иде. Кстати, он сказал, что в час подойдет.

Җавапның монысы Мөхәммәтне канәгатьләндерде. Димәк, Һади абый кайдадыр монда гына. Ул бүлек мөдиренә рәхмәт әйтеп, коридорга чыкты. Тагын ишек янында таптанырга керешә. Бер өлкән яшьтәге шәфкать туташы (шәфкать әбие дисәң, дөресрәк булыр, чөнки пенсия яшендәге авыр гәүдәле әбиең коридордан барганда да ике як стенага бәрелә-сугыла, алпан-тилпән атлый иде. Әллә ул хастаханә ыгы-зыгысыннан шулай талчыкканмы, бәлкем, төнен кизү торып арыган, алҗыгандыр) аның янына килеп, ике мәртәбә куып чыгарырга тырышкан иде, гөрнәдирдәй гәүдәсе, һәйбәт киеме, житмәсә, чем-кара түгәрәк сакаллы кыяфәте әбигә артык батыраеп китәргә ирек бирмәде бугай. Өстәвенә Мөхәммәт: «Я только Виктор Саматовича дождусь! дип, тавышын калынайтып әйткәч, «шәфкать әбие» тынычланды, бүтән бәйләнмәде.

Табиблардан да, укытучылардан да һәрвакыт могжиза көтәләр, ә ул тормышка ашкач, бу хәлгә бераү дә гаҗәпләнми, диган кемдер. Мөхәммәтнең «Больницага алып килеп житкерүләре әйбәт булган әле»—дип, уйлап бетерүе булды, ишектә иң өстенә ак халат салган Һади абый күренде. Бик жылы күрешсәләр дә сүзләре ялганып китә алмады. Күренеп тора, ул энесе өчен бик борчыла, аның күңел халәте йөзенә үк чыккан иде.

—Барыйга ни булган соң, Һади абый?

—Ни булганын кем белсен! Урманнан табып алып кайттылар. Машинасыннан 40-50 метрлар чамасы читтә, кырмыска оясы өстендә капланып яткан ди. Тәнендә яра-фәлән дә, бәрелгән-сугылган җирләре дә юк. Үзе сөйләр иде дә, аңына килә алмый бит!

Сәер. Нәрсә булырга мөмкин Барыйга? Әле генә жир жимертеп йөри иде ич!

—Урманга нәрсәгә барганы аңлашыла инде. Марилардан колхозга делянка сатып алган иде. Нишләп аңын югалтып егылган, монысы һич тә башка сыймый.

Төш вакыты житәрәк, шәфкать туташы (маржа әбине мөлаем гына яшь кыз алыштырган иде) алар янына чыгып, авыруның күзен ачуы, сөйләшә башлавы хакында хәбәр итте. Кыз әйтүенчә, күзен ачуга Барый сау-сәламәт кешегә әйләнгән дә куйган. Ләкин барыбер янына керергә рөхсәт юк әле. Кәефе шулай әйбәт торса, кичкә гади палатага күчерәбез, дип, вәгъдә бирде, күрешү дә шул вакытта гына рөхсәт ителәчәк иде.

Мөхәммәт Һади абыйсын өенә чакырды, кичкә чаклы ял итеп, аннан соң бергәләшеп тагын килербез дигәч, тегесе карышмады, чөнки шәһәрдә башка барыр кешесе дә юк, хәер, укучысы Мөхәммәттән дә якынрак кеше Казанда болай да юк иде. Мөхәммәт—рәсем төшергәндә бите, борыннарына чаклы буяуга манчылып беткән малай—житди кешегә әверелгән, үз-үзен тотышы гына түгел, холык-фикере дә нык үзгәргән иде.

Петербургларда укып йөрү, күрәсең, эзсез калмаган. Гап-гади авыл малае дип һич кенә дә әйтә алмыйсың!

Мөхәммәт хастаханә каршына чыгуга, Һади абыйсы хөрмәтенә машина туктатты. Танкодром, Вишневский урамнары аша кайттылар. «Барыйның кәефе яхшырса, килгән юлы берәр мәчеткә кереп чыгарга кирәк әле...», дигән теләге барлыгын әйтте Һади абый.

Мөхәммәт укытучысының мәчет сүзен телгә алуына гажәпләнмәде, чөнки белә: соңгы елларда Һади абый шәмаилләр язу белән хирысланып киткән иде. Ул моннан жиде-сигез ел элек Казан кызына өйләнгән һәм алар Байтимердә бер малай үстерәләр. Югары белемле табибә хатын авыл медпунктында гади фельшер булып эшли.

Мөхәммәт яшәгән биш катлы «хрущевка» йортының ишегалды бизәкле тимер рәшәткә белән әйләндереп алынган. Аның ике капкасы бар, берсе жәяүлеләр өчен, зурысыннан жиңел машиналар кереп-чыгып йөри.

Хужа кеше өйгә керер алдыннан янәшәдәге маркет-кибеткә сугылмакчы иде, аннары кунагы белән йөрүне килештермәде, соныннан үзем генә чыгып керермен дигән уй белән Һади абыйны туп-туры өенә таба алып китте.

Баскычтан бишенче каттагы фатирга күтәрелү беркайчан да матур хисләр уятмый, иртәләрен бигрәк тә шулай. Беренчедән, подъезд янындагы үләндә шприцлар аунап ятса, баскычта сыра шешәсе ватыклары аяк баскан саен чытыр-чытыр килә. Югыйсә, бу күптән салынган «хрущевка»ның байтак фатирларында ялгыз әбиләр, гомумән, карт-коры яши. Надан булмаган кеше яхшы белә: ул шприцлар әби-бабайлар чакырткан «скорый»дан төшеп калмаган, кич житүгә, ишегалдына, подъезд төпләренә яшь кызлар, яшь малайлар жыела. Наркомания Казанга яшен тизлеге белән үтеп кереп, яшь буынны яртылаш гарипләндерергә өлгерде инде!..

«Кәефеңне күтәрү өчен түгел, кәефең начар булмасынга инә кадау моменты бик тиз килеп житә икән ул»,—дип, ачынып әйткән атаклы француз жырчысы Эдит Пиаф. Заманында ул да әлеге чирдән дәваланып йөргән.

Без һәммәбез дә, хәтта хөкүмәт кешеләр дә—халык. Шулай булгач, пычрак сәясәт белән мавыгып дөньясын онытkan сәясәтчеләр, дәүләт-хөкүмәт бәндәләре үз гаиләләрен, кызларын-малайларын наркомания дигән афәттән ничекләр итеп саклап калмакчы булалар икән?

Ниндидер бер бәйрәм табыны артында, кызып киткән бер хөкүмәт чиновнигы, күкрәген кагып мактана-мактана: «Минем байлык оныкларымның оныкларына житәрлек! Халык турында уйлый-уйлый чәчләрем агарып бетте инде, болай да!»—дип ычкындырды. Шулчак Мөхәммәт янәшәсендә тәмәке пыскытып торган таныш язучы: «Малаең яки кызың инәгә утырса, байлыгын оныкларына калу түгел, ничек итеп соңгы ыштанынны салганыңны үзең дә сизми калырсың әле, туган!»—дип, тегенең авызын каплаган иде. Чынлап та, наркомания һава буенча таралган яман вирус кебек бит ул!.. Аннан балаларыңны яки оныкларыңны зиннәтле коттеджына бикләп куеп кына качып котыла алмассың, кем әйтмешли, тынчу көннәрдә барыбер тәрәзәнне ачасы булыр! Шуна күрә, син агай, кулыңда власть бар чакта, ул афәткә каршы аяусыз көрәш инде, яме. Әгәр дә халык турында уйлый-уйлый, аның мәнфәгатьләрен кайгырта-кайгырта каешланып бетеп, бик шомаргансың икән, йөрәген маемлаган икән, һичьюгы үз балаларымны, оныкларымны кайгыртам дип тырыш, ичмаса, чиновник агай!

Бернәрсә дә юктан бар булмый. Үзгәртеп корам дип, Горбачев Ил капкасын төбенә чаклы каерып ачып куюга, Рәсәйгә күп афәтләр инде. Ә боларның тамыры ерактан, бик ерактан килә икән ләбаса!

Ул яшүсмер чакта Һади абыйсы Мөхәммәткә Шопенгауэрлар,

Нишшелар тәгълиматенең кайбер җөмләләрен тукый иде, ә бүген, баскычтан күтәрелгән арада, наркомания хакында авыл укытучысына үзе тулы бер лекция сөйләп ташлаганын сизми дә калды.

Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Америка Кушма Штатлары Советлар иленә каршы салкын сугыш ача. Аларның максаты СССРны таркатып, илне кол итү була. Миша Горбачев ярдәмендә алар тыныч юл белән, нәкъ яһүдләргә хас булганча салкын акыл белән, максатларына ирештеләр. 1945 нче елда Америка стратегы Даллесның нәрсә дип хыялланганы һәркемгә мәгълүм хәзер.

Сугыш бетәр, барысы да тегеләйме-болаймы тиешле эзенә төшәр, көйләнер,—ди ул. Һәм без бөтен көчне, булган бар нәрсәбезне... барлык алтыныбыз, матди куәтебезне совет халыкларының башын әйләндерүгә, аларны җүләргә сабыштыруга ташлаячакбыз.

Кешенең баш мие, акылы үзгәрүчән бит. Анда буталчыклыклар тудырып, без чын кыйммәтләрне ялган кыйммәтләргә алыштырачакбыз. Ничек итепме? Фикердәшләр, аркадашлар һәм ярдәмчеләрне без Рәсәйнең үзеннән үк табачакбыз.

Дөнья сәхнәсендә, пәрдә арты пәрдә, жир йөзендәге иң башимәс халыкның һәлакәте, аның акылының тәмам, инде кабат уянмаслык итеп сүнүе хакында биниһая фаҗига уйналачак. Әдәбияттан һәм сәнгатьтән без, мәсәлән, әкренләп социаль мәгънә дигән нәрсәне юып алачакбыз. Сәнгатькәрләрне кабаттан өйрәтәчәкбез, аларны гавам эчендә барган процессларны тасвирлауга диикме, өйрәнүгә диикме, булган теләкләреннән сыптырачакбыз. Әдәбият, театрлар, кино—һәммәсе, кешенең иң түбән хисләрен сурәтләячәк һәм данлаячак. Кеше аңына секс, көчләү, садизм, хыянәт—бер сүз белән әйткәндә, һәртөрле әхлаксызлык тутыру һәм төйгечләү белән шөгыльләнәчәк андый «сәнгатькәрләр»не без һәрдаим яклаячакбыз. Дәүләт белән идарә итүдә без буталчыклык һәм башбаштаклык тудырачакбыз...

Без сиздермичә генә, әмма бик актив һәм даими рәвештә чиновникларның, ришвәтчеләрнең башбаштаклыгын, аумакайлыкны алга сөрүгә булышачакбыз. Бюрократик һәм чуалчыклар унай сыйфатлардан саналып йөртеләчәк. Намуслылык һәм гаделлектән көләчәкләр, алар бөтенләй кирәкләре бетеп, искелек калдыгына әвереләчәк.

... Ерткычлык һәм оятсызлык, алдашу һәм ялган, эчкечелек һәм наркомания, бер-береннән хайваннарча курку, читенсенә белмәү, хыянәт, милли өстенлек, халыклар арасында дошманлык—боларның һәммәсен без оста һәм шома гына чәчәчәкбез һәм болар һәммәсе гөрләп чәчәк атачак һәм бары тик азчылык, бик кечкенә азчылык кына нәрсә барганын төшенер яки хәтта аңлар да... Әмма андыйларны без мескен хәлгә куячакбыз, тәмам көлкегә калдырачакбыз, алар турында ялган фикер тудыру һәм аларны җәмгыять төпкелендә дип игълан итү юлларын табачакбыз. Большевизмның рухи тамырларын йолкып ыргытачакбыз, әхлакый нигезләрен пычратачакбыз һәм юк итәчәкбез. Без шулай итеп буын арты буыннарны какшатачакбыз. Ленинча фанатлыкны эшкәртәчәкбез, төп игътибарны һәрвакыт яшьләргә бирәчәкбез, аларны таркатачакбыз, бозачакбыз, аздырачакбыз. Без алардан шпионнар, космополитлар ясаячакбыз. Без моны нәкъ менә шулай эшләячәкбез.

Мөхәммәт ватык сыра шешәләренә басмыйм-басмыйм дип, сак кына атлаган Һади абыйсына кыскача шуларны сөйли башлады. Һади абзый бу мәсьәләләрдә үзе дә төшеп калганнардан түгел икән:

—Гасырлар буе урыс хакимлек иткән бу илне, ниһаять, кызык иттеләр!—диде ул.

Сөйләшә торган сүзләре күңелсез темага булгач, бишенче катка менеп җитү бик авыр, газаплы гомер узуга тиң иде кебек.

—Гитлер кадәр Гитлер биш ел буе сугышып та басып ала алмаган иде. «Горби жилләре» исә башлагач, ниһаять, безне чит илләр сугышсызнисез генә басып алдылар!

—Әйе шул, әйе,—дип куәтләде аның сүзләрен остазы.—Дошман тугыз, без сигез генә икән ләбаса!

Алар икесе дә яхшы аңлап бүгенге җәмгыятьнең сәяси һәм икътисади хәленә шактый ныклы анализ бирә алырлык кешеләр иде.

Гомумән, нәрсә соң ул бер илнең икенче илне тыныч юл белән басып алуы? Гади генә аңлашканда, басып алучы алынган Илнең икътисадын кысрыклап, үзенекен кертә. Басып алынган Илнең халкы үзе берни житештерә алмый, басып алучының үтмәс тауарын гына үзләштереп ята. Кыскасы, тегеләрнең байлыгын арттыра!

Икенче ягы да бар. Анысы тагын да куркыныч һәм ул кабахәтләрчә эшләнә. Монысы мәдәниятне, рухи мирасны үтерү. Ягъни басып алучы Ил үз мәдәниятенең төссез, ямьсез тауарын басып алынган илгә кертеп тутыра һәм шуның белән «кол» халыкның миен агулый, күңелен тупасландыра, пычрата.

Карагыз, көнбатыштан һәм океан аша кергән ул «хлам»ны! Ниләр генә юк! Секс, үтереш, шакшылык, пычраклык һәм дә иң әшәкесе—наркомания!

Остаз белән шәкерт икенче кат белән өченче кат баскычлары арасындагы мәйданчыкта тукталып калдылар. Бүген якшәмбе көн булгач, баскыч мәйданчыклары җыештырылмаган, төнге хәлләр аерымачык булып күз алдында тора. Чүп савытлары сыра шешәләре һәм шприцлар белән тулган...

Боларны күрү бик авыр да һәм шул ук вакытта әлеге ансыз яшьләр кызганыч та иде. Һади тәрәзә янагына сөялеп, урамга карап тора башлады. Тәрәзә каршындагы ялгыз каен агачы,—күрәсең, күптән утыртылган булгандыр, бишенче катка чаклы матур булып үскән, ямь-яшел яфраклар ярган.

Каен гына аны баягы күңелсез сөйләшүдән һәм авыр уйлардан арындыра алмады. Ул үзе кебек үк тәрәзә янагына сөялеп урамга карап торган Мөхәммәткә таба борылды.

—Телевидение көне-төне наркофильмнар, боевиклар әйләндерә. Минем кечкенә малаем телевизордан пычрак секс карап утырырга тиеш! Нишли алам соң? Шарт иттереп телевизорны сүндереп куйдым ди. Бу мәсьәләне хәл итү түгел. Баланың күңеле ымсынып калачак, чөнки аның кызыксыну хисен берничек тә сүндереп булмый, ул телевизор гына түгел. Шулай итеп бары бер юл—фильмдагы хәлләргә балана аңлатма биреп утырырга гына кала. Ләкин ул «безобразие»гә беркем дә, бернинди дә аңлатма бирә алмаячак!

Әгәр дөньялар киләчәктә дә болай бара калса, иманым камил, тагын ун-унбиш елдан бозык буын барлыкка киләчәк. Күреп торасың, әледән үк тараканнар кебек үрчи инде алар. Тиздән яшьләр женси теләкләрен нәкъ этләр кебек урамнарда, чүплек артларында канәгатьләндерә башлаячак!

Һади шулай дип әйтеп тә бетерде һәм шуның артыннан ук әллә нинди ямьсез тавыш белән көлеп тә җибәрде.

—Әнә, әнә, күрәсеңме!

Ул уң кулы белән каенга таба ишарәләде. Каен ботакларына, җиргә төшеп житә алмыйча, өч презерватив эленеп калган да, җил искән саен, агач яфраклары белән бергә, җилфер-җилфер киләләр иде...

Мөхәммәт үзе дә сизмәстән сүгенеп җибәрде. Подъезддагы тәртипсезлеккә ул иялнгән, әлләни игътибар да итмәгән иде, шешәләрне дә таптап кына узды. Ә Һади абыйсы алдында, укытучы һәм авылдан килгән кеше каршында, унайсыз, бик унайсыз иде. Әйтерсең, тәртипсезлекләрне ул үзе эшләгән, баягы сүзен дә аклану өчен генә башлап җибәргән иде. Һади абыйга шул житә калды, ул боларны күңеленә бик якын алып, кызып китте. Беркавымга Барый да онытылып торды.

—Океан артыннан массакультураның язгы ташу кебек килеп керүе бигрәк тә безнең Татар милләте өчен куркыныч! Без, урыс итәге астында болай да «үләм-бетәм» дип яшәгән милләт, үзебезнең борын-борыннан килгән милли гореф-гадәтләребезне ничек саклап калырбыз, газиз балакайларыбызны ничекләр итеп, кемнәр итеп үстербез икән!

Мөхәммәт аның сүзләрен куәтләгәндәй:

—Урыс итеге белән маржа итәге астында яшәгән милләт без,—дип кенә куйды да, башка сүз әйтмәде.

—Кая, синең «Урман» картинаң нинди хәлдә? Ул урман үзе таланып бетеп бара бит инде. Ичмаса, синең картинаңда булса да саклап каласы иде аны.

Әлеге сүзләрне Һади абыйсы ачынып, йөрәге җылап әйтсә дә, Мөхәммәтнең ул хактагы сүзне артык куертасы килмәде. «Һаман шул картина!»—дип көрсенде дә:

—Тәмам инде ул, диде. Бу вакытта фатир ишегенә килеп житкәннәр иде инде. Өендәге радиосы бар көченә кычкырып эшләп утыра, алар ишектән кергән шәпкә дикторның иртәгә булачак һава торышы хакында әйткән жөмләсен ишетеп калды: «Иртәгә көн кояшлы»...

«Кояшлы, пычагым! Көн иртәгә болытлы булачак! Нәкъ бүгенге кебек. Синоптиклардан алган хәбәрне укыганчы, ичмасам, тәрәзәдән урамга күз ташлар идең. Дөньяны болыт каплаган бит!»—дип көрсенде Мөхәммәт, диктор белән күңелленнән бәхәскә кереп.

## Эттән туган...

Әнисе аңына килеп, кәефләре яхшыргач, Һади абый Байтимергә кайтып китте. Мин иртәнге якта көн саен Барыйның хәлен белергә бардым. «Бәлки, невроз булгандыр, ял итсен, каннарын чистартабыз»,—дип, табиблар Барыйны тагын бер атнасыз чыгармаячакларын әйттеләр. Урындагы кеше урындагы кеше инде, Хәниф Хатыйпович шалтыратып, Барыйны тыныч, уңай палатага күчерттерде. Шуңа күрә мин аның янына баргач, иркенләп сөйләшеп утырырга да мөмкинлек зур, комачаулаучы кеше юк. Ә палатадашы исә үзе дә сөйләшергә сусаган пенсия яшендәге абзый кеше менә дигән әңгәмәдәш. Ул гомере буе университетта фәнни коммунизм һәм атеизм укыткан. Хәзер дә хезмәттә икән, хөкүмәттә дин эшләре буенча консультант, Татарстанда мәчетләр төзү буенча Үзәк Киңәшмә әгъзасы. Ул һәрвакыт диярлек гәүдәсе каеш белән тартылган кыяфәттә түшәмгә карап ята. Остеохондрозмы, умырткасының нервылары кысылып шулай булганмы, биле катып, гәүдәсе алга таба бөгелгән килеш калгач, хастаханәгә керергә мәжбүр булган. Үзе әйтмешли, гәүдәсе фәнни коммунизм фәне кебек берзаманны тиктомалдан каткан да калган. Юморга бай, күңелен төшенкелеккә бирми торган жор телле кеше Сабит Садыйкович.

Хәл сораудан башка, иркенләп Барый белән сөйләшеп утыра алганым юк. Килеп керүгә, Сабит Садыйкович сүзгә кушыла һәм аның ару белмәс тиктормас теле тегермән тартуда. Үзе сөйләвенчә, ул карчыгы белән ике малай тәрбияләп үстергән. Карчыгының аяклары авыртса да ул аның хәлен белергә атнага бер булса да килеп китә, ә малайларның эзе дә юк һәм алар турында сөйләргә Сабит Садыйкович үзе дә бик атлыгып тормый. Шул хакта сүз чыкканда да әңгәмәне бик җайлап кына икенчегә борып жибәрә иде.

Мин килеп кергәндә Барый баш өстендәге радиосын тыңлап ята, Сабит Садыйкович гәжит укый, ара-тирә ат кебек пошкырып көлеп жибәрә. Аның белән янәшә ятакта керәшен Василий түшәмгә карап тавышсыз-тынсыз гына нидер уйланып ята. Күренеп тора, Сабит Садыйковичның ат кебек пошкыруы бер дә ошамый, әлеге авазлар кинәт, көтелмәгән булгач, ул сискәнеп-сискәнеп китә, әмма күршесенә шелтә белдерергә һич тә жөрьәт итә алмый. Сабит Садыйкович килештереп сөйли, кызык итеп сөйли, аны тыңлап ятуы үзе бер рәхәт! Нәкъ менә шул сәбәпле түзәргә дә туры килә инде. Ни хәл итәрсең!..

Ул Сабит Садыйкович авызыннан үз гомерендә беренче мәртәбә «масон» дигән ят сүз ишетте. Әүвәл ул аны «масло» дип аңлаган иде. Кешеләрнең иң каймакларын гына ул оешмага кертәләр ди бит! Каймак

белән май бертуганнар бит инде, әлләни аерма юк! «Масон»ны «масло» дип анласа да гаеп түгел.

—Егетләр, тынлагыз әле менә!—диде Сабит Садыйкович. Һәм рөхсәт тә сорап тормыйча укырга керешге.—Умнеющей и хитреющей нации ты принадлежишь, Хакимов, то есть татарской, ди Виктор Астафьевның бер герое татар кешесе турында. Икенче урында башка герой нәкъ шул ук сүзләрне еврейлар хакында әйтә. Күрәсезме, яратмый атаклы урыс язучысы татарны. Еврейларны да яратмый, әмма курка. «Умнеющая и хитреющая нация», дип атый, еврейлар белән бер калыпка сала. Һе, кызык бу кызыгын. Дөреслек тә бар монда. Чынлап та, умнеющая нация без, еврейлар кебек. Бәлки, алардан да умныйрактыр әле. Кыскасы, чуваш әйтмешли, полно умныйлар. Татарстан дигән җиребез бар. Мәдәниятебез, телебез, динебез. Еврейның болар юк бит! Урыс булып йөриләр. Ул милләтне кимсетеп әйтмим мин. Затлы халык алар. Әнә, безнен табибны, профессор Берманны гына алыйк. Андый шәп табиб бөтен Татарстанга берәү! Бертуган абыйсы күрше кафедрада, философиядә эшләде. Беләсезме, шунын, Михаил Израиловичның, лекциясен тынларга бар институт җыела, утырырга урыннар булмый торган иде.

Сабит Садыйковичның сүзе бүленде, палатага, гомере озын булыр, профессор Александр Израилович Берман үзе килеп керде.

Александр Израилович уртача буйлы, анын бер генә бөртек кара чәче дә юк, ап-ак һәм коелмаган, бик куе. Шул ак ефәк чәче бөдрәләнеп тә тора. Күзләре конгырт, иреннәре калын, борыны карчыга борыны сыман: алай ук очлы булмаса да дуга кебегрәк. Профессорнын кыяфәте читтән караганда, житди кебек тоелса да, авыру янында ул гел көләч йөзле. Шунысы кызык, авыру янәшәсендә берничә минут хәлен сораштырып һәм киңәшләр биреп утырганнан соң тегесе дарусыз да терелеп киткәндәй була, профессорнын йә күзләреннән, йә кулларыннанмы, зур дәвалау көченә ия булган унай энергия агыладыр шикелле. Бу юлы да ул, һәркем белән итагатьле генә исәнләшкәннән соң әүвәл Барый янына килде (бу палата махсус һәм түләүле палата булып, авыруларны атнага ике мәртәбә профессор үзе кереп карый). Мин гафу үтенеп, коридорга чыгып торырга уйлаган идем, профессор кузгалмаска кушты. Ул авыру ятагы янәшәсендәге артсыз урындыкка утырды.

—Син борчылма, егет! Тиздән өенә кайтып китәрсен. Җаның өшәнгән булган. Арыган, талчыккан булган рухын, егет. Чөнки син соңгы арада аны үстерү, баету өчен эшләмәгәнсен. Җан—үлемсез. Ана һәрвакыт энергия өстәп тору мәҗбүри. Шулай итмәсән, ул сине ташлап китәчәк. Синен бар бәхетен үзенә салынган, индивидынның нинди булуы синен тормышына турыдан-туры йогынты ясый, Гетены укыганың бармы синен? Ул менә нәрсә ди:

Кол, халык һәм җинүче
Күптән инде танылган.
Һәм җирдәге зур бәхет
Шәхескә бит салынган.

Сәламәт хәерче авыру патшага караганда күпкә бәхетлерәк.

Рухы бай кеше адым саен кызык эзләп йөрми. Ана болай да тормыш күнелле. Сократ нәрсә дигән, беләсенме? Ул әйткән: «Уйласан, тормышта мина бөтенләй кирәге булмаган бик күп нәрсәләр бар икән!»

Йә, ярый, күп сөйләп ташладым. Син акыллы егет, үзең дә анларсын. Җан тынычлыгы кирәк сина, җан тынычлыгы. Якын иткән кешен булса, өйләнеп җибәрерсен тагын!

Анын бу сүзләреннән мин үзем дә сизмичә көлеп җибәрдем һәм Барыйнын да ирен читләре бел н елмаеп куйганын күрдем. Барый җавапсыз калмады:

—Рәхмәт, профессор! Минем туйда түр башында булырсыз!

Профессор саф татар акценты белән:

—Алла боерса!—диде. Аның күзләренә чаклы елмая иде.

Профессор чыгып китүгә Сабит Садыйковичның тел тегермәне янә хәрәкәткә килде. Аның гәүдәсе каеш белән тартылган иде, ул башын чак кына күтәрә төшеп:

—Акыллы адәм дә инде бу профессор!—диде ул.—Тик беләсезме, еврейлар бер-берсе өчен тырыша, яклый диләр. Безнең татар да шулай. Казанда димим, диаспорада шулай. Читтә татарлар бер-берсе өчен үлеп торалар! Нәоборот, без еврейларның бер-берсен ничек кырулары турындагы фактларны күбрәк беләбез. Троцкийларны искә төшерегез. Бер-берсен ничек бугазлыйлар! Ә шулай да еврей барыбер татарга караганда өстенрәк бит! Ни өчен шулаймы! Аңлатам, диаспорада татарлар бер-берсен яклый, күтәрә дидем бит әле. Ә еврей өчен бу жир шарының һәр кыйтгасы да үз туган иле. Еврейның туган иле—диаспора! Юк, юк, бу гына түгел әле! Ул халыкның иң светлый умнары масон ложасында тора! Менә көч кайдан килә аларга! Заманында безнең татар да әлеге ложаларга кергән булсамы!!! Их, юк шул!.. Беләсезме?!

Сабит Садыйкович сүзен тәмам кылырга өлгерә алмады, шәфкать туташы кереп тарттырылган каешларны чиште һәм аны икенче процедурага алып чыгып китте.

Мин аның масон ложалары хакында әйткән сүзләре белән килешмичә:

—Петербургта укыганда күрдем мин, Сабит Садыйкович! Жир йөзендәге барлык бәла, афәт шул масоннар аркасында!—дип калдым. Миңа каршы жавап бирергә вакыты юк иде.

—Шат күңелле карт,—дип куйды Барый аның артыннан.—Бүген малайлары турында сөйләп алды әле. Монарчы ул турыда авыз ачканы юк иде. Начар төш күргән, борчыла. «Үзем гомерем буе фәнни коммунизм укыттым. Ә гаиләмдә тәртип ясый алмаганмын. Балалар ач-ялангач йөрмәсен, кеше булсыннар дия-дия көн-төн эшләдем. Нәрсә килеп чыкты диген? Зур түрәнең игезәк кызларына өйләнделәр. Ул иркә кызлар икесе дә наркоманка булып киттеләр. Үз артларыннан малайларны да иярттеләр!—дип сөйләп торды.

Мин сүз катмадым, авыр итеп көрсенеп кенә куйдым.

—Бүген көн тагын болытлы ахрысы?—дип сорады Барый тәрәзәгә карап.—Әйбәт йокладым бүген. Бер төш тә күрмәдем,—диде ул шуның артыннан ук һәм янә миңа таба борылды.—Профессор—хәйләкәр карт. Кичә миннән сорый, аракыны күп итеп эчәсеңме, ди. Мин әйтәм, туры килгәндә берәр шешә инде дим, тик ул гына күзгә чыкмый дим. Еш туры киләме соң, ди. Дөресен әйтмәдем, айга бер-ике мәртәбә генә дидем. Үзенчә, белая горячка булмаганмы икән дип, кызыксынуыдыр инде. Бар ди сиңа, белая горячка! Начар аракы эчәбез, мин әйтәм. Шуны эчкәч, күзгә әллә нәрсәләр күренә башлый, мин әйтәм. Алар үзләре чиста спирт кына эчеп яткач та!..

Василий тәмәке тартырга чыгып китте. Икебез генә калгач, Барый белән күзгә-күз карашып сөйләшеп булачак иде. Ул минем төпченә башлавымны көтмичә, үзе:

—Беләсеңме, малай, мин урманда ул көнне кызык хәлгә тап булдым бит,—дип, сүз башлады.

—Кеше башлы бүре күрдем мин!

—Кит! Ул көнне үзең әйтмешли, начар аракы эчкән идеңме әллә?

—Юк, ул көнне грамм да тотмаган идем. Аның алдагысында да!

—Алайса нәрсә булды икән соң?

—Син, зинһар, бу хакта бер кешегә дә ләм-мим, яме. Хәтта Һади абыйга да әйтмәдем мин моны.

Күренеп тора, Барый уйнап та, шаярып та сөйләшми, сүзләре чыңга охшаган иде. Тик ул таланып беткән шәрә урманда кеше башлы нинди бүре булсын?! Бүре башлы чын ерткычлар да качып киткәннәрдер инде!

Барый беркавым тәрәзәгә таба карап хәрәкәтсез утырды да кинәт утырган урынында кымшанып куйды һәм кипкән иреннәрен ялаштыра-ялаштыра миңа төбәлде.

—Беләсенме, Мөхәммәт. Пиратны күрдем бугай мин. Хәтерлисенме безнең Пират исемле этне? Бүрегә әйләнгән ул. Бәлки, Пиратның баласы булгандыр. Мин аны күптән юкка чыккандыр дип уйлаган идем. Урманнан кире кайтмады бит теге вакытта. Кыйнаган идем, мина үпкәләде. Ул үзе дә бүрегә охшаган иде бит. Хәтерлисенме син?

—Хәтерлим,—дидем мин моннан байтак еллар элек булган вакыйгаларны, дөресрәге, үземнең Сигнал кушаматлы нечкә билле маэмаемны һәм Барыйның бүре белән эт гибриды булган Пиратларын искә төшереп.

—Пират иде ул. Йә баласы! Янымда мылтыгым юк иде. Шуны сизеп урман авызына чаклы артымнан озата барды. Ярый, машина сүнеп калмады әле.

—Ярый,—дидем мин Барыйның сүзләре белән килешкәнлегемне белдереп.—Пират та булсын ди. Этнең бүре белән кушылып гибрид барлыкка килүе дә яналык түгел, бәлки, Пиратның баласы булгандыр. Ә теге кеше башлы бүрең?

—Белмим—дип, жилкәсен сикертеп алды Барый һәм, аптырап, гажәпләнеп, мина карады.—Бүре гәүдәсендә... беләсенме, олы кеше башы түгел иде ул. Бала... бала башы иде, Мөхәммәт.

—Әкият!—дидем мин, капылт кына урынымнан торып тәрәзә янына килдем. Болытлар таралып, күк йөзе ачыла башлаган кебек тоелды.—Әкият!—дип кабатладым мин.—Син, брат, мөгаен, урманда югалган малаеңны сагынып саташасыңдыр. Шуңа күрә сина шулай булып тоелган да ул! Профессор дөрес әйтә, жаның талчыккан синең...

—Бернинди дә әкият түгел, дустым. Саташмадым да, төш тә күрмәдем мин.

—Син ул көнне точно исерек түгел идеңме?

—Юк, юк, шыр аек идем. Шуның алдыннан гына, килгән юлы дип, Гөлйөзем янына да кереп чыктым әле...

—Син может кара махмырдан булгансыңдыр. Махмырдан да күзгә әллә нинди шайтаннар күренә бит ул. Мәсәлән, минем шулай булганы бар. Кичтән бик көчле йокы даруы да эчеп яткан идем. Төнлә саташып уяндым. Имеш, безнең урман дөрләп яна икән. Гөлчәчәк белән икебез ут-ялкын эчендә калганбыз. Әллә төш күрәмме икән соң дип, тәнне чеметеп карыйм, авырта, нормально, төшләнмәгәнмен дә. Менә шулай да була ул, брат.

—Юк, юк!—диде Барый аның сүзләренә каршы.—Анысы мин ул көннәрдә арыган, талчыккан идем, ике-өч көн рәттән йоклый алмадым. Шуннан һади абый хатынына, жингәйгә зарландым. Кичен ул мина нииндидер укол салды салуын. Барыбер йоклый алмадым. Аунап яттым-яттым да нәрәдкә чаклы урманга чыгып киттем. Өйләре янында Гөлйөземне очраттым. Ул атлары янынннан кайтып килә икән. Машинаны таныган, капка янында көтеп торган.

—Жингәң йоклата торган укол салып, минем кебек син дә саташкан булсаң?

—Белмим,—дип Барый янә жилкәләрен сикертте.—Ну, аңа чаклы, бүрене дә, бүрегә әверелгән Пиратны да күрдем бит мин. Димәк, ул мине сагалый! Корытам мин ул урманны, Мөхәммәт! Авылны тау башына күчергәндә яна йортлар салу өчен агач та күп кирәк булачак. Үзәнгә, иске Байтимер урынына, яна урман утыртачакмын!

—Ничек бетермәкче буласың син ул урманны, Барый туган, тайгага чаклы дәвам итә бит ул!—Илләтнең теге ягы мариныкы бит әле аның.

—Мари белән дә уртак тел табарбыз. Кирәк булса.

Безнең әңгәмәне, тәмәкесен пыскытып бетереп, палатага кергән Василий бүлде. Ул нигәдер ялт-йолт минем якка карап куйды да урынына барып ятты. Аннары үзалдына сөйләнгәндәй:

—Без берни белмибез икән, ә, малай!—дип мыгырданды.

Мин дә, Барый да аның сүзләрен игътибарга алмадык, үзебезнеке куәтлерәк иде. Ләкин чит кеше янында сөйләшеп тә булмый иде инде. Сүзләренең жавапсыз калуын Василий өнәп бетермәде бугай, ул башын күтәрә төшеп, мина эндәште:

—Син... Сез художник бит, иеме?

—Әйе,—дидем мин салкын гына. Дөресен генә әйткәндә, бу вакытта анын белән ачылып сөйләшеп тә торасым килми иде. Шуна күрәме, кыяфәтем дә, сүзләрем дә төксе иде.

Әлбәттә, ул кешегә салкынрак мөгамәләдә булуыма бернинди сәбәп юк. Аз-маз,—якынча гына инде,—авыру тарихын да беләм: нервылары какшаган Василийнын. Ул студентлар тулай торагында комендант булып тора икән. Апрель аенда ике студент белән тулай торак түбәсеннән кар төшергәннәр. Егетләрнен берсе түбәдән егылып төшеп һәлак булган. Анын наркоман икәнлеген Василий белмәгән, кесәсенә шприцын тыгып менгән булган икән. «Әгәр наркоман икәнлеге ачыкланмаса, минем урыным болницада түгел, төрмәдә булыр иде инде хәзер!—дип кабатларга ярата кершен абые.

—Общежитиенен бер залын бизисе бар ие. Шуна художник таба алмыйбыз.

Бу кешенен мина ни өчен сүз катарга тырышуы анлашылды, тулай торак бизәргә үзенчә рәссам эзләве икән. Ләкин мин ана тагын жавап кайтармадым. Кабат сүз кушарга ул үзе дә уңайсызланды булса кирәк, караватын шыгырдата-шыгырдата, тәрәзәгә таба борылып ятты.

Мин, Барый белән саубуллашып, палатадан чыгып киттем һәм коридорда баягы профессор белән мангайга-мангай бәрелешә яздык. Ул мине туктатты да:

—Сез Петербург Академиясен тәмамладыгызмы?—дип сорап, мине гажәпкә калдырды.

—Әйе,—дидем мин анын бу соравына бик тә аптырап.

—Сезне Берман укытмадымы?

—Берман? Христофор Израилевич!

Профессорнын йөзе яктырып китте.

—Әйе, әйе. Минем бертуган абый ул!

—Укытты. Сәнгать теориясеннән. Һәм бик зур художник та бит ул!

—Әйе, әйе,—дип жөпләде профессор, үзенен көйле тавышы белән.—Йә, ярый, гафу итегез. Мин шул хакта гына сорамакчы идем. Ләкин сез, яшь егет, төрле оешмалар хакында... атап сөйләшмик, үзегез дә анлыйсыз, шактый ялгыш фикердә икәнсез! Ул Сезнен фикерегез генә булып калсын. Сөйләп йөрмәгез. Сезгә файдага эшләмәячәк дип уйлыйм мин ул ялгыш фикерләрне. Йә, ярый, гафу итегез. Мин болай гына. Онытыгыз минем сүзләремне, аларны башкалар белән анализлау мәжбүри түгел. Анламаган кешеләр бар. Мәсәлән, ул гап-гади комендантка шул кирәкме сон инде! Минем янга кергән дә, башымны катыра. Ә сез... Сез башка! Сез үсәсе кеше әле! «Война и мир»ны укып чыгыгыз әле тагын бер кат! Хәер, Казанда Сезнен күргәзмәләр бармы?

Мин ана жавап йөзеннән санап чыктым. Бу минутта бик каушаганымны сиздем мин. Моны, әлбәттә, профессор да тойды булса кирәк, ул кулын дусларча инбашыма куйды да:

—Уңышлар Сезгә! Вакытыгызны алдым! Мине гафу итегез!—дип, тиз генә коридорнын аргы башына таба китеп барды.

Минем бөтен тәнем манма су иде...

«Вак балык йокыга талмасын өчен елгада чуртан да кирәк!» Кем әйтте бу сүзне? Профессор Берманмы?

Әллә... Әллә аны егеткә нииндидер яшерен, серле тавыш китереп ирештердеме? Санк-Петербургта укыганда ишеткән идеме әле? Таныш бит, бик таныш сүзләр?..

... Петербургта без тулай торакнын бер бүлмәсендә өчәү: Мәскәү янындагы бер авылда туып үскән чандыр озын гәүдәле, сары чәчле егет Василий Иванов һәм Кырымнан бөдрә чәчле, кин мангайлы, уртача буйлы Абрам Соловьев белән бергә тордык.

Василий бәйрәм-сәйрәмдә авылына кайтып йөри һәм һәрвакыт, үзе әйтмешли, чык тамчысы кебек саф көмешкә кыстырып килә, аннан шул

кичне үк өчебез утырып авыз итә идек. Көмешкә каннарга йөгерә башлагач Иванов белән Соловьев һәрвакыт милли темаларга кереп китеп, соныннан бу анлашуның ахыргы нәтиҗәсе тәпәләшүгә дә барып җитәргә мөмкин иде.

Гадәттә, бәхәсне һәрвакыт Иванов башлый, мин, араларына кереп, нокта куярга ярдәм итә торган идем.

—Масоннар һәм еврейлар, якты идеягә хезмәт итәбез дигән булып, халыкның башын катырып яталар!

—Ә нигә? Халыклар арасында аерма булырга тиеш түгел! Милләт дисен! Причем монда милләт! Милли төшенчәне без онытырга тиеш!

Мин аларның бу бәхәсләренә кысылмаска тырышам. Бүлешсеннәр, талашсыннар шунда икесе генә дип уйлыйм.

—Абрам, беләбез бит инде! Алар милләтләрне бер тагаракка салып бутап, көчсезләндерү максатын куялар. Нигәме? Чөнки милләт аерым, үзенчә булганда куәтле, көчле була. Аңа бу көчне милли идея бирә! Бер тагаракта буталгач, милли идея бетеп, ул үләчәк, еврейнең итек астында калачак! Масон итәге астында...

—Масоннарга тел тидермә син! Белмәгән башың белән! Барлык дәүләтләрдә дә көчле йогынтылы, дәрәҗәле кешеләр һәм идарәчеләр масон булган. Алар Европаны урта гасыр баткагыннан алып чыкканнар

Алар бар халыкларның да туганлыгы идеясен таратучылар!..

—Икътисад, финанс, капитал масоннар һәм еврейлар кулында. Урта гасырда масоннар «ирекле ташчылар», ягъни төзүчеләр булганнар һәм төп эшләре храмнар төзү булган. Ә хәзер төзү эшләрен онытып алтын чүпләү белән мәшгульләр.

—Барлык гыйлем-белем дә, таралу дәрәҗәсенә карап, тора-бара беренчел максатын югалта һәм һаман саен үзгәртелә. Ә үзгәртү нәрсә ул? Үзгәртү—бозу ул, кадерлем! Такова человеческая природа!..—Дема-а-ааа-го-гия бу, Соловей! Масон син!

—Масон оешмаларының бер характерлы ягы бар: алар беркайчан да ачыктан-ачык чыгыш ясамыйлар, кире какмыйлар һәм мактауга да, тәнкыйтькә дә җавап бирмиләр. Ә мин синен фикерләрне кире кагып утырам. Димәк, мин масон түгел! Югыйсә, минем бу гамәлем масон этикасын бозу булыр иде. Мин бары хакыйкатьне яклыйм!

—Җир йөзендәге бар зур үзгәрешләр, революцияләр, канлы сугышлар, дәүләтләрнен юкка чыгуы, һәммәсе дә,—интернациональ еврей һәм масоннар эше! Алар бүтән халыклардан өстен булырга, бүтәннәрнен муеннарына менеп атланып, рәхәтлектән аякларын селтәп утырырга телиләр!

—Син алайса җавап бир: нинди партия яки оешма, йә булмаса кайсы халык өстенлеккә, башкалар өстеннән идарә итәргә омтылмый соң? Бармы андый халык?

—Мин сиңа Валентин Распутин сүзләре белән җавап бирәм: без, урыслар, байлыкка омтылмыйбыз. Байлык кешеләрне боза ул!

—Распутинны хөрмәт итәм мин. Ләкин икегез дә мине гафу итегез, байлыкка, яхшы тормышка омтылмаган халыкның мондый психологиясе аңлашылмый! Гел гөмбә җыеп, тозлаган кәбестә чәкәне суырып утырып кына да яшәп булмый ич инде!

—Башка халык өстеннән идарә итәргә омтылу—кешелек алдында коточкыч җинаять! Наполеон, Гитлер язмышлары ничек тәмамланды? Шул ук Гитлер һәм Сталин еврейларга коточкыч ачулы иделәр. Икенче бөтендөнья сугышына кадәр һәм шуннан соң синен күпме туганын кырылды! Сез үз халкыгызга каршы җинаятьне үзегез эшлисез. Березовскийларын эшли! Бар капиталнын бер учта булуы бүтәннәрнен ачуын чыгара.

Үз халкыма каршы андый җинаять эшләгәнче, иң яхшысы тозлаган кәбестәгә канәгать булып утырам мин. Уразов, ник дәшмисең, шулай бит?

Мин болардан ансат кына котылып булмаслыгын яхшы беләм, шуңа күрә берәр сүз кыстырып куям:

—Үз урынында тозлаган кәбестәсе дә, капиталы да кирәктер инде аның!

Иванов мен тапкыр кабатлаган сүзләрен тагын әйтә:

—Ну хәйләкәр татар син, Уразов!

Мин бертуктаусыз бимазалап тенкәмә тиеп беткән тизәк чебенен кугандай анын ягына таба кулымны селтим. Янәсе: «Чукынышып китегез шунда! Мине генә кыстырмагыз!»

Әнгәмәнен читкә борылуы Соловьевнын эчен пошыра, ул кызу гына:

—Ну, ярый, синенчә булсын ди. Берәр халык икенчесе өстеннән идарә итәргә омтылсын ди. Ләкин монда бөтен кешелек өчен дә бернинди куркыныч янамый лабаса! Эволюция ич бу, тормышнын алга бару законы! Каршылыксыз үсеп булмый бит! Бу, беләсен килсә, файдалы да әле! «Вак балык йокыга китеп харап булмасын өчен елгада чуртан да кирәк»диме әле? Юкса, йокыга талган вак балыкны агым үзе белән ияртеп китәчәк һәм көчле дулкыннар аларны яр өстенә ыргытачак! Менә һәлакәт кайда ул туган!

Иванов, көмешкә шешәсен әнгәмәдәшенә табарак этеп:

—Әйдә, эчеп куйыйк әле. Сал әле чак кына! Демогог кешенен сүзләре кебек кулы да жинел була ди.

—Бернинди демагог түгел мин! Демагог булсам, синен тавык тизәгеннән ясалган көмешкәнне эчеп утырыр идем мәллә?

Соловьев үпкәләде ахрысы. Әмма анын үпкәләве әнгәмәдәше каршында, биреләм дип, ике кулын күтәрүе түгел иде әле, ул һаман телләшә:

—Вак балык турындагы сүзләремне дәвам итәм, Василий Петрович! Менә шул, мәгәр вак балыклар чуртанга каршы көрәшә-көрәшә ныгырлар, көч жыярлар һәм дә беркөнне чуртаннан курыкмый да башларлар. Мин монда, беләсен килсә, синен файдага сөйләп утырам әле!

—Син нәрсә, безне вак балык дип атамакчы буласынмы?!

—Мин чагыштыру гына китерәм.

Көмешкә Ивановнын «кәллә»сенә барып житеп, егетнен холкы кайнарлана башлаган иде бугай, мин, бу ике әтәч арасында сугыш-фәлән чыгып куймасын дигәндәй, сагаеп, караватымнан башымны күтәрәм. Юк икән, әлегә икесе дә тыныч. Шулай да Ивановнын бала башы чаклы йодрыгы өстәл өстендә ята иде инде. Соловьев хәйләкәр һәм өстәвенә сак та, ул Ивановнын йодрыгына ымлап:

—Йодрык белән сугышып, үзеннен хаклыгынны исбатлый торган заман узды, дустым. Терсәгеннен очлы булуы кирәк хәзер. Төртеп кенә аласын—кем төрткәнен чуртым да белми, шулай бит, Мөхәммәт?

Боларнын мина еш мөрәҗәгать итә башлаулары бәхәскә нокта куярга кирәклеген анлата иде. Мин аларнын икесеннән дә куәтлерәк. Ачуым чыкса, икесен берьюлы тотып, түшәмгә эләм дә куям! Алар моны яхшы белә. Ләкин, Иванов бер кызып китсә, тиз генә туктатырмын димә, бүлмәдә барыбер нәрсә булса да ватылачак һәм тавышнын коридорга чыгуы да бар. Шуна күрә мин әнгәмә темасын икенчегә борырга тырышып, бәхәсне тыныч юл белән тәгәлләргә исәплим.

—Сез нәрсә, егетләр, юк белән башны катырасыз! Сез рәссамнәр бит! Сәнгать турында бәхәсләшегез, файдасы күбрәк булыр.

Алар минем әлеге хәйләмне икесе дә бик яхшы сизә, әмма минем белән һәрвакыт килешәләр тагын үзләре.

—Дөньяга татар тугач, еврей кычкырып елаган ди.

Бу Ивановнын яратып кына мина төрттерүе.

Соловьев та жавапсыз калмый:

—Шатлыгыннан елаган ул, ичмасам, жиргә тагын бер юньле халык туды дип!

Без өчебез дә дәррәү көлешәбез.

—Татармы? Татар—жүнле шул!

—Юкка гына заманында масон ложасына кермәгәннәр. Әрәм булып йөриләр.

Монысы Соловьевнын Ивановнын касыгына янә бер мәртәбә терсәк белән орынып алуы иде. «Тагын башлана бит!»—дип уйладым мин һәм өстәлгә Пикассо әсәрен китереп салдым.

—Әйдәгез, кем нинди мәгънә чыгара.

Бу Пабло Пикассонын «Герника» картинасы иде. Пикассо аны Басклар илендәге Герника җимерелгәч, шул унайдан яза. 1937 елның 26 апрелендә көпә-көндез фашистлар авиациясе саклаучысыз шәһәр өстенә ябырыла. Җиде мең кешедән мең алтын йөз илле дүрт кеше һәлак була, сигез йөз сиксән тугызы каты яралана. Картинада әнә шул дәһшәтле мизгелләр сурәтләнә.

Мин дә үзебез яшәгән бу болгавыр дөньяны, кызыклы-кызыксыз җәмгыятьне, аның бар матур якларын һәм бөтен фаҗигасен картинада сурәтләргә хыялланам! Беренче хыялым «Урман кызы»н язып, аны Гөлчәчәккә бүләк итү булса, икенче һәм зур максатым әнә шул!... Ходай мәдәт бирсен! Өметсез шайтан гына була ди...

—Үгез... Үгез нәрсәне анлата картинада?—дим мин, егетләргә карап. Иванов иренеп кенә:

—Нинди катлаулыгы бар инде аның? Үгез образы аяусызлыкны, мәрхәмәтсезлекне гәүдәләндерә.

Соловьев ана янә каршы төшә:

—Үгезнең кыяфәте усал, рәхимсез түгел бит! Пикассо анын сугышка ташланырга әзерләнгән мизгелен сурәтләгән!

—Ана белән бала образлары хакында ни диярсең?

—Пикассо кубизм алымы белән иҗат итә бит. Бер рәсемдә үзе сурәтләгән предметның барысын да символлар белән күрсәтергә омтыла. Парижда яшәгән испан егетенең француз көймәсенә утыруы дигән сүз инде бу. Әнә, ананың ачыргалануы хәнҗәрне хәтерләткән үткен тел ярдәмендә тасвирлана.

—Ат... Ат образы, Пикассо үзе раславынча, халыкны анлата!—дим мин, егетләрнең салынкы утыруларына эчем пошып. Югыйсә, монарчы телләре телгә йокмый иде!.. Хәер, алдагы көнне алар икесе дә лекциядә булмадылар. Югыйсә, Берман ничек шәп сөйләгән иде Пикассо турында!..

Әйе, шул рәвешлерәк Пикассоны «сүтеп» чыктык та тынычландык без. Тик минем күнелне генә Иванов белән Соловьевнын бәхәс-чәкәләшләре вакыт-вакыт тырнап тора һәм мин, кайсысы ягына чыгып уйласам да, уртак фикергә килә алмыйм, әмма үз акыл-көчем белән дөрес җавапны табарга азаплана идем.

Ул җаваплар тормышның үзендә икән... Аны анлау өчен вакыт һәм тәҗрибә кирәк һәм, әлбәттә, бик еш кына тирә-юненә дә күз салу мәҗбүр икән... Хакыйкать лапас артындагы тиреслектә генә аунап ятмый икән ләбаса!..

Барыйның, тирә-юньдәге төрле милләт халыкларыннан торган берничә авылны берләштереп-укмаштырып, тау башына менгезеп утырту хыялы, ни белән тәмамланыр сон? Төрле-төрле милләт халкы бергә-бергә,—дөресрәге, укмашкан хәлдә,—ничек яшәп китәрләр?

Әлбәттә, бу хактагы уйлар Барыйның башына да кереп карамаганлыгын мин яхшы чамалыйм. Идеологик максаты юк аның. Ана хәрәкәт кирәк, ана үзгәреш, яналык кирәк...

Минем анымдагы әлеге уйлар—Барый хакындагылары да, Петербургтагы бәхәсләр дә буталып бетте. Әмма мин күнелем белән тоям һәм сизәм, алар арасында ниндидер эчке бәйләнеш бар... Әлбәттә, бу очракта ул ансыз бәйләнеш түгел иде.

Әмма ни дисән дә СССР чаклы держава капылт кына таркалды да куйды бит! Тиктомалдан гынамы? Гомере беткән идеме? Горбачев белән Ельцин таркаттыларммы? Әллә аларның куллары белән генә эшләндеме?

... Хәтерем нәкъ кинофильм тасмасы кебек. Кадрлар берсе артыннан берсе чиратлашып, алышынып тора.

Соловьев. Дөнья белән масоннар да, яһүдләр дә түгел, өлкән ир туганнардан торган күзгә күренмәс Хөкүмәт идарә итә. Ул масоннардан да, яһүдләрдән дә һәм кешелектән дә өстенрәк. Кешелекнен бөтен бәхетсезлеге—әнә шуны анларга теләмәүдә. Ахыр чиктә аны белергә кирәк. Һәм үзеннен чын Хөкүмәтенә ышаныч белән карау зарур. Ул безгә нәрсә кирәген үзебездән дә яхшырак белә.

Иванов. Мин сина, Соловей, бер генә сүз белән җавап бирәм: демагогия!..

Соловьев. Яна Бөек Ачышлар шуны күрсәтә: киләчәк якты чор—рух чоры. Анда узып баручы изге расаның алтын Үгезбозавы бар мәгънәсен югалта. «Җирнең алтынын Яна металл белән коям. Алтын калкан нык түгел»,—ди Ходай. Яна чорга алтын калкан түгел, рухи капитал зарур. Киресенчә уйлаучылар бик каты ялгышачаклар. Дөрес, әлегә алтын Үгезбозау тулы һәлакәткә дучар булмады. Шулай булгач, эволюция вакытында ул да кирәксез түгелдер.

Иванов. Масоннар халыкның инде бәгырьләренә кереп сеңгән изге диннәргә каршы киләләр. Диннән тыш мораль тудыралар. Имеш, ул бар халыклар өчен дә уртак булырга тиеш. Масоннарның байраклары Шайтан-Иблис кулында. Алар шуның ярдәмендә безнең диннәргә каршы көрәшәләр.

Бар кешелекне, барча халыкларны, милләт, раса, кабилә һәм динмәдәниятләренә дә карамастан, бергә берләштерергә азапланалар. Утопистлар!..

Хәтерем тасмасы әлеге урынга җиткәч, мин сискәнеп киттем һәм Барыйның «Бөек көчеш»ен күз алдына китерергә күпме генә тырышсам да, барып чыкмады, мин буталып кына беттем. Ләкин кызык нәрсә, башта кырыкмаса кырык төрле уй-фикер яки фаразлар диикме, йә аны нинди дә булса хәлгә, күренешкә бәяләмә дип атыйбызмы—барысы да үз вакыты җиткәч, барыбер мәгънәви калыпка салына икән. Син йә тагын бер мәртәбә арба тәгәрмәче «уйлап табасың», яисә ул синен үзеннең бәләкәйме, зурмы ачышың була. Үз ачышың!..

Бүгенге җәмгыятьнең үсешенә, андагы төрле-төрле һәм эреле-ваклы үзгәрешләргә табигать кануннарыннан тыш, тагын башка көчләр дә тәэсир итә, зур йогынты ясый түгелме соң?..

Әйтик, коммунизмның максаты да милләтләрне уртак тагаракта болгатып совет кешесе дигән соры масса «тудыру» иде бит!

«Туганлык! Тигезлек! Ирек!»—лозунгысы да нәкъ шул максатка чакыра түгелме соң? Хәтта диннәрне дә юк итәргә өнди! Шуна каршы явыз Иблисне өстерә...

Гасыр капкасы ябылыр алдыннан безнең татар милләтен салып бәйләгән «капчык»ның авызын ачып алдылар. Бераз һава керде. Иркен сулыш алып җибәрдек. Ул янә ныклап, каты итеп бәйләп куелды. Сулап калган һавабыз тагын күпмегә җитәр?!

... Барыбер, мин, бер татар баласы, шуннан соң масоннар хакында тагын да ныграк кызыксына башладым. Әлбәттә, беләм, табигать кануннарына каршы баруның нәтиҗәсе соң чиктә һәлакәт белән бетәчәк! Ә шулай да масоннар феодализм чорыннан бирле яшәп килә бит әле... Исән-саулар, чәчәк аталар!..

Хәер, тагын шуны аңладым бугай, боларның серенә төшенми торып, алдынгы сыер савучыларның портретларын яки натюрмортлар ясаудан ары китә алмаячакмын!.. Мин... мин... мин мона гына риза, канәгать түгелмен!

Бәлкем, татар масоны оештырыргадыр? Безнең халык та бөтен җир шары буйлап сибелгән ләбаса!.. Ләкин максат изге, гүзәл, якты, матур булырга тиеш!..

Һай! Янәшә үскән ике агачның да көчләренә, көчсез күршесен узарга тырышып, тизрәк Кояшка омтылырга тырыша шул!..

Әгәр уйлый китсәнме? Бер уйлый башласаң, әллә ниләргә барып чыгасың! Әнә бит, теге чакта, Ивановны яклаганым өчен Солоевьев мина «Шаһгалиле халык бит сез!»—дип үчен алды.

Йә, әйтеп кара син мина Соловей туган: кайсы милләттә булмаган һәм хәзер дә юк соң ул Шаһгалиләр?..

Кайсысында чын каһарманнары юк?!. Йә, әйтеп кара!..

... Барый, авылларын тау башына күчергәнче, әүвәл андагы калкулыкка мәчет, чиркәү һәм синагога салдырам дигәч, аңа бу әңгәмә-чәкәлешләр турында сөйләгән идем. Ул, кызыксынып китеп, масоннар хакында язылган

китаплар да укып чыкты. Болай гына, үзем өчен генә дигән иде. Ай-һай, Барый дустым кызык өчен генә вакыт әрәм итеп, китап укып ятар микән, дип тә уйлап куйган идем. Хәер, белмәссең Барыйны!..

Әлегә исә Әкбәровта дөнья кайгысы түгел иде.

* * *

Барый саташмаган иде, Барый Әкбәров үз акылында һәм ул чынлап та аның югалтып кырмыска оясы өстенә егылганда кеше башлы, дөресрәге, бала башлы бүре күргән иде.

Бүре генә дә түгел әле... Бүре белән эт кушылмасы булган Пиратны һәм үзенең малае Әнвәрне...

Пират, чынлап та, бүре нәселеннән иде. Аның әнкәсе кайчандыр кыргый эт, әткәсе чын бүре иде. Пиратта кечкенәдән ике җан яшәде: аның берсе—урман-кырларын сагынып өзгәләнүче бүре җаны булса, икенчесе—кешеләрне тансыклаган эт-җан иде. Эттән туган бүре баласы иде Пират...

Эт әнкәсе аны юеш карлы апрель аенда урманда дөньяга китерде. Энеләре-сенелләре белән дүртәү иде алар. Ни сәбәпледер туганнарының икесе җиде көн дигәндә үлеп беттеләр. Алар бер кыз туганы белән генә калды. Дөньяга килгәннәренә егерме көн булды дигәндә, май башлары иде ул, өлкәннәр аларны ояларында ялгыз калдырып, азык эзләп чыгып киттеләр. Ояны аучылар килеп тапты. Урманда бүреләр ишәйгән чак, хәтта кешеләргә дә һөҗүм итә башлаганнар иде. Аларны мылтыклы адәмнәр эт балалары дип алдап, кешеләргә саттылар. Кыз туганы белән икесе бер хуҗада яши башладылар. Ләкин кыз туганы сагынуга түзә алмады, бер атна эчендә дөньялыктан китеп барды. Ул ялгызы калды, әти-әнисез һәм туганнарсыз. Тууына егерме көннән артты дигәндә, хуҗа аны бер танышына зур акчага сатып җибәрде. Шулай итеп, ул Барыйларга килеп эләкте.

Кешеләр арасында, эт тәрбиясендә яши башлагач, аның тамырларында атасы каны суына төшеп, әнкәсеннән килгән эт каны хакимлек итәргә керешә. Әмма барыбер холкы атасыныкы, ул башка этләр кебек һич кенә дә кирәксә-кирәкмәсә дә койрыгын болгап, кеше кубызында биергә теләмәде. Хәтта койрыгын да эт кебек өскә күтәреп йөрми, куе йонлы койрык күп вакыт асылынып тора иде.

Яна хуҗасы Барыйга тиз ияләште Пират. Аны үз итте, яратты. Әмма чак кына үсә төшкәч, аларның аралары суынды. Хуҗа малай аннан цирк эте ясамакчы була, үзенчә әллә нинди һөнәрләргә өйрәтергә тели. Аны күршеләренең Сигнал кушаматлы чәңгелдек этеннән үрнәк алырга өнди. Имеш, ул хуҗа ташлаган таякны алып килеп бирергә, бөҗра аша сикереп чыгарга тиеш. Әлбәттә, ул бу эшләрнең барысын да күз ачып йомган арада башкара ала, тик бүре үҗәтлеге аңа буйсынырга ирек бирми, дөньяга килүенә өч ай тулды дигәндә ул инде җитди эт-бүрегә әйләнгән, бала-чага уены аны һич кенә дә мавыктырмый иде.

Барый белән аралары бозылды. Сүзен тыңламагач, хуҗа малай аңа типкәли, таяк белән тондыра башлады. Түзде Пират, чөнки тамырында эт каны да ага һәм нәкъ менә шул нәрсә нәкъ эт кебек түземле булырга көч бирә иде бугай. Һәр түземлекнең ахыры була. Көннәрдән бер көнне урманга баргач, Пиратта йокымсырый башлаган бүре җаны уянып, ул үзен янадан тугандай хис итте. Ул хәзер монда, үзенең туган урманында, гел таяк белән кизәнеп торган усал хуҗага буйсынмаячак, ул урманнан яклау таба алачагына өметләнә, бүре җаны аңа кыюлык бирә иде. Барыйдан чираттагы каеш эләккәч, Пират аны-моны уйлап тормады, арырак чабып китеп, урман куелыгына кереп югалды.

Урман буйлап ике-өч көн ачтан тилмереп йөрде ул. Кешеләр янында яшәгәнлектән, анда эт геннары өстенлек итә, ул урманда тереклек итәргә әзер түгел, зур куе урман, андагы агач ботакларының җил искән саен шартлап сынуы, төнге кошларның ямьсез тавышлары аны яман куркыта иде. Эт булып бәйдә яшәгәндә, койрыгы чак кына өскә күтәрелә башлаган

иде, куркыныч урманда ул нәкъ атасыныкына охшый башлады—салынып төште.

Бүре туганнары белән очрашып, аралашып китү дә җинел генә булмады. Әмма ул очрашу котылгысыз иде. Ләкин ничек кабул итәрләр бит һәм кабул итәрләрме әле?

Өченче көн дигәндә Пират борынына җил белән килеп бәрелгән ят ис тоеп сагаеп калды, алай гына да түгел, җаны тәмам шинеп-шәлперәеп, өнсез булды һәм куркудан дерелдәгән гәүдәсен куаклар арасына яшерергә ашыкты, җиргә сенеп бетте, кызганыч тавыш белән еламсырап та карады, әмма курку аны ташлап китәргә ашыкмады, ул һаман дер-дер килде, күзләре яшьләнеп, авызыннан берөзлексез селәгәе акты. Борыны янәшәдә генә бүре исен сизгән иде.

Бичара Пиратның болай да мескен башына ишелеп төшкән кайгысы, эт җанындагы коточкыч курку хисе аны өченче көн изеп, сытып тора иде инде. Янәшәдә бүре барлыгын сизү әлеге куркуны бермә-бер көчәйтеп, аны тәмам эштән чыгарды, ул сонгы көчен җыеп, гәүдәсендәге эт җанын саклап калырга тырышты. Ләкин эт җаны мондый курку халәтен күтәрә алмады, Пиратның гәүдәсеннән суырылып чыкты да, куе нарат ботаклары арасыннан үзенә юл табып, күккә ашты. Һәм шул мизгелдә үк Пират үз гәүдәсендә икенче бер төрле Җанның—бүре Җанының уянуын тойды, ана рәхәт булып китте, гәүдәсе калтыраудан туктады, аякланып куак арасыннан аланга чыкты һәм, нәкъ чын бүре кебек, куе ябалдашлы чыршы очына карап улап җибәрде.

Дүрт-биш айлык бүре баласы белән алар нәкъ шул аланда күзгә-күз очраштылар. Гәүдәсенә яна гына ингән «бүре Җаны» куркусыз булса да, мондый шартларга ияләнмәгәч, кыюсызрак иде әле. Шулай да яшь бүрене горур кыяфәт белән каршы алды. Алар беркавым алан уртасында, бер-берсенә сынап карап, тынсыз тордылар. Пиратның койрыгы ялгыш бер мизгелгә генә өскә күтәрелеп алды. Яшь бүрегә шул җитә калды, ул аны эт дип кабул итеп, бүре-этнен өстенә ташланды. Пират яртылаш кына бүре кавеменнән булса да, эт акыллары булу ана әлеге сугышта зур өстенлек бирде, ул яшь бүрене аландагы чәчәкләр өстендә ауната-аунатa кыйнады, аннан сон истәлек өчен дигәндәй, кырт итеп, сул колак очын тешләп алды.

Аларны, канга баткан ике сугыш чукмарын, ана бүре килеп аралады. Бу бүре үзе дә бүре генә булмыйча, яртылаш кыргый эт кавеменнән һәм ул Пиратны дөньяга тудырган Ана да иде.

Танышу һәм бүре өеренә кушылып китү әнә шулай булды.

Ул вакытта урман әле кешеләр тарафыннан таланмаган, зур куе урманда азык табу да кыен эш түгел, шуна күрә бүреләр интегеп яшәмәделәр һәм янәшәдәге авылларга да зур бәла-каза китермәделәр.

Пиратның «Эт-Җаны» күккә ашып өлгермәгән, мөгаен, ул озын агач ботагына гына эленеп калган булгандыр, чөнки беркавымнан әлеге Җан анын үзенә кире әйләнеп кайтып, бүре Җаны белән янәшә ояланды.

Шуна күрә Пират вакыт-вакыт монсулана һәм кешеләрне дә сагынгалап куя. Бер көнне әнкәсеннән аерылып калган колыннан күргәч, ул нишләргә белмәде, шул чакта ничек сөенүләрен күрсәгез иде икән! Ул колын белән уйнап чак кына булса да сагыну-сагышларын басарга теләде, тай янына якынрак килде, аякларын кытыкларга теләде. Әлбәттә, колын моны уен гына дип кабул итә алмады, куркуыннан ачыргаланып, кешнәде дә, арт аяклары турысында кайнашкан бүрегә тибеп җибәрде, аны-моны абайламаган, мондый һөҗүмне көтмәгән эттән туган бүре чалкан әйләнеп төште. Алар ауга китек колак белән икесе чыкканнар иде. Агачлар артына яшеренеп сыйланырга уйлап торган китек колак әлеге хәлне күреп, колынның бугазына барып ябышты. Аларның кешеләргә беренче мәртәбә зыян салуы иде бу.

Еллар үтә торды. Пират тәмам чын бүрегә әйләнеп калса да, җанындагы этлек һаман аны ташлап китмәгән һәм ул ара-тирә барыбер кешеләрне юксына, ләкин хәзер алардан курка, бигрәк тә тәгәрмәчле һәм яман тавыш белән бар урманның котын алып тырыллаучы үзйөрешле тимер өйләреннән

коты алына. Өстәвенә, агачлар да сирәгәйде, элеккеге куе урман эченә кояш иңләшә башлады.

Көннәрдән бер көнне ул, шул рәвешле кешеләрдән бераз шүрләп тә, аларны чак кына сагынып та урман буенча килә сарып йөргәндә урман каравылчысы йортына барып чыкты һәм... өйдән шактый читтә уйнап йөргән нәни кешегә юлыкты. Куанычыннан Пират эт булып өреп куйды һәм курка-курка әлеге бала янына якынлашты. Нәни кеше аннан курыкмады, киресенчә, кечкенә кулларын сузды, үз янына уйнарга чакырды, кесәсеннән баллы перәннек алып алдына ташлады.

Алар беркавем дөньяларын онытып уйнадылар. Тик берзаман кыр ягыннан чатыр-потыр килгән яман тавыш ишетелә башлады. Бу кешеләрнең урманны кыра торган үзйөрешле өйләре иде. Пират аны күргәч, тизрәк качу ягын карый иде. Әлеге афәттән кеше баласын да йолып калырга уйлап, аны киеменнән әләктерде дә урман ешлыгына кереп югалды.

Тешләре белән нәни кешенең күлмәген әләктереп шактый ара узды Пират. Бу рәвешле бару үзенә дә уңайсыз булганга күрә тиз талчыкты. Нәни кешегә дә рәхәт түгеллеген сизә иде эт-җан. Бер аланлыкка җиткәч, ипләп кенә куе үлән өстенә салды. Борыны белән төрткәләп-төрткәләп аягына бастырды. Шулчак алар туктаган җиләкле аланның икенче ягында зур кеше пәйда булды. Үлән арасында басып торган малайның башы, олпат бүренең гәүдә өлеше кешегә аерымачык булып күренде.

Пират нәни кешесен җәһәт кенә әләктерде дә бәладан башаяк дигәндәй, агачлар арасына кереп югалды.

## Барый Әкбәр кара мәчедән курка

Колхозны үземнең әтидән алып калдым: өлкән Әкбәров пенсиягә китте, мине, аның малае Барыйны, авыл хуҗалыгы институтының соңгы курсын тәмамлап, кулга диплом алуга үзебезнең Байтимердә «Ленин юлы» колхозының рәисе итеп сайладылар... Куйдылар, билгеләделәр дисәк тагын да дөресрәк булыр.

Мин, яшь рәис Барый Әкбәров, эшне колхозның исемен үзгәртүдән башладым, чөнки хәзер берәү дә «Ленин бабай юлыннан» бармый, ул сакау яһүднең сызган юлыннан без күптән тайпылышып беттек.

Эш анда гына да түгел. Инде канга «перестройка» аңы сеңеп, ул шунда эрегән, үзгәртеп корунын үзе кебек кан белән буталып бер булган һәм үземне замана житәкчесе итеп хис итәргә гадәтләнгән идем инде. Колхозга «Кукуруз» дигән исем кушып, аның хуҗалык итү формасын да үзгәрттем. Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять булды ул. Авыл хуҗалыгы өлкәсендә Республика буенча берләнбер экспериментал хуҗалык! Үзебезчә, ягъни урысча итеп әйткәндә ООО була (Общество ограниченной ответсвенности) инде бу...

Әлбәттә, әти белән аның зур урындагы танышлары булмаса, теләсә нәрсә кыланырга миңа берәү дә рөхсәт бирмәс иде. Әтинең якын дусты Хәниф Хатыйпович, колхозга «Кукуруз» дип исем кушам дигәч, имтихан алган кебек маңгай астыннан миңа сөзеп карап:

—Нәрсә ул кукуруз? Хәзер үк шуңа аңлатма бирә алсаң, молодец буласың!—диде. Сизеп, тоеп торам: нәкъ шушы минутларда минем колхозның исеме хәл ителәчәк. Хәниф Хатыйпович әти белән бераз кызып алырга да өлгергәннәр иде инде.

Безнең Байтимер Казан артында гына бит, турыдан машина белән утыз биш минутлык юл. Урман эчендәге Умырзая күле буенда әтинең, төгәлрәге, колхозның инде умарта бакчасы һәм ике төрле мунчасы бар. Берсе ак мунча, икенчесе юкә бурасыннан махсус эшләнгән кара мунча. Эшеннән туеп бик арыган чакларында Хәниф Хатыпович Казаннан безгә ял итәргә килә иде. Хәтерлим, мин үсмер чакта ул еш кына хатынын,— исеме дә тел очымда гына тора инде... Әйе шул, Сиринә атлы кара тутлы ханымны, ияртеп килә иде. Соңгы елларда шоферы белән икесе генә

йөриләр. Кайчакта дусларын да ияртә. Ялгыз башы килгән чакта әтинен удмурт авылындагы бригадиры Николай Михайлыч мунчаны һәрвакыт зәңгәр күзле, чибәр ар кызы Наташага яктыра иде.

Хәниф Хатыйпович бу юлы да үзе генә килгән. Наташа кара мунчага су ташый. Хәниф Хатыйпович белән әти күләгә астындагы беседкада корт балыннан коелган салкын эчемлектән авыз итеп утыралар.

—Кукурузмы?—дидем сорауны кабатлап.—Берөйлеләр семьялыгыннан, орлыклары чәкән формасында булган юан, озын сабаклы, кыяк яфраклы берьеллык үлән үсемлек!—дип, чатылдатып җавап та бирдем. Хатыйповичның күзләре мангаена менеп, кулындагы чәркәсенә чаклы чайкалып куйды һәм сары сыеклык аның ак, төссез йонлы ботына түгелеп, озын балаклы трусигы эченә агып кереп китте. Әллә шул галәмәттән, әллә инде кыю һәм төгәл җавапка шаккатып, ул эскәмиядән үк сикереп торды:

—Ну, молодец, ну, майттавай! Акберыч! Күрденме, яшьләр нинди грамотный хәзер, ә! Да, болар кулына колхозны гына түгел, районны да ышанып тапшырырга була! Районны гына түгел, хәтта, хәтта... Хәниф Хатыпович «Республика»ны да дип тә өстәмәкче иде, ләкин вакытында туктальп кала белеп, «кһым» дип, тамагын гына кырып куйды.

Әйе, Республика аларның үзләренә кирәк иде шул әлегесен...

Шулай итеп, умарталыкта колхозның исеме хәл кылынды, «Ленин юлы»ннан ул «Кукуруз» булып үзгәртелде. «Кукуруз» якын арада бу төбәктә булачак зур үзгәрешләргә ишарә, хәтта шуның символы да кебек иде. Тарих кабатлана бит ул...

Капылт кына исем үзгәртергә рөхсәт биргәч, колхозның һәм ана кергән биш авылның астын өскә китерәм дисәм дә, түрәләрнен ризалыгын аласына ышандым хәзер. Һәм бу ышанычым һәр гамәлемдә көч бирел, рухландырып торырга тиеш иде. Шулай булмаса, бу заманда башынны ташка орсаң орырсың, әмма җүнле эш кырырмын димә. Авыл хуҗалыгы турында атлаган саен чыгып торган мәгънәсез законнар, күрсәтмәләр, эт эчәгесе кебек аякка уралудан бүтән бер нәрсәгә ярамыйлар. Шундый замана килде ки, әгәр баш шөрепләренне кыймылдатырга иренмәсән, теләгән нәрсәгә ирешергә мөмкин.

Кайчан тәртип булыр икән соң бездә?! Һәм аннары нәрсә соң әле ул «тәртип»? Ул ничек була икән соң?..

Бөтен максатым—хуҗалыкны компьютерлаштыру. Һәр сыерның аягына датчик куячакмын. Савым сыерын компьютер ныклы күзәтү астында тотачак. Әгәр ул елына ун тоннадан да кимрәк сөт бирә икән, аны колбасага җибәрүен файдалырак булачак. Колхоз тракторлары солярка коргаксып яткан заманда компьютер дип авыз ачу сәеррәк яңгырый инде, әлбәттә. Яңгырасын. Акча табарга кырыкмаса кырык төрле җаем бар. Мин бу рәвешле берниндн җинаять тә кылмыйм. Бары урыннан кузгалып китәргә этәргеч өчен генә ул. Аннан соң минем «Кукуруз» аны уңы белән кайтарачак бит.

Мин тик тора торган кеше түгел. Әүвәл гектарыннан шунын чаклы уңыш алдым, һәр сыердан шул чаклы сөт дип лаф органчы, хуҗалыкны төптән ныгытырга уйладым. Бу ныгыту эше, әлбәттә, үзгәртеп корулардан башланырга тиеш иде. Әти карт үпкәләмәс, чөнки ни булса да майтарган саен: «Әти, синең кинәшсез булмый. Шулай итсәм, ничек уйлыйсың?» дигән булып, аның салпы ягына гел салам кыстырып торам. Беренчедән, әтине әти буларак үпкәләтергә ярамаса, тагын икенче ягы да бар әле аның: Казандагы түрәләр әтинең җан дуслары. Түрә дигәч тә аларның да кара мунчада яки ак мунчада чабынасылары килмимени! Анысыннан да бигрәк, урман эчендә бит, галәмәт аулак җирдә. Ә корт балыннан койган медовуханы исә мари карты, умартачы Бачли (чын исеме—Василий бугай) Хан заманындагы рецепт белән әзерли. Аннан соң мунча ягучы зәп-зәңгәр күзле ар һәм чирмеш кызларын кар өстеннән төртеп чыккан гүзәл умырзаялардан аера алмассың!

Хәер, Казан түрәләре һәрвакыт «умырзая җыярга» гына килә дисәм, сүзләрем хата булыр. Минем сымак малайларын ияртеп, аүга да еш йөри алар безнең якларга. Аннан соң әти Тәбәнәк тау дип аталган уйсулыкта—ул

галәмәт зур урман аланлыгында, анда мүк арасыннан бихисап чишмәләр тибеп ята—балык күле ясатып, карплар да җибәрттерде. Димәк, кунаклар балыкка дип тә киләләр булып чыга. Әнә шуларның үзем кебек шыртлака малайлары белән куян, төлке артыннан куып арыган чакларда, дөньябызны онытып балык та тотабыз. Кыскасы, Казан кунаклары килгән көннәр минем өчен зур бәйрәм була иде. Әти—акыллы кеше—алдан күрә белгән икән: ул малайлар белән аралашу киләчәктә минем өчен зур мөмкинлекләр ачачак һәм урыннарында аталарын алыштырган балачак дусларымның ике кат ишекле кабинетларына шакымыйча да керә алачак идем. Вакыт аяусыз, күз ачып йомган арада буыннарны алыштыра да куя. Кичә—атасы, бүген—баласы.

Әти «Ленин юлы» хуҗалыгының урмандагы «фазенда»сына гел мине ияртеп бара иде. Һади абый яшькә зуррак, акыллырак булса да ул аны андый бәйрәмнәргә катнаштырмады. Хәер, баштарак абыйны да ияртеп йөртүен. Әле мин бөтенләй бәләкәй чакта ук. Һәм ул бар эшне дә бозып ташлаган. Сөйләүләренә караганда, бер яшьрәк түрә атна саен килә башлаган. Һәр килүендә үзе белән яна кыз-хатын ияртә икән. Һади абый бигрәк беркатлы инде ул безнен, әлеге түрәнең чираттагы килүендә сорап куймасынмы: «Абый, син мулла булып эшлисеңме әллә! Әллә бүген өченче хатының белән киләсең инде?» Санап барган икән бахыр... Шуннан соң ни булганын күз алдына китерәсезме инде? Мин китерәм, мәсәлән...

Андый чакларда Мөхәммәт дустымны да ияртми идем. Әти кушмый.

Читкәрәк киттем бугай, хәерлегә булсын. Сүзем ничек итеп әтидән колхоз дилбегәсен алып калу турында иде бит әле. Әйе, мин эшне колхозның исемен үзгәртүдән һәм... хосусыйлаштырудан башлап җибәрдем. Бу адымга үзенең «приватизация» сәясәте белән Мәскәү түрәләре дә этәргеч бирде. Өстәгеләр ни эшли—астагылар шулай кылана. Хәтта берничә мәртәбә арттырып ук җибәрә. Әти әйтмешли, тегеләр таякны бөгеп кенә күрсәтә, болары, ягъни «безнең белән бер чыбыкка кунып сайрый торган» җитәкчеләр, ул таякны шартлатып сындырып та куя...

Әлбәттә, урман эчендәге күлдә бергәләшеп балык тоткан малайлар булмаса—алар хәзер зур җитәкчеләр—колхоз чаклы колхоздан шәхси милек ясап булмый иде. Без бергәләшеп авыл хуҗалыгына яналык кертергә уйладык. Сабакташым Мөхәммәт бер акыллыбашның сүзләрен кабатларга ярата: «Рәсәйдә йә революция, йә ачлык!...» Без дә эш күрсәтергә, ягъни «революция» ясарга ният кордык. Шулай итеп мина әтидән калган колхоз «Кукуруз» исемендәге җаваплылыгы чикләнгән оешма булачак!.. Әлегесен моны халыкка әйтмим. Белеп торам, күпчелек аяк терәп каршы киләчәк. Халык бездә үзенчәлекле һәм кире. Байтимердә татарлар яши. Чудрасала авылында марилар, Нырыяда удмуртлар, Грибники исә урыс авылы. Дөрес, урыс авылының авыл диярлеге калмаган инде. Алтмыш алты хуҗалыкның яртысыннан күбрәгенең капкасына йозак эленгән. Алар җинел тормыш эзләп Казанга китеп беттеләр. Ташсу буенда ук тагын бер авыл бар, кыш көне анда каравылчы белән эте генә яши. Җәй житүгә Казаннан унбиш яһүд гаиләсе кайтып тора. Үзләренең әйтүләренә караганда, алар бу җирләрдә моннан ике мең ел элек яши башлаганнар, имеш. Мин үзем тарихчы булмасам да беләм: Казан артындагы бу авыллар—татар авыллары нугай белән кыпчак кушылмасы. Нугайлык төс-кыяфәтләрендә сакланса, кыпчакмишәрлек сөйләмнәрендә ярылып ята. «Ч»ны «ц» хәрефенә охшатып һәм, гомумән, болай каты итеп безнең якта гына әйтәләр... Иван Грозный татарларны Казаннан кырык-илле чакрым еракка сөргән. Ә яһүдләр монда ике мең ел элек нигез салган, имеш. Ай-һай... Дарвин, кеше маймылдан килеп чыккан дип, бик нык хаталанган булгандыр, бахыр. Без барыбыз да яһүдләрдән килеп чыкканбыз ахрысы, маймыллардан түгел...

Шулай җинел кулдан гына башланып китәр төсле иде бул эшләр. Ләкин көн саен мәшәкать, вак-төяк ыгы-зыгысы туа да тора. Гаҗәеп үзенчәлекле, сәер халык яши бу якта дидем бит инде: татарлары ат урынына эшли һәм эт кебек урлаша, удмуртлар көмешкә мичкәсендә коена, урыслары шәһәргә шылды, монда калганы эшкә яраксыз исерек-усырык, мари халкы урманда гөмбә җыюдан һәм балыктан кайтып керми, яһүдләре исә «курортка»

гына кила. Менә шулар белән алып барып кара син колхозны! Әтинен башында кырык биш яшендә ни сәбәпле бер тотам кара чәче дә калмаганлыгын анлыйм мин хәзер. Ләкин мин эшне башкачарак оештырып жибәрдем. Удмурт кызлары егет-жилән күрмичә зар елый, кияүгә чыга алмыйча интегәләр һәм һәркайсы да, бары тик шул сәбәпле генә, шәһәр ягына каермакчы була. Чөнки үз авылы егетләре көн-төн кәмешкә чөмерә. Уйладым уйладым да Байтимер белән Нырыя арасында зур итеп клуб салдырып куйдым. Авыл аралары нибары бер чакрым гына. Хәзер ул уртак клубта татар егетләре гармун тарта, ар кызлары типтереп бии. Берәүгә дә күнелсез түгел. Кызлар шуннан гына туп-туры иртәнге савымга, егетләр басуга китә. Өстәвенә, удмурт авылына бригадир итеп татар кешесен куйдым. Өйләнмәгән яшь егет иде. Фердинанд атлы малаем шундук Пирдинат Пәритовичка өйләнде дә куйды. Житмәсә, матур гына бер ар кызына өйләнеп тә жибәрде.

Байтимердә бригадир итеп урыс кешесе Иван Михайловичны билгеләдем. Элеккеге трактористны, монарчы мунчага кергәндә дә күн итеген салырга иренгән Михалычны күрсәгез сез хәзер! Министрмыни! Сөйләшүе генә түгел, нечкә тавышына хәтле калынайды. Нәчәлник булу килешә икән үзенә! Мариларда бригадир булып ар хатыны эшли. Монарчы унбер бала табып кояш йөзен дә күрмичә өендә чаршау артында гына яткан кырык яшьлек Настя яше буенча егермегә төште дә китте. Ире өендә балалар карап утыра.

Бу «кадровой перестройка»ларнын унай нәтиҗәсе дә күп, тискәре яклары да булгалый. Ни чыкса һаман да шул татардан чыга инде. Узган атнада гына удмурт авылы бригадиры Фердинандны чак кына рәшәткә артына утырудан йолып калдым. Егетнен кылган эшләре үзе бер вакыйга. Удмуртлар арасында матур гына эшләп киткән иде егетем. Ар кызына өйләнеп жибәргәч, аны тагы да үз иттеләр. Тик егетнен бер «кимчелекле» ягы бар—аракы эчми. Әлбәттә, егетнен бу «һөнәр»не белмәве халыкка ошап бетми инде. Үзләре кебек булмагач, берзаманны аны өнәми дә, сүзен дә тынламый башлыйлар. Нишлисен инде, йә дөньяны үзгәртәсен, йә булмаса үзен үзгәрәсен. Өченче юлы юк. Егетебез үзе үзгәрергә була һәм капкалый башлый. Эшләр дә көйләнә төшә кебек, авторитет та үсә. Ләкин егет каршында көтелмәгән тагын бер каршылык калкып чыга: киявенен эчүенә кайнанасы каршы. Ник дисән, кияү балакай бүтәннәр кебек кәмешкә эчми, кибет аракысын гына эчә икән. Ә бу нәрсә күп чыгымнар белән бәйләнгән, чөнки көн саен бит ул. Берәр шешәдән исәпләп карасан да...

—Аптарититы булмаса булмас, Пирдинатны эчүдән биздерик, кызым,—ди кайнана беркөнне кызына.

—Ничек итеп?

—Аракчинода бер карчык бар. Шул бер зәхмәтле сыеклык әзерли икән. Бу сыеклыкны эчә торган аракыга жиде тамчы итеп тамызсан, кеше бөтенләй бизә,—ди.

Әлеге сөйләшүне кияүнен бабасы да ишетеп торган һәм серне нәчәлник кияүгә чишкән. Менә беркөнне Нина түтәй Аракчинога дип чыгып китә. Кич кияү эштән кайтуга мул итеп табын әзерлиләр, өстәл өстенә кибет аракысы утырталар. Нина түтәй кияүне ишектән тәмле телләре белән үзе каршы ала. «Әйдә, кияү, кулларынны ю да, өстәл янына рәхим ит. Эшеннән бик арып кайткансыңдыр»,—дип, бертуктаусыз сөйләнә үзе. Кияү балакай да Шомбай кебек хәйләкәр, ыштан бавына бер урыс малаен кыстырып кайткан була һәм, тегеләр күрмәгәндә генә, өстәл өстендәгесе белән алыштыра да куя. Менә хатыны белән әбисе кияүне кыстарга керешәләр. Эһ тә итмичә бер стаканны каплап куя кияү балакай, икенчесен... Һәм берзаманны тиктомалдан, кайнанасына карап, эт булып өрә башлый! Нина түтәйнен коты алына, зәхмәт салынган аракы кияүне кешелегеннән яздырды, кеше хәтле кешедән эт ясады, дип, коты ботына төшә карчыкнын. Кияү, һау-һаулап өрә-өрә, кайнанасына ташлана. Тегесе аннан кача, тоттырмаска тырыша. Аптыраган карчык куркуыннан караватастына качып котылмакчы

була. Кызып киткән кияү-эт тә шунда томырыла һәм, караватт астына башын тыгып, әбинең йомшак жиреннән тешләп тә ала. Әби-карчык коты алынудан шундук җан тәслим кыла, куркуыннан йөрәге ярылган була бичараның...

Шулар белән эшләп кара син менә. Үз башың себер китәр...

Ләкин вакыт узган саен мин каешлана барам. Иртән иртүк ферма мөдире исерек булса, аны тагаракка салып, кабыргалары сынганчы тукмыйм, басуда угры-бур тотсам, алып кайтып барган салам-печәненә тәмәке төпчеге ыргытам—ул шундук көлгә әйләнә. Урманда гөмбә җыйган мари, ар кызларын күрсәм, ул көнне һичшиксез бирәр кырмыска оясы тузгый инде.

Халык мине ярата. Колхоз паркын яңа техника белән тутырдым. Ай саен хезмәт хакын түлим. Икмәген, салам-печәнен, хәтта корылык елны да җитәрлек итеп бирдем. Бригадалар арасында асфальт юллар салдырдым, җимерек күперләрне яңарттым. Яңа клубны әйттем бугай инде.

Әллә халык курка гына микән?.. Хәер, анысы да юк түгелдер. Рәсәй халкы белән җитәкчелек итү рәхәт ул. Безнең халык сарык көтүе кебек, әүвәл, чыбыркы шартлатып, аның котын аласың, башыннан сыйпап, ипи каптырасың. Кызганам мин бу халыкны. Шул исәптән үземне дә... Һай канын чистартасы иде безнең милләтнең! Элек шәп, затлы кан булган бит ул! Хәзер бозылган, сыеклана башлаган...

Ә мин үзем бары тик кара мәчедән генә куркам. Ике мәртәбә урман юлында кара мәче юлымны кисте. Беренчесендә, малаемның югалганын белдем. Икенче юлы кеше башлы бүре очраттым... Язмышмы бу? Ул язмыш дигәннәренең, борынымнан сөйрәп үз артыннан йөрүеме, әллә, үзем гел аның артына тибеп торамы соң?

Хәер, киләчәк күрсәтер... Кем әйтмешли, рожденные ползать летать не умеют. Әнигә рәхмәт: ул мине, нәкъ шундый малайны тапкан. Әтигә рәхмәт: миңа түш белән шуышырга туры килмәде. Әлегесен... Хәер, бар нәрсә дә үземнән тора. Мин әнә шул хакыйкатьне аңлап, аны үземнең акылыма сеңдерә алдым. Кара мәчедән куркуым исә ул без яшәгән җәмгыятьнең тотрыксыз булуыннан гына килә. Иртәгә нәрсә буласын бу мәлдә беркем дә белми. Иртәгесе өчен ишәк кайгырсын диләр диюен дә... Ләкин минем ишәк буласым килми!..

## Язмыш яры текә була

Гөлчәчәк хакында Барыйдан бик сорыйсы килсә дә Мөхәммәтнең теле әйләнмәде. Хәер, бу турыда авыз ачарга башка вакытта да җөрьәт итә алмас иде. Иң яхшысы Гөлчәчәкнең үзе белән сөйләшү. Мөхәммәт Гөлчәчәк янына кайтырга җыенды.

Ләкин планнар бу юлы да җимерелеп төште. Күрәсең, Гөлчәчәк белән күрешү тиз арада гына насыйп булмагандыр инде. Ул, Барыйны озатып, хастаханәдән кайтып кергәндә ишегенә язу кыстырылган иде. «Кайтуга, миңа килеп җит! Сиринә»,—диелгән. Мөхәммәт Мөштәри урамында узгынчы машинаны туктатты да, Сиринә Самуиловна өенә юнәлде.

Ул килеп керүгә Сиринә Самуиловна егеткә кыланып, кул биреп күрешә дә яшь кызлар кебек җинеләеп, битеннән үбеп алды һәм кулын һаман әле җибәрмичә залга әйдәде. Диванда йокымсырап яткан песи тавышка уянып иренеп кенә күзләрен ачты да каршында Мөхәммәт икәнлеген белгәч, үпкәләгән кыяфәт чыгарып, кухня ягына кереп китте. «Харап икән! Песи дә үпкәли белә!» дип уйлый-уйлый, Мөхәммәт диванга песи урынына килеп утырды.

Сиринә Самуиловнага ни булган соң, нигә кош тоткандай йөри әле ул? Мөхәммәт, җавап эзләп, аның йөзенә текәлде: «Йә, сөйлә инде!»—ди иде аның сораулы карашы.

Сиринә Самуиловна бүген, чыннан да, яшь кызлар кыяфәтенә кергән иде, өстендә итәге тездән югары юка халат, чәч-башы да яшьләрчә фасон белән лакка катырылган, битендәге иннек-кершән дә аеруча мул, күзгә бәрелеп тора, болай да озын кара керфекләре буяудан тагын да каралып

киткән. Чибәр, тагын да матур иде бүген Сиринә Самуиловна.

—Италиягә жыен. Синен загранпаспортыннын срогы чыкмаган бит әле?

—Чыкмаган,—диде Мөхәммәт, хатынның әлеге хәбәренә аптырап.

—Чыкмаса, әйбәт. Анда международный выставка була. Татарстаннан син генә. Россиядән барысы ике кеше. Икенчесе Мәскәү художнигы. Хәтерлисеңме узган ел Петербургта танышкан идек. Эрнст Козловский. Пейзажист.

—Хәтерлим,—диде һаман ис-хушын жыеп өлгермәгән Мөхәммәт.

—О-ооо! Син күрсән иде ул! Теге ата кара таракан үз малаен исемлеккә кертү өчен ничек чабулады! Мәскәүләргә хәтле барып житкән! Хәниф Хатыйповичка шалтыратып әйткән идем, шул сәгатьтә үк үзенә чакыртып эт иткән. Ярый, бог с ним! Искусствовед буларак, списокта мин дә бар, беләсең килсә!

Сиринә Самуиловна куанычыннан Мөхәммәтне муеннан ук кочаклап алды. Хатыннан гажәп тәмле хушбуй исе килә. Бите егетнең битенә орынып китте. Утын агачы кебек утыру унайсыз, жавап йөзеннән Сиринә Самуиловнаның иңбашына кул салу исә тагын да унайсызрак. Утын агачы булмый хәлең дә юк, нишләрсең!.. Өстенлек Сиринә Самуиловна ягында иде. Ул чарасыз утырган егетнең салкын мангайлы башын күкрәгенә кысты, ни арада төймәләре ычкындырылып өлгергән, Мөхәммәт борыны белән кайнар имиләр арасына төртелгәнен сизми дә калды. Салкын маңгае кызыша башлады: монарчы үз жаена, салмак кына типкән йөрәге урыннан кузгалды диярсең, бөтен күкрәк читлеген селкетә, чыгар урыны булса, кош булып ачык форточкадан атылыр иде дә һәм... һәм, әнә, теге каенга, тәрәзә каршындагы яшь каен ботагына кунып, өздереп-өздереп, сайрап жибәрер иде...

* * *

Яшь рәссамнарның чит илдә узарга тиешле күргәзмәсе Мөхәммәт Уразовның тормышында бик зур борылыш ясарга тиеш, моны һәммә кеше дә аңлый һәм юкка гына: «Нигә Уразов? Нигә мин түгел?!!»— дигән кара тавыш чыкмаган иде. Шуңа күрә, иртәгә китәсе дигән көнне дә әллә нинди көтелмәгән үзгәрешләр булырга мөмкинлеген Мөхәммәт үзе дә, Сиринә Самуиловна да чамалый, икесе дә ул көннең тизрәк килеп житүен түземсезлек белән көтәләр иде.

Китәсе көн тәгаен генә билгеле булмаса да, күргәзмә гонорары долларда исәпләнгәнен белмәгән кеше юк иде. Калжа бик майлы һәм дәрәжәсе дә бик зур. Шуңа күрә күпләрнең йокысы качты. Берничә рәссам һәм сәнгать белгече, үз араларыннан делегация төзеп, Мәскәүгә чыгып чаптылар, чөнки Казанда Хәниф Хатыйповичны узып берни кылып булмый, аның сүзе исә катгый, ул үз фикерен әйткән иде инде.

Үзешчән делегация Мәскәүдә әллә ни эш кыра алмаса да, барыбер «сиңа да, миңа да булмасын» дигән максатларына иреште: Татарстан исеменнән Италиягә барырга тиешле яшь рәссамны Мәскәүнең үзеннән табып кайттылар. Мөхәммәтнең яшьтәше, атасы ягыннан чыгышы буенча Бөгелмә егете Яков Крысин атлы егет алар тарафыннан Республика һәм Рәсәй даның якларга лаеклы дип табылды. Атасы тумышы белән Бөгелмәдән булгач, ул Татарстан исеменнән барырга тиеш иде. Халыкара күргәзмәдә катнашу өчен Мөхәммәт Уразовны артык провинциаль һәм әлегә чак кына житлегеп бетмәгән диделәр. Ни хәл итәрсең, демократик жәмгыять төзеп маташабыз, чиновник сүзенә карап, аңа ләббәйкә дип утыра торган заманалар күптән узды. Шуңа күрә рәссамнарны әйдәп баручы рухи лидер агай, минем малай катнашмагач, Уразовка да тәтемәсен дигән катгый һәм ныклы, алай гына да түгел, үз фикеренчә, гадел принциптан чыгып эш итәргә карар кылды. Демократия булгач, демократия булсын, әлеге мәсьәләне ижат көчләренең гомуми жыелышы хәл кылырга тиеш һәм бары тик яшерен тавыш белән генә.

Иртәгә жыелыш буласы көнне, рухи лидерны Хәниф Хатыйпович үзенә чакыртып алды һәм кабинетта сүз кыска, әмма житди булды:

—Синең малай Госсоветка кайсы районнан кандидат әле?—дип сорады Хәниф Хатыйпович.

Тегесе район исемен атады.

—Ул районга тагын ике кандидат билгеләргә булдык әле.

Һәм Хәниф Хатыйпович әлеге кандидатларның исемнәрен атады, аларның берсе бик атаклы язучы, икенчесе бай эшмәкәр, зур заводның директоры иде.

—Ничек?! Алар белән көрәшеп булырлык түгел бит! Сез моны юри оештыргансыз!

—Ә иртәгә булачак җыелышны сез юри оештырмадыгызмы?

—Аңламадым, Хәниф Хатыйпович!

—Бик яхшы аңладың. Отмени җыелышыңны!

—Ничек? Белдерү элenгән, халык белә бит инде.

—Көн тәртибен үзгәрт! Сезнең оешмага санаторийга бушлай ике путевка бар, җыелышта шуларны кемнәргә бирәсен хәл итегез. Аңлашылгандыр бит?

—Аңлашылды, Хәниф Хатыйпович, аңлашылды.

Шифаханәгә барырга тиешле кешеләрне икенче көнне иҗат көчләренең гомуми җыелышы көне буе хәл итте, чөнки лаеклы һәм сырхау кешеләр байтак, һәммәсенең барасы килә иде. Халык тәмам алҗып, инде «путевка» сүзен ишетәсе килми башлагач кына, соңгы чиктә җинел юлы табылды: җирәбә салдылар. Һәм шуннан соң тавыш та тынды. Баштан ук шулай эшлиселәре калган икән!

Җыелыштан халык төркеме белән чыгып барганда, кемдер Мөхәммәтнең касыгына төртте. Кеше күп һәм барысы да янәшә булганлыктан, ул төртүченең кем икәнлеген абайламый калды. Шунысы хак, ул иптәшнең терсәге хәйран очлы булып чыкты—авырту озакка сузылды.

«Астан һәм астыртын гына пычагым да кыра алмагач, болай төртү белән генә канәгатьләнәләр икән—бик хуш, күнелләре булып, тынычланып кына кала күрсеннәр!»—дип уйлады Мөхәммәт. Ләкин астыртын сугыш-Терсәк сугышы моның белән генә тәмамланмаган, алда аның дәвамы булачак иде әле...

* * *

Чит илгә кайчан китәсе һаман ачыкланып бетмәде, дөресрәге, хәбәрләре һаман килеп җитми иде әле. Мөхәммәт, Сиринә Самуиловнага авылга кайтып киләм, телефон аша хәбәрдә торырмын диде дә, үзе Ютазыга юл тотты.

Рәзифә авызыннан коелып калган гайбәт күңелен бертуктаусыз тырнап тора. Мөхәммәт шуннан бирле сәер халәттә яши, уйлый-уйлый да берара һәммәсенә кулын селтәгәндәй: «Гөлчәчәк үз иркендә бит! Ничек тели, шулай яшәсен сәнә!»—ди. Ләкин ярата ич ул аны? Ярата-а-а-ааа! Кызык кына инде! Әгәр яратса, «Урман»ны сатарга риза булыр идеме соң? Чыннан да, бу сату гына да түгел, бу—сатылу! Хәлдән котылу юлын тапкан иде бит инде: тиз генә тотып, шул бәхетсез картинаның күчерелмәсен ясарга кирәк!.. Үз кулы белән язгач, хәтта күчермә генә дә булмый ич әле ул! Авторы үзе үк ләбаса!

Ләкин Рәзифә житкергән хәбәр?.. Бәлки, ялгандыр ул? Берәр хәйлә, тозак кынадыр? Чөнки «Урман»ны алу өчен нинди көрәш бара: өстән дә, астан да (Барый, Сиринә Самуиловна) тынгылык бирмиләр. Имеш, ахыр чиктә ул картина аркасында Мәскәү түрәсенең хатынын—сәнгать белгечен үпкәләтү бер дә җүнлегә китермәячәк дигән булалар... Ул имеш-мимешләрдән кырыкмаса кырык төрле фараз-мазарлардан Мөхәммәт тәмам гарык иде.

Сиринә Самуиловна: «Миндә генә яшәп тор, үз фатирың остаханә булып калсын»—ди. Хатын аннан тугыз яшькә өлкәнрәк. Ләкин яшь аермасын белмәгән кеше әллә ни чамалап та бетермәс кебек. Сиринә, Америкада житкән кызы булуга карамастан, үзе дә кызлар кебек. Кара тутлы хатыннар тиз картаймый диләр.

Ә яшь аермасы нәрсәгә соң сиңа! Ул акчаларга син бар тормышыңны

көйләп җибәрә аласың: коттедж, машина, диңгез буендагы иҗат йортлары... Авылдагы нигез җиргә чүгә башлаган, аннан соң әтисе кайткан саен Сибгат абыйның тракторы хакында авыз суларын корытып сөйли, үзенә дә шундый тәгәрмәч булдыру хакында хыяллана. Бер апасы кияүдән аерылып кайтты, Казанда тулай торакта яшәп ята...

Гөлчәчәк!.. Гөлчәчәкнең гаебе үзендә бит! Мөхәммәт ничә еллар буе урман кызын шәһәргә алып китәм, рәсемдә генә булса да урман ясыйм дип хыялланып йөргәндә... Кая ул хыялланып кына?! Ул хыялы тормышка ашты: картина язылып бетте ич! Остаханә-фатирда гына булса да тормышны башлап җибәрергә мөмкин ләбаса!

Язмыш яры текә, аннан чамаламыйча гына сикерсәң, муеныңның шартлап сынуын көт тә тор.

Мөхәммәт көне-төне «Урман»ның күчермәсен язды. Көн саен Сиринә Самуиловна фатирында кунып йөрмәскә дә яхшы сәбәп иде бу. Мөхәммәт ана: «Яңа картина язам. Тәгәлләмичә күрсәтмим!»—диде.

Ләкин Сиринә төн уртасында булса да шалтыратып, таңга чаклы гына булса да килим инде дип, желегенә тия. Хәер, җанына тияме икән соң? Ул аны Гөлчәчәктән аерырга уйламый ич! Ирсез хатынның төннәрен ничек уздырырга теләве—аның үз иркендә, яманлап та, кыек сүз әйтеп тә булмый. Хатын-кыз, нинди генә зур әхлаклы, саф-намуслы булса да, табигатькә каршы бара алмый, сау-сәламәт тәнендә—тамырларында уйнаган кайнар канны салкын су сибеп кенә суытып булмый!..

Хәер, хатын-кызның һәммәсенә дә мондый бәя бирергә аның ни хакы бар, башы яшь, үзе дә яшел бит әле...

Ә Гөлчәчәк!..

Ә Гөлчәчәк, гадәттәгечә көннәрдән бер көнне килеп чыгар дип, Башкортстан чигендә аны көтеп яши. Ул урманда егетнең вәгъдәсен җитди кабул итмәгән иде. Ләкин егетнең үҗәтләнеп үз дигәнен итәргә, әйтүенчә, картинасын язып тәмам кылу алдында йөрүе аның мәхәббәт учагына ялкын гына өсти һәм егерме биш яшькә җитеп килүе дә һич куркытмый иде. Мәхәббәт көтә белгәндә генә кадерле-газиз була икән ул! Әлбәттә, хәзер ул Мөхәммәткә: «Урманымны ташлап китмим!»—дигән шарт та куя алмаячак! Урман таланып, мәсхәрәләнеп бетте. Урман каравылчысы булып торган Ярулла абзыйның бар эше, кешедән калган ботак-сатакларны җыеп, яндырып йөрү. Әнә, Мөхәммәт, аның Мөхәммәте, «Синең урманыңны картинада булса гына да саклап калдым, Гөлчәчәк!»—ди. Рәхмәт сиңа, Мөхәммәт! Мин яратам, сине, Мөхәммәт! Бик яратам!

Гөлчәчәкнең күңелендә, быел җәй ахырларында булырмы, кыскасы, август ае җитеп, җиләк-җимешнең мул чагында кавышырбыз дигән өмет тә шытып килә иде.

Мөхәммәт Гөлчәчәк белән күрешүне бу рәвешле күз алдына һич тә китермәгән иде. Ютазыга кайтам дип ым кагуга, аның дус-таныш председателе «Волга»сын җибәргән иде, районның иң алдынгы хуҗалыгы җитәкчесенең зур портретын ясап бүләк иткән иде, икенче юлы Хәким Фаруковичның мөлаем хатыны Рәвия ханымны рәсемгә төшерергә вәгъдә итте.

Хәким Фарукович, таң белән Казанга чыгып киткән машинасының кайчан кире әйләнеп кайтачагын чамалый иде, күрәсең, «Волга» Гөлчәчәк яшәгән йортның капка төбенә килеп җиткәндә, өйлә вакыты якынлашып килгән чак, үзе дә шунда Мөхәммәт кайтканын көтә иде.

Беренче мәртәбә генә түгел, Мөхәммәт белеп тора, Хәким Фарукович, яше белән алтмышка якынлашып килгән карт җитәкче, Мөхәммәт Казанга кайтып киткәнче, кунакны күз уңыннан җибәрмәячәк, көн саен мунча яктырып, шашлык, шашлама һәм башка төрле ризыклар белән сыйлый-сыйлый, яратып кына әйтсәк, «тенкәсенә» тиячәк. Үзе шундый сәнгать җанлы кеше инде ул Хәким Фарукович. Әнә, эш вакыты дип тормаган, хәер, аның колхоздагы эше майлаган кебек көйләнгән, җаена салынган, үзе әйтмешли, акыллы җитәкченең эше үзе булмаганда көйлерәк барырга тиеш, машинасын да Казанга чаклы куган, каршыларга да килеп җиткән.

Гөлчәчәк бу юлы, кеше бар дип тә тормады, мәктәптән кайтып килеше

икән, Мөхәммәтнең муенына килеп асылынды. Башка чакта болай итми, кеше булмаса да, сагынуын йөзендә балкыган кояш нурларыннан гына аңлап була иде. Мөхәммәт аны үзе дә кочаклап алды. Хәким Фарукович көлде.

—Мәктәптә укулар да бетте. Үзеннән калдырма инде син аны. Казанга алып кит. Апасын карарга кеше табарбыз,—диде ул гадәттәгечә аталарча кайгыртып. Мөхәммәткә дә бирәр сүз кушарга кирәк инде кирәген, югыйсә. Ләкин ул каушап калган, бик тырышса да теленә кирәкле сүзләр килми, аптыраганнан, сүз булсын өчен генә:—Ютазы һавасы килешә икән сиңа!—дип, кызга комплимент әйтте.

Хәким Фарукович ниндидер сәбәп тапкан булып чыгып китте, ләкин тиздән әйләнеп киләчәген һәм алма бакчасында шашлык әзерләнүен әйтте.

—Бу юлы балык шашлыгы!—дип өстәп тә куйды. Мөхәммәтнең балык яратканын белә Хәким Фарукович, шуңа басым ясап әйтүе хәйләкәр картның.

Колхоз рәисе китеп бармаган булса, яхшырак булыр иде, бәлкем. Гөлчәчәк белән икесе генә калгач (әнисенең авыру апасы аерым бүлмәдә кузгала алмыйча ята, бусагадан атлауга, аның белән күрешеп чыккан иде инде), берара сәер тынлык урнашты. Мөхәммәт моны үзеннән күрде. Рәзифә житкергән хәбәр һаман күңелен тырный, Гөлчәчәкнең үзе белән күрешкәч, әлеге жәрәхәт тагын ачылып киткәндәй булды, көнчелеге жанын суытып, сөйләшә алмас хәлгә китергән дип уйлады. Күңелендә кайнаган хисләрне, вакытыннан алда, Гөлчәчәккә сиздерәсе килмәде. Ләкин кызның күзләре үткен, күңеле сизгер, үзгәрешне, тотыш-гамәлендәге сәерлекне тояр дип курыкты. Ләкин Гөлчәчәк аны-моны әйтмәде, чөнки күптән түгел генә аның үз жанына да тоз салганнар иде. Ул күңелсез хәбәр хакмы, юкмы дигән уй аны да бертөзлексез борчый һәм ул аны яшерергә, белгертмәскә тырыша иде. Беркөнне, аны сорап, мәктәпкә шалтыраттылар. Казаннан. Ят ир-ат тавышы. «Мөхәммәт Уразов «Урман» картинасын сөяркәсенә бүләк иткән. Ул сине алдап кына йөри, имеш...» Гөлчәчәк бу хәбәргә ышанмады, дөресрәге, ышанмаска тырышты һәм әле дә тырыша, кыскасы, күңеле икеле-микеле, ул ныгытып кына ни дип уйларга да белми, бу хакта чынын үзеннән ишетермен дип, Мөхәммәтнең кайтуын зарыгып көтте. Менә ул көн килеп тә житте. Әмма тиктомалдан гына бу хакта сүз башлап та булмый. Мөхәммәтнең үпкәләп куюы бар.

Монарчы сүзгә, сөйләшергә туймаган Гөлчәчәкне, икәү генә калгач, алыштырып куйдылармыни! Мөхәммәтнең шөбһәсе көчәйде. Кыз нәрсәдер әйтмәкче дә була кебек, ләкин теле чишелеп китә алмый, күңел түрендәге ниндидер яшерен сер тирәли тик әйләнеп йөри, аны тышка чыгармый. Мөхәммәтнең Казаннан ук төяп кайткан шик-шөбһәләрен кызның әлеге халәт-гамәле тагын да арттыра, аны талый иде.

Монарчы, икәү генә калгач, Мөхәммәт кызга Казан хәлләрен, үзенең эше хакында, «Урман»ның ничек язылуы турында бертуктамый сөйли ала иде. Бу юлы егет үз эченә йомылган, күз карашына чаклы, монарчы Гөлчәчәкне сөеп туймаган коңгырт күзләренә чаклы сынагандай бораулап карыйлар, әлеге гадәти булмаган карашны кыз бик авыр күтәрә һәм елап жибәрмичә чак кына тыелып тора иде.

Мөхәммәт үзе дә шундыйрак хәлдә. Әмма Рәзифәдән ишеткәнне—ничекләр итеп Гөлчәчәккә әйтмәк кирәк!

Мәхәббәт... Ярату, гашыйк булу адәм баласының йөрәген яшүсмер чакта гына жилкетеп, еллар өстенә еллар өстәлүдән хасил булган Вакыт, торган саен, читлектәге кош баласыдай бәргәләнгән, тасырдык йөрәкне тынычландырып, урынына утыртып куяр төсле иде ләбаса!.. Юк икән. Алай гына түгел икән!..

Сагыну үзенә бер төрле газаплы рәхәт. Ашкынып көткәнең тормышка ашып, ниһаять, күрешү минутлары килеп житү тагын үзенчә татлы һәм... газаплы була икән.

Янып торган оятсыз күзле кара мәченең коерыгында бастырык буе гайбәт сөйрәлә... Акыллы кешеләр яхшы белә: үзең ишеткәннең яртысына гына ышанырга кирәк. Ләкин бик акыллы кешеләр генә шуның кайсы яртысы хак икәнен аера алалар. Бер хатын-кыз әйткән бу сүзләрне. Мөхәммәт

исә әлеге ярты өлешнең кайсысына ышанырга белмичә интегеп утыра. Шунысы хак, йөрәге инде үсмерлек чорын узып, һәр нәрсәне акыл иләге аша уздыру яшендә булуга карамастан, бар гайбәтләрдән дә өстен иканлеген белгертеп, тасырдый-ашкына, Гөлчәчәккә тартыла...

Бу газаплардан аларны Хәким Фаруковичның шоферы килеп аралады. Алма бакчасында шашлык әзер һәм капка төбендә аларны машина көтә икән.

Вакытында хәл кыла алмыйча изаланган тормыш мәсьәләләрен киләчәккә калдырырга Мөхәммәт күнегеп беткән иде. Һәм бу дөрестән дә бик һәйбәт ысул, шулай итеп, монарчы хаталанганы юк бугай әле. Бу юлы да алар арасында хасил булган соры томан пәрдәсен, бәлкем, вакыт җилләре куып таратыр—аңлашуы җиңелрәк булыр, бәлки, ярдәмгә кояш нурлары килер, томанны аралар һәм бар нәрсә дә ачыкланыр, җайланыр...

«Матур хатын-кызлар беркайчан да үзләре генә булмыйлар, ләкин алар һәрвакыт ялгыз».

«Әгәр дә ялгызлыктан куркасыз икән, өйләнмәгез». Беренче гыйбарәне кем әйткәндер—билгесез, дөресрәге, Мөхәммәт хәтерләми, ә соңгысы—Чехов сүзләре.

Ялгызмы соң ул, юкмы? Ул әле өйләнмәгән бит. Димәк... Ә Гөлчәчәк, матур, гүзәл зат, ялгызмы?

Чынлап та хыянәт иттеме икән Гөлчәчәк?!

Ә үзе?.. Рәзифә... Сиринә Самуиловна? Болары нәрсә? Хыянәтме, хыянәт түгелме? Хыянәт түгелдер, мөгаен, ул үзе... үз теләге белән түгел ләбаса! Язмышның текә ярында, аякларын асылындырып утырган бер мәлдә, ул баскыч-баскыч уелган ярдан ялгыш нәкъ бер басмага түбән төште түгелме соң инде? Ир-ат белән хатын-кыз якынлыгы табигатьнең иң зур могҗизасы, табигатьнең гаҗәеп зур сере түгелме соң? шулай булса, ул, өйләнмәгән егет, әлеге сернең капкасын бернинди әзерлексез, җиңел ачты һәм шул рәвешчә аның кадере кимеде, алай гына да түгел, өстәвенә күзгә күренеп торган бик нечкә кыллардан торган күңел дөньясы әлеге хис-кыллары каешланырга, тупасланырга өлгерде ләбаса!

Шулай булмадымыни, ул хәтта картинасын да сатып җибәрергә әзер бит! Әйе, әйе, берәү дә шыр надан түгел, Италиягә аны күзләре матур булган өчен генә җибәрмиләр... Ләкин бу бәладән котылып була сыман иде әле: күчермәне тизрәк тәмамларга кирәк.

Казанга кайткач, төнге бердә телефон шалтырады. Сиринә Самуиловна икән, хәзер сина килеп җитәм ди. Бу юлы Мөхәммәт канәгатьсезләнеп каш-күзен җимермәде, киресенчә, бу минутларда Сиринә Самуиловна аңа бик кирәк иде. Ул сәнгать белгечен урамга чыгып каршы алды. Янәшәдәге төнге кафеда музыка дөберди. Йолдызлы күк сискәнеп-сискәнеп китә.

Сиринә Самуиловнаның сүзе катгый булды:

—Мәскәүләргә—оригиналын!—диде матур хатын.—Синең кыргый урман кызын барыбер берни аңламаячак!

Сиринә Самуиловна ул кызны көндәш дип исәплиме, юкмы—белгән юк. Әмма үз көченә һәр алышта җиңеп чыгачагына нык ышана торган хатын.

Заманында бик үзсүзле һәм каткан коммунист җитәкче Хәниф Хатыйповичны да тез чүктергән иде ул! Бу җиңүнең гомере кыска булды: алар икесе ике якка киттеләр. Уртак җимешләре—кызлары—Америкада укый. Бүген исә Хәниф белән дустанә мөнәсәбәттә яшиләр.

Нindидер кыргый урман кызы аның өчен дулкын өстендәге йомычка гына!..

### Гөлчәчәк

Урманда үссәм дә, кыргый кыз түгел мин. Беренче сыйныфтан ук бүтәннәр белән бергә без дә мәктәптә укыдык ич, аралашып яшәдек, яраткан укытучыларыбыз, дус кызларыбыз да бар.

Урманда туып үссәк тә, Гөлйөзем белән икебез дә дөньяви кешеләр без. Нәкъ авыл кызлары кебек Кызылъяр чишмәсенә суга йөрдек, әти-әни,

ни теләсәк, шуны алып кайтты. Авыл кызлары кигән киемнәрне кидек, мәктәптә аларга куйган «ике»ләрне безгә дә куйдылар, «биш»леләрне без дә ала торган идек. Дөрес, гомеребезнең күп өлеше урманда үтте. Шуна күрә Бурянның марҗа кызлары—сыйныфташларыбыз—безгә чак кына башкачарак карыйлар, әмма яраталар, һәркайсы безнең белән дуслашырга тели, безне үз итә; укытучыларыбыз исә, башкалардан аерып, безне бер башка өстен куя, гомумән, гап-гади сыйныфташ кызларыбыз кебек үк булсак та, безгә карата бераз аерым караш булуын сизә идек. Ни дисәң дә урманда үскән кызлар бит, усал аю-бүреләр һәм хәйләкәр төлкеләр патшалыгында.

Тик аерма шунда гына—берчак буй үстергәч, Бурян кызлары да, Байтимернекеләр дә кичке уеннарга чыгалар, ә без өйдә утырабыз, китап укыйбыз һәм сандугач оялаган күнелләребезне килгән-киткән туган-тумачаның, кунак-фәләннең кичке әкият-хикәяләрен тыңлап баса идек. Хәер, берзаман без дә Байтимер малайлары белән дуслашып киттек, алар бик еш безгә, әти янына килеп йөриләр, ара-тирә кыю гына аралаша да башладык, соңрак, «күңел оясындагы бала сандугач канат чыгарып, сайрарга өйрәнгәч», безнең әлеге аралашулар, мавыгуга, тора-бара гыйшык-мыйшыкка ук әверелеп китте!.. «Гыйшык-мыйшык» дип, китап сүзләре белән генә әйтүем. Без һәрвакыт дус-таныш малай-кызлар гына идек. Әмма шунысы хак, толымнар билгә житеп килгән чакта әлеге малайлар белән—Мөхәммәт белән Барый исемле алар—булган мөнәсәбәтләребез сәерләнде, тагын да дөресрәге, Гөлйөзем дә, мин дә бер дә бер көнне әллә ничек үзгәрдек тә куйдык менә.

Мөхәммәт, агач башыннан егылып төшеп, кабыргаларын сындырганнан соң минем ничек кайгырганнарымны, ничектер итеп борчылуымны белсәгез иде сез! Үлә яздым! Кызгандым, жәлләдемме? Әллә?.. Нәрсә, «әллә?» Берниндидә «әллә-мәллә» түгел. Сызлануын күреп, жәлләдем! Бары шул гына! Аннан соң үләр дип уйладым, курыктым, бик-бик курыктым. Гөлйөзем генә пошмас жанлы безнең. «Маймыл кебек агач башында сикереп йөрмәсен, шул кирәк!»—диде. Имеш, ул инде дәү кыз! Имеш, мин әле бәләкәй, шуна күрә сытык та. Һай, харап икән, дәү кыз! Апа имеш. Үзе миннән нибары унбиш минутка алданрак туган ул. Хәер, нишлисең, унбиш минут тек, унбиш минут олырак, димәк, «апа» тиеш. Юк ла, нинди «апа» ди, ул мина игезәк сыңары гына ла...

Мөхәммәт агач башыннан мәтәлгәч, мин чынлап та аны бик кызгандым. Һәм шуннан соң күнелемдә ул малайга карата ниндидер хис тә яши башлады. Әүвәл кызгану хисе генә булды микән соң ул?.. Тора-бара әлеге хисләр мәхәббәткә үк әйләнеп китте ич? Мәхәббәт дигән олы хис әллә һәр кешедә дә, дөресрәге, башка кешеләрдә дә, нәкъ миндәге кебек, кызгану, жәлләүдән башлана микән?.. Алай булса, кызык... сәер. Бәлки, ул малай агач башыннан егылып төшкәнче үк, аны күргән мизгелләрдә үк, күнелдәге бер кылым сиздерми генә чынлап, тибрәп куйгандыр?... Алла белсен... Мин биолог кеше, моны үзем дә чамаларга, аңлата белергә тиеш идем, югыйсә! Тик андый теләгем юк. Бәлки әле бу кешенең—биологик бербөтен организмның—саклану галәмәтедер! Әйе, әйе. Мәхәббәтнең ни икәнлеген аңлатырга, әлеге олуг хисне кем әйтмешли «частен частька!» аерырга маташкан акыллы башның күнелендә максатына инде килеп життем, зур ачыш ясыйм дигәндә генә Илаһи көч әлеге Теләкне юк итә дә куя! Табигать могъжизасы! Мәхәббәт дигән хисме ул, халәтме—кем ничек тели шулай атасын—үзе үк Илаһи могжиза булмаса, гасырлар буе табынырлар идеме соң ана! Мисалларны тезеп китсәнме, бу хакта бер сөйли башласанмы!.. Мен дә бер кичә генә дә житмәс, билләһи...

Мөхәммәт, тырыша-тырыша, «Урман»ны яза, минем портретны. Аның рәсемнәрне матур ясавын беләм. Тик «Урман»ы минем күнелгә ошармы икән соң? Әгәр дә мәгәр портретым үземә ошамаса? Дөресрәге, үзем дә сизмичә, әлеге портретны күрүгә, ихтыярсыздан йөземә-сүземә канәгатьсезлек төсмере чыгарып куйсам! Ике төрле була алмыйм бит, эчтән бер төсле, тыштан икенче... Һәм шуның белән Мөхәммәтнең күнелен кайтарсам?.. Һай, әлеге мизгелләрне бик көтәм көтүен, тик куркам да. Ярабби бер

Аллам дим, Мөхәммәтнең «Урман»ы минем иләс-миләс, әле утырып житмәгән күңелемә хуш кына килә күрсен иде!.. Ходайдан мин шулай дип сорыйм. Аннары, исемә килеп, үземне сүгәргә, әрләргә тотынам! Каян килгән хан кызы! Күңелемә хуш килмәсә, имеш!.. Мөхәммәтнең әлеге гамәле—сине дә, урманыңны да шәһәргә алып китәм дип талпынып йөрүе үзе генә дә ни тора ләбаса! Без, кыз-кыркын, аллай, масаеп куябыз инде кайчакта! Әллә кем булабыз!..

Шөкер, үземне шул рәвешле тәнкыйтьли беләм икән әле! Дөресен әйткәндә, хәзер үз һөнәрем турында түгел, Мөхәммәтнең эшләре хакында ешрак уйлыйм, ана булышасым, ярдәм итәсем килә. Мин ана әйбәт хатын булырмын. Туп кебек малайлар, күбәләктәй кызчыклар алып кайтып бирермен, Алла боерса! Без барыбыз да аның илһамчысы булырбыз!... Ә ул ижат итәр. Кыскасы, без бик бәхетле булырбыз кебек.

Мин, Гөлчәчәк, элекке урман кызы, урманчы кызы бүген әнә шундый хыял белән яшим. Мин бәхетле! Бүген үк бәхетле инде! Һай, Аллаһы Тәгаләм, шуны бездән күпсенә генә күрмәсеннәр иде инде берүк. Арага керә күрмәсеннәр...

Күңелемдә гомер буе балачакта ишеткән бер хикәят яши. Аны безгә кунакка килгән чагында әнинең апасы—хәзер ул урын өстендә, мин аны тәрбиялим,—сөйләгән иде. Алар шулай берзаман карты белән икесе генә кич чәй янында юк-барны сөйләшеп, балачакларын исләренә төшереп утыралар икән. Бабай Идел буендагы «Кызыл байрак» пионерлар лагерында булган вакытларын искә ала. Болай гына, балачагын исенә төшереп, хисләнеп китеп кенә. Пионер лагерында дус күреп, ошатып йөргән бер кызым бар иде. Беркөнне су буеннан тузбаш еланы тоттым да теге кыз, әй чыркылдады!.

Аның сүзен әби ялгап китә: «Карале,—ди ул.—Нәкъ шундый ук хәл минем белән дә булды ич! Пионерлагерьда бер малай миндәрем астына елан салган иде... Туктале, тукта! Ул лагерьның да исеме «Кызыл байрак» иде бит! Идел буенда! Класстан иң яхшы укучы биш кызны, Казандагы пионерлагерьга путевка белән бүләкләгәннәр иде. Бишенче классны бетергәч!...»

Моны ишеткәч, бабайның кулындагы шакмаклы шикәре өстәл астына тәгәри. «Ничек алай?!! Мин дә бишенче класттан соң бит! Путевканы әтигә профсоюз биргән иде!.. Алайса ул кыз син булгансың бит инде!!! Алайса... унбиш елдан соң яңадан Казанда күрешкәч, ник мине танымадың соң? Мин сине ник танымаганмын?!!»

Менә бит! Алар икесе ике районнан.

Зур үскәч, Казанда яңадан күрешкәннәр!

Әбинең шаккатып сөйләгәне елан гына түгел. Кызлар яшәгән бина бик биек койма белән уратылып алынган була. Ул малай шул койма аша ничек менә алды икән дип, аның кыюлыгына шаккаткан кыз ул чакта!.. Батырлыгына сокланган булган!

Илаһи могҗиза—Мәхәббәт—үзенең эшен эшләгән: күп еллардан соң очраклы рәвештә генә Казанда күрешкәч, алар тагын бер-берсен ошатып, кавышып та куйганнар... Апа белән җизни бер-берсен сөешеп, бик матур гомер кичерделәр. Монысы безнең күз алдында иде инде.

Мәхәббәткә ышанмый кара син шуннан соң менә!..

* * *

Италиягә китү Казан сабантуена туры килде. «Урман» картинасын иртән иртүк күргәзмәгә илтеп тапшырдылар да (Мәскәү кунагына ул шундук бүләк ителергә тиеш иде) сәнгать белгече һәм рәссам егетне «джип» машинасы аэропортка илтә китте.

Туган ягында үзенә киләчәк дәрәҗәне һәм капыл кына ишелеп төшәчәк бәхетне Мөхәммәт Уразов чит илдән табып алып кайтачагына чын күңелдән ышана һәм ул бүген дә үзен бәхетле, ай тулган төннән соң кичергән бәхет кебек үк бәхетле хис итә иде.

Гөлчәчәк Мөхәммәтнең чит илгә җыенганын белсә дә, китәсе көн төгәен билгеле түгел дигәч, Казанга килер алдыннан барыбер телеграмма

сукты. «Сабантуена киләм. Каршы ал», дип хәбәр ителгән иде анда.

Телеграмманы Мөхәммәт ишектән чыгып барганда гына кулына тоттырдылар. Аны укып берара аптырап торды да аннан соң йомарлап кесәсенә тыкты.

Гөлчәчәк исә, үзен каршы алучы булмагач аптырап тормады, үзәккә кадәр баручы ярым буш троллейбуска кереп утырды һәм аннан Толстой тукталышында төшеп, туп-туры Мөхәммәтнең фатирына китте. Егет ана фатир ачкычын калдырып киткән иде.

Тимер челтәрле койма белән әйләндергән ишегалдында Гөлчәчәк Гөлйөзем белән Барыйны күреп алды. Алар машинага утырырга җыеналар иде. Гөлчәчәкне беренче булып кыз туганы күреп алды. Һәм машинаның алдагы ишеген ачып:

—Карале, кем килә!—дип кычкырды, аннары җәһәт кенә арткы ишекне ачты да кулыннан тотып, бер баланы төшерде.

Гөлчәчәк җинсез матур күлмәк, шорты һәм аякларына әллә кайдан кычкырып торган кроссовка кигән малайны танып, югалып киткәндәй булды.

—Әнвәр ич бу? Кайдан? Ничек?

Энәдән-җептән генә чыккан өр-яңа киемле бала, чыннан да, Гөлйөземнең малае Әнвәр, урманда югалган малай иде!

Әнисе аны кулыннан бер дә ычкындырмый, малай да үзен әллә ничек сәеррәк тота, әнисеннән ычкынып китмәкче булып, әледән әле тартылып куя, бу теләге барып чыкмагач, бер урында сикерә, чәбәләнергә керешә. Элек туп шикелле тәгәрәп йөргән бала суырылган, ябыккан, шыр сөяккә калган дип әйтергә мөмкин иде. Йөзе, муены тырналып беткән, ике беләгендә дә, аякларында да тырналмаган, кутырламаган бер генә сау җире дә юк. Гөлйөзем ана ни дип кыска җиңле күлмәк һәм шорты киерткәндер? Малайның ике тез башы да каралып тора.

Гөлчәчәк малайны бик ярата, ул аны бишектән үк үзе карап үстерде, чөнки үз әнисе хастаханәгә кереп, айлар буе дәваланып ята иде. Корсаклы чагында, кешегә сиздермим дип, билен буып йөрүе эзсез калмады, күрәсең.

Гөлчәчәк Әнвәрне кочагына алды һәм күкрәгенә кысты.

—Кайларда булган бу бала?

Гөлйөземнең йөзе шат, кәефе күтәренке иде.

—Белмибез,—диде ул туганның соравына каршы.—Әни әйтә, капка астыннан шуышып керде дә мунча буендагы ком өемендә калган машинасы белән уйный башлады,—ди.

—Адашкан булгандыр инде.

Сүзгә Барый кушылды:

—Адашмаган ул. Адашса, тапкан булыр идек. Бөтен урманны тарап чыктык бит!—диде ул. Малайның, үз баласының табылуына ул да чиксез куанган, җитди председательнең йөзендә кояш балкый иде.

—Үзе бернәрсә сөйләмиме?

—Юк, сөйләми шул. Күрәсең, ни булганын үзе дә анлашып җитмәгәндер.

—Урманда адашкан ул, адашкан. Берәр чокырда, йә куак арасында яткандыр, шуңа күрә табылмагандыр,—дип, Гөлчәчәк энесен күкрәгенә кысты.—Нәрсә генә ашап торган сон ул анда?

Бу юлы аның сүзенә каршы да килмәделәр, җөпләмәделәр дә һәм капка төбендәге комда ярылып яткан бүре эзләрен дә әйтмәделәр. Бүренең эттән туган бүре Пират икәнлегән беләләр һәм Барый, аны табып, юк итәргә тели иде.

Гөлйөзем сүзне икенчегә борып җибәрде:

—Мөхәммәт өйдә юк икән. Без аны Казан сабантуена алып чыкмакчы идек,—диде ул һәм тагын югалмасын дигәндәй үз янына тартты.

—Шушы көннәрдә Италиягә китәргә тиеш иде ул. Бәлкем, китеп баргандыр. Без күптән түгел күрештек.

Гөлчәчәкнең бу сүзләре Барыйга ток суккандай тәэсир итте:

—Ничек?! Бүген, Казан сабан туе көнне, Казанда аның күргәзмәсе бит! Мәскәү кунаклары киләчәк!

Гөлчәчәк Барый белән сүз көрәштереп тормады, белгәнемне әйттем мин дигәндәй, инбашларын сикертеп куйды да:

—Минем күргәзмәгә барып карыйсым килә. Әйдәгез, бармыйсызмы?—дип, әңгәмәдәшләренә мөрәҗәгать итте.

Күргәзмә төштән соң гына ачылырга тиеш икән. Залда каравылчыдан башка кеше-кара юк. Каравылчы, зур гәүдәле урыс хатыны тупас кына:

—Күргәзмә төштән соң ачыла!—диде. Барый, алгарак чыгып, маржа апайны итагатьле генә читкәрәк дәште һәм кесәсеннән акча чыгарды:

—Без айн-момент! Сдача да кирәкми, билет да кирәкми!

Каравылчы йомшарды.

—Тик тиз булыгыз! Начальство сабан туена китеп барды, югыйсә...

Мәскәү делегациясе төштән соң гына киләчәк. «Урман»ның да күргәзмәгә куелачагын Мөхәммәт үзе үк әйтте. Һәм шуннан соң туйда мин аны сина бүләк итәрмен дигән иде.

Гөлчәчәкнең күзенә ак-кара күренмәде, ул «Урман»ны эзләп китте. Теле белән әйтмәсә дә Барыйны да нәкъ шул картина кызыксындыра иде. Әгәр Мөхәммәт Италиягә китәргә ризалык биргән икән, димәк...

Әйе, Хәниф Хатыйпович тәки үзенекен иткән. Һәм анын, Барыйнын да, тырышлыгы бушка китмәгән, күрәсең...

«Урман»ны иң беренче булып Гөлчәчәк эзләп тапты һәм күругә, залны яңгыратып кычкырып җибәрде: «Әнекәем! Мин бит бу!»

Урман. Кызылъяр өсте. Яшь наратлар үсеп утыра. Кырыйдагы сирәк агачлар арасыннан чәчәкле алан күренер тора. Алан өстендә мәһабәт бөркет әйләнә. Анда бер кыз такыя үрә. Ул кыз—Гөлчәчәк! Бу кадәр ошаса да ошар икән! Кара, чынлап та, үзе бит! Коеп куйган!..

Чып-чын урман бит бу! Җанлы, тере урман. Кызылъяр өсте. Әнә, тегендә, чак кына сулда һәм астарак чишмә тибеп ята!

Урман кызларына мондагы һәр агач, һәр түмгәк, аланлыктагы һәр чәчәк таныш ләбаса! Күз тимәсен, фотоаппарат белән дә бу хәтле төгәл һәм чын итеп чагылдырып булмастыр урманны!..

Хәзер урман киселеп беткән диярлек. Ләкин кызлар икесе дә, Гөлчәчәк тә, Гөлйөзем дә яхшы хәтерлиләр, моннан берничә ел элек Кызылъяр өсте урманы нәкъ картинада сурәтләнгәнчә иде...

Кызларның күзләре яшьләнде. Бигрәк тә Гөлчәчәк... ул тын гына елый иде. Кыз телсез-авазсыз калды. Якынрак та килеп, арткарак та китеп карады.

Рәсем-картинада гына булса да урман исән-сау бит!

Барый дәшми, ул да сүзсез калган. Анын бердәнбер кешенен, бу картина янынннан тизрәк китәсе, моннан качасы килде.

«Мәскәүләр тиле түгел икән шул! Һе... купмегә сатып була икән сон бу картинаны? Италиягә китү шушының хакыдыр инде?»—дип уйлап куйды ул һәм әлеге хакта берни белмәгән Гөлчәчәккә күз ташлады, кыз аңа кызганыч булып китте.

Хәтта... хәтта... әлеге картина һәм бер егет белән бер кыз турында халыкта матур риваять тә йөри.

Риваять-легендалар тарихта гына түгел, бүген дә бар. Имештер, яшәгән ди, булган ди бер бик гүзәл кыз бала. Ул урманчы кызы, урман кызы икән ди. Бу кыз баланың күзләре урман кебек серле, тавышы урман чишмәседәй саф, күнеле шул кара урман кебек ихлас икән ди.

Урмандагы бар җәнлекләр—куяннар, керпеләр, тиеннәр, хәтта аю-бүреләре дә кызны бик яраталар, якын итәләр икән ди. Башка иптәшләре булмагач, кыз шул җәнлекләр белән күнел ачкан, уйнаганнар, биегәннәр, җырлаганнар. Һәм җәнлекләргә бәла-каза янаса, кыз аларны яклап чыккан, тегеләре, үз чиратларында, анын күнелен ача торган булганнар. Менә шулай күнелле һәм бик тату, дус яшәгәннәр алар.

Кыз бала үсеп җиткән. Бик матур кыз булган ул! Анын гүзәллегенә бар тирә-юнь шаккаткан! Урманга килгән аучылар, кызны күргәч, анын матурлыгына таң калып, кулларындагы мылтыкларын ташлаганнар да чәчәк җыярга керешкәннәр. Шулай итеп һәр аучы кызга үзенең мәхәббәтен аңлатырга, аны үзенә каратырга тели икән. Көннәрдән бер көнне гүзәл

урман кызы турындагы хәбәр ерак тайгада яшәүче Диюгә дә барып ирешкән. Дию бу хәбәрне ишетүгә, агач башларына баса-сикерә генә бик тиз генә урманга килеп житкән. Елга ярындагы куаклыкта, кызны күзләп, өч көн, өч төн кунган ул һәм, дүртенче көн дигәндә, ап-ак атка атланган гүзәл урман кызын күреп алган! Ул Дию егете бик хисле һәм кайнар йөрәкле булган, кызны күргән дә, телдән язган, йөрәге котырып тибәргә керешкән. Тасырдаган йөрәге, күкрәк читлеген ватып, чыгып китәм дигәндә генә, Дию егете салкын суга чумган. Өч көн, өч төн судан чыга алмыйча йөрәген суытып яткан ди. Инде тынычланып, яр буена чыкса, урман кызы жырлый-жырлый такыя үреп йөри икән. Диюнең каны тагын кызган, йөрәге янә тасырдарга керешкән, хисле егетнең йөрәген мәхәббәт ялкыны урап алган һәм ул дөрләп яна башлаган. Ялкын-ут, агачтан-агачка күчә-күчә, бар урманны чолгап алган һәм зур янгын чыккан.

Дию дә, агачлар да өч көн, өч төн янганнар, урман кара күмергә әйләнгән!..

Гүзәл урман кызы исә кара кайгыга баткан, ашаудан калган, телдән язган. Шуннан соң Аю-табиб аучыларга мондый хәбәр салган: кем дә кем урман кызын савыктыра, кыз шуңа кияүгә чыгачак! Бу хәбәрне ишетеп, тирә-яктан бар аучы халкы жыелган. Уйлашканнар, киңәш-табыш иткәннәр, ләкин уртак фикергә дә килә алмаганнар. Араларыннан бер яшь аучы егет, табиб Аюны дәшеп, әйткән: «Иртәгә кызны шундый-шундый урынга алып килегез!»

Билгеләнгән урынга кызны күтәреп алып килгәннәр. Егет аның күзләрен бәйләргә һәм шуннан соң тау мәгарәсенә керергә кушкан. Мәгарә эче бик якты, бик зур ди! Һәм аның диварында кыз туып үскән урман рәсеме ди! Чып-чын урман! Агач башында тукылдап утыручы тукранына хәтле бар ди! Аучы егет бик оста рәссам икән ди. Кыз күзен ачып жибәргәндә, рәсем-урманны күреп, сөенеченнән елмая-көлә башлаган, күзләренә нур ингән, сөйләшергә тотынган.

Шуннан соң инде, Аюның вәгъдәсе буенча, рәссам егет белән урман кызы бик зурлап туй ясаганнар. Аларның бик күп балалары булган. Ул балалар үсеп житеп, янган урман урынына бик күп агачлар утыртканнар.

Менә сиңа әкият, легенда... һәм менә сиңа чын тормыш!..

Гөлчәчәк картинаны кул очы белән сыйпап куйганын сизми дә калды. Каравылчы хатын, аның беләгеннән тотып, читкә этте.

—Мин әле тагын сезне жәлләп керткән булам! Барыгыз, бар! Хәзер үк чыгып китегез! Милиция чакыртам! Бүләккә дигән картина бит ул! Бүген аны Мәскәүгә алып китәләр!

Аларны эткәләп-төрткәләп диярлек чыгарып жибәрделәр.

—Барый, син берәр нәрсә беләсенме? Ни сөйли ул теге хатын?

Барый тамагын кырып куйды, беркавым жавапсыз торды, аннары кызны юатырга теләгәндәй:

—Күрмисенмени анын кем икәнлеген! Каян белсен ди ул! Надан бит ул, надан хатын!—дип куйды да, аннан соң шунын артыннан ук:

—Әйдә, лучше сабан туена киттек.

—Мин бармыйм!..

Бу минутта канаты сынган кош сыман иде кыз...

Күргәзмәдән Барый белән Гөлйөзем Каенлыкка сабан туе карарга китеп бардылар. Гөлчәчәк Казансу яры буенда тезелеп киткән эскәмияләрнен берсендә утырып калды. «Урман»нын тәэсире әле һаман көчле иде...

Ишек ачык, янәшә тирәдә кеше-кара күренми. Кыз песи адымнары белән генә икенче катка күтәрелде, аннан соң, сак кына атлап, «Урман» янына узды. «Мөхәммәт! Мин сине яратам! Рәхмәт сиңа, Мөхәммәт!»

Ул, өнсез калып, картина каршысында байтак басып торды; калын, алсу иреннәре дерелди, нидер әйтмәкчеме, әллә сурәттәге урман кызы белән сөйләшәсе, гәпләшәсе килә һәм ана: «Урман кызы! Син—мин ул! Исәнме! Саумы минем үсмер кыз чагым! Казанга ук килеп житә алдынмы? Ә мин һаман читтә әле... Мөхәммәт сәфәрдән исән-сау әйләнеп кайтсын инде, яме. Көтик. Ул безнен икебезне дә ярата. Тик белеп тор: мин синнән

тамчы да көнләшмим. Син—мин. Мин—син...» дигән сүзләрне тәкърарлый; нәкъ тере зат кебек эндәшә.

«Чү!.. Сине алып китәләр диме?.. Хуҗан да бар инде диме? Юк, юк, борчылма! Мин дә, Мөхәммәт тә сине бирәүгә дә бирмибез, яме...»

Гөлчәчәкнен тагын да якынлашып, картинанын рам-кысасына гына булса да (ул бик затлы, әллә алтын белән йөгертелгән инде?) бармак очын тигезеп карыйсы килде.

—Не трогать! Милиция!!! Охрана! Ничек керден син монда?! Милиция! Милиция! Хәзер үк чыгып кит! Милиция!

Кыз коелып төште, югалып калды.

Күз ачып йомган арада анын ике ягыннан ике егет култыклап алдылар да:

—Пройдемте!—дип, ишеккә таба әйдәделәр.

Милиция бүлегендә күпме утыргандыр, анысын тәгаен генә әйтүе кыен, әмма аны урамга чыгарып җибәргәндә көндезге эссе һава суынган, димәк, көн дә кичкә авышып бара иде.

Ул тирә-ягына каранып беркавым басып торды-торды да, кинәт катгый карарга килгәндәй, янә күргәзмәгә таба атлады. Урамнар көндезге кебек буш түгел, сабан туенда кәефләнгән халык шәһәргә кайта башлаган. Ул йөгерергә үк кереште. Бу күнел дигәненнен сизгерлеге! Күргәзмә куелган бина янында, чыннан да, җинел машиналар, карангы пыялалы затлы чит ил машиналары, автобуслар тезелешеп тора. Бина каршындагы тар урамда эт көтүе кебек халык, төрлесе-төрле киемнән һәм төрле кыяфәттә. Кара урманда күзләрен бәйләп йөри ала торган кызыбыз бермәлгә каушап, югалып калды. Ләкин бу хәләте шул бермәл генә булды да. Ул халык дингезен терсәкләре белән ишә-ера ишеккә таба китте.

Һаман шул ук кешеләр арасыннан кысыла-төртелә икенче катка күргәзмә залына күтәрелде. Ләкин ни файда, картиналар янына үтәрлек түгел. Халык төркемен ул терсәкләре белән булса да этә-төртә түргә уза алыр иде. Ләкин мондагы халык сабан туеннан кайтып килүче гади халык кына түгел иде. Кыскасы, сәер халык һәм күргәзмә карарга килмәгән болар. Ә алдагы төркем,—ул төркем каршылыксыз үтү өчен буш коридор калдырылган, кыскасы, ул төркем янында һәрвакыт шактый зур бушлык бар. Төркем кузгалса, «бушлык» та анын артыннан «калышмый». Гөлчәчәкнен әнә шул бушлыкка эләгәсе килгән иде. Тик кая ул! «Бушлык» картиналар эленгән дивар буенча шуыша да шуыша.

«Бушлык» «Урман» янында туктап калды.

—Бу картинаны Сезгә дип әзерләдек!!!

—...

—Узган юлы, хәтерлисезме, ул Сезнен күнелегезгә хуш килгән иде.

—Я не имею такого желания. Спасибо.

—Ул Сезгә бик охшаган иде бит!

—Я картин не коллекционерую. От них слишком много пыли.

—У Фаины Максимовны от пыли аллергия!

«Бушлык» ары китте. Әлеге төркем залнын икенче почмагына күчүгә, кемдер килеп, «Урман»н салдырып алды да тиз арада каядыр юкка чыкты.

Беравыктан «Урман» эленеп торган урында бушлык күргәч, безнен Гөлчәчәгебез чак кына һушыннан язмады. Йә, Хода, картина урынында буш дивар гына!..

Бераздан зал үзе дә бушап калды.

Буш... бушлык... Нишләптер «мәгънәсез бушлык» диләр... бушлыкнын үз мәгънәсе бар анын...

Бушлыктан, бернәрсәсез юклыктан барысын да табарга була, анда бетмәс-төкәнмәс көч яшерелгән. Бу—алҗыган гакылнын аллавыч халәттән арынып, бушанып, үзенен чын табигатенә кайтуынын бердәнбер юлы...

*Беренче китап тамам*



## Клара Булатова

### ЯҢА ЕЛГА—СӘГАТЬ ЯРЫМ...

Синнән соң да, әни, ун ел үткән,
Яңа еллар килгән дөньяга.
Синнән соң да күпме хезмәт иткән:
Синең мирасыңны иҗат иткән,
Кешеләргә илткән бу бала.

Әле тагын күпме гомер бардыр—
Аны белә бары бер Ходай.
Синең рухны, әнкәй, рәнҗетмичә,
Синең сүздән читләргә китмичә
Яшәп булса иде гел шулай.

Яңа елда кайдадыр
Яңа җаннар яралыр.
Яңа елда кайдадыр
Газраилләр җан алыр—
Шуны тою, һай, авыр...

Яңа елда бәхет көтеп
Күпме күңел алданыр,
Их! Беркатлы ышанычлы
Яңа еллар кайдадыр?...
Өметсезлек, һай, авыр,
Авыр!...

Клара БУЛАТОВА— *шагыйрә, «Җәйләр җитсә», «Гел Кояшка карап», «Шушы җирдән, шушы туфрактан без», нәниләр өчен «Мирас китабы» һ. б. шигырь китаплары авторы. Әлмәттә яши.*

Минем һаман яратасым килә,
Яратасым, ярattырасым.
Синең белән төннәр үткәрәсем,
Синең белән таң аттырасым.

Куеныңа сыенасым килә,
Иңнәреңнән килә үбәсем.
Үзеңнән дә сөйдерәсем килә—
Яшәп булмый шунсыз, күрәсең.

Чәчләремне туздырасым килә,
Туздыртасым, тараттырасым,
Минем һаман яратасым килә,
Килә һаман яраттырасым.

Яфраклар очты, очты да
Туктадылар очудан.
Кар төшүдән башланмаган
Кыш башланды шушыннан.

Әллә нинди бер талчыгу
Изерәтә башны шулай...
Яшь үтүдән башланмаган
Картаю башы бугай.

Тәнәкә—Шагыйрь җанының
Үз көе булган икән.
Җирдәме, күктәме туган
Чын сөю булган икән.

Табигатьнең Ул яратыр
Баласы булган икән.
Йөрәгенең җыр тудырыр
Ярасы булган икән.

Каләменең шигырь язар
Карасы булган икән.
Үзеннән соң Дастан булып
Каласы булган икән.

Сер булып кала алмаган
Төене булган икән...
Тәнәкә—Олы Шагыйрьнең
Сөюе булган икән.

Үз шигырен үзе укый икән,
Ничек теле—шулай укырга
Хакы бар бит аның! Сүзләренә
Үзе хуҗа бары ул гына.

Актер түгел, Автор сезнең алда!
Һәм сез шулай кабул күрегез,
Сәнгатьле сүз остасы дип түгел,
Шигыренә бәя бирегез.

Бәяләгән чакта—үзегезне
Тикшерегез ләкин иң элек:
Шигырьләрне бәяләрлек булып
Җиттегезме икән өлгереп?

Җаннарыма кайчак кара кайгы куна,
Кайчакларда сары сагыш сыгылып тора.
Кара кайгы, салкын сагыш тулганда да
Үлми ул җан—мәңге тере—җырлап тора.

Җырларына кайдан шундый көч табадыр,
Көйләренә нинди сүнмәс хис саладыр,
Кайгы китә, сагыш үтә—югаладыр,
Җирдә шулар нигез булган җыр каладыр.

Тәхетлеләр тәхетендә бәхетледер,
Әмма алар вакытлыча тәхетледер.
Алар өчен тәхет җую—бәхетсезлек,
Җыр тудырган—мәңгелеккә бәхетледер.

Ботакны сарган сыкылар—
Алмаш җәй чыкларына.
Туңган җимешләр—татлы нан
Миләш чыпчыкларына.

Янәшә, парлап кунганнар
Кар төшкән чыршыларга.
Салкыннан курыкмый алар—
Әзерләр кыш чыгарга.

Илаһи кышкы матурлык
Тын урман уртасында,
Сокланып торам,
... һәм торып
Каласым килә шунда.

Мин бу җирдә озак яши алмам,
Бу гомернең язы санаулы.
Быел миңа күктән бар йолдызлар
Чакыру күзе белән карады.

Яктылык бит аннан озак килгән—
Шунысы өмет бирә йөрәккә!
Мин җавапны тавыш белән бирәм—
Ә ул озак йөри бигрәк тә.

Шулай булгач, кемдер көенергә,
Кемдер сөенергә ашыгып
Ялгышуы мөмкин. Үзем исә
Яшим әле ташка баш орып.

Беләм юкса күпме орышсак та
Таш ярылмас—башым ярылыр.
«Шул кирәк!»—дип кемдер шатланса да
«Иртәрәк...»—дип күпләр кайгырыр.

Мин кешеләр өчен яндым һаман,
Халык үзенеке санады.
Тик барыбер китми кала алмам,
Бу гомернең язы санаулы...

*

Яңа елга сәгать ярым,
Яннарымда түгел ярым,
Бу елда да бу бәйрәмне
Каршылыйбыз аерым-аерым.

Аерым-аерым кергән елда
Булырбызмы уртак юлда?

... Яңа елга тик бер сәгать,
Очрашмаута эше сәбәп,
Яңа еллар килер кич тә
Ташлый алмый шуны һич тә.

Һәркем көтә яңа елны,
Ә ул саклый кышкы юлны.

Юллар берүк имин торсын,
Еллар берүк имин тусын.
Аерым-аерым кергән еллар
Бергә-бергә кавыштырсын.

Бергә-бергә үтәр еллар,
Бергә-бергә булса юллар,
Бергә-бергә булыр юллар,
Бергә-бергә булса уйлар.
Уртак булсын безнең уйлар,
Бергә булсын барыр юллар,
Аерым-аерым кергәндә дә
Котлы булсын Яңа еллар,
Котлы булсын, котлы булсын,
Котлы булсын Яңа еллар!

*1999-2001*



# Чыңгыз Мусин

## ҮЗ ЖЫРЫМ БАР

Төннәр буе утырып җырлар яздым,
Җырларымны кемнәр гаепләр?
Гаепләрләр, бәлкем, туң йөрәкле,
Рухи сукыр, рухи гарипләр...

Күп йөрәкләр ахры күгәргәннәр,
Шигъриятне, моңны сизмиләр.
Тик шулай да һаман ярсый-ярсый,
Җырларымнан ертык эзлиләр.

Сандугачлар җырлар, һай, сузамы?
Гомерләр соң җырсыз узамы?
Һәр күңелнең җирдә үз моңы бар,
Тыңламыйбыз гына без аны.

Җыр—милләтнең асыл хәзинәсе,
Күпме йөрәк шуңа табынган.
Аерылалмый кеше, аерылалмый,
Бу табигый—сихри агымнан.

Җырчы дигән даным булмаса да,
Моңсыз түгел минем йөрәгем.
Ләкин,
Ятлар арбасына утырмадым,
Ятлар җырын җырлап йөрмәдем.

Тоя белсәң әгәр, дөнья безне
Илаһи бер моңга ураган.
Әле дә шөкер җирдә үз моңым бар,
Үз җырым бар, шуңа куанам.

## Ак хыял

Ак хыялым ал таңнарда
Тирбәлә рәшә кебек.
Ул мине чиксез-кырыйсыз
Җирләргә дәшә кебек.

---

Чыңгыз МУСИН *(1934)—шагыйрь, «Тамырлар», «Язмышым—үзәннәрдә», «Кадер кичендә» исемле китаплар авторы. Әгерҗе районында яши.*

Диңгездә кораб тирбәлә,
Ак хыялдай ак җилкән.
Җилкәнне җил ега, диләр,
Хыялны ега микән?

Ак хыялым, ак канатым,
Давылларга тиң көче,
Ак хыялын юрга итеп,
Дөнья гизә ир кеше.

## Нәваига

Белмим, бармы дәвам итүчеләр
Шагыйрь Нәваилар токымын?
Мин бит аның шигырь-газәлләрен
Ничәнче кат инде укыймын.

Нәваины кат-кат укыймын да,
Күңелемә тула изгелек.
Әйтерсең дә бөтен тарафымда
Аның рухы тора сиздереп.

Бу заманда аны кемнәр беләә?
Газәлләрен кемнәр ятлаган?
Безнең бит бу рухи дөньябызны
Тоташ кара болыт каплаган.

Ул заманнар инде узган диләр,
Узмаган ул әле, узмаган.
Үзгәрер дә дөнья һәм яңадан
Нәваилар калкыр бер заман.

Нәваича минем таңым ата,
Нәваича йөзә болытлар...
Без кайнаган чорлар узып бара,
Укырлармы аны оныклар?

Мин бит аны кат-кат укыймын да,
Дөньяларым кала үзгәреп...
Кабере аның кайсы тарафларда?
Дога кылыр идем тезләнеп.

## Кадер кичендә

Кайвакытта рухың белән үсәсең дә,
Сихри дөнья тарафына күчәсең дә.
Фәрештәләр җиргә иңгән бер заманда
Шигырь яздым—изге кадер кичәсендә.
Шигырь туса минем күңелем үсә кебек,
Нурланамын, гүя назлы бичә кебек.
Шигърият ул ходай биргән олы тәхет,
Һәркемгә дә тәтемидер мондый бәхет.
Бу гамәлем дөньябызны җайлар кебек.
Җырларымны кошлар отып сайрар кебек.
Фикер кылу тынмас җанга бер сәбәптер,
Һәр ялгышны ярлыкарлык мең сәваптыр.
Бу могҗиза һәр гамәлдән югарырак,
Ни кызганыч, күпләр аннан еаграк.
Шигърият ул яңа туган бер таң кебек,
Бу бәхетемне җуярмын дип куркам кебек.
Сәясәттә зиһеннәре какшаганда,
Укып аны илһамлана патшалар да.
Шигырьне мин түшәк итеп җәямен дә,
Юрган итеп ябынамын өсләремә.
И Ходаем, тагын бер зур бәхетем артты,
Илһам бирдең изге кадер кичләрендә!

Күп ишеттек инде гайбәт сүзне,
Ишетәсе килә әйбәт сүзне.
Кемдер, бәлкем, яманатны сатып,
Төгәллеккә чакырадыр безне?

Акылың кыска, күңелең бозык,
Гомер иттең азып-тузып.
Диндар булып карт көнеңдә
Үзгәрүең кызык.

Күңел елдам, өмет—зурдан,
Ымсынып гомер үтә.
Әйтерсең лә туасы көн
Ал таңнар вәгъдә итә.
Алданганны белә-белә,
Алданып гомер үтә.

Телең бетсә, динең бетсә,
Кайда соң кыйммәтең?
Чукынасың гына кала,
И, газиз милләтем!

Юлларыма гөлләр үреп барам,
Юлларымны гөлләр бизәсен.
Мин тормышта кемгә кирәк булсам—
Гөлләр арасыннан эзләсен.

# Drama əsərlərə
# Драма әсәрләре



## Туфан Миңнуллин

## ШӘҖӘРӘ

ИКЕ ПӘРДӘЛЕ ДРАМАТИК ХИКӘЯ

**Катнашучылар:**

Сәет Шәрәфетдинов—17 яшьтә
Сәлимә Сәетбәкова—16 яшьтә
Халисә Сәетбәкова—82 яшьтә
Артур Сәетбәков—40 яшьтә
Эльза Сәетбәкова—Артур яшендә
Саетбеков Владимир Васильевич—55 яшьтә
Людмила Саетбекова—50 яшьтә
Азат Сәетбәков—36 яшьтә
Юныс Сәетбәков—70 яшьләрдә
Сәлимә Сәетбәкова—65 яшьтә
Алимбәк Сәетбәков—20 яшьтә
Гөлгенә Сәетбәкова—19 яшьтә

### Беренче пәрдә

**Казан шәһәре. Аның уртасында шәҗәрә агачы үсеп утыра. Юан һәм биек. Аның яшен инде белүче юк. Шактый гына ботаклары корыган. Яфрак ярып утырганнары да аз түгел. Шул агач тирәсендә фатирлар. Казан урамнары буйлап йорт номерларын карый-карый бер егет атлый. Үтеп баручы бер кызны туктата.**

Сәет. Ыздраствуйте.

Сәлимә. Здрасте.

Сәет. Сурык пиятый дум где?

Сәлимә. Кырык бишенче йорт диген.

Сәет. Син татармыни әле. Кырык бишенче йорт кирәк ие.

Сәлимә. Нәрсәгә ул сиңа кырык бишенче йорт?

Сәет. Кирәк иде.

Сәлимә. Әнә ул сурык пиятый дум. Ишек алдында.

Туфан МИННУЛЛИН *(1935)—язучы, драматург, РСФСРның К. Станиславский, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләре лауреаты, Россия, Татарстан, Башкортстан театрларында куелган күпсанлы пьесалар, ике дистәдән артык китап авторы. Казанда яши.*

Сәет. Рәхмәт.

Сәлимә. Авылдан килденме?

Сәет. Авылдан.

Сәлимә. Кайсы авылдан?

Сәет. Син кайсы авылны беләсең соң?

Сәлимә. Кара, кара сөйләшеп торган була. Сурык пиятый. Әйт инде, кайсы авылдан?

Сәет. Ерыклы.

Сәлимә. Шундый авыл да бармыни?

Сәет. Бар.

Сәлимә. Кайсы районда?

Сәет. Әлки районында.

Сәлимә. Андый район да бармыни? Кайда соң ул?

Сәет. Саесканның койрык астында. *(Китә башлый.)*

Сәлимә. Әй, сурый пиятый. Әйт инде, кырык бишенче йорт ник кирәк?

Сәет. Йорт кирәкми миңа, квартир кирәк.

Сәлимә. Ничәнче фатир кирәк?

Сәет. Фатир кирәкми миңа, квартир кирәк.

Сәлимә. Фатир шул квартира була ич инде. Ничәнче квартира кирәк?

Сәет. Егерме алтынчы.

Сәлимә. Әллә безгә киләсеңме?

Сәет. Ничек инде сезгә?

Сәлимә. Чөнки без егерме алтынчы фатирда торабыз.

Сәет. Янгалама.

Сәлимә. Менә кызык. Ни өчен мин сиңа ялганларга тиеш әле.

Сәет. Фамилиягез ничек?

Сәлимә. Сәетбәковалар.

Сәет. Соң миңа шул кирәк инде.

Сәлимә. Ни өчен кирәк?

Сәет. Кирәк инде.

Сәлимә. Әйтмәсәң, кертмим. Мин дә быел авылда булдым. Дәү әбием белән кайттык. Әтнә ягына. Минем дәү әбиемнең әтисе шунда туган. Әйт инде, безгә нигә киләсең?

Сәет. Акча бирергә.

Сәлимә. Нинди акча?

Сәет. Син тучны шул квартирада торасыңмы?

Сәлимә. Ышанмыйсыңмы?

Сәет. Казан кызларына ышансаң...

Сәлимә. Ни дидең? Их син, мокыт. Сурык пиятый. *(Китә башлый.)*

Сәет *(куып җитеп)*. Йә инде. Нәрсә син. Тучны шул квартирданмы? Сәетбәковамы?

Сәлимә. Әйтеп торалар бит сиңа.

Сәет. Йә инде, пырлама инде. Синең бабаңның әтисеме, бабасымы бай булганмы?

Сәлимә. Сәетбәковлар морза булганнар.

Сәет. Миңа морза кирәкми, бай кирәк.

Сәлимә. Морза булгач бай була инде ул.

Сәет. Тучнымы?

Сәлимә. Син авылда торып татарча белмисең мәллә?

Сәет. Тучныньң татарчасы юк.

Сәлимә. Точно ул нәкъ шулай дигән сүз була.

Сәет. Өйрәтмә. Өегездә олы кеше бармы?

Сәлимә. Менә мин олы кеше.

Сәет. Син олы кеше түгел.

Сәлимә. Дәү әбием бар.

Сәет. Алайса, акчаны аңарга бирәм.

Сәлимә. Әйт инде, нинди акча? *(Сумкасыннан паспорт чыгарып.)* Менә, ышанмасаң кара. Язылганмы? Сәетбәкова Сәлимә Закировна дигәнме? Ә синең исемең ничек?

Сәет. Сәет Шәрәфетдинов.

Сәлимә. Әйт инде, Сәет Шәрәфетдинов, нинди акча?

Сәет. Моннан сиксән ел элек минем бабайның бабасы Шәрәфетдинов Гарәфетдин Сәетбәков Хәсәнбәктән бурычка акча алып торган булган. Менә шул бурычны китердем.

Сәлимә. Ничек, ничек?..

Сәет. Хәсән Сәетбәковны беләсеңме?

Сәлимә. Мин аны каян белим.

Сәет. Белмәгәч нигә сорашасың? Өегездә олы кеше бармы дип сорадым ич.

Сәлимә. Әйдә, алайса, керәбез. *(Кырык бишенче йортның егерме алтынчы фатирына таба атлыйлар. Ә ул фатирда Халисә Сәетбәкова күзлеген борын өстенә атландырып китап укып утыра. Сәлимәнең кайтып кергәнен дә ишетми.)*

Сәлимә. Дәү әби...

Халисә *(күзләрен китаптан алмыйча гына)*. Мин сиңа күпме әйтәм, кычкырып сөйләшмә.

Сәлимә. Ә бездә кунак бар.

Халисә *(күтәрелеп карап)*. Кем ул?

Сәлимә. Сәет Шәрәфетдинов. Авылдан килгән. Акча бирергә.

Халисә. Нинди акча?

Сәлимә. Хәсәнбәк Сәетбәков

бабасының бабасына акча биреп торган. Шул әҗәтне китергән Сәет.

Халисә. Ни сөйлисең син?

Сәлимә. Сәет үзе әйтте. Әйт, Сәет.

Сәет. Исәнмесез.

Халисә. Исәнме, исәнме.

Сәет. Минем бабамның бабасы...

Халисә. Кунакка урын тәкъдим ит, Сәлимә.

Сәлимә *(Сәет басып торган ишек төбенә урындык илтеп куеп).* Утыр.

Халисә. Сәлимә, күпме әйтергә мөмкин. Кунакның урыны түрдә. Төрки халыкларда кунак иң кадерле кеше.

Сәлимә *(урындыкны түргә күчереп).* Рәхим итегез, кадерле кунак. *(Сәет кыюсыз гына килеп утыра.)*

Халисә. Чәй куй.

Сәлимә. Тыңлыйм инде, дәү әби. *(Халисәнең алдына килеп утыра.)*

Халисә. Сәлимә, күпме әйтергә мөмкин. Сиңа унҗиде яшь.

Сәлимә. Унҗиде яшь кенә.

Халисә. Унҗиде яшь кенә түгел, унҗиде яшь инде. *(Сәлимә күчеп утырга-гач, Сәеткә.)* Тыңлыйм сине, балам.

Сәлимә. Сәетнең бабасының бабасы...

Халисә. Сәлимә...

Сәет. Акча алып торган. Шуннан революция булган. Бабайның бабасы бурычын түли алмый калган. Ә-ә-ә... Ни... Минем бабайның бабасы Хәсәнбәк Сәетбәков дигән байда күчер булып эшләгән. Революция байларны бетергәч, ул эшләгән бай да беткән. Минем бабайның бабасы ул байны бүтән күрмәгән. Шуннан ул минем бабайның әтисенә әйтеп калдырган, байны табып бурычымны түлә дигән. Минем бабайның әтисе дә минем бабайга әйтеп калдырган. Шулай килә-килә минем әти әйтте: Хәсәнбәк Сәетбәковның нәселен эзләп тап—бабаңның бабасының амәнәтен үтә диде.

Сәлимә *(әлеге хикәя аңа бик нык тәэсир иткән).* Дәү әби...

Халисә. Сабыр, кызым. *(Сәеткә.)* Әтиең үзе исәнме?

Сәет. Исән булмыйча. Ана әле утыз сигез генә яшь. Бабай да исән. Ул бер тапкыр килеп эзләп караган да тапмаган кемгә бирергә. Әти эзләми, миңа кушты. Мин менә белештем дә, Сәетбәковларны язып чыктым. Менә спискесе.

Сәлимә. Йә, карыйм әле. *(Сәет кулыннан дәфтәр битен тартып ала.)*

Халисә. Сәлимә, күпме әйтергә мөмкин. Татар кызлары әдәпле булырга тиеш.

Сәлимә. Урыс кызлары әдәпсез булса да ярыймыни?

Халисә. Сәлимә! Өйдә кунак бар.

Сәлимә *(дәфтәр битендәге исемлекне укып).* У-у-у... монда ничаклы Сәетбәков. *(Сәеткә.)* Кайдан җыйдың?

Сәет. Өйрәттеләр инде.

Сәлимә. У-у-у... *(Кинәт күңелсезләнеп.)* Дәү әби, монда минем әти белән бабай да бар. *(Исемлекне атып бәрә.)*

Халисә. Сәлимә... Кил әле монда. *(Сәлимәне алдына утыртып.)* Йә, йә, булды. Тынычлан. *(Сәеткә.)* Син гафу ит инде, балам. *(Кулъяулык алып Сәлимәнең күз яшьләрен сөртә.)* Булдымы? Бар инде, чәй куй, кунак ерактан килгәндер. *(Сәлимә чыгып киткәч.)* Моннан ун ел элек аның әтисе-әнисе белән бабасы, әбисе бер машинада һәлакәткә очрадылар. Һаман оныта алмый. Кинәттән генә холкы үзгәреп куя. Игътибар итмә... Димәк, син Хәсәнбәк Сәетбәков нәселен табып, бурычны түләргә килдең?

Сәет. Әйе.

Халисә. Гаҗәп.

Сәет. Әти дә әйтә, кешеләрне көлдереп йөрергә кирәкми ди. Үзе миңа кушты.

Халисә. Мин биредә көләрлек сәбәп тапмыйм. *(Кухнядан чыккан Сәлимәгә.)* Булдымы, кызым?

Сәлимә. Куйдым.

Халисә. Табын әзерлә.

Сәет. Юк, мин ашыгам. Акчаны алыгыз да...

Халисә. Сабыр, балам. Акчаны бирү җиңел булмаган кебек, алуы да җиңел түгел. Уйларга кирәк.

Сәет. Сез шул Хәсәнбәк Сәетбәковның туганымы соң?

Халисә. Әйе, Сәетбәковлар нәселеннән. Ләкин мин ул нәселгә килен булып кына төшкән кеше. Минем нәсел Галиәхмәт морзаларыннан килә.

Сәет. Барыбер инде ул. Алыгыз. Миңа тиз кайтып житәргә кирәк. Имтиханнарга да әзерләнергә кирәк. Быел Казанга укырга киләсе бар. *(Кесәсеннән акча чыгарып.)* Менә монда өч миллион. Санап алыгыз да.

Халисә. Нигә өч миллион?

Сәет. Бабай шулай санап чыгарды инде. Николай патша акчасын совет акчасына күчергәч, совет акчасын Ельцин акчасына күчергәч шулай килеп чыгарга тиеш диде.

Сәлимә. Ә күпме булган Николай акчасы белән?

Сәет. Мин каян белим. Күпме бирделәр—шуны алып килдем.

Сәлимә. Дәү әби, ә нигә без ул акчаны алырга тиеш?

Халисә. Әкрен. Алган юк бит әле.

Сәлимә. Ул безгә тиеш түгел.

Сәет. Туганы диде ич инде.

Халисә. Әкрен, әкрен... Болай, балам. Әйе, без чыннан да Сәетбәковлар нәселеннән. Әмма Хәсәнбәк Сәетбәков тармагыннан түгел. Хәсәнбәк Сәетбәков минем иремнең абыйсы булган. Аны 1920 елда кулга алалар һәм... Сәлимә, кунакка кул юа торган жирне күрсәт. Чиста сөлге бир.

Сәет. Рәхмәт. Эчәсем килми. Кайтып житәргә кирәк.

Халисә. Безнең татарда чәйдән олы булмыйлар, балам.

Сәет. Алыгыз инде акчаны.

Халисә. Сиңа, балам, акчадан котылырга кирәкме? Алайса, син аны ташла да берәр жиргә, бабаңа кайтып әйт—бирдем диген.

Сәет. Алай булмый инде ул.

Халисә. Булмагач, олыларны тыңла. Монда синең исемләгән зур. Бәлки Хәсәнбәк абый тармагындагы табылыр.

Сәет. Сез белмисезме?

Халисә. Кызганычка каршы, белмим. Оныттырдылар. Рәхмәт. Син килеп искә төшердең. Бар. Ю кулларынны. Сәлимә, чиста сөлге бир.

Сәет. Юк инде, сау булыгыз. *(Чыгып китә. Йорт номерларын карый-карый атлый. Аны Сәлимә куып тота.)*

Сәлимә. Нигә син минем дәү әбиемне үпкәләттең?

Сәет. Нишләп үпкәләтим мин аны.

Сәлимә. Чәен эчмичә чыгып киттең.

Сәет. Кергән бер жирдә чәй эчеп утыра башласаң...

Сәлимә. Кергән бер жиреңдә чәй эчертмәсәләр нишләрсең.

Сәет *(Сәлимәгә карап торып).* Нәрсә син...

Сәлимә. Мин дә синең белән йөримме?

Сәет. Нишләп?

Сәлимә. Сәетбәковларны эзләп.

Сәет. Үзем дә йөри белəм мин.

Сәлимә. Русча белмисең бит. Казанда русча белмәсәң йөреп булмый.

Сәет. Үземә кирәген беләм мин.

Сәлимә. Беләсең инде... Сурык пиятый... Тучны...

Сәет. Кит әле моннан.

Сәлимә. Син әллә кызлар яратмыйсыңмы?

Сәет. Анда синең ни эшең бар.

Сәлимә. Мин кызлар бит...

Сәет. Кызлар булсаң бүтән егетләр эзлә.

Сәлимә. Миңа син ошадың. *(Төбәлеп карап торган Сәеткә.)* Нигә шулай карап торасың? *(Дәшми генә китеп барган Сәеткә ияреп.)* Сәет, сиңа ничә яшь? *(Сәет дәшмәгәч.)* Әйт инде?

Сәет. Сиңа ничә кирәк соң?

Сәлимә. Егерме. Әгәр дә сиңа егерме яшь булса, мин сиңа абый дип әйтер идем.

Сәет. Әллә син чынлап та жүләрме? *(Йорт номерын карап.)* Дивянусты сим. *(Кесәсеннән исемлекне алып карый.)*

Сәлимә. *(Сәет кулындагы исемлеккә үрелеп карап.)* Ничәнче фатир?

Сәет. Егерме алты...

Сәлимә. Боларның да егерме алты. Әйдә, керәбез. *(Егерме алтынчы фатирда фатир хужалары Артур белән Эльза пыр тузып талашалар.)*

Эльза. Мин көне-төне ат кебек эшлим, урамга киеп чыгарга күлмәгем дә юк.

Артур. Мин эшләмимме?

Эльза. Эшләгәч акчаң кайда?

Артур. Хезмәт хакы бирмәгәнгә мин гаепле түгел бит.

Эльза. Син беркайчан да гаепле түгел. Гел мин гаепле. Балаларны әниләргә кайтарып ыргыттың да рәхәтләнеп йөрисең.

Артур. Ни сөйлисең син, Эльза? Үзең бит.

Эльза. Нәрсә, мин аларны монда ач яткырыйммы? Бүтән ирләр таба бит. Син генә һаман, конструктор дигән булып... Нәрсә кырдың конструктор булып. Ике балаңны ашата алмыйсың.

Артур. Нишләргә кушасың миңа? Кулымны сузып чатка чыгып утырыймы? Кеше талыйммы?

Эльза. Базарда синең кебек ирләр басып тора.

Артур. Ю-у-ук, Эльза, матуркаем, мин ул эшне булдыра алмыйм. Мин сәүдәгәр түгел. Ул эш минем кулымнан килми, аңа да осталык кирәк.

Эльза. Алайса, миңа ник рөхсәт итмисең?

Артур. Сиңа бигрәк тә ярамый, Эльза. Син болай да холкың белән базар хатыны. Син анда бер чыгып китсәң, кайтмаячаксың. Ә мин сине югалтудан куркам. Чөнки мин сине яратам. Аңла, Эльза матуркаем, башбаштаклыклар барсы да вакытлы гына. Дөнья рәтләнәчәк.

Эльза. Мин үлгәч нигә кирәк аның рәтләнүе. Бу дөньяда рәхәт күреп каласым килә.

Артур. Нәрсә соң ул рәхәт күреп калу?

Эльза. Тагын тотынды мораль укырга. Миңа синең моралең кирәкми, акча кирәк.

Артур. Булыр.

Эльза. Кайчан?

Артур. Абыйдан сорап торырбыз.

Эльза. Алырсың анардан кыш көне кар. Кесәсе тулы акча. Карак, жулик.

Артур. Акчалы кеше дә ошамый сиңа, Эльза, акчасызы да канәгатьләндерми.

Эльза. Бүген ашарга пешермим.

Артур. Пешермә инде, пешермә, ач ятырбыз. Студент чакта ач килеш кочаклашып ята идек ич әле.

Эльза. Дурак булганмын.

Артур. Әлбәттә, дурак булгансың. Чыкмаска иде миңа.

Эльза *(елап.)* Үртәмә мине.

Артур. Йә, булды инде, булды. Нигә инде. Без генә түгел бит. Безнең кебекләр дөнья тулы. Элек тә булган, хәзер дә күп, киләчәктә дә булачак. Бу илдә, Эльза, эшләгән кеше беркайчан да акчалы булмаячак. Әгәр бу илдә эшләгән кеше акчалы булса, миллионлаган чиновник акчасыз калачак. Син аларны да кызган инде, алар да кеше бит. Мәскәү тулы чиновник ач утырса, сиңа рәхәт булыр идеме? Аннан соң, сиңа Эльза, күп акчалы булу ярамый да. Синең холыктагы кешеләрне ачлы-туклы тотарга кирәк. Әгәр дә син баеп китсәң, иң беренче кылган гамәлең мине өйдән куып чыгару булачак. Синең тормозың юк, Эльза матуркаем. *(Хатынының иңнәренә кулын куеп.)* Йә, булды, булды.

Эльза *(иренең кулларын алып ташлап).* Кит!..

Артур. Кая?

Эльза. Атаң башына.

Артур. Ә-ә-ә, анда. Анда барып кайтырга кирәк. Анда барырга ярый. Пенсия алганнардыр.

Эльза. Теләнеп йөрмә.

Артур. Юк, мин теләнмим. Үземә тиешлесен таләп итәм. Тудырмасыннар иде бу дөньяга. Кайсы илдә яшәгәннәрен белмәгәннәрмени.

Эльза. Йөрмә диләр.

Артур. Ашарга юк дисең. Әйдә, булмаса бергә барыйк, ашап кайтырбыз. *(Ишектә звонок.)*

Эльза. Кайсы йөри инде эч пошырып...

Артур. Бу, Эльза, Хозыр Ильяс. Безгә акча китергән. Ишектән кергәч тә, мә, Эльза ханым, сиңа миллион сум диячәк. Бар, ач ишекне.

Эльза. Бик кирәге барые синең ач дусларыңның. Җыеласыз да дурак сатасыз.

Артур. Сатарлык бүтән әйберебез юк. *(Звонок кабатлана. Артур барып ишекне ача. Сәет белән Сәлимәне күреп.)* Исәнмесез. Эльза, каршыла, туганнарың килгән.

Эльза *(килеп карап).* Нинди минем туганнарым булсын алар.

Артур. Кем кирәк сезгә, матурларым. Кого вам надо?

Сәлимә. Исәнмесез. Безгә Сәетбәковлар кирәк.

Артур. Сәетбәковлар? Кирәгез алайса, Сәетбәковлар кирәк булгач. Кем дип белик инде үзегезне?

Сәлимә. Ашыктырмагыз инде. Татарларда иң элек утырырга урын тәкъдим итәләр.

Артур. Тю-тю-тьюю... *(Урындыклар куеп.)* Рәхим итегез.

Сәлимә *(Сәеткә күрсәтеп).* Бу Сәет Шәрәфетдинов, мин—Сәлимә Сәетбәкова.

Артур. Әһһе... *(Эльзага күрсәтеп).* Ул—Эльза Сәетбәкова, мин—Артур Сәетбәков. Шуннан?

Сәлимә. *(Эльзага).* Исәнмесез. Мин Сәетбәкова дигәч, нигә гаҗәпләнмәдегез?

Артур. Нигә мин гаҗәпләнергә тиеш?

Сәлимә. Бәлки мин сезнең туганыгыздыр.

Артур. Бик мөмкин.

Сәлимә. Бәлки мин сезне гомерем буе эзләгәнмендер.

Артур. Сезнең гомерегез шулай бик озынмыни инде?

Сәлимә. Минеке—озын. Ярый, инде йомышны әйтик. Сезнең нәселегездә бай кеше булганмы?

Артур. Бай? Ә нигә ул?

Сәлимә. Нигә икәнен соңрак әйтербез. Булганмы?

Артур. Ә нәселне кайдан башларга?

Сәлимә. Сезгә ничә яшь?

Артур. Әйтик, кырык.

Сәлимә. Кырык булгач, кырык булгач... бабагызның әтисе була инде.

Артур. Кызык, Эльза, минем бабайның әтисе бай булганмы? *(Эльза эндәшмәгәч).* Гафу итегез, апагызның тотлыга торган гадәте бар, кеше алдында сөйләшергә ояла.

Сәлимә *(Эльза янына килеп).* Минем дус кызымның әнисе логопед. Мин аңа әйтермен, ярыймы? *(Артур янына килеп).* Ничек инде сез бабагызның әтисен белмисез?

Артур. Сез беләсезме соң?

Сәлимә. Беләбез. Сәет белә, мин дә беләм.

Артур. Мин менә белмим шул. Чыннан да әйтегез, нигә кирәк?

Сәлимә. Сәет бабасының бабасы Шәрәфетдинов... *(Сәеткә)* Исеме ничек әле?

Сәет. Гарәфетдин.

Сәлимә. Сәетнең бабасының бабасы Гарәфетдин Шәрәфетдинов Хәсәнбәк Сәетбәковтан әҗәткә акча алып торган. Сәет авылдан шул бурычны түләргә килгән.

Артур. Ә минем ни катнашым бар? Туктагыз әле. Кайчан алган?

Сәлимә. Кайчан алган әле, Сәет?

Артур. Унҗиденче елда.

Сәлимә. Унҗиденче елда. Алган да түләп өлгерә алмаган. Революция булган. Беләсезме?

Артур. Анысын беләм. Әле... Димәк... Әманәт...

Сәлимә. Әйе.

Артур. Шәп бит бу. Акча юк чак иде. Күпме алган булган?

Сәлимә. Башта сез әйтегез, Хәсәнбәк Сәетбәков сезнең бабагызның әтисеме?

Артур. Сәетбәков булгач, шулайдыр инде.

Сәлимә. Ю-у-ук... Минем дәү әби, мәсәлән, алмады. Мин Хәсәнбәк Сәетбәковның ерак туганы гына диде.

Артур. Мин якын туганыдыр.

Эльза. Башларын әйләндермә. Каян килсен бай. Нәселләре белән ыштансыз. Сез дә йөрмәгез. Әйтегез, нәрсә кирәк?

Сәлимә. Без—чынлап. Сәет, күрсәт акчаларны. *(Сәет акчаны күрсәткәч).* Өч миллион сум.

Артур. Кызык бит бу, Эльза.

Эльза. Бер дә кызык түгел. Барыгыз, бар, байлар түгел алар. Булмаган да, барыгыз.

Артур. Туктале, Эльза.

Эльза. Кемгә әйтәм. Барыгыз. *(Сәет белән Сәлимәне этеп-төртеп диярлек чыгарып җибәрә.)*

Артур. Нәрсә инде син... Дәшмидәшми торгач та.

Эльза. Йөрмәсеннәр. Җыен жулик. Кереп карап йөриләр дә, чишендереп чыгып китәләр.

Артур. Чишендерерлек ниебез бар. Күренеп тора бит инде жулик түгелләкләре.

Эльза. Күренеп тора. Күрсәтәләр ди алар сиңа. Бай... Тапканнар бай.

Артур. Ә нигә? Ишеткәнем бар иде бабайдан. Без морза нәселеннән дия иде.

Эльза. Ялгыш ишеткәнсездер. Морза димәгәндер, морҗа дигәндер.

Артур. Усал син, Эльза матуркаем, усал. Туктале, әтигә шалтыратып карыйм әле. *(Телефоннан шалтыратып.)* Әтиме? Нихәлләрдә, әти? Әни исән-саумы? Вакыт юграк әле. Эльза да әйтә, барып хәлләрен белеп кайтыйк ди. Карале, әти. Сәетбәков фамилиясе каян килгән безгә? Борынгыдан? Ә син Хәсәнбәк Сәетбәковны ишетеп беләсеңме? Күреп беләсең? Әһһе... Әйе... Нигәме? Берәү монда акча өләшеп йөри. Әманәт ди. Бабасының бабасы Хәсәнбәк Сәетбәковтан акча алып торган. Эльза да жулик, ди. Ләкин алар жуликка охшамаган. Берсенең фамилиясе Сәетбәкова. Ярый, сау бул. Әнигә сәлам әйт. *(Эльзага)* Ишеттеңме? Без Хәсәнбәк Сәетбәков белән туганнар икән. Нәсел агачыбыз бер икән.

Эльза. Булса ни булган. Әллә оялмыйча алыр идеңме шул акчаны?

Артур. Акчадамыни мәсьәлә. Туктале... *(Тиз-тиз киенә башлый.)*

Эльза. Кая барасың?

Артур. Куып тотыйм әле тегеләрне.

Эльза. Йөрмә.

Артур. Эльза... ну, Эльза... ну... Син мине белмисеңмени? Ну... *(Тиз генә чыгып китә. Ул куа торсын. Без Сәет белән Сәлимә янына ашыгыйк. Алар чираттагы Сәетбәковны эзләп атлыйлар. Сәлимәнең кызуы әле басылмаган.)*

Сәлимә. Менә син әйт, Сәет, шундый кеше буламы? Буламы шундый кеше. Өенә кешеләр килгән, әйеме? Ә ул куып чыгара.

Сәет. Ире аның ишәк.

Сәлимә. Ничек ишәк?

Сәет. Соң инде. Нишлисең син, хайван, дияргә иде дә алып ыргытырга иде.

Сәлимә. Ничек алып ыргытырга? Хатын-кызнымы? Ни сөйлисең син?

Сәет. Хатын-кыз булса, урынында утырсын, теләсә кая кысылмасын.

Сәлимә. Син үзең шулай булыр идеңме?

Сәет. Булса ни булган?

Сәлимә. Синең әтиең шундыймы?

Сәет. Минем әни беркайчан да әти сүзеннән чыкмый. Мин клубка чыкканда да әтиеңнән сора ди.

Сәлимә. Син сорыйсыңмы?

Сәет. Сораса... Әти ич ул.

Сәлимә *(кинәт күңелсезләнеп).* Мин дә әтидән сорар идем. *(Сүзсез генә атлыйлар.)*

Сәет. Синең әбиең укытучы мәллә?

Сәлимә. Әбием укытучы түгел иде, дәү әбием укытучы.

Сәет. Мин дә шуны әйтәм инде. Укытучылар кебек сөйләшә. Сез икәү генәме?

Сәлимә. Әйе... Ул инде мине үстерде. Бик күп язучыларны, артистларны белә ул.

Сәет. Кемнәрне?

Сәлимә. Алар картлар инде.

Сәет. Безнең районнан да артистлар чыккан.

Артур *(Сәет белән Сәлимәне куып җитеп).* Гафу итегез. Эльза апагыз аңлап житкермәгән. Ул да гафу үтенә. Килешегез, чыннан да, сәеррәк хәл бит. Безнең заман кешеләренә хас түгел хәл. Хәтта мин дә ышанып житмәдем. Мин әтидән белештем. Без чыннан да Хәсәнбәк Сәетбәковның туганнары.

Сәлимә. Без барыбер акчаны сезгә бирмибез. Бирмибез бит, Сәет, әйеме?

Артур. Гафу итегез, мин акча сорап килмәдем. Эльза апагызны ачуланмагыз. Авыл кызы ул.

Сәет. Авылда начарлар гына яшимени?

Артур. Юк, мин алай дип әйтмәдем. Киресенчә. Кирәгеннән артык гади. Сез беләсезме, дөньяда барлык нәрсә дә логикага корылган. Ике генә нәрсәнең логикасы юк, мәхәббәт һәм хатын-кыз холкының. Сау булыгыз.

Сәлимә. Сау булыгыз.

Артур *(китә башлаган җиреннән яңадан борылып).* Ә сез чынлап та бөтен Сәетбәковларга акча өләшеп йөрисезме?

Сәлимә. Без өләшмибез.

Артур. Ә сез ул акчаны кайдан алдыгыз?

Сәлимә. Урладык.

Артур. Мин шаяртмыйм.

Сәлимә. Без дә шаяртмыйбыз.

Артур. Гафу итегез алайса. Аңлыйм, без сезне рәнжеттек. Сез чынлап та Сәетбәковамы?

Сәлимә. Сәетбәкова булса ни.

Артур. Гафу итегез. Әгәр дә мөмкин булса, Сез миңа шалтыратыгыз. Утыз ике туксан алты утыз сигез... Утыз ике туксан алты утыз сигез. Сау булыгыз. *(Китә.)*

Сәлимә. Бәйләнчек. *(Атлыйлар.)* Хәзер кемнәргә барабыз, Сәет? Ничек диде әле телефонын?

Сәет. Утыз ике туксан алты утыз сигез.

Сәлимә. Шулай шул. Хәтерең яхшы синең. Урладык дип шәп әйттек, әйеме?

Сәет. Син нигә гел минем өчен сөйлисең? Мин әллә үзем сөйләшә белмимме? И вапшым ияреп йөрмә миңа.

Сәлимә. Син, Сәет, русча белмисең. Рус сүзләрен кушып сөйләшмә. Минем дәү әби әйтә, телең саф булсын ди. Татарлар белән саф татар телендә, руслар белән саф рус телендә сөйләш ди. Син ничәнчедә укыйсың, Сәет?

Сәет. Укып бетердем инде мин.

Сәлимә. Институтнымы?

Сәет. Унынчыны.

Сәлимә *(көлеп).* Укып бетердем ди. Әле сиңа укып бетерергә Институт бар, аспирантура бар. Әле аннан соң да укырга була.

Сәет. Миңа шунысы житкән.

Сәлимә. Юк, житәргә тиеш түгел. Мин гимназияне тәмамлагач, университетка керәм. Аннан аспирантурага. *(Сәет көлгәч.)* Нигә көләсен?

Сәет. Син Пират кебек.

Сәлимә. Нинди Пират?

Сәет. Минем эт шундый. Син дә шунын кебек.

Сәлимә. Ничек шунын кебек?

Сәет. Берәр жиргә барсаң, гел янда чуала. Әле уң якка чыга, әле сул якка. Өскә сикерә.

Сәлимә. Тупас син, сурык пиятый.

Сәет. Әгәр тагын шул сүзне әйтсән...

Сәлимә. Нишләтәсең?

Сәет. Бар, кит диләр.

Сәлимә. Китмәсәм, нишләтәсең. Син мине бернишләтә алмыйсың. Мин сугыш түгәрәгенә йөрим, беләсенме? Миңа орынып кына кара. Менә шушында жылап ятачаксың. Син беләсенме минем арттан өч егет ухаживать итә. Менә мондыйлар. Быел гимназияне тәмамладылар. Ухаживатьнын татарчасы ничек анын?

Сәет. Мин каян белим.

Сәлимә. Үзе укып бетердем дигән була.

Сәет. Җиттеме сиңа, юкмы? *(Йорт номерын карый.)*

Сәлимә. Егерме бер.

Сәет. Үзем дә күрәм. Миңа егерме өч кирәк.

Сәлимә. Безгә егерме өч кирәк диген. Без-гә... Күпме әйтергә мөмкин.

Сәет. Җиттеме сиңа, юкмы? *(Чыгып китәләр. Саетбеков Владимир Васильевич фатиры. Сәлимә белән Сәет тә анда.)*

Саетбеков. И что же вы хотите от меня?

Сәлимә. Долг надо вернуть.

Саетбеков. А причем здесь я?

Сәлимә. Но вы же Саетбеков.

Саетбеков. Ну и чтож Саетбеков? Ну Саетбеков. Владимир Васильевич. Дальше что?

Сәлимә. Вы же родственник Хасанбека Саетбекова.

Саетбеков. Кто вам сказал? У меня сосед—Козлов. Что, он внук козла что ли?

Сәлимә. Саетбеков—татарская же фамилия.

Саетбеков. Кто вам сказал?

Сәлимә. Вот я—Саетбекова. Чистокровная татарка.

Саетбеков. А я вот чистокровный русский.

Сәлимә. Не может быть. Вы наверное только забыли.

Саетбеков. Нет, ничего не забыл. И отец у меня чистокровный русский. Василий Никанорович Саетбеков, дед—Никанор Иванович Саетбеков.

Сәлимә. Интересно.

Саетбеков. А что тут интересного. Вы просто плохо знаете историю, девочка.

Сәлимә. По истории у меня отлично. Наверное, ваши предки татары.

Саетбеков. Возможно.

Сәлимә. А вы не интересовались?

Саетбеков. Зачем это нужно? Если бы я копался в родословной, я по учению Дарвина... Вы знаете Дарвина?

Сәлимә. Знаю.

Саетбеков. Так вот, по учению Дарвина я докопался бы до обезьяны.

Сәлимә. Саетбековы не были обезьянами.

Саетбеков. Кем же были?

Сәлимә. Зачем вы оскорбляете моих предков?

Саетбеков. Разве? А я и не подозревал. Простите, девочка.

Сәлимә. Я не девочка.

Саетбеков. Простите. Девушка. Чтож ваш парень молчит?

Сәлимә. Он не мой парень. Он—Сает. Он плохо разговаривает по-русски.

Саетбеков. Ничего. Научим.

Сәлимә. Как научите?

Саетбеков. Так научим. Я же сказал. Я чистокровный русский. Со всеми достоинствами и недостатками. Вы меня поняли, девушка? А теперь прощайте.

Сәлимә. До свидания. *(Телефон күреп.)* Можно позвонить?

Саетбеков. Звоните.

Сәлимә *(телефоннан шалтыратып).* Дәү әби!.. Мин бу. Курыкма, дәү әби, без Сәет белән...

Саетбеков. Положите трубку.

Сәлимә. Дәү әби! Син күрсән, шундый кызык...

Саетбеков *(телефон трубкасын Сәлимә кулыннан алып).* В этом доме, девушка, говорят только на человеческом языке.

Сәлимә. Как?
Саетбеков. Вот так.
Сәлимә. А вы не русский.
Саетбеков. Убирайтесь. Убирайтесь вон!
Сәет. Чаво ты кричишь?
Саетбеков. Убирайтесь говорят.
Сәлимә *(чыга-чыга)*. Вы не русский, вы не русский... *(Чыгып китәләр.)*
Людмила *(ул Саетбековның хатыны. Әлегә чаклы сүзсез генә бер читтә оек бәйләп утырган иде)*. Зачем ты так?
Саетбеков. Надоело.
Людмила. Они-то при чем?
Саетбеков. При том. В России место не осталось.
Людмила. Ну уж...
Саетбеков. Вчера морда одна горло дерет. Насианалнос надо писать, насионалнос. Свая паспорт надо, свая паспорт.
Людмила. Ну и что? Ты каким-то раздраженным становишься, Володя.
Саетбеков. Ладно, хватит.
Людмила. Мне неудобно.
Саетбеков. Перед кем?
Людмила. Соседи стали сторониться.
Саетбеков. Эти жиды-то?
Людмила. Володя... Кстати, ты же соврал. Прадед-то твой не Иван.
Саетбеков. Кто же?
Людмила. Разве не знаешь?
Саетбеков. Нет, не знаю. И знать не хочу.
Людмила. Не хочешь копаться в родословной?
Саетбеков. Да, не хочу.
Людмила. Ну, это твое дело. Только не надо других с толку сбивать.
Саетбеков. Что этим хочешь сказать?
Людмила. А то—что в тебе заговорил комплекс неполноценности.
Саетбеков. Ты что?
Людмила. Сядь и успокойся. Полноценные люди не злятся по пустякам. Тем более не кричат на детей. Мне стыдно за тебя. Девочка— и то оказалась умнее тебя. Она точно уловила, кто ты такой. *(Сәет белән Сәлимә урам буйлап атлыйлар. Сәлимәнең әле кызуы басылмаган.)*
Сәлимә. Рус түгел ул, Сәет. Менә мин сиңа әйтәм, әйеме, рус түгел. Безнең күршедә Нина Павловна бар, менә ул чын рус апасы. Әйт әле син, Сәтбәков рус була аламы?
Сәет. Булган ич.
Сәлимә. Юк, булмаган. Убирайтесь дигән була. Син молодец, Сәет. Сугышса, жинә иденме? Сиңа сукса мин аны. Мин дә молодец, әйеме, Сәет, Ярый әле акчаны алмады, әйеме?
Сәет. Кем бирә ана акчаны. Әллә мин җүләрме?
Сәлимә. Әйттен, ә... Чава ты кричишь... Авылда русча укытмыйлармыни?
Сәет. Житте диләр сиңа.
Сәлимә. Әллә бүтән сүз белмисенме? Мин булмасам, монын белән сөйләшә алмый иден бит.
Сәет. Мин анын белән сөйләшеп тә тормый идем. Кем икәне күренеп тора.
Сәлимә. Сәет, тагын эзлибезме әллә?.. Әйдә, бүген туктыйк, иртәгә эзләрбез. Дәү әби, кайт, ди.
Сәет. Бар, кайт.
Сәлимә. Син мине озатып куймыйсынмы?
Сәет. Үзен керден бит.
Сәлимә. Ә син кайда кунасын, Сәет?
Сәет. Әнинен абыйларында.
Сәлимә. Иртәгә кайда очрашабыз?
Сәет. Ник?
Сәлимә. Табылмады бит әле.
Сәет. Табылыр.
Сәлимә. Мин кайтам инде, Сәет.
Сәет. Әйттем ич инде, нәрсә син...
Сәлимә. Без инде бүтән күрешмибездәме?
Сәет. Ник?
Сәлимә. Кызык инде син, ник дисен... Сау бул, Сәет. Монда трамвай тукталышы.
Сәет. Сау бул. *(Китә. Бераз атлагач артына борылып карый. Ялгызы басып калган Сәлимәне күреп.)* Ник китмисен?.. *(Сәлимә дәшмәгәч.)* Әйдә... *(Сәлимә йөгереп килеп җиткәч.)* Тагын бер квартирага гына керәм дә илтеп куярмын. *(Атлыйлар.)*
Сәлимә. Сәет, синен йөри торган кызын бармы?
Сәет. Юк. Кирәге дә юк.
Сәлимә. Сәет, син жырлый беләсенме?
Сәет. Юк. Син беләсенме сон?
Сәлимә. Мин дә юк шул. Дәү әби әйтә, музыканы бик нечкә тоясын ди. Тавышын утыргач жырлаячаксын ди. Син кайсы артистны яратасын, Сәет?

Сәет. Үзебезнең районнан чыкканнарны.

Сәлимә. Син патриот, әйеме?

Сәет. Әйе.

Сәлимә. Сәет, син бии беләсенме?

Сәет. Юк.

Сәлимә. Мин беләм. Әтнәгә кайткач, сабан туенда да биедем. Бүләк тә алдым әле.

Сәет. Анда бөтен кешегә бирәләр.

Сәлимә. Сәет, син усалмы?

Сәет. Юаш булсаң бу дөньяда...

Сәлимә. Усал булсаң ярый, Сәет, явыз булма, ярыймы?

Сәет *(кесәсеннән исемлекне алып карап)*. Сиксән алты. Син кермә.

Сәлимә. Алайса, мин кайтып китәм.

Сәет. Китмәгәең. *(Китеп бара. Азат Сәетбәков фатиры. Анда Азат Сәетбәков диванга җәелеп утырган да каршыда сылу гына ике кызның ярымшәрә килеш биегәнен карап кәефләнеп утыра. «Стоп!» дип биючеләрне туктата.)*

Азат *(биючеләрнең берсенә)*. Син чыгып тор. *(Икенчесенә.)* Ә син бие. *(Кызның биюен сокланып карап тора да, үзе дә торып биючегә кушыла. Әйтергә кирәк, ритмны тоюы, хәрәкәтләренең нәфислеге күренеп тора. Кул чабып биюне туктата. Икенче бүлмә ягына карап.)*

Татарчаны уйнат. *(Татарчага охшаган «көй» ишетелгәч туктата.)* Татарчаны, болван. *(Татарча көй ишетелгәч, биючегә.)* Өстенә киеп чык. *(Кыз кереп киткәч кәнәфигә чумып көйне тыңлый. Өстенә киеп чыккан биючегә.)* Бие. *(Кыз биегәндә аны туктатып.)* Көйне тынла. Татар көе бу. *(Хискә бирелеп балет хәрәкәтләре ясап салмак кына бии. Кызга.)* Кабатла. *(Кызның кабатлавын кәефе килеп күзәтә. Кыз биюдән туктагач.)* Җыр! *(Биюче кереп китә. Җырчы кыз чыккач.)* Кармен ариясен.

Кыз. Мин аны белмим.

Азат. Белмәгәч, нигә килдең?

Кыз. Мина әйтмәделәр.

Азат *(кәнәфи култыксасында торган микрофонга)*. Рашит болван, кемне китердең син? *(Кызга.)* Татарча җырлый беләсеңме?

Кыз. Беләм.

Азат. «Озата барма»ны беләсеңме?

Кыз. Җырлап карыйм.

Азат. Җырлап карама син мина, җырла. Җырлап карауучылар сәхнә тулы. *(Кызның җырлаганын тыңлаганнан соң.)* Синнән ярыйсы гына җырчы чыгачак. Өйрән. *(Азатның баш очындагы тавыш көчәйткечтән тавыш ишетелә.)* Сезне сорыйлар.

Азат *(микрофонга)*. Кем?

Тавыш. Бер малай.

Азат. Нишләп йөри?

Тавыш *(паузадан соң)*. Авылдан килгән. Акча бирәсем бар ди.

Азат. Акча? Карап керт. *(Көтелмәгән кунакны каршыларга әзерләнә. Кергән Сәеткә карап тора.)* Нинди акча?

Сәет. Сез Сәетбәковмы?

Азат. Йомышыңны сөйлә.

Сәет. Минем бабамның бабасы Хәсәнбәк Сәетбәковтан акча алып торган. Кучер булып эшләгән чагында алып торган Хәсәнбәк байдан. Унҗиденче елда. Бурычын кайтарып өлгермәгән. Бабай әйтте Хәсәнбәк Сәетбәковның нәселен эзләп табып, бурычны бирергә...

Азат. Нинди бурыч?

Сәет. Әйттем ич инде. Алып торган.

Азат. Ә ни өчен монда килдең?

Сәет. Сез бит Сәетбәков.

Азат. Каян белдең?

Сәет. Белдем инде.

Азат. Адресны кем бирде?

Сәет. Бирделәр инде. Менә миндә исемлек бар.

Азат. Йәле, бир әле *(исемлекне карап)* Син боларның барсында да булдыңмы?

Сәет. Юк әле. Икесендә генә.

Азат. Алар алмадылармы?

Сәет. Юк. Якын туганнары түгел, диделәр.

Азат. Күпме инде ул бурыч?

Сәет. Өч миллион.

Азат. Шулай да, кем бирде адресны?

Сәет. Бирделәр инде.

Азат. Юк инде, син әйт.

Сәет. Әнинең абыйсы.

Азат. Ә ул ничек белгән?

Сәет. Белмим.

Азат. Акчаң бик күпмени?

Сәет. Юк. Әти белән бабай җыйдылар.

Азат. Коньяк эчәсеңме?

Сәет. Мин бернәрсә дә эчмим.

Азат. Концерт карыйсын киләме?

Сәет. Нинди концерт?

Азат. Студент кызлар концерты.

Сәет. Мина кайтып җитәргә кирәк. Ерак.

Азат. Кай якка?

Сәет. Чистай ягына.

Азат. Чистай? Ә син беләсеңме Хәсәнбәк Сәетбәковның Чистай ягыннан икәнлеген?

Сәет. Белмим. Мин Чистайдан түгел. Әлкидән.

Азат *(кәнәфигә күрсәтеп)*. Утыр.

Сәет. Мин ашыгам.

Азат. Утыр. *(Сәет утыргач микрофонга.)* Дәвам итәбез! Чегән биюе! *(Бию көе яңгырый. Кызларның берсе чыгып бии. Бию тәмамлангач кул чаба. Сәеткә.)* Нигә син кул чапмыйсың, әллә ошамадымы?

Сәет. Ошады.

Азат. Кочаклыйсың киләме шул кызны?

Сәет. Юк.

Азат. Чибәрме ул кыз? Әйт инде, оялма.

Сәет. Чибәр.

Азат *(кызга)*. Кочакла шул авыл малаен.

Сәет *(урыныннан торып)*. Кирәкми.

Азат. Утыр. *(Кызга.)* Ярый, бар. *(Кыз киткәч.)* Ул да авыл кызы. Димәк, акча? Китер.

Сәет. Расписка язгыз. Бабай алып кайтырга кушты.

Азат. Расписка? Була ул. Башта акчаңны күрик. *(Сәет кулыннан акчаны алып әйләндереп-әйләндереп карый.)* Өч миллион дисеңме?

Сәет. Әйе.

Азат *(өстәл өстеннән акча алып, Сәет акчаларына куша)*. Менә хәзер өч миллион да илле доллар булды. Алып кайтып бабаңа бир. Тагын сиксән елдан соң түләрсез. Бабаңа һәм әтиеңә әйт, Хәсәнбәк Сәетбәковның энесенең оныгының малае бирде диген.

Сәет. Кирәкми.

Азат. Ал дидем. Ә хәзер бар. Йөрмә Казанда буталып. Шул өч тиен акчаң өчен кыйнап үтерүләре бар. Монда шпана житәрлек. Сәетбәков дигәннәре дә бардыр. Бар, бар, юлыңда бул. Ишеткән-күргәннәреңне сөйләп йөрмә. *(Мондый очрашудан миңгерәбрәк калган Сәет урамга чыга. Анда Сәлимә елап утыра.)*

Сәет. Әйдә. *(Сәлимә эндәшмәгәч янына килә.)* Нишлисең син, ә? Ник жылыйсың? *(Сәлимәнең янәшәсенә утыра.)* Ярый әле, кермәдең *(Сәлимә эндәшмәгәч.)* Нишлисең соң син? *(Сүзсез генә шактый озак утыралар.)*

Сәлимә. Алдылармы?

Сәет. Юк.

Сәлимә. Нәрсә диләр?

Сәет. Кирәкми диләр.

Сәлимә. Бөтенесе дә акча юк ди. Берсенә дә акча кирәкми.

Сәет. Син ник жыладың соң?

Сәлимә. Ир бала булып туган булсам...

Сәет. Нишләриең соң?

Сәлимә. Белер идем әле. Хәсәнбәк Сәетбәков туганы түгел диләрме?

Сәет. Туганы...

Сәлимә. Татарча сөйләшәләрме?

Сәет. Татарча.

Сәлимә. Ә мин сине сагындым, Сәет. Курыктым да. Чыкмассың кебек тоелды.

Сәет. Чыкмый кая барыйм.

Сәлимә. Һәй, белмисең әле син Казанны. Әйдә, кайтабыз. *(Урыннарыннан торалар да урам буйлап атлыйлар. Сәлимә бик борынгы бер көйне сызгырып кайта.)* Дәү әби әйтә, сызгырма, малайлар гына сызгыра ди. Күпме әйтергә мөмкин, ди. Син сызгыра беләсеңме, Сәет?

Сәет. Юк.

Сәлимә. Үзе егет, үзе сызгыра белми. Өйрәтимме?

Сәет. Кирәкми.

Сәлимә. Сәет, син әллә нинди, әйеме. Юк, белмим, кирәкми, дип кенә сөйләшәсең. Елмайганыңны да күргәнем юк.

Сәет. Жүләр мәллә мин.

Сәлимә. Жүләрләр генә елмаямыни? Йәле, бер елмаеп күрсәт әле.

Сәет. Нәрсә бәйләнәсең соң син миңа? Сезнең кебек шарык-шорык килеп йөрергә вакыт юк безнең.

Сәлимә. Нишлисез соң сез?

Сәет. Тире жыеп көн эшлибез. Әнә трамвай килә.

Сәлимә. Жәяү генә кайтыйк әле, Сәет. Ерак түгел моннан. *(Китеп югалалар. Һәм Сәлимә өенә кайтып керә. Китап укып утырган Халисә янына әкрен генә килеп.)* Вау, вау, вау.

Халисә. Уф, котымны алдың. Күпме әйтергә мөмкин.

Сәлимә. Күпме әйтергә мөмкин, дип күпме әйтергә мөмкин.

Халисә. Житкән кыз бит инде син, кызым. Һаман бала-чага кебек.

Сәлимә. Ә мин гашыйк булдым, дәү әби.

Халисә. Ничәнче тапкыр?

Сәлимә. Монысы чынлап, дәү әби. Уф, арыдым. Алдына утырып торыйм, дәү әби.

Халисә. Кулыңны юып кил башта. *(Сәлимәнең сызгыра-сызгыра юынганын ишетеп.)* Сәлимә! Күпме әйтергә мөмкин? *(Сәлимә чыгып алдына утыргач.)* Авырайдың инде.

Сәлимә. Дәү әби, гашыйк булган кыз нишләргә тиеш?

Халисә. Нишли иден соң элек?

Сәлимә. Дәү әби, мин чынлап...

Халисә. Гашыйк булган кызлар җитди булалар. Сызгырынып теләсә ни сөйләп йөрмиләр. Егет муенына асылынмыйлар.

Сәлимә. Ә мин асылынмадым.

Халисә. Шул егеткә гашыйк булдыңмы?

Сәлимә. Әйе, Сәеткә.

Халисә. Бик тиз түгелме соң? Бер көн эчендә.

Сәлимә. Бер көн түгел, дәү әби. Ул безгә килеп керүгә гашыйк булдым мин.

Халисә. Миңа да өйрәт инде, ничек була икән алай.

Сәлимә. Аны күрдем, әйеме, шунда кемдер колагыма пышылдаган кебек булды. Сәлимә, син аңа гашыйк булдың, ди.

Халисә. Кара син аны. Үзенә әйттеңме соң?

Сәлимә. Юк әле. Синнән сорагач кына әйтәм. Иртәгә күрәм ич әле. Вәт күрдем мин, дәү әби, Сәетбәковларны. Син дә күрсәң...

Халисә. Мин аларны күп күрдем инде, кызым.

Сәлимә. Юк, дәү әби, боларын син белмисең. Әле Сәетнең исемлегендә беләсеңме күпме. Берсе дә акчаны алмый, дәү әби. Нигә мин егет булып тумаганмын икән, дәү әби?

Халисә. Сәетбәковлар нәселенә бик матур кыз кирәк дип сине Ходай кыз итеп яраткан.

Сәлимә. Юк, дәү әби. Әгәр мин егет булсам, бөтен Сәетбәковларны бергә җыеп очраштырыр идем, таныштырыр идем. Менә кызык булыр иде.

Халисә. Соң, җыеп йөрисең юк инде. Туеңа чакырырбыз.

Сәлимә *(куанычыннан сикереп үк торып)*. Чакырабыз, дәү әби!.. Хәзер, дәү әби... *(Искә төшерергә тырышып.)* Утыз ике... Утыз ике. Утыз ике туксан алты... утыз сигез *(Телефон шалтыратып)* Алло, Сәетбәковлар фатирымы? Артур Сәетбәковмы? Бу Сәлимә Сәетбәкова. Ничек инде?.. Бүген күрештек ич. Хәзер сезнең белән минем дәү әбием сөйләшә. Дәү әби, кил. Кил инде тизрәк.

Халисә. Куй...

Сәлимә. Кил инде, дәү әби... Дәү әби...

Халисә *(трубканы алып)*. Исәнмесез... Әйе, онык... Әйе, гафу итегез. Әйе, шулай... юк, белмим шул. Аны беләм, әйе. Әйе, Галиәкбәр Сәетбәков, әйе. *(Сәлимә Халисә сөйләшкәндә шатлыгыннан яңаштада биеп тора. Трубкага колагын куеп тыңлый да. Ниһаять, түзми, трубканы Халисә кулыннан ала.)*

Сәлимә. Артур абый!.. Сез тагын кайсы Сәетбәковларны беләсез? Хәзер, хәзер, кәгазь белән ручка алам.

## Икенче пәрдә

**Урам чатында Сәет басып тора. Сәлимә йөгереп керә. Сәетне күрә дә туктап кала. Сәетнең килгәнен көтә. Сәет күрмәгәч, тамак кырып, үзенең барлыгын белдерә.**

Сәет *(борылып карап)*. Ник килмисең?

Сәлимә. Исәнмесез.

Сәет. Нихәл. Әйдә... *(Сәлимә ялындырган булып кына әкрен килгәч.)* Әйдә инде, тизрәк. *(Сүзсез генә атлыйлар. Сәлимәнең такылдавына күнеккән Сәет, аптырап, Сәлимәгә карап.)* Әллә әбиең сүктеме?

Сәлимә. Нигә?

Сәет. Сөйләшмисең ич. *(Сүзсез генә атлыйлар.)*

Сәлимә. Сәет, мә.

Сәет. Нәрсә?

Сәлимә *(учындагы кәгазен Сәеткә сузып)*. Исемлек. Сәетбәковлар.

Сәет *(исемлекне карап).* Каян алдың?

Сәлимә. Артур абый бирде. Ул әйбәт кеше булып чыкты.

Сәет *(үз исемлеге белән чагыштырып).* Болары бар, болары юк. Адресларын ник сорамадың?

Сәлимә. Менә боларының телефоннары бар. Мин инде сөйләштем. Ышанмыйлар. Монысы кунакка чакырды. Монысы тагын русча гына сөйләште.

Сәет. Аларына бүтән кермибез.

Сәлимә. Ул бик кызыксынды. Анысы иртәгә чакырды. Бик әйбәт сөйләште.

Сәет. Иртәгә миңа кайтырга кирәк. *(Китә. Аңа Сәлимә иярә. Сәет сызгыра-сызгыра атлый.)*

Сәлимә. Сызгыра белмим дигән идең.

Сәет. Бүген өйрәндем. Бер анекдот сөйлимме?

Сәлимә. Сөйлә.

Сәет. Әби, сызгыра беләсеңме дигән ди бер әбигә бер егет. Белмим, улым, дигән ди әби. Кызыңны урлап киткәннәр дигән ди егет. Әби сызгырып җибәргән ди.

Сәлимә *(рәхәтләнеп көлә).* Тагын сөйлә әле, Сәет, тагын, тагын... *(Көлә-көлә Сәет тирәсендә сикеренгәли дә гашыйк булган кыз нишләргә тиешлеген исенә төшереп, әйбәт кенә, сүзсез генә атлый. Сәеттә дә үзгәреш сизелә, ул инде Сәлимәгә ияләшә төшкән. Шуңадыр, күрәсең, кирәгеннән күбрәк сөйләшә.)*

Сәет. Сезгә килгәндә астановканы узып киткәнмен. Кальсаны күрми калганмын.

Сәлимә. Хәзер кольцо түгел инде, Тукай мәйданы.

Сәет. Ыһы. Кире килдем. Абыйларга кайткач кино карадым. Бер кыз бер егетне яратып йөри. Егет ул кызның апасына өйләнгән була. Бу барыбер ярата. Апасының ире моны яратып ук бетерми. Ул барыбер ярата. Аннан апасының ире сугышка китә. Сугышлы кино ул.

Сәлимә. «Унесенные ветром»...

Сәет. Ыһы. Шундый исемле. Бүген икенче сериясе була. Син карадыңмы?

Сәлимә. Мин аны әллә кайчан карадым инде. Видеосы да бар миндә.

Сәет. Саталармы?

Сәлимә. Бөтен җирдә тулып ята.

Сәет. Күрсәтерсең әле миңа. Сәетбәковлар бик күп икән, әйеме. Шәрәфетдиновлар да күп. Авылның яртысы безнең нәсел. Авыл зур безнең. Тарих укытучысы Хәйруллин абый әйтә, болгар заманындагы авыл ди. Баз казыганда чүлмәк ватыклары да күп чыга. Өченче ел Хәмит акча да тапты. Казанга илтеп бирделәр. Тә-ә-әк... Сорок восьмой. Әйдә, Аллага тапшырдык. *(Китәләр. Нәсел агачы, әйләнеп, бер фатирның каршында туктый. Аның эчендәниләр барын һәм ниләр эшләгәне күренми, пәрдә капланган. Пәрдә артында шәүләләр һәм хатын-кызның чытлыкланып, кытыкланып көлгәне ишетелә.)*

Хатын-кыз тавышы. Син чынлап яратасыңмы мине?

Ирләр тавышы. Юри генә! *(Хатын-кыз көлә. Ишектә звонок шалтырый.)*

Хатын-кыз тавышы. Кем булуы мөмкин?

Ирләр тавышы. Анысын син беләсең инде.

Хатын-кыз. Прошу без намеков. Сәетбәкованың кем икәнен беләсең.

Ирләр тавышы. Гафу үтенәм. *(Звонок кабатлангач.)* Ачыйммы?

Хатын-кыз. Үз ишегемне мин үзем генә ачам. *(Ишек янына барганы күренә. Аннан яңадан элеккеге урынга килә.)* Ниндидер малай белән кыз.

Ирләр тавышы. Безнең кебекме? *(Көлә.)*

Хатын-кыз. Әкрен. *(Сәет белән Сәлимә урамга чыгалар.)*

Сәет. Монысы булмады. Эшкә киткәннәрдер. Киттек дәлше. *(Китәләр. Сәет сызгырына-сызгырына атлый. Сәлимәгә борылып карап.)* Синең долларны күргәнең бармы?

Сәлимә. Бар.

Сәет. Күпмелекне?

Сәлимә. Илле сумлыкны, йөз сумлыкны.

Сәет. Мин дә илле сумлыкны күрдем... Безнең авыл бик усал булган. Кара баганалы авыл булган. Син кара баганаы беләсеңме?

Сәлимә. Юк.

Сәет. Элекке заманда усал авыллар янына кара багана утыртып куйганнар. Бу авыл яныннан узганда күзеңне ачыбрак бар дигәнне аңлаткан ул. Без усал булсак та юкка-барга сугышмыйбыз. Безгә тимәсәң, без дә тимибез.

Әгәр дә инде безгә тисәң, утыз ике тешеңне кырып төшерәбез.

Сәлимә. Ә нигә тешләрне кырасыз?

Сәет. Ашый алмасын өчен. *(Сәлимә көлә. Сәлимәгә кушылып Сәет тә көлә. Хәтта арттырып та җибәрә бугай әле.)*

Сәлимә. Синең белән йөрергә куркыныч икән.

Сәет. Әйттем бит, без тимәгәнгә тимибез. Безнең тарих укытучысы Хәйруллин абый да әйтә, без тимәгәнгә тимибез, тияләр икән, ачуыбызны чыгаралар икән, иманнарын укытабыз ди. Ул инде безнең авыл турында гына әйтми, вапшы татарлар турында әйтә. Татар бар җирдә хәтәр бар дигән сүз шуннан чыккан ди.

Сәлимә *(каршыга килеп туктаган йортка күрсәтеп)*. Менә. Алтмыш алты.

Сәет. Ыһы. Йәле, карап җибәрик әле спискене. *(Кәгазьдән карап.)* Шул. Әйдә. *(Звонок бирәләр. Ләкин фатирда җавап бирүче юк. Җитмәсә әле караңгы да. Һични күренми. Звонок кабатлана. Бүлмә эчендә ниндидер шаулә селкенгән сыман. Тавышы да ишетелә. Исерек икән.)*

Шәүлә. Кем ул анда? Синме, сука!... *(Сәет белән Сәлимә чыгалар.)*

Сәет. Монысында да булмады.

Сәлимә. Нидер ишетелгән кебек булды анда.

Сәет. Ярар, бүтәннәр табылмаса, янадан килербез әле. Ә син кайсы көрәшкә йөрисең?

Сәлимә. Каратэ.

Сәет. Мин дә быел район сабантуенда зурлар белән көрәштем. Үз авырлыгымда батыр асты калдым. Киләсе елга чәпим мин аны. Быел алдады гына. Йәле, күрсәт әле каратэне. Ничек?

Сәлимә. Мондамы? Монда келәм юк ич.

Сәет. Ә син кул белән генә күрсәт. *(Сәлимә көрәш алымы күрсәтә. Сәет аны җыештырып күтәреп ала.)*

Сәлимә. Җибәр. Җибәр, диләр.

Сәет. Көрәшәм дигән була. Хәйруллин абый әйтә, татар көрәше дөньяда иң чистный көрәш ди. Шулай шул. Аяк чалырга ярамый, кулны каерырга ярамый. *(Күңелсезләнеп калган Сәлимәгә.)* Әллә авырттымы?

Сәлимә. Билне кыстың.

Сәет. Бетә ул. Сабан туенда болай гына кысалармы әле. Билне бирмәскә кирәк. Билне бирсәң, бетәсең. Сразы җиргә сылыйлар.

Сәлимә. Авырта...

Сәет. Үзең бит. Хатын-кыз башың белән. Нәрсә, каратэдә авыртмыймыни?

Сәлимә. Анда да авырткалый инде.

Сәет. Билләреңне боргала. *(Сәлимә боргалангганда сокланып карап тора. Бәлки аның беренче тапкыр кызлар гәүдәсенең матурлыгын, сылулыгын күреп соклануыдыр. Сәлимә бу карашны хатын-кыз буларак инстинктив рәвештә тоя. Туктап кала. Пауза.)*

Сәлимә. Әйдә.

Сәет. Авыртмыймы?

Сәлимә. Юк. *(Сүзсез генә атлыйлар һәм Юныс Сәетбәковларга керәләр.)*

Юныс *(аларны очынып каршылый)*. Түрдән узыгыз, минем яшь дусларым. *(Бүлмә буйлап очып йөреп урын әзерли.)* Рәхим итегез, рәхим итегез. Сез миңа, яшь дусларым, шалтыратмыйча гына килегез. Килегез дә керегез. Ишек һәрвакыт ачык. Танышыйк. Юныс Хәербәк улы Сәетбәков.

Сәлимә. Сәлимә.

Юныс. О-о-о... Нинди күркәм исем. Сәлам бирдек, сәлам бирдек дигән сыман янгырый. Без еш кына исемнәребез турында уйланмыйбыз. Исем бит ул философик төшенчә. Кеше дөньяга туганнан элек аның исеме туа. Әйе, әйе. Моны, әлбәттә, күпләр инкарь итәргә җыеналар. Гаҗәп нәрсә бит, сез игътибар итегез. Кеше этләргә һәм башка хайваннарга исемне төгәл куша. Әгәр дә этнең тәпи очлары ак икән, актырнак ди, әгәр дә атның маңгаенда ак төс бар икән, кашка ди. Ә бит кешенең дә үз исеме үзенә тәнгәл килергә тиеш. Борын заманда бит шулай булган. Кеше, димәк, үз асылын югалта бара. Сезнең исем, туташ, нәкъ үзегезнеке. Дөньяга сәлам биреп матурлык туган. *(Сәеткә.)* Инде сезнекен ишетик, яшь дустым.

Сәет. Сәет.

Юныс. Сәет?! О-о-о. Бу инде чын ирләр исеме. Сәет! Ә сез Сәетнең ни аңлатканын беләсезме? Мөхәммәт пәйгамбәр нәселен дәвам итүчеләргә кушалар ул исемне. Мин үз фамилиямнең Сәетбәков булуы белән горурланам. Ах, гафу итегез, яшь дусларым, сандугачны мәсәл белән сыйламыйлар, ди руслар. Хәзер мин сезне чәй белән сыйлыйм. Юк, юк, юк... Үзем

Сез утырып кына торыгыз. *(Очып кухняга кереп китә.)*

Сәет. Әйдә, китәбез.

Сәлимә. Нигә?

Сәет. Күрмисеңмени?

Сәлимә. Күрәм.

Сәет. Күргәч.

Сәлимә. Кызык бит.

Сәет. Нигә килгәнне дә сорамый. Карале китапларын. Укый-укый ычкынган инде бу.

Сәлимә. Юк, шундый кешеләр дә бар. Безнең рус теле укытучысы Пушкин булып та уйнап күрсәтә, Лермонтов булып та дуэльдә егыла. Син аның шигырь укыганын күрсәң.

Сәет. Бездә дә бар андый кеше дә... Ул бит җүләр. Шулай сөйләнә-сөйләнә дә җылый башлый, аннары егыла.

Юныс *(очып чыгып)*. Хәзер, яшь дусларым. Шулай. Сез, әлбәттә, минем лекцияләргә йөрмисез. Зачет куярга кирәк булгач кына мина мөрәҗәгать итәсез. Юк, мин сезне һич тә ачуланмыйм. Сез әле яшьләр. Ә яшьлек ул бөтен нәрсәгә дә көлеп карый. Һәм дөрес эшли. Чөнки кешегә көлеп калырга кирәк. Чөнки аны алда җылыйсы көннәр сагалап тора. Бу дөньяның үлчәве гаҗәеп төгәл. Күз яше дә, көлү дә кешегә тип-тигез бүлеп бирелгән. Фифти-фифти. *(Өстәлгә чәй ризыклары куя-куя.)* Кайберәүләр дөньяга бары тик көлер өчен килдем дип уйлыйлар. Кайсыларын исә җыларга гына хөкем иткәннәр. Ярамый! Ярамый, яшь дусларым! Сәнгатьтә дә шулай булырга тиеш. Җылау һәм көлү аралашып барырга тиеш. Әгәр дә театрда туктаусыз комедия генә уйналса тамашачы көлүдән арып, ялыгып театрдан китәчәк. Әгәр дә трагедияләр генә уйналса, тамашачы шулай ук ул театрга йөрүдән туктаячак. Әгәр дә сез язмышыгызны театр белән бәйләргә җыенгансыз икән, сез аны белергә тиешсез. Ах, гафу итегез, безнең чәйнегебез сызгыра. *(Кухняга чыгып китә. Сәет белән Сәлимә пырхылдап көлеп җибәрәләр. Тыела алмыйча көләләр. Юныс ике кулына ике касә тотып чыкканда көчкә тыелалар. Юныс касәләрне өстәлгә куя да кулларын җәеп, башын иеп, яшьләрне өстәл янына чакыра.)* Рәхим итегез, яшь дусларым. Юк-юк, баш тартмагыз, студентның хәлен аңлыйм. Сәнгать, яшь дусларым, һәрвакыт югарыга омтылырга тиеш. Бары тик югарыга гына. Үзе белән бергә кешене дә үстерергә тиеш. Сез беләсезме, кеше җиргә күктән төшкән. Әйе, әйе, космостан. Кеше маймылдан килеп чыккан диючеләр тиран ялгышалар. Алай була алмый. Чөнки кеше илаһи зат. Кеше маймылдан түгел, киресенчә, маймыл кешедән килеп чыккан. Үзенең асылын югалткан кешеләрдән эволюция нигезендә маймыл барлыкка килгән. Игътибар иткәнегез бармы, маймыл һәрвакыт кеше кыланышларын кабатлый. Нигә? Янадан кеше булырга омтыла ул. Ләкин инде соң. Әгәр дә кешелек дөньясы шушы юл белән баруын дәвам итсә, җир өстендә бары тик маймыллар гына калачак. Кешелек дөньясын бу афәттән бары тик театр гына саклап кала алачак. Югарыга, бөек идеалга хезмәт итүче театр, дигән Гамлет. Бу сүзләр бүген аеруча актуаль. Йә булабыз, йә булмыйбыз. Башка юл юк. Кызганычка каршы, сез боларны аңларга теләмисез. Ләкин зарар юк, аңларсыз. Мин сезне көттем, яшь дусларым. Озак еллар көттем. Сез килергә тиеш идегез. Мин әйттем, ялгышасыз, дидем. Алар мине китәргә мәҗбүр иттеләр. Чөнки мин өченче курс студенты гына булсам да алардан өстен идем. Мин әйттем, сезнең урынга кайтам дидем. Һәм менә килде ул көн. Әлбәттә, мин әле академик ук түгел. Ләкин аңларлар. Кешелек дөньясын миннән дә тирәнрәк белгән галим юк. Сез аңлап килгәнсез, яшь дусларым. Китерегез зачеткаларыгызны, мин студентның юлына киртә булучы профессор түгел. Һәм мин, гомумән, студентлардан имтихан алу тарафдары да түгел. Кеше бит белемгә ниндидер бишле яки дүртле алу өчен омтылмый. Ана камилләшергә кирәк. Кешенең вөҗданы, намусы бар. Нигә кешене һәрвакыт сынап торырга? Кешегә ышанырга гына кирәк. Телисезме, мин сезгә шигырь укыйм.

Абагалар, абагалар, абагалар—
Чәчәк атмый торган гөлләр алар.
Шуңа күрә дә шул алар оялудан
Урман ышыгына сыеналар.
Абагалар, абагалар, абагалар—
Вазаларга сезне утыртмыйлар.
Әмма сезнең чәчәк аткан төнне көтеп,
Күпме асыл затлар картаялар.

Килер бер көн, күктәге Тәңребез безне бу мәрхәмәтсез җирдән алып китәр. Минем кешеләремнең кадерен белмәде бу җир, мин үземнең кешеләремне кире күккә алып китәм дияр. Һәм космоста кеше үзенең бөеклегенә янадан кайтыр. Җир ул маймыллар өчен, кешеләр өчен түгел. *(Машина гудогы ишетелә. Юныс тәрәзәгә ташлана. Кул болгый. Очып ишек янына бара. Аны ачып тора. Ишектән Азат керә. Юныс аны честь биреп каршы ала.)*

Азат. Здравия желаю, товарищ генерал.

Юныс. Здравия желаю, товарищ маршал. В армии все в порядке.

Азат. Вольно. *(Кочаклап күрешә.)*

Юныс. Ә миндә кунаклар. Искиткеч кешеләр. Минем яшь дусларым. Беләсеңме, алар минем белән килешәләр. Әйе, әйе. Без җирне анабыз дип атыйбыз. Ләкин җир безне улları итеп санамый.

Азат. Әлбәттә, шулай. Син миңа берәр чашка кофе эчер инде.

Юныс. Хәзер, хәзер, улым. Ләкин чашка түгел—касә. *(Кухняга үтеп барышлый, Сәет белән Сәлимәгә.)* Минем улым килгән. Ул һәрвакыт минем белән килешә. Ул минем ачышымны хуплый.

Азат. Мин ашыгам, Юныс Хәербәкович.

Юныс. Хәзер, хәзер... *(Кухняга кереп китә.)*

Азат *(Сәет белән Сәлимә каршына килеп).* Исәнмесез. *(Торып баскан Сәеткә.)* Утыр. Әле син кайтып китмәдеңмени?

Сәет. Юк.

Азат. Акчаны бирдеңме?

Сәет. Юк.

Азат *(Сәлимәгә карап).* Бусы кем?

Сәет. Сәлимә ул.

Азат *(Сәлимәгә).* Син дә акча таратып йөрисеңме? Сәетбәковлар хәер алмыйлар. *(Сәеткә.)* Мин сиңа әйттем бит.

Сәет. Миңа бабай кушты.

Азат. Барыгыз, юлыгызда булыгыз.

Сәлимә. Сез Сәетбәковмы?

Азат. *(Сәлимәгә төбәлеп карап).* Авылдагы бөтен кызлар шулай чибәрме?

Сәлимә. Мин авылдан да түгел, чибәр дә түгел.

Сәет. Сәетбәкова ул.

Азат. Сәетбәкова? Менә монысы кызык. Сәетбәковлар авылда да яшимени?

Сәлимә. Мин—Казанныкы.

Азат. Бәлки, без туганнардыр. *(Сәлимәгә якын ук килеп карап.)* Әлбәттә, туганнар. Менә инде күптән үземә сеңел эзли идем.

Сәлимә *(кухня янына ымлап.)* Ул сезнең әтиегезме?

Азат. Ул—Юныс Хәербәкович. Ул—минем әтиемнең абыйсы. Миңа улым ди. Сәер кешеме? Нигә дәшмисез? Философ ул. *(Касә күтәреп чыккан Юныска.)* Ләкин, абзый, син бигүк хаклы түгел. Җир бит кешене ашата. Әгәр дә җир кешенең дошманы булса, ул аны ашатмас иде. Киресенчә, үзен ашаткан җиргә кеше рәхмәт әйтә белми, җирне кыерсыта.

Юныс. Ә кеше ашарга тиеш түгел. Ашарга аны җир өйрәткән. Фәрештәләр ашамыйлар. Чөнки алар күктә калган, җиргә төшмәгәннәр. Кешенең иң зур дошманы—корсак, улым. Шул корсак аркасында йөрәкне май баса. Йөрәкләрен май баскан кешеләр күбәйде җирдә.

Азат. Шулай, шулай, абзый.

Юныс. Син дә минем белән килешәсең.

Азат. Килешәм, килешәм. *(Сәлимәгә күрсәтеп.)* Менә бу туташ, абзый, Сәетбәковлар токымыннан ди.

Юныс. Бик мөмкин. Чөнки ул фәрештәгә охшаган.

Азат. Диссертацияне язып бетерәсеңме әле?

Юныс *(зур телевизор тартмасы сөйрәп килеп).* Менә беренче бүлеге.

Азат. Давай, давай, дәвам ит. Дәфтәрләрең бармы?

Юныс. Бар. Рәхмәт, улым.

Азат. Булды бу, абзый. Мин киттем. Кунакларыңны да алып китәм. До свидания, товарищ генерал.

Юныс. До свидания, товариш маршал. *(Азат, Сәет, Сәлимә чыгып китәләр. Алар белән урамда янә очрашабыз.)*

Азат. Аны ардырырга ярамый. *(Визит карточкасын Сәлимәгә бирә.)* Шалтырат. *(Сәеткә.)* Бабаңа сәлам әйт. Кызның чибәрен очраткансың, югалтма. *(Китә.)*

Сәет *(кесәсеннән долларын чыгарып).* Менә ул бирде. Кичә. Мафия микән ул?

Сәлимә. Мафия булса, безнең

белән сөйләшеп тә тормый. Теге абзый чыннан да шундый микән ул. *(Визит карточкасына карап.)* Азат Шаяхметович Саетбеков. Шалтыратырга микән? Дәү әбигә шалтыраттырам. Хәзер кемнәргә барабыз?

Сәет. Мина әйтте ул, Казанда буталып йөрмә, диде.

Сәлимә. Юк инде. Эзлибез. Бөтенесен йөреп чыгабыз. Киттек. *(Атлыйлар.)* Сәет, фәрештәләр чыннан да бар микән ул?

Сәет. Белмим.

Сәлимә. Әгәр дә күктән килеп безне алып китәбез дисәләр, син китәр идеңме?

Сәет. Кем килсен.

Сәлимә. Килсәләр?..

Сәет. Карап кайтырга була инде анысы.

Сәлимә. Әгәр дә кайтмаска алып китсәләр?

Сәет. Әллә ышандыңмы шунын сүзләренә?

Сәлимә. Кызык бит. Юк, мин китмәс идем. Казанны сагынып үләрсең.

Сәет. Фәрештәләр үлми инде ул.

Сәлимә. Без бит фәрештәләр түгел. *(Атлыйлар.)* Сәет, әгәр дә жир өстендәге бөтен кешеләр дә бу абзый кебек булса, ничек булыр иде икән?

Сәет. Кем белгән инде аны.

Сәлимә. Син уйлап кара әле, ничек булыр иде икән?

Сәет. Кем белгән инде аны?

Сәлимә. Син уйлап кара әле, ничек булыр иде икән?

Сәет. Һәй, ул турыда уйлап баш ватарга...

Сәлимә. Уйламагач та баш ни өчен соң ул.

Сәет. Уйлар өчен инде, билгеле. Тик разный жүләр уйларны уйлар өчен түгел инде.

Сәлимә. Уйнын жүләре дә буламы?

Сәет. Күрдең бит инде үзең дә.

Сәлимә. Бәлки әле жүләр түгелдер. Кызык бит.

Сәет. Жүләр кеше гел кызык була инде.

Сәлимә. Бәлки кызык кешене жүләр дип уйлыйбыздыр. Син кызык кешеме, Сәет?

Сәет. Театр уйнаганда кызык диләр. Көлдереп үтерәсең диләр.

Сәлимә. Син артистмыни?

Сәет. Авылда гына инде. Укытучылар уйнаттыралар.

Сәлимә. Сәет, әгәр дә мин хәзер абынып егылып аягымны сындырсам, нишләр идең?

Сәет. Нигә син әллә нинди жүләр сораулар бирәсең?

Сәлимә. Бәлки мин жүләрмендер.

Сәет. Итәрсең сине жүләр. Мине сынап барганыңны әллә мин белмимме? Дурак микән бу Сәет, юк микән дип тикшереп барасың. Авылда дурак булсаң яшәп булмый, беләңме? Авылда әле акыллы булып та яшәве авыр, беләңме? Менә син яшәп кара авылда, белерсең аннары. Иртән сәгать өчтә торасың, кояш баегач эт булып кайтып егыласың.

Сәлимә. Алдашма, күрдем инде, күрдем.

Сәет. Нәрсә күрдең, нәрсә күрдең. Син бит пиянчукларны гына күрдең. Эшләгән кешене күрмәдең. Эшләгән кеше Казаннан кайтканнарга күренеп йөрми ул. Авылга кайтып обидка хәтле йоклыйсыз да... Күрдем дигән була.

Сәлимә. Усал икәнсең син.

Сәет. Ачуны китерәсең ич *(атлыйлар)*.

Сәлимә. Син мине ачуланма, Сәет, ярыймы.

Сәет. Ярар.

Сәлимә. Беркайчан, беркайчан да ачуланмыйм, диген.

Сәет. Ярар.

Сәлимә. Син мине бүгеннән башка бүтән күрмисең дә инде. Ачулана да алмыйсың.

Сәет. Ну син минем әтинең хатыны булсаң, әйтер иде ул сина.

Сәлимә. Нәрсә дип?

Сәет. Хватит балтать ерунду, дип. Тәк... Ничәнче йорт була әле монысы? *(Без Сәет белән Салимә керәсе фатирда. Ике Сәлимәне бутамас өчен әлеге фатир хуҗасын Салимә карчык дип язарбыз. Ул кыйшаеп беткән өстәл янындагы кыйшайган табуреткага утырган да мандолина чиртә. Авыз читендә сигарета. Ишектә звонок.)*

Сәлимә карчык *(керүче булмагач)*. Чево звониш. *(Звонок кабатлана. Сәлимә урыннан торып ишеккә бара, ишекне тибеп ача.)* Чево надо?

Сәлимә. Исәнмесез.

Сәлимә карчык. Нәрсә кирәк? У меня ничего нет. Сама беженка.

Сәлимә. Без качаклар түгел, әйбер сорамыйбыз.

Сәлимә карчык. Сорамаучылар да бармыни әле бу илдә? *(Көйләп урынына барып утыра.)* Вперед сказал комбат, сам пошел назад. Ой-ой-ой, ой-ой-ой, пой пока молодой. *(Мандолинада чиртүен дәвам итә. Сәет белән Сәлимә нишләргә белми торалар.)*

Сәлимә. Безгә Сәетбәков кирәк.

Сәлимә карчык. Монда Сәетбәков юк.

Сәлимә. Ә сез?

Сәлимә карчык. Мин—Сәетбәкова.

Сәлимә. Сәетбәкова булса да ярый.

Сәлимә карчык. Сөйләгез.

Сәлимә. Алай килешми инде. Сезгә кунак килгән, сез...

Сәлимә карчык. Ә? *(Сәлимә каршына килеп.)* Кунак? Нинди кунак? Кто вы такие?

Сәлимә. Урын тәкъдим итәр идегез.

Сәлимә карчык. Да?

Сәлимә. Да.

Сәлимә карчык. Ну, ну... *(Сәеткә ишек күрсәтеп.)* Алып чык шуннан. *(Сәет кыйшайган табуретка алып чыккач.)* Бирәү генә. Кавалер басып торыр.

Сәлимә *(утырып.)* Ә сез нигә тәмәке тартасыз?

Сәлимә карчык. Нәрсә—ә?

Сәлимә. Сез бит татар карчыгы.

Сәлимә карчык. А ну-ка вон отсюда. Ычкыныгыз.

Сәлимә. Ычкынмыйбыз.

Сәлимә карчык. Сез кем?

Сәлимә. Ул—Сәет Шәрәфетдинов, мин—Сәлимә Сәетбәкова.

Сәлимә карчык. Сәлимә?

Сәлимә. Сәлимә.

Сәлимә карчык. Сәетбәкова?

Сәлимә. Сәетбәкова.

Сәлимә карчык. Ә мин кем?

Сәлимә. Сәетбәкова дидегез. Исемегезне әйтмәдегез.

Сәлимә карчык. Мин дә Сәлимә. Алдашмыйсызмы?

Сәлимә. Менә паспортым. Карагыз.

Сәлимә карчык. Вот так дела. Вперед сказал комбат и пошел назад. Постойте. *(Кайдандыр фотоаппарат тартып чыгара.)* Бу тарихи вакыйганы тарихка калдырырга кирәк. Сәлимә Сәетбәкова яшьлеге белән очраша. Пой, пока молодой. *(Сәлимәне берничә ракурстан фотога төшерә.)* Ә син чибәр.

Сәлимә. Сез дә чибәр булгансыз.

Сәлимә карчык. Да?

Сәлимә. Да.

Сәлимә карчык. Сәетбәков яки Сәетбәкова сезгә нигә кирәк?

Сәлимә. Сез Хәсәнбәк йә Шаһибәк Сәетбәковны белмисезме?

Сәлимә карчык. Юк, белмим. Мин беркемне дә белмим.

Сәлимә. Ничек инде белмисез. Үзегез Сәетбәкова.

Сәлимә карчык. Булса ни. *(Сәеткә күрсәтеп.)* Ул синең кемең?

Сәлимә. Ул да Сәетбәковларны эзләп йөри. Без Сәетбәковларның шәҗәрәсен төзибез.

Сәлимә карчык. Нәрсә ул шәҗәрә?

Сәлимә. Родословное дерево.

Сәлимә карчык. Вот как. Ә нигә ул бер сүз дә дәшми?

Сәлимә. Ирләр алар иң кирәкле сүзне генә әйтә.

Сәлимә карчык. Да?

Сәлимә Да.

Сәлимә карчык. Син Сәетбәковларга охшагансың.

Сәлимә. Димәк, сез аларны беләсез?

Сәлимә карчык. Юк, белмим. Сәетбәковлар юк. Аларның тамырларын корыттылар.

Сәлимә. Менә ич—сез исән, мин исән.

Сәлимә карчык. Алар юк. Мин дә юк. Бетерделәр.

Сәлимә. Ничек бетерделәр?

Сәлимә карчык. Син нәрсә төпченәсең? Әйттеләр бит—бетерделәр. Гулагны беләсезме?

Сәлимә. Беләм. Совет төрмәсе.

Сәлимә карчык. Вот мин шул лагерьның кызы. Шунда туган. Әтине атканнар, әни үлгән. Анладыңмы? Мин беркемне белмим. Анладыңмы? Родословное дерево да? Срубили его. Кистеләр. Мин син эзләгән агачтан түгел.

Сәлимә. Әтиегезнең исемен дә белмисезме?

Сәлимә карчык. Язганнар. Мартазовна. Вот так милая девочка. *(Ишек ачыла, анда таушалып беткән бер бәндә күренә. Сәлимә карчык аның кырына килә.)* А ну-ка вон отсюда. Иди, иди, у меня гости. Кому говорят. Пузырек оставь. *(Бәндәнең сәләмәсе*

*арасыннан шешә тартып алып, тегене төрткәләп чыгара. Үзе көйләп өстәл янына килә.)* Вперед сказал комбат, сам пошел назад. Пой, пока молодой.

Сәлимә. Сез аракы да эчәсезмени?

Сәлимә карчык. Эчәм.

Сәлимә. Эчмәгез. Минем дәү әбием әйтә, иң начар хатын-кызлар гына аракы эчә ди.

Сәлимә карчык. Әбиеңә сәлам әйт, ярыймы.

Сәлимә. Эчмәгез. Сез бит Сәетбәкова. Сез бит морзалар нәселеннән. Сез бит татар әбисе.

Сәлимә карчык. Да?

Сәлимә. Да, да... Әйе, әйе, әйе. Эчмәгез, үтенеп сорыйм.

Сәлимә карчык. Сез мине тәрбияләргә килдегезме?

Сәлимә. Юк, юк. Мин үтенеп сорыйм. Сәет, син дә үтен. Үтен инде, Сәет.

Сәлимә карчык. Үтен инде, Сәет, үтен. *(Сәет аның кулыннан шешәсен алгач.)* А ну-ка отдай, сопляк. Кому говорят. Кемгә әйтәләр. *(Кинәт Сәетнең күзенә карап.)* Постой. *(Кабаланакабалана Сәетне төрле яктан фотога төшерә.)* Смотри какой он. *(Сәлимәгә.)* Бас әле аның янына. *(Сәлимәне Сәет янына бастырып икесен фотога төшерә.)* Синең иреңме ул?

Сәлимә. Юк.

Сәлимә карчык. Яратасың что ли?

Сәлимә. Без кичә генә таныштык.

Сәлимә карчык *(Сәеткә)*. Бир. Эчмим.

Сәлимә. Бир, Сәет.

Сәлимә карчык *(Сәет биргән шешәне алып куеп, Сәлимәгә)*. Ярат син аны.

Сәлимә. Сез фотографмы?

Сәлимә карчык. Идем. В Магадане. Ә монда... Вперед сказал комбат, сам пошел назад.

Сәлимә. Балалайкада уйныйсызмы?

Сәлимә карчык. Балалайка түгел ул—мандолина.

Сәлимә. Уйнап күрсәтегез.

Сәлимә карчык. Да?

Сәлимә. Да.

Сәлимә карчык. Что ж. *(«Гөлҗамал»ны уйный. Уйнаудан туктап.)* Беләсезме бу көйне?

Сәлимә. Әйе.

Сәлимә карчык. Мин аны монда кайткач өйрәндем. *(Карлыккан, ләкин әле моңын югалтмаган тавыш белән җырлый.)*

Шәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлҗамал,
Житкән кызлар киндер жеп эрлиләр.
Энже-мәржән кызларның кулбавы,
Авыр жан сөйгәннәрнен булмавы.

*(Җырлап туктагач, тын гына, селкенмичә елап утыра.)*

Сәлимә *(ул да кушылып елый)*. Эчмәгез сез, тәмәке дә тартмагыз... Балаларыгыз бармы?

Сәлимә карчык. Юк. Бер кемем дә юк минем. *(Тәмәке алып кабыза.)*

Сәлимә. Тартмагыз.

Сәлимә карчык. Замолчи. Бер сорау да бирмә. Бер сорауга да җавап бирәсем, бер кем белән дә сөйләшәсем килми. Аңладыңмы? Һәм яшисем дә килми дөньягызда. Пычрак ил, пычрак бәндәләр. Гулагтан. Тоткыннар һәм аларны саклаучылар. Бүтән беркем дә юк бу илдә. Кил әле яныма. Кил, җирәнмә. Мин сезнең бөтенегездән дә чиста. Мин ике сәгать саен юынып илегезнең пычрагыннан арынам. *(Сигаретасын тәмәке савытына куеп, янына килгән Сәлимәне кочаклый.)* Сәлимә... Сәлимә... Рәхмәт мине эзләп килүеңә.

Сәлимә. Сәет белән икәү.

Сәлимә карчык. Аңа да рәхмәт. Язмыш безне бу пычрак илдә туарга мәҗбүр иткәнгә син дә, мин дә гаепле түгел. Алла сиңа ни көткәнне бирәү дә белми. Пычратырлар, сине дә пычратырлар. Чүп базыннан чиста чыгып булмый.

Сәлимә. Нигә инде алай дисез?

Сәлимә карчык. Дәшмә. Ачуланма мине. Мин берни дә онытмадым. Телемнән биздергәннәр иде— өйрәндем, бабайларымның моңыннан биздергәннәр иде өйрәндем. Яшим әле мин. Оныттырырга телиләр, берсен дә онытмыйм. Бу пычрак тарихның шаһиты мин. *(Сәлимәнең буй-сынына сокланып карап торып.)* Сакла үзеңне. *(Сәеткә.)* Кил әле монда. *(Сәет селкенмәгәч.)* Кил диләр. *(Теләртеләмәс кенә килгән Сәеткә.)* Сакла аны. Карашың ышанычлы синең. *(Сәлимәгә.)* Сыен аңа. Барыгыз.

Сәлимә. Сәлимә апа...

Сәлимә карчык. Ничек, ничек?

Сәлимә. Сәлимә апа... Сәлимә апа, без Сәет белән...

Сәлимә карчык. Барыгыз... Барыгыз, диләр.

Сәлимә. Сәлимә апа, сезнең янга тагын килергә...

Сәлимә карчык. Юк. Юк!.. Юк!.. *(Сәет белән Сәлимә чыгып киткән ишекне каты итеп ябып бикләп куя да өстәл янына килеп кулына шешәне ала.)* Вперед сказал комбат, сам пошел назад. Пой, пока молодой. *(Урамда Сәет белән Сәлимә.)*

Сәлимә. Кайтыйк, Сәет, минем берәүне дә эзлисем килми. Мин куркам, Сәет.

Сәет. Нәрсәдән?

Сәлимә. Күрдең ич.

Сәет. Исерек күргән саен курка башласаң.

Сәлимә. Сәет! Ни сөйлисең син?! Исерек түгел иде ул. Исерек түгел иде, түгел иде!

Сәет. Нишлисең син?

Сәлимә. Кит, кит! Синнән дә куркам. Бар, кайтып кит авылыңа. Кирәкми синең акчаң. Нәрсә син өч миллион акчаң белән мактанып йөрисең. Тун йөрәк син.

Сәет. Нишлисең син, ә?

Сәлимә. Яратмыйм мин сине.

Сәет. Нәрсә кычкырасың? Әллә мин сине ияртеп чыктыммы? Үзең иярдең. Нәрсә пырлыйсың? Нәрсә әйттем ул кадәрле.

Сәлимә. Син шундый тыныч. Берни булмаган кебек. Берни ишетмәгән кебек, берни күрмәгән кебек.

Сәет. Мин күрмәгәнме, мин ишетмәгәнме? Авыл тулы пиянчук. Әчәләр дә акчалары беткәч жылап йөриләр. Әйтерсең бүтәннәр гаепле. Минем әти дә жыламый, әни дә жыламый, бабай белән әби дә жылamыйлар. Әти бер салып кайткан иде, бабай янак төбенә утыртты да вәссәләм булды. Миңа дә әти әйтте, әгәр кулыңда шешә күрсәм, башыңны бот арана кыстырып куям диде. Малайлар миннән көләләр, мин барыбер эчмим. Эчмәячәкмен дә. Хатыныма да, балаларыма да эчертмәячәкмен. Эчкән кешене кызганмыйм да—үлсен, бетсен, дөнья сасытып йөрмәсен. Нәрсә миңа кычкырасың?

Сәлимә. Анламыйсың син...

Сәет. Анламаска, дурак мәллә мин...

Сәлимә. Бәхетсез ул. Әтисен үтергәннәр, әнисе үлгән.

Сәет. Синең дәү әниеңнең дә улы, оныгы үлгән, эчми бит. Син дә эчмисең.

Сәлимә. Әйдә, эзлибез.

Сәет. Миңа кычкырмасаң гына йөр. Бабай әйтте: йөри торган кызың бер генә тапкыр сиңа кычкырса да, аңа өйләнмә, диде. Өйләнгәч, көнене мең тапкыр кычкырачак ул диде. Гөлсинә бер генә кычкырган иде, киттем дә бардым, янына бүтән бармадым да. *(Атлыйлар.)*

Сәлимә *(паузадан соң).* Нәрсә дип кычкырды Гөлсинә?

Сәет. Ялгыш аягына баскан идем, сыер дип кычкырды.

Сәлимә. Алай ук ярамый инде. *(Паузадан соң.)* Сәет, син Сәлимә апаны кызганмадыңмы?

Сәет. Кызганмаска, жырлаган чагында күздән яшьләр килде... Бергә төшкән карточканы алып булмый инде анардан, әйеме?

Сәлимә. Килмәскә кушты.

Сәет *(паузадан соң.)* Дөнья куласа шул.

Сәлимә. Нәрсә дисең, Сәет?

Сәет. Куласа дим. Жырлата да, жылата да.

Сәлимә. Сәет, Гөлсинә чибәр идеме?

Сәет. Ыһы.

Сәлимә. Ә мин чибәрме?

Сәет. Ыһы.

Сәлимә. Юри генә әйтәсең инде.

Сәет. Син тавык кебек, гел кирегә генә тырмалыйсың. Әйткәнәр бит инде сиңа чибәр дип.

Сәлимә. Яратмыйм мин сине дип, мин ялгыш кына әйттем.

Сәет. Беләм инде.

Сәлимә. Син бөтен нәрсәне беләсең, әйеме, Сәет?

Сәет. Дурак түгел ич мин.

Сәлимә. Сәет, мин арыдым.

Сәет. Әйдә, утырып ял итәбез.

Сәлимә *(сүзсез генә утырганнан соң).* Беләсеңме, Сәет, гашыйк булыр өчен унбиш секунд вакыт житә икән. Яратыр өчен бөтен гомер дә житми икән.

Сәет. Унбиш секунд?.. Бер, ике, өч... Күп ич ул. Бер карап алуга ничә секунд кирәк.

Сәлимә. Сәет, син миңа гашыйк булыр идеңме?

Сәет. Юк, ярамый.

Сәлимә. Нигә?

Сәет. Гашыйк булгач өйләнергә кирәк. Безгә өйләнешергә ярамый.

Сәлимә. Ник?

Сәет. Мин Казанга килмим, син авылга кайтмыйсын.

Сәлимә. Каян беләсең?

Сәет. Белмәскә. Дурак түгел ич мин. Мине син Казанга кыйнап та китерә алмыйсын. Бабай әйтә, Казанга сыймыйм мин ди. Сулышым кысыла ди. Таш базга бикләп куйган кебек ди. Мин дә шулай. Казан кызлары авылдан курка. Анда эшлисе бар. Иртән иртүк торасы бар. Ирен буяп йөрергә вакыт юк.

Сәлимә. Син әллә нинди, Сәет.

Сәет. Син дә әллә нинди инде.

Сәлимә. Нинди? Менә әйт әле, мин нинди?

Сәет. Әйтмим.

Сәлимә. Әйт инде.

Сәет. Әйтмим диделәр бит инде сиңа.

Сәлимә. Әгәр дә мин авылда булсам, миңа гашыйк булыр идеңме, Сәет?

Сәет. Ну башны әйләндерәсең син, ә? Дәү әбиең ничек түзә синең. Әйттеләр бит инде сиңа. Анда булсам, монда булсам. Булмагансың бит инде. Нәрсә аны. Минем бер дус малай бар. Хәмит. Шул тотына. Мин Америкада булсам, мин Японияда булсам. Триллион тәнкә акчам булса... Хыялый.

Сәлимә. Син хыялланмыйсынмы?

Сәет. Була инде ул. Ну Хәмит кебек түгел инде. Менә өй саласы бар. Машина аласы бар.

Сәлимә. Өегез юкмыни?

Сәет. Ну кызык син, ә. Ничек инде булмасын. Анысы бит анын әти өе. Минем үз өем булырга тиеш. Төп йортта энекәш кала. Ир кеше үз гомерендә бер өй салырга тиеш, беләнеңме? Сезнең Казанда гына бит ул, квартир бир, квартир бир дип жылап яталар. Миңа үз өем кирәк. Шул өйне тотарлык хатын кирәк. Белдеңме инде?

Сәлимә. Белдем.

Сәет. Белсәң—шул. Разный чипуха сораулар бирмә.

Сәлимә. Син картлар кебек сөйләшәсең.

Сәет. Авылда да миңа әйтәләр. Дурак түгел ич мин балалар кебек сөйләшергә.

Сәлимә. Кызык та түгел синең белән сөйләшергә.

Сәет. Кызык булмаса сөйләшмә. Кызык кеше белән сөйләш.

Сәлимә. Сау бул.

Сәет. Хуш. *(Китә. Сәлимә басып кала, Ләкин «Сәет!» дип, Сәет артыннан чыгып йөгерә.)*

**Тагын бер Сәетбәковлар фатиры. Анда яңа гына өйләнешкән пар—Алимбәк белән Гөлгенә. Алар туй күлмәкләреннән. Бүлмә буйлап бөтереләләр, кочаклашалар, сөешәләр. Гомерләренең иң бәхетле мизгеле. Менә алар бүлмә уртасындагы затлы итеп җыештырылган затлы карават янына туктыйлар да көлешә башлыйлар.**

Алимбәк. Нигә көләсең?

Гөлгенә. Ә син нигә көләсең?

Алимбәк. Мин туктадым.

Гөлгенә. Мин дә.

Алимбәк. Бу безнең караватыбыз, Гөлгенә.

Гөлгенә. Беләм. Синең әниең әйтте.

Алимбәк. Ул инде хәзер синең дә әниең.

Гөлгенә. Мин аңа әнкәй дидем. Минем әнием синең әниеңә шулай дәшәргә кушты. *(Караватка карап.)* Чыннан да ике йөз ел микән бу караватка? Бер җире дә тырналмаган.

Алимбәк. Аны гел янартып торалар. Менә без дә, Гөлгенә, үзебезнең улыбызга аны шул килеш калдырырга тиешбез.

Гөлгенә. Кызларга калдырырга ярамыймы?

Алимбәк. Юк. Сәетбәковлар нәселе дәвам итәргә тиеш. Шуңа күрә дә яңа өйләнгән Сәетбәковлар беренче төнне шушы караватта үткәрәләр. Нигә безне монда ябып куйганнарын аңладыңмы инде? Сәетбәковлар нәселе дәвам итәр өчен. Бу тылсымлы караватт. Аны Хәсәнбәк Сәетковның бабасы Париждан алып кайткан. Махсус эшләткән. Бу караватта йокласаң, бары тик егетләр генә туа, Гөлгенә. Мин инде туачак улыбызга исем дә сайлап куйдым. Рәимбәк. Алимбәк улы Рәимбәк Сәетбәков.

Гөлгенә. Ә ул исем миңа ошамаса?

Алимбәк. Ошарга тиеш. Мине

ошаткач минем сүзем дә ошарга тиеш. Кызыбыз туса, исемен дә син табарсын.

Гөлгенә. Рәхмәт инде. *(Көлешәләр.)*

Алимбәк. Өйләнгәнче мин сиңа әйтмәдем, Гөлгенә. Мин бик явыз ир булачакмын. Әгәр дә син минем сүземә каршы чыксаң, беләсеңме мин сине нишләтәчәкмен?

Гөлгенә. Нишләтәчәксең?

Алимбәк. Әйдә, сүземә каршы чыгып кара әле.

Гөлгенә. Ничек?

Алимбәк. Мин синеңчә эшләргә теләмим, Алимбәк Сәетбәков диген.

Гөлгенә. Мин синеңчә эшләргә теләмим, Алимбәк Сәетбәков.

Алимбәк. Әһә, әле син шулаймы? Син минем сүземә каршы чыгасыңмы? Хәзер, хәзер, эләгәчәк сиңа. Нинди җәза уйлап табыйм икән? Кил әле монда, бас әле шунда. Җырла.

Гөлгенә. Җырламыйм.

Алимбәк. Әһә, тагын тыңламыйсыңмы? Алайса өч җыр җырлыйсың.

Гөлгенә. Җырламыйм.

Алимбәк. Алай итмә инде, Гөлгенә. Минем авторитетны төшермә инде. Сәетбәковлар нәселендә ирләр сүзен хатыннары тыңлаган.

Гөлгенә. Якушевлар нәселендә кызлар бер кайчан да кол булмаганнар.

Алимбәк. Җырламыйсыңмы?

Гөлгенә. Җырлыйм. Ләкин үзем теләгән җырны, үзем теләгән вакытта.

Алимбәк. Алай булмый.

Гөлгенә. Була.

Алимбәк. Талашабызмы?

Гөлгенә. Юк.

Алимбәк. Нишлибез?

Гөлгенә. Белмим.

Алимбәк. Кызык икән син. Син минем хатыным ич инде. Ир белән хатын нәрсәдер эшләргә тиеш ич инде.

Гөлгенә. Белмәгәч, өйләнмәскә иде.

Алимбәк. Белмәгәч, кияүгә чыкмаска иде. Әйдә үбешәбез.

Гөлгенә. Әйдә. *(Ишектә звонок.)*

Алимбәк. Кем булырга тиеш бу? Әйдә әле, карыйк әле, кем безнең тынычлыкны бозып йөри? Ачабызмы?

Гөлгенә. Кемнәр икәнен белик. *(Чыгып керәләр дә Сәет белән Сәлиманы ияртеп керәләр.)*

Алимбәк. Әйе, без Сәетбәковлар булабыз. Мин Алимбәк Сәетбәков, ә минем хатыным—Гөлгенә Сәетбәкова. Безнең кечә туебыз үтте, бүген безне монда бикләп куйдылар. Сезнең кем икәнлегегезне, ни өчен килгәнегезне әлегә сорамыйбыз. Безнең бу фатирыбызга без барында килгән беренче чит кешеләр—сез. Без сезгә ачык күңел белән ишек ачтык. Сез безгә үзегезнең безгә теләгән теләкләрегезне әйтегез.

Сәлимә. Ничек?

Алимбәк. Безгә ничек булса да ярый. Сүзегезгә карап үзегезнең кем икәнлегегезне белербез.

Сәлимә. Сәет...

Сәет. Ә нигә мин?

Сәлимә. Син эзлисең бит Сәетбәковларны.

Сәет. Ә син үзең Сәетбәкова.

Сәлимә. Син егет кеше.

Сәет. Син телгә оста.

Сәлимә. Яхшы, яхшы... Әйтәм. *(Алимбәк белән Гөлгенәгә.)* Ә сез чынлапмы?

Алимбәк. Без бик житди кешеләр.

Сәлимә. Яхшы... Болай... мөмкинме, мин сезгә җырлыйм.

Алимбәк. Монысы да бигрәк яхшы.

Сәлимә. Тик сез көлмәгез. Юк, җырламыйм, шигырь генә сөйлим.

Галибанә яктырып әкрен генә ал таң ата,
Моңланып, хәсрәтләнеп ялкау гына ак ай бата.

Бу—Тукай шигыре. Мин аны бик яратам. Шуңа күрә сезгә багышладым. *(Алимбәк белән Гөлгенә, рәхмәт әйтеп, Сәлиманы кочаклыйлар.)*

Алимбәк *(Сәеткә)*. Синең чират.

Сәет. Минем сүзем юк. Мин бабайның абый туенда әйткәннәрен генә әйтә алам. Ярыймы соң шулай?

Сәлимә. Әйт, Сәет, әйт.

Сәет.

Өйләндеңме—ахылдама,
Кияүгә чыктыңмы—уфылдама,
Иреннең кәефе юк чакта хыйхылдама,
Хатының кәефсез булса, хахылдама,
Иреннең колак төбендә тырылдама,
Хатының кыек сүз әйтсә,пырылдама,
Чит хатыннарга сүз салып ихылдама,
Чит ирләрнең каршысында михылдама.
Хатының яратам дисә, гырылдама,
Ирен яратам дигәндә шырылдама,
Акча житми дип иренә мырылдама,
Хатының акча сораса, ырылдама.
Өйдә булганны урамга бакылдама,

Өлкәннәр алдында туктаусыз такылдама.
Чырылдама, шырылдама, ысылдама, пысылдама,
Чупырдама, тыпырдама, шыелдама, чыелдама...

Җиттеме шулар? *(Көлешәләр.)*

Алимбәк. Бетерде бу безне, Гөлгенә. Исемең Сәет бит, әйеме?

Сәет. Сәет.

Алимбәк. Сез дә ирле-хатынлымы?

Сәет. Юк.

Алимбәк. Кемнәр сез?

Сәлимә. Без Хәсәнбәк Сәетбәков дигән кешенең туганнарын эзлибез.

Алимбәк. Сез дөрес кергәнсез. Сезнең каршыгызда Хәсәнбәк Сәетбәковның оныгының оныгы Алимбәк Сәетбәков һәм аны хәләл җефете Гөлгенә Сәетбәкова.

Сәет *(акча чыгарып, Алимбәккә бирә)*. Бу сиңа инде алайса.

Алимбәк. Нәрсә бу?

Сәлимә. Акча ул. Хәсәнбәк Сәетбәковтан Сәетнең бабасы акча алып торган булган... *(Ул арада Сәет чыгып китә, Сәлимә аның артыннан иярә. Ул Сәетне урам чатында гына куып тота.)* Сәет! Сәет! Нишлисең син ә? Нигә качасың?

Сәет. Йөри-йөри арыдым инде мин. Ату монысын да алмыйм дип ялындыралар. Болай да инде ике көн йөрим. Тырай тибеп йөрергә авылда эш бетмәгән.

Сәлимә. Син шундый да матур итеп әйттең, Сәет. Минем әле андый сүзләрне ишеткәнем дә юк иде.

Сәет. Минеке түгел ич ул сүзләр—бабайныкы. Салих абыйларның туенда әйтте дә, кодагый әби әйтә—кайдан уйлап чыгардың боларны, кода, ди. Син дә әйбәт әйттең. Мин Тукайның андый шигыре барлыгын да белми идем.

Сәлимә. Бәхетле булсыннар инде инде.

Сәет. Кемнәр?

Сәлимә. Алимбәк белән Гөлгенә.

Сәет. Син тикшереп тор. Туганнарың ич.

Сәлимә. Сәет, кочакла әле мине, ә?

Сәет. Ярамый.

Сәлимә. Әз генә. Кочагына гына сыенып торыйм. Әз генә. Минем кемнеңдер кочагына сыенасым килә. Дәү әбием янымда булса, аның кочагына сыенып идем. Сыенасым килә, Сәет. Мине яклаучы булсын иде. Минем кызым дип әйтүче булсын иде, минем сеңелем дип әйтүче булсын иде.

Сәет. Шулай инде анысы. Абыең булса яхшы. Минем дә Салих абый булгач яхшы иде. Өйләнде дә мина күңелсез калды. *(Кочагына кереп сыенган Сәлимәгә.)* Кара, син бәләкәй икән. Минем әни дә бәләкәй. Әти әйтә, сандугач зур булмый ул ди.

Сәлимә. Сәет, гашыйк бул инде миңа.

Сәет. Мин гашыйк булдым инде ул. Әллә кайчан инде. Урамда беренче очратканда ук. Ярамый гына. Менә бүген авылга кайтып китәм дә, каласың.

Сәлимә. Калмыйм.

Сәет. Ничек инде калмыйсың?

Сәлимә. Мин сине котәрмен.

Сәет. Килеп алганымныммы? Алай җинел генә түгел ул.

Сәлимә. Мин сине көтәрмен.

Сәет. Килмәсәмдәме?

Сәлимә. Минем дәү әби дәү бабайны һаман да көтә. Сугышта үлгән дәү бабай.

Сәет. Мин кайтып киткәч онытырсың да әле. Казанда егетләр күп.

Сәлимә. Синдәе юк.

Сәет. Син инде бигрәк. Ике көн эчендә.

Сәлимә. Гашыйк булу өчен өч секунд та вакыт җитә. Үзең әйттең.

Сәет. Мин әйтмәдем аны, син әйттең.

Сәлимә. Мин унбиш секунд дидем. Сәет, син елмаясың, әйеме?

Сәет. Каян күрәсең?

Сәлимә. Сизәм. Син елмаясың, Сәет, елмаясың. Димәк, мине яратасың, яратасың...

*Пәрдә.*



## Фарсель Зыятдинов

### КӨЗГЕ КОЯШ ТАУГА СЫЕНГАНДА

**Мин килермен әле кабат...**

Канат җәеп очып барам кебек
Фани дөнья аша чиксез күккә—
Мәңгелектән кабат Мәңгелеккә...
Еллар үткәч бер килермен әле
Аккош булып шушы үзәнлеккә—
Гашыйк булып Сезнең гүзәллеккә.

Бер генә кат килмәс әле җаным
Кунак булып шушы җирләргә:
Дөнья куып, бәхет эзләргә.
Чәукә булып килсә әгәр җаным,
Ашыкмагыз мине тиргәргә—
Чәукәләр дә кирәк илләргә!

Канат җәеп очып барам кебек
Фани дөнья аша Мәңгелеккә,—
Мәңгелеккә—чиксез зәңгәр күккә.
Зәңгәр күкләр аша килермен күк
Аккош булып шушы үзәнлеккә,
Гашыйк булып сезнең гүзәллеккә...

Көзге кояш, соңгы нурын сирпеп,
Сыенганда таулар артына,
Белмим үзем, күңелем никтер
Шул тауларга таба тартыла.

Фарсель ЗЫЯТДИНОВ *(1937) - язучы, икътисад фәннәре кандидаты, балалар өчен язылган шигырь һәм проза китаплары авторы. Казанда яши.*

Баксам кайчак шул тауларга кабат,
Нурсыз тауга кояш охшаган:
Әллә якынлаша баешларым,
Әллә күңелем нурга сусаган?!.

## Кемнәр килә?

*Тик гамьсезгә нәрсә аңа—*
*Килгән ни дә киткән ни...*

Фәннур Сафин

Иң яраткан, күңел тарткан дуслар,
Ник китәсез җирдән бик иртә?
Сизенде шул күңелем, сизенде—
Тәңребезме алдан сиздертә?
Әйтелмәгән күпме җылы сүзләр,
Җырланмаган җырлар калды ла...
Күпме хыял, күпме бөреләр
Ачылмыйча гына яндылар—
Җимеш бирә алмый тындылар.
Янар җаннар иртә китә, диләр,
Халык әйтсә инде хак әйтә...
Сезнең эздән гамьсез җаннар килә,
Күңелемне шунсы сагайта—
Битарафлар безне вагайта.

## Кыяташлар булып...

Вәхшилектән ничек туйганымны
Белсәң иде әгәр син, белсәң...
Кыяташлар булып калкыр идем,
Менәреңне әгәр мин белсәм.

Туйдым, дускай, туйдым вәхшилектән,
Җаным туйды талау, алдаудан.
Телен, денен сатып алданганнар
Котыла алмый бүген ялганнан.

Учларымда учак ягар идем,
Кызганмыйча әгәр син түзсәң.
Мәңгелеккә китеп барыр идем,
Килереңне әгәр мин белсәм.

Тере килеш йотар кебек бары,
Сыгыла калсаң әгәр, бил бөксәң.
Кыя ташы булып калкыр идем,
Менәреңне әгәр мин белсәм.
Менәреңне әгәр мин белсәм...

## Озатырга килми калма

Вакыт дигән тар булса да дөньялыкта,
Соңгы юлга озатырга килми калма.
Килми калсаң, керермен дә төшләреңә,
Уяныргсың мине уйлап иртә таңда.

«Үлеләрдән шикләнәм» дип, берүк, яме,
Соңгы юлга озатырга килми калма.
Рухым минем исәннәргә зыян салмас,
Тик тереләр куркыныч ул—шуны аңла.

Таш атканга дөньялыкта аш аттым мин,
Үч тотмадым беркемгә дә—шуны аңла.
Юк-бар нәрсә саклап күңелемдә миңа,
Соңгы юлга озатырга килми калма.

Йөзләремә бер моңаеп карыйм, дисәң,
Соңгы юлга озатырга килми калма.
Барыбыз да кунак кына бу дөньяда,
Чират җитсә, күңелеңә авыр алма,
Ә шулай да озатырга килми калма.

Ера-ера зәгыйфь тамырларны,
Кайнар каным кая ашкына?
Бармакларда минем капиллярлар
Ярылалар, түзми басымга.

Ә тарайган саен тамырым юлы,
Тибә йөрәк, тибә көчлерәк.
Китәр өчен шундый уңай вакыт...
Тик, китәсе килми, ди йөрәк.



## Резидә Әхтәмова

### СӨЯРГӘ, СӨЕЛЕП ЯШӘРГӘ

Төн.
Без ятабыз дүртәү.
Ачык күзләр сиңа
төбәлгәннәр:
Иртәгесен ризыклы кыл,
Раббым,
Иртәгесен уңышлы кыл,
Раббым,
Балаларым насыйблы кыл,
Раббым—
Рәхмәтеңнән безне ташлама.

Алар нәни,
Алар бәби әле—
Бу дөньяда берни
аңламыйлар:

Резидә ӘХТӘМОВА—*шагыйрә, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, «Хисләреңне җилгә чәчмә...» исемле китап авторы. Казанда яши.*

«Миңа әннә мәми алып
кайтты
Миңа әттә тәти
алып кайтты»,—
Диеп, алар
Үзләре күк нәни,
Үзләре күк бәби
дусларына
Берсен-берсе узып
мактаналар.
Чәбәк-чәбәк итеп
шатланалар.

Төн.
Без ятабыз дүртәү,
Ачык күзләр—
Ачык дүрт күз
Сиңа төбәлгәннәр:
Иртәгесен ризыклы кыл,
Раббым,
Иртәгесен уңышлы кыл,
Раббым,
Рәхмәтеңнән безне ташлама.

Мендәр аерам,
мендәр аерам әле—
Мамыклары оча
җилләргә.
Сыяр чакта да без
сыя алмадык
Ак мамыктан тулган
мендәргә...

Сөелергә теләп
башым салдым—
Елый-елый,
үксеп уяндым...
... Хәзер инде...
Берсе—сиңа булыр,
Берсе—миңа булыр
сыңарның...

Сыңар мендәремә
башым салып,
Сине сагынып
үксеп елармын...

*(Бер килен монологы)*

Минем дә булгандыр хыялым—
Ап-актан бәхетле булырга,
Яраткан яр белән тормышны
Чәчәкле болындай узарга.

Минем дә булгандыр хыялым—
Сөяргә, сөелеп яшәргә.
Минем дә булгандыр хыялым—
Пыскырга түгел һич—
яшьнәргә!

Ап-актан бәхетле булмадым,
Туй үткәч, төн буе еладым:
«Сөексез яр булдым.
Сөексез яр булдым—
Бәхетсез канатка
Бәхетсез пар булдым».

Бәхетсез нигезгә
Ап-актан төштем мин.
Бәхетсез нигезгә
Пар чиләк тутырып,
Тамчысын да түкми
Саф сулар керттем мин.

Бәхетсез канатка пар булдым—
Гомерем юллары тоташ яшь,
зар булды...

Сыек томан артларында
Алсу рәшә:
«Бу—мин, синең бәхетең»,—диеп
Мине дәшә.

Кайнар чүлнең өсләреннән
Елан булып шуышып карыйм.
Бөркет булып очып карыйм,
Үрмәкүчтәй ятьмә үреп,
Шул томанны сөзеп карыйм.

Сыек томан артындагы
Алсу рәшә
Ничә еллар инде—мине
Үзенә дәшә...



## Луиза Янсуар

### БАРЫСЫ ДА—ЯРАТУДАН!..

Күкрәгеңдә моңнар шавын тоям:
Йөрәк ярлары да тардыр сыман.
Кабырчыктан ишетелгән көй күк—
Сихерләрлек көче бардыр сыман...
Күкрәгеңдә моңнар шавын тоям.

*Луиза ЯНСУАР (1981) —шагыйрә, «Күзен ача умырзая» исемле китап авторы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

Күкрәгеңдә еллар шавын тоям:
Мәңге тынгы тапмас давыл сыман,
Хәтер упкыннарың актарып да,
Җаның кабат йолкып алыр сыман...
Күкрәгеңдә еллар шавын тоям.

Күкрәгеңдә... чорлар шавын тоям:
Учак җыры, хәнҗәр чыңы сыман...
Далаларга җәелеп, иңри-иңри
Җанга күчкән сорнай моңы сыман—
Күкрәгеңдә чорлар шавын тоям!

Сиңа түгел, язмышыма рәнҗим
Очраштырган өчен артык соң.
Мин бит синең бәгырь түрләреңә
Үкенечкә кергән актык моң.

Сиңа түгел, язларыма рәнҗим:
Әверелсә алар көз булып,
Без кавыша алыр идек, бәлки,
Яфрак дулкынына кушылып.

Сиңа түгел, мәхәббәткә рәнҗим,
Таба алмаган өчен шундый көч:
Таулар күчеп, сулар үргә аксын,
Тик калмасын булып үкенеч!

## Яратудан...

«Нигә шулай газаплыйсың?»—
Күзләреңдә сорау туган.
Күкрәгеңә сарылам, елап:
—Яратудан! Яратудан!

—Нидән кинәт читләшүең?
Йөрәк—гүя кыргый болан.
Аһ, аңлата алсам икән(!)—
Яратудан! Яратудан!

Елауларым, шашуларым,
Рәнҗүләрем хәтта булган:
—Аңла гына, бердәнберем,
Барысы да—яратудан!..

Китәсеңне беләм... иртәрәк...
Аһ, соң ничек Синсез калырмын?!
Йөрәгемне ал Син үзең белән!
Бәлки...
Мин йөрәксез яши алырмын?!

## Монда

Ә кайдадыр үргә ага сулар.
Күкләр тигез бага һәркемгә.
Монда... ярым тере күләгәләр
Кулын суза ярты телемгә.

Монда ятим, үксез җаннар йөри,
Учларына салып йөрәген.
...Сусап кипкән иреннәргә тамар
Мәрхәмәтен көтеп Күкләрнең...

## Кирәк

Эткә—оя.
Бөркеткә—таш кыя.
Юлчыга—юл.
Һәм наз—үксезгә.
...Синнән—миңа, синнән миңа җитә
Җан җылытыр өчен бер сүз дә!..

Син Сөюдән өлкән булалмасаң,
Мин яшьрәк була алмам аннан.
...Безгә кадәр яшәү булмагандай,
Бар дөньяны ялкын биләп алган.

Күкләрнеңме иңгән мәрхәмәте,
Тууымы Җирнең өр-яңадан?!
...Сине сабый иткән икән Сөю,
Мин дә аннан өстен була алмам!

Эзләреңә Синең тезләндем дә,
Мин ант иттем. Шаһитларым—
Җир, Күк.
Бүгеннән, дип, минеке дә булыр
Аның юлы. Һәм кыйблабыз бер үк.

Таулар кичәр сәйяр дәрвиш гүя—
Йөземә нур иңде, җаныма—гамь.
Сәфәр—озын. Һәм төбәлгән миңа
Синең күзләр аша бөтен Галәм!..

Яраларын ялыйм җанның,
Кача-поса ят күзләрдән.
Һәр күзәнәк саен бер уй:
Аһ, тапсалар...
Бу эзләрдән?!

Аһ, тапсалар... Яңа хөкем.
Яңа җәза. Яңа газап...
Чытырманнар күкрәгенә
Яшеренәм, җанны каплап.

Яраларны ялыйм. Ялгыз
Айга карыйм күтәрелеп.
Яшьле күзләр белән багып:
—Бу—Тәкъдирең!—
ди Мәңгелек.

**Фәүзия Бәйрәмова**

# АК ҺӘМ КАРА КӨРӘШЕ

Укыгач та онытылган әсәрләр була, еллар үткәч тә һаман онытылмыйча, кайта-кайта уйландырган әсәрләр дә бар... Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» повестен мин соңгылар рәтенә кертер идем—бу әсәрне берничә ел элек укып чыксам да аның хакында кайта-кайта уйланам, күнелемә шулай көчле тәэсир иткән әсәр турындагы фикерләрем башкалар белән дә уртаклашуны көтә... Дөресрәге, «Өч аяклы ат» повесте, инде менә ничә ел хаксызга онытылып, үзе турында фикер әйтүне көтә, гадел бәя көтә...

Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» повесте башта 1993 елда «Казан утлары» журналында, аннан 1998 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты. Укучыларның хәтеренә төшерү өчен башта әсәрнең кыскача гына эчтәлеген бирен үтик.

Вакыйга сугыштан соңгы елларда, Ырынбур чикләрендә урнашкан татар авылында бара. Әсәрнең төп герое—унике-унөч яшьләрдәге Кәбир исемле малай... Һәм Бамбук дигән байтал. Малай шушы атны җигеп әнисе белән ерактагы туганнарының хәлен белергә бара һәм килгән төнне үк мал абзарына бүре төшеп, бияне яралый. Ат өч аякка кала һәм ана белән бала туган авылларына үзләре генә кайтып китәләр. Сугыштан соңгы кырыс еллар законы белән малайның әнисен, атка зыян салганы өчен дип, утыртып та куялар. Малай ничек кенә булса да атны исән-имин туган авылына алып кайтып күрсәтергә, шулай итеп, әнисен төрмәдән коткарып калырга ниятли. Өч аяклы ат һәм атасыз ятим бала, зур газаплар һәм мажаралар күреп, 50 чакрым араны өч көндә үтәләр.

Юлдагы вакыйгалар повестьта символика дәрәҗәсенә күтәрелеп тасвирланган, әсәрнең үзәк линиясен дә алар тәшкил итә. Ат һәм малайлыктан чыгып килгән яшүсмер шушы юлда бер тәңгә, бер җангa, бер образга әйләнәләр—ир-атка! Әсәрнең азагы тетрәндергеч һәм фаҗигале бетә: мең газап белән өч аягында авылына кайтып егылган буаз бияне шунда ук иткә суялар... Колынкаенын мәетен исә котырган этләр бүлешә...

Гадәттә, әсәрне беренче кат укыганда, аны жанрларга да бүлмисең, балалар әдәбиятымы, олыларныкымы—аңа да игътибар итмисең; әсәр сина ошый икән, күнеленә тәэсир итә алган икән, аны тулысынча—ничек бар, шулай кабул итәсең. Ә менә бәя бирергә алынганда, әсәргә анализ ясаганда, күнелгә андый уйлар килә. Тукта, бу—балалар әдәбиятымы соң, әллә өлкәннәр өчен классик әдәбиятның бер үрнәгеме? Бер караганда, бу әсәрне балалар әдәбияты кысаларына кертергә бөтен шартлар бар: язманың төп герое—үсмер малай, әсәр үзе дә аның аша тасвирлана. Вакыйгаларның барлешендә, агышында да балаларча беркатлылык, чисталык күренә... Әмма шул ук вакытта аңга

туктаусыз кырыс һәм рәхимсез тормыш сулышы да бәреп тора. Әсәргә, бик нечкә генә чорналып, сиздермичә генә малайның әнисе—Сания образы, аның бөтен нәсел фаҗигасе килеп керә... Шушы затлы нәселдән үч алырга, аларны төрмәдә черетергә тешләрен шыгырдатып торган Бөкебаш Галләметдиннәр, участковый Сәйфуллиннар, депутат Сәҗидәләр, явыз бүре кебек, әсәрнең буеннан-буена бу нәселне куа баралар... Һәм әсәрнең ахыры: аксак килеш туган нигезенә кайтып егылган буаз бияне авыл халкы иткә суя... Балалар әдәбияты, бала күңеле күтәрә аламы шушы хәтле фаҗигане, шушы хәтле рәхимсезлекне? Әсәрдә барысы да бергә—ат һәм малай күзләрендәге илаһи яктылык та, Бөкебашлар һәм бүреләр күзләрендәге үлем караңгылыгы да...

Шушы сорауларга җавап эзләгәндә, хәтергә Чыңгыз Айтматовның «Ак пароход» әсәре килеп төште. Анда да шушы ук хәл: формасы белән—балалар әдәбияты, эчтәлеге, идеясе белән—дөнья әдәбиятының классик үрнәге. Биредә дә әсәрнең төп герое—малай, повесть аның күзаллавы аша тасвирлана. Малайның янында ата-анасы юк, ул бабасы белән яши. Малайның яраткан ак боланын—матурлык һәм мәңгелек символын—бабасы үзе үк атып үтерергә мәҗбүр була. Әсәр үзе дә малайның, хыялындагы ак пароходы артыннан барып, суга батып үлүе белән тәмамлана... Бу ике әсәрдә дә саф бала күңеленең, үсмер ир баланың япа-ялгыз башына тормыштагы рәхимсезлекләр белән очрашуы, аларга мөнәсәбәте һәм җавабы тасвирлана. «Ак пароход»та ул җавап—әчкерсез җанның үлеме, саф бер кыргыз баласының бу караңгы дөньядан китүе, көрәшә алмыйча, сынуы булса, «Өч аяклы ат»та, киресенчә: татар малаеның үҗәтләнеп тормышка ябышуы, елый-елый тырмашуы, кечкенә генә шатлыгына да куана-куана яшәргә омтылуы, ат урынына үзе тәртәгә җигелеп булса да, бу тормышны алып барырга тырышуы. Һәм—көрәшүе, көрәшүе, үлгәнче Бөкебашлар белән, соры бүреләр, явызлык белән көрәшүе!

«Өч аяклы ат» повестеның кыйммәте, бик сирәк үзенчәлеге тагы шунда—монда кеше булмаган ЖАН ИЯСЕ, бу очракта ат малкае әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрелгән. Әйткәнебезчә, дөнья әдәбиятында бу сирәк очрый торган, язучыдан гаять дәрәҗәдә осталык, нечкәлек һәм талант таләп итә торган күренеш. Әле кеше хәтле кешене образ дәрәҗәсенә күтәрү гаять авыр һәм катлаулы эш, ә монда телсез җан иясе турында җан тетрәндерерлек, җан җылатырлык образ тудырырга кирәк! Бу эшне бары тик зур талант иясе генә булдыра ала. Тагын Чыңгыз Айтматовның үлемсез «Бәхил бул, Гөлсары!» әсәре искә төшә. Бу повестьта да, нигездә, ике генә герой бар—кыргыз карты һәм Ат... Үлеп бара торган ат һәм... гомере үтеп киткән ир-ат... Әсәр менә шушы ике җан иясенең мең газап белән соңгы урләренә менүләре, соңгы сәфәрләре, соңгы сөйләшү-бәхилләшүләре турында... Шушындый ук соңгы сөйләшү һәм бәхилләшү Эрнест Хемингуэйның «Карт һәм диңгез» әсәрендә Карт һәм балык арасында бара. Татар әдәбиятында да тереклек иясен образ дәрәҗәсенә күтәрә алган талантлы әсәрләр бар. Галимҗан Ибраһимовның «Алмачуар»ын, Һади Такташның «Караборынның дусты» әсәрен, Ринат Мөхәммәдиевнең «Ак кыялар турында хыял» повестен шундыйлар рәтенә кертергә мөмкин. Һәм менә «Өч аяклы ат»... Исемендә үк—символик ишарә, исемендә үк—фаҗигале мәгънә. Тарих төпкелендә үк буыны сындырылган, гарипләндерелгән милләтнең өч аяклы гарип аты... Үтеп кара шуның белән 500 еллык коллык юлын, ат урынына үзең җигелеп, килеп егыл бүгенге көнгә! Ә анда сине, колларына сугым пычаклары тотып, яңа заманның яңа Бөкебашлары, Илбашлары, Җанбашлары көтеп торсын...

Айдар Хәлим—символлар теле белән эш итә белгән нечкә тоемлы язучы. Ә бу тел бары тик талант ияләренә генә буйсына һәм аларга гынан үзенең серләрен ача. Символлар белән язуның иң бөек үрнәген безгә тагын шул Чыңгыз Айтматов күрсәтте. Аның «Гасырларга тиң көн» романы, «Ахырзаман» («Плаха») әсәре һәм соңгы «Тәкъдир тамгасы» («Тавро Кассандры») романы—фәлсәфи-психологик эзләнүләрнең, уйлануларның, өзгәләнүләрнең иң галәми югарылыгына күтәрелеп житкән, бөтен кешелекнең һәм дөньяның фаҗигасен илаһи символлар аша ачып бирә алган бөек әсәрләр. Татар әдәбияты әле үзенең мондый әсәрләрен көтә генә ала. Үзенең «Кыйбла» әсәре белән Айдар Хәлим бу юлга аяк атлады инде. Биредә ул гади генә тоелган бер татар гаиләсе язмышына җиһани биеклектән карый алды, язучы фатыйхасы белән башкорт-ырынбур далаларыннан җәяүләп чыгып киткән бу Ир-Ат белән Хатын-Кыз

хәзер Киек Каз юлыннан мәңгелеккә китеп баралар... Безнең тарихыбыз, безнең газапларыбыз һәм өметләребез турында дөреслекне житкерү өчен алар Мәңгелекнең Үзенә таба китеп баралар...

«Өч аяклы ат» повесте дә—тоташы белән символ-мәгънәләрдән торган әсәр. Әмма алар ясалма тудырылган символлар түгел, әсәрнең тукымасыннан тырпаеп, тәртеп чыгып тормыйлар, аларны бары тик күңел күзе белән генә эзләп табарга мөмкин. Чөнки бу символлар сүз, идея символына гына кайтып калмыйча, әсәргә вакыйга-вакыйга булып салына барган. Абзарга явыз бүре төшеп, нәселле бияне гарипләндерүеннән башлап, шушы атның өч аякта да туган нигезенә кайтып егылуы һәм суелуы—барысы да зур мәгънәгә ишарә. Әйткәнебезчә, сүз ат турында гына бармый бит, сүз шушы атның элеккеге хужалары булган затлы нәсел фажигасе турында гына да бармый, сүз МИЛЛӘТ турында бара. Гарипләндерелгән, имгәтелгән, әмма шул хәлендә дә яшәргә омтылган, ыңгыраша-ыңгыраша булса да алга ыргылган татар милләте турында сүз бара! Милләтнең баш очында һаман пычак кайраулары турында сүз бара! Бу хәтле тирән фажигане балалыгы белән аңлап бетермәгән, аңламавы белән бәхетле, аңламавы белән куркусыз, аңламавы һәм аңларга да теләмәве белән өметле булган ИР БАЛА, ТАТАР БАЛАСЫ—КИЛӘЧӘК турында сүз бара!

Әсәрдә Кәбирне бер генә мизгелгә дә өметсез итеп күрмисең. Инде әтисе сугышта үлгән, өйләрендәге бөтен мал-мөлкәтне салым жыючылар талап алып чыгып киткән, кайчандыр бай, укымышлы нәсел булган бу гаилә ачлыктан интегә. Инде менә, атны сәбәп итеп, малайның әнисен дә утыртып куйдылар... Автор язганча, «бер башак өчен—бер ел, ике башак өчен ике елга утырта торган» вакытлар бит... Әгәр атка берәр нәрсә булса, ул юкка чыкса, малайның үзен дә төрмәдә черетәчәкләр. Бер караганда, бөтен дөнья бу балага каршы кебек. Әмма—юк. Малай дөньяны алай күрми, малай, явызлыкны күрсә дә, аның жинәсенә ышанмый. Күңеле чиста, иманы саф, таза бу бала гел яхшылыкка ышанып, шуңа омтылып яши, һәм дөнья ана яхшылык белән жавап бирә дә. Дөньяга яңа күзләрен ачып, ат ялына ябышып өлгергән бу малайның өстенә, бер яктан, ятимлек, ачлык, төрмә куркынычы ябырылса, икенче яктан, изгелек, рәхим-шәфкать дип аталган зур илаһи көч гөнаһсыз баланы фәрештәләренең канатлары белән гел саклап бара. Сыный-сыный саклый, авырлыклар белән сыный-сыный чыныктыра, бу ир баладан киләчәктә гаделлек өчен, милләт өчен көрәшерлек каһарман әзерли...

Әсәрдә тылсымлы әкият алымнарын да очратырга була. Шушы 50 чакрым арада малай белән ат өч зур вакыйга-сынау аша үтәләр. Беренче вакыйга—чегәннәр белән очрашу күренеше. Атны исән-имин авылга алып кайтып күрсәтим, дип юлга чыккан малай сәяхәтенең башында ук ат каракларына очрый. Чегәннәр, сөйләшеп тә тормыйча, аның атын талап алалар. Бу исә—малайның әнисе гомерен төрмәдә үткәрә, дигән сүз, нәселләре өстенә кара тап төшә, малайның үзен дә төрмә көтә, дигән сүз. Әмма иң куркынычы—чегәннәр бу өч аяклы атны суеп ашарга мөмкиннәр, чөнки алар өчен ул башкага ярамый. Менә шушы зур фажигане, өстенә килгән афәтне, бөтен йөрәге белән сизгән малай, үләненкалганын белмичә, пәке белән чегәннәр өстенә ташлана. Әмма—кая ул! Үзе—бер якка, пәкесе икенче якка очып барып төшә. Шулчак малай: «Мә, алыгыз, барысын да алыгыз! Тик атка гына кагылмагыз!» дип, өстендәге күлмәк-ыштанын салып, чегәннәргә ыргыта. Урман уртасында анадан-тума калган ир баланың, сугыш инде болай да талап коры сөяккә калдырган ятим баланың, ат өчен, дип, мал хакына дип шулай өзгәләнүе дөнья күргән чегәннәрне дә айнытып жибәрә. Гөнаһсыз баланы алдарга, таларга ярамавын алар да аңлый.

—Без ятимнәргә тимибез,—диләр чегәннәр, һәм малайның кулына атын тоттырып, ялан тәпиләренә шыгырдап торган чүәкләр кидереп, урманнан чыгарып жибәрәләр. Кыргый чегәннәр малайга тими, ә Бүләк авылыннан «үз татарларымыз», инде атка утырып, малайны куа чыгалар. Аларга үз сүзләрен өстә калдырырга кирәк, атны юк итеп күрсәтергә кирәк, башбирмәс бу нәселне төрмәдә черетеп, үзләренә гомер буе хакимлек итәргә кирәк... Бүре булып бүре ат һәм малайны эзәрлекләвеннән туктап кала, котырган этләр дә урман башына кадәр генә куа баралар, ат караклары чегәннәр дә аларга тимиләр—әмма авылдаш татарлар арттан куа чыгалар! 50 чакрым буе куа киләләр. 500 ел буе, кяфер кулына тотып бирү өчен, «үз татарларымыз» куа килә, бүгенгә кадәр куа киләләр...

Бүреләрдән дә, ач этләрдән, чегәннәрдән дә котылган ат һәм малай инде кешеләрдән кача башлый. Юлда авылларны әйләнеп үтә-үтә, төн кунарга да алар татар авылларына түгел, чуашларның ат алачыгына барып керәләр. Повестьта икенче зур вакыйга менә шушы ат алачыгында бара. Кәбир инде ат алырга барышлый биредә кунган була, хәзер дә бу алачык аңа дөньяның иң тыныч, иң ямьле урыны булып күренә. Биредә табигатьнең үзе кебек чиста һәм эчкерсез чуаш кызы Нәстүк һәм Хозыр Ильяс кебек гади, ярдәмчел Чтапан дәдәй яши. Бу изге кешеләрнең дә үз фаҗигаләре—Чтапан дәдәй сугышта вакытта хатыны аның өстеннән йөргән, өенә ирләр керткән. Яралы Чтапан дәдәй сугыштан аларның өсләренә кайтып керә, бу хәлләрне күргәч, балаларын алып, ат алачыгына чыгып китә. Хыянәт кергән туган йортын, туган нигезен үз куллары белән яндырып, көлгә әйләндерә. Исерек хатыны хәзер көн саен ат алачыгына килеп, елый-елый Чтапан дәдәйнең чабата киндерәләрен үбә, әмма ир хыянәтне кичерә алмый... Ат алачыгында көн саен Шекспир трагедияләренә тиң фаҗигаләр бара, мәхәббәт һәм нәфрәт, хыял һәм хыянәт бәрелешә...

Үз кайгысы да түбәсеннән ашкан Кәбир-малай ат алачыгында менә шушы фаҗигаләрнең шаһиты була. Әмма малайлыгыннан инде яшьлегенә кереп барган үсмер ир бала тормышның бу кара якларына озак тукталып тормый, аның күңеле барыбер яктылык, матурлык эзли. Һәм ат алачыгында да илаһи матурлыкны таба үсмер егет күңеле, ул—буй җитеп килгән чуаш кызы Нәстүк. Яшьлек беркайчан да авырлык, каралык, өметсезлек белән килешми, тормышның бу ягын кабул итми, аңа буйсынмый, ул һәрвакыт үз тирәсендә мәхәббәттән хасил булган саклану һәм соклану божрасын кора. Шулай итеп караңгы ат алачыгында да бу ике бала, ике үсмер, ике яшь йөрәк бер мизгел эчендә үзләре өчен әкият дөньясы корып өлгерәләр. Юк, бу әле ярату да түгелдер, әмма яратырга омтылу, ул яратуны эзләү, аңа каршы йөгерү генә дә түгел, канатланып очу... Күңел белән, күзләр белән, бөтен җаның һәм тәнең белән... Чөнки бу хәтле авыр тормышны оныттырырлык, аннан бастырмаслык татлы өмет, якты хыял кирәк... Һәм адәм баласы аны үзе тудыра, үзе яшәтә, үзе саклый. Инде шушы соңгы хыялын да тартып алсалар, адәм баласы күзгә күренеп җимерелә, җиңелә башлый...

Бу ике үсмернең ат алачыгындагы эчкерсез хисләрен автор үзенә күрә бер сагыш һәм сагыну белән, бу сафлыкка биниһая соклану белән, шул ук вакытта бу кара заманның ак күңелле балаларын яшерен кызгану белән дә тасвирлый. Бүгенге 13 яшьлек наркоманнар һәм төнге урам чатларында ир-атлар көтеп басып торган фахишә кыз балалар бу бөек бәхетне—эчкерсез ярата алу бәхетен—татый алмыйча тере мәетләргә әйләнгәннәр. Гүя автор, еллар аша, адәм балаларына менә шушындый бәхетсез, өметсез, кара яшьлек киләсен дә күрә, шуңа күрә, үз җанын яндырып, бу караңгылыкны, өметсезлекне таратырга тырыша, үзенең эчкерсез геройлары аша, алар мисалында булса да, сафлыкның һәм яктылыкның үрнәген бирә, явызлыкны яхшылык белән җиңәргә өйрәтә...

Чуаш Чтапан дәдәй Кәбирнең атын бала караган кебек карый, яраларын бәйли, азык һәм даруларын биреп, ат һәм малайны тагы юлга озата. Әмма Бөкебашлар да тик ятмый, алар козгын кебек шушы ятимнәр өстендә бөтереләләр, авыл саен кереп, аларны эзлиләр, үзләренең мәкерләрен коралар. Әмма Кәбир дә инде курка-курка качып юлга чыккан малай түгел, ул үзендә яңа бер көч-гайрәт сизә. Ул инде юлның күп өлешен үтте, котырган этләрдән дә, чегәннәрдән дә исән калды. Ул гынамы, кем генә очраса да аңа ярдәм итте, көч бирде. Ә чуаш кызы Нәстүк аңа гомерендә беренче тапкыр ир-ат итеп, үзенең сыендыручысы, яклаучысы итеп карады. Һәм хатын-кызның шушы бөек ышанычы, өмете Кәбир малайны күз алдында курку белмәс гайрәтле ир-атка әйләндерә, тормышка карата да дәртен, ыргылышын, омтылышын арттыра. Кәбирнең бу мизгелдәге уй-фикерләрен, кичерешләрен автор менә ничек тасвирлый:

«Кәбирдә курку дигән нәрсә бетте, Бөкебашларның алда түгел, артта булуы аңа нишләптер тынычлану китерде. Бамбукның үз жае белән генә сикеренгәләп баруы аңа һәрнәрсәгә фәлсәфи нәтиҗә ясау мөмкинлеген бирде. Юлга чыксаң, анда тан калырлык тормыш ыгы-зыгысы икән; кырмыска түмгәгендә дә, агач ботагындагы карга оясында да, сарут төбендәге тычкан өендә дә, күзең кичерә, зиһенең сыйдыра алган һәр төштә, һәр адымда яшәү өчен көрәш бара икән; бөтенләй таныш түгел кешеләр туганыңнан да якын

туганга әверелә икән; юл ач итми, ул ашата һәм эчертә, чөнки ул кешеләр һәм язмышлар кайнашкан чиксезлеккә алып бара...»

Әмма тормыш гел шушындый бөеклектән, илаһи биеклектән генә торамы соң?! Инде туган авылына кайтып життем дигәндә генә, урман уртасында авызларын ыржайтып, бу бичара баланы төпсез сазлык көтеп торган икән бит! Кешеләрдән кача-кача бара торгач, кара урман уртасында, кара төндә табигать куйган капкынга очрады бит бу бала! Менә ул инде упкынга тездән батты, менә билдән батты, аты, аннан читтә нишләргә белмичә, адәм тавышлары белән ыңгыраша, адәм тавышлары белән өзгәләнә... Кара урманнар никадәр кара булса да, заманалар никадәр авыр булса да, сазлыклар никадәр төпсез булса да, ярдәмгә, коткарырга, таянырга барыбер кешеләр кирәк шул, кешеләр кирәк... Менә бу инде малай үтәсе юлда көтеп торган өченче вакыйга—сынау. Монда кемнәр килер, кемнәр ярдәмендә чыгар ул бу төпсез сазлыктан? Чыга алырмы? Әсәр дә, малайның гомере дә шушында бетәргә мөмкин иде бит. Айтматовның «Ак пароход»ындагы кебек... Юк, Айдар Хәлимнең геройлары сазлыкка батып үлә алмый. Бигрәк тә—бала кеше, әле бөтен тормышы, бөтен көрәш юлы, бөтен бәхете алда кебек тоелган ир бала, татар баласы... Һәм аңа бу юлы «үз татарларыбыз» ук ярдәмгә килергә тиеш. Милләт бит Бөкебашлардан һәм депутат Сажидәләрдән генә тормый. Иң авыр, иң чарасыз чакларда ярдәмгә барыбер үзеннең канкардәшләрен—үз милләттәшләрен килә, кан чакыруы, жан чакыруы буенча киләләр алар... Кара урманнарны, төпсең сазлыкларны ерып киләләр... Барыбер киләләр...

Кәбирне ат караучы Нәби агай коткара. Кәбир бу урман аланында тагы балалыгына кайта—ул малайлар белән учак яга, печән чаба, такмак әйтә, узыша, шаяра—бөтен дөньясын онытып, тагы бала булып кала. Югыйсә, балалыкка кайту өчен күп тә кирәк түгел икән бит—янында таянырга терәк булсын да (ул—Нәби агай), үзең кебек томырылып торган малай-шалай булсын икән! Әй ул иртә картайган сугыш елы балалары! Аякка басуга кара эшкә жигелгән, башын жирдән күтәрмәгән, чамасыз авыр эштән билсез-буынсыз калган авыл балалары... Аз гына буш вакытлары булуга, жирләргә ятып ауный белгән, һаваларга ыргылып оча алган, хыялдан, сөенечтән, өметтән мөлдерәп торган саф, эчкерсез, бәхетле татар балалары... Автор сезне кызгана да, сезгә кызыга да... Шуңа күрә ул артык мавыгып та китә, кайвакытта сюжет жебен дә кулдан ычкындыра, һаман болынлыкта балалар белән мәш килә, алар белән бергә уха пешерә, су керә, такмак әйтә, бил биреп көрәшә... Гаепләмик аны... Бәлки ул үзенең героен шушы урман аланында, яхшы кешеләр янында озаграк тотарга телидер, аны алда үзен көтеп торган явызлыклардан, гаделсезлекләрдән азга гына булса да тоткарларга, балалыгында тотарга уйлыйдыр... Гаепләмик аларны: уйнасыннар балачакларының соңгы уеннарын, алда аларны башка төрле уеннар—кырыс һәм рәхимсез уеннар көтеп тора бит... Моны автор белә, моны Кәбир малай да бала йөрәге белән сизенә инде...

Бала йөрәге дөрес сизгән икән... Инде авылларына кайтып життем дигәндә, соңгы урман авызында, ул үзен куа килгән Бөкебаш Галләметдине һәм участковый Сәйфуллин белән маңгайга-маңгай очраша язып кала. Бәхете: малай алдан сизенеп, атын урман эченә яшереп өлгергән була. Куа килүчеләрнең салмыш булулары, урман авызында да ашап-эчүдән һәм сүгенү-мактанышудан ерак китә алмаулары малайны һәм атны коткарып кала. Аларның сөйләшүләреннән малай үзе өчен сөенечле дә, көенечле дә хәбәрләр ишетә. Сөенечлесе шул—авыл халкы, имза жыеп, малайның әнисен коткаруны сораган, иртәгә ул авылга кайтырга тиеш икән. Хәбәрнең көенечлесе дә бар—әнисе белән ул өйдә югында, бу бандитлар кереп, сандыктан әнисенең соңгы алка-беләзекләрен урлаганнар. Житмәсә, әтисенең «похоронка»сын ертып ташлаганнар. Әле Кәбирнең үзен төрмәдә черетергә дә ант итешәләр... Болар урыс авылыннан: «ат бүредән түгел, ә ялланып бүрәнә ташыганда жәрәхәтләнгән», дигән язу алып кайтып киләләр икән. Алар өчен хәзер иң мөһиме—атның авылга кайтып житмәве. Ул вакытта боларның сүзе өскә чыга, ә «халык дошманы» нәселе булган ана белән бала төрмәдә черияч‌әкләр...

Ә ат барыбер кайта! Өч аягында булса да өстерәлеп, дүртенчегә малайның ябык гәүдәсен терәү итеп, ат барыбер авылга кайтып егыла...

Авылдан бала булып чыгып киткән Кәбир бу кадәр явызлыкларны

күргәч, олыгайган ир-ат кебек, үзенә сорау бирә:

«Салкын кышларда әгәр таудан тауга түбәне япсаң, бар авыл халкы бер өйдә яшәп, бер самавыр чәйдән жылына алыр кебек. Әмма нигә алай түгел? Нигә бертугандай яшәргә тиешле кешеләр бер-берсенең бугазыннан буып бара? Юклык шулай иттерәме? Гомеренең башында туган шушы бик гади сорау Кәбирне шулай ук гомере буе жәфалар: нигә? Жир шары әйләнүдән туктагач кына туктармы мондый аһ-зар һәм рәнжеш?»

Шушы сорауга жавап бирү өчен, инде өч аягында да басып тора алмаган аягүрә хырылдап жан бирә башлаган байталны малай үз йөрәгенә күтәреп диярлек авылга алып кайтып житкерә. Бер авыл халкы каршында булса да дөреслекне исбат итү өчен, бер карыш жирдә булса да явызлыкны жиңү өчен...

Образлар системасы ягыннан караганда, малай образы әсәрдә—әлбәттә, иң камил эшләнгән, иң тере, әдәбият өчен иң яңа образларның берсе. Дөрес, татар әдәбиятында батыр малайлар да, хыялый балалар да, куркак, сатлыклары да булды. Әмма Кәбир башка төрлерәк. Табигать тарафыннан ихлас жан бирелгән бу бала, сугыш, ятимлек, ачлык һәм зур гаделсезлекләр сәбәпле, акылы белән вакытыннан элек олыгая. Бу кечкенә бала жанында эчкерсез сабый күңеле белән хәстәрле, чама белән эш йөртүче агай акылы бергә сыешкан. Балалыгы белән авыр хәлләргә калса да (чегәннәр белән очрашу, сазлыкка бату һ. б.), авыл агайларына хас зирәклеге, төптән күрә белүе, кирәк икән, төп башына да утырта алуы белән ул бу хәлләрдән чыгу жаен да таба. Юк, малайда хәйлә-мәкер юк, чөнки ихласлык белән хәйлә-мәкер бер жанга сыеша алмыйлар, әмма малайда, вакыты-вакыты белән исәп-хисапка корылган салкын акыл да сизелеп китә. Әйтик, бала күңеле белән ул гарип атны мондый озын юлга алып чыгарга жәлли, атны кызганып, аны муеныннан кочып елый. Шул ук вакытта малай бик яхшы аңлый: әгәр ат янында елап кына утырса, аның әнисе мәңге төрмәдән чыкмаячак, дөреслек аста калачак. Атны һәм үзен тинсез газапларга салып булса да, жаны белән моның гарип атка карата рәхимсезлек икәнен аңласа да, малай бу юлны үтә, үзенекен исбатлау өчен үз жаны аша да атлап уза... Юк, бу—мона кадәр әдәбиятта тасвирланган «урра патриотизм» яки әкияти батырлык түгел, ә вакытыннан алда өлгергән баланың мәкергә һәм явызлыкка каршы һәр күзәнәгендә үз-үзен саклау тойгысы барлыкка килүен күрсәтә торган күренеш. Малай «мин көрәшче булам», дип үсми, әмма малайның һәр күзәнәге үз-үзен сакларга һәм якларга әзер тора, куркыныч заманга каршы тору өчен малай үз-үзен шулай программалаган, көрәшеп исән калуга көйләгән. Әдәбият өчен шунысы да кыйммәтле: Айдар Хәлим бу образ турында, «менә ул көрәшә, менә ул жинә», дип бер сүз дә әйтми, туктаусыз башка төеп тормый. Ул көрәшче характеры тууын катлаулы психологик һәм экстремаль халәттә күрсәтә. Малай—кайнап-актарылып торган холыклы һәм укучы күз алдында үскән, формалашкан, укучы белән бергә көрәшергә һәм жиңәргә өйрәнгән яңа герой, яшь герой. Әйткәнемчә, гаять нечкә күңелле, үзе туып үскән бу урман-кырларны тыны-сулышы белән өзелеп яраткан, бу урман-аланнарда үскән һәр агачны, һәр чәчкә-яфракны танып белгән, шулар белән сөйләшеп-аңлашып, бөек бер күңел гармониясендә яшәп яткан авыл баласы ул Кәбир. Шул ук вакытта аның тынгысыз аңы инде баш өстеннән очкан самолетлар артыннан күккә күтәрелә, үзе бер тапкыр да күрмәгән Кремльләргә хәтле килеп житә, сугыш вакытында әтисен мәңгегә алып калган Татра тауларына китеп бара ул... Туган ил, Ватан турында да ирләрчә уйлый башлый. Малай атны житәкләп алып барган кебек, вакыты-вакыты белән автор да малайның акылын үз югарылыгына күтәреп, аны мәңгелек фикер дөньясыннан житәкләп диярлек алып бара. Үз артыннан алып бара, ияртеп алып бара...

«Мәңгегә атасыз, әлегә хәтта анасыз, күкрәкләрендә үр жилләре кураен уйнатып, кеше биргән күлмәк-ыштанда, кеше биргән кәвешләрдә, сугышларны үтеп исән калган, явызлар пычагы астыннан очраклы гына котылган атны әтәреп, черегән ботак-сатак, мурыган үлән, тамырлар исе белән пошлыгып яткан урман төпкелләреннән йөрәге сыман күтәреп алып чыгып килгән малай—кемең булыр ул синең, туган ил? Кем өчендер бик тә кадерле, кем өчендер бик тә кадерсез, туфрактан яралган, кояшта карайган, жилдә жилләнгән, кырда көрәйгән, илдә иләнгән, төптән, бик тирәннән күтәрелгән бу тере тамыр, тормышның зирәк һәм хисле бер күзәнәге—кемең булыр ул синең, туган ил?

Кешелек басуының тук бөртекләр белән тулышырга ният091 бер башагы, болыннар чәчкәсенең күзләве, иртәсен дә, кичен дә дөньяга инәлеп, мәңгелек сагыну авазлары салган, явызлык белән очрашканда сыкраган-сыктаган, янартау булып күкрәп чыккан бу сабыен—кемен булыр ул синең, туган ил?»

Әнә шулай итеп, автор образы белән малай образы, автор сөйләме белән малай сөйләме вакыты-вакыты белән берләшеп, кушылып та китә. Әсәр, нигездә, малай образы, малай сөйләме аша бирелсә дә, бу баланың сакчы фәрештәсе кебек, автор һәрвакыт аның янында, аның җанында. Бер караганда, ул вакыйгалар агышына да, малайның уйлар агышына да катнашмый кебек. Әмма шул ук вакытта, бик зур осталык һәм нечкәлек белән, автор әсәргә малай катнашында булмаган вакыйгаларны, башка образларны да китереп кертә. Әсәр бер аерым герой исеменнән сөйләнгәндә, әле ул герой бала кеше дә булганда, вакыйгаларга авторның катнашып китүе бик зур төгәллек һәм осталык сорый. Чөнки монда ясалмалыкка һәм фальшка инде бер генә адым кала. Бер әсәр эчендә «төкерек белән ябыштырылган» ике әсәр, ике дөнья килеп чыгарга мөмкин, бу очракта автор белән үз герое арасында бер-берләрен аңламау кебек каршылык туу ы да бар. Бары тик талант ияләре генә мондый күзгә күренмәс каршылык кыяларын йомшак кына әйләнеп үтә алалар, төрле холыктагы, төрле дәрәҗәдәге кешеләр турында сөйләсәләр дә аларны бер әсәр тукымасына туплап, бер дулкынга көйли алалар. Һәм нәтиҗәдә аларның барысын да бер фикергә—автор фикеренә—булышырга мәҗбүр итәләр. Айдар Хәлим бу әсәре белән шундый рухи бердәмлекнең уникаль үрнәген бирә алган.

Әсәрдә эпизодик характерда гына тасвирланган, әмма язмышлары белән роман жанрын күтәрә алырлык образлар бар. Шуларның берсе—малайның әнисе Сания образы. Дөрес, аны эпизодик образ дип әйтеп бетереп булмый, ул малай белән берлектә әсәрдә төп йөкне күтәреп бара, татар әдәбиятында уңай хатын-кыз геройлар галереясен тулыландыра. Ул заман өчен дә, татар әдәбияты өчен дә Сания—типик герой. Ул—бай, укымышлы нәселдән, аның ата-анасы кулак булып авылдан сөрелә, бертуган апасы белән җизнәсен дә Молотов урманнарына сөргәннәр. Санияне исә укытучы Хәлим белән гаилә коруы гына коткарып кала, башка туганнары ата-анасыннан баш тарта, бер авылда яшәсәләр дә, алар Саниялар белән йөрешмиләр. Саниянең ире, өч баланың газиз атасы Хәлим, сугыш бетәр алдыннан гына һәлак була. Кечкенә Кәбирнең картәтәсе бу кайгыдан акылга җиңеләя һәм кышкы көндә коега төшеп үлә. Бу гаилә өстенә өелеп-өелеп килгән кара кайгы, соңгы ярсуы белән әни-карчыкка—картәниләренә дә китереп суга—ул параличтан үлеп китә... Колхоздагы иң кара, иң авыр, иң бәгырьне өзә торган эшкә, ятим балалары белән бергә Сания җигелә, Сания тарта. Җитмәсә үзен гомер буе тар маңгайлы, аты бар өстенә хәер сорашып, урлашып йөргән, соңыннан Совет аркасында түрә булып алган исерек Галләметдин-Бөкебаш эзәрлекли. Сания кебек затлы кызның үзенә кияүгә чыкмаганы өчен бу бәндә аның бөтен нәселеннән үч ала. Ата-анасын сөргенгә озату белән башланган бу үч менә хәзер Саниянең үзен һәм улы Кәбирне төрмәгә тыгу белән тәмамланырга мөмкин. Әмма тормышның иң бәхетсез, иң өметсез чакларында да, Галләметдиннең туктаусыз эзәрлекләвенә һәм басымына карамастан, Сания бозык юлга аяк басмый. Ул иренең якты рухына да, үз намусына да хыянәт итми, төрмәгә китсә китә, әмма тәненә дә, җанына да чит ир-аттан кагылдырмый...

Кечкенә генә авылда, кечкенә генә кебек тоелган кешеләр арасында менә шундый фаҗигаләр, астыртын һәм ачыктан-ачык көрәш, бер-берләрен юк итү һәм коткарып калу кебек күренешләр булып ята... Һәм шуларның уртасында—бала йөрәге, бала язмышы... Әгәр Кәбир төп герой булмыйча, аның әнисе Сания алгы планга чыгарылса, татар әдәбиятында Айтматовның «Анам кыры»ндагы Тулганайлар янәшәсенә куярлык образ туган булыр иде. Чөнки Саниянең язмышы, биографиясе, характеры моны күтәрерлек; ул повестька гына сыешмый, роман жанрын сорый. Автор бу образ өстендә эшләвен алда язылачак зур әсәрләрендә дәвам итәр, дигән өмет бар. Сүз уңаеннан Сания образында авторның үз әнисе Срур апаның прототибы бирелгәнен дә әйтеп үтәргә кирәк.

Бөкебаш Галләметдине—әдәбият өчен яңа образ түгел кебек. Утызынчы елларда, Совет власте аркасында сәнәктән көрәк булып киткән мондый надан һәм әрсез бәндәләр турында күп язылды. Әмма Галләметдин образының автор

ачкан бер кызыклы ягы, әдәбият өчен шактый үзенчәлекле бер табышы бар— без кеше хәтле кешенең, аның психикасының урталай ярылып, буталып, чынында—ялган белән, ялган тормышында—чын кеше булып яшәвен күрәбез. Ягъни, әсәрдә иң явыз образларның берсе итеп сурәтләнгән Бөкебаш Галләметдине исерек вакытта чын кешегә әйләнә дә куя бит! Бу бәндә аек вакытта— ерткычның-ерткычы, ә эчеп алгач—кешеләр өчен җанын ярып бирергә әзер торган бер мәхлук икән ләбаса! Хәер, бу күренешне авторның үзеннән дә оста итеп тасвирлап булмас, сүзне әсәргә бирик:

«Билгеле булуынча, Галләметдиннең яшәү гамәле өч фасылдан тора: айнык, исерек һәм махмырдан башы авырткан чак. Ниндидер үтенеч, эш турында сөйләшү өчен халык аның икенче фасылын кулайрак күрә. Җир астыннан табып булса да эчерергә тырыша, ягъни, тагы шунысы кызык: айнык чагында кеше белән ничектер ырылдап кына сөйләшкән, холкына туры килмәсә, сынмас җирдә дә шарт сындырган бу адәми зат ычкынганчы эчеп, халык әйтмешли, судагы агач кебек бүртенеп, «йөзе килгәч» кенә күнеле йомшара, яхшыра, хәтта ки көлә, җырлый,—һәм иң аптыратканы!—хәтта дә ки елый башлый... Әйе, вакыйган, елый! Мондый чакта урамда очрадынмы, беттен— туктата, кочаклый, елый... Тимгел-тимгел булып бүртенгән битләреннән гөрләп яшь ага. Айнык хәлдә кеше елатып, инде исерек хәлдә үзе үк елаткан кешесенә елый алу, үзен кызгандыру сәнгатенен нечкәлекләренә төшенеп алыпмы, әллә табигатеннән шулай яратылыпмы, Галләметдиннең бу фасылы беркатлы, эчкерсез, берсен-берсе чакмый, кинә кумый, түгәрәкләп әйткәндә, туганнарча килешеп яшәгән авыл халкын ярыйсы гына оста алдата иде. Түзә мескенкәй халык. Аек чагында кеше өчен—тәмуг, исерек чагында—оҗмах иясе, янәсе.»

Галләметдин образы, аның фаҗигасе аша Айдар Хәлим җәмгыятьнең асты-өскә килеп, түбәндә—тирес арасында аунаучыларның лаексыз рәвештә иң югары биеклеккә менүләре, ә биектә—нур арасында булырга тиешле акыл ияләренең аяк астында калып тапталу, мәсхәрәләнү фаҗигасен бирә. Кеше үз урынында түгел! Акылы, сәләте, мөмкинлекләре чикле һәм шикле бәндәләр хан тәхетенә үрмәли, хан була, ә талант ияләре, ачтан үлмәс өчен, шушы тилемсәләрнең ишек төбен каравылларга мәҗбүр... Әмма тиле—тәхеттә дә тиле, акыл иясе—тормыш төбендә дә акыл иясе... Баш миендә булган бер күзәнәге белән Галләметдин моны чамалый, дуңгызның беркайчан да йолдыз була алмаячагын, йолдызның беркайчан да дуңгыз булмасын белә ул... Галләметдин бөтен авылны уч төбендә биетеп тотса да, халык кинәшкә барыбер шул Хисам хаҗилар нәселенә бара. Халыкка кирәк вакытта акыллы сүзне шул ук Хәлимнәр, Саниялар, хәтта әнә шул бала Кәбирләр әйтә... Табигать барысын да барыбер үз урынына куеп чыга. Галләметдин дә аңлый моны, шуңа күрә аның да үзе булып, шушы гап-гади авылның гап-гади Галләметдине булып яшисе килгән вакытлары була. Эчкәндә ул шул халәткә кайта да—үзе булып кала... Ул кыланмый, акылы белән үзе күтәрә алмаслык житәкчелек йөген күтәрми, ул авылның гап-гади бер агае булып кала... Совет власте аны, хәер сорашып йөргән бер гидайны, шушы авыл өчен зур хуҗа ясаган, ә ул бер йортта, хәтта бер гаиләдә дә хуҗа булырга сәләтле түгел икән бит ләбаса! Эшли алмаганнан түгел, халәти рухиясе белән кешеләр өстеннән идарә итәргә сәләтле түгел ул. Авыл кешесенең иң начар дигәне дә озакка сузылган ясалмалыкны, ялганны күтәрә алмый, гомер буе икенче кеше булып уйный алмый. Һәм Бөкебаш Галләметдин дә һәркөн эчеп, үзенә кайта, табигате кушканча яшәп ала, ә айныгач, ул тагы чит кеше, тагы хуҗа, тиешсезгә эләккән властьны ул бары тик битлек киеп кенә тотып тора ала...

Шулай итеп дөньяның гына түгел, дөнья белән бергә кеше күнеленең дә асты-өскә килә—кеше аек вакытта битлек кия, исереп алгач—үзе булып кала. Айдар Хәлим бер Галләметдин образы аша гына замананың менә шушы фаҗигасен ача алган, меңнәрнең тормыш фаҗигасен аңлата алган, адәм баласының актарылып ташланган күңел дөньясын бар җәрәхәтләре һәм сызланулары белән күрсәтеп бирә алган. Ә бүген күпме ул дөньяда үз урынында булмаган яки үз урынын таба алмаган Бөкебашлары... Илбашлары... Бүген кешегә кеше өстеннән тиңе булмаган власть бирелгән, кешегә кеше өстеннән тиңе булмаган изү һәм җәберләү бирелгән... Асты-өскә килгән заман...

Сания образы кебек үк, Галләметдин образы да—алга таба үстерелүне

көткән, язмышы һәм яңалыгы белән роман жанрын таләп итәрлек образ. Бу образ бөтен яктан килеп, зур итеп ачылса, без бүгенге тормыш куйган күп кенә сорауларга җавап та табар идек: нигә ил башында, эш башында күп очракта иң затсыз, иң бәгырьсез кешеләр утыра? Нигә милләт кара эчү белән эчә? Нигә без һаман бәйсезлек ала алмадык? Хәзер һәр образга гына түгел, һәр шәхескә дә психологик анализ, җитди бәя бирер вакыт килеп җитте. Татар әдәбияты милләт алдына, ил алдына куелган шушы сорауларга да җавап бирергә тиеш.

Әйткәнебезчә, әсәрдә эпизодик төстә генә бирелгән, әмма язмышлары белән зур әсәр геройлары булып китәргә лаеклы образлар бар. Әйтик, гаиләләре белән сөргенгә сөрелгән, соңыннан туган авылларына кайтмыйча, урыс авылында яшәп калган Муса һәм Зөлхиҗә образы. Шушы урыс арасында да кеше булып кала алган, Кәбир малай өчен могҗиза тоелган электрлы-радиолы өйдә, матур итеп, тыйнак һәм горур гына яшәп ятучы татар гаиләсе ул. Һәм шушы бәхетле йортка тагы бүре төшә! 1937 елларда бу явыз бүре ике аяклы тираннар кыяфәтендә булып, үзләренең язмышларын ботарласа, хәзер исә, еллар үткәч, ач бүре кыяфәтендә алар нәселенең соңгы атына төшләрен батыра. Әсәр менә шушында төенләнә, шушы кайгы-хәсрәттән башланып китә һәм шушы вакыйгалар тәэсирендә без Кәбир-малайның ир-егет булып өлгерү-үсү халәтен күрәбез. Муса белән Зөлхиҗә образы шушы урында югалып торган кебек булсалар да, аларның догалары, алардан килгән туганлык җылысы, яктылык әле малайны юл буе гына түгел, гомер буе озата барачак. Әле бу образлар, авторның «Кыйбла» хикәясендә Ир һәм Хатын булып тагы төрки-мөселман дөньясына килеп керерләр, шулай җилкәгә-җилкә, язмышка-язмыш куеп, Мәңгелектән—Мәңгелеккә үтеп китәрләр... Һәм анда да Татар Хатыны, татар Ире булып милләттәшләрен, диндәшләрен көтәрләр...

«Өч аяклы ат» повестеның теле дә авторның күп әсәрләреннән аерылып тора. Бу тел әле балаларга хас ихлас, саф, назлы тел. Соңыннан, инде «Авылдашлар», «Татар вакыты» әсәрләренә кучкәч, авторның теле дә кырысланыр, геройлары да кырыс, каты һәм рәхимсез кешеләр булыр... Тормыш белән бергә, авторның үзенең дә дөньяга карашы үзгәрер, авыраер, гомер башында җемелдәп, ымсындырып торган якты нур да инде ерагаер, бөтенләй күренми үк башлар... Болары—соңыннан... Ә «Өч аяклы ат»та әле ул нур бөркелеп тора, әсәр өмет белән мөлдерәп тулган, телдә дә каргыш түгел, дога һәм җыр, җыр һәм дога...

Әсәр көтелмәгән чагыштыруларга, табигатьнең үзе кебек саф тәгъбирләргә гаять бай. Менә бу җөмләгә генә игътибар итегез: «Байтал ак гәрәбә тешләрен ай нурында чарлап, ипине умырып капты.» Ун сүзле бер җөмләгә күпме манзара сыйган! Ат тешләренең ай нурында чарлануы... Матур әйтелгән бит, мона кадәр әйтелмәгәнчә әйтелгән, истә калырлык итеп әйтелгән! Менә барыбызның да хәтеренә яшерелгән туган нигез күренешен ничек тасвирлый автор: «Күз алдына яшел бәбкә үләне, тупса тирәсе зәңгәр ташлар белән түшәлгән ишегалды, калай түбәле, әмма череп, һәр төшеннән яңгыр үткән карагай йортлары, хуҗасыз калган нигездә каңгырашып йөргән кәҗә бәтиләре килде. Төнлеккә абзарга ябарга онытмый микән аларны Хәмдия әбисе?» Әсәр башыннан ахырына кадәр менә шушындый самими күзәтүләр, мона кадәр әйтелмәгән, кабатланмаган тасвирлаулар белән тулган. Татар теле монда бөтен зиннәтләре белән зеңгелдәп, елкылдап тора, тантана, падишаһлык итә... Автор белән бергә, аның һәр тере сүзенә, табышына, оста һәм урынлы кулланган һәр чагыштыруына куанасың: «һай, үз телем шул, бай телем, май телем, җай телем!» дип, иксез-чиксез горурлык хисләре кичерәсең. Бу әсәрнең теле турында галимнәребез махсус хезмәт язарларына өмет итеп, бу тел стихиясеннән һәм байлыгыннан аерылып, повестьның башка үзенчәлекләренә күчәргә мәҗбүр булам...

«Өч аяклы ат» әсәренең сюжет-композиция төзелеше артык катлаулы түгел. Вакыйга гарип ат һәм ятим малайның кача-поса чит авылдан чыгып китүләре белән башлана һәм өч тәүлек эчендә туган нигезгә кайтып егылулары белән тәмамлана. Калган барлык хәл-вакыйгалар малайның хәтерендә янара яки юл дәвамында бара. Бала хәтерендә Хисам хаҗи нәселе фаҗигасе дә, Бөкебашлар, депутат Сәҗидә образлары да яңадан туа, яши башлый, аларга Чтапан дәдәй тормышындагы кайгы-хәсрәтләр, Нәби агай мажаралары килеп өстәлә. Малай тормышында беренче мәхәббәт җиле дә сирпелеп үтә... Бу вакыйгалар, образ-геройлар әсәрне артык катлауландырмыйлар да, шул ук вакытта артык беркатлы,

гади дә итмиләр—барысы да үз урынында, барысының да әсәрдә үз роле, үз бурычы бар. Вакыйга арты вакыйга килә, малайга сынау арты яңа сынау ябырыла, бу бала инде бетә, инде харап була, дигәндә, гап-гади кешеләр балага ярдәмгә киләләр... Әсәр тагы яктылыкка таба, яхшылыкка таба, күзгә күренмәгән нурларын чәчә-чәчә, дәвам итә.

Әмма әсәрнең ахыры укучы көткәнчә дә, автор теләгәнчә дә барып чыкмаган кебек. Тормыш хакыйкате авторны да җиңгән. Өч аякта кайтып егылган нәселле бияне, барыбер үләр, дип, авыл халкы иткә суя... Ат җаны белән кушылып беткән Кәбир-малай күз алдында, укучы күз алдында, ил алдында... Күрәсең, авторның үзенең дә бу хәл белән килешәсе килми, аның гел яктылыкка һәм яхшылыкка юнәлтелгән уй-фикерләре чуалып, тетрәнеп китә. Ул мондый фаҗигале тәмамлау белән килешә алмый... әмма шулай тәмамларга мәҗбүр була. Аннан, әсәренә тагы төп герое—Кәбир күзе белән карап, автор барыбер шушы хәлдән соң да яктылык, өмет эзләп карый. Ягъни, әсәрне атның үлеме белән генә бетерми, атның йөрәгеН балалар кулына тоттырып, аны авыл читендәге Түгәрәк Имән төбенә илтеп күмдерә. Мин моның шулай булуына да чын күңелдән ышанам, чөнки бала җаны беркайчан да үлем белән килешә алмый, ул шушы үлемнән дә үлемсезлек эзли, хәрәкәт итә, алга ашкына. Менә шулай: милләтнең бөек фаҗигасе—абынганны сугып үтерү һәм бөек батырлыгы—үлгәннәрне мәңгеләштерү—гел янәшә бара... Татар тормышындагы бу кадәр кансызлыкны һәм кансызлык янәшәсеннән барган мәңгелек мәрхәмәтне, бу кадәр явызлыкны һәм явызлык янында мәңгелек юлдаш булган сагыш-моңны бала күңеле түгел, хәтта автор күңеле дә күтәрә алмый. Әсәрнең ахыры, авторның уй-фикерләре бәргәләнүе, ике урында тәмамлану әнә шул чарасызлык турында сөйли. Һәм без әсәрне, тормышның үзе кебек, ничек бар—шулай кабул итәргә тиешбез: өч аяклы атлары белән дә, Бөкебашлары белән дә, әчкерсез бала—Кәбирләре белән дә... Милләтебезнең үзен дә, ак һәм кара яклары белән, бөтен фаҗигасе һәм шатлыклары белән, ничек бар—шулай кабул итәргә, яратырга һәм хезмәт итәргә тиешбез. Әсәр шуна өйрәтә, рәхимсезлек турында сөйләгәндә дә рәхимле булырга өйрәтә, милләт тормышындагы каралык турында язса да, яктылык барлыгын да күрсәтә, шуңа чакыра. Дөньяда яхшы кешеләрнең барыбер күбрәк булуына, яхшылыкның, дөреслекнең барыбер җиңеп чыгасына ышандыра, өмет уята Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» дигән әсәре.

Айдар Хәлимнең бу әсәре тагы шунысы белән әһәмиятле: ул—меңъеллык дәвамында татар милләтенең милләт булып оешуына китергән ИР-АТ һәм АТ БЕРЛЕГЕ турында, заманында бөтен дөньяны тетрәтә алган ИР-АТ һәм АТ ГАЙРӘТЕ хакында, заман ахырына гариплэнеп килеп җиткән ИР-АТ һәм АТ ФАҖИГАСЕ турындагы әсәр! Ат һәм малай үткән 50 чакрым газаплы юл—татар милләте 500 елда үткән көрәш һәм коллык, мәрхәмәт һәм хыянәт, чарасызлык һәм өмет юлы ул. Өч аяклы ат—ул без үзебез инде, безнең гариплэнгән, имгәтелгән, сугымга салынган милләтебез. Кемнәр коткарып калыр аны заманның сугым пычагыннан? Әсәрдә бу гаять зур сорауга да җавап бар—татар баласы, без үзебез, без дөрес итеп тәрбияләгән балалар коткарып калырга тиеш милләтне. Атасыз һәм әсәр ахырында атсыз да калган бер татар баласы—безнең күз алдыбызда үзе Иргә һәм Атка әйләнгән бер нәни көрәшче—шушы сират күперен исән-имин үтә ала. Беркемне дә сатмыйча, үз-үзенә дә хыянәт итмичә, намус һәм ныклы иман белән, үзе кебек яхшы кешеләр ярдәмендә үтә ул бу юлны. Димәк, нинди генә заманда да КЕШЕ булып калып була икән! КЕШЕ булып калганнар гына бу сират күперен кичә ала икән! Язмыш сынауларыннан сынмыйча, тормышның үзеннән көч һәм гайрәт алып, бетмәс өмет, сүнмәс дәрт белән яшәгәннәр генә яшәү мәгънәсенә ия булалар икән...

Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат» әсәре мәктәп программаларына кертелгәнме икән—белмим, әмма бу бинийһая якты, өметле әсәрне татар балалары укып, өйрәнеп үсәргә тиешлеген беләм. Бу әсәр аларны яхшылык белән явызлыкны аерырга, дуслык һәм хыянәтне аңларга, өмет һәм иман белән яшәргә өйрәтәчәк. Бу әсәр аларны көрәшергә һәм җиңәргә өйрәтәчәк! Мин ышанам: бу яңа буынның инде атлары өч аяклы булмас, хыяллары ярты юлда калмас, милләте дә дәүләтсез һәм бәхетсез булмас! Әсәр әнә шундый өметле уйларга канат куя...

# ӨМЕТЛӘР УЯТА ТОРГАН ӘСӘР

Тел—кешелек дөньясы тудырган иң зур могҗизаларның берсе ул. Тел—күп гасырлар буена чарланган, һаман камиллеккә омтылган кешелек җәмгыятенең серле һәм тугры юлдашы ул. Кешелек дөньясының яшәеше һаман төрләнәнә барган: тел исә елларга, гасырларга яраклашып һаман камилләшә торган, үскән. Тарих бер урында тормаган кебек, тел дә бертуктаусыз диярлек үзгәргән. Бер телләр үскән, ныгыган, икенчеләре исә тарих кануннарына буйсынып, егылып үлеп калганнар.

Татар теленә килсәк, галимнәр аның яшәешен мең елларга җиткерәләр. Шушы соңгы мең ел эчендә халкыбыз күп яктан сыналган, күпне кичергән. Урыс империясе белән янәшә яшәү, урысның аяусыз, дәһшәтле кануннарына буйсынырга мәҗбүр булу, телебезгә һәрчак тәэсирен сеңдереп торган. Ләкин заманында татарлар горур халык булганнар. Ә тел шушы эчке горурлыкның чагылышы. Империя татар халкына тыныч кына яшәргә ирек бирмәгән. Урыс дәүләте мең еллар буена халыкларны көчеп йөрергә мәҗбүр иткән. Татарлар—Урыс дәүләтендә яшәгән халыклар арасында иң күпне татыган милләт. Урыслар Алтын урданы да, Алтын урдага көч өстәгән татарларны да онытмаганнар, җай чыккан саен татар тарихын бозып, аның язмышын каралтып, исән буыннарны куркытып, өркетеп килгәннәр. Соңгы еллар тарихчыларының, ниһаять, авызлары ачылды. Без моңарчы телгә алырга да курыккан бик күп мисалларны көнгә чыгара башладык. Баксаң, татарлар тарих дәвамында бер дә канечкеч вәхшиләр булмаганнар икән!

Империя, аның дәвамчысы булган урыс дәүләте, социализм, дип аталган ялган хакимиятләр һәм бүгенге көннең кара урыслары гомер-гомергә Алтын Урда варисларын—Казан татарларын үзләренең килешмәслек дошманнары итеп санаганнар. Бу, кай ара, халыкның язмышын чишкәндә, бик күңелсез нәтиҗәләргә дә китергән. Берәүләр татар тарихын үзләренең шәхси язмышларына бәйле рәвештә борып куярга омтылып, урысның теләген канәгатьләндереп, татарлыкларыннан ваз кичкән. Татар телен изеп-таптап чукынганнар. Бу исә, халыкларның бүлгәләнүенә китергән, татар теленең дәрәҗәсен төшергән. Әле хәзерге көндә дә, йомык телебез әзме-күпме ачыла башлаган чорда да, астан да, өстән дә империягә ярарга тырышалар. Бу хәл бигрәк тә татар әлифбасын латин графикасына күчергәндә, фикерләр чәкәләше вакытында тагын да ачыграк күренде. Гомер буе шовинистларның канлы табан астын ялаган, урыска ярарга тырышкан татарны, аның телен имгәтеп шактый югарыга үрләгән, мактаулы исемнәр алган кара йөзләр, татарны туры, ак мәгърифәт юлыннан каерып алып, тарихны үзләренә кулайрак итәргә тырышалар. Булды! Андый кешеләрнең күбесен социализм чорындагы сынышлар вакытында күп күрдек. Әйтик, татар теленең, татар халкының язмышын хәл итәргә алынган кайбер явызлар «телләр берләшәчәк, дөнья йөзендә бары тик бөек урыс теле генә калачак»,—дип сайраган шәхесләр, соңгы ун елда тәртәләрен кире якка борып, бөтәнчә сөйли башладылар. Әле бит алар исән. Андыйлар—әле көч. Тел—ул үтә нәзберек, үтә назик күренеш. Ул үзенең вәкилләреннән сак булуны таләп итә. Бер генә мисал: телгә үтә сак килгән Ибраһим ага Гази сөйләгән хатирәләрнең берсе күңелдә калган. 20 елларда тел язмышына хуҗа булырга омтылган кызыл авызлар, халыкның гасырлар буена аңына сеңеп килгән ир белән хатын сүзләреннән баш тартып «тормыш иптәше» дигән сүзне кертергә маташтылар, дип әйткән иде.

Гаилә ныклыгын билгеләгән ир һәм хатын сүзләрен ташлап, соңгы елларда шыксыз, ясалма «тормыш иптәше» дигән сүз бик тиз генә халык авызына кереп оялады. Радио-телевидение дикторлары аерата тәм табып,

җиңгән бер кыяфәттә, шушы сүзне көн туса кабатлыйлар. Телевизор каршысына утырсам, шушы ямьсез гыйбарәне туктаусыз басым ясап кабатлый башласалар каным суынып китә. Әле бит татар теленә һөҗүмнең тукталганы юк, аны төрлечә бозарга омтылучылар ишәя генә бара. Ә бездә телне юньләп белмәгән, аның тирәнлеген аңламаган сөрхәнтәйләр телебезгә ясалма гыйбарәләрне тоташтан сеңдерә баралар. Булыр-булмас кулъязмалары белән Язучылар берлегенә үрләгән әрсезләр, «кем әйтмешли» дигән сүз тезмәсен әсәрдән әсәрләргә сөйрәп йөртәләр. Шундый Саламторханнар сүзлектән алган кайбер сүзләрне әрсезләндереп, аны кирәксә-кирәкмәсә дә мәкаләләренә, әдәби әсәрләренә кертеп җибәрәләр. Телебез «Әле генә табадан төшкән», дигән гыйбарә белән җәфа чигә, изалана. «Әйтәсем килә», дип аптыраталар. Гариф Ахунов мәрхүм, шушы сүзләрне ишеткәч: «әйт соң, әйтәсең килгәч», дип үзенең килешмәүчәнлеген гел тыңлап утырганда да сиздереп куя торган иде. Көтек телле, татарның моңлы-сыгылмалы телен белмәгән, булыр-булмас язучылар, әнә шундый әсәрдән-әсәргә ансат күчеп йөргән сүзләр кулланып, үзләренең наданлыкларын яшерергә омтылалар, һәм кайвакытта теләкләренә ирешәләр дә.

Гомумән, татарча белүче язучылар азайды. Су буе язылган, зур-зур романнарны да хәзер урысча гына тәгәрәтәбез. Әдәбиятка бервакытта да, бер чакта да татарча укымаган, телебезне ярым-йорты гына белгән эшкуарлар килеп тулды. Ярым-йорты әсәрләрне шома гына татарчага әвәләүче әрсезләр пәйда булды. Алар урысча язучы әрсезләр ишәюенә куаналар гына шикелле. Вакыт әрәм итеп, көч түгеп андый әсәрләрне, андый җитез тәрҗемәчеләрне санап торасым килми. Ләкин, яшермичә әйтәм, үзем белән бер чорда иҗат иткән Ә. Еникине, Г. Бәшировны, М. Мәһдиевне, ихлас күңелле, риясыз дустым Г. Ахуновны... сагынам. Башка исемнәр дә бардыр, мөгаен, мин санаганнар белән генә чикләнмидер татар әдипләренең саны. Мин бит әле М. Әмирне, Ф. Хөснине, И. Газины, А. Шамовны күреп калган язучы.

Гасыр азагы тирән борчылулы уйларга салды. Асылзатларыбыз, телнең исәнлеге, бөтенлеге сагында сизгер торган бөекләребез берәм-берәм китеп барды.

Һәр яңа гасыр үзе белән көтелмәгән гамәлләр дә алып килә. XX гасыр башында татар әдәбияты искиткеч зур үзгәрешләр—яңарышлар кичерә: Тукай туа, һәм ашыгып-кабаланып бу дөньядан китеп тә бара, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый тарихка якты эзләрен салалар. Без хәзер XX гасырда татар әдәбияты, татар теленең кая таба үскәнен, нинди борылышлар ясаганын тулысынча күзаллый алабыз. XX гасыр әдәбияты безнең күз алдында, безнең кулларда. XXI гасыр әдәбиятын кемнәр, нинди талантлар бөртекләп ачып салыр, яңа гасырга эстафетаны кемнәр илтеп тапшырыр. Бик хәвефле уйлар килде башка. Чөнки әдәбиятыбыз вакланды, кечерәйде. Әдәби көрәш мәйданында Шәйхи ага Маннур куркып көткән «лилипутлар» калкып чыкты. Бу очраклы хәл түгел иде. Татар халкының әдәби зәвыгы үзгәрде. Бүгенге укучылар бик ансат кына арыш саламын да күши башладылар. Тәнкыйтьчеләрнең дә ориентир-лары үзгәреп, әдәби тәнкыйть мәйданында да шул ук әрсез лилипутлар үрчи башлады.

Һәм, шул чакта инде, өметсезлеккә бирелгәндә, гасыр башында, әдәби тормышыбызда бер яңарыш абайладым.

Татар теленең бүгенге көнге язмышын һәм киләчәген билгеләгәндә, без кайчак бик ансат фикер йөртәбез. Бигрәк тә радио-телевидениеләр бу җәһәттән өлгерлек күрсәтәләр. Татар теле онытылып барган төбәкләрдә «якшәмбе мәктәпләре» ачыла,—дисәләр, без дәррәү куптарылып кул чабабыз. Әһә, дибез, телебез исән, телебез яши. Тел яшәсен булсын өчен аның җанлы әдәбияты, тел сихерен үзенең эченә алган әдәбият казанышлары да кирәк. «Якшәмбе мәктәпләре»нә йөреп телебезне аннан-моннан өйрәнергә маташкан бәндәләр бер чакта да телнең сихри бөеклегенә ирешкән әсәрләр бирә алмыйлар. Һәр чорның серләрен эченә алган әдәби казанышларыннан башка тел тулы хәлдә какшамас көчкә ия булып яши алмый. Мең, хәтта миллион кешеләр мәхәббәттә аңлашкан, туган илен, туган җирен сөю дәрәҗәсенә

ирешә алган кешеләр генә татар теленең сагында булалар. Һәр күренекле әдип, тылсым көченә ия булган язучы гына халыкның ышанычын, буыннан-буынга какшамас дәрәҗәдә тапшыра тора. Телнең язмышын билгеләүдә ышанычлы көчләр кирәк. Ул көчләр үзләренең барлыкларын, үзләре яшәгән чорда раслап үтәргә дә тиешле. Флүс Латыйфиның исеме шыксызрак булса да *(«Бәйсез этләрне атарга». «Казан утлары», № 12, 2000)*, татар теленең җегәренә таянып, аның көчле рухына буйсынып язылган бу әсәре халык язмышы өчен борчылган һәр укучыга көч чыганагы, рухи терәк булып хезмәт итәргә тиеш. Чөнки бу татар тормышын югарыга менгереп татар күңеленә ятышлы, гыйбрәтле персонажларга нигезләнеп язылган әсәр. Әсәрнең кыйммәте шунда ки, ул бүгенге заман татар балаларының язмышын ача. Нәкъ менә бүгенге татар балаларының! Яшерен-батырын түгел, милләтебезнең иң какшатылган буыны—үсмерләр! Бүгенге көн балаларының уй-фикерләрен, яшәешләре төрлелеген чынлап торып өйрәнергә керешкән һәм бу җәһәттән сизелерлек уңышларга ирешкән әсәр юк иде моңарчы.

Автор беренче сүзеннән үк үзе өстенә зур бурычлар ала. Әсәрен сугыш елларында дөнья мәшәкатьләре суырып алып үзе артыннан ияртеән чордашларына багышлый.

Әйе, бу хакта инде байтак әсәрләр язылган. Әдипләр ул дәһшәтле елларны аркылыга да, буйга да сөреп чыкканнар. Флүс Латыйфиның яңалыгы шунда, ул татар балалары турында, татар авылы тормышы мисалларында мәсьәләне хәл итә.

Мин үзем дә сугыш еллары һәм сугыштан соңгы еллар малае. Без шул елларны язып, әдәбиятка дәррәү төркем булып килеп кердек. Без бу еллардагы хәлләрне, әллә кайда еракта барган сугыш хәлләрен каләмебезне аркылыга-буйга йөртеп, язып карадык инде. Татар әдипләре сугышта катнашкан, шунда батырларча һәлак булган татар егетләренең якты истәлегенә багышлап кайта-кайта яңадан-яңа әсәрләр иҗат итте. Инде бетте, бусы соңгысы булыр, дип уйлыйсың, уйлап та бетермисең, кемдер калкып чыга да, яңа сүзе, яңа фикере белән сине сискәндереп җибәрә. Хәзер беләм, әле гасырны тетрәткән, миллионнарның гомерен вакытсыз тартып алган сугыш турында соңгы сүз әйтелмәгән. Әле соңгы хак сүзне әйтә алганыбыз юк. Сугыш дип аталган канлы еллардан күпме ялган, ничаклы мәкер тарих төпкелләрендә посып, дәшми-тынмый гына качып ята. Килер буыннарда татарча язучылар булса, алар һичшиксез бу якка борылып карарлар. Татар тарихын бозу әле һаман дәвам итә. Шовинистлар безнең халыкның сугышта күрсәткән батырлыкларын дәвамлы рәвештә киметеп, кимсетеп киләләр. Рейхстагка җиңү байрагын кадаган татар егете һаман урыс вә грузин күләгәсендә кала килә. Флүс Латыйфи бу хакта яңа сүз әйтә алган. Коры һәм буш сүз генә түгел, чын хакыйкатьне әйтеп биргән. Вакыйгалар беренче карашка гап-гади генә булып узсалар да, автор хәзерге укучыга уйланырга, сугыш заманы хәлләрен аңлап, дөрес нәтиҗәләр чыгарырга ярдәм итә. Әсәрдә сүз Харис исемле малай авызыннан сөйләтелә. Совет мәктәбе кануннары сизгер һәм тапкыр малайны изеп, таптап аның хаклыкны аңлау дәрәҗәсен, сәләтен имгәтеп, аны дөньяны аңлауда коммунистик кысаларга көчләп тыгарга омтылалар. Моның өчен Мәскәүдән яки Казаннан шовинистик карачкыларны китереп тә азапланмыйлар. Харислар имгәтергә сайлап алынган беренче буын түгел. Сугыш елларында татарның үз палачлары, шомлы кара күләгәләре инде туып ныгыган һәм алар халык рухын имгәтергә җайлы урыннарны, беренче чиратта мәктәпне сайлап алганнар. Күрегез инде сез Мила Әхмәтовнаны, ул һич тайчынмыйча үзенең кемлеген балалар алдында ярып сала. Ул болай ди: «Мин—бөек рус культурасы традицияләрендә тәрбияләнгән кеше. Миннән үрнәк алыгыз. Өйрәнегез. Шул тәрбиянең кайбер элементларын тырнак очы хәтле генә булса да сезгә дә йоктырырга телим...» Иң кызыгы шунда, бу рухи үзгәреш кичергән, совет властеның җылысына сыенган бәндәләр үз телләрендә түгел, күбесенчә урысча сөйләшәләр. Урысча сөйләгәндә күнегелгән стандарт фикерләр, канун көченә кереп, балаларны буйсынырга мәҗбүр итә. Заман куркыныч, сүз

буйсынырга тиешле яңа буын кешеләре, киләчәкнең ышанычы булырга тиешле вәкилләре турында бара. Харис исемле малай бәхетсез һәм кимсетелгән нәселнең бер нәни генә вәкиле. Әти-әниләре дөньяның караңгылы якларын аңа үз авызларыннан белдермәскә тырышалар. Ләкин Харис аңлы бала, ул үзенең нәсел вәкилләре булмавын, аларның кайдадыр качып йөрергә мәҗбүр ителгәнен төшенеп ала. Аларның гаиләсе дә урыннан-урынга күчеп йөрергә дучар ителгән. Шушы гади генә булып күренгән татар гаиләсе дә кемнәрнедер куркыта, сагайта. Харислар көннәрнең берсендә Вәрәш авылы тирәсендә урнашкан МТС утарына килеп урнашалар. Ходаның ни хикмәтедер, әле алар халык тормышына катнашып китә алмыйлар. Корама йортларын да авылның иң читендә корып куялар. Вәрәш авылы малайлары белән МТСка килеп эшкә кергәннәрнең балалары арасында еш кына тарткалашлар да булып ала. Автор бу вакыйгаларны һәм анда катнашучы малайларны аз сүзгә зур мәгънә салып зур ышандыру көче белән тасвирлый. Харисның әти-әниләре заман имгәткән аз сүзле, саран хәрәкәтле авыл кешеләре. Алар шул үзара аңлашуларны төнгә, караңгы тынлыкка калдыралар. Балалык елларына багышланган кысан сәндерә Харисны әнә шул шомлы төннәргә якынайта. Малайның җаны тере. Ул нидер эзли, нидер көтә, әти-әнисенең ни өчен урыннан урынга куылып йөрүенең сәбәпләрен ачыкларга омтыла. Әти-әнисенең төнге әңгәмәләреннән өлешчә ачыклый да ала. Бу әсәрдә кешеләр гомумән аз сөйләшәләр. Харисның унынчы сыйныфта укучы абыйсы да бар әле, без аны да ярым сүзсез уйчан егет итеп кенә күрәбез. Ул нидер белә, Харис аңламаганны аңлый, ул да заманның зирәк улы. Харис мәктәптәге тарих дәресеннән кабынып, дәртсенеп Дмитрий Донской гаскәрләренә кушылып сугышканнан соң: «Без татарны җиндек»,— дип авызы колагына җитеп кайткач, абый кеше Харисның: «Мамай белән сугыштым»,—диюенә: «Син үзең кем соң? Дурак! Татарны җиңгәнгә сөенеп кайттыңмы?»—ди. Абый кеше Харисның маңгаена чиртеп тавык күкәе хәтле шеш ясап, аны сискәндереп аңына килергә мәҗбүр итә. Артына типми, җилкә чокырына кундырмый, уй-хәтер чыганагы булган маңгаена чиртә.

Татар балалары, мәктәпкә йөреп тарих белән таныша башлагач, тоташтан шовинист урыс галимнәре тарафыннан язылган тарихны укып, үзләренең «поганый татар» балалары булуын беренче тапкыр искәргән классташ урыс малайлары сүз белән, йодрык белән тегеләрне җиңгәч, өйләренә җылап кайтып: «Мин татар булмыйм, мин татар түгел»,—диюләре искә төшә.

Мәктәпләр Харис укыганда татарны изүгә, татарны кимсетүгә корылган иде. Әнә шул явыз хаксызлык еллар буена татар аңына да сеңдерелгән. Урысның бөеклеге, аның гына ил белән, көн белән идарә итәргә тиешлеген раслаган фән үзенең кара миссиясен үтәде.

Мин быел «Казан» санаториясендә дәваланып ятканда, гүзәл, сылу татар шәфкать туташлары сүз берләштергәндәй балаларыннан зарландылар. Минем: «Балаларыгыз татарча беләме?»—дип соравыма: «Белә, ләкин сөйләшми, ояла»,—дип җавап бирделәр. Инде ике буын арасында шундый каршылыклар яшәп килгәч, өченче, дүртенче буын дөньяга яралган чорда татар башы ниләр күрер! Автор мәсьәләләрне үзәккә үтәрлек итеп күтәрә. Харис: «Маңгайны тотып карадым. Тавык күкәе хәтле шеш чыккан. Башка вакыт булса, күземдәге яшьләрне тыя алмас идем. Әмма бу юлы түздем, тешләремне кыстым... Без кемнәр соң? Нигә без иң изге урын дип санап йөргән йортта—мәктәптә безне үз авызыбыз белән үзебезне үк сүгәргә өйрәтәләр? Дәресләрдә ерак бабаларыбызны хурлап, сүгеп утыргач, үскәч бездән кемнәр чыгар?»—ди. «Үземчә фикер йөртәм инде, ә алар белергә тиеш бит! Үзенең кем икәнен белмәгәннәрнең маңгаена, абый шикелле итеп күзләреннән ут чәчрәтеп, чиртеп торучылары да кирәктер...»

Флүс Латыйфи гаилә, балалар тәрбиясе мәсьәләсендә саран штрихлар белән бик күп мәгънәләрне әйтә ала. Харисның әтисе юаш, акыллы, белемле, тормышта инде бик күп кыенны ашап өлгергән хисапчы һич тә якты көнгә чыга алмый. Ул тәлинкә тота, ялагайлана белми, аның бәләкәй генә хезмәт

хакын заем дигән аждаһа йотып бетереп бара. Харис укый башлаганнан бирле гаиләнең кулы арасына керергә, әнисенә ярдәм итәргә тырыша. Гаиләнең бердәнбер ризык чыганагы булган ике кәҗәгә бәйле ситуацияләрне автор көлке катыш тирән моңсулык белән бәян итә. Кәҗәләр татар әдәбиятында әз чагылмады, Сталин сыерларын һәр буын үзенчә язып тарихка беркетте. Флүс Латыйфи да кәҗәләргә багышлаган сәхифәләрен зур осталык белән бәян иткән. Тормышның ачы кануннарын хәтеребездә яңарткан. Мин дә, безне бик еш елаткан, малларыбызны тотып ябып интектергән Югары Баграж пләвәе Чулак Питерне әле дә каным калтырап искә алам. Чулак Питер дә совет чынбарлыгының дәһшәтле бер вәкиле, ышанычлы терәге булган икән бит.

Совет чынбарлыгы нәни генә татар авылларында да үзенең өстенлеген төрле юллар белән халык аңына сеңдерергә тырышкан. МТСларга, политбүлекләргә урысның иң ялкау, иң эшлексез бәндәләрен китереп утырткannar. Нинди гадиләр, яхшылыкка омтылучы авыл малайлары. Харисның күршесе, яшьтәше Гыйльфан образын авторның зур уңышы дип саныйм. Аның һәр кылган гамәле әле көлке, әле уйчан сагыш уята. Ике дусның сәхнәгә чыгып «Комсомолка Гөлсара» җырын башкарулары дисеңме, болын чәчәкләрен җыеп, Мила Әхмәтовнаның туган көнендә бүләк итүләре дисеңме, иске-москы җыючы Бата Калка кушаматлы Гаделшә-үтилчегә барып йөрүләре дисеңме... Оста кул белән, татарча юмор белән язылган.

Саф күңелле, әле бозылмаган холыклы малайларга каршы көчләр дә бар. Мила Әхмәтовналар ни өчен кыю, ни теләсәләләр шуны башкаралар, телләренә ни килсә шуны сөйли алалар? Чөнки алар һәрдаим яклаучы, кирәк чагында таяныч була алырлык көчләре барлыгына ышаналар. Автор шул көчләрнең берсен, күп вакыйгаларда күренмәсә дә, авылны тетрәтеп яши ала торган бер кешене—милиционерны бик урынлы китереп кертә. Милиционерның әсәргә килеп керүе гади генә түгел, әле яшьрәк чагында ул Харисның әнисенә—Хөррия апага сыенып яшәгән. Тамагы ачса да, нәни генә чирләп китсә дә, ул шушы гаиләгә килеп сыенган. Черек бәрәңге кәлҗемәсеннән пешкән ризык ашап булса да тамагын үткәргән.

Килә бер көн, совет власте аның сүзсез буйсынучан холкын ачыклый. Милиционер үсеп җитә, Харислар шикелле үк пионер баскычын да уза. Әсәрдә күренмәсә дә без аның актив комсомол булуын да чамалыйбыз. Берзаман ач тамагын кешеләрдә үткәреп үскән милиционер гайрәтле, куркыныч көчкә әйләнә. Автор хаклы, ул авылның тере җанлы малайларына милиционерны—совет власте канаты астында пешеп чыккан кара көчне каршы куя. Харис МТС янында яши һәм аның башка малайлар шикелле үк йөрткеч арба ясыйсы килә. Бәхетсезлегенә каршы, малай энесе белән ат тизәге җыярга баргач, Харис күптән эзләгән тәгәрмәчне табып ала. Тәгәрмәч аңа шул йөрткечне ясап бетерергә кирәк иде бит. Без үскәндә авылларда андый йөрткечләр бик популяр нәрсә иде. Чишмәдән су да ташый идек без аның белән, атлар кардасыннан ат тизәге дә алып кайта идек.

Автор тема таләп итә дип анда-монда сугылмый, ул хаклыкны ярата. Әле шундый чикләнгән гамәлләрен үтәгәндә дә, аларны кансыз, явыз көчләр сагалап тора. Бу әсәрдә нәкъ шул сагалап торулар, юньсез, ашаган табагына кәкәй иткән милиционер образына йөкләнгән. Әсәрнең милиционер белән Харис мөнәсәбәтләренә багышланган сәхифәләре зур тәэсир көченә ия. Милиционер, тәгәрмәч караклыгында гаепләп, малайны кулга ала. Харисны һәм аның энесен чын мәгънәсендә төрмәгә ябып куя. Әйе, әйе МТС утары тирәсендә тәрәзәләре рәшәткәләнгән төрмә дә бар икән. Милиционер җәза законнарын уйлап та тормыйча, бары тик үз ихтыяры белән генә малайларны ябып та куя. Аңа төрмәче булу бик ошый. Харисның энесе бәләкәйрәк малай, караңгы камерага эләккәч үрсәләнеп җылый. Әле ярый малайларның сизгер әнкәләре бар. Ул улларын эзләп милиция бүлмәсенә бастырып килеп җитә. Ана кеше—дөнья күргән, ире белән бергә бик күп сынауларны узган чая хатын. Ул милиционерга баш биреп буйсынып тормый, аны урыс сүгенү сүзләре белән коендыра. Ике улын караңгы камерадан йолып ала.

Мила Әхмәтовнаның совет илендәге балалар хакында әйткән купшы сүзләрен хәтерлисезме? Ул сүзләр Харисның күңеленә килеп җитә. Ул чынбарлыкның нәрсә икәнен яхшы аңлый. Язмышына кем хуҗа булуына да төшенә башлый. Тормышта аңа үрнәк булырлык якын кешеләр дә бар. Вәрәшне ташлап чыгып киткән апасына эчтән генә рәнҗегән малай, хаксызлык канатлары үзенә кагылгач, бүтәнчәрәк уйлый башлый. Апасы: «Бу Вәрәштә ачка койрык чәнчеп ятканчы»,—дигән иде ич әрнеп.

Ире военкоматта киерелеп утырган урыс теле укытучысы Мила Әхмәтовна: «Мин бөек халыкның бөек әдәбиятын, бөек телен укытам»,—дип көн саен, сәгать саен туглап торган укытучы хаклымы? Дөрес, урыс теле төшеп калган теллардән түгел. Ул дөньяга Пушкиннарны, Лермонтов, Толстойларны биргән тел. Бер үк вакытта урыс теле дөньяны басып алырга омтылган генералларны, купшы адмиралларны гасырлар буена ныгытып килгән басып алучылар теле дә.

Вәрәш авылында туып үскән тере җанлы Харис, Гыйльфаннарны изеп тәртә арасына кертергә, телләрен, гореф-гадәтләрен изәргә ялланган тел дә ул урыс теле. Татар теле! Татар телендә күпме адәмнәр мәхәббәттә аңлашалар, сабыйларын иркәлиләр, өлкәннәргә, апа-абыйларга яшәү мәгънәсе өстәп торалар. Укытучы Мила Әхмәтовнага да, урыс сүгенүләренә ябышып яшәгән милиционерга да бу телнең кирәге юк. Алар буйсындыру әмәлләрен шушы урыс теле ярдәмендә дә башкара алалар. Автор тормышның куркыныч кара еллары турында язса да, аның эш алымнары якты, өметле. Күрегез әсәрдәге Лилия образын! Үсмерчак еллары мәхәббәте кешенең аңын тәрбияли, якты хисләрен ныгыта. Лилия әсәрдә күп күренми. Ләкин без Харисның шушы тыйнак татар кызына булган изге хисләрен берчакта да хәтердән чыгармыйбыз. Кызганыч, татарның борынгыдан килгән хатын-кыз сафлыгын күңелләрендә төйнәгән кызлар хәзер кимеп бара. Безнең аңыбызны, кызларыбызның яшәү принципларын үзгәрткән, аларның гыйффәтләренә пычрак аткан телевизор тартмасы күңелләрнең патшасы булып ныгып бара. Шуңа да мондый әсәрләр безгә бик кирәк, без аларны берәзлексез пропагандаларга тиеш. Татар балалары: кызлары вә егетләре акны карадан аерып әби-бабаларыбыз мең еллар буена салган якты сукмаклардан тайпылмаска өйрәнсеннәр. Дөрес, мин күпне татыган өлкән кеше Флүс Латыйфиның җыйнак кына повестен укып, кемнәрдер рухи борылыш ясар дип уйламыйм, ләкин әдәбияттан, сәнгатьтән читкә тибәрелмәгән егетләр, туташлар әз булса да уйланырлар, дөрес юлга төшәрләр дип ышанам.

**Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ,**
*Татарстанның халык язучысы.*





# 18—КӘҺАФ (МӘГАРӘ) СҮРӘСЕ

**Кәһаф сүрәсе 110 аятьтән тора. Кәһаф, ягъни, Мәгарә сүрәсе Мәккәдә иңгән. Сүрәдә «Әсхаб-ел Кәһаф—Мәгарәдәге кешеләр» турында сөйләнә, сүрәнең исеме дә шуннан килә.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әлхәмдүлилләһ! Аллаһка мактаулар булсын. Ул һичбер кимчелексез итеп *(мөкәммәл рәвештә)*, Коръәнне *(Мөхәммәдкә)* илчесенә иңдерде. **(2)** Ул ачык *(һәм хәйләсез Коръән гөнаһкярларны җәһәннәм белән)* кисәтү өчен, иманлы вә игелекле кешеләрдән *(җәннәткә керәчәксез, анда мөэминнәргә олуг әҗерләр бар, дип)* сөенче алу өчен индерелде. **(3)** Алар анда мәңгегә яшәп калачак. **(4)**

—Аллаһ бала атасы булды,—дип әйтүчеләрне хәтәр куркыту өчен. (5) Алар үзләре дә, аталары да бу турыда бернәрсә дә белми. Алар авызыннан чыккан бу сүз—гаять көфер сүз. Алар ялганнан башка сүз сөйләми.

**6.** Бу Китапка *(Коръәнгә)* ышанмыйча *(үлеп)* киткәннәр өчен кайгырып, син үзеңне дә харап итмәкче буласыңмы әллә? **(7)** Күбесе игелек кылырмы *(әллә—яманлыкмы)*, дип кешеләрне сынар өчен, Без Җир йөзен гүзәл итеп яраттык. **(8)** Тора-бара Без Җир йөзен *(һични үсмәслек итеп)* коп-коры туфрак калкулыклары итәчәкбез.

**9.** *(Ий, Мөхәммәд)* мәгарә кешеләре белән Раким вакыйгасын син аять могҗизаларыбызның берсе түгел, дип уйламыйсыңдыр *(шиккә алмыйсыңдыр)* бит?

**10.** Ул үсмер-егетләр мәгарәгә кереп качты һәм ялвара башладылар:

—Йа, Раббыбыз, зинһар, безне рәхмәтеңнән ташлама. Безгә котылырлык тугры юл күрсәт,—диделәр. **(11)** Шулай итеп, Без ничәмә-ничә елларга аларның колакларын томаладык *(мәгарәдә йокыга талдырдык)*. **(12)** Әсхабе каһаф *(үсмер егетләрнең мәгарәдә күпме уздырганнарын)* мөддәтен кайсы як *(кайсы кавем)* яхшырак хисаплап чыгарыр икән дип, ахырда Без аларны уяттык. **(13)** Без сиңа аларның вакыйгасын хаклык белән аңлатабыз. Хакыйкатән, алар Раббыга иман китергән үсмерләр иде. Без аларга тугры юлны күрсәттек.

**14.** Без аларның күңелләрен ныгыттык. Ул егетләр *(йокыга талганга кадәр)* аягүрә торур басып:

—Безнең Раббыбыз—күкләрнең вә Җирнең хуҗасы. Безнең өчен Аннан гайре тәнре юк, дибез. Юкса *(киресенчә әйтсәк)*, без хәттин ашкан булып *(кяфер)* калыр идек. **(15)** Безнең кавемебез Аллаһтан башка тәнреләргә табына. Ул тәнреләрнең, чыннан да, илаһ булганлыгына берәр дәлил китерә алсалар иде *(китерә алмыйлар)*. Шулай булгач, Аллаһ хакында теләсә нинди уйдырмалар чыгарганнардан да залимрәк кеше бармы?—диделәр.

**16.** *(Берсе әйтте)*:

—Хуш, сез алардан *(мөшрикләрдән)* һәм алар табынганнардан баш тарткансыз икән инде, бер Аллаһка иман китергәнсез икән, *(иң яхшысы)* сез мәгарәгә кереп качыгыз. Раббыгыз сезне рәхмәтеннән ташламас вә сезнең эшегезне уңышлы итсен,—диде.

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

**17.** *(Әгәр дә син шул мәгарәләр янында булса идең)* күрер иден. Кояш мәгарәнең уң ягыннан чыга, баеганда исә сул тарафта байый иде. Шулай итеп, алар Кояш кыздырудан интекмичә, мәгарәнең бер почмагында рәхәтләнеп йоклый бирәләр иде. Менә бу аять могҗизаларыбызның берсе иде. Аллаһ берәрсен тугры юлга бастыра икән инде, ул аны Хакыйкатькә чаклы алып барыр, кемне тугры юлдан мәхрүм итә икән инде, аны тугры юлга бастырырлык бер генә яклаучы да булмас. **(18)** Син аларны күрсәң, уяу яталар икән, дип уйлаган булыр иден. Гәрчә, алар тирән йокыда. Без аларны ара-тирә ян-якларына *(уңга-сулга)* әйләндергәләп тора идек. Этләре дә бусага янында башын ике тәпие өстенә салып йоклый иде. Аларны шул килеш күрсәң, куркып качар иден, куркуыңнан котың алыныр дәрәҗәгә житкән булыр иден. **(19)** Шулай итеп, *(мәгарәдә күпме ятканнары турында)* бер-берсеннән сораштырсыннар дип, Без аларны уяттык. Берсе әйтте:

—Сез кайчаннан бирле монда ятасыз?—диде.

Икенчесе әйтте:

—Бер көн яки ярты көндер,—диде.

Башкалары:

—Күпме торганыгызны Аллаһ яхшырак белә. Хәзер сез берегезне шушы көмеш тәңкәне тоттырып, шәһәргә җибәрегез, барып баксын: *(шәһәрдә)* саф *(хәләл)* ризыклар ашый торган булсалар, сезгә дә сатып алып кайтсын. Бик сак кылансын, сезнең кайдалыгыгызны сиздерә күрмәсен,—диделәр.

**20.** Әгәр дә алар сезне тапса, таш белән бәреп үтерәчәк яки үз диннәренә кертәчәк. Ул чагында инде сез мәңге дә Сәгадәткә ирешә алмассыз.

*(Бәйзави аңлатуынча, шәһәргә җибәрелгән егет кулындагы иске акчадагы Дияконос патшаның сурәтен күреп, бу егет борынгы акчалар хәзинәсе тапкан дип уйлап, үзен хөкемдар янына алып килэләр. Хөкемдар христиан кешесе икән. Әлеге егет патшага башыннан кичкәннәрне сөйләп бирә. Шулай итеп, егет аларны мәгарәгә алып китә. Яңадан терелү мөмкин икәнлеген исбатлаганнан соң, Аллаһ Тәгалә егетләрне мәңгелек йокыга талдыра.*

Мостафа Чагрыжы тәфсиреннән.)

**21.** Аллаһның вәгъдәсе хак икәнлеген Без әнә шулай исбат иттек. Кыямәтнең, һичшиксез, киләчәгенә ышансыннар дип. Бакчы, алар инде шул турыда бәхәс куптардылар. Берсе әйтә:

—Аларның *(мәгарәдә йоклап ятучы үсмерләрнең)* өстенә бина корып куйыйк. Алар турында Аллаһ яхшырак беләдер,—диде.

*(Бәхәстә)* өстен чыкканнар исә әйтә:

—Без, һичшиксез, алар янына бер мәчет корып куябыз,—ди.

**22.** —Алар өч кенә кеше иде, дүртенчесе эт иде,—ди берсе.

—Биш кеше иде алар, алтынчысы эт иде,—дип икенчесе, белмәгән башларына фараз кылалар:

—Җиде кеше иде алар, сигезенче эт,—ди башкалары.

Әйт син:

—Аларның санын Аллаһ яхшы белә, алар турында белүчеләр бик аз,—диген.

Син алар хакында бәхәскә кермә, чөнки ул бәхәснең очы-кырые булмаячак. Ул турыда берәүдән дә сораштырма.

**23.** Берәр эш башлар алдыннан һичбер вакытта да *(иншааллаһ, Аллаһ теләсә, димичә)*:

—Мин моны иртәгә, һичшиксез, эшләячәкмен,—димә.

**24.** Онытып җибәрәсең икән, Раббыңны исенә төшер дә әйт:

—Өмет итәмен ки, Раббым *(бу мәсьәләне ачыклар өчен)* мине монысыннан да тугры юлга юнәлтер,—диген.

**25.**—Алар мәгарәдә өч йөз ел йоклады. Шуңа тагын тугызны өстәргә кирәк,—диделәр.

*(Өч йөз тугыз саны турында бәхәсләр бар. Кояш елы буенча үсмер егетләр нәкъ өч гасыр йоклаган булып чыга. Ай елы буенча—өч йөз тугыз ел. Х. Чантай тәфсирендә болай язылган: Җәнабел Хак бу сәнәне Ай елы буларак бәян боерды.)*

**26.** Әйт:

—Аларның күпме вакыт мәгарәдә булганнарын Аллаһ яхшы белә. Күкләрнең, Җирнең яшерен серләрен белү бары тик Аллаһка гына хас. Аның күреп-ишетеп торуы шаккатарлык нәрсә. Аларның *(Күкләр вә Җирнең)* Анардан башка һичбер тәртипләүчесе юк. Ул үз хөкемнәренә һичберкемне дә уртак итмәс,—диген.

**27.** Раббың сиңа вәхий иткән Китапны укы *(һәм аңлатып бир)* Аның сүзләрен алмаштырырга беркемнең дә хакы юк. Аллаһтан башка сыеныр зат табалмассың.

**28.** Раббыңның ризалыгын теләп, иртә-кич дога укыганнар белән чын күңелдән дус булып яшә. Дөньяның җиңел-матур тормышына алданып, алардан йөз чөермә. Безне зикер итүдән мәхрүм калдырылганнарга, яман нәфесләре артыннан йөри торганнарга вә эше-көче белән хәттин ашканнарга буйсынма *(иярмә)*.

**29.** Тагын әйт:

—Хакыйкать Раббыңдандыр. Шулай булгач, теләгән кеше иман китерсен, теләмәгән инкарьчы булсын,—диген.

Без залимнәр өчен шундый бер җәһәннәм хәзерләдек ки, аларны ялкынлы диварлар чолгап алыр. *(Сусап)* ярдәм сораганнарга эчәр өчен чырайларны көйдерерлек эретелгән сыек тимер бирерләр. Һай, начар бер эчемлектер ул һәм алар ята торган урын да бик яман.

**30.** Иман китереп, игелекле булганнарга килсәк, хактыр ки, Без изге гамәллеләрнең әҗерен киметмәбез. **(31)** Андыйлар өчен асларыннан *(арыклардан)* ермаклар агып торучы Гаден җәннәтләре булыр. Анда алтын беләзекләр тагып, нәфис атласлар, матур яшел парчалар киеп, гүзәл көрсиләрдә утырырлар. Нинди гүзәл бүләк, нинди Сәгадәт, нинди күркәм урындыр бу.

**32.** Шушы ике адәм белән булган хәлне мисал итеп күрсәт. Боларның берсенә ике җирдә йөзем бакчасы бирдек, һәр ике бакчаны да Ул хөрмә агачлары белән уратып алды. Шул агачлар арасына иген житештердек. **(33)** Ике бакча да бик мул уңыш бирде. Бер генә үсемлек тә һәлак булмады. Араларыннан елга агыздык. **(34)** Бу бакчаның хуҗасы зур уңыш алды *(аның башка килере дә бар иде)*.

Үзара сөйләшкәндә ул дустына әйтте:

—Малым белән мин синнән баерак, кардәшләрем, угылларым да синекеннән күбрәк,—диде.

**35.** *(Масаеп, күкрәк киереп)* үзенә үзе бәла җыйнап, бакчасына керде һәм әйтте:

—Боларның кайчан да булса юкка чыгуына мин ышанмыймын,—диде.— **(36)** Кыямәт көне килер дип уйламыйм мин. Әгәр дә *(Кыямәт булып)* Раббымның хозурына килеп бассам, һичшиксез, болардан да *(бу бакчалардан да)* яхшырак байлыкка *(җәннәт бакчаларына)* ирешәчәкмен.

**37.** Дусты аңа җавап буларак әйтте:

—Син үзеңне туфрактан, сонра тамчыдан *(шәһвәттән)* яраткан, аннан соң сине адәм рәвешенә китергән Аллаһны инкарь итәсеңмени?—диде.—**(38)** Ләкин ул Аллаһ минем Раббымдыр вә мин Раббыма һичбер нәрсәне тиңләмим. **(39)** Нишләп соң син бакчаңа кергәндә:

—Машалла, кодрәт бары тик Аллаһтандыр,—дип әйтмисең? Әгәр дә син мине мал ягыннан да, балаларым ягыннан да кимсетәсең икән. **(40)** Кем белә, Раббым миңа синең бакчаңнан да яхшырагын бирер; синең бакчаңны, бәлки, яшен сугар, бакчаң коп-коры туфрак өеменә әверелер. **(41)** Яки бакчаңнан дым качар да, син ул дымны кире кайтара алмассың.

**42.** Шуннан соң тегенең бакчасы *(байлыгы)* һәлакәткә дучар ителде. Күпме көч сарыф иткән, *(бакчасының харап булганына карап)* ул кулларын угалый иде. Бакчасындагы йөзем агачын бәйләп куйган терәкләр кырылып җиргә ауган иде.

Ул:

—Аһ, әгәр дә мин Раббыга тиңнәрне эзләмәгән булса идем,—диде.

**43.** Аңа ярдәм итүче булмады һәм ул үзен *(фәкыйрьлектән)* коткара

алмады. **(44)** Ярдәмне, дуслыкны да бары тик Аллаһтан гына көт. Бүләкләүче дә Ул, язмышны хәл итүче дә Ул.

**45.** Син аларга гыйбрәт итеп күрсәт. Дөнья тормышы ул Күктән аккан су кебек. Жир йөзендәге үсемлекләр ул суны йотып бетерә *(үләннәр, агачлар шаулап үсә, чәчәк ата).* Соңыннан ул кырлар жил-давыллар узгач, коры чүп булып кала. Аллаһның һәрнәрсәгә кодрәте житә.

**46.** Ул маллар, ул угыллар *(бары тик)* дөнья тормышының бизәкләре генә. Игелекле гамәлләр генә мәңгегә калачак, Раббы алдында *(ул гамәлләр)* савап булачак һәм дә өметкә нигез булачак.

**47.** Ул Көнне тауларны урыннарыннан күчергәч, син Жир йөзен ялангач хәлдә күрерсең. Һичберкемне онытмыйча, аларны *(мәетләрне)* Мәхшәрдә бергә туплаячакбыз.

**48.** Һәм алар берәм-берәм сафка тезелешеп, Раббының хозурына бастырылачак.

—Әүвәлендә сезне ничек яралткан булсак, шул рәвештә *(ялангач, малсыз, бичара хәлдә)* Безгә килерсез. Сез *(фани дөньяда)* кисәтүләрем тормышка ашмас *(Кыямәт көне килмәс, килсә дә безгә жәза булмас),* дип уйлыйсыз, шулай түгелме?

**49.** Китап *(гамәл дәфтәре)* уртага куелгач, язылган гөнаһларын күреп, ничек курыкканнарын күрерсең.

—Харап булдык. Бу нинди китап соң, *(кылмышларыбызның)* зурысы да, кечесе дә, берсе дә онытылмыйча язып куелган,—дип әйтерләр.

Шулай итеп, кылганнары алар каршысында булыр. Раббың һичберкемгә гаделсез булмас.

**50.** Фәрештәләргә әйттек:

—Адәмгә сәждә итегез,—дидек.

Иблистән калганнары барысы да сәждә итте. Иблис ул жен нәселеннән иде. Раббының әмеренә буйсынмады. Хәзер сез Мине инкарь итеп, аны вә аның токымыннан булганнарны дус итәрсезме? Юкса, алар бит сезнең дошманыгыз. Кяферләр өчен бу әверелеш *(Аллаһтан йөз чөереп, шайтанга ияру)* коточкыч зур афәттер.

**51.** Мин аларны *(иблис белән аңа ияргәннәрне)* күкләр һәм Жирне яралтканда да, үзләрен яралтканда да ярдәмчем *(вә шаһит)* итеп чакырмадым. Мин юлдан яздыручыларны *(шаһит)* ярдәмчем итеп алмаячакмын.

**52.** Ул Көнне *(Аллаһ кяферләргә)*:

—Мина тиңләштергән *(уйдырма тәңреләрегез)*не, чакырыгыз,—дип боерыр.

Алар чакырыр, ләкин алар жавапсыз булыр. Без алар *(мөшрикләр белән потлары)* арасына куркыныч-шөбһәле бер упкын уптырдык. **(53)** Гөнаһлылар *(тәмуг)* ут*(ын)* күрер-күрмәс, шунда эләгәчәкләрен аңлап алыр. Аннан котылыш юлын да табалмаслар. **(54)** Хакыйкатән, Без бу Коръәндә инсаннар өчен һәр төрле гыйбрәтле кыйссаларны кат-кат мисалга китердек. Ләкин адәми зат, гадәттә, киресенә тарта.

**55.** Тугры юлга өндәүче *(Коръән, пәйгамбәр)* килгәч, кешеләрне иман китерүдән һәм Раббының ярлыкавын сорап ялварудан *(намаз укудан)* тыйган нәрсә—ул ата-бабаларының башына килгәнне *(һәлакәтне)* үз башларына да ки-лүен көтү һәм вәгъдә ителгән жәза белән йөзгә-йөз очрашырга теләүләреннән килә.

*(Ягъни, кяферләр, мөшрикләр Аллаһның жәзасын үз күзләре белән күрмичә, иман китермәс. Жәза килгәч, иман китерүләре кабул булмас.)*

**56.** Без рәсүлләребезне *(жәннәткә керерсез дип)* сөенче алыр өчен һәм *(гөнаһлылар тәмугка керәчәк дип)* кисәтергә генә дип, жибәрәбез. Кяферләр исә, Хакыйкатьне какшатыр өчен, хакны ялган, ялганны хак дип гауга куптаралар. Алар аятьләребездән вә *(жәһәннәм газабы белән)* куркытуларыбыздан мыскыллы көләләр.

**57.** Раббының кисәтүләрен исләренә төшереп тә, аларга арка белән борылган, үзләре кылганнарын *(гөнаһларын)* онытकан кешедән дә залимрәк кеше

булырмы? Без аларның күңеленә, боларны аңламаслык итеп, колаклары ишетмәслек итеп, комачау куйдык. Син аларны туры юлга чакырсаң да, алар мәңге дә туры юлга басмас.

**58.** Шулай да, ярлыкау мәрхәмәте киң булган Раббың аларны *(гөнаһлары өчен)* җәзаларга теләсә, бик тиз җәзалаган булыр иде. Ләкин аларга билгеләнгән бер мөддәт *(вакыт)* бар. *(Шул вакыт узып киткәч)* алар *(җәзадан)* качып котылыр урын табалмас. **(59)** Шулай итеп, Без гаделсез-әхлаксыз шәһәрләрне*(ң кешеләрен)* һәлак иттек. Аларны һәлак итмәк өчен билгеле бер вакыт тәгаенләгән идек.

**60.** Менә бервакыт Муса бер яшь егеткә әйтте:
—Ике диңгез кушылган урынга хәтле барып җитмичә, еллар буе барсам да, мин туктамаячакмын,—диде.

*(Муса пәйгамбәрнең әмерендәге ул егетнең исеме Юшаг иде. Аятьтә телгә алынган ике диңгез турында төрле фикерләр бар. Берәүләре: аларның берсе—Кара диңгез, икенчесе:—Хазар (Каспий) диңгезе, ди. Бәгъзеләре исә: Зәңгәр Нил белән Ак Нил, дигән фикердә тора. Өченчеләренең фаразынча, ике диңгез күчермә мәгънәдәге гыйбарә, ягъни хәзрәти Муса белән Хозер (галәйһи вәсәлләм) ике диңгезгә тиңләштерелә.)*

**61.** Һәр икесе дә диңгезләр кушылган җиргә барып җиткәндә балыклары турында оныттылар. Балык исә, диңгезгә чумып, юк булды.

*(«Тәрҗемәләр, тәфсирләр бу турыда төрлечә сөйли. Ногманида: балыклары терелеп, суны ярып, диңгезгә карап китте. Кочигиттә: балык та диңгездә юлын табып, юк булды. Чантайда: балык диңгездә (хасил булган ярыкка) туры юлны тотты».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**62.** *(Очрашу урыныннан)* күчеп киткәч, Муса егеткә әйтте:
—Тамак ялгарга ризыгыбызны әзерлә,—диде.—Чынлап та юл йөреп бик тә йончылдык.

**63.**—Беләсеңме,—диде яшь егет.—Ял итәргә утырган кыя янында балыгымны онытып калдырганмын. *(Бу турыда сиңа әйтергә)* шайтан гына оныттырды, башкасы түгел. Ул *(балык)* могҗиза көче белән *(терелеп)* диңгезгә төшеп, йөзеп китте.

*(«Җансыз балык терелеп, диңгезгә төшеп киткән урын Хозер (галәйһивәссәләм) белән очрашасы урын иде. Балык терелеп төшеп киткәнне хәзрәти Муса күрми калды. Егет бу хәлне Мусага әйтергә онытты.»*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**64.** Муса әйтте:
—Эзли торган җиребез менә шул булыр,—диде.
Һәм алар килгән эзләре буйлап кире китте. **(65)** Алар бәндәләремнән бер бәндәмне *(хәзрәти Хозерны)* очратты, аңа Бездән бер рәхмәт *(вәхий вә пәйгамбәрлек)* бирелде, янә Без аңа гыйлем өйрәттек. **(66)** Муса аңа әйтте:
—Үзеңә өйрәтелгәннәрне миңа өйрәтерсеңме, сиңа ияримме?—диде.

**67.** Ул *(Хозер)* әйтте:
—Минем белән йөрергә синең чыдамлыгың җитмәс шул,—диде. **(68)**—Асылын аңламаган көенчә, син ничек сабыр итәрсең икән?

**69.** Муса әйтте:
—Иншаллаһ, син минем чыдамлыгымны күрерсең. Синең әмереңнән чыкмам.

**70.**—Әгәр миңа иярәсең икән, үзем мәсьәләнең асылына әйләнеп кайтканчыга кадәр, берни турында да сорашма,—диде *(Хозер галәйһиссәләм)*.

**71.** Шулай итеп, алар юлга кузгалды. Ниһаять, көймәгә утыргач, ул *(хәзрәти Хозер)* көймәнең төбен тиште.
Муса:
—Көймәдәгеләрне батырыр өчен көймәне тиштеңме?—диде.—Чыннан да син зарарлы эш кылдың.

**72.**—Миңа иярсәң, сабырлыгың җитмәс *(сорашмыйча түзәлмәссең)*,—димәдемме?

**73.** Муса:
—Онытканыма күрә, син мине шелтәләмә, зинһар, эшемдә миңа авырлык йөкләмә,—диде.

**74.** Алга таба киттеләр. Ниһаять, аларга бер үсмер очрады. Хозер аны үтерде.
Муса әйтте:
—Гөнаһсыз бер саф җанны кыйдың. Чыннан да, син яман кылдың,—диде.

**75.**—Миңа ияреп йөрсәң, түземлегең җитмәс, дип мин сиңа әйтмәдемме?—диде *(хәзрәти Хозер).*

**76.** Муса әйтте:
—Әгәр тагын берәр нәрсә турында сорасам, мине юлдашың итмә. Хакыйкатән, синең мине гафу итүләрең тәкәнгәндер инде. *(Янымнан кусаң да, мин сиңа үпкәләмәм)*,—диде.

**77.** Тагын алга таба киттеләр. Ниһаять, бер авылга кереп, алар ашарга сорады. Ләкин авыл халкы аларны кунак итүдән баш тартты. *(Шулай каңгырып йөри торгач)* алар аварга торган бер койма янына килеп чыкты. *(Хозер)* тиз генә койманы турайтып, төзәтеп куйды.
Муса:
—Әгәр дә теләсәң, син бу эшең өчен түләү алыр идең,—диде.

**78.** *(Хозер)* әйтте:
—Менә шушы була инде безнең аерылышуыбыз. Хәзер мин сиңа сабыр итмичә сораганнарыңның асылын аңлатып бирәмен,—диде. **(79)**—Көймә мәсьәләсе болай тора. Ул көймә фәкыйрь балыкчыларныкы иде. Мин ул көймәне яраксызга чыгардым. Чөнки алардан ерак түгел генә көймәләрне талап алучы бер *(юлбасар)* патша бар иде. **(80)** *(Баягы азгын)* үсмергә килгәндә, аның ата-анасы мөселман иде. Һәм без: *(ул үсмер)* азгынлыгы һәм хәттин ашуы белән *(ата-анасына тагын)* зыян-зәхмәт китерер, дип бу эшне башкардык. **(81)** Без шулай теләдек:

—Раббы *(азгын үсмер)* урынына аннан пакь һәм мәрхәмәтле бала бирсен,—дидек. **(82)** Койма мәсьәләсе болай булыр. Ул койма ике ятимнеке иде. Астында аларга тиешле хәзинә ята иде. Аталары бик игелекле кеше иде. Раббың теләде, ул ике сабый балигълыкка ирешкәч, Раббының рәхмәте буларак, шул хәзинәне табачак. Бу эшне дә мин үз белдеклегем белән башкармадым *(Аллаһ кушканча гамәл кылдым)*. Менә, сине кызыксындырган, сабырсыз иткәннәрнең асылы шулдыр.

**83.** *(Ий, Мөхәммәд)* алар *(кяферләр)* синнән Зөлкарнәйн турында сорар. Әйт:
—Мин аның турында сөйләрмен,—диген.
*(Бәйзави тәфсиренә күрә, Зөлкарнәйн ул—Искәндәрнең (Александр Македонскийның) кушаматы икән. Аның пәйгамбәр булганмы, юкмы икәнлеге төгәл ачыкланмаган. Ләкин аның игелекле шәхес икәнлеге, дөньяны яулап алганга, Иранны, Румны үзенә буйсындырганга, таҗында ике мөгез булганга күрә, аны Зөлкарнәйн, ягъни Икемөгезле дип йөрткәннәр. Бәгъзе тәфсирчеләр исә, Искәндәр Зөлкарнәйннән элек шул исемне йөрткән башка бер пәйгамбәр булганлыгы турында язалар, чыннан да, бу фикер хакыйкатькә якын.*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.)

**84.** Хактыр ки, Без аны *(Зөлкарнәйнне)* Җир йөзендә хаким иттек, аңа бөтен юлларны ачтык. **(85)** Ул *(сайлаган)* юлыннан китте.

**86.** Ниһаять, Кояш баткан җиргә килеп җитте, Кояш исә кара-кучкыл сулы дәрьяга бата икән. Аның янында кешеләр барлыгын күрде.
Шунда Без:
—Әй, Зөлкарнәйн, син аларны җәзалый аласың яки син аларга игелек кыла аласың,—дидек.

**87.** Ул шулай диде:
—Хаксыз кыланганнарны җәзаларбыз, соныннан алар Раббы янына китереләчәк. Шунда Аллаһ аларга куркыныч газаплар тәгаенләячәк. **(88)** Иман

китереп, игелек кылганнарга исә, бездән гүзәл бүләкләр булыр. Без андыйларга үтәве җиңел булган әмерләр бирербез.

**89.** Ул тагын юлга чыкты. **(90)** Ниһаять, ул Кояш чыккан җиргә килеп иреште. Анда шундый халык яши иде. Өсләренә Кояш чыга, без аларга күләгә ясарлык нәрсә бирмәдек.

**91.** Менә шулай итеп, Без аның ни кылганын, ни кылмаганын—бөтенесен белеп тордык.

**92.** Соныннан ул тагын юлга чыкты. **(93)** Ниһаять, ул ике тау арасына килеп житте, анда һичбер сүз аңламый торган бер халык белән очрашты. **(94)** Алар *(тәрҗемәчеләр аша)* әйтте:

—Әй, Зөлкарнәйн, бу җирләрдә Яәҗүҗ белән Мәәҗүҗ бозыклык кыла. Ике арага бер койма житкереп бирсәң, без биргәннәрне алырсыңмы?—диделәр.

**95.** Әйтте:

—Раббым миңа биргән нигъмәтләр һәм кодрәт *(сез түләгәннәрдән)* хәерлерәк. Сез миңа эшче куллар белән ярдәм итегез, ике арага кеше менә алмас биек дивар корырмын.

**96.**—Миңа тимер тәрәкләр китерегез,—диде.

Ниһаять, тау арасын *(тимер белән)* тоташтыргач *(тигезләгәч)*:

—*(Күрекләр белән)* өрдерегез,—диде.

Эретелгәч:

—Алып килегез, өстенә эретелгән бакыр коярбыз,—диде.

**97.** Шуннан соң *(дошманнар)* аңа *(коймага)* менә алмадылар, вата да алмадылар. **(98)** Зөлкарнәйн әйтте:

—Бу эш Раббымнан бер рәхмәттер. Ләкин Раббымның вәгъдә Көне *(Кыямәт)* килеп житкәчтен, бу диварны җир белән тигезләр. Раббымның вәгъдәсе хактыр,—диде.

**99.** Ул Көнне Без аларны үзара кычкырышкан хәлдә, тоташ агым-дулкын булып өерелешкән хәлдә калдырырбыз. Сур быргысы кычкыртыр, шунда без аларны бергә җыярбыз. **(100)** Һәм Без аларга *(кяферләрнең хаклыкны күрмәгән күзләренә)* тәмугның ни икәнен күрсәтербез. **(101)** Алар*(ның күңел күзләре)* аятьләремне укымаслык дәрәҗәдә томаланган иде. *(Коръәндәге)* сүзләремне ишетмәслек саңгырау иде колаклары.

**102.** Ул кяферләр Мине инкарь итеп, колларымны *(Гайсә белән Гозәерне)* үзләренә яклаучы, ярлыкаучы итеп таныдылар. Без җәһәннәмне алар *(гөнаһлылар)* өчен ятакханә итеп хәзерләдек.

**103.** Әйт:

—Кылмышлары аркасында иң күп зыян күргәннәр турында сөйлимме?—диген.—**(104)** Игелек кылабыз дип, фани дөньяда чабаланганнары бушка киткәннәр. **(105)** Раббының аятьләрен вә Аның белән *(Ахирәттә)* күрешәчәкләрен инкарь итүчеләр—кылган гамәлләре заяга киткән кешеләр булачак. Кыямәт көнендә Без аларга бернинди дә бизмән тотмаячакбыз *(аларны санга сукмаячакбыз)* **(106)** Әнә, аларның бүләге—җәһәннәм. Аллаһка инанмаганнары, аятьләремне инкарь иткәннәре вә рәсүлләремне мыскыллаганнары өчен. **(107)** Иманлы кешеләр өчен, игелек кылганнарга торыр урын—Фирдәвес җәннәтенең бакчалары булыр. **(108)** Алар анда мәңгегә торып калачак. Аннан һич тә чыгарга теләмәсләр.

**109.** Әйт син:

—Диңгезләрнең суы язу карасына әверелсә дә, Илаһның сүзләре *(хикмәтләре, могҗизалары)* төкәнмәс, яза-яза диңгез суы төкәнер иде. Хәтта тагын шулкадәр кара диңгезе ясасак та,—диген.

**110.** Әйт син:

—Мин сезнең кебек үк гап-гади кеше,—диген.—Миңа бары тик Аллаһыбызның бер икәнен әйтү генә йөкләнгән. Инде кем дә кем Раббысы белән кавышырга өмет итә, игелек кылсын вә Аллаһка гыйбадәттә чакта һичбер башка тәңрегә йөз тотмасын,—диген.

# КҮРЕНЕКЛЕ ӘДИП, ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ

## КАВИ НӘҖМИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Күренекле татар әдибе, җәмәгать эшлеклесе Кави Нәҗми (Нәҗметдинов) 1901 елның 15 декабрендә хәзерге Түбән Новгород өлкәсенең Кызыл Атау авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә.

Гаиләләре бәхет эзләп Казакъстан якларына күченеп киткәч, Кави Актүбәдәге рус-татар мәктәбендә укый. Зиһенле бала буларак, яхшы укый ул, телне дә әйбәт үзләштерә, аң-белемен тирәнәйтә, тормышка карашларын бик иртә формалаштыра.

Илдә гражданнар сугышы башланып китә. Унсигез яшьлек Кави 1919 елда үзе теләп Кызыл Армия сафларына языла, шул елда ук коммунистлар партиясе әгъзасы була. Беренче иҗат җимешләре дә матбугат битләрендә күренә башлый.

Революция идеяләренә чын күңелдән бирелгән Кави Нәҗмине, гражданнар сугышы басыла төшкәч, Мәскәүгә югары хәрби-педагогик мәктәпкә укырга җибәрәләр. Ул аны 1922 елда тәмамлап та чыга. Яшьли хәрби кием кигән Кави Нәҗми соңгы елларына кадәр хәрби киемнән йөрде—аягында хром итекләр, билендә киң каеш булыр иде. Әйе, яшьләрнең күңеленә ул кара тут йөзле, куе кара чәчле бер командир кыяфәтендә уелып калды.

Кави Нәҗми, чынлап та, командир булды—татар совет әдәбияты командиры. Ул бит Татарстан Язучылар союзы идарәсенең беренче рәисе дә—монысы 1934 елда, СССР Язучыларының беренче съезды үткәрелеп, Язучылар союзы оештырылганнан соң була. Аннары «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының баш мөхәррире вазифасын башкара. Төрле елларда төрле җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша.

Әдип буларак, Кави Нәҗминең иҗаты күпкырлы һәм бик бай иде: ул чәчмә әсәрләр (хикәя-повестьлар, роман) белән беррәттән тезмә әсәрләр (шигырь-поэмалар) да яза. Балаларны да читт итми—алар өчен матур-матур шигырь китапларын бастырып тора.

Бу уңайдан шуны да искәртеп үтү кирәктер, Кави Нәҗминең бай иҗат үрнәкләре мәктәп дәреслекләренә беренче сыйныфтан алып унынчы сыйныфка кадәр күп мәртәбәләр кертелә килде.

Без дә үз балаларыбыз белән бергә Кави Нәҗми сүзләренә язылган күңелле-матур җырларны яратып башкара идек. Алар әле дә онытылмый, күңелебездә яңгырап тора. Мәсәлән:

Яшел чыршы,
Басып торчы
Өйнең түрендә!
Килдек бергә
Без биергә
Синең тирәңдә,—

дип башланган «Чыршы бәйрәме» җырын искә төшерик. Яки башлангыч мәктәпнең дүртенче сыйныфы өчен уку китабында күп тапкырлар басылган «Туган йортыбыз» җырының:

Совет иле- туган йортыбыз!
Шундый иркен синдә сулавы.
Тауларыңнан, бәхет җырыдай,
Шаулап ага чишмә сулары,—

кебек беренче юлларын кем онытсын?!

Соңгы җырның музыкасын композитор Ренат Еникеев иҗат иткәне дә хәтердә калган. Ул ноталары белән «Пионер сәхнәсе» җыентыгының 1971 елгы дүртенче китабына да кертелгән иде.

Кави Нәҗминең иҗат эшчәнлеге татар әдәбиятының үсеш тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Аның «Иң соңгысы» (1925), «Шобага» (1926), «Яр буендагы учаклар» (1929) исемле китапларына тупланган әсәрләрендә гражданнар сугышы еллары җанлы итеп, чын сәнгатьчә сурәтләнде. «Якты сукмак» (1930) һәм «Беренче яз» (1930) повестьлары татар прозасында колхозлашу чорын яктырткан тәүге әсәрләрдән булды.

Бөек Ватан сугышы елларында исә Кави Нәҗми күпсанлы ялкынлы публицистик мәкаләләрен, «Хәят апа» (1941), «Фәридә» (1944) кебек популярлык казанган поэмаларын иҗат итә.

Әдипнең иҗатында яуланган иң югары биеклек—«Язгы җилләр» (1948) романы. Монысы тарихи-революцион әсәр иде. Ул Кави Нәҗмигә зур уңыш китерде. Татар әдәбияты өчен дә күренекле вакыйгага әверелде. Гомәр Бәшировның «Намус» романы белән Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романына 1951 елда Сталин премияләре бирелде. Бу—безнең әдәбият тарихында күрелмәгән шатлыклы хәл иде.



*Сулдан уңга: Гадел Кутуй, Кави Нәҗми, Фәхри Әсгать. 30 еллар.*

Ләкин куанычлар озакка бармады. 1953 елның 5 мартында «Ленинның турылыклы шәкерте һәм иң якын көрәштәше, Маркс, Энгельс, Ленинның тәгълиматларын һәм эшләрен дәвам иттерүче, Коммунистлар партиясе һәм совет халкының укытучысы һәм бөек юлбашчысы» Иосиф Виссарионович Сталин вафат булды. Ил кара кайгыга батты. «Бәхет кояшыбыз—бөек юлбашчыбыз Сталинсыз ничек яшәрбез?...»—Бу сорау дистәләрчә миллион кешеләрне зур хафага салган иде. Турылыклы шәкерте һәм иң якын көрәштәше булган Сталин мәетен Ленин янына—Мавзолейга куйганда Мәскәүдә тапталып та, йөрәкләре ярылып та үлүчеләр күп булган...

Әмма... әмма...

Тормыш дәвам итә икән, яшәлә икән. Кояш та кире яктан чыкмады, СССР дигән бөек дәүләт таркалырга да дүрт дистә елга якын вакыт бар иде әле.

Коммунистлар партиясе җитәкчелеге арасында ул чорда ил-халык күзеннән яшертен, астыртын киеренке көрәш барган. Ул, ниһаять, 1956 елны дөньяга фаш булды, сызлавык тишелде...

Мәскәүдә 1956 елның февраль азакларында КПССның тарихи Егерменче съезды булып узды. Отчет докладың белән Н. С. Хрущев чыкты. Ул, Сталинның шәхес культын фаш итеп, илдә гаепсезгә корбан булган миллионнарча «халык дошманнарын» искә алды.

Сталин җәллады Лаврентий Бериянның явызлык-рәхимсезлекләре турында ишеткән халык тагын «аһ» итте. Н. С. Хрущевның докладың кызыл тышлы ябык хат төсендә безгә—югары уку йортларындагы студентларга да укылды. Хәтерлим: пединститутның актлар залында утыручылар арасында һуштан язучылар да бар иде—аларның да этиләре яки кайсыдыр туганнары «халык дошманы» булган икән, имеш.

Илнең каймагы—зыялыларны аеруча күп кырганнар... Сталинның яраткан сүзләре: «Нет человека—нет проблемы» булган, диләр.

Инде язучыларыбыз язмышына әйләнеп кайтыйк. Сталинга дан җырламаган, мәдхия укымаган берәр әдип калдымы икән ул заманнарда?

Булса да—алар юк ителгән. Безнең татар әдипләренең дә иң асыллары шул ачы язмышка дучар булды. Соңыннан аларның бик азы—бер уннабы гына исән-

сау әйләнеп кайта алды. Һәлак булганнарының исемнәре кире кайтарылды. Сталин исеме кергән китаплар типографияләрдән олау-олау җыеп макулатурага озатылды. Алар урынына «халык дошманы» саналганнарның әсәрләре басылып чыга башлады.



*Бер төркем күренекле совет язучылары. Алгы рәттә: Кави Нәҗми һәм Александр Фадеев. 50 еллар.*

1956 елның май аенда, тарихи Егерменче съездан соң берничә ай үткәч, күренекле рус язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе атаклы «Тар-мар», «Яшь гвардия» һәм башка роман-повестьлар авторы, 1934 елдан бирле СССР Язучылар союзында җитәкче урыннарда эшләгән Александр Фадеев, рухи төшенкелек-өметсезлеккә бирелеп, үзен атып үтерде. Сәбәбе—ул озак еллар дәвамында Сталин заказы буенча «Кара металлургия» дигән роман язып азапланган. Һәм, менә, барысы да җимерелеп төшкән...

Сүзебез озынга китте. Инде Кави Нәҗми бу елларда нишләгән соң? Шунысы кызык: алар Александр Фадеев белән бер елгылар—1901 елның декабрь аенда туганнар, Гомәр Бәширов та шул ук елның башында туган шәхес. Өчесенең дә яшьлек язмышлары бер төрлерәк—гражданнар сугышында катнашканнар, аннары җитәкче оешмаларда эшләгәннәр. Өчесе дә Сталин премиясе лауреатлары. Хәер, ул премиянең исеме соңыннан Дәүләт премиясе дип үзгәртелде.

Сталинның мәете ничек бер төндә Мавзолейга иңдерелсә, шулай ук тын гына Кремль дивары буена чыгарып җирләнде. Бу хакта Евг. Евтушенконың «Сталин варислары» дигән тетрәндергеч шигыре бар. Мин аны тәрҗемәләп бастырдым да.

Кави Нәҗми дә, Гомәр Бәширов та романнарының төзәтелгән яңа басмаларын әзерләргә мәҗбүр булды.

Янә бер кызык чагыштыру—мәкаләмә материаллар туплаганда шуңа тап булдым: Кави Нәҗми Сталинга охшаш киенеп йөргән икән! Фоторәсемнәрендә икесе дә хәрби киемнән, икесенең дә куе кара чәчләре артка тарап куелган. Кави Нәҗминең бары тик мыегы гына юк...

Кызу канлы, кырыс холыклы кызыл командир, үзенең иң югары иҗади җимеше «Язгы җилләр» романына кырын караучылар була башлагач, нишләргә тиеш иде соң? Җитмәсә, Язучылар оешмасының җитәкчесе булып эшләгән елларында һәм аннан соң да «халык дошманнарын» фаш итүдә дә катнашканлыгы турында хакмы-нахакмы сүзләр ишетелгәләгән.

Менә шушы фаҗига аның да иртә үлеменә китергән дип фараз кылырга ярый. Ул Александр Фадеев атылып үлгәннән соң бер ел тулыр-тулмастан—1957 елның 27 мартында Казанда вафат. Аның йөрәге үзенә ишелеп төшкән кайгы-хәсрәтләрне күтәрә алмый...

Кави Нәҗминең әдәби иҗаты мул булды. Ул биш-алты дистә китап авторы. Аның «Язгы җилләр» романы үз вакытында бик күп СССР халыклары һәм чит ил телләренә тәрҗемәләнеп дөнья күрде. Әдәбият галиме Нур Гыйззәтуллин аның тормыш юлы һәм иҗаты турында «Кави Нәҗми» дигән монографиясен бастырып чыгарды.

**Марс ШАБАЕВ**

# Гомәр Бәширов

## Замандаш турында берничә сүз

Кави Нәҗми белән безнең тормыш сукмакларыбыз байтак еллар дәвамында янәшә барды. Кави минем яшьтәшем иде.

Әмма яшьрәк чагында Кави миңа караганда җитезрәк, өлгеррәк булып чыкты. Мин беренче әсәремне язарга батырчылык иткәндә, Кави Нәҗми танылган язучы, татар-башкорт хәрби мәктәбенең комиссары, «Кызылармеец» газетасының редакторы, Татарстан Язучылар союзының рәисе, күренекле җәмәгать эшлеклесе һ. б. булып өлгергән иде инде.

Кави Нәҗми татар совет әдәбиятын башлап җибәрүчеләрнең берсе булды. СССР Язучылар съездында татар әдәбияты хакында беренче булып ул доклад ясады. Татарстан Язучылар союзының беренче председателе, «Совет әдәбияты» журналының беренче редакторы, һәм, ниһаять, татар совет әдәбиятына беренче булып СССР дәүләт премиясе алып бирүчеләрнең дә берсе Кави Нәҗми иде.

Кави белән мин беренче мәртәбә утызынчы еллар башында очраштым. Бу вакытта ул «Совет әдәбияты» журналының редакторы, ә минем Татарстан районнарының берсендә халык тикшерүчесе булып эшләгән вакытым иде. Кави минем «Кызыл Татарстан» газетасында басылган «Сиваш» исемле очеркымны бик ошаткан, Казанга килгәндә редакциягә кереп чыгуымны үтенгән иде. Мин Казанга хезмәт эшләре белән килгәндә редакциягә дә кереп чыгарга булдым. Хәзерге Ленин исемендәге китапханә урнашкан йортның икенче катындагы җыйнак кына бүлмәдә мине ярым хәрбиләрчә—аягына күн итек, өстенә яшел френч кигән таза гына бер кеше каршы алды. Хәрби кием мине башта сагайта төшкән иде. Ләкин Кави минем белән мәсьәләне хәрбиләрчә кыска тотып, өзек-өзек кенә итеп түгел, бәлки иркенләп, ягымлы тел белән сөйләште. Әлеге очеркымны илне саклауга багышланган махсус җыентыкка кертергә уйлый икән, аны тагын да киңәйтебрәк язып бирүемне үтенде. Сораштыра торгач, шушы очеркны язу белән туктап калуыма бик гаҗәпләнүен белдерде. Дөресен генә әйткәндә, ул вакытта мин әдәби әсәрләр язарга көчем җитүгә бик үк ышанып та җитмидер идем әле. Ләкин мин аңа моны әйтмәдем, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү уңае белән чамасыз эшем күплеген, язарга вакыт юклыгын сылтау итеп күрсәттем. Кави башын чайкап торды да:

—Алай ярамый, әдәбиятка яшь көчләр бик кирәк. Сездә язу сәләте бар. Бу мәшһүр Сиваш сугышлары турында сез зур әсәр дә яза аласыз, язу алымыгыз шуны күрсәтә,—диде.

Билгеле, Кави кебек танылган язучының яхшы киңәше нәтиҗәсез калмады. Ул миндә язарга сәләтем барлыгына ышаныч тудырды. Мин әдәби иҗат мәсьәләсенә җитдирәк карый башладым. Берничә елдан ул әйткән зур әсәрне—«Сиваш» повестен—язып та чыктым. Бу беренче очрашуны соңыннан без бик рәхәтләнеп көлә-көлә искә төшерә торган булдык.

Бөек Ватан сугышы елларында Кави Нәҗми белән без Татарстан радиокомитетында берничә ел бергә эшләдек. Бик авыр еллар иде ул. Гадел Кутуй кебек талантлы язучылар сугышка китте, бик күп бүлекләрдә нибары берәр генә кеше эшли. Иртәнге сигездән кичке тугызларга кадәр баш күтәрмичә тырышсак та, өлгерүе бик кыен иде. Фронтта хәлләр бик тиз үзгәреп тора, фронтка ярдәмне көчәйтү өчен партия һәм хөкүмәт тарафыннан тылда күп төрле җитди чаралар үткәрелә. Безгә исә шул уңайдан көне-сәгате белән эфирга чыгарга кирәк була.

Әйтик, Ленинград камалышта калганнан соң, казакъ халкының мәшһүр акыны Җамбул Ленинград халкына шигъри мөрәҗәгать белән чыкты. Безнең гаскәрләр Мәскәү тирәсенә килеп җиткән фашистларны тар-мар итеп үзләре һөҗүмгә күчтеләр. Белоруссия партизаннары искиткеч батырлыклары белән дан казаналар. Шундый очракларда тылдагы халыкның рухын күтәрерлек ялкынлы чыгышлар оештырырга кирәк була. Андый чакта мин, радиокомитетның баш редакторы буларак, әдәби-

драматик тапшыруларның редакторы, танылган язучы Мирсәй Әмиргә яисә агитация-пропаганда бүлеге мөдире Кави Нәҗмигә мөрәҗәгать итә идем.

—Кави, ялкынлы публицистик чыгыш кирәк!—дим мин аңа.

Кави яза торган урыныннан башын күтәреп:

—Кайчанга?—дип сорый.

—Бүгенгә.

—Ничә минуттан?

—10 минутка сыйсаң, менә дигән була инде!

Кави урыныннан торып тәмәке төрә дә бүлмәсендә йөри-йөри уйлана башлый. Аннары баш кагып:

—Сәгать ярымнан!—дип әйтеп куя.

Мин аңа ышанам. Сәгать ярымнан ул кәгазьләрен кыштырдатып машинистка янына барып утырачак.

Кыскасы, шундый киеренке вакытларда һәркайчан Кавиның өлгергәнлегенә, аның публицистик осталыгына таяндык. Аның җитәкче эшләрдә сыналган зур стажлы коммунист булуы, комиссарлык тәҗрибәсе дә ярап куйды. Дөньякүләм әһәмияте булган зур әдәби-политик вакыйгаларны җиңел аңлардай йөгерек телдә, көчле дәлил белән баетып, публицистик мәкаләләрендә күбесенчә ул аңлатып чыга иде.

Бу урында минем татар халкының фронттагы сугышчыларга хатын да Кави Нәҗми язуын аеруча ихтирам белән әйтеп узасым килә. Вакытында ул хат һәм фронтта, һәм тылда зур политик вакыйга булып яңгырады, русча, татарча Бөтенсоюз радиосыннан укылды, татар телендә чыга торган II фронт газетасында басылды, аерым брошюра булып чыкты, гомумән, сугыш чоры тарихында якты сәхифә булып истә калды.

Революциянең беренче еллар әдәбияты хакында сүз барганда, кайберәүләр Кави Нәҗминең имажинизмны яклап чыгуына, шулай итеп реалистик әдәбият алымнарына хилаф юлдан китүенә кирәгеннән артык басым ясыйлар. Хәлбуки бу мәсьәләне күпертергә бер нигез дә юк. Яшь шагыйрьнең бу мавыгуына, үзе әйтмешли, фәкать «Октябрь революциясе, гражданнар сугышы тудырган темаларны яңа әдәби калыпка салып язу өчен әлләничә төрле тәҗрибәләр эшләп...» каравы гына сәбәп булган. Ул караштан Кави тиз үк баш тарта. Димәк, бу мавыгу аның өстенә күләгә төшерерлек сәбәп тә була алмый.

Кави Нәҗминең бу тырышып эзләнүләре исә, әдәбиятта яңалыкка, иҗатта үзенчәлеккә омтылулары һич тә бушка китмәде. Ул безнең проза теленә бик кирәкле яңалыклар өстәде.

Әмма сүлпән тормышка өермәдәй ярсып килеп кергән революция, гражданнар сугышы, билгеле, җитез хәрәкәт, динамика таләп итә иде. Сизгер талант буларак, Кави Нәҗми моны яхшы аңлаган, ул үзенең әсәрләрендә, бигрәк тә, публицистикада озынга сузылган салкын канлы ваемсыз җөмләләр кулланмый. Аның әсәрләренә хәрәкәт тизлеге, җанлылык, конкретлык, образлылык хас иде.

Мәсәлән, Кави «Кырлар буенча» дигән хикәясен болай башлап җибәрә:

«Үткән елларның эзен капшап нәрсәдер табасы килә.

Менә фронтлар.

Полк артыннан полк. Һәрберсендә иске тормышның җанын алырга баручы егетләр. Барысының да исемнәре бертөсле—кызылармеец...

Ул—авыр ботинкалар белән Урал тауларына үрмәләде.

Ул—обмоткасын туздыра-туздыра Варшауга чапты.

Ул—диңгез күршесендәге төннәрнең томанын ертып, Сиваш сазлыгы аша, Кырымга үкчә тидерде...»

Яисә, менә аның «Җир шарына рапорт» исемле шигыреннән башлангычы:

Шаркылда, җил!
Ике бармак куеп
Сузып сызгырт!
Җырлап үт тагын...

Кыскасы, Кави Нәҗминең эзләнүләре нәтиҗәсез калмады. Ул үз заманының иң гади укучылары да аңлардык җиңел, әмма образларга бай тел белән яза башлады. Бу әдиптә хәтта һич көтелмәгән урында да, иң гади тормыш детале ярдәмендә бик

матур итеп көлү сәләте бар. Мәсәлән, аның бер әсәрендәге карт үзе белән янәшә кайтучы карчыгына:

— Әйдә, тизрәк атла, трамвай булдыңмы әллә! — ди.

Гади генә күренеш, әмма көлке һәм мәгънәле. Аның әсәрләреннән, шул рәвешчә, күп вакыт шаян юмор яки усал сатира бөркелеп тора. Кави Нәҗми әсәрләрендәге менә шушы алым безнең прозабызга үз вакытында бик кирәкле һәм көтелгән яңалык булып килеп керде.

Кави Нәҗми шәхес буларак та теләсә кем белән тиз аралашырга, уртак тел табарга сәләтле күркәм холыклы, шаян телле, юморист кеше иде. Ул булган мәҗлестә көлке мәзәк, шаян сүз беркайчан да өзелеп тормады. Кави шулай ук докладлар, нотыклар сөйләргә дә бик һәвәс кеше, анда күпләрдә булмый торган ораторлык маһирлеге дә мулдан иде.

Замандашымның шәхси сыйфатлары хакында сүз кузгалу уңае белән, мин Кавинең артык беркатлы, йомшак холыклы һәм чамадан тыш мавыгучан булуын әйтер идем. Чөнки аның бу сыйфатлары тормыш юлында аңа шактый авырлыклар китерде.

Иҗатын башка бик күпләр кебек үк шигырь язудан башлаган булса да, Кави Нәҗми ахырда барысыннан да бигрәк күренекле проза остасы булып танылды. Революция елларында ук барлыкка килгән үз алымын, үз телен торган саен камилләштерә барып, ул әдәбиятыбызга чын реалистик алым белән язылган байтак кына яхшы әсәрләр бүләк итте. Сугыштан соң язган иң талантлы әсәре — «Язгы җилләр» романы белән Кави Нәҗми татар совет әдәбиятын Бөтенсоюз аренасына һәм күпчелек Европа илләренә танытучыларның берсе булды.

Татарстан китап нәшриятында Кави Нәҗминең дүрт томлык әсәрләр җыентыгы чыгуын укучылар җәмәгатьчелеге хуп күреп каршы алды. Бу күренекле язучының әсәрләре әдәбият сөючеләрнең, бигрәк тә яшь буынның китап шүрлекләрендә, һичшиксез, урын алыр һәм укучыда рәхмәт хисләре уятыр дип ышанасы килә.

*1981*

## Афзал Шамов

### Кави Нәҗми — «артистка»

**1920** ел. Җәй айлары.

Мин Казанда, хәрби командирлар әзерли торган курсларда укыйм.

Курсларны тәмамлау хөрмәтенә без Шамил Усмановның «Канлы көннәрдә» исемле пьесасын сәхнәгә куярга булдык.

Күршедә бер запас батальон белән бер интернациональ батальон тора. Анда руслар, латышлар, мадьярлар, словаклар һәм татарлар хезмәт итә. Менә шундагы татарлар өчен куярга телибез без спектакльне.

«Канлы көннәрдә» пьесасын курсант Габделкави Нәҗметдинов белән икәү бергә сайладык. Бераз бөдрәләнеп торган куе кара чәчле, шадра йөзле, зирәклеге коңгырт күзләреннән сизелеп торган бу егетне мин курсларга кергән көннән бирле күреп белә идем. Бер ротада булмасак та, бер батальонда идек без. Аягының кәкрелегенә, йөрешенә карап, кавалериядә хезмәт иткәндер дип уйлый идем. Кавалериядә хезмәт итмәгән икән. Мин аны буш сәгатьләрдә уку залында, китапханәдә, китаплар, газета-журналлар тирәсендә очрата идем. Аның һәрвакыт нәрсәдер укуы, нәрсәдер язуы күңелемне җәлеп иткән иде. Аннары бик мавыктыргыч итеп сөйләве, сүзгә, тасвирга осталыгы, кешеләрне көлдерә, җанландыра белүе дә игътибарымнан читтә калмаган иде.

«Канлы көннәрдә»не куярга әзерләнгәндә генә мин Габделкави Нәҗметдиновның яшь шагыйрь икәнен белдем. Ул чакта әле ул шигырьләрен Кави Нәҗми дип түгел, ә Габделкави Нәҗметдинов дип бастыра иде.

«Канлы көннәрдә» пьесасы эчтәлеге белән дә, катнашучыларының азлыгы белән дә, бигрәк тә хатын-кызлар роленең ике генә булуы белән дә безнең өчен уңай иде. Ирләр ролен уйнарга теләүчеләр күп.

Гимназистка Нәфисә ролен уйнарга теләүче кыз тиз табылды. Бер Казан егете үзенең сөйгән кызын алып килергә булды. Тик менә Мәрьям карчык ролен уйнарга теләүче генә юк.

Безнең курсларда ике-өч татар кызы эшли.

Шулар арасыннан күздә торган бер кыз бар. Кара бөдрә чәчле, ут күзле чая кыз. Чыннан да, кызыбыз бик тиз риза булды. Без шатлыгыбыздан, Кави белән икәү, нишләргә дә белмәдек. Алдан ук рәхмәтләребезне әйтеп, кулын кыстык.

Кызый нинди роль икәнен сорады. Карчыклар роле икәнен әйттек. Әсәрнең эчтәлеген сөйләп бирдек, Мәрьям карчык сүзләре белән дә таныштырдык, шул рольне күчереп алырга дип, пьесаның бер нөсхәсен аңа суздык. Карчык булып уйнаячагын белгәч, бөдрә чәченең бераз кәефе китте, кыйгач кашлары җыерылды, йөзе дә, ничектер, озынчарак булып салынып төште.

—Бик кызганыч, яшь кыз роле түгел икән. Карчык ролен уйнау әллә ничегрәк шунда... Понимаете, егетләр алдында... күңелемә бик үк ятып бетми...

Кави аңа Мәрьям карчыкның кызыл командир әнисе икәнен, бу спектакльдә катнашу политик эш, изге эш икәнен аңлатырга тырышты. Кызыбыз эреп китте. Рәхмәт яусын Кавигә!

Кави телгә дә, кешене юмаларга да, үгетләргә дә оста иде. Теленә шайтан төкергән иде аның.

Без, бик шатланып, репетициягә тотындык. Репетициябез матур гына дәвам итте. Спектакль көне дә килеп җитте.

Кави суфлер хезмәтен үтәячәк. Дикциясе дә, интонациясе дә яхшы. Сүзләрне шундый ачык итеп әйтеп бирә. Артист җанлы кеше иде безнең Кави.

Пәрдә ачылыр сәгать җитте. Сәхнәбез Карл Маркс урамында, хәзерге Химия-технология институтының яңа бинасы салынган урындагы бакчада иде. Бакчабыз зур. Шуңа карамастан, ул кызылармеецлар, курсантлар белән шыгрым тулы, аяк басарлык урын юк. Хәтта тамашачылар, коймаларга, агач башларына да менеп кунаклаганнар.

Комиссар, безнең янга кереп, ике-өч тапкыр рухландырып чыкты:

—Тырышыгыз, иптәшләр, подкачать итмәгез! Сезне бөтен дөнья күзәтеп тора.

Без, «артистлар», дулкынлануыбыздан урыннарыбызда басып тора алмыйбыз. Йөрәкләребез доп-доп тибә... Халык алдына чыгасы булганга түгел, юк,—безне дулкынландыра, борчый торган башка зуррак сәбәп бар. Мәрьям карчык булып уйнарга тиеш булган әлеге бөдрә чәчле кызыбыз, моннан бер-ике сәгать элек килергә тиеш булса да, күренми. Пәрдә ачылыр вакыт җиткән, ә ул һаман юк. Бу безнең барыбызны да бик борчый.

Суфлер будкасына күптән кереп утырган Кави, әледән-әле башын чыгарып, миннән сорый:

—Теге пумала баш килдеме әле?

—Юк.

Озак та үтми, Кавинең башы яңадан суфлер будкасыннан күренә:

—Теге никтудым бикә нихәл? Килдеме?

Ахырда түзмәдек, квартирасына бер курсантны җибәрдек:

—Үле булса да, тере булса да алып кил! Алып килмичә калма!

Шунысы яхшы: ул елларда һәр спектакль алдыннан халыкара хәл турында доклад ясыйлар, озын-озын речьләр сөйлиләр иде. Ялкынлы революцион речьләр иде алар.

Доклад беткәнче тузма башның килеп җитүенә өметләнә идек без. Килер, килмичә калмас... Килмичә калуы мөмкин түгел. Чөнки бу беренче һәм шул ук вакытта соңгы спектаклебез. Казан белән саубуллашу спектакле!

Комиссарның докладьг бетте. Әмма аңа карап безнең «артисткабызның» нурлы йөзе күренмәде, бары аны алып килергә дип киткән курсантыбыз гына мышкылдап кайтып керде:

—Өйдә юк. Кая киткәнен белмиләр,—диде.

Без телсез калдык. Ә халык, спектакльне башлагыз дип, бик каты кул чаба,

кычкыра, акыра, үкерә, күн итекләре, ботинкалары, чабаталары белән җирне ярырлык итеп тыпырдый. Хәтта кайберләре, авызларына бармакларын тыгып, һаваны ярып, бик ачы итеп сызгыралар. Әгәр берничә минуттан пәрдәне ачмасак, спектакльне башлап җибәрмәсәк, сәхнәбезне тар-мар итеп, үзебезне кыйнап, изеп, тетеп ташларга әзер шикелле иде алар.

—Нишләргә?!—дидек без.—Әсәрне куя алмый калу хурлыгыннан ничек котылырга?..

Комиссар сәхнәгә атылып килеп керде.

—Нишләвегез бу?!—диде ул безгә, искиткеч ачуланып.—Харап итәсез бит! Җитмәсә, мадьярлар, словаклар, латышлар алдында. Бөтен дөнья каршында. Ә үзегез кызыл курсантлар!..

Шунда Кави сыкранган, агарынган, шул ук вакытта ниндидер кискен хәрәкәткә әзер булган бер кыяфәт белән суфлер будкасыннан атылып чыкты да кулындагы китабын курсант Насрулла Максудовка тоттырды:

—Мә, суфлер булырсың. Будкага төш! Ә мин Мәрьям карчык булып уйныйм.

Безгә бераз җан кереп китте. Кавине карчык итеп киендерергә, битен бик тырышып акшарларга, буярга тотындык.

Яшермим, бөтен труппага дип алып кайткан пудрабыз да, гримыбыз да кереп бетте, шулай да Кавинең шадрасын күмеп бетерә алмадык. Бер урынына грим сыласак, икенче урындагысы кубып төшә дә Кавинең шадрасы ялтырап килеп чыга. Ниһаять, ничек кирәк алай әмәлләдек.

Сәхнә ачылды. Суфлер беренче сүзләрне бирде.

Залдагы шау-шу да басылды, тынлык урнашты. Йөткермиләр дә, төчкермиләр дә шикелле. Сизеп торабыз, тынлыкны сакларга, әсәрнең эчтәлеген, мәгънәсен аңларга тырышалар.

Белмим, ничек уйналгандыр, анысы турында хөкем итә алмыйм. Шулай да пәрдә төшкәч, бик каты кул чаптылар. Татарлар гына түгел, руслар да, латышлар да, мадьярлар да кул чапты, бакча берничә минут тоташ яңгырап торды. Курсантларның кайберләре сәхнәгә үк сикереп менделәр:

—Мәрьям карчыкны кем уйнады?.. Нинди артистка?..

—Кави,—дидек без.

Ышанмадылар. Чыннан да, ул уйнаган икәнен белгәч, гаҗәпләнеп һәм мактап, аның кулын кыстылар. Шунда ук аңа, дусларча шаярып, үз итеп, «Янган театрның атказанган артисткасы» дигән исем дә биреп өлгерделәр.

Үз итеп, яратып әйтелгән бу сүзләргә Кавинең үпкәләвен, кәефе кырылуын хәтерләмим. Дусларча әйтелгән шаяртуларны аңлый белә, үзе дә оста шаяртучылардан иде ул.

*1981*

# Гариф Ахунов

## Әдипнең киңәшләре

Язучы кайчан башлана? Нәрсәдән башлана?

Күп милләтле совет әдәбиятының кабатланмас бер вәкиле Кави Нәҗмине укучылар аның «Шобага», «Миңлебикә кодагыйның кайгысы» кебек беренче хикәяләреннән үк үз иттеләр. «Миңлебикә кодагыйның кайгысы»н мин, ихтимал, өченче классларда чакта укыганмындыр. Хикәянең беренче җөмләсе мине таң калдырган иде.

«Кышкы давыл, тәбәнәк өйләрне кар көртләренә күмеп, авыл буенча бөтен авырлыгын салып атлаганда, ул кайтты».

Авторның «Ул кайтты»ны аерым урынга, җөмләнең азагына ук китереп куюы күңелдә уйлар, тойгылар, шомнар уята. Нәкъ менә «ул кайтты»га, бүтән беркемнең дә түгел, аның кайтуына басым ясый автор. «Ул кайтты»ны җөмләнең азагына, удар урынга китереп кую, кайткан кешенең юк-бар кеше генә түгел, аерым

игътибарга лаек кеше икәнен укучының күңеленә салып кую өчен кирәк икән. Алдагы тасвир моның шулай икәнен раслый.

«Төрмәдән качып, полиция күзеннән яшеренеп йөргән улы, крестьяннар белән бергәләп җир өчен, ирек өчен көрәшкән Хисамие кайтты. Исәнләшеп чыгарга гына дип кергән Хисамине күргәч, куркудан, сагыштан мие тонып беткән Миңлебикәнең башы боз астында калгандай булды. Хисами:

—Әнкәй, Хәернисаны уятма, йоклый бирсен. Мин бары бер генә кич кунам. Тышта бүген бәйдәге эт тә тормас, шундый салкын... Менә бу төргәкне эчендәге хаты белән Юкә тау тегермәнендә эшләүче Васильев дигән егеткә тапшырырсың, иртәгә үк тапшырырсың... Ә менә бусы сиңа кәшимир яулык. Сагынганда төсем итеп ябынырсың. Бусы Хәернисага чәч бавы. Берәр заводка кереп эшкә тотынсам, зуррак бүләкләр дә җибәрермен. Сезне дә үз яныма алырмын. Ә хәзергә бер дә кайгырмагыз. Мин бераз ятып йоклап алыйм. Бер атнадан бирле йокы күргәнем юк. Берүк таң атканчы уята күр... Мукловкага җәяүләтә, аннан ат белән стансага,—диде дә җылы мич башына менеп ятты».

Илдәге хәлләрне, хәсрәт-кайгыларны, моң-сагышны биредә Кави Нәҗми җөмлә сөрешенә, тасвирлау барышына ук сала барган. Ул моңа ничек ирешкән соң?

Без, университет студентлары, язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубына әдәби җомгаларга бик теләп йөри торган идек.

«Миңлебикә кодагыйның кайгысы» хикәясен язган авторны да мин беренче тапкыр әнә шунда күрдем.

Язучылар клубында кырыгынчы елларның азагында, илленче елларның башында «Тукай», «Намус», «Алтын йолдыз», «Язгы җилләр» кебек киң колачлы, социаль яңгырашлы романнар буенча фикер алышулар үткәрелә иде. Шундый җыелышларның берсенә Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар» романы буенча фикер алышу куелган иде. Хәтеремдә—халык шыгрым тулы иде. Докладны әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Гали Халит ясады. Гали абыйны Арча педучилищесыннан ук белгәнгә күрә (ул безгә әдәбият укыта иде), докладны бик зур игътибар белән, бер генә сүзен дә ычкындырмаска тырышып тыңладым. Романның авторы Ибраһим Газиның портрет остасы, диалоглар остасы, пейзаж остасы булуын җентекләп сөйләде докладчы, образларның социаль җирлегенә аеруча нык басым ясады. Фикер алышуда катнашкан әдипләрдән бер ораторның портреты минем күңелдә уелып калды. Уртача, хәтта тәбәнәк дип әйтерлек буйлы, юантык гәүдәле, кәкре аяклы, шадра битле, кысык күзле иде ул. Утлар чәчеп сөйли, теле телгә йокмый иде аның. Һәм ул роман авторын буржуаз милләтчеләрне фаш итмәүдә гаепләве белән күңелгә шом да салган иде. Тик Ибраһим Газиның моңа исе китмәде, трибунага егетләрчә чыгып, күзлек астыннан күзләрен елтыратып: «Куркытма, Кави!—дип кенә куйды.—Милләтчеләрне фаш итү—синең эш. Крестьянның революциягә килүен язу—минем эш!»

Әнә шул көннән башлап «Миңлебикә кодагыйның кайгысы» хикәясенең авторын мин үз күзем белән күреп белдем. Ә 1951 елны, университетның дүртенче курсыннан ук, «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналында әдәби хезмәткәр булып эшли башлагач, миңа Кави абый белән якыннанрак танышырга, аның яшь язучыларга биргән киңәшләрен ишетергә туры килде.

Ярым хәрби гимнастеркадан, галифе чалбардан, җиңел хром итектән, кулына зур гына сары саквояж тотып, ул Казанның Бауман урамындагы Матбугат йортына килеп керә, китап нәшриятын, газета-журнал редакцияләрен йөреп чыга, соңыннан, барлык урында да йомышларын йомышлаганнан соң гына безгә, «Совет әдәбияты» редакциясенә керә. Ул әлеге журналның баш редакторы да булган кеше, хәзергесе көндә редколлегия члены иде.

Без, ул чагында редакциядә эшләүче яшьләр, аны ихтирам белән каршылыйбыз, кулына берәр авторның әсәрен (кулъязма хәлендә) тоттырмакчы булабыз, кул гына селти Кави абыебыз:

—Шту сез, егетләр, вакыт юк!

Шуннан соң ул бездә ике-өч сәгать утыра, дөньяның барлык мәзәкләрен сөйләп, безне туйганчы көлдерә, азактан гына:

—Ярый, бирегез инде кулъязмагызны, укып карыйм, кем белә, бәлки, мишәр әйтмешли, татар литературасын падбадить итми торган нәмәстәкәй бардыр,—дип редакциядән чыгып китә.

Без күп очракта аның белән әдәби осталык хакында сөйләшәбез.

—Кави абый, ул тел дигән каһәр суккан явызны ничек үзебезгә буйсындырырга соң? Ничек җиңәргә аны, ә?—дибез.

Кави абыйның беренче киңәше әле һаман истә.

—Минем остазым Алексей Максимович Горький, «Шобага» хикәясен укыгач, язып җибәрде: «Чын мәгънәсендәге матурлык һәм акыллылык гади итеп яза белүдә».

—Ә ул хикәяне каян алган? Үзе эзләп тапканмы?

—Тарихы озын аның. Белергә бик теләсәгез, әйтәм.

Без, яшьләр, Кави абыйны сырып алабыз.

—Егерменче елларны мин, күпчелек татар язучылары белән бергә, ашкынып-ярсынып яшәдем. Шигырь йә хикәя, очерк яки публицистик мәкалә бастырмаган көн сирәк иде. Татар классик поэзиясендә урнашкан традицион шигырь калыбы мине канәгатьләндерми иде. Төрле агымнарга да кушылып киткән чаклар булды. Футуризм белән имажинизмның революция сәнгатенә файда китерәчәген исбатларга тырыштым та йөрелде. Булды инде! Алар—узылган этап. Һәрхәлдә мин иҗтимагый-әдәби тормышның уртасында булырга тырыштым. Бәлкем, Кызыл Армия мәктәбеннән турыдан-туры әдәбиятка килүем дә моңа ярдәм иткәндер.

«Бәлки, аның ярым хәрби форманы гомер буе киеп йөрүе дә шул Кызыл Армия мәктәбеннәндер»,—дип уйлаган идем мин ул чакта.

Кави абыйның барлык сүзләре дә төп-төгәл хәтердә калмаган, әмма зур әдәбият, социалистик реализм әдәбияты юлына килеп чыгуының төп шарты итеп әйткән сүзләре хәтердә. «Мин күп укыдым, шулай итеп пролетариатның бөек язучысы Максим Горькийга килеп тоташтым...—диде ул.

Менә шуларны сөйләде безгә Кави абый. «Горький һәм татар әдәбияты» дигән проблема безнең күңелгә нәкъ менә Кави абый аркылы кереп калды.

1928 елның җәендә, А. М. Горький Казанга килгәч, Кави Нәҗми аның белән чынлап торып таныша һәм «Шобага» хикәясен биреп җибәрә. Озакламый М. Горькийдан хат ала. Горький аңа мөмкин кадәр гади итеп язарга кирәклеген әйтеп менә шул хатында киңәш бирә.

Бер башланган дуслык өзелми. Совет язучыларының Беренче Бөтенсоюз съездында Алексей Максимович киңәше белән татар әдәбияты турында доклад ясау көн тәртибенә куела, бу эш Кави Нәҗмигә тапшырыла. Украин, грузин, белорус әдәбиятлары белән янәшә Бөтенсоюз съездында безнең әдәбиятыбыз хакында доклад тыңлау—бу безгә зур ышаныч, әдәбиятыбызның мең еллык тарихына игътибар белән карау дигән сүз. Язучыларның Беренче Бөтенсоюз съездында татар әдәбияты турында доклад ясалуның ихтирамнан тыш җаваплылыгы да зур булган. Ник дисәң—әле 1928 елны ук, ягъни язучыларның Бөтенсоюз съездына кадәрле алты ел элек үк, А. М. Горький Казанга мондый хат язып җибәрә: «Татар поэзиясенең һәм прозасының чәчәк атуын мин җаным-тәнем белән телим, әмма моңа әдәбият алдында торган бурычларны үтә җитди аңлаганда гына ирешеп була».

Максим Горький совет язучылары алдына «Җир йөзендә иң кирәкле кешене»—яңа геройны иҗат итү проблемасын куйган иде. Әнә шул яңа геройны иҗат итү өчен Кави Нәҗми утызынчы елларда да, Бөек Ватан сугышы елларында да җиң сызганып эшләде—поэмалар, драматик әсәрләр, хикәяләр, повестьлар язды, патриотик җырлары белән дә катнашты. Болар, һичшиксез, игътибарга бик тә лаеклы әсәрләр. Әмма яңа геройны иҗат итү өлкәсендә аның иң зур хезмәте «Язгы җилләр» романы булды. 25 ел буена язган бу эпик әсәрне, 1951 елны Дәүләт премиясенә лаек булганнан соң, «Правда» газетасы «татар әдәбиятының гына түгел, барлык тугандаш әдәбиятларның да үсеше өчен принципиаль әһәмияте булган күренекле әсәр»,—дип бәяләде.

«Язгы җилләр» якты-куе буяулар белән, көчле характерлар аша, илебез тарихының мөһим бер дәверен—октябрь кораллы восстаниесенә хәзерлек чорын сурәтли. Революцион-азатлык хәрәкәте романда, тарихи дәреслеккә туры китереп, рус, татар, һәм башка халыкларның, бигрәк тә Идел буе халыкларының туганлык союзы нигезендә тасвирлап бирелә. Романдагы көчле сурәтләү чаралары, образлы, бизәкле тел, вакыйгаларның һәм характерларның ышандыру көче бүгенге яшь язучыларга үрнәк булып, өлге булып хезмәт итәргә тиеш.

Ачлык елны романда автор менә нинди дәһшәтле итеп сурәтли:

«Рәшә челтәре җәйрәгән кырлар өстендә ялгыз тилгән оча.

Көн шундый кызу: тирән ярыклар белән телгәләнгән туфракка басар хәл дә юк. Инеш буендагы талларга хәтле яфракларын коеп, сусызлыктан көйрәп утыралар. Кайчан гына әле йомшак каз үләне белән капланган яр буйлары да хәзер тап-такыр.

Ерак чүлләрнең эссе сулышын алып килгән коры җилләр, әкияттәге пәри туен хәтерләтеп, иләмсез чиныйлар. Җиде юл чатларында, тузан баганалары күтәреп, өермәләр бөтерелә. Кырлар буенча йомарланып бүре уты тәгәри».

Аз һәм төгәл сүзле, тирән мәгънәле картина!

Кави Нәҗминең хикәяләү алымы, персонажларының сөйләше мине әле студент чакта ук мавыктыра, мин аның әсәрләренең телен кулга каләм алып өйрәнә идем. Бәлки, шул мавыгуларымның нәтиҗәсе булгандыр, «Язгы җилләр» Дәүләт премиясенә лаек булгач, мин ул хакта 1951 елны яшьләр газетасында мәкалә дә бастырдым. Әлләни зур мәкалә түгел иде, тирәнлеге дә, бәлки, чамалы булгандыр, әмма ил күләмендә танылган язучының миңа, журналның гади бер әдәби хезмәткәренә, шуның өчен редакциядә иптәшләрем алдында рәхмәт әйтүе мине шатландырган да, бераз гына гаҗәпләндергән дә иде.



*Татарстанның күренекле шәхесләре. Сулдан уңга: мәшһүр табиб Г. Терегулов, академик А. Арбузов, К. Нәҗми. 1951 ел.*

Бераздан мин бу рәхмәтнең чын күңелдән әйтелгән икәнен аңладым. Беренчедән, Кави абый миңа, син телне беләсең дип, җыелышларда русча сөйләгән берничә чыгышын тәрҗемә иттерде, икенчедән, мин аның яшьләргә карата үтә дә ярдәмчел икәнен белдем. Илленче елларда Казанга Куйбышевтан талантлы яшь шагыйрь Әнвәр Давыдов килде. Ул чагында квартир табып урнашу яшьләр өчен ифрат авыр иде. Давыдов гаиләсе белән бер хуҗадан үзләре тормый торган особнякны арендага алды. Хуҗалар берничә елга акчаны алдан түләүне таләп иттеләр. Ун мең сум (хәзерге белән санаганда бер мең сум) акча түләргә кирәк иде Давыдовка. Шул акчаны аңа, гонорарны күп итеп эшли башлагач кайтарырсың, дигән шарт белән Кави абый Нәҗми һәм аның хатыны, язучы Сәрвәр апа Әдһәмова биреп тордылар. Бу изгелектән канатланган Әнвәр Давыдов җан-фәрманга иҗат итәргә тотынды һәм нибарысы биш-алты ел эчендә барыбызны да сокландырган күп кенә поэмалар язарга өлгерде.

Әйе, сугыштан соң әдәбият мәйданына килгән яшьләргә Кави Нәҗми белән аралашу, аның киңәшләрен ишетү бәхете эләкте. Без аның татар әдәбияты тарихында зур урын тотканын аңлый идек. Иҗатының беренче чорларында ук ул ялкынлы трибун, пролетар революциясенең идеяләрен ашкынып пропагандалаучы, эшчеләр сыйныфының революцион көрәшен һәм илебез халыкларының дуслыгын армый-талмый җырлаучы булып күтәрелә. Иҗатында шушы сыйфатларны гомере буе саклый.

Кабатлап әйтәм: тормышта ул бик тиз аралашучан, сөйләсә авызына каратып тотучан, шат күңелле кеше иде. Дөнья хәлләрен, төрле мәзәкләрне аңардан да күбрәк белгән, аңардан да матуррак сөйләгән икенче берәү юктыр дисәм дә ялгыш булмастыр төсле. Шундый гадилеге, ягымлылыгы, халыкчанлыгы өстенә ул тормышны биш бармагы кебек белгән, җилкәсендә тау кадәрле энциклопедик белемнәр йөрткән зур галим дә иде.

Безнең күңелгә ул әнә шундый зур сыйфатлары белән кереп калды һәм шулай саклана. Аның иҗаты әле киләчәк буын яшьләргә дә ярдәм итәчәгенә мин бик нык ышанам.

*1986*

# АККОШ КҮЛЕНЕҢ АК КҮҢЕЛЛЕ ШАГЫЙРЕ

СИБГАТ ХӘКИМНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Сибгат Хәкимне онытa башладык түгелме? Ничектер, исеме дә соңгы араларда сирәгрәк ишетелә шикелле, җырлары да онытканда бер генә яңгырый, китаплары да чыкмый диярлек... Әгәр дә шушындый шагыйребезне дә искә алмый башласак, нинди халык булабыз соң инде без? Әллә киләчәккә Сибгат Хәкимнәрсез генә барырга уйлыйбызмы? Ай-һай, ерак китә алырбыз микән...

Кыска хәтерләләрнең исләренә төшереп китим. Сибгат Хәким (Сибгат Таҗи улы Хәкимов) күренекле татар шагыйре, җәмәгать эшлеклесе. 1911 елның 4 декабрендә хәзерге Әтнә районының Күлле-Киме авылында туган. Шунда җидееллык мәктәпне тәмамлый, пионервожатый булып эшли. 1931 елда Татрабфакка укырга керә, Казан дәүләт педагогия институтында белем ала. Аннары Татарстан китап нәшриятында, "Казан утлары" журналында эшли. 1938 елда яшь шагыйрьне СССР Язучылар союзына кабул итәләр... 1941 елның июнь аенда ук ул Кызыл Армия сафларына алына. Бөек Ватан сугышында катнашып, аннан Кызыл Йолдыз ордены һәм сугышчан медальләр белән кайта... Аннары С. Хәким янадан "Казан утлары"нда эшләп ала һәм бөтен гомерен әдәбиятка багышлый, фәкать язучылык эше белән генә шөгыльләнә. Үзе исән чагында ук төрле телләрдә 60 тан артык китабы чыга... Әмма, казна эшендә хезмәт хакы алып эшләмәсә дә, ул баш-аягы белән җәмәгатьчелек эшенә чума. Менә аның дәрәҗәләре: Россия Федерациясенең М. Горький исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык шагыйре, Ленин ордены кавалеры. Ул шулай ук күп тапкырлар Татарстан Югары Советы депутаты, РСФСР Язучылар союзы секретаре, идарә әгъзасы, КПССның Татарстан өлкә комитеты әгъзасы, Татарстан Язучылар союзы идарәсе әгъзасы булып та сайланды. Озак еллар дәвамында Язучылар союзында кабул итү комиссиясен җитәкләде, Татарстан радиосында художество советында да, "Казан утлары" журналының редколлегиясендә дә әгъза булып торды. СССР һәм РСФСР язучылар съездлары да, Мәскәүдә, илебезнең төрле өлкәләрендә, республикаларында уздырылган Татарстан әдәбияты һәм сәнгате көннәре дә С. Хәкимнән башка узмады, делегатлар арасында иң күренекле, иң хөрмәтле аксакалларның берсе булды. Кая гына барса да, кайсы халык алдында чыгыш ясаса да, татар язучылары, татар халкы исеменнән үз сүзен саллы итеп, матур итеп әйтә белде. Аның шәрык шагыйрьләренә генә хас тирән фикерле, образлы шигъри сүзе тыңлаучыларда һәрчак матур тәэсир калдыра иде.

Җыеп кына әйткәндә, Сибгат Хәким әдәбиятыбызның да, халкыбызның да, республикабызның да намусы, йөз аклыгы булды. Ул сәхнәдән үзенең "Бер горурлык хисе" дигән шигырен сөйләргә ярата иде. Әлеге шигырь яңгыраганда шагыйрьнең үзенең дә, залдагы тыңлаучыларның да күңелләре һәрвакыт халкыбыз өчен, республикабыз өчен горурлык хисләре белән тула торган иде. Яна заманнар килде, республикабыз азмы-күпме мөстәкыйльлеккә иреште. Татар язучылары да парламент трибуналарыннан үз сүзләрен әйтә башладылар. Шундый чакларда без еш кына Сибгат аганың шушы шигырен искә алабыз, үз чыгышларыбызны шул шигырь юллары белән башлап җибәрәбез:

> Бер горурлык хисе яна миндә
> Әчтән бәреп яна битләрдә.
> Сөйләр идем аны дөньядагы
> Барлык-барлык парламентларда.

* * *

Безнең буын әдипләре (шагыйрьләре дә, прозаик-драматурглары да, тәнкыйтьче-тәрҗемәчеләре дә, татарча, русча язучылары да) Сибгат ага Хәкимнең жылы канаты астында үсте: аның ярдәме белән язарга өйрәндек, аның фатихасы белән олы әдәбиятка аяк бастык, аның игътибарлы карашы астында ныгыдык, чыныктык. Алай дисәң, Фәйзуллиннар буыны да, хәтта Ш. Галиев белән И. Юзеевлар да, Сибгат аганы остазлары санады, авыр чакларда аңа таянды, анардан жылы сүз көтте, киңәш белән аңа килде. Зөлфәт белән Мөдәррис Әгъләмне әйтеп тә торасы юк... Алай гына да түгел, Сибгат ага янына, яшь каләм ияләре белән бергә, яшь композиторлар да, жырчылар да, рәссамнар да, артистлар да, галим—голәма да тартылды. Бу—рухи тартылу иде. Өлкән шагыйрь аларның һәммәсенә хәер-хак булды, ижатларына игътибарлы, үзләренә аталарча хәстәрлекле булды, алтындай вакытын да, көчен-энергиясен дә кызганмады. Нинди генә жыелыш булмасын, яшьләр турында иң кирәкле сүзне иң элек ул әйтә торган иде, кайсы гына газета-журналны ачып карасаң да, яшь каләмдәшләре турында ул язып чыга торган иде, нинди генә радио-телетапшыруны карый башласаң да, яшьләр турында ул сөйли иде. Күңеле кушканга, кирәк булганга, әдәбиятыбызның киләчәге хакына эшли иде ул әлеге изге эшләрен...



*Сибгат Хәким һәм Роберт Миңнуллин. 80 еллар.*

Сугыштан соңгы еллардан башлап Сибгат Хәким татар шигъриятендә иң абруйлы, иң актив, иң тәэсирле шагыйрьләрнең берсе булды. Үзе дә шигырь остасы иде, башкалардан да шуны таләп итте. Аның матбугатта дөнья күргән һәрбер шигырь бәйләме, һәрбер шигырь циклы, һәр яңа поэмасы олы әдәби вакыйгага әйләнде, әдәби жәмәгатьчелек аның һәрбер китабын көтеп алды. Халыкчан, тормышчан, ихлас иде аның лирик шигырьләре. Һәр татарның күңел кылларын чиртерлек образлар, гыйбарәләр таба белә иде шагыйрь. Татарның бәгыренә үтеп керерлек, таш йөрәкләрне дә эретерлек, үксеп елатырлык шигырь юлларын укыйсың да шагыйрьнең талантына, аның олылыгына, ихласлыгына сокланасың. Ул бит— туган жиренең һәр үләнен, һәр бөжәген, һәр тыкрыгын, һәр чишмәсен, үрен, сукмагын шигырьгә әйләндергән шагыйрь! Н. Нәжми үзенең Сибгат агага язган бер хатында соклануын болай белдергән иде: "Бүген хатын—кызлар көне. Ул көн синең шигырьләр белән яктыра башлады—таң алдыннан синең 2нче сандагы ("Казан утлары") шигырьләреңне укып утырдым. "Уйларыма хаким булды шул чак татарның зур, моңлы Хәкиме" дигән сүзләремне тагын да кабатлыйсы кала. Шигырьләрең берсе артыннан берсе күңелгә тама-тама сеңә бара, сеңгән саен күңел тулыша бара. Күп шигырьләр бит хәзер тамалар да, ташка тамган су тамчысы кебек, күңелдән чәчрәп очып китәләр. Салкын шигырьгә, начар шигырьгә күңел таш кебек, ә синекеләр жилеккә житәләр..." Әйе шул, жилеккә житә торган шигырьләр.

Ул, чыннан да, шигырь остасы иде. Шуңадыр да, бәлки, аның күпме шигырьләре жырга әйләнеп, халык күңелендә урын алды. "Юксыну" *(Ш. Мәжитов көе)*, "Фазыл чишмәсе" *(татар халык көе)*, "Әй, язмыш, язмыш" *(С. Садыйкова көе)*, "Кайда да йөрәктә" *(М. Мозаффаров көе)*, "Бу кырлар, бу үзәннәрдә" *(Ж. Фәйзи көе)*, "Сусау" *(С. Садыйкова көе)*, "Минем таныш өянкеләр" *(Р. Яхин көе)*, "Үрләренне менгәч" *(Р. Еникеев көе)*, "Башка берни дә кирәкми"

*(М. Мозаффаров көе)*, "Өзелгәнсең сиреньнән" *(Н. Жиһанов көе)*, "Таң атканда" *(татар халык көе)*... Нинди гүзәл җырлар! Халкыбызның үлемсез җырлары! Нинди асыл композиторларыбыз язган бит аларны! Белгәннәр бит кем шигыренә язарга! Гомумән, татар җыр сәнгатендә үзенең камиллеге, шигъри нечкәлеге, нәфислеге, образлылыгы ягыннан Сибгат Хәкимгә житкән, аны уздырган җырчы-шагыйрьләр күренми әле. Һаман да аннан үрнәк алабыз, аннан өйрәнәбез, аңа ияребез... Йә, әйтегез, кайсыбыз шушылай нечкә, нәфис итеп, таш җаннар да сусарлык итеп яза ала:

Ник болай гомерем буена
Бетмәгән сусау икән?
Сусаудан янган күңелгә
Су салып торсаң икән.

* * *

Билгеле инде, Сибгат Хәким туган ягының гына җырчысы түгел. Ул халык күңеленә барыбызга караганда да якынрак, әмма аның шигъри колачы тагын да киңрәк, аның үз җирен, үз халкын яратуы шигырьләренә бәреп, ургылып чыкса да, шигъри фикерләве, барыбер, тирәнрәк ята. Шагыйрьнең үз халкына мәхәббәте арткан саен, аның шигъри даирәләре тагын да ныграк киңәя бара, ул инде туган җир кысаларына гына сыя алмый башлый. Аңа яна киңлекләр, яңа офыклар кирәк! Җан әрнүләрен, күңел сыкрауларын, иксез-чиксез уй дәрьяларын ничек тыймак кирәк?!. Нәтиҗәдә, бер-бер артлы "Дуга", "Дәверләр капкасы", "Эзлиләр Европа буйлап", "Кыти" поэмалары, "Немец дәфтәрләре", "Карловы Вары шигырьләре" туа. Аның Мәскәүдә китаплары чыга тора, исеме телгә керә, иҗатына рус тәнкыйтьчеләре тарафыннан да игътибар арта. Үзәк матбугатта аның исеме Р. Гамзатов, К. Кулиев, М. Кәрим, Д. Кугелтдинев, Н. Нәҗми, Я. Ухсай кебек күренекле шагыйрьләр рәтеннән атала башлый. Сибгат Хәким хаклы рәвештә Россиянең, элекке Советлар Союзының иң зур шагыйрьләре рәтенә күтәрелә. Шулай итеп, ул үзенең иҗатын гына түгел, гомумән, татар шигъриятенең дә ил күләмендә мәртәбәсен арттыра, данын күтәрә. Бөтен илгә, дөньяга мәгълүм Тукай белән Җәлил янына Сибгат Хәким дә килеп өстәлә...

Сибгат Хәким безнең искиткеч зур милли шагыйребез иде, чын мәгънәсендә, халык шагыйребез иде. Ул бер вакытта да бернигә дә битараф булмады. Ул гомер буе татар дип җан атты, әдәби-мәдәни тормышыбызның, республика тормышының уртасында кайнап яшәде. Аны партия өлкә комитеты пленумнарында да, иҗат союзлары уздырган һәртөрле җыелышларда да, юбилей кичәләрендә дә, язучыларның иҗат секцияләре эшендә дә еш күрергә була иде. Һәм, һичшиксез, чыгыш ясап, үзенең төпле фикерен әйтә, теге яки бу мәсьәләгә үзенең мөнәсәбәтен белдерә иде. Тормыштагы, җәмгыятьтәге һәртөрле гаделсезлекләр, бәхетсезлекләр, һәртөрле ялганнар, ялгышлар аның җанын бертуктаусыз телгәләп торды. Шуна күрә дә ул барысын да кайгыртырга тырышты. Ә бит ул татар шигъриятен генә түгел, милләтебез кайгысын да кайгыртып гомер сөрде. Иҗатында да, тормышында да газиз халкы өчен, газиз республикасы өчен ут йотып яшәде. Аның еш кына Тукай, Җәлил образларына мөрәҗәгать итүе дә бер дә юкка гына түгел иде. Милли хисләрен, милләтпәрвәрлек тойгыларын ул бөек әдәбиятыбыз, аның Тукайлары, Җәлилләре, Туфаннары, Бабичлары аша, аларның бөеклекләре аша да житкерергә омтылды...

Килергә дә ярый дөньяга,
Ташлап читкә бар эшне,
Тик укыр өчен генә дә
Шәехзадә Бабичны.

* * *

Сибгат Хәким җәйге гомеренең купчелеген Аккош күлендә уткәрде. Татар шагыйрьләренең Мәккәсе! Татар шигъриятенең тылсымлы бер төбәге.

Биредә—Х. Туфан, Ә. Фәйзи, Г. Бәширов, А. Әхмәт, А. Шамов, И. Гази, Н. Дәүли, З. Нури, Н. Юзиевларның рухы, биредә—Ш. Галиев, Р. Харис, Р. Гаташ, Г. Рәхим, М. Әгъләм шигърияте... Сибгат Хәкимнәрдән соң монда башка язучылар, шагыйрьләр күчеп килде. Традицияләр дәвам итә. Күпме татар шигыре беренче тапкыр шушында туган, беренче тапкыр ак кәгазь битенә шушында төшкән, беренче тапкыр шушында яңгыраган. Шул исәптән, Сибгат аганың да күпме асыл шигырьләре шушы Аккош күлендә язылган, Аккош күленә багышланган...

Соңгы елларында минем үземә дә Сибгат ага белән Аккош күлендә күршеләр булып яшәргә насыйп булды. Йортларыбыз кара-каршы гына иде. Үзеннән-үзе якынаеп киттек. Сөйләшеп сүзебез бетмәде. Әлбәттә инде, күбрәк ул сөйли иде. Мин бераздан телевидениегә эшкә күчтем. Яна эштә яна уй-планнар да житәрлек. Күп очракта өлкән шагыйрь белән киңәштабыш итәм, аның сүзенә колак салырга тырышам. Үзен дә телевидениегә чакырыштырам. Безнең тапшыруларда бик теләп катнашты ул. Әгәр дә берәр тапшыруга чакыра башласаң, һичшиксез, килми калмас иде. Сибгат аганың зәвыгын, әдәбиятка, язучыларга таләпчән булуын яхшы белгәнгә күрә, без үзебез дә аны теләсә кайсы тапшыруга чакырмый идек. Дөресрәге, аны кайсы тапшыруга чакырырга-чакырмаска икәнен чамалый идек. Мин телевидениегә күчкәч, ул Х.Туфан, Ә.Еники турындагы тапшыруларда чыгыш ясады, С.Садыйковага, Б.Урманчега, Н.Нәжмигә, Т.Хажиәхмәтовка багышланган тапшыруларда бик теләп катнашты. Соңгы чыгышы М.Мәһдиев хакында булды. Без аны кинооператор В.Миронов белән шагыйрьнең өенә барып яздырдык. 1986 елның 9 апреле иде ул.



*Бер төркем язучылар. Сулдан уңга: Ф. Хөсни, С. Викулов, Г. Ахунов, З. Нури, К. Кулиев, С. Хәким, Я. Мостафин, Г. Кашшаф. 1971 ел.*

Сибгат ага белән тагын бер изге эш эшләгәнбез икән әле. Хәсән Туфанның вафатыннан соң бер төркем язучылар (С. Хәким, Г. Бәширов, Ш. Галиев, Н. Юзиев, И. Юзеев, Р. Гаташ...) Аккош күленә жыела торган булдык. Туфанның туган көнендә! Салкын декабрь аенда! Гадәттә, Сибгат агаларның өенә кереп тулабыз. Мичкә ягып жибәрәбез, чәй куябыз, бәрәңге пешерәбез. Казаннан килгән күчтәнәчләр чыга. Аннары Туфан дачасына сугылабыз. Түгәрәк өстәл янында истәлекләр сөйләнә, шигырьләр укыла. Сибгат ага—мәжлеснең уртасында. Аның телендә—Туфан гына. Ул—канәгать, ул—бәхетле, ул—монсу... Берничә ел рәттән шулай жыелдык. Телевидение

архивында ул кинокадрлар әле дә саклана торгандыр. Тик менә Сибгат ага үзе арабыздан китеп баргачтын, жыелулар бетте...

Ә шагыйрьнең үлеме турында хәбәр килгәндә без режиссер Әхтәм Зарипов белән күпсерияле "Тукай" телевизион спектакленең просмотрында утыра идек. Мин телсез калдым. Әхтәм абый: "Эх, "Тукай"ны тәки карый алмады",—дип кенә әйтә алды. Хикмәт шунда иде ки, Сибгат ага телеспектальнең сценариен укып, аңа уңай рецензия дә язган кеше. Аның күптән инде шундый бер сериал күрәсе килеп йөри иде.

Гомумән, соңгы елларын, Тукайның 100 еллыгы алдыннан, шагыйрь фәкать Тукай рухы белән генә яшәде шикелле. Аккош күлендәге сәгатьләр буенча сузылган бихисап әңгәмәләр, сөйләшеп утырулар һәрчак Тукайга килеп тоташа иде. Бөек шагыйрь турында сүз чыгуга ук: "О-о-о, Тукай бит ул!"—дип башлый торган иде ул сүзен. Аннар тезеп китә: "Тукай турында әле өстән генә язалар бездә. Әнә, Пушкинның, Лермонтовның шигырьләре янына ясалган рәсемнәре турында гына да том-том әйберләр язалар. Тукайның "Уклар" кебек газеталардагы рәсемнәре турында яза башласаң да әллә күпме әйберләр язып булыр иде... Р. Нәфыйков Тукай турында яңа китап язган. Тукайның даирәсе турында. 300 битле. Менә шунда күренәчәк инде Тукайның зурлыгы. Нәфыйков бит үзе дә Уральскидан. Аннары ул Әхмәт Фәйзиләрдә торды. Тукай белән кызыксынуы шуннан башлангандыр да әле аның... Тукай милли шагыйрь ул. Интернационалист та. Зур шагыйрь бер чакта да чикләнми. Милли шагыйрь булмаса, интернационалист та булмас иде... Ике мәкалә язып бетердем. Ленинградта Тукай "Библиотека поэта"да чыгачак. Шуңа кереш. "Художественная литература" Җәлилнең сайланмаларын әзерли. Шуңа 12 битлек мәкалә бетердем. Рафаил (улы) машинкада баса. Машинистка эзләп торасы юк. Аннары кыска гына бер әйбер язып куйдым. "Кем ул шагыйрь" дип атала. Тукайны укыганда туган уйлар, хисләр... Тукайның иске тәрҗемәләре әйбәтрәк. Стиле, рухы сакланган. Тәрҗемәчеләре дә тегенди-мондый гына түгел: Ахматова, Маршак, Петровых, Звягинцева, Липкин. Ә Шубин Тукайны берүзе тәрҗемә итәргә теләгән иде. Үзе китеп барды. Хәзергенекеләрдә Тукай юк. Жыйсаң, бөтенесе 20 ләп бардыр. Әйбәтләре. Хәзерге калыпка салып тәрҗемә итәләр. Тукайны алай ярамый... Тукай турында күпсерияле хроникаль фильм эшләргә кирәк. Балачагыннан алып үлеменә чаклы. Әнә үзбәкләр Хәмзә турында төшергән кебек. Мәскәүдән күрсәтерлек итеп. Башка халыклар белерлек итеп. Ә Хәмзә безнең Тукай янында бик бәләкәй ул... Туфан театрга яза дип ишеттем. Тукайның Акчуриннарда булуы турында. Ну мин бераз куркам. Социаль якка басым ясап, ялгыш якка китмәсә дип. Ә бит Тукай Акчуриннарга да барган, Петербургка Бигиевларга да. Мәһдиевкә күпме әйттем. Яз, синең тема ул дип. Юк, язмый..."

Тукайга табынганын, Тукай аны һәрчак борчып торганын яхшы белгәнгә, беркөнне мин аңа телевидениедән Тукай турында чыгыш ясарга тәкъдим иттем. Телестудиядә түгел, ә Кырлайда, Тукай туган жирләрдә. Ул уйлап карарга булды. Аннары Аккош күлендә очрашкан саен: "Тукай нишли, Сибгат абый?"—дип сорый торган идем. "Оешып килә",—дип жавап кайтара иде. Ә беркөнне урманнан ял итеп кайтып килгәндә: "Менә каеннарга Тукай турында сөйләп кайтып киләм әле",—дип үзе сүз башлады. Аның бу сүзләре миңа бик нык тәэсир итте. Баксаң, Сибгат абыебыз ничә атна инде телевидениедән сөйлисе сүзләрен урманда кабатлап, шомартып, репетиция ясап йөри икән. Бу аның Тукайга, әдәбиятка, үз-үзенә һәм, ниһаять, безнең телевидениегә булган житди мөнәсәбәтен чагылдыручы бер мисал иде.

Тапшыруны халык яратып карады. Редакциягә дә, шагыйрьнең үзенә дә бик күп хатлар килде. Шагыйрь Г.Афзал шушы тапшыру тәэсиреннән хәттә шигырь дә язып бастырды. Анда шундый юллар да бар:

Шагыйрь эзе буйлап шагыйрь йөри,
Эстафета алган ике куллап.
Күңел тулып, шагыйрь жаны эри,
Ак каеннар тыңлый башын болгап.

* * *

Сибгат Хәким минем күңелемдә зыялы бер зат булып, ифрат та сабыр холыклы шәхес булып калды. Хак мөселман тәрбиясе, чын татар тәрбиясе иде анда. Гомерендә күпне күргән, сугыш ялкыннарын узган солдат булса да башка фронтовиклардан аерылып торды. Ул үзеннән өлкәнрәкләргә тартылды, алардан үрнәк алып яшәде. Аның зыялылыгы әнә шул өлкәннәргә булган игътибарлы, ихтирамлы мөнәсәбәтеннән дә ачык күренде. Тукайларга, Җәлилләргә табынуы шигырьләрендә, поэмаларында чагылса, Исәнбәт, Туфан кебек өлкән каләмдәшләре белән дусларча аралашулары кеше арасында, җыелышларда, мәҗлесләрдә аеруча күзгә ташланды. Ул булганда тупас кылану, ямьсез сөйләшү гайре табигый хәл булыр иде. Кайбер әрсезрәге урынсыз мәзәк-мазар сөйләп теленә салына башласа да Сибгат ага бер генә карап куяр иде. Өлкәннәргә дә, безнең кебек яшьләргә дә ул һәрвакыт "сез" дип кенә дәште.



*Сибгат Хәким улы Рафаэль белән. 80 еллар.*

Сибгат ага гади укучылар белән дә, җитәкчеләр белән дә уртак тел таба белде. Аның белән киңәш-табыш иттеләр, аның сүзенә колак салдылар. Шунысы кызык, ул яшәгән йорт партия өлкә комитеты бинасы белән янәшә генә иде. "Обком секретаре Вәлиев белән безнең тәрәзәләр кара-каршы гына. Тәрәзәләрне ачабыз да сөйләшеп алабыз. Обкомга барып та торасы юк",—дип шаяртканы истә калган. Ә татар шигърияте өчен Сибгат Хәким үзе "обком" иде. Беренчедән, ул үзе яшьләргә дә, өлкәннәргә дә ярдәм итәргә тырышты. Икенчедән, шигырь чыгарулар, китап бастырулар, со?зга керүләр, исем-дәрәҗәләр, премия-ләр бирү, нигездә, аның ризалыгы, фатихасы белән эшләнде. Шигырь мәсьәләсендә ул һәрчак принципиальлек күрсәтте. Халтураны җене сөймәде, начар шигырьгә, начар шагыйрьгә ничек тә юл куймаска тырышты. Тик шунысы: ул артык киң күңелле иде. Аның шул киң күңеллелегеннән шактый гына урта кул шагыйрьләр дә еш файдаланды. Аларсыз булмыйдыр да инде, күрәсең.

Сибгат Хәким дусларга бай иде. Үз татарыбызны гына түгел, чувашларны да, башкортларны да яратты ул. Мари халкына булган олы мәхәббәте үзе генә дә ни тора! Шагыйрьнең мәхәббәте соңыннан шигырьләргә, поэмаларга да күчте. Гомер буе Я. Ухсай, К. Кулиев, М. Дудин, М. Львов, Д. Кугульдинов, Р. Моран белән аралашып яшәде. Нажар Нәҗми белән дуслыклары гомер азакларына кадәр дәвам итте.

Әйе, шагыйрьнең офыклары киң иде, шигъри күңеле бернинди чикләрне дә белмәде. Ул татар дөньясы белән генә канәгатьләнмәде, татар шигъриятен дөнья әдәбиятыннан аерып карамады: бөек Кол Гали белән Тукайны да, Дәрдмәнд белән Туфанны да, Пушкин белән Лермонтовны да, Гете белән Шиллерны да үзенең остазлары итеп санады. Әлеге бөекләрнең шигърияте, дөньяга карашлары, фәлсәфәләре, тормыш юллары аңа һәрвакыт үрнәк булды. Шагыйрь һәрвакыт остазларының бөеклегенә, аларның шигъри биеклегенә омтылды. Татар шигъриятенең бәхетенә, Совет чоры шартларында да шагыйрь бик тә югары шигъри биеклекләргә ирешә алды. XX гасыр татар шигъриятенең биеклеге, бөеклеге Сибгат Хәким иҗаты белән дә үлчәнә...

Аккош күленең ак күңелле шагыйре иде Сибгат Хәким. Андый шагыйрьләр онытылмый, андый шагыйрьләр халык күңелендә, гасырлар хәтерендә, тарих хәтерендә саклана!

**Роберт МИҢНУЛЛИН**

# АК ЧӘЧӘКТӘЙ ГОМЕР

ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Мәңге тынгы белмәс күңелләре, ашкынулы җаннары һәм ярсу хыяллары белән чорларны колачлап, төрле кыйтгаларны иңләп яшәгән иҗатияләре—язучылар да—көннәрдән беркөнне бу якты дөньяны калдырып китәләр... Әйе, китәләр... Ләкин алардан соң халык күңелендә яшәүләрен дәвам итәр өчен әдәби әсәрләр кала... Алай гына да түгел: әдипләр яшәп киткәннән соң җирдә алар турында төрле хатирәләр, риваятьләр дә кала... Шулай итеп, иҗат кешеләре халык хәтерендә яшәүләрен ике төрле юл белән дәвам иттерәләр: әсәрләрендә һәм истәлекләрдә...

Әдәбият галиме Мөхәммәт ага Гайнуллинның инде бик күп еллар элек без яшьләргә сөйләгән мондый хатирәсе истә калган.

Алтмышынчы еллар башында Мөхәммәт ага үзенең гаиләсе белән Ялтадагы иҗат йортына ял итәргә бара. Берничә көннән ике чемоданын күтәреп Габдрахман Әпсәләмов та килеп төшә. Аңа тәрәзәләре диңгезгә карап торган «люкс» бүлмәләрен бирәләр... Ярый, икенче көнне безнең Мөхәммәт абыебыз Габдрахман Әпсәләмовны су коенырга чакырыйм дип керә бит инде. Әмма... Әмма керсә—аның бүлмәсендә таныш түгел егет белән кыз утыра! Галим кеше моңа бик аптырый һәм шундук язучыны эзләп таба да аны «допрослый» башлый: «Моны ничек дип аңларга? Бу ни эш?»

Ә Габдрахман Әпсәләмовның җавабы нинди булган дисез?

—Мөхәммәт туган...—ди ул үзенең ипле-сабыр тавышы белән.—Мин инде хәзер дөньяны бик күп күргән. Миңа инде хәзер диңгезгә карап ял итү әлләни кызык түгел!.. Аннары соң шул: монда да минем бөтен вакытым иҗат белән үтә! Ә бу яшьләр әле яңа гына туй үткәргәннәр, бирегә дә беренче мәртәбә килүләре. Шулай булгач, аларның менә бу көннәре гомергә хәтердә калырдай күңелле узсын—кинәнсеннәр яшьләр! Алар минем булачак әсәрләремнең геройлары бит... Ә миңа, әнә, аларның бер бүлмәсе дә бик җитә: язу машинкам белән көн-төн чүкелдәп утырам мин шунда...

Моннан күп еллар элек ишеткән булсам да, бу хатирә минем хәтеремә бик озакка сеңеп калды. Менә хәзер дә ул якты күренеш күз алдымда тора һәм әдипнең холкы-фигыле, дөньяга карашлары хакында бик күп нәрсә сөйли.

Чыннан да, әдип шәхесенең кем икәнлеге, аның нинди икәнлеге менә шушы эпизодта бик ачык күренә түгелме соң?! Әйе, биредә Габдрахман Әпсәләмовның киң күңеле чагыла. Күп авырлыклар күргән, фронт юлларын узган, яшьлегендә заводның кырыс сынавын уңышлы үткән һәм яшәүнең, кеше гомеренең гади, әмма үтә җитди кануннарын яхшы төшенгән кеше күңеленең чагылышы бу.



*Хәсән Туфан белән Габдрахман Әпсәләмов укучылар арасында. 60 еллар.*

Татар халкының атаклы әдипләреннән берсе—басылып чыккан китаплар саны буенча ул бары тик Тукайдан гына калыша—Габдрахман Әпсәләмов язган әсәрләре белән генә түгел, ә үз тормышы белән дә җирдә яхшылыкны, кешелеклелекне үстерү, күбәйтү максаты белән илһамланып, дәртләнеп яшәде.

Сугыштан соңгы елларда аның әсәрләрен укып кемнәр генә әсәрен-

мәде дә, кемнәр генә үзенә рухи канат алмады икән?! «Ак төннәр».. Карелиянең салкын кышы, ялангач кыялары, адәм баласы чаңгысыз адым да атлый алмастай тирән кар катламы... Әнә шундый гаять авыр шартларда безнең солдатлар дошманга каршы сугыша. Бу китап сугышның кырыс чынбарлыгы, анда кеше характерының чагылышы, онытылмас конфликтлары белән истә кала.

Әлбәттә, ул чорның рухи тормышына хас булганча, монда «урра патриотизм» да, совет солдатының соң дәрәҗәдә дип әйтелердәй фидакарьлеге дә бик еш күренә. Аннары тагын бер мөһим факторны истә тотыйк: биредә язучы үзе дә яшьрәк, тәҗрибәсезрәк шәхес бит әле. Аның өчен бары тик бер генә нәрсә мөһим—дошман начар, безнекеләр—әйбәт!

Ләкин объектив булу өчен тормыш чынбарлыгына тарихи карау, тарихи якын килү дигән таләп бар. Ягъни вакыйгаларны шул чор контекстында, шул чорда хөкем сөргән социаль һәм сәяси тормыш яссылыгында аңларга омтылу. Әгәр дә бүген без ул чорның психологик халәтенә керә алсак—дошманны җиңү өчен әлеге карашның булу мәҗбүриятен аңларбыз.

Язучыга зур популярлык китергән әсәр «Алтын Йолдыз» романы булды. Укучылар кулына 1948 елда килеп кергән әсәрнең бөтен эчтәлеге, бөтен барлыгы, бөтен рухы исемендә үк чагыла төсле. Вакыйга сугыш чорында бара, үзәктә—яшьләр, төньяктагы диңгез сугышлары, яшь егетләрнең тәү мәртәбә фронт чыныгуы алулары... Әмма романда иң истә калганы—Галим Урманов образы, әле яңа гына урта мәктәпне тәмамлаган татар егетенең батырлыкка күтәрелү баскычлары...

Габдрахман Әпсәләмовның бу романы тиз арада рус һәм башка телләргә тәрҗемә ителә, аларның да иң яраткан әсәрләреннән берсенә әверелә. Русча басылган китапның «Нинди матур! Какая прелесть!»—дигән иң беренче сүзләре үзләрендәге романтик аһәң, күтәренкелек дулкыны, пафос белән менә инде ничә дистә еллар укучыларны тылсымлап йөртә, яшәтә.

Сугыш һәм кеше батырлыгы, горурлык яисә куркаклык темасы Габдрахман Әпсәләмов иҗатының буеннан буена кызыл җеп булып сузыла.

Без тынычта аттан артык эшлибез,<br>Без сугышта юлбарыстан көчлебез!—

дип язган бөек Тукайдан алып «Алтын Йолдыз», «Газинур», «Мәңгелек кеше» романнарын язган Габдрахман Әпсәләмовка хәтле әдипләребезнең бу мәсьәләгә карашы бер төрле: яуда туган җирне саклау, аның өчен сугышу—изге гамәл. Мондый иман безгә бәләкәйдән үк сеңдерелгән, ул безгә ана сөте белән кергән. Әнә шуңа күрә немец фашистлары сугыш ачкач илдә күп санлы каһарманнар барлыкка килә: Брест крепосте батырлары, үз очкычын дошманга юнәлтеп үзе дә шунда һәлак булучы очучылар, партизан кыз Зоялар...

Ә инде аннары Шакирҗан Мөхәммәтҗанов (аны башта Александр Матросов дип йөрттеләр) батырлыгы... Бераздан тагын бер татар егете Газинур Гафиятуллин каһарманлыгы...

«Газинурның үз исеме үк мине әсәр язарга илһамландырды...—дип сөйләгәне истә калган бу әдипнең.—Чөнки «гази» сүзе ул «мәңгелек» дигән мәгънәне аңлата. Димәк, бу батырның исеме дә мәңгелек нур булып чыга!»

Ил үзенең сугыш каһарманын Советлар Союзы Герое исеме биреп зурласа, Габдрахман Әпсәләмов бу фидакарь затка багышлап үзенең «Газинур» исемле атаклы романын язды һәм аны 1951 елны бастырып чыгарды. Алдагы әсәре шикелле үк авторның бу романы да иң башта татар укучыларының, ә аннан соң башка милләт китап сөючеләренең дә яраткан әсәренә әйләнде.

«Алтын Йолдыз», «Газинур»... Болар икесе дә үткән сугыштагы татар каһарманнарына дан җырлаучы әсәрләр. Үз вакытында да, хәзер дә укучылар тарафыннан яратып кабул ителә торган романнар.

Анысы шулай. Әдәби әсәр буларак болар, һичшиксез, уңышлы әсәрләр. Ләкин менә без—егерме беренче гасыр башында яшәүче кешеләр—бу романнарга ничек карарга тиеш соң?

Иң башта без үткән сугышның төп мәгънәсен искә төшерик. Каян килеп чыгу, ничек башлану сәбәпләренә кереп тормасак, сугышның асылы үзебезнең туып үскән җиребезне саклауга кайтып кала. Газинурлар, Шакирҗаннар үз

гомерләрен әнә шул туган җир өчен бирделәр.

Биредә безнең оппонетлар: «Ә ул ил бит безнең ил түгел иде!»—дип каршы төшәргә телиләр. Бу сүздә дә күпмедер хаклык бар. Әйе. Элеккеге СССРның нигезе булган Русия безне 1552 елда басып алды, меңләгән татарны кырды, юк итте. Олуг өметләр белән көтеп алынган социалистик революциядән соң да безнең бихисап асыл затларыбыз атылды, төрмәләрдә черетелде. Ләкин, менә шуларның барысына да карамастан, без бит үзебезнең туган җиребездә яшәвебезне дәвам иттек. Бу җирләр безнең туган җир булудан туктамады! Һәм аннары: болар бит барысы да—безнең бик борынгы җирләребез! Борынгы дәүләтебез киңлекләре! Без әнә шул җирләрне сакламыйча тагын нәрсә сакларга тиеш идек соң?!

Минемчә, менә шушы хакыйкать—иң зур дәреслекнең барыбер, Газинурлар, Шакирҗаннар һәм алар батырлыгына дан җырлаучы әдип Габдрахман Әпсәләмовлар ягында булуын раслый.



*Татар һәм чуваш язучыларыннан бер төркем. Сулдан уңга: Александр Алга, Габдрахман Әпсәләмов, Афзал Шамов, Педер Хузангай, Хәсән Туфан, Зәки Нури. 60 еллар.*

Югарыда аталган әсәрләр турында сүз барганда аларда күтәрелгән тагын бер мөһим проблеманы узып китү мөмкин түгел. Роман геройларының укучыга булган әхлакый тәэсире, тәрбияви роле. Чыннан да, Газинурлар батырлыгы, аларның фидакарьлеге турында матбугат битләрендә бүген бер дә юкка гына бәхәсләр куермый. Тормышыбызда яңадан шәхси мәнфәгатьләр көчәя, кешеләребездә ертксычлык инстинктлары көннән-көн үсә бара. «Америкача яшәү» дип аталган тормыш стиле дә телевизор экраннары аша бары тик физик көчне, бүтәннәрне изү-сытуны, буйсындыруны һәм әнә шул максат белән үтерүне, кыйнауны, мыскыллауны пропагандалый. Халыкка, бөтен җәмгыятькә матур үрнәк күрсәтергә тиешле кешеләребез дә, җитәкчеләребез дә, еш кына шәхси мәнфәгатьләреннән өстен була алмыйлар—матди байлык туплау дигән рухи сазлыкка бата баралар. Мондыйларга карата халыкның, илнең нәфрәте көннән-көн артуы гаҗәп түгел.

Нәкъ менә шуңа күрә дә безнең көнелләрдә яңадан да Газинурлар—мәңгелек нур булып калка. Аларның батырлыгы, ул каһарманлыкның олуг мәгънәсе ачыклана бара.

Юк, аларның батырлыгы тарихи күренеш кенә булып калмады. Бүгенге яшәеш өчен дә Газинурлар кирәк! Бүген милләтнең иң мөһим, иң җитди эшләренә алынучылар ни өчен бик тә аз? Шәхси мәнфәгатьләргә зыян килгәнгә күрәме? Халык кайгысын кайгыртырга вакыт калмагангамы? Ил, милләт мәнфәгате икенче, өченче урынга чиккәнгә күрәме?

Әгәр дә, чыннан да, шулай булса—без ул чагында ничек итеп бүгенге шәхесләребезнең зурлыгы, бөеклеге турында сөйли алабыз соң?

Биредә зур каршылык килеп чыга түгелме соң? Яисә инде бу—тыштан бик зур күренергә тырышкан кешенең, чынбарлыкта, бик тә бәләкәй адәм булып чыгуымы икән?

Габдрахман Әпсәләмовның моннан ярты гасыр чамасы элек язылган әсәрләре бүгенге укучыда әнә шундый җитди уйлар уята. Аларның бүген дә мәгънәсе һәм тәрбияви көче зур.

Менә хәзер, милләтебезнең бу атаклы әдибе үзе дә инде мәрхүм булганнан соң, аның иҗаты турында кат-кат уйланасың да тагын бер мәртәбә шундый фикергә киләсең: чыннан да, Габдрахман Әпсәләмов кешеләр яшәеше өчен мәңгелек булган мәсьәләләр хакында уйланып язган икән! Мисал өчен

аның 1960 елда иҗат ителгән «Мәңгелек кеше» романын алыйк. Бирелә дә без авырлыклар уртасында калган Кешене күрәбез. Авырлыкның да ниндие әле—фашист концлагере! Әсәрнең төп каһарманы—Бакый Назимов шул ук Газинур, Шакирҗаннар һәм Карбышевлар нәселеннән!

Бүгенге көн ноктасыннан караганда, бигрәк тә, яшьрәк буын вәкилләре исеменнән сүз йөртсәк—физик авырлык кичерүчеләргә, иман, идея өчен, гаделлек өчен зур корбанга баручыларга ничектер елмаебрак та, өстәнрәк тә карарга мөмкин шикелле. Ләкин... Ләкин без үткәндәге һәм хәзерге тарихи вакыйгаларның ничек барышын истән чыгармыйк, көрәшнең котылгысыз булган шартлары, таләпләре турында онытмыйк. Гел кеше артына посып, кеше җилкәсенә салынып яшәүчеләр үзләрен эчтән генә иң акыллы дип саный бугай инде, ә халыкка бит алар комик бер персонаж булып күренә!

Хәзерге тормышта рухи яктан көчсез, мескен типлар күбәя барганда Габдрахман Әпсәләмовның мәңгелек кешесе Бакый Назимов та безнең өчен зур, монументаль шәхес булып һаман да тере килеш яши бирә.

Ә инде 1965 елның январь аеннан «Казан утлары» журналы үзенең битләрендә бу язучының «Ак чәчәкләр» романын бастыра башлагач татар укучылары, гомумән, бөтен дөньяларын онытты шикелле. Ул чагында, чыннан да, бөтен кешенең кулында әнә шул әсәр кебек күренә иде! Юк, биредә табиблар тормышы, галимнәр дөньясы гына түгел—ә тулаем яшәеш үзе, мәхәббәт һәм нәфрәт дәрьялары иде! Бу романдагы төп образ Гөлшаһидә үзе генә дә ни тора! Ә аның җыры, хәзер дә халык тарафыннан яратылып җырлана торган үлемсез сүзләре:

Син чыда барсына, сөюең хакына,
Ул килер баш ияр бер заман каршыңда.

Габдрахман Әпсәләмовның бу романы шулай ук тиз арада рус теленә тәрҗемә ителде һәм Мәскәүдәге «Роман-газета»да басылып чыкты. Күп миллионлаган тираж белән! Менә шушы елларда Г. Әпсәләмов ил күләмендә иң күп укыла торган язучыга әверелде. Бу хакта ул чор матбугатында бик күп хәбәрләр басылды, моның чынлап та шулай икәнлеге әллә ничә мәртәбә расланды.

Шул ук елларда Татарстан җитәкчеләре әдипне Социалистик Хезмәт Герое итү фикерен дә күтәрәләр. Бу идея шактый ук реаль дә була. Ләкин... Ләкин ул чагында бу фикергә Татарстан Язучылар идарәсе... каршы төшә! Нилектән һәм ни өчен икәнен укучыбыз үзе дә аңлый булыр. Көнчеләр һәм хөсетлеләр һәр заманда да табыла тора.

Шулай итеп, әдәбиятыбыз гомергә «геройсыз» торып калды. Байтак еллардан соң күтәрелгән Сибгат Хәким кандидатурасына исә Мәскәү риза булмады...

Көрәсез, Габдрахман Әпсәләмов тормышы безгә бу яктан да зур гына гыйбрәт бирә. Әдип гомере үзе үрнәк булган хәлдә дә!

Әйе, әле моннан соң да язучының бик күп әсәрләре иҗат ителде: «Сүнмәс утлар», «Агыла болыт», «Яшел яр» романнары булды... Билгеле, алар турында үз заманында төрле сүзләр ишетелгәләде. Романнарның берсенә «производство темасы» дип, икенчесенә «Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренә багышланган» дип, ә өченчесенә исә «укытучылар тормышын яктырта» дигән тамга суктылар да, аларның эчтәлеген байтак кына тарайттылар. Ул елларда минем үземә дә бер мәкаләмдә Габдрахман аганың исемен атамыйча гына: «бер темадан икенчесенә сикерү» дигән рәвешлерәк сүзләр белән төрттереп үтәргә туры килгән иде. Билгеле, моның өчен үкенмим үкенүен, ләкин барыбер: «ул чагында мәсьәләгә киңрәк карарга кирәк булмадымы икән?» дигән шик яши күңелдә... Мөгаен шулай кирәк булгандыр ул.

Яңадан да бөек Тукаебыз сүзләрен искә төшерик: «Без сугышта юлбарыстан көчлебез, Без тынычта аттан артык эшлибез!» Сөекле әдибебез Габдрахман Әпсәләмов үзенең бөтен әсәрләре белән әнә шул хакыйкатьне тагын бер мәртәбә раслады түгелме соң?! Милләтебезнең сугыш һәм хезмәт каһарманнарына әдәби һәйкәл—рухи һәйкәл салды ич ул! Газинур Гафиятуллин, Галим Урманов, Бакый Назимов, Урәзмәт карт, Гөлшаһидә, Җәлил һәм аның көрәштәшләре... Менә бу шәхесләр барысы да бүген халкыбыз күңелендә онытылмас якты образлар булып яши.

Халкыбызның тырыш та, батыр да булуын күп мәртәбәләр әйтәбез. Соңгы елларда гына да тагын бер каһарманыбызның зур егетлеген үзәк газеталар да танырга һәм язып чыгарга мәҗбүр булды: рейхстагка беренче булып байрак кадаучы Гази Заһитов батырлыгы ил күләмендә якты балкыш булып калыкты! Аның сугыштан соң авылда гап-гади тормыш алып баруы, ул сөйләгән сүзләргә күпләрнең ышанмавы һәм батыр Газиның (аның исеме дә «мәңгелек» дигән мәгънә) серле һәм очраклы рәвештә үлеп китүе... Менә шушы шәхес язмышы да бүген үзенә язучы игътибарын—яңа Әпсәләмовны көтеп тора түгелме?!



*Ватан сугышы фронты газеталарында эшләгән редакторлар һәм хәрби корреспондентлар. Алгы рәттә, уртада Габдрахман Әпсәләмов. 1965 ел.*

Әйе, соңгы елларда әдәбиятыбыз тормышның кара, начар якларын күрсәтү белән мавыкты... Артык нык мавыкты! Без менә хәзер: «телевизордан күрсәтелгән Америка кинолары халыкны боза!»—дип чаң сугабыз, ил күләмендә ниндидер кискен чаралар күрүне таләп итәбез. Һәм бу—бер яктан бик тә дөрес таләп, кичектергесез рәвештә хәл итүне сорый торган проблема... Әмма әдәбиятыбыз үзе дә соңгы елларда тормышның гел начар ягын гына күрсәтеп, шулай ук халыкның күңелен боза түгелме соң?!

Чыннан да, безгә хәзер Габдрахман Әпсәләмов әсәрләре шикелле якты, нурлы, «мәңгелек нур» белән өретелгән романнар, повестьлар җитми! Тулаем яшәвебезгә дә яктылык, матурлык, оптимизм һәм фидакарьлек җитешмәгәнгә күрә, әлеге саналган сыйфатларга хәзер безнең җәмгыятьтә бик тә зур дефицит булганга күрә—андый әсәрләр язылса калса укучыбыз бигрәк тә нык сөенер иде.

Татар халкының бик ерак гасырларга сузылып киткән тарихи юлында байтак каһарманнар, фидакарь җаннар булган. Юк, милләт аларның якты гомерләрен, изге гамәлләрен онытмаган—андый фидакарь җаннар турында төрле легендалар, кыйссалар, дастаннар чыгарган. Андый әсәрләр авыр яшәү юлында аерым кешеләргә дә, тулаем халыкның үзенә дә бик нык булышкан. Кыен чакларда рух ныклыгын сакларга, алда торган яктылыкны югалтмаска чакырган алар! Бу айда 90 еллык юбилее билгеләп үтелә торган атаклы язучыбыз Габдрахман Әпсәләмов та илгә, туган җиргә әнә шундый зур миссия үтәүче әдәби әсәрләр бүләк итте. Үзенең туган халкына багышланган титаник хезмәт, көчле иҗат калдырды. Әнә шундый олуг эш кылган язучы турында бүген һич икеләнмичә әйтергә була: әйе, әдип үзе дә каһарман иде!

Аның каһарманлыгы халык күңелендә шулай якты һәйкәл булып сакланыр да!

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ**

# ШАГЫЙРЬНЕ ЯД ИТЕП

## ЗӘКИ НУРИНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Кемнәр генә килмәгән дә, яшәп-яшьнәп, кемнәр генә кичмәгән-үтмәгән бу фани дөньядан... Әле безнең күз алдында булганнарны искә алсаң да, исләр китәрлек: күпме сулар аккан, дәверләр алмашынган, күпме якын кешеләр белән аерылышканбыз икән ләбаса! Ә колакта һаман шул—Идегәйнең сорау-ораны: «Заман кемнең заманы?.. Дәвер—кемнең дәвере?..» Безнең яшь чаклардагы әдәби мохитне, Язучылар Союзы, газиз журналыбыз «Казан утлары» даирәсен күзалласам, чын мәгънәсендә олпат, азаматтай ирләр, узаман аксакаллар, аларның гулливерлардай гәүдәләрен күрәм: Афзал Шамовлар, Нури Арсланнар, Гомәр Бәширләр, Шәйхи Маннурлар, Зәки Нурилар... Мәһабәт кыяфәтләре, йөрешләре, сөйләшүләре... Ә бит, хәзер инде үзебез дә алар яшенә житеп барабыз. Без нинди икән?—дип үземә сорау бирәм дә оялып китәм: холыкта, төс-кыяфәттә, тән-бәдәндә генә дә түгел, кылган эшләрдә дә безне нәрсәдер, нидер, Рөстәм дус Мингалим әйтмешли, әле һаман чикли, «читли кебек»... Ә теге агайлар чын мәгънәсендә аксакал булып, акыл, тәжрибә белән гүяки балкып ук, әйләнә-тирәдә, әдәби мохиттә бер нур, аура тудырырга сәләтле, ышанычлы шәхесләр булып хәтердә калган. Хәсән ага, Сибгат агалар да шулай... Шөкер, әл дә без шуларны күреп калганбыз, мөгаен, соңгы могиканнарны, дим. Тиздән 80 яшен тутырачак могътәбәр басмабыз «Казан утлары» да әнә шундый—колоритлы, олпат, акыллы баш мөхәррирләрне дә, күп әдипләрне дә белә, онытмый. Әйе, безгә—ишетеп йә укып кына белгән Гомәр Гали, Кави Нәжмиләр чоры ераграк сәхифә булса, соңрак дәвердәге Абдулла Гомәр, Газиз Мөхәммәтшин, Рафаэль Мостафиннар—безнең яшьлекнең дә баш мөхәррирләре (чын мәгънәсендә дә бу шулай!). Ә инде алардан соңгы Зәки Нури, Гариф Ахун... янә Зәки Нури, яшьтәшебез Ренат Харис һәм, ниһаять, бүгенге «баш» Равил Фәйзуллиннар чоры—болар инде үзебезнең, якын тарих... Ә вакыт ага, ага... Үзем дә озак еллар журналда эшләгәнгә, хатирәләр дә, истәлекле фотосурәтләр дә шактый җыелган икән. Хәтердәге рәсемнәр дә күп! Бүген шуларның кайберләрен карыйм, туына бу айда 80 ел тулачак Зәки абый Нури белән бәйләнгәннәрен... Менә берсе—1982 ел сентябрендә төшкәнбез. Мансур ага Хәсәнов (зур постлар биләгән абруйлы каләмдәшебез!) журналга «Почет билгесе» орденын тапшырырга килгән. Аның белән Язучылар берлеге идарәсеннән Фәрваз Миннуллин дустыбыз һәм аксакал әдип Әмирхан ага Еники килгән. Калганнары—редакция коллективы... Күпләре азак «зур кеше» булачак, зур дәрәҗәләргә ирешәчәк кешеләр. Төрле язмышлар...

Инде арада булмаганнар да бар: әнә Рәшит Әхмәтҗанның күзләре монсу-тирән карый... Ә Фәүзиябез алда булачак үзгәрешләргә, зур көрәшләргә әзерләнә кебек... Гыйбрәтле фото бу!

Ә Зәки абыебыз журналның баш мөхәррире булып ике мәртәбә—1968—1971 һәм 1974—1982 елларда, димәк, шактый озак еллар эшләгән икән. Бу әле нидидер зур сәяси үзгәрешләр, борылышлар чоры түгел, бер көйгә аккан Брежнев бабай дәвере... Журнал да обком, хөкүмәт химаясендә, эшләү-оештыру механизмы да җайлы-унайлы кебек иде. Язучылар Союзы органы, еш-еш отчет-хисап бирелә, зур җыелышларда тикшерелә һәм әсәрләр дә языла, басыла тора. Кыскасы, әдәби тормыш ул чакта да бара иде, үзенчә кызыклы да иде. Бәхәс уяткан әсәрләр дә басылмады түгел. Совет тәнкыйте дә үтә уяу иде, ансын да хәтерлибез. Әмма шунсы: бөтен совет иле буйлап таралган журналыбыз бик тансык басма булып, тиражы гаять зур иде. Сиксәненче еллар башында ул, мәсәлән, йөз меннән артып китте. Моның өчен, ягъни «журналны «читтә артык нык пропагандалап, чамасыз арттырган өчен» баш мөхәррир З. Нурига, урынбасары Ә. Баянга, Язучылар берлеге рәисе Г. Ахуновка шелтә дә бирде «обком агай»... Менә шул еллардан Зәки абыйның көләч йөзе, елмаюы, шаян сүзләре белән матур, мөлаем үз сурәте җанлана, сагындырып искә төшә. Дөресен әйтергә

кирәк, һәр кайда үз итәләр, санлашалар иде анын белән. Хәер, безгә килгәнче үк зур тормыш, хезмәт юлы үткән, чыныккан ир-азамат иде ул.

Чүпрәле районынын Татар Төкесе авылында туып үскән егет Лубян урман техникумында укыган, әмма язмыш җилләре аны Ерак Көнчыгышка да илтеп, дингез портында михнәт һәм «дөнья күрсәткән» икән. Аннары—сугыш... Чолганышта калып, Белоруссия партизаннарына кушылу. Өч елга сузылган партизанлык, атаклы Константин Заслонов отрядында «Андрей» кушаматлы озын яшь егет... Шунсы кызык: сугыштан соң мин күргән беренче кино (фильм) «Константин Заслонов» иде. Поездлар шартлатыла, немецлар кырыла—шатлык! «Әнә безнекеләр!»—дип кычкырабыз без-сабыйлар, «урман кешеләре»н күреп... Шунда безнен Зәки Нури атлы шагыйрь булганын ул чак кем белгән? Соңыннан бу елларны шагыйрь «Үлгәннәр дә үч алды» дигән проза китабында тасвирлады. Әле бит ул шул тарафта—Оршада горисполкомда, зур урында эшләп, яшәп тә ала, соныннан аңа Оршаның «почетлы гражданы» исеме дә бирелде. Иң истәлекле факт шулдыр: беренче китабы самолет белән «Зур җир»гә чыгарылып, Казанда 1945 елда дөнья күрә. Шагыйрь булып кайта партизан егет туган якларына! Буада һәм Тарханда леспромхоз директоры булып эшли, аннан Казанга чакырылып, «Яшь Сталинчы» (бүгенге «Татарстан яшьләре») газетасынын редактор урынбасары итеп билгеләнә. Аннан—нәшриятта яшьләр-балалар секторы мөдире. Мәскәүдә Югары әдәби курслар тәмамлап кайткач, инде Язучылар союзында—җаваплы секретарь булып озак еллар эшли. «Идеальный секретарь иде Зәки!»—дияргә ярата Аяз ага Гыйләҗев... Чыннан да, утлар-сулар кичкән ир үзен гаҗәеп унган, булдыклы эшмәкәр итеп танытты. Житәкче, югары даирәләр дә яраталар иде үзен. Язучылар да. Һәркемгә яхшы мөнәсәбәте, ярдәмчел булуын да әйтми кала алмыйм. Безгә, яшьләргә матди ярдәмне дә кызганмый юмарт бирде ул. Андыйлар сирәктер, мөгаен. Һәм Зәки абыйнын асыл сыйфатларын бөтен ил буенча беләләр, хөрмәт итәләр иде. Кайда барсаң да: «Зәки Нури ничек яши анда? Аңа сәлам әйт!» диләр иде... 1971—1974 елларда инде, Ходай кушып, идарә председателе дә булгач, бигрәк тә... СССР Язучылар берлеге идарәсенең алмаш секретаре дә иттеләр үзен: үзе сөйләвенчә, кандидатурасын М. Шагинян тәкъдим иткән һәм бик каты яклаган. Мәскәү дә анын булган кеше икәнен тиз таныды, әлбәттә. Аның район, шәһәр һәм Татарстан Югары советы депутаты буларак та зур җәмәгать эшен күреп тордык, «Почет билгесе», «Халыклар дуслыгы» орденнары кавалеры булуына да сөендек без, анын яшь дуслары, замандашлары. Күп китаплары басылу шаһиты да булдык: урысча һәм башка телләрдә дөнья күрде алар. Тәрҗемә китаплары да булды. Сайланмалары—1971 елда һәм 1980 елда *(«Шигырь китапханәсе» сериясендә)*



*«Казан утлары» журналына Почет Билгесе ордены тапшырылган көн истәлеге. Уңнан бишенче—Зәки Нури. 1982 ел*

калын томнар булып чыкты: «Еллар һәм юллар», «Күнел яктысы» исемендә. Лирика, публицистик шигырьләр, юмор-сатира... бигрәк тә яратып язганы кыска шигырьләр, чәнечкеле дүртьюллыклар... Аралаш рифма белән язуы да матур бер күренеш иде. Аларда да—шагыйрьнең төсе, елмаюы, җан нуры. Юкка гына аңа багышланган берничә мәкаләнең исеме «Зәки елмаюы» дип аталмый иде бит! Ә шагыйрь турында Д. Кәгелтдинев, М. Львов, В. Турбина, Н. Хохлов һ. б. мәгълүм әдипләр язып чыкты. Болары—үзәк матбугатта. Ә башка халыкларда? Казанда, Уфада?! Бигрәк тә үзе кебек солдат, ветеран, зур юллар узган буын кешеләре ярата иде аны. Яшьләр дә якын итте. Гади халык та хөрмәт белән карады. Шундый бер якты шәхес булып яшәде ул!

... Сурәтләргә кайтыйк әле. Менә тагын берсе. Журналыбызда «түгәрәк өстәл» сөйләшүенә җыелганбыз. Әлеге аксакаллардан берничәсе... Хәзер инде барсы да мәрхүмнәр... Менә-менә телгә килеп, гакыллы, олпат сүзләре белән безгә нидер сөйләрләр кебек. Ә азактан Зәки агабыз ниндидер мәзәк сүз әйтеп, көлдерер, йомгаклап куяр... арганнарны оныттырыр.. Карагыз, нинди нурлы, самими аларның йөзе!

Әйе, өлкәннәребез булды безнең. Хәзер дә бар алар, арабызда йөреп, яшәп яталар. Тормыш дәвам итә, журналыбыз да исән-имин чыгып килә, яңа исемнәр, әсәрләр көтә. Инде яңа меңъеллыкта!

Әйе, кемнәр генә килеп, кемнәр генә китмәгән бу вафасыз дөньядан! Ә эзләре һәркайда бар, эзләр кала, өзеп сагындыра икән...

**Рәдиф ГАТАШ**

---

## *Котлыйбыз!*

Мансур Шаһимәрдәновның прозага ныклап аяк басуы 80 еллар башына туры килә. Бүген ул урта буын прозаикларының кызыклы бер вәкиле.



Мансур Шаһимәрдәнов 1951 елда Татарстанның Балык Бистәсе районы Кече Әшнәк авылында туа. Аннары гаиләләре белән Олы Елга авылына күчәләр.

Мансур яшьтән үк әдәбият-сәнгатьне үз итә, рәсемнәр ясау белән мавыга, үсә төшкәч шигырьләр яза, соңрак, тәвәккәлләп прозага күчә. Беренче хикәяләре «Идел» альманахында, «Азат хатын» («Сөембикә») журналында басыла. Яшь язучының кечкенә күләмле әсәрләре, шулай ук, «Татарстан яшьләре», «Ватаным Татарстан», «Заман» газеталарында еш күренә. 1992 елда М. Шаһимәрдәновның беренче зур күләмле әсәре—«Кеше күнеле—карурман» повесте «Казан утлары»нда басыла һәм берничә елдан шул ук әсәр Татарстан китап нәшриятендә аерым китап булып чыга. 1997 елда «Казан» журналында аның «Яшь шагыйрь мажаралары» исемле трагикомедиясе басыла.

Мансур Шаһимәрдәнов гади кешеләр тормышын, аларның көн күрешен, холык-гадәтләрен яхшы белә. Аның озак еллар сәүдә системасында, хуҗалык-тәэминат өлкәсендә эшләве дә иҗатында, тел-стилендә чагылыш тапмый калмаган. Ул, шулай ук, юмор-сатира өлкәсендә дә уңышлы иҗат итә.

Аның иҗатын Г. Ахунов, Ә. Гаффар, С. Шәмси кебек күренекле прозаиклар унай бәялиләр.

Мансур Шаһимәрдәнов 1997 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

# КЕШЕ КИТӘ–ҖЫРЫ КАЛА

"Никадәр генә тыныч, басынкы табигатьле кебек тоелмасын, безнен татар әдәбиятында да шаулы-даулы вакыйгалар булгалап тора. Мин аларны юл буенда янып калган учакларга тиңләр идем. Кәрван инде киткән, учактагы ялкын сүрелгән, сүнгән. Тик көл катламы астындагы кузлар әле һаман көйрәп ята: җил генә исеп куйсын–җемелдәп ачылачак алар! Сонга калган берәр юлчы килеп җылы көл өстенә коры-сары ташлауга, учак дөрләп кабыначак та, җылысы, яктысы белән сөендерәчәк әле..."

Заманында Фәиз Зөлкарнәй "Әверелеш" исемле китабын *(Тат. кит. нәшр. 1988)* әнә шундый юллар белән башлап җибәргән иде. Сиксәненче-туксанынчы еллар әдәби хәрәкәтендә һәм иҗтимагый фикер үсешендә тирән эз калдырган күренекле тәнкыйтьче һәм шагыйрь дустыма багышланган бу язманы әзерләгәндә шул китапны кулыма алдым һәм сискәнеп киттем. Әйтерсен лә Фәиз аны үзенең иҗаты хакында, китапларында һәм төрле газит-журналларда таралып калган үз мирасы хакында язган! Акыл казанында дөнья барышынын, гомумяшәешнең серләрен кайната алган гали затлар шундый була торгандыр инде ул. Укыган саен аларның әсәрләреннән яңа мәгънә табасың, кайчандыр игътибар ителмәгән фикер агышында нәкъ менә бүгенге дөньяны аңлатырлык, бүгенге халәтебезне анык күз алдына китерерлек мәгънәгә һәм анализга тап буласың. Танылган әдибебез Мөхәммәт Мәһдиев нәкъ менә шундый кешеләр хакында "Кеше китә–җыры кала" дип язгандыр да...

Фәиз энциклопедик дәрәҗәдә белемле, гаҗәеп дәрәҗәдә киң карашлы иде, дөнья әдәбиятын тирәннән өйрәнгән кеше буларак, ул татар әдәбиятының да шундый үрләре барлыгын белә һәм раслый иде, аны дөнья халыкларына



*Фәиз Зөлкарнәй (алгы рәттә, уртада) хезмәттәшләре арасында. 1995 ел.*

таныту якты хыялы һәм максаты иде. Нәшриятта китапларын ул редакцияләгән язучыларны мин бәхетле саныйм. Чөнки Фәиз китапка бөтен жанын, белемен һәм тәжрибәсен сала торган сирәк редакторлардан иде. Ул баш редактор булып эшләгән елларда "Идел" журналы татар яшьләрен генә түгел, гомумән татар зыялыларын, фикер ияләрен үз янына туплаган мәдәни һәм ижтимагый-сәяси үзәккә әйләнде. Еллары нинди иде бит! Татарстанның бәйсезлеге өчен милли-азатлык хәрәкәте гөрләгән, Казан мәйданнары һәм урамнары митинглардан ярсыган, әдәбиятка һәм мәдәнияткә Гаяз Исхакыйлар, Садри Максуди һәм Йосыф Акчура кебек бөек затлар әйләнеп кайткан чорлар. Һәм Фәиз һәрвакыт әнә шул вакыйгаларның уртасында кайнады. Үзенең мәкаләләренең берсендә ул "Чиксезлекне колачлый алмамдыр, әмма дөньяның кечкенә моделе булган күңелемдәгене жентекләргә һәм язарга кодрәтем житәр. Тик менә гомерем житәрме? Шунысы куркыта" дип язган иде. Якты дөньяда санаулы гына көннәре калганын белгән кебек ул ялкынланып язды, ижат итте, татар матбугатын бугазыннан алган "капитализмга күчеш" чорында "Идел"не саклап калу өчен кулыннан килгәнен дә, килмәгәнен дә эшләргә тырышты, "Идел" дип янды, "Идел" дип яшәде. Һәм ни кызганыч, үз язмалары, монысын анык беләм, бәгырендә кайнаган, инде өлгереп житкән байтак мәкалә-эсселары кәгазь битенә төшәргә өлгерми калды. Менә шуңа күрә дә аның басылып чыккан һәр китабы, һәр язмасы безнең өчен кадерле, затлы бер истәлек кенә дә түгел, алар татар ижтимагый фикер үсеше хәзинәсендә заман тутыгына бирешмәүче асыл жәүһәрләр дә. Форсаттан файдаланып, Язучылар берлеге һәм Татарстан китап нәшрияты житәкчеләренә, Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренә бер фикеремне дә житкерәсем килә: Фәиз Зөлкарнәйнең бар ижатын (әдәби тәнкыйть, фәнни мәкаләләр, ижат портретлары, публицистик язмалар, шигырьләр һ. б.) туплап бастырып чыгару турында уйларга вакыт житмәде микән?! Яңа буыннарга егерменче гасыр азагы әдәби тәнкыйтен, эстетик фикерләү тарихын өйрәнү өчен менә дигән кулланма-дәреслек булыр иде алар.

Бик иртә, артык иртә китте Фәиз Зөлкарнәй безнең арабыздан. Талантлы замандашыбызның гомере 1997 елның июлендә туган ягы—Бакалы районының Саскүл авылыннан кайтып килгәндә автомобиль һәлакәтендә өзелде. Быел декабрь аенда аңа нибары илле яшь тулган булыр иде.

**Флүс ЛАТЫЙФИ**

***Түбәндә тәкъдим ителгән әңгәмәне уткәргәндә аның якты дөньяда нибары дүрт ай гомере калган булган. Фәиз Зөлкарнәй белән әңгәмәне язучы СӘЙДӘ ЗЫЯ алып бара. Үзе исән булса, бүгенге вәзгыятьтән чыгып, ихтимал, ул, әдәбияттагы хәлләргә үтә сизгер кеше буларак, язмадагы кайбер бәяләмәләргә үзгәртүләр дә керткән булыр иде. Ә без исә әңгәмәне ул вакытта ничек язылган булса шул хәлендә урнаштырырга булдык.***

# САБЫР ТӨБЕ АЛТЫНЫМ

**С. Зыя.** *Зөлкарнәй әфәнде! Сүзне шигъриятән башлыйк әле. Сез 1988 елда: «... Без, бүгенге укучылар, шигъриятән вакыйга булырлык әсәрләр көтәбез. Шагыйрьләр үзләре дә моны тоеп, аңлап тора, әлбәттә. Әмма, шуңа да карамастан, андый вакыйганы күргәнебез юк әле!»—дип язган идегез. Шигырь ни өчен вакыйга булырга тиеш әле? Моңа бүгенге аңлатмагыз бармы?*

**Ф. Зөлкарнәй.** 1988... Ул бит татар дөньясында тормышны үзгәртү омтылышлары ниһаять өскә бәреп чыккан вакыт, бу бөекмәмләкәтчел тоталитар илдә иза чиккән халыклар өчен тансык вакыйгалар башланган чак. Шәһәрләрдә халык фронты митинглары гөрли, Татар ижтимагый үзәге узаманнары фикер-ан мәйданына жәмгыятьне үзгәртеп кору турында яңадан-яңа тәкъдимнәр

ыргыталар, «хәбәрдарлык» дигән нәрсәнең татарга да кагылуын раслап, яна бер басма—«Идел» журналы дөньяга юл ярып ята. Кешеләр, рухи богаулар коелып төшүен, офыклар кинәя баруын чамалап, менә-менә зур бер Яңалык килер сыман, бәйрәм алдыннан гына була торган әчке бер куаныч тоеп яшиләр. Кызык еллар...



Сез дикъкать иткән фикерем исә, ялгышмасам, минем «Сабыр төбе алтынмы? (Поэзияне яклау)» дигән язмамнан булырга тиеш. Мин аны татар шигъриятен шул чактагы урынсыз каныгу-яманлаулардан якларга теләп язган идем. Милли кысу-чикләүләре белән тәмам үзәккә үткән торгынлык заманында шигърият татарның җан саулыгын кайгырткан, милли рухыбыз сүнмәсен дип кайнар сулышын өреп торган фидакяр бер көч булуын исбатлаган идем мин анда. Дөрес түгелмени: татар милли хәяты әдәбиятта гына сакланып калып бара иде ич инде. Тел очында йөреп тә монарчы әйтелмәгән, әйтергә ярамаган сүзләрне әйтә белде, күпме гомерләр буе шуны нәкъ кирәк вакытта җаен табып әйтә килде шигърият. Әлеге ислах (реформа) заманы житкәч тә, төп сүзне, яңа сүзне күнегелгән гадәт буенча анардан көттеләр. Шундый сүз генә ул чакта вакыйга була ала иде. Гомумән, үз мәнфәгатьләребезгә кагылышлы әйберне генә, күңелнең көткәненә тәңгәл сүзне генә бер вакыйга итеп кабул итәбез шикелле. Һәм ул сүзнең тиешле вакытында әйтелүе шарт әле. Артык көттерсә, вакыйга булмый инде ул, күңел кайтаргыч банальлеккә әйләнә. Шулай бервакыт радиодан И. Шакиров «Уян, татар!» җырын җырлый башлады. Гасыр башында ук җырланган шәкерт садаларыннан гына сипләп корыштырылуына да карамастан, халык күңеленә сары май булып ятты ул җыр.

Татар өчен кем көрәшсен,
Көрәшмәсә татар үзе...

Вакыйга идеме бу? Вакыйга иде. Чалпы-гавам өчен. Нәкъ кирәк вакытта яңгыравы белән, иҗтимагый әһәмияткә ия мәгънәләрне белдерүе белән. Үзенең кем икәнен аңламас хәлгә китереп җиткерелгән, тарихи хәтереннән мәхрүм ителгән (гасыр башында чыгарылган җыр аның өчен зур яңалык!), туган халкының мәдәни байлыкларын ятсына башлаган хәзерге заман татары өчен бу, әлбәттә, вакыйга иде. Ләкин менә шигъриятнең үзе өчен вакыйга булдымы соң ул?

Рәшит Әхмәтҗановның Казанның Ирек мәйданында татарга ирек даулап ач торган чакта язган «Ачлык мәйданы» шәлкемен мин икеләнмичә шул дәвер шигъриятендәге күренекле вакыйга дип әйтә алам. Х. Туфаннардан башланып, ничә еллар дәвамында татар шигъриятендә астан җибәрелгән ут сыман пыскып килгән милләтпәрвәрлек рухы шулай гөлтләп өскә бәреп чыкты. Чөнки турыдан ярып әйткән ялкынлы шигъри сүзгә көн килгән иде. Вакыйганың зурысы, әлбәттә, шушындый вәзгыять үзе иде.

Кызык заманда яшибез лә!.. Татар өчен җан атып иҗат иткәнгә күрә торгынлык елларында гел дә әдәбиятның Хуҗа Насретдине мисалында йөртелгән М. Әгъләмгә бер көн килеп (1992 ел) иң абруйлы саналган Тукай бүләген бирерләр дип кем уйлаган! Дөньялар шулай үзгәрде ки, бүләкнең дәрәҗәсен саклау өчен—киресен сөйли һәм сөйләгәненең киресен эшли (яза) торган бүгенге көн Насретдине кирәк булып чыкты... Һәм моның гыйбрәтле ягы шунда иде: вакыйгаи әсәр көтеп ятучылар өмет иткән сәнгать кимәлендәге шигырьләр нәкъ менә аның иҗатында икән бит!

Шигырьнең, ахыр чиктә иҗатның, вакыйга булу-булмавы менә шулайрак икән. Бу аның киң катлам укучыга кызыклы булуы, ягъни иҗтимагый әһәмияте ягы.

**С. Зыя**. *Ә мәсьәләнең эстетик ягы...*

**Ф. Зөлкарнәй.** Анысы инде зәвык эше, һәм асылда, бу бездә хәзер әлләни киң булмаган даирәне генә кызыксындыра шикелле. Тәэсирлелек, зәукый-хисси мәгълүматлылык, шәкли яңалык һәм осталык... Тәэсир көченә ия булган әсәр генә вакыйга итеп кабул ителә, ягъни тормыш вакыйгаларына тиң рәвештә күңелдә, хәтердә эз калдыра, рухи тәҗрибә бирәмлегенә әйләнә. Шушы ук фикерне икенче яклап та килеп әйтә алам: шигырь ул укучы күңеленә үтү һәм аңа йогынты ясау өчен вакыйга булырга тиеш. Монысы инде Сезнең «ни өчен?» дигән соравыгызга туры җавап.

Бездә бит элек-электән (бигрәк тә хәзер—әдәби тәнкыйть җан тәслим кылып яткан чакта) әсәрнең сәнгатьчелек (поэтика) ягына игътибар аз булды. Теге заманнарда ул хупланмады, хәзер инде бәһа бирердәй әзерлекле кешесен дә табу кыен. Ә баксаң, бу өлкәдә дә вакыйга саналырлык күренешләр булып тора югыйсә. Менә Чаллыда гомер сөрүче гаҗәеп шагыйрь Габделнур Сәлимов... «Идел»нең 1996 ел 9 нчы санындагы, яки шуннан бер ел тирәсе алдарак «Аргамак»тагы шигырьләрен генә булса да укыгыз! Һичкемнекенә охшамаган затлы шигырь тукымасы, әсәр эченә бөтереп алып кереп китә торган авазлар әйлән-бәйләне, сәерлек чигендәге шигъри күзаллау, сүзгә, кешегә, дөньяга илаһи сак мөнәсәбәт... Болар барысы бергә югары кимәл, шигъри бөтенлек тәшкил итәләр. Мондый мөнәсәбәт, мондый шигъри халәт—бүгенге әдәбиятның саф алтыны! Менә бу хәзинә инде югалып калмаячак дип өметләнәм мин.

Ике дистә еллар элек М. Шабаев америкaн шагыйре У. Уитменның иркле шәкелдә язылган шигырьләрен яңгырашы татар колагы өчен табигый булган дүртәр иҗекле буыннардан гыйбарәт тезмәләр белән тәрҗемә кылган иде. Гадирәк булса да, ритмны яхшы ук тотрыклы итә торган ышанычлы поэтик чара бу. Һәм менә иркле шигырьдә үз сукмагын сабып ятучы Ж. Сөләйман иҗатында мин шуны уңышлы куллану мисалына кабат юлыктым. Иске танышны яхшы сыйфатта очратып куандым, әйбәт шигырьләр укыгач, бөтенләй күңелем булды.

> Гасыр буйлап кисәк-кисәк өзелеп килә
> киселгәнен сизмәс хәлдә
> сагышлы мон—татар теле...

Сөләйман соңгы арада ике китап чыгарырга өлгерде, күп яза. Һәм һәвәскәрлек кимәленнән Каләм Иясе дәрәҗәсенә күтәрелә алды дип саныйм. Әлеге китаплары авторның талантлы икәненә ышандырса да, моңарчы күп әсәрләре эче җыелып бетмичә борынлаган чебешләрне хәтерләтә иде. Ә менә соңгылары инде (дөнья күрергә әзерләнгән өченче китабындагыларын укыдым мин)—камил шигырьләр. Өсләреннән тәкълид рәшәсе (өлгегә иткән шагыйрьләр йогынтысы) дә акрынлап таралып бетәр әле, шәт.

Ләкин шунысы тәгаен ачык: вакыйга бар инде, Сөләйман дигән шагыйрь килде татар шигъриятенә.

Иҗтимагый кимәлдә дә, шигърият кимәлендә дә вакыйга (монысы инде олы мәгънәсендә вакыйга) була алган әсәрләр исә (әйтик, Дәрдмәнднең «Кораб»ы), күрәсең, бик сирәк, гасырга бер генә туадыр ул.

**С. Зыя.** *Бүгенге татар шигърияте укучысын нинди вакыйгалар куандыра алыр иде?*

**Ф. Зөлкарнәй.** Куандырсын иде дә бит ул вакыйгалар... Ләкин мин пессимист кеше—зурга өметем юк. Әйтик, менә болайрак:

—Р. Фәйзуллинның яңадан иҗади сулышы киңәеп киткән! дисәләр—

—Р. Харис, телебезнең үзенә генә хас тәме ләззәтеннән исереп, урысчага тәрҗемә итә алмаслык шигырь язган! дисәләр—

—И. Юзеев белән Р. Закиров шигырьдә зарланудан туктаганнар! дисәләр

—Р. Гаташ салмак, моңлы, төзек җөмләләр белән яза башлаган! дисәләр—

Зөлфәт, Х. Әюп һәм Ш. Галиевләр әдәби янәшәлек алымыннан гайре дә шигырь язу мөмкин икәнен ачканнар! дисәләр—

—И. Гыйләҗев шигырьдә, фикер шакмаклары өюдән ниһаять туеп, мантыйкка баш бирәсе килмәгән хисләрен җилбәгәй җибәргән! дисәләр—

—Г. Морат кемгәдер, нәрсәгәдер булган ачуын шигырьгә төкми башлаган! дисәләр—

—Л. Зөлкарнәйнең шигырь җене биш-алты ел буе авызына су кабып йөреп арган, кабат телгә килгән! дисәләр—

—Ф. Зөлкарнәй шушы кирәкле-кирәкмәс әңгәмә басылып чыкканнан соң шагыйрьләр арасыннан үзенә яна «дуслар» тапмаган! дисәләр—әйе, әгәр шулай булса, чыннан да куаныр идек. Ләкин юктыр, булмастыр...

Ә гомумән караганда, безнең шигъриятнең сәнгатьчәнлек, тормышчанлык дәрәҗәсе һич кимемәде. Ничәдер ел аптыраулы төшенке кыяфәттә йөргән И. Юзеевнең соңгы вакытта шигырьдә өр-яңа ягы белән ачылып китүе куандырды. Бик ихлас һәм нечкә тоемлы шигырьләр язды ул. Шулай ук узган ел мин Роберт Әхмәтҗанов, М. Әгъләмнәрнең күнелне шигъриятнең иң югары биеклекләренә алып менә торган искиткеч шигырьләрен укып җан ләззәте таптым. Р. Харис, Зөлфәт, Р. Фәйзуллин, Х. Әюпләрнең яңа китапларын тотып төн йокыларын калдырган чакларымда безнең татар шигъриятенең дөнья әдәбияты югарылыгында яшәвенә тагын бер кат ышандым.

**С. Зыя**. *Әдәбият туктаусыз хәрәкәттә—аккан су кебек. Ләкин табигатьтә су, әйләнеш ясап, яңгыр булып елгага кабат кайта. Әдәбият та шулай түгелме? Бүгенге заман хәлләрен гасыр башындагы вакыйгалар белән чагыштырырга яраталар. Әдәбиятта да вакыйгалар әйләнешеме әллә?*

**Ф. Зөлкарнәй**. Әдәби хәрәкәт—Гераклит елгасы сыман. Теләсән дә, бер үк суга кабат керә алмыйсың. Агым ияртеп алып китте исә—элеккеге ярга кабат кайту юк. Яңгыр сыман кайта алсаң да, ул ярда инде бүтән үләннәр үсә, бүтән яфраклар су төбендә ята, судагы чагылышын да үзеннеке түгел хәтта. Ләкин әйләнеп кайтасы килү бар, бигрәк тә—үткәндәге бөеклеккә.

Соңгы елларда безнең шигърияттә борынгы шәкелләрне кайтару, янарту омтылышы көчәеп килә. Моңа тәүдә ныклап Р. Гаташ тотынды бугай, бу юлда аның шәкертләре, юлдашлары да табылды. Шулардан күрепме, халкыбызның әдәби вә мәдәни мирасы белән кызыксыну арткан бүгенге көн таләп иттеме—хәзер һәр шагыйрь, мәсәлән, газәл язуны мәртәбә итеп саный кебек. Элеккечә унбергә-унбер үлчәмен куллану, гомумән шигырьне бәетләп язу үзе бер шаукымга әйләнде. Ә минә борынгыларча гаруз (ачыгиҗек шигырь) белән язу юк әле. Һаман да шул бармак вәзене (саниҗек шигырь) хөкем сөрә. Чөнки гаруз—шигырьнең эчке сыйфатын ук үзгәртә торган көч. Аны үзләштерү өчен үзенә дә күпмедер дәрәҗәдә үзгәрергә кирәк. Шуна да әлегә борынгы шәкелләрне кайтару омтылышы күп дигәндә стильләштерү булып кына кала килә. Болай катгый фикер йөртүемнең хикмәте шунда: бу юнәлештә минем үземнең дә бераз эшләп караганым булды.

Азмы казгандым—заманнан һич алапа алмадым:
Хәтта рәтле үз дөньямда мин ярата алмадым.

Алама булдым үземме, заманамы—аңламыйм.
Түренә уздым—ләкин зурлый, ярата алмадым.

Мәңге чалыш күзгеләр һәм чалыш авызлар иле!
Монда мин дәрманга дәртне, юк, ярата алмадым.

Гарузның мең елдан ашкан тарихы бар, шул гомер дәвамында тупланган, сыналган бай шигъри алымнар хәзинәсе бар. Алымнары белән бергә гаруз бербөтен. Шул алымнарын белмичә, үзләштермичә, бүгенге көннән җинел холыклы җөмләсе белән гаруз дөньясына барып керү, ул дөньяда табигый урын табу—ай-һай... Бер үк суга кабат кереп булмаган сыман, борынгы гарузга да кайту юктыр инде ул. Аны хәзерге телебезгә, хәзерге ритмнарга яраклы рәвештә янарту гына мөмкиндер.

**С. Зыя.** *Форма борынгылыгы сүзләрнең дә борынгыларын тартып китерәме әллә? Шигырегездәге «алапа» сүзен ничек аңларга? Һәм андый сирәк очрый торган сүзләрне куллану нигә кирәк? Сез борынгылар өчен түгел, хәзерге укучылар өчен язасыз ич.*

**Ф. Зөлкарнәй.** «Алапа» дип татар теленең кайбер шивәләрендә сабантуй батырына тигән бүләкне атыйлар. Борынгы заманнарда бу сүз яу батырына бирелә торган хезмәт хакын, мөлкәтне, өстенлекне аңлаткан. Аның «алып» (батыр, рыцарь) сүзеннән ясалганы күренеп тора. Тау ягы авылларында халык сабан туенда көрәшчеләрне әле дә «алпа! алпа!» дип дәртләндерә икән. Хоккей уенын караганда урысларның «шайбу!» дип кычкыруы сыман инде бу. «Егетлегенне, батырлыгынны күрсәт», янәсе... Каманың дала ягында Алпар авылы бар. «Алып ир», «батыр», «рыцарь» мәгънәсен белдерә бу авыл исеме. Моннан мең еллар элек көнбатыш кыпчакларның урыс елъязмаларына теркәлгән «олперуовичи» ыруы билгеле. Бу сүзне ишеткәч, үзе дә, аты да корычка төренгән, кулына булат кылыч тоткан алпарлар күз алдына килеп баса («алпар үе»—алпар өе, ыруы). Халык тарихы шулай сүзләрдә сакланган. Чабатасыннан каккан тузаннан курганнар өелеп калган әзмәвердәй алып гәүдәле әкият каһарманнары түгел, безнең батыр бабаларыбыз булган ул алып ирләр, алпарлар. Дошман өстенә яу чапканнар, саугa (трофей), тотсак (әсир) , кырнак (ару кыз) алып кайтканнар, җиңү белән кайткан өчен патша алапасына лаек булганнар.

Мин кешене бер бүгенге көн белән генә яши дип уйламыйм. Менә мәрхүм әбием исемә төште. Без, оныкларын, аркадан кагып сөйгәндә «Аллага шөкер мөселманбыз әле, татарбыз әле» диярргә ярата иде ул. Белүемчә, әби авылыбыздан һичкая чыкмыйча гомер кичергән. Ләкин ул күрше авыллардан да ары авыллар барын, аларда да үзе кебек үк мөселман һәм татар булуы белән горурлана торган кешеләр дөнья көтүен белеп яшәде. Шулар белән бергә үзенең бөтен бер татар халкын тәшкил итүен аңлап яшәде. Алай гына да түгел, ул үзенә кадәр дөньядан кичкән жиде бабасын белә һәм алар да, аларның бабалары да мөселман һәм татар булганлыгына иманы камил иде. Булдыра алганча без, оныкларын, тәрбияләп, бездән дә шундый ук мөселманнар вә татарлар туып үсәр дип өметләнә иде. Кешеләрнең бергәлеге, милләтнең бөтенлеге бер бүгенге көн белән генә чикләнми, ул бөтенлек үткән белән киләчәкне дә колачлый. Шуны тоеп яшәсә генә, милләт чыннан да бөтен, камил һәм озын гомерле була. Мин үзебезнең татар милләтенең менә шундый бербөтен булуын телим. Бу теләк бер минеке генә түгел, асылда бөтен милли мәдәниятебезнең төп теләге, төп вазифасы ул. Моны аңлаучылар бар, аңламаучылар бар. Ләкин аңа карап без, әдипләр алдында торган бу вазифа үзгәрми. Без бүгенге байлыкларыбызны гына түгел, үткәндәге байлыкларыбызны да барлап, туплап, югалтмыйча яшәргә тиеш. Сез дикъкать иткән сүз әнә шул олуг хәзинәнең бер бөртеге генә. Онытып, нииндидер килмешәкләр, әрсез алабайлар кулына калдырмаска иде андый җәүһәрләребезне. Болай да күп югалттык инде. Шуна күрә дә мин аны, күз уңында торсын дип, шигырьдә укучы игътибарын җәлеп итәрлек тәхеткә утырттым, астөшермәдә кызыксынучыларның исендә калырлык итеп аңлатма бирдем.

Соңгы вакытларда татар шигыренә гарузны кайтарырга омтылу да Вакыт дәрьясы өстенә сибелеп калган милли мәдәниятебез байлыкларын янәдән җыеп алырга тырышуның бер чагылышы ул.

Тирбәләбез, бу жир безгә бишек.
Юк, ул көймә... Без барабыз ишеп.
Кеше кулы койган матурлыклар
Безнең белән бара тирбәлешеп.

Мең елларча гомере дәвамында халкыбыз коеп куйган матурлыклар, М. Әгъләм әйткәнчә, шулай безнең белән бергә барсын иде.

**С. Зыя.** *Калмык Д. Көгелтдинев, балкар К. Кулиев, авар Р. Гамзатов ише шагыйрьләр үз заманында урыс дөньясында шаулап яңгырады. Алардан һич тә кайтыш*

*булмаган Х. Туфан, С. Хәким, И. Юзеев, Зөлфәт, М. Әгъләмнәр андый яңгыраш ала алмадылар кебек. Сәбәп нәрсәдә?*

**Ф. Зөлкарнәй.** Бу сорау бүгенге көндә динозавр сыман сәер, моннан егерме еллар элек шундыйрак сораулар бирү гадәттә иде. Рәхмәт, динозавр тунап карау кем бәхетенә тигән әле. Ул елларда татарның кимсенүчәнлеге (урыс аны «комплекс неполноценности» ди) шушы сорау рәвешендә калкып чыга иде. «Урысча яңгыраш алуны» югары бәя алуга тиңлиләр иде. Зур-зур гына абзыйлар әлеге сорауга җавап бирергә тырышып карады, хәтта мин — кичәге студент та шул тирәдә буталдым *(«Казан утлары», 1983, № 4).* Төрле кеше төрле сәбәпне әйтте. Ләкин иң төгәл җавапны Вакыт галиҗәнапләре бирде.

Әсәрнең, иҗатның чын әһәмиятен урысчада яңгырау-яңгырамау билгеләми икән, болар арасында туры бәйләнеш юк. Була да алмый. Мәнфәгатьләр туры килү-килмәүне генә чагылдыра ул урысчага тәрҗемә ителү һәм урысча «яңгыраш алу». Кол белән хуҗаның мәнфәгатьләре кайчан туры килгәне бар? Сез исемнәрен атаган шагыйрьләр бу илдә кол кавеменнән саналмаганнардыр, күрәсең. Ә безнең татар бит, Тукай әйтмешли, урыс белән «вакытлар алмашып шаярышкан» халык, бу мәмләкәт биләмәләрендә урыстан алдарак дәүләт төзегән халык. Ә моны сәясәттә дә, әдәбиятта да һәм, гомумән, бер җирдә дә, беркайчанда онытмыйлар, гафу итмиләр. Чөнки җиңүчеләрнең үз комплекслары була. Тиң күрерләр дип өметләнү — артык садәлек. Монда талант түгел, сәясәт төп хаким. Урыс армиясендә иң югары дәрәҗәләрнең берсенә күтәрелә алган армия генералы М. Гәрәев әйткән сүзләр бар: «...Татар егетләренә, генерал яки адмирал дәрәҗәсе алу өчен, башкалардан ике-өч баш өстен булу кирәк», — ди ул. Урыска хезмәт итеп урыс арасында танылу өчен шулхәтле талант һәм тырышлык кирәк булганда татарга хезмәт итеп урыс арасында танылу өчен ни-нәрсә һәм күпме микъдарда кирәк икән соң?!

Түрәләр, битәрләп, татар язучылары битенә сез биргән сорауны еш ыргыта торган 70 нче елларда, мин Х. Сарьянга, «Бер ананың биш улы» повестең тел, сүз, интонация кимәлендәге мәгънәләргә гаять бай, хәтта бүтән телгә тәрҗемә итеп булмас дәрәҗәдә артык татарча, дигәч, ул: «Мин татар өчен язам, татар укыса, бәһаләсә, шул бик җиткән», — дип кырт кискән иде. Аңладым хәзер: акыллы булган Сарьян абый.

«Урыс дөньясында шаулап яңгыраган» шагыйрьләребез әле ярый булмаган, дип куанырга кирәк безгә. Димәк, алар чын-чынлап милли әдипләр икән, Казанны Явыз Иванга яулап биргән ниндидер «йомышлы татарлар» кавеме түгел.

**С. Зыя.** *«Бездә әдәбият анкәсе гомердән шигърият», ди Р. Фәйзуллин. Прозаны исә әдәбиятның алтын баганасы диясе килә. Кызганыч, бу жанр соңгы елларда көпшәкләнә төште шикелле. Сезгә ул хәзер үзенә күрә кризис кичерә сыман тоелмыймы?*

**Ф. Зөлкарнәй.** Тоела. Прозаның дәрт-дәрманы (тонусы) сүрелә төште, татар әдәбиятының бу тармагы шактый сыекланды, дип саныйм мин. Уртакулдан түбән кимәлдәге әйберләр күбәйде. Моның берничә сәбәбен күрәм. Иң хәтәре шул: бүгенге заман — татар прозасында буыннар алмашу вакытына туры килде. Алмашка басучылар арасында Ә. Еники, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗевләр дәрәҗәсендә иҗат итә торган язучылар юк булып чыкты. Бу аеруча прозаның бездәге төп жанрлары роман белән повестьта нык сизелә. Дөрес, аерым яклары белән уңышлы саналырлык кызыклы гына әсәрләр языла тора. Ләкин тел-өслүб, сәнгатьчәнлек җәһәтеннән Еникиләр буыны белән дә, Мәһдиевләр буыны белән дә ярыша алырдайлары юк. Каләм хакының бик аз түләнүе яисә кайчакта бөтенләй түләнмәве дә язучыларның кәефенә тәэсир итте, әлбәттә. Дөньялар гел шулай барса, озакламый бездә югары мәдәният кимәлендә иҗат ителгән роман-повестьларның бөтенләй югалу ихтималы да юк түгел. Янә дә бер сәбәп. Элек әдәбиятның санитары вазифасын үтәп килгән әдәби тәнкыйтьнең вакытсыз үлеме дә уртакуллар баскынчаклыгына юл ачты.

Прозада сан үсеше күзәтеләдер дим мин. Жанрлар арта (яңа жанрлар:

тарихи хикәя, фентези, бәян-пародия), элек сирәк языла торганнары ишәя (сатирик бәян, детектив, юмористик һәм сатирик хикәяләр). Бәлки әле бу сан үсеше тора-бара сыйфат сикерешенә дә китерер. Проза жанры турында «Казан утлары» журналы зур сөйләшү алып бара. Шуңа күрә мин, кабатланырга теләмичә, сезнен сорауга кыскача гына җавап бирдем.

**С. Зыя.** *Әдәби тәнкыйтькә килсәк, чын, эстетик таләпләр яктылыгында әдәбиятны анализлый торганы шактый кимеде сыман. Тәнкыйть жанры үзара макташуга гына кайтып калмыймы?*

**Ф. Зөлкарнәй.** Чын әдәби тәнкыйть үлгәч, әдәбият мәйданында кайбер мәсъүли затларга хезмәт күрсәтү тәртибендә язылган язмалар гына торып калды шул. Боларны һәм язучыларның юбилейлары уңаеннан дөнья күргән язмаларны әдәби тәнкыйть дияргә тел бармый. Ялган шәраб сыман суррогат болар: башны дивана итә, ахырдан махмыры газаплый. Ярый әле үзләрен авторлары һәм дә багышлап язылган төп каһарманнарыннан гайре кеше укымый.

Әдәби тәнкыйть гомер-гомергә әдәбиятның «кара эше» булып килде. Аны кайвакыт күтәреп «әдәбиятнын үзаңы», «әдәбиятның көзгесе» дисәләр дә, тулысы белән ул «кара эш», «неблагодарный труд». Тәнкыйть белән исәпләшергә була, әмма аны яратып булмый. Ә бит кулына каләм алган кеше—прозаикмы ул, тәнкыйтьчеме—барыннан элек ярату өмет итә. Соңгы елларда аеруча көчәйгән менә шул яхшы мөгамәлә кытлыгы әдәби тәнкыйтьчеләрнең кулыннан каләмен төшерде. Ярату мөмкин түгел икән инде, «кара эш» өчен һичьюгы яхшы түләргә кирәк. Ләкин түләү дә юк. Хәзерге гәзит-журналларның фәкыйрьлеге бөтенесеннән дә алда нәкъ менә әдәби тәнкыйтькә китереп сукты. Таләпчән, фикерле, аналитик әдәби тәнкыйть мәкаләләре гәзит-журнал битләреннән ялап алган кебек юкка чыктылар.

Үзендәге яхшы, яман якларны даими ачыклап бармаса, үз бәясен үзе белмәсә, әдәбият яши алмый. Әдәби тәнкыйтьнең ни дәрәҗәдә кирәк икәнен язучылар аңлый башладылар бугай инде. Язучылар берлегендәге җыелышларда күренә бу.

Җитди әдәби тәнкыйть, мәсәлән, Көнбатыш илләрендә университет галимнәре кулында. Дөнья үзенекен итәр, бездә дә ул шулай булыр дип уйларга кирәк. Әлегә безнең әдәбиятчы галимнәр татар әдәбиятының тарихын эшләү, дәреслекләр язу белән мәшгуль. Бүгенге көн әдәбиятына да нәүбәт җитәр дип ышаныйк.

80 нче елларда әдәби тәнкыйть, жанр буларак, Көнбатыш әдәбиятлары үрнәгендә эссе жанрына тартылу кичергән иде. Аны нәфис әдәбият төренә әйләндерергә омтылу иде бу. Мин үзем шул юнәлештә эшләдем. С. Маннапов шундый әсәрләрдән гыйбарәт бер-ике китап чыгарды. Н. Гамбәр шунын кызыклы мисалларын бирде. Кызганыч, бу омтылышлар ул чакта әдәби күренеш буларак ныгып, канунлашып бетә алмадылар. Ләкин ничек кенә булмасын, киләчәктә бу юнәлеш әдәби тәнкыйть үсешенең төп тармакларыннан булыр дип ышанам мин, аны язучылар үзләре эшләргә мәҗбүр булачаклар. Икенче шундый тармак академик өслүбтәге тәнкыйть булып, анысын әдәбиятчы галимнәр үстерәчәк.

**С. Зыя.** *Соңгы елларда татар гәзитләренең, журналларының исемнәре ишәйде, тиражлары кимеде. Сәбәп ни?*

**Ф. Зөлкарнәй.** Җәмгыятьтә коточкыч бер үзгәреш булды. Күреп тордык юкса, ләкин аның ничек шулай килеп чыгуын һаман аңлый алмыйбыз. Элек ничек иде? Һәр гаилә берничә гәзит һәм берничә журнал алдыра иде. Юк, акча күп булганнан түгел—уку, бигрәк тә матур әдәбиятны уку абруй санала иде. Укыган әйберләр турында сөйләшү, фикер алышу зыялылык, өстенлек билгесе иде. Ә кешемен дигән кеше өстен булып күренергә тырыша, шуна да матбугатка акча кызганмыйлар иде. Һәм менә соңгы биш-алты ел эчендә укымышлылыкның, мәдәнилекнең, тәрбиялелекнең—гомумән, зыялылыкның капылт абруе төште. Чөнки зыялылар катламы

җәмгыятьнең иң фәкыйрь өлешенә әйләнде. Урам себерүчеләр, идән юучылар, сатучылар, «челноклар» алардан хәллерәк хәзер. Тормыш көтү, акча эшләү өчен элек тәгъбирләнгән рәвештә белемле, тәрбияле вә мәдәни булу мәҗбүри түгел икән. Инде хәзер зыялылык өстенлек саналмый, аңа зыялылар үзләре дә язмыш казасы сыман карыйлар бугай. Житмәсә, җәмгыятьнең әле бер, әле икенче катламы фәкыйрьлек упкынына төшеп-төшеп алды. Анда булып менгән кеше инде фәкыйрьлектән оялмый башлый. Куркыныч хәл! Акча җитмәүдән зарлану—хәзер күнегелгән гадәт. Бу гадәт барысын да аклый.

Кеше хәзер елтырап торган күн кием генә киеп йөри, базардан туклана, фатирын, мебелен янарта, машинасын ала, шәһәр читендә коттедж торгызу хыялы белән яши. Ләкин акча җитми, акча! Кичен кайткач «Санта-Барбара»ны карап, Петросян белән Сорокинаны тыңлый да матди һәм рухи тормышыннан бик мәмнүн булып йокыга тала. Китап уку, гәзит-журнал актару кебек совет дәвере йоласыннан ул бизгән инде. Чөнки абруй саналган йолаларны гына үтәргә өйрәткәннәр иде аны. Көндәлек матбугатны даими укып бару, мәдәният, сәнгать яңалыкларыннан хәбәрдар булу абруй өстәми хәзер. Акча җитми дигән сүз барысын да каплый. Аннары аның матбугаты да нинди бит! Сәяси дә иҗтимагый-сәяси... Сәясилекләре дә нинди диген, һаман шул Ельцин белән Шәймиевне мактауга һәм Жириновский белән Бәйрәмованы сүгүгә генә кайтып кала. Биш ел элек тә шул иде, бүген дә—шул. Бернинди үзгәреш юк. Яңалык юк! Яңалык дигәннәре яңа булмагач, пычагымамы ул матбугат?

Гавам кешесе шулайрак уйлый дип беләм мин. Һәм ул хаклы. Артык сәясиләшү үтерәчәк безнең матбугатны. Гади кешегә югыйсә сәясәтнең телевидение бирә торган микъдары да бик житкән. Безнең татарда барысы да аягыннан башына куелган: телевидение көне-төне сыер саву, урам чистарту турында сөйләп, бетмәс-төкәнмәс һәвәскәр җырчылар кәмитен күрсәтсә, гәзит-журналлар исә барысы да бер балык башын чәйни—сәясәт, сәясәт, сәясәт...

Дөрес, соңгы биш-алты ел эчендә матбугат, күмәк көч белән тотынып, иҗтимагый фикерне үстерүдә, яңа сәяси, җәмгыяви фикерләр шәкелләштерүдә бик зур эшләр майтарды. Өмәгә җыелып күмәк эш эшләү сыман булды бу. Инде ул күмәк эшне тәгәлләндерә саныйк, гәзит-журналларга, өмәдән таралып, һәркайсына үзенеке генә булган эшенә кайтыр вакыт житкәндер. Югыйсә шуны көтеп арыган укучыларының урыс матбугаты канаты астына китеп бетүләре бик ихтимал.

**С. Зыя.** *Без кайчакта: «Соңлап тугансың син, Сиңа элегрәк яшәргә иде»,—дип шаяртабыз. Сезнең теләктән торса, гомер итәр өчен кайсы гасырны сайлар идегез? Ни өчен?*

**Ф. Зөлкарнәй.** Марсель Галиненң студент чакларыннан ук килә торган бер гадәтен беләм. Теге торгынлык заманнарында ул гадәт аеруча эффектлы, көттә тоела иде. Кибеттә прилавка алдындамы, вокзалда билет кассасы янындамы, сырханә төбендәме чират торганда ул, бу илдә ялгыш туганмын мин, берәр юньлерәк, кеше кадерен белә торганрак илдә туарга иде мина, дип кычкырып сукранырга ярата. Туу, яшәү урынын һәм вакытын сайлау кешенең үз ихтыярында булмагач, минем ничектер бу хакта уйлаганым булмады. Марсельнең дә андый гасабилануларын әле дә көлеп кенә тыңлыйм. Ләкин, уйласаң, ул хаклы бит. Кеше болай ук кадерсез булган тагын нинди ил бар икән? Русияне начар юллары һәм ахмак житәкчеләре харап итәчәк, дигән бер акыл иясе. Кадерсезлек, кеше мәнфәгатьләрен санламау харап итәчәк, дияргә кирәк иде. Бу илдә бөтен нәрсә кешегә каршы эшләнә, интексен әле дип эшләнә бит. Дәүләт кешеләр өчен түгел, кешеләр дәүләт өчен булган илдә шулай инде ул.

Минем төп кагыйдәм: теләкнең үтәлерлеген генә телим мин (исемемә хилафлык китерергә ярамый ла). Шунадырмы, дөньяга моннан 45 ел элек туып дөрес эшләгәнмен дип уйлыйм. Әнә бит безнең гомер нинди дәвергә туры килде. Кулда көч тоя торган житлеккән мәлебез хәзер. Кытайларда,

имеш, «Сиңа үзгәреш-көчешләр заманында яшәргә язсын» дигән каргыш бар, ди. Без болай да инде каргалган халык балалары бугай. Куркасы түгел. Нинди кызык һәм мәгънәле вә гыйбрәтле чорда яшибез. Мөһиме: иң хыялый теләкләр дә тормышка ашар сыман тоелган заман бу. Ничек инде шундый заманнан ваз кичәсең?

**С. Зыя.** *Сез ни турында яза алмыйча калудан куркасыз?*

**Ф. Зөлкарнәй.** Соңгы вакытта шигырьләр язам. Шагыйрь гомер буе, әллә нинди тирәнлекләргә төшеп, үз күңелендә казына. Тапкан мәгънә мәгъдәннәре шигырь булып дөньяга чыга тора. Яшәве дә аның үз күңелен яхшырак аңлау өчен түгел микән әле? Гомумән, без бер-беребезгә—үзебезне аңлау өчен түгелме? Шигърият ул—уйлый китсәң, халыкның, җәмгыятьнең үз күңелендә казынуы. Самоанализ, урыс әйтмешли. Шуңа күрә минем бу казынуым табигый.

Тамчыда диңгез чагыла, чөнки диңгез—үзе биниһая зур тамчы. Дөнья турында да шулайрак әйтергә ярый. Кеше күңеле—үзе бер дөнья, диләрме? «Киң күңел» дигән гыйбарә дә бар. Чиксез киң күңел дисәк, хәзерге фән тасвирлаганча чиксез киңәеп бара торган дөнья була инде. Чиксезлекне колачлый алмамдыр, әмма дөньяның кечкенә моделе булган күңелемдәгене җентекләргә һәм язарга кодрәтем җитәр. Тик моңа гомерем җитәрме? Шунысы куркыта.

Хәер, тагын бер куркуым бар икән: мин сабырлыгым югалтудан куркам.

Минем сабырлык—ул туган халкыма, аның киләчәгенә ышанычым.

Безнең татар, урыс империясендә гасырлар буе изелеп яши-яши, «сабырлык» төшенчәсен фәлсәфи категория дәрәҗәсенә күтәргән. Сабырлык ул, кемнәрдер уйлаганча, түземлек тә, чыдамлык та һәм, әлбәттә, күндәмлек тә түгел, ә бәлки көчләреңне кирәкле вакытка кадәр җуймыйча саклау. Әнә Тукай әйтә ич:

Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,
Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым.

Кыямәт көндә бәндәләрнең кубарылып чыгу вакыты җиткәнен сур мөгезе кычкыртып хәбәр итәргә тиешле фәрештә бар безнең мифологиядә. Татар әдәбияты шул фәрештә хәлендә. Вакыт инде җиткән. Империядә—кыямәт...

Kitap kuzətu
Китап күзәтү

# ҖЫРЛЫ ЧИШМӘЛӘР

Татар әдәбият белеме үсешенең төрле баскычларында әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләре тарафыннан милли әдәби хәрәкәтне, аерым язучыларыбыз иҗатын өйрәнү, анализлау һәм бәяләү юнәлешендә байтак матур тәҗрибәләр ясалган. Бу тәҗрибәне тулаем һәм ретроспектив планда караганда анда әдәби-теоретик фикернең, әдәби анализ эшенең билгеле бер дәвамчанлык, күчемлелек канунына корылып үсүен күзәтергә туры килә.

Әдәбият белеме өлкәсендә, бигрәк тә егерменче-утызынчы елларда—катлаулы, каршылыклы, киеренке эзләнүләр чорында—табылган фәнни-теоретик, фәнни-методик фикер казанышлары, һичшиксез, бу тәҗрибәнең нигезенә алынды. Күренекле әдәбият галимнәре Гали Рәхим, Габдрахман Сәгъди, Җамал Вәлиди, Газиз Гобәйдуллин, Габделбари Баттал, Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Нигъмәти һәм башка бик күпләрнең хезмәтләрендә әдәбиятның үзенчәлеге һәм милли әдәбият күренешләрен, әдәби процессны, аерым татар язучылары иҗатын өйрәнү белән бәйләнешле рәвештә әйтелгән кыйммәтле фикерләре, фикер башлангычлары алардан соң килгән буын әдәбият галимнәренең тикшеренүләрендә дәвамлы үстерелеш тапты.

Бу мәкаләдә без күренекле каләм әһелләре иҗатына фәнни-эстетик анализ ясауны һәм яңача бәя бирүне максат итеп куйган яңа бер хезмәт турындагы фикерләребез белән уртаклашмакчы булабыз. Сүз—танылган әдәбият галимәсе, педагог, филология фәннәре кандидаты, доцент Мәдинә Җәләлиеваның әле күптән түгел генә «Мәгариф» нәшриятында басылып чыккан «Әдәбиятыбызның җырлы чишмәләре» дип аталган китабы турында бара. Ул «Укытучы китапханәсе» сериясендә укытучыларга, педагогия колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма сыйфатында бастырып чыгарылган булса да, профессиональ галим-филологлар даирәсе өчен дә бик кызыклы һәм файдалы бер хезмәт.

Китап авторының исеме әдәбият белгечләренә, милли мәгариф системасында эшләүчеләргә, татар әдәбияты укытучыларына, мәктәп укучыларына, гомумән, киң катлам укучыларга—әдәбият сөючеләргә яхшы таныш. Чөнки, бердән, Мәдинә Җәләлиева озак еллар дәвамында Казан дәүләт педагогика университетында әдәбият дисциплиналары укыткан, үзеннән алда шушы гыйлем һәм уку йортының татар әдәбияты кафедрасында эшләгән галим-педагогларның традицияләрен дәвам итүче, үстерүче галимә-педагоглардан берсе булса; икенчедән, шушы көнгә хәтле милли мәктәпләребез өчен татар әдәбиятыннан матур-матур дәреслекләр, методик кулланмалар төзеп бастыруда актив һәм даими катнашып килүче авторлардан берсе; өченчедән, ул төрле фәнни җыентыкларда, татар вакытлы матбугаты битләрендә милли әдәбиятыбыз мәсьәләләре буенча төпле, тирән эчтәлекле мәкаләләре белән чыгыш ясап торучы автор буларак билгеле. М. Җәләлиеваны әдәби-фәнни-педагогик җәмәгатьчелек шулай ук язучыларыбызның юбилей конференцияләрендә ясаган кызыклы чыгышлары—фәнни докладлары буенча да яхшы белә. Ул лаеклы ялда һәм олы яшьтә булуына карамастан, әле бүген дә оригиналь фикерләү сәләтен, зиһен ачыклыгын һәм ныклыгын җуймаган хәлдә фәнни-тикшеренү эшчәнлеген дәвам итә, һаман эзләнә, иҗади фикер хәрәкәтендә яши, яза, үзенең матур,

кызыклы һәм яңа фәнни табышларын, фикер-күзәтүләрен мәкаләләр, җыентыклар рәвешендә дөньяга чыгарып, укучы хөкеменә тәкъдим итеп тора.

М. Җәләлиеваның яңа басылып чыккан һәм югарыда телгә алынган китабында XX йөз татар әдәбиятының бай катламнарын тәшкил итүче олы язучылар Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Һади Такташ, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Әхсән Баянов иҗатлары тикшерелә, әдәбиятның кайбер мөһим теоретик мәсьәләләре яктыртыла. Хезмәтнең тарихи-милли, әдәби-теоретик нигезгә корылган булуы игътибарны җәлеп итә. Эстетик анализның хәзерге таләпләргә җавап бирә алуы, китапка алынган язучыларның иҗатын психологик процесста алып, аның татар әдәбият белеменең үзенчәлеге буларак анализлануы әдәби үсешнең югары ноктасы рәвешендә күз алдына килә. Авторның мондый аспекттагы тикшеренүләре үз вакытында Җамал Вәлиди, Габдрахман Сәгъди, Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Нигъмәтиләрнең кайбер аерым хезмәтләрендә билгеләнгән позитив фикер башлангычларын, теоретик позицияләрне (язучы шәхесе, иҗат психологиясе, әдәби стиль, психоанализ һ. б. мәсьәләләр буенча) шактый киңәйтеп, тирәнәйтеп, заманча үстереп каравы белән кызыклы һәм әһәмиятле. Автор үзе дә хезмәтенең төп максатын элеккеге традицияләрне яңартуда күрә.

Әйтергә кирәк: китапның Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташка багышланган бүлекләре турыдан-туры егерменче-утызынчы еллар әдәби процессы белән тыгыз бәйләнештә бирелә. Бу чорның бай, катлаулы, каршылыклы, җанлы картинасы алда телгә алынган шәхесләр иҗатын әтрафлы тикшерү белән мөнәсәбәтле рәвештә хезмәттә шактый тулы ачыла, объектив чагылдырыла.

Автор әлеге китабында бигрәк тә Г. Ибраһимов иҗаты белән тыгыз бәйләнештә, әдәбият белеме фәнендә әле бүген дә катлаулы һәм бәхәсле булып кала торган әдәби метод һәм әдәби стиль мәсьәләсен күтәрә. Аны дөнья әдәби процессының бер проблемасы итеп карап, татар һәм күрше рус әдәбияты белән генә түгел, Европа әдәби процессына нигезләнеп тә ачыкларга, тәгаенләргә омтыла. Билгеле ки, әдәби метод, өслүп (киң һәм тар мәгънәләрендә), әдәби стиль мәсьәләләре фәнни җирлектә әле егерменче-утызынчы еллар татар әдәбияты белемендә үк өйрәнелә, җитди тикшерелә башлаган иң актуаль мәсьәләләрнең берсе. Үзенең хезмәтләрендә автор әлеге мөһим проблеманы яңа шартларда яңадан калкытып куеп, моңа карата бүген үз позициясен, үз мөнәсәбәтен белдерә, әлеге проблеманың бүгенге этапта да ахыргача хәл ителмәгән булуын тагын бер кат искәртә.

Язучының шәхесе һәм аның әхлакый гуманизмы, субъектив ягы да хезмәттә бер кадәр урын алган. Чөнки һәр кешенең аңына сеңгән холкы, фигыле, үзенең характерлы сыйфатлары була. Бу турыда Г. Тукай да уйланган икән. Ул әдипнең иҗатын гына түгел, шәхесен дә ачып бирүне теләгән. «Килер заман,—дип яза мөхтәрәм шагыйрь, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле». *(Г. Тукай. «Уянгач беренче эшем» мәкаләсе. «Кояш» газете, 14 март, 1913).* Әлеге аспект М. Ш. Җәләлиева китабының бигрәк тә язучылар Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, Ә. Еники иҗатларына багышланган бүлекләрендә матур ачыла. Мәсьәләнең бу ягын күтәрүе белән автор элегрәк татар әдәбият белемендә урын тоткан «биографизм» методы принципларын яңа шартларда әдәби иҗат процессын өйрәнүдә куллануны дәвам итә. Аның бу эше әдәбият галиме Г. Нигъмәти хезмәтләрендә, бигрәк тә аның «Әдәбият һәм тормыш» *(Казан, 1930)* дигән хезмәтендә һәм иҗат психологиясе мәсьәләсен тикшерүгә багышланган бүтән мәкаләләрендә куелган «язучы шәхесе» мәсьәләсен тикшерүне яңа заманда дәвам итүчеләрнең берсе буларак бәяләнергә хаклы.

Китапта исемнәре алда санап үтелгән язучылар иҗатына җыйнак, кыска, әмма төпле тирән фәнни-эстетик анализ ясала. Анда урнаштырылган аерым мәкаләләрдә тегеяки бу язучы иҗатының сәнгатьчә

үзенчәлекләре яңарак ракурста, моңа кадәрге тикшеренүләрдә күрелмәгәнчә яклары белән, моңа кадәр игътибар биреп җиткерелмәгән үзлекләре белән ачыла.

Әйтик, «Шагыйрьнең миф дөньясы» дигән мәкаләсендә автор үзенең игътибарын Г. Тукай иҗатының бөтенләй өйрәнелмәгән, яки, өйрәнелсә дә объектив яктыртылмаган, берьяклы гына каралган өлкәсенә юнәлтә. Шагыйрь иҗатына яңача якын килә. Аның иҗатында мәҗүсилек, ислам дине белән бәйле мифик образлар, персонажлар, сюжетлар куллануны махсус алып өйрәнеп, аларның Тукай әсәрләрендә үтәгән эстетик вазифаларын ачыклауны максат итеп куя, Тукайның фикер тирәнлеген, тасвирлау осталыгын яңа яктан килеп ачуның матур һәм уңышлы тәҗрибәләрен ясый.

«Әдип Галимҗан Ибраһимов» дигән җыйнак бер мәкалә күләмендә автор язучының тулаем иҗат эволюциясен һәм аның иҗатының сәнгатьчә үзенчәлекләрен эзлекле итеп тикшереп, анализлап чыга. Бу мәкаләсендә ул Г. Ибраһимов иҗатын яңабаштан һәм яңача карап чыга дип әйтергә мөмкин. Монда Г. Ибраһимов иҗатының һәм шәхесенең моңа хәтле тикшеренүчеләр игътибарыннан читтә калып килгән моментларына, якларына басым ясала.

Тагын бер нәрсәгә игътибар итәргә кирәк: автор Г. Ибраһимовның совет чорында язылган әсәрләрен, аерым алганда «Кызыл чәчәкләр», «Адәмнәр», «Тирән тамырлар» әсәрләрен анализлап, аларда язучының «чынбарлыктан туган аналитик фикерләрне астарлы һәм күп мәгънәле итеп тасвир кылу үзенчәлеге»нә басым ясый, Г. Ибраһимов әсәрләрендә, астарлы фикернең (подтекстның) үзен сиздерүен реализмның куәте, язучының тасвирлау осталыгы белән бәйләп аңлата.

Китаптагы «Тарих әһеле *(Кәрим Тинчурин турында уйланулар)*» дигән мәкаләдә милли драматургыбызның иҗат үрнәкләре һәм үзенчәлекләре барлана һәм бәяләнә. Хезмәт авторы монда К. Тинчурин иҗатын беренче этабыннан алып ахыргача эзлекле карап, күзәтеп, тикшереп чыга, аның әсәренең сәнгатьчә эшләнешендәге отышлы якларны дөрес күрсәтә. Шул яссылыкта аның «Беренче чәчәкләр»е, «Соңгы сәлам»е, классик югарылыкта торган «Сүнгән йолдызлар», «Зәңгәр шәл», «Җилкәнсезләр» драмалары анализлана. Кәрим Тинчурин—автор бәяләвендә «Г. Исхакый, Г. Камал, Ф. Әмирхан, М. Фәйзиләрдән килгән милли татар драмасы үзенчәлекләрен биниһая баетучы сәхнә остасы» ул.

«Әдәбиятыбызның җырлы чишмәләре» китабына кертелгән мәкаләләрнең тагын берсе—«Шагыйрь Такташ». Монда шагыйрьнең романтизмда формалашкан матур лирикасы анализлана, автор бик хаклы рәвештә Такташны дөнья романтизмының куәтле вәкилләре В. Гюго, А. Мицкевич, П. Шелли, Дж. Байрон, Һ. Һейне кебек мәшһүр шагыйрьләр белән бер рәткә куеп карый. Шулай ук шагыйрьнең зур үзгәрешләр, каршылыклы еллар барышында язылган әсәрләрнең сәнгатьчә үзенчәлекләрен дә тәфсилле тикшерә, ул иҗат иткән, ул тудырган шигъри образларны, сурәтләрне, поэтик чараларны табып алып күрсәтә. Анализ Такташның шигъри әсәрләреннән китерелгән, гаҗәп уңышлы сайланган өзекләр белән аралаштырып бирелә. Аларны укыганда шагыйрьнең моңа хәтле мең кат укылган шигырьләре тагын да яңа яклары, яңа кырлары белән ачылып, балкып китә, алар тагын да тәэсирлерәк, гүзәлрәк яңгырый башлыйлар.

Татар прозасының затлы вәкиле, халык язучысы Әмирхан Еники турындагы бүлек «Тойгы катламнары» дип атала. Биредә Ә. Еникинең иҗат үзенчәлекләре, таланты, психологик сурәтләү осталыгы шактый тирән ачыла. Еники сурәтләвенең психологик үзенчәлекләре язучының гүзәл әсәрләренә, алардан алынган өзекләргә таянып яктыртыла. Автор Ә. Еникигә багышланган бу мәкаләсен әдип әле исән вакытта аның үзенә укытуы һәм аның: «иҗатыма шактый тирән кергәнсез» дигән кыска, ләкин кыйммәтле бәясен алуы турында миңа да сөйләгәне бар иде.

«Аяз Гыйләҗев повестьларында әдәби герой» дигән бүлектә, аның исеменнән үк күренеп торганча, талантлы каләм иясе, халык язучысы

Аяз Гыйләҗевның образ-характер иҗат итүдәге эзләнүләре, табыш, казанышлары барлана, бәяләнә, чынбарлыкны, аның катлаулы якларын персонажның рухи дөньясы аша карап чагылдыруы кебек сәнгать үзлеге алга куеп карала. Аяз Гыйләҗевның иҗат осталыгын билгели торган табышлары аның «Өч аршын җир», «Урталыкта», «Берәү», «Урамнар артында яшел болын», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Кызлар хатлары», «Язгы кәрваннар», «Әтәч менгән читәнгә», «Мең чакрым юл», «Җомга көн кич белән» кебек әсәрләрен анализлау аша дәлилле күрсәтеп бирә.

Китап авторы хәзерге татар прозасында психологик якны сурәтләү осталыгы белән танылган Ә. Еники, Аяз Гыйләҗев, Әхсән Баянов, Гариф Ахунов иҗатларын күздән кичереп, аларның психологик сурәтләү үзенчәлекләрен иҗатларында зур һәм мактаулы урын алган конкрет әдәби әсәрләре җирлегендә уңышлы ачып бирә алган. Бу җәһәттән автор аларны В. Быков, В. Распутин кебек танылган рус язучылары белән бер югарылыкта торучы әдипләр дип бәяли.

Әйтергә кирәк, китапта язучы Әхсән Баяновның индивидуаль стилен анализлауга багышланган махсус бер бүлек тә бар (*«Әхсән Баянов повестьларында әдәби герой»*). Ә. Баянов әсәрләрендәге фикер зирәклеге, хисләр байлыгы, ритмик кыскалык һ. б. биредә сәнгатьчә осталык үрнәге, әдип ирешкән уңышлар буларак бәяләнә.

Китаптагы һәр мәкалә бер сулыш, бер йотым белән укыла. Авторның үз әдәбиятын ихлас яратуы, аның уңышлары, сәнгатьчә ачышларын күреп ихлас сөенүе, аерым җитешсез якларын күреп көенүе һәм шуларны дөрес объектив бәяли белүе, гомумән, үз әдәбиятының чын патриоты булуы күренә.

Язучылар иҗаты белән генә чикләнмичә, хезмәтнең авторы «Проза әсәрләрендә әдәби вакыт һәм әдәби пространство» һәм «Жанр хәрәкәттә» дигән мәкаләләре, гомумән, әдәби процесска карата кызыклы күзәтүләре белән уйландыра. Китаптагы эстетик анализның рус һәм дөнья әдәби процессы белән бәйләп алып барылуы, фәнни стиле белән дә уңай тәэсир калдыра.

Ләкин ахырда бер генә битлек гыйльми йомгак бирелсә иде дигән теләк туа.

Кыскасы, М. Җәләлиеваның «Әдәбиятыбызның җырлы чишмәләре» дип аталган мәкаләләр җыентыгы—бүгенге әдәбият белеме үсешенә җитди өлеш булып керерлек фәнни хезмәт.

**Эльмира ГАЛИЕВА**

*Безнең календарь*

# ОЛУГ ЯКТАШЫМ, АВЫЛДАШЫМ

### МИФТАХЕТДИН АКМУЛЛАНЫҢ ТУУЫНА 170 ЕЛ

Шушы елның 14 декабрендә шагыйрь Мифтахетдин Акмулланың тууына 170 ел тула. Акмулла турында байтак кына мәгълүматлар булса да, аларның шактые каршылыклы һәм буталчык. Казакъ халкының бер үк чорда яшәгән Акмулла исемле ике шагыйре булган икән дигән ныклы фикер дә бар.

Мифтахетдин Акмулланың туган авылы Башкортстанның көньягында урнашкан Эстәрлебаш авылыдыр. Әтисе Мөхәммәдъяр исемле казакъ кешесе. Ул Эстәрлебаш мәдрәсәсендә укуын тәмамлагач, шунда хәлфәлек итә. Мифтахетдиннең әнисе Бибиөммегөлсем исемле татар кызы булган. Өммегөлсем чыгышы белән Эстәрлетамак каласында имам һәм ахун булган атаклы Сәлим хәзрәтнең кызыдыр. Аның әнисе Сәлим хәзрәтнең өченчегә алган яшь хатыны булган. Сәлим хәзрәт үзе борынгы, зыялы татарлар нәселеннән килә. Риза Фәхретдин хәзрәтләренең «Асар»ендә аның турында шундый мәгълүмат бар:

«Сәлим бине Рәхимкол, бине Урман, бине Капкай, бине Юлай, бине Кулай, бине Сөләйман, бине Тимри, бине Рәми, бине Ихсан». *(«Асарь», III том, 149 бит).*

Тимри бине Рәми Мәскәү каласында урыс дәүләте хезмәтендә толмач (тәрҗемәче) булган.

Сәлимнең Исмәгыйль бине Рәхимколый исемле бертуган абыйсы булган. Исмәгыйльнең улы Гәбделкәрим атаклы шагыйрь Дәрдмәнднең бабасы (Дәрдмәнднең әтисе Мөхәммәтсадыйкның әтисе була). Шулай итеп, булачак шагыйрь Мифтахетдин Акмулла әнисе Өммегөлсем ягыннан шагыйрь Дәрдмәндкә туган тиеш.

1778 елның сентябрь аенда Екатерина II фәрманы белән Мөхәммәт дине җәмгыяте идарәсе (Диния нәзарәтенә) ачыла. Һәм шул Диния нәзарәте беренче мөфти итеп урыс армиясендә капитан дәрәҗәсендә әфисәр булган Мөхәммәтҗан Хөсәенов куела. Мөфтинең атасы Хөсәен хәзрәт Эстәрлебаш мәчетендә имам булган.

Екатерина II үз ирекләре өчен һәм Казан ханлыгын кире торгызу максаты белән фетнә артыннан фетнә күтәреп сугышкан Казан татарларын ислам динен һәм мөселман руханиларын кулланып буйсындыра башлый. Урыска буйсынырга өндәп вәгазьләр укыган муллаларга мөфти тарафыннан махсус «указлар» бирелә. «Указной мулла» дигән төшенчә шул 1778 елдан соң барлыкка килә. Диния нәзарәте Русиянең эчке эшләр министрлыгына буйсынып, тулысынча Русия хөкүмәтенең сәясәтен уздыра. Бу кара эшнең башында беренче мөфти тора. Урыс сәясәтенә каршы чыгып, татар халкының иреге, ханлыгы өчен көрәшүче муллалар, ахуннар юк ителәләр. Аларны мәчетләрдән куалар, төрмәләргә тыгалар. Сәлим хәзрәт урыс колонизациясенә, православие диненең кысуларына һәм татар мөселманнарын чукындыруга каршы көрәшүче атаклы шәхес була. Мөфтигә указ алырга бармый һәм мәчет-мәдрәсәләрдә азатлык көрәшенә чакырып чыга. Сәлим ахун һәрчак мөфтинең урыслаштыру сәясәтенә каршы төшкән. Шунлыктан, юк сәбәпләрне бар итеп, мөфти Сәлим хәзрәтне мәчетеннән кудырып, төрмәгә яптыра. Сәлим хәзрәт фаҗигале хәлдә һәлак була. Ул үлгәч, ике олы хатыны өченче яшь хатынын 15 яшьлек кызы Өммегөлсем белән урамга куып чыгаралар. Бу кара эштә аларга Сәлимнең шул ике хатыныннан туган 14 малае ярдәм итәләр.

Сәлим хәзрәтнең дусты Эстәрлебаш мәдрәсәсе мөдәррисе, мәчетнең имамы Нигъмәтулла бине Биктимер, бине Тукай урамда калган абыстайны кызы Өммегөлсем белән Эстәрлебашка алып кайта һәм үз йортында сыендыра. Өммегөлсемне, буй җиткәч, казакътан булган Мөхәммәдъяр хәлфәгә кияүгә

биргәннәр. Шул никахтан булачак шагыйрь Акмулла Мифтахетдин туган.

Халыкта бер күзәтү бар: кеше туганда ук бәхетсез булса, гомере буена бәхетсез була. Акмулланың язмышы да туганнан алып үлгәнче фаҗигале.

Мифтахетдингә биш яшьлек чагында әтисе Мөхәммәдъяр вафат була. Әнисен, биш яшьлек Мифтахетдинне ияртеп, Дим буендагы Туксанбай авылына Камалетдин исемле башкортка өченче хатынлыкка бирәләр. Өч ел чамасы яшәгәч, сигез яшьлек Мифтахетдиннең әнисе Туксанбайда дөньядан китә. Малай үги әти һәм ике үги әни кулында кала . Һәм... качып Эстәрлебашка кайтып китә. Димнән алып Эстәрлебашка кадәр 70-75 километр. Сигез яшьлек малай шул юлны үткәнче ниләр генә кичермәгәндер...

Эстәрлебашка кайткач, Мифтахетдин мәдрәсәдә күн күрә һәм шунда унбер ел торып укый. Эстәрлебашка кайтуы 1839 елның иртә көзе булырга тиеш. Өс-башын карауны, тамак туйдыруны Мифтахетдиннең үзенә кайгыртырга туры килә. Ул баерак шәкертләргә аш пешерә, керләрен юа, йомышка йөри. Ә Эстәрлебаш—мәдрәсә-мәчетләре белән Көньяк Уралда, Урта Азиядә, Әстерхан, Ырынбур далаларында дан тоткан авыл. Авыл—галимнәре, китапханәсе, шагыйрьләре, чишмәдән уздырылган суханәләре белән (авыл халкы аны «Фонтал» дип йөрткән), ташчылары, балта осталары, тимерчеләре, итекчеләре белән дан тоткан. Хатын-кызлар тегүгә, чигүгә, асалы һәм чүпрәк паласлар сугуга бик маһир булганнар. Акмулла да тимер, балта эшенә остарган, итек-читек, киемне дә үзе теккән.

«Фонтал» турында. 1835 елның җәендә (авыл тау астында утырган) тау итәгеннән чыккан алты чишмәгә чаннар төшереп, шунда бик зурдан сужыйгычлар ясаганнар. Һәм озынлыгы 85 сантиметр имән һәм нарат агачларын махсус станокта тишеп, торбалар ясаганнар. Шул торбалардан агызып, авылның сигез урнына су үткәргәннәр. Икесе мин үскәндә дә бар иде. Җиргә казып, диаметры алты (!) метрлы, биеклеге өч метрлы чаннар күмелгән. Өсләре матур итеп тимер белән түгәрәкләп ябылганнар. Уртадан куелган 3-4 метрлы сырлап ясалган агач башына ярымай куелган. Суны шул «фонтал» эченнән агачтан ясалган пешкәк белән алалар иде. Элекке байлар, ишаннар бакчасында тагы торбадан агып ята торган урыннар булган. Урамдагы ике «фонтал» 1955 елга кадәр эшләделәр. Суы искиткеч салкын һәм тәмле иде. Минем уемча Эстәрлебаш «фонталы» бөтен Русиядә беренче төзелгән булырга тиеш.

Эстәрлебаш мәдрәсәсе 1720 елда эшли башлап, 1923 елга кадәр шәкертләр укыткан. 203 ел буена. Андый озын гомерле мәдрәсәләр Русиядә тагын бар микән? Акмулланың бәхетенә анда ике атаклы шагыйрь укытканнар: Шәмсетдин Зәки һәм Гали Чокрый. Яшь, сәләтле Мифтахетдин, бигрәк тә, тумыштан сукыр Шәмсетдин Зәки белән дуслашып киткән. Эстәрлебаштан өч чакрым чамасында көньяк-көнчыгышка таба Бакыр Чагыл исемле тау бар. Биеклеге 150 метр чамасы, ә текәлеге 70-75 градуслар булыр. Таудан бакыр ташы чыгарып тау астындагы мичтә бакыр эреткәннәр. Тау авыл ягына һәм көнбатышка текә булып карап тора. Сул ягы бүген дә куе каенлык белән капланган, каенлыкның көнчыгышында миләш бик күп. Тауның текә якларын, башын биек ак кылганнар каплаган. Тау башында һәрвакыт тымызык кына булып жил исә. Әллә кайлардан дала, тау исләрен алып килә ул жил. Менә шул тау башына менеп, Шәмсетдин Зәки, Гали Чокрый белән Мифтахетдин жил тавышын тыңлаганнар, исен иснәгәннәр һәм... бер-берсенә үзләренең шигырьләрен сөйләгәннәр. Ә табигать анда искитмәле матур, гүзәл, саф. Таудан уң якта куе урман җәелеп китә. Еракта, урман эченнән икенче тауның, Ак Чагылның шихан ташлы ак башы күренә. Тау астында Эстәрлебаш авылы урнашкан. Авылдан унгарак карасаң еракта-еракта Кайраклы таулары күгелҗем томан эченнән күренәләр. Уң яктарак ике тау тезелмәләре уртасыннан, Ашказар елгасын эзләп, Эстәрле ага. Аңа сул яктан Кайракы елгасы килеп кушыла, ә уң яктан Каенлы елга, Бакый Баткан һәм Гөмбәз елгалары. Ә Бакыр Чагыл тавы белән сул яктарак урнашкан Сәхәп тавы өсләрендә канатларын селкетмичә генә бөркет әйләнгәли—үзенә азык өчен корбан эзли. Һәм шул табигать кочагында өч атаклы шагыйрьнең шигырьләре янгырый. Әлегә Шәмсетдин Зәкинең билгесез шигырьләрен миңа табарга насыйп булмады. Ә Гали Чокрыйның бер шигырен таптым. Эстәрлебаш «фонталына» багышланган. Менә ул:

Агар чишмәне таулардан ничә һөнәр ярдәмендә
Китерде йортына; һәрчак саф, тонык су килеп тора.
Фәкыйрь мескен, гарип, мохтаж дус-иш,
Бары аннан саф су ала, күңелләрен сафландыра.

Мифтахетдин Акмулла 1850 елда Эстәрлебаш мәдрәсәсен тәмамлап китә. Ул чакта анарга 19 яшь була. Туксанбайга үги әтисе Камалетдингә әнисенең мирас малын сорап кайтканы мәгълүм. Тик үги әтисе аңа бернәрсә дә бирмичә чыгарып җибәрә. Эстәрлебашта туганнары юк. Бабасы Сәлим хәзрәт нәселенә дә кайтып сыенып кешесе булмый. Һәм Акмулла Мифтахетдин үз әтисе Мөхәммәдъярның нәселен эзләп, казакъ далаларына чыгып китә.

Шагыйрь Акмулла үзенең шигырьләрен өч тел кулланып язган: татар, казакъ һәм башкорт. Өч телне дә яхшы белгән. Акмулланы табигать биргән зур сәләте аркасында аның шигырьләрендә фәлсәфи уйлар, төрле хәлләргә, кешеләргә зирәк бәя бирүләр бик күп. Мәсәлән, ялган «дуска» бәя:

Саклансын данешмәнд[1] ир җаман дустан,
Надан дуст—бер айлык дуст, төбе—дошман.

Тагын:

«Җаман дуст—кара җылан!»—дигән мәсәл,
Җар булып, юха җылан җулдас булмас!
Җаманды күп үстерсән—өмид кисәр,
Хызырдын кадрен белмәс тинтәк исәр;
Залимдең зольме күп, күп симертсәнез,
Табактан эттең башы чурчып[2] төсәр;
Җаманды түрә кылсаң—йортын бозар,
Гакылсызны үстерсән—ботын сузар!

«Иң әүвәл кирәк нәрсә...» дигән шигырендә Акмулла асыл затлар өчен алты иң кирәк әйберне шигырь итеп санап чыга: иман, күңел, гакыл, шөкер, әдәб һәм сабыр.

Минем уйлавымча Мифтахетдин Акмулла иҗатын җентекләп, ныклап без татарга бик нык өйрәнү фарыздыр.



Акмулла 1895 елның 26 октябреннән 27 октябрьгә каршы төндә урман кырында шигырь язып утырган чагында арттан пычак белән чәнечеп үтерелә. Үтерүчеләр—Надиршаһ улы Дәүләтшаһ һәм Байморат улы Гафиятулла исемле башкортлар. Чиләбе янындагы Миас каласы зиратында җирләнгән. Дусты, Троицк каласы мәчете ишаны Зәйнулла хәзрәт аның каберенә таш куйдырган булган (ул таш урынында хәзер бүтән ташбилге). Бу язмада ташның фотосы һәм язуын бирүне тиеш таптык. *(Акад. М. Госманов фотосы).*

«Къәтле шәһидән сәнәти 1313 нче фи сәманийәти Җөмади—ел—уля фи ләйләтиул—җомга мелла Мифтахетдин әлмәгъруф би Акмулла ибне Мөхәммәдъяр хәлфә нәсәбән вә ибне мелла Камалетдин тәрбиятән. Тәммә, тәммә».

Бүгенгечә тәрҗемәсе:

«Шәһидләрчә үтерелгән, 1313 (һиҗри) елда сигезенче җөмадиел уләдә, җомга көнне кичен, Акмулла исеме белән билгеле, Мифтахетдин, нәсел буенча атасы Мөхәммәдъяр хәлфә, тәрбия буенча атасы мелла Камалетдин. Тәмам, бетте».

Урыны оҗмахта булсын!

**Зәки ЗӘЙНУЛЛИН**,
*М. Акмулла премиясе лауреаты*

---

[1]Данешмәнд—укымышлы.
[2]Чурчып—ыргынып, сикереп төшү.

# KİŅ QARAŞLI ƏDİP

SADRİ CƏLƏLNEŅ TUUINA 110 YIL

Anıŋ fotorəsemenə qarağaç, bu keşe—aqıl iəse, olpat şəxes, dip bəyələdem min. Anıŋ maqsatçan-uyçan qaraşında keşelek turında uylana belüe, keşelərneŋ bəxetle yazmışı əçen üzen cawaplı toyuı, başqalarğa ixtiramlı mənəsəbəte, xolqınıŋ nıqlığı sizelə. Mondıy bəyələr—Sadri Cələlneŋ ozaqqa suzılmağan ədəbi icatı, pedagogik eşçənlege belən də raslana.



Sadri Cələl (Sadretdin Xəyretdin ulı Wəlidov) 1891 yılda Apasta mulla ğailəsendə tua. Aŋa başlanğıç belemne ətise birə. Ul ğilemen mədrəsələrdə, xərbi uçilişçeda, Uçitel'skaya şkolada bayıta. Rabfakta həm səngət texnikumında tatar tele həm ədəbiatı uqıta, gəzitə-jurnal redaksiələrendə eşli, ədəbi əsərlər, şul isəptən, xəzer də yaratıp uqıta torğan «Dim buynda» romanın icat itə, rus yazuçıları M. Gor'kiy, D. Mamin-Sibiryak, A. Kuprin həm başqalarnıŋ əsərləren tatarçağa tərcemə itə, anıŋ publistikası da şaqtıy uq bay.

Yegermençe yəz başı ədəbiatın tirənten belüçe, Qazan dəwlət universitetı dotsentı Yaqub abıy Agişevnıŋ bezgə, studentlarğa, Sadri Cələlneŋ yaŋalıqqa omtıluçı ədip ikənlegen iskərtkəne buldı. Monı ul leksiədə tügel, ə leksiədən soŋğı «əstəmə dəreslər»də qızıqsınuıbızğa cawap itep əytte—uzğan ğasırnıŋ urtalarında S. Cələl icatı uqıtılmıy ide. Həm Yaqub abıy ədipneŋ icatına uŋay mənəsəbəte turında soŋınnan anıŋ saylanma əsərlərə cıyıntığına kereş süzendə tulıraq itep yazdı.

Ə Sadri Cələlneŋ onıtılıp toruı əlege də bayağı repressiə waqiğalarına bəyle. Ul 1931 yılnıŋ may ayı başında şifaxanədə dəwalanğanda qulğa alına, ğalim həm yazuçı Ğəli Rəxim həm tuğannan tuğan abıysı Camal Wəlidi (Camaletdin Cələletdin ulı Wəlidov) belən bergə, «soltanğəlievçelərneŋ Qazandağı yəşeren filialı»n təzüdə ğəyeplənə. Bu uŋaydan Sadri Cələlneŋ üzendə iŋ başta əytelgən sıyfatlarıŋ tərbiələwdə Camal Wəlidineŋ də yoğıntısı şiksez bulğandır. Çөnki, belgənebezçə, C. Wəlidi isə tirən belemle, kiŋ qaraşlı ədəbiatçı ğalim, tel belgeçe (ul 1927 həm 1929 yıllarda, qalın ike tom itep, üze təzegən «Tatar teleneŋ aŋlatmalı süzlege»n bastıra).

Biş yılğa suzılğan cəza srogın tutırıp qaytqanda, Sadri Cələlneŋ sələmətlege bik nıq qaqşağan bula (əstəwenə ul inde yarım suqıraya) həm yaqın tanışı professor L. Şulutko yərdəme belən genə massajçı bulıp eşkə urnaşa ala. Ləkin 1937 yılda anı qabat tərməgə yabalar. Xəle bətenləy əmetsezgə əylənəç, Plətən tərməsennən əyenə qaytarıp taşlıylar. Şunnan soŋ inde ul ozaq yəşi almıy: 1943 yılnıŋ 29 iülendə dənya quya.

Ğalim Y. Agişev Sadri Cələlneŋ qıŋqlap xikəyə həm fel'eton (süz gəzitə janrı tügel, ə ədəbi janr turında bara) yazuın əytkən ide, monı ul məqələsendə də iskərtə. Unbiş yıl çamasına ğına suzılğan icat çorı əçen bu miras az tügel. Anıŋ xikəyələreneŋ kimçeleklərə də bardır, ləkin bu xəzinə, berençe çiratta, uzğan ğasırnıŋ yegermençe yıllarında xikəyə janrın üsterüdəge əleş bularaq bəyələnergə tieş.

...Ədəbiatıbıznıŋ üseşenə ayırım yazuçılarnıŋ icatı aşa küz salğaç, ədəbi baylığıbıznıŋ zurlığına soqlanasıŋ.

**Məğsum XUCİN**

Uqucı süze
Укучы сүзе

## «Казан утлары» Уфага Таганрог аша килә

Нәкъ шулай. Ничәнче ел шулай дәвам итә. Дөрес, уку чираты минем гаиләгә соңлабрак «тәти». Быелгы өч сан нибары август башында алынды. Беләм, Таганрогта аларны берничә кеше укыган, журнал төпләре шактый тузган. Ул гына да түгел, һәр журналда «Коръән алынды», гафу ит» дигән искәртү язылган. Монысы эчне кырса да, түзәргә туры килә. Чөнки язылу хакы да, почта чыгымнары да миннән түгел...

Бертуганым Марат туган-үскән төбәгебезне 1963 елда ташлап киткән иде. Гаиләсе белән. Уңышлы төпләнеп, югары белем алды, «Прибой» исемле заводта цех начальнигы, бүлек начальнигы булып эшләп абруй казанды. «Безгә биредә үз исемеңне югары тоту өчен икеләтә-өчләтә артык көч салып эшләргә туры килә» дияр иде. Хәзер пенсиядә. Кызы, кияве белән берлектә зур йорт салып керделәр, мул яшиләр.

Марат туганым үз туган телен һич онытмый, классик язучыларның китапларын да укып яши. «Казан утлары»ндагы әсәрләрне икешәр кат укып чыга. Язучыларыбызның әдәби осталыгына, телебезнең байлыгына, журнал эшләнешенең югары камиллегенә сокланып туя алмый. Һәр бандерольдә миңа ике-өч журнал килә. Әсәрләрнең барысы да диярлек укылганлыгын карандаш белән тамгаланган ассызыклардан, искәртүле язулардан күреп торам. Башка укучыларның тырышлыкларын журналның таушалуыннан күреп була. Укыйлар «Казан утлары»н Азау диңгезе яр буендагы Таганрогта да.

Журналда нәрсәләр йөрәкне тетрәндерә, бәгырьне телгәли дигән сорау тууы ихтималын күздә тотып, шуны әйтәсе килә. Беренче чиратта Равил Фәйзуллин, Әгъдәс Борһанов, Фәүзия Бәйрәмова, Нәҗибә Сафина, Факил Сафин, Рәшит Галләмов, Мирза Мәхмүтов, Туфан Миңнуллин кебек фикер ияләренең публицистик чыгышлары. Гомумән, татарлык проблемалары, тарихи романнар, җан атып язылган шигырьләр күңелдә тирән эз калдыра. «Агыйделнең аръягында», «Ялгызак», «Иртәләгән сагыш», «Күңелем серләре», «Утлы дала» (авторларын язып торсам, сүз озынга китә) роман һәм повестьлары белән яраткан журналыбыз күңелләрдә гүзәл чәчәкләр үсәчәк буразналар сала. Шигъри шәлкемнәр, хикәяләр үрнәкләре турында да шуны әйтеп булыр иде.

Кулдан килгәнчә мин дә журналдан мул сирпеп алган гамәли һәм фикри байлыгым белән бүлешеп яшәргә тырышам. Аерым кешеләр белән булган әңгәмәләр белән бергә мәктәпләрдә, гимназияләрдә чыгышлар ясыйм һәм татарлык проблемаларын яктыртып, аңлатып барырга тырышам. Укучылар алдында гына түгел, укытучылар арасында да.

«Казан утлары»на мәхәббәт бүген-кичә туган нәрсә түгел. Без аны—журналны—иртә балачактан беләбез, даими укып киләбез, еллык бәйләмнәр (барысы да булмаса да), шөкер, саклана килә. Хәтеремдә, Ватан сугышыннан соң без, мәктәп балалары кич утырып «Совет әдәбияты»нда басылган заманча повесть һәм хикәяләрне тыңлый идек. «Ак төннәр» аеруча күңелдә тирән эз калдырган иде. Без үскән Котлыгужага (Гафури районы) бу журнал нинди юллар үтеп юлыга торган булгандыр, әйтүе кыен. Пионервожатыебыз Әкълимә апа Вахитова безгә аны бик теләп укып ишеттерә иде...

Сүземне тәмамлап, төп темага кайтам. Без киләчәктә дә «Казан утлары»ның аерылгысыз дуслары булып, Казан—Таганрог—Уфа арасын тоташтырып яшәргә ниятлибез. Журналыбызның якты йөзе, тирән мәгънәлелеге, актуальлеге саклаңачагына шигебез юк. Тик шунысы бераз эчне пошыра: тиражы һаман артмый. Шушы асыл белем, хис, гүзәллек чыганагыннан читтә калып яшәгән татар үзен ничек милләт вәкиле дип саный икән?

**Фәрит ВАХИТОВ,**
*Уфа*

# 2001 ЕЛДА ЖУРНАЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ


**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ**

2001 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләрен бирү турында. №6

«Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мактаулы исем бирү турында. №8

Россия Президентына хат. №5

**КАЗАННЫҢ 1000 ЕЛЛЫГЫНА**

Чал тарихлы башкала. *(Фаяз Хуҗин белән Алмаз Гыймадиев әңгәмәсе).* №5

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Фәйзуллин Р. Иман безне ташламасын. №1

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Әйди Т. Венада очрашу. *Бәян.* №5

Гыйльманов Г. Албастылар. Хыялый кыйсса. №№1, 2

Гыйматдинова Н. Аргы очта, бирге очта. *Повесть.* №11

Закир М. Өч хикәя *(М. Хуҗинның кереш сүзе белән).* №11

Зарипов М. Агымсу ташуы. *Хикәя.* №10

Зәнкиев Я. Өтелгән мәхәббәт. *Роман.* №№1—4

Зыя С. Булат һәм кызыл канат. *Хикәя. (М. Хуҗинның кереш сүзе белән)* №2

Зәйнуллин З. Иван дәдәй. *Хикәя.* №8

Маликов Ә. Тылсымлы хатлар. *Яңа әсәрдән өзек.* №№8, 9

Маликова М. Алтын ятьмә. *Повесть.* №7

Сабиров С. Алтын балдаклы абыстай. *Документаль повесть.* №10

Сабитов Г. Туган жир туфрагы. *Хикәя. (М. Шабаевның кереш сүзе белән)* №6

Садриев Ф. Бәхетсезләр бәхете. *Роман.* №№4—6

Сафин Ф. Саташып аткан таң. *Роман.* №№8, 9

Сафиуллин Ә. Җепнең очы. *Мажаралы повесть.* №7

Тимбикова К. Уртак яр. *Хикәя.* №6

Хәким З. Уйлар уйнавы. №1

Хөснияр З. Кышлаган үгез. *Хикәя.* №4

Хөснияр З. Терсәк сугышы. *Роман.* №12

Шиһапов И. Аклы-каралы гыйшык. *Сатирик кыйсса.* №11

Яхин Ф. Ат уены. *Хикәя.* №11

**ШИГЪРИЯТ**

Акъегет. Моңсу гына күңел бер җыр көйләр. *Шигырьләр.* №3

Афзал Г. Гамь төсмерләре. *Шигырьләр.* №5

Әгъләм М. Яңа гасыр керә. *Шигырь.* №1

Әхмәтҗан Рәш. «Ачлык мәйданы» китабыннан шигырьләр. №4

Әхмәтҗан Роб. Офыклар артында. *Шигырьләр.* №8

Әхтәмова Р. Сөяргә, сөелеп яшәргә. *Шигырьләр.* №12

Баян Ә. Тик бер юл илтә Тәңрегә. *Шигырьләр.* №9

Булатова К. Яңа елга—сәгать ярым... *Шигырьләр.* №12

Габдерәхим Ф. Мирасым бар. *Шигырьләр.* №7

Габиди Ә. Егет булса—җинсен, күкрәсен. *Шигырьләр.* №9

Галиев Ш. Яңа шигырьләр. №11

Гамбәр Н. Югалтырлык түгел... югалтмам. *Шигырьләр.* №1

Гаташ Р. Алтынмы, көмешме касәм... *Шигырьләр.* №3

Гыйззәтуллина Ф. Хаклык ихтыяры ача йөзне. *Шигырьләр. (Р. Гаташның кереш сүзе белән).* №9

Гыйләҗев И. Сагындырып төшеп исегезгә. *Шигырьләр.* №1

Дәүләтбаев Ф. Кыска шигырьләр. №11

Җиһангирова Ш. Иделемә төшеп сулар алам. *Шигырьләр.* №2

Зыятдинов Ф. Күзгә кояш тауга сыенганда. *Шигырьләр.* №12
Исхаков Ә. Сагыну көен җырлый күңел. *Шигырьләр.* №8
Каюмов М. Дастан. *Шигырьләр. (Р. Гаташның кереш сүзе белән).* №2
Кутуй Р. Киту. *Шигырьләр.* №8
Маннапов Ш. Шигъри вәхиләр. №9
Мингалим Р. Кылыч йөзе буйлап. *Шигырьләр.* №10
Мирза М. Әткән-әнкән фатихасы. *Шигырьләр.* №7
Морат Г. Илемне уйлап килешем. *Шигырьләр.* №8
Мөслимова Ф. Мәңгелек өн. *Шигырьләр.* №11
Мөхәммәтшин Г. Тургайларга иш булып... *Шигырьләр.* №10
Мулла Гали С. Таллар нидер тынлый бик тынып. *Шигырьләр.* №6
Мусин Ч. Үз җырым бар. *Шигырьләр.* №12
Низами Р. Кем шакый замана ишеген? *Шигырьләр.* №4
Рахман Р. Юрыйм яхшыга. *Шигырьләр.* №7
Рәхим Г. Димәк. *Шигырьләр.* №7
Рәхимова Б. Алтын-кызыл яшен яшьни күктә. *Шигырьләр.* №6
Рәшит Ә. Уртак булсын гамьнәр, борчулар. *Шигырьләр.* №4
Сафина Н. Ут белән су елгасы... *Шигырьләр.* №10
Сөләйман. Җиде күккә күтәрел дә... *Шигырьләр.* №6
Синугыл Ә. Фәрдләр. №11
Фәйзуллин Р. Яңа шигырьләр. №2
Фатыйхов В. Мин бит... *Шигырьләр.* №10
Харис Р. Хыянәт. *Поэма.* №5
Хәлим А. Меңьеллыклар арасында. *Шигырьләр.* №2
Шагыйрьҗан Л. Үз җанына үзең әнкә булсаң. *Шигырьләр.* №5
Шиһап Р. Утлы уем йөри каударланып... *Шигырьләр.* №11
Юзеев И. «Татар яши» дигән өйдән мин. *Шигырьләр.* №1
Янсуар Л. Барысы да—яратудан. *Шигырьләр.* №12
Яруллин Ф. Җыр башы. *Шигырь.* №4
Яруллин Ф. Кереп барам урманга мин. *Шигырьләр.* №6

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Зәйдулла Р. Хан һәм шагыйрь. *Тарихи риваять.* №7
Миннуллин Т. Шәҗәрә. *Драматик хикәя.* №12
Хәмид Р. Тигезәкләр. *Заман трагифарсы. (Илдар Юзеев кереш сүзе белән).* №10

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

Вәлиева Г. Тылсым. *Шигырьләр (Ф. Латыйфи кереш сүзе белән)* №1
Гарипова Г. Гөрләвек. *Шигырьләр.* №3
Зөлкарнәева Л. Йөрәк янгыры ява. *Шигырьләр.* №3
Уралия. Изге сүзләр. *Шигырьләр.* №3

**ДӨНЬЯ ШИГЪРИЯТЕ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ**

Байрон Д. Г. Төш. *(Лена Шагыйрьҗан кереш сүзе белән).* №11
Баласагунлы Й. Котадгу белек. Өзекләр. *(Ә. Синугыл тәрҗемәсе).* №6

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Шамов А. Кыз урлау. *Хикәя. (М. Хуҗинның кереш сүзе белән)* №3

**ДУСЛАР ҖЫРЫ**

Әлибай С. Бергә-бергә Идел кичәек. *Шигырьләр.* №2
Игебаев А. Вакыт тулпарын иярләп. *Шигырьләр.* №7

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Борһанов Ә. Урыс сөймәс җан түгелмен, мин—татар. №1
Таһиров И. Җиңү җинел яуланмый. *(Татарстанның бәйсезлеге өчен көрәш сәхифәләреннән).* №8
Измайлова Н. «Океанның аръягында...» №7
Юныс М. «Кәрәзле телефон» кирәзлеме? №4
Юныс М. «Чит җирләргә йөреп гыйбрәт ал...» №10

**ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ**

Латыйфи. Ф. Мәсләгебезгә тугрыбыз. №11

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Әхмәдуллин А. Әле нокта куймыйбыз. №7
Бәйрәмова Ф. Ак һәм кара көрәше. №12

Вәли-Баржылы М. Алмагачлар чәчәктә *(Яшь прозаиклар иҗаты турында уйлану).* №4

Галиева Г. Милләт каһарманы. №4

Галиева Г. Чын сәнгать әсәре булсын. №9

Госманов М. Жанрның язмышы һәм янаруы. №1

Гыйләҗев А. Өметләр уята торган әсәр. №12

Закирҗанов Ә. Яңа жилләр исәме? №6

Закирҗанов Ә. «Могикан»нар кисәтә. №10

Заһидуллина Д. «Албастылар» яки татар прозасында яна сыйфатлар. №11

Ихсанова Л. Сез кабызган утлар. №2

Макарова В. «Зур әдип әзер хакыйкать белән яши алмый...» №7

Сафин Ф. Хыянәтсез ижат. №6

Сибат Р. Хәтер һәм мәхәббәт. *Эссе.* №8

Сибат Р. «Йәгез, бер дога!» *Эссе.* №10

Урманче Ф. Гасырларны кичкән гүзәллек. №9

Хаков В. Сүздән чәчәк ясаганда. №8

Хатипов Ф. Рухи куәт. №5

XXI гасыр бусагасында. Әдәбиятыбыз кая бара? *(«Казан утлары» журналы редколлегиясенең киңәйтелгән утырышыннан).* №3

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫ

Галиуллин Т. Тукайны янадан укыйбыз. №4

Исхакый Г. Шагыйрь Габдулла Тукай. №7

Мусабәкова Р. Кешеләр арасында яшәп тә. №10

Рәмиев З. «Алтайлы» татар шагыйре. №11

## ЮБИЛЕЙЛАР

МИФТАХЕТДИН АКМУЛЛАНЫҢ ТУУЫНА 170 ЕЛ

Зәйнуллин З. Олуг якташым, авылдашым. №12

КАЗАН ДӘҮЛӘТ ПЕДАГОГИКА УНИВЕРСИТЕТЫНА 125 ЕЛ

Озын юл, нурлы юл *(Университет ректоры Рузәл Йосыпов белән әңгәмә).* №10

МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Шәрәфиев Р. «Мин синнән ераклармын, ераклармын, ераклармын...». №11

ҺАДИ ТАКТАШНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Гаташ Р. Үзгәрмәячәк мәхәббәт сүзе. *Эссе.* №1

ГОМӘР БӘШИРОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Бәширов З. Әдипнең мирасы. №1

КАВИ НӘҖМИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Ахунов Г. Әдипнең кинәшләре. №12

Бәширов Г. Замандаш турында берничә сүз. №12

Шабаев М. Күренекле әдип, җәмәгать эшлеклесе. №12

Шамов А. Кави Нәҗми—«артистка». №12

СӘРВӘР ӘДҺӘМОВАНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Ихсанова Л. Гасыр яшьтәше. №4

ХӘЙРЕТДИН МӨҖӘЙНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Мөҗәй Х. Шагыйрь кабере янында. *Шигырьләр.* №3

МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 95 ЕЛ

Мостафин Р. Җәлилнең билгесез рәсеме. №2

ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Вәли-Баржылы М. Ак чәчәктәй гомер. №12

СИБГАТ ХӘКИМНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Миңнуллин Р. Аккош күленең ак күнелле шагыйре. №12

ИБРАҺИМ САЛАХОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Минһаҗева Л. Язмыш хатасы микән? №8

ГАМИЛ АФЗАЛГА 80 ЯШЬ

Гаташ Р. Гамь һәм моң илчесе. №5

ЗӘКИ НУРИНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Гаташ Р. Зәки Нурины яд итеп. №12

ЮНЫС ӘМИНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Вәли-Баржылы М. Бергәлек бәхете. №11

ХИСАМ КАМАЛОВКА 75 ЯШЬ

Вәлиев М. «Мин чигенә алмыйм» №4

ӘЗһӘР ГАБИДИГӘ 75 ЯШЬ

Гаташ Р. Мәңге яшь хыял. №9

ШӘһИДӘ МАКСУДОВАГА 75 ЯШЬ

Бәйрәмова Г. Китаплы гомер. №11

РӘШИТ ГӘРӘЙНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Әхмәт Р. Матурлыгын мактап таңнарның. №4

РАФАЭЛЬ МОСТАФИНГА 70 ЯШЬ

Мостафин Р. Хәрби әсирләр иҗаты. №5

АДЛЕР ТИМЕРГАЛИНГА 70 ЯШЬ

Ант һәм өмет *(Язучылар А. Тимергалин һәм М. Хуҗин әңгәмәсе).* №1

РОЗА ХӘЛИУЛЛИНАГА 70 ЯШЬ

Сибгатуллина Т. Шәфкатьлелек. №6

РАДИК ФӘИЗОВКА 70 ЯШЬ

Хуҗин М. Туры юлдан. №6

НИЛ ЮЗИЕВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Хисамов К. Күңелдәге сурәт. №1

АЛЬБЕРТ ЯХИНГА 70 ЯШЬ

Кәримов К. Икенче юл. №11

ФОАТ САДРИЕВКА 60 ЯШЬ

Әмәк Ф. Елга ага да ага... №3

ФОАТ ГАЛИМУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

Хатипов Ф. Иҗле галим, төпле тәнкыйтьче. №3

РӘДИФ ГАТАШКА 60 ЯШЬ

Миңнуллин Р. Гаташның «шигырь шәрабе» №3

НУРИСЛАМ ХӘСӘНОВКА 60 ЯШЬ

Камалов Б. Тормыш кирпечләре. №3

РӘШИТ ӘХМӘТҖАННЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Фәйзуллин Р. Җанында давыллар иде. №4

РЕНАТ ХАРИСКА 60 ЯШЬ

Фәйзуллин Р. Заманга иш иҗат №5

ГӘРӘЙ РӘХИМГӘ 60 ЯШЬ

Галиев М. «Чын исеме Гәргәри...». №7

АКЪЕГЕТКӘ 50 ЯШЬ

Гамбәр Н. Тамчы күзендәге сурәтләр №3

ФӘИЗ ЗӨЛКАРНӘЙНЕҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ

Латыйфи Ф. Кеше китә—җыры кала... №12

Зөлкарнәй Ф. Сабыр төбе алтыным. №12

ӘХӘТ МУШИНСКИЙГА 50 ЯШЬ

Гамбәр Н. Очканында ни булса... №5

МАНСУР ШАһИМӘРДӘНОВКА 50 ЯШЬ

Юбиляр турында белешмә. №12

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ ЯҢАДАН АЧЫЛУГА 10 ЕЛ

«Мәгариф» гасыры. №5

**ФӘН**

Абилов Ш. Галишер Нәваи—төрки шигърият йолдызы. №2

Алишев С. Татар халкының дәүләтчелек өчен көрәш елъязмасы. №10

Ганиев В. XX йөз татар әдәбияты. *Тарихи-библиографик күзәтү.* №№2—6

Госманов М. Төрки-татар мәгърифәтчелек тарихында Исмәгыйль Гаспралы. №3

Зәйнуллин Җ. Гарәп илләрендәге тел проблемалары. №6

Миңнуллин К., Сөнгатов Г. Җырның ертыгы юк. №7

Мөхәммәтшин Р. Заман чатсысы. №5

Надиров И. Телен белгән—иленә юл табар. №10

Насыйбуллин И. Казан ханлыгының чикләре каян узган? №10

Таһир О. Финляндия татарларының алфавиты һәм орфографиясе тарихыннан. №10

Хәбипова З. «Идегәй» дастанында ил тоту һәм тәрбия мәсьәләләре. №4

Хәмидуллин Б. Таулы Алтай—төрки халыклар этногенезының бер үзәге. №6

**ТАРИХ**

Алишев С. Татар халкының дәүләтчелек өчен көрәш елъязмасы. №10

Гариф Н. Халкын олылаган олы галим *(Тарихчы-галим Фаяз Хуҗинга 50 яшь).* №8

Госманов М., Арсланова А. Бер гыйбрәтле тарихи хезмәт хакында. №9

Мәхмүтова А. Иж-Бубый мәдрәсәсенә 220 ел. №11

Миргалиев И. Әмир Мамай кем булган ул? №8

Миңнуллина Л. Татар календарьлары тарихыннан. №7

Насыйбуллин И. Казан ханлыгының чикләре каян узган? №10

Насыйров Т. Татар мөһаҗирләре матбугаты. №7

Хәбибуллин М. Хазарлар. №6

Хужин Ф. Болгар цивилизациясе—безнең мирас. №8

### СӘНГАТЬ

Закир М. Моң хикмәте *(җырчы, мөгаллим Миңгол Галиев белән әңгәмә).* №9

Ильясова Л. Җырлыйк Түмән көйләренә. №2

Җәмитов К. Нәрсә ул «Хөррият»? №5

Минлебаев К. «Исемсез» олуг исем иясе. №9

Миннуллина Ә. Щепкинчылар... №11

Монасыйпов Ш. Назлы моң *(Рөстәм Яхинның тууына 80 ел).* №10

Юсупова Р. Моң һәм тәүге мәхәббәт. *(София Гобәйдуллинага 70 яшь).* №10

### ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ

Коръән татар телендә. №№1—12

Госман Исхакый. Тугры юлга чыкканда. №11

Харис хәзрәт Салихҗан. Ислам вә хәят. №6

Дини бәйрәмнәребез һәм истәлекле көннәр. №2

2002 елда дини бәйрәмнәребез һәм истәлекле көннәр. №11

### ХӘТЕР

Маликова М. Марат абый. №3

Мөдәррисова Х. Кем уйлаган? №11

Хәсәнов Г. Язмышлар уртаклыгы *(М. Шабаев кереш сүзе белән)* №6

Хисамов Н. Күңелдәге сурәт. №1

### КИТАП КҮЗӘТҮ

Вәли-Барҗылы М. Америкада татар әдибәсе. №9

Вәли-Барҗылы М. Оя тойгысы. №8

Галиева Э. Җырлы чишмәләр. №12

Урманче Ф., Мәхмүтов Х. Чорлар кичеп кайтты безгә шагыйрь. №2

Шәмсиева Г. Кешеләрнең чын йөзе. №6

Шәяхмәтов Ш. Сафта калыр, сакта калыр! №2

### НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Корбан Р. Ватан. *Шигырьләр.* №2

Мингалимова А. Хикәяләр. *(М. Хуҗинның кереш сүзе белән).* №11

Нуретдинова А. Әкиятләр. №9

Солтан И. Яратам. *Шигырьләр.* №8

### ЮМОР-САТИРА

Баттал Ф. Сабакташлар. *Хикәя.* №2

Зарипов Р. Төш. *Шигырьләр.* №9

Кәримов К. Шаян хикәяләр. №10

Нәҗми Т. Хикмәтле хәлләр. №11

### УКУЧЫ СҮЗЕ

Вахитов Ф. «Казан утлары» Уфага Таганрог аша килә. №12

Насретдинов К. №8

Теләшов Р. Беренче татар дәүләте кайчан төзелгән? №9

### ЛАТИН ИМЛАСЫНДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР

Әсгать Ф. Батырлар. *Хикәя. (М. Шабаевның кереш сүзе белән).* №10

Гатауллина Л. Әсәрләрендә—якташлары. *(Хәниф Хәйруллинның тууына 70 ел).* №9

Кәрим Я. Бүгенге марш. *Шигырьләр. (Р. Гаташның кереш сүзе белән).* №6

Морат Г. Сабан туе. *Шигырь.* №6

Нәсин А. Өч фәрештәчекнең энисе. *Хикәяләр.* №5

Рәмиев З. Алтайлы татар шагыйре. №11

Солтан И. Яратам. *Шигырьләр.* №8

Такташ Һ. Мәңгелек әкият. *Шигырь.* №1

Хәким С. Давыл чәчәкләре. *Шигырь* №12

Хужин М. Киң карашлы әдип. *(Садри Җәләлнең тууына 110 ел).* №12

Тарихның хәтер йортлары. №3

Бер сорауга—бер җавап. №№5, 7

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№1—12

## Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### МӘСКӘҮДӘ МАТБУГАТ КҮРГӘЗМӘСЕ

Бөтенроссия күргәзмә үзәгендә «Матбугат-2001» күргәзмәсе булып узды. Анда республикабыздан 65 газета, журнал һәм китап нәшриятлары катнашты. Оештыру комитеты рәисе М. Ненашев республика журналистларының хезмәтен югары бәяләде.

### МӘШҺҮР ЯКТАШЫБЫЗ ФЕСТИВАЛЕ

20-22 октябрьдә Казанда дөньякүләм данлыклы композитор **София Гобәйдуллина** иҗатына багышланган халыкара фестиваль узды.

Фестивальдә Татар дәүләт филармониясенең симфоник оркестры, Казан консерваториясе һәм музыка училищесының җыелма хоры, Татарстан Республикасының кыллы квартеты, солистлар Р. Абдуллин, Г. Мөхәммәтдинова, Ю. Сокольская, Мәскәү коллективлары катнашкан—М. Пекарскийның бәрмә инструментлар ансамбле һәм Санкт-Петербург хоры, В. Гергиев җитәкчелегендәге Мариински театры оркестры катнашты.

22 октябрьдә композиторның яшьлеге үткән Тельман урамының 29 нчы йортында София Гобәйдуллина исемендәге заман Музыкасы Үзәге ачылды.

Күренекле композиторга «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде. Шулай ук, Татарстан башкаласында София Гобәйдуллина исемендәге конкурс үткәрергә дигән карарга килende.

### ҖАЕККА ҺӘЙКӘЛ БУЛЫП КАЙТТЫ

30 октябрьдә Казакъстанның Җаек (Уральск) шәһәрендә татар халкының бөек шагыйре **Габдулла Тукайга һәйкәл ачылды**. Һәйкәлнең авторлары—скульптор Мәхмүт Гасыймов, яшь архитектор Алмаз Галиев.

Бюст Казандагы «ВКНИИВОЛТ» эксперименталь-җитештерү заводында бронзадан коелды. Ул Җаек каласында Габдулла Тукай яшәгән йорт һәм булачак шагыйрь укыган мәдрәсә янындагы урында—үзәктәге Дуслык урамында урнаштырылды.

Һәйкәл-бюстны ачу тантанасында Көнбатыш Казакъстан өлкәсе хакиме Кырымбәк Кушарбаев катнашты һәм чыгыш ясады. Казаннан килгән кунаклар—Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Ренат Харис, олуг әдибебезгә күрсәтелгән зур хөрмәт өчен, Казакъстан җитәкчеләренә һәм халкына рәхмәт әйтеп чыгыш ясадылар, Г. Тукайның дөнья әдәбиятына керткән өлеше турында сөйләделәр.

Татарстан вәкилләре бирелдәге университет галимнәре белән дә очраштылар, татар җәмәгать оешмасында булды, Г. Тукайга багышланган рәсемнәр күргәзмәсен карады, бу тантанага олуг казах язучысы Әбҗәмил Нурпеисов җитәкчелегендәге Алматы каласыннан килгән бер төркем әдипләр белән аралаштылар. Зиратка барып, Г. Тукайның остазы Мотыйгулла хәзрәт кабере янында дога кылдылар, телевидениедән чыгыш ясадылар.

### ГАСПРАЛЫГА БАГЫШЛАП

Мәскәүдә төрки халыкларның бөек мәгърифәтчесе **Исмәгыйль Гаспралының** (Гаспринский) тууына 150 ел тулу уңае белән халыкара фәнни конференция булды. Ул Рәсәй сынлы сәнгать Академиясендә башланып, Мәскәүнең Карнеги Үзәгендә дәвам итеп, «Мемориал» халыкара кеше хокукларын яклау җәмгыяте бинасында тәмамланды. Конференциядә илледән артык кеше доклад белән чыгыш ясады.

Үз рефератларын Татарстан галимнәре дә тәкъдим итте. Э. Аетдинов «Гаспринский идеяләре яктылыгында хәзерге Рәсәйдә этникара мөнәсәбәтләр», Ф. Солтанов «Исмәгыйль Гаспринский һәм татар милли хәрәкәте», А. Мәхмүтова «Габдулла Бубый—И. Гаспринскийның дәвамчысы», Ш. Мөхәммәдьяров «Җәдитчелекнең татар историографиясе язмышына карата» һәм Д. Госманова «XX гасыр башында Рәсәйдә мөселман басмалары тиражы мәсьәләсенә карата» исемле докладларын укыдылар.

### ТОЛЬЯТТИДА КИТАП БӘЙРӘМЕ

Тольяттида татар мәдәнияте көннәре булып үтте. Аны Тольятти татарларының милли-мәдәни мохтарияте оештырды.

Танылган татар язучылары, ша-

гыйрьләре, нәшрият житәкчеләре һәм артистлары Тольяттидагы татар диаспорасы белән очрашты. Мәдәният көннәре кысаларында китап күргәзмәләре уздырылды. «Татар хикәясе антологиясе», «Такташ» альбомы, Гаяз Исхакыйның жыелма әсәрләре, Гомәр Бәшировның «Гыйбрәт» романы аеруча кызыксыну уятты. Мәдәният көннәрендә концертлар, татар телендә аудио һәм видеопродукция ярминкәләре оештырылды.

### ТӨРКИ ДӨНЬЯ ХАНЫМНАРЫ ЖЫЕНЫ

Октябрь уртасында Анкара шәһәрендә беренче мәртәбә төрки дөнья хатын-кызларының дуслык һәм хезмәттәшлек корылтае үтте. Төркия башкаласына «Төрек учаклары» исемле оешма чакыруы буенча 33 илдән 300 гә якын делегат килгән иде. Корылтайда катнашучылар 4 комиссиягә бүленеп эшләде, әдәп-әхлак, мәдәни чыганаклар, гореф-гадәтләрне саклау, жәмгыятьне пакьләндерү мәсьәләләрен тикшерделәр.

Татарстаннан корылтайда танылган язучы Фәүзия Бәйрәмова, Чаллының «Нур» гәзите журналисты Наилә Хөрмәтова, «Сөембикә» журналының жаваплы сәркәтибе Филисә Хәкимова һәм «Мөслимә» гәзитенең баш мөхәррире Әлмира Әдиатуллина катнашты.

Киләсе корылтай 2003 елда Кипрда үткәреләчәк.

### АКЫШ АРХИВЫ КАЙТАРЫЛДЫ

Республикабыз Милли архивына Алманиянең Мюнхен каласында яшәүче милләттәшебез **Гали Акышның** шәхси архивы кайтарылды. Заманында «Азатлык» радиосында эшләгән һәм Алман илендәге татар жәмгыятен житәкләгән бу күренекле шәхеснең архивы тарихи һәм библиографик яктан зур әһәмияткә ия. Ватаныбызга кайткан ядкарьләр арасында татар халкының мәшһүр шәхесләре Гаяз Исхакый, Йосыф Акчура, Садри Максуди, Фатих Кәрими, Габделбарый Батталга кагылышлы материаллар һәм документлар, Гали Акышның үз хезмәтләре һәм көндәлекләре, сирәк китаплар, чит илләрдә чыккан татар газета һәм журналлары тупланмәләре һ. б. бар.

### ТАТАРЛАР ТУРЫНДА КИТАП

Мәскәүнең «Наука» нәшрияты «Халыклар һәм мәдәниятләр» дигән китаплар сериясен бастырып чыгара. Ул **«Татарлар» («Татары»)** дигән яңа китап белән тулыланды. Бу китап «Руслар», «Белоруслар», «Украиннар», «Идел буе һәм Урал яны халыклары» дигән китаплардан соң бишенче китап булып тора. Н. Н. Миклухо-Маклай исемендәге Этнология һәм антропология институты әзерләгән жыентык татар халкының көнкүреше, хужалыгы, матди һәм рухи культурасы, шул исәптән, халык шигърияте һәм музыка ижаты, гореф-гадәтләре турында сөйли.

Урта Идел һәм Урал буенда, шулай ук Көнбатыш Себер, Әстерхан өлкәсе, Үзәк Россия, Төньяк Кавказда һәм башка төбәкләрдә яшәүче татарлар да китапта киң тасвирланган.

### ЛОНДОНДАГЫ КАЛӘМДӘШЕБЕЗ

Лондонда яшәп ижат итүче каләмдәшебез **Равил Бохараевка** 50 яшь тулды. Ул—Россия һәм Венгрия язучылар берлекләре, халыкара ПЕН-клуб әгъзасы. Хәзер Лондондагы Би-би-си радиосында эшли.

Октябрь ахырында Р. Бохараев Казанга кайтты. Юбилей кичәсе Казан университетында узды. Кичәдә юбилей уңаеннан «Мәгариф» нәшрияты тарафыннан чыгарылган «Бесконечный поезд» исемле китап та тәкъдир ителде. Шагыйрь Шәриф Камал музеенда булды, яңа әсәрләрен укыды.

### УЛ БЕЗНЕҢ МОҢСАР ИДЕ

Салих Сәйдәшев музеенда олуг татар композиторы (милләте буенча рус кешесе) **Александр Ключаревның** тууына 95 ел тулу уңаеннан «Туган жирем—Татарстан» дигән музыкаль кичә үткәрелде.

Анда Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Э. Жәләлетдинов, Татарстанның халык артистлары Ф. Хәсәнова, М. Әхмәтов, М. Галиев, Татарстан республикасы дәүләт квартеты, Татарстанның жыр һәм бию ансамбле чыгыш ясады, хор, вокал әсәрләре, А. Ключарев эшкәрткән татар халык жырлары яңгырады.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Татарстан республикасының милли китапханәсе.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Тәлгат Нәжмиев.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. **Әле без туганчы**.—Казан: Татарстан китап нәшрияты.—2001. 320 б. Тиражы—2000 данә.




Филология фәннәре докторы, профессор Фоат Галимуллинның бу гыйльми хезмәте XX гасыр татар әдәбиятының егерменче-утызынчы елларындагы хәлен һәм әдәби хәрәкәтнең шактый катлаулы халәтен ачып бирүгә багышланган. «Эстетик фикер һәм социологизм мөнәсәбәте», «Иҗат ысуллары һәм социологизм», «Өслүп хәрәкәте: аның асылы һәм алшартлары» дип аталучы өч зур бүлектән торган бу китапта моңарчы әдәбият белемендә читләтеп үтелгән бик күп әдәби әсәрләргә беренче тапкыр гадел бәя бирелеп, тиешле һәм мөһим нәтиҗәләр, гомумиләштерүләр ясала. Китап авторның кереш сүзе белән ачыла, ә ахырда галим хезмәтләренең тулы исемлеге бирелгән. Фоат Галимуллинның 60 яше уңаеннан чыгарылган бу китапта Ф. Хатиповның «Каләмдәшебез турында» дигән мәкаләсе дә урын алган.

Харрас ӘЮП. **Көй эзләү** *(Поэмалар, баллада)*.—Казан: Татарстан китап нәшрияты.—2001. 110 б. Тиражы—2000 данә.




Күренекле шагыйрь Харрас Әюпнең бу яңа китабына төрле елларда язылган поэмалары («Биш вакыт намаз», «Базарлар», «Су хәтере», «Йөрәк атым», «Көй эзләү», «Авыл жаны», «Көзге», «Гасыр чәчәге», «Кеше тавышы») һәм «Капка баганасы турында баллада»сы тупланган. Аларда автор халкыбызның үткәнен, бүгенгесен, киләчәген лирик-фәлсәфи уйланулар аша күздән кичерә, яңа буыннарны тормышыбызның рухи бөтенлегенә битараф булмаска чакыра.

Китап заманча полиграфик ысул белән сувенир басма итеп чыгарылган. Мөхәррире—Ф. Зыятдинова, рәссамы—Й. Вәлиәхмәтов.

Индекс 73210



Тәлгат Нәҗми

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)